# Хатыйп Миңнегулов

# Гасырлар өнен тыңлап...

Укытучылар, педагогия колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма

Казан • «Мәгариф» нәшрияты • 2003

УДК 82: 821.512.145
ББК 83 (2Рос=Тат)
М57

*Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства*.

**Миңнегулов Х.Й**.

Гасырлар өнен тыңлап...— Казан: Мәгариф, 2003.— 335 б.
ISBN 5-7761-1236-2

Әлеге китап авторның меңьеллык татар сүз сәнгате, аның аерым ядкярләре, проблемалары, үзенчәлекләре хакында уйлану-күзәтүләрен үз эченә ала. Җыентыкта Г.Тукай, Р.Фәхреддин, Г.Исхакый кебек олуг әдипләр турында да язмалар бар.

Китап тел-әдәбият укытучыларына, студентларга, галим-голямага һәм, гомумән, әдәби мирас белән кызыксынучыларга адреслана.

**Б3—11(70)—133—2004/2005**
ISBN 5-7761-1236-2 © «Мәгариф» нәшрияты, 2003

Үткәнгә күзе җиткәннең
Киләчәккә дә җитә.
*(Мәкаль)*

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫНА БЕР КАРАШ

*(Кереш сүз урынына)*

Сүз сәнгате, әдәбият — кешелекнең юлдашы, сердәше, рухи елъязмасы, остазы. Әдәбият һәм әдәп сүзләренең бер тамырдан булуы да юкка гына түгел. Чөнки аларның икесе дә шәхесне тәрбияләү, кешене кеше итү белән бәйле. Милли әдәбият халыкны бербөтен итеп тотуда, телне, гореф-гадәтләрне саклауда, хәтер дәвамчанлыгын тәэмин итүдә гаять зур роль уйный.

Татар сүз сәнгате, халкыбызның үзе кебек, озын һәм катлаулы юл үткән. Үзенең идея-сәнгати байлыгы, тәрбияви әһәмияте белән ул дөнья халыклары әдәбиятында мөһим урынны алып тора.

Татарның килеп чыгышы, яшәеше борынгы төрки тарихы белән тыгыз бәйләнешле. Шуңа мөнәсәбәттә аның XII—XIII йөзләргә кадәрге сүз сәнгате дә уртак әдәбият, уртак мирас итеп карала.

Төркиләрнең әдәбият тарихы мең ел ярымнан артык чорны үз эченә ала. Ул, борынгы әби-бабаларыбызның яшәү урыннарына, мәмләкәтләренә (Төрки каганлыклары, Бөек Болгар дәүләте, Хәзәр

патшалыгы, Уйгур, Сәлҗүк империяләре һ.б.) карап, Евразиянең зур мәйданнарында тарала, туран, рун, уйгур, гарәп графикалары белән языла. Ислам дине белән бергә безгә гарәп казанышлары да керә. VII гасыр урталарында башланган бу процесс соңгы дәвергәчә дәвам итә. Һәм, гомумән, мөселман дине халкыбыз тарихында, мәдәниятендә, аны мөстәкыйль кавем итеп яшәтүдә искиткеч зур роль уйный.

Рун, уйгур язуларындагы борынгы ядкярләр эчтәлекләре, жанрлары белән төрле: каберташ язмалары, дини текстлар, юридик документлар; оригиналь һәм тәрҗемә әсәрләр һ. б. Аларда төркиләрнең тарихына, тормыш-көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә хас кызыклы гына мәгълүматлар бар. Мәсәлән, кешенең җанын кош рәвешендә күзаллау, күкне олуг Тәңре дип уйлау һ. б.

XI йөздә борынгы төрки әдәбиятның күренекле ядкярләре языла. Мәхмүд Кашгарыйның зур күләмле «Диване лөгатет-төрк», ягъни «Төрки телләре сүзлеге»ндә (1072—1074) күп санлы мәкаль-әйтемнәр, шигъри текстлар, лексик берәмлекләр тупланган. Арада фикри яктан гаять тирән мәгънәле, сәнгати яктан югары дәрәҗәле үрнәкләр бар. Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» («Бәхет китабы») поэмасы (1069) — борынгы төркиләрнең бөек ядкяре, шигъри энциклопедиясе. 13 меңнән артык шигырь юлын эченә алган бу әсәр озак гасырлар буе тормыш дәреслеге булып хезмәт итте.

Урта Азиядә яшәгән һәм иҗат иткән Әхмәд Ясәви (1166 елда вафат була) һәм Сөләйман Бакырганый (1186 елда үлә) әдәбият тарихына һәм рухи тормышка бөек шагыйрь һәм суфый-философ рәвешендә кереп калганнар. Аларның әсәрләре татар мәктәп-мәдрәсәләрендә дәреслек, әсбап рәвешендә укыла, күп кенә шагыйрьләргә, шул исәптән Гафури һәм Тукайга, зур йогынты ясый.

Хәзәр, Болгар мәмләкәтләре — төрки-татар дәүләтчелек тарихының мөһим сәхифәләре. Бу чорда, аеруча Идел Болгарстаны дәверендә, мәгариф, фән, мәдәният шактый зур үсеш ала. Мәсәлән, Таҗеддин Болгариның дарулар ясау турындагы хезмәте (1220) Шәрык дөньясында да киң таралыш таба. Кол Галинең мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» дастаны (1212—1233) — Болгар чоры әдәбиятының бөек ядкяре. Анда, Йосыф сюжетына нигезләнеп, мәхәббәт, тугрылык, ата-ана һәм балалар мөнәсәбәте, сүз һәм гамәл берлеге һәм башка мәсьәләләр сәнгати гәүдәләнеш таба. Бу әсәр тууыннан алып хәзергәчә халкыбызның юлдашы булды, рухи тормышка гаять көчле тәэсир ясап килде.

XIII йөзнең урталарында төзелеп, XV гасырның урталарына кадәр яшәгән Алтын Урда дәүләте халкыбыз тарихында тирән эз калдыра. Бу чорда безнең әби-бабаларыбыз, ягъни хәзәр, болгар, кыпчак, татар кавемнәре, үзара керешеп, кушылып, татар халкын формалаштыралар, бу атама безнең даими исемебезгә әйләнә. Көнчыгыш Европаның һәм Көнбатыш Азиянең күп җирләрен биләгән Алтын Урда дәүләте дөньяның ул вакыттагы иң кодрәтле мәмләкәтләреннән берсе хисаплана. Ул күп кенә илләр, халыклар белән тыгыз бәйләнештә тора. Бигрәк тә Мисыр белән багланышлар көчле була. Чөнки анда Идел буеннан, Төньяк Кавказдан чыккан кыпчаклар («мәмлүкләр») идарә итә. Алтын Урдада, аеруча аның үзәге Идел буенда шәһәр тормышы алга китә. Илдә татар теле төп аралашу теле булып тора. Ислам — төп дин. Әмма башка диннәргә дә тулы ирек бирелә.

Кызганыч ки, Алтын Урда чорыннан безгә аз санлы ядкярләр генә килеп җитә. Әмма бар булганы да бу чор язма мәдәниятенең гаять бай, төрле икәнлеген күрсәтеп тора. Татар әдәбияты үзенең күп гасырлык үсешендә мөселман Көнчыгышы казанышларын мул файдалана. Алтын Урда чорында, мәсәлән, гарәп-фарсы классикларының әсәрләре оригиналда укыла, тәрҗемә ителә.

XIV йөз — төрки-татар әдәбиятының зур үсешкә ирешкән дәвере. Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия» («Пәйгамбәрләр тарихы»,1310), Котбның «Хөсрәү вә Ширин» (1342), Харәзминең «Мәхәббәтнамә» (1353), Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» («Оҗмах бакчаларына ачык юл», 1358), Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» (1369), Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» («Төркичә Гөлестан», 1391), «Сөһәйл вә Гөлдерсен» (1394) кебек мәшһүр әсәрләре — барысы да шушы гасырга карый. Аларда эпик, лирик, лиро-эпик планда, дастан, кыйсса, роман, хикәят, газәл һәм башка жанрларда кеше тормышының, инсаниятнең төрле проблемалары сәнгати югарылыкта гәүдәләнеш таба. Кешегә хөрмәт, аның әхлакый сафлыгы, иманлыгы, үз гамәле өчен үзенең җаваплы икәнлеге — бу чор сүз сәнгатенең асылы, төп мәгънәсе.

XV йөзнең урталарында, Алтын Урда таралып, аның җирләрендә Кырым, Әстерхан, Казан, Себер, Нугай, Олы Урда дәүләтләре, шулай ук Касыйм ханлыгы төзелә. Аларның төп халкын татарлар тәшкил итә, шуңа күрә бу мәмләкәтләрне еш кына татар дәүләтләре дип йөртәләр. Аларның мәдәнияте — Алтын Урда культурасының дәвамы. Бу чорда Хәсән Кайгы, Өмми Кәмал, Колшәриф, Шәрифи һәм башка әдипләр иҗат итә. Шәрифинең «Зафәрнамәи вилаяти Казан» («Казан мәмләкәтенең җиңүе», 1550) әсәре әдәби яктан гына түгел, тарихи җәһәттән дә игътибарга лаек. Анда казанлыларның Явыз Иван һөҗүмнәренә каршы батырларча көрәше тасвирлана. Бу язмада шулай ук Казанның матурлыгын, элек-электән ханнар шәһәре, мөселман каласы булуын мактаган шигъри юллар да бар. Бу чор әдәбиятының йөзек кашы,— әлбәттә, Мөхәммәдьяр иҗаты (1497—1549). Шагыйрьнең тууына 500 ел тулу 1997 елда

Татарстан һәм бөтен татар җәмәгатьчелеге тарафыннан зурлап бәйрәм ителде, әсәрләре дөнья күрде, аның хакында тамаша, кичәләр оештырылды.

XVI йөз урталарыннан татар халкы, дәүләтчелегеннән мәхрүм ителеп, колониаль изелү астында калды. Күп кенә кешеләре юкка чыкты, башка төбәкләргә күчеп, качып китте. Халкыбызга чукындыру, руслаштыру афәте килде. Ирек өчен көрәшләр җиңелү белән төгәлләнде. Әмма иман ныклыгы, ислам дине безнең әби-бабаларыбызны инкыйраздан саклап калды. XVII—XVIII йөзләрдә, мәгълүм сәбәпләр аркасында, әдәбиятның торышы түбәнәя. Күп кенә элекке ядкярләр юкка чыгарыла, яңалары аз туа. Бу гасырларда Мәүла Колый, Габди, Габдессәлам һәм кайбер башка шагыйрьләр иҗат итә. Әхлак, дин, суфыйчылык — аларның әсәрләрендә төп темалар. Мәүла Колый игенчелекне иң изге, иң олуг һөнәр дип саный, Габди ата-ананы хөрмәт итәргә чакыра. XVIII йөздә фарсы теленнән атаклы «Мәҗмугыл хикаят» тупламы тәрҗемә ителә. Анда мавыктыргыч сюжетлар, гыйбрәтле вакыйгалар бар.

XVIII һәм XIX гасырларны үзара тоташтыручы Габдерәхим Утыз Имәни (1754—1834), Таҗеддин Ялчыгол (1768—1838) иҗатлары шактый бай, күпкырлы. Алар халыкны белем-мәгърифәткә, әхлаклылыкка өндиләр, ызгыш-талашны, бозык гамәлләрне тәнкыйтьлиләр. Таҗеддин Ялчыголның атаклы «Рисаләи Газизә» әсәре (1805) Октябрь инкыйлабына кадәр күп мәртәбәләр басылып чыга, уку йортларында өйрәнелә. Дини-әхлакый, тәрбия мәсьәләләрен үз эченә алган бу китап белән хәзер янә кызыксыну артты: басмалары чыга, аның хакында мәкаләләр туа тора.

XIX йөз — татар тарихының, әдәбиятының милли уяну, билгеле бер үсеш чоры. Аны икенче төрле Мәгърифәтчелек дәвере дип тә йөртәләр. Бу гасырда күпләгән мәчетләр төзелә, мәдрәсәләр ачыла, китап басу алга китә; оригиналь һәм тәрҗемә әсәрләр туа, элеккеге рухи казанышларның бер өлеше торгызыла. Поэзиядә Әбелмәних Каргалый (1782—1833), Һибәтулла Салихов (1794—1867), Шәмседдин Зәки (1821—1865), Габделҗәббар Кандалый (1797—1860), Гали Чокрый (1826—1889), Акмулла (1831—1895), Әхмәд Кормаши (1855—1883) һәм башка шагыйрьләр иҗат итә. Аларның иҗатлары идея-тематик байлыгы һәм жанр төрлелеге белән сыйфатлана. Кандалый әсәрләрендә шәхеснең рухи халәте аеруча тулы бирелә. Шушы гасырда драматургия туа. Шиһабеддин Мәрҗани, Каюм Насыйри хезмәтләре татарның мәдәни, гыйльми дәрәҗәсен күтәрүгә сизелерлек өлеш кертәләр. XIX йөздә татар прозасы зур үсеш ала. Муса Акъегетзадәнең «Хисамеддин менла» (1886), Заһир Бигиевнең «Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (1887), «Зур гөнаһлар» (1890) романнары татар әдәбиятының реалистик нигездә үсешендә яңа этапны башлап җибәрәләр. Исмәгыйль Гаспралының «Тәрҗеман» газетасы — татар вакытлы матбугатының тәүге карлыгачы.

XX йөз башы — мең ел ярымлык татар әдәбиятының иң үскән, чәчәк аткан чоры. Аңа халкыбызның милли-азатлык өчен көрәше, татар телендә күп санлы газета-журналлар чыгу, татарча театр зур йогынты ясый. Әдипләребез, милли традицияләргә нигезләнеп, рус, Европа, Шәрык әдәби казанышларын иҗади файдаланып, төрледән-төрле әсәрләр тудыралар. Бу чор сүз сәнгатенең үзәгендә — милләт язмышы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге, башка кавемнәр белән мөнәсәбәте. Татар язмышы инсан яшәеше, аның уй-кичерешләре, эш-гамәлләре аша гәүдәләндерелә. XX йөз башында иҗат иткән татар әдипләре гаять күп: Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Мәҗит Гафури, Дәрдемәнд, Сәгыйт Рәмиев, Галимҗан Ибраһимов, Галиәсгар Камал һ. б. Боларның һәрберсе — теләсә кайсы әдәбиятны бизәрлек олуг затлар, иҗат ияләре. Октябрь инкыйлабына кадәр, аеруча XX йөз башында татар әдәбияты, татарча газета-журналлар дөньяның милләттәшләребез яшәгән һәр төбәгендә тарала. Шуның белән бергә, татарча китаплар, басмалар тугандаш төрки халыклары тарафыннан да теге яки бу дәрәҗәдә укыла. Мәсәлән, үзбәк шагыйре Гафур Голәм, төрекмән әдибе Бирде Кербабаев, казакъ классигы Сабит Муканов Тукай, Ибраһимов иҗатларына югары бәя бирәләр, алардан өйрәнүләрен искәртәләр.

Совет чорында татар әдәбияты, гәрчә аерым казанышларын юкка чыгарса да, билгеле бер дәрәҗәдә үсешен дәвам иттерде. Һади Такташ, Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким һәм башка шагыйрьләрнең иҗатлары күпләргә мәгълүм. Прозада Ибраһим Гази, Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Габдрахман Әпсәләмов, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәд Мәһдиев кебек әдипләр кызыклы гына әсәрләр тудырдылар. Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Хәй Вахит, Туфан Миңнуллин һ.б.— драматургиянең төп вәкилләре. Гаяз Исхакый, Сания Гыйффәт, Хәсән Хәмидулла, Хөсәен Габдүш, Минһаҗ Исмәгыйли, Исфәндияр Ишгай һ. б. Советлар Берлегеннән читтә, мөһаҗирлектә иҗат иттеләр. Аларның иҗатында XX йөз башына хас булган милли тематика уңышлы дәвам иттерелде һәм үстерелде. Хәзерге вакытта татар сүз сәнгате яңа бер милли уяну, күтәрелеш чорын кичерә. Аеруча тарихи проблемалар нык эшкәртелә. Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рабит Батулла, Әхмәт Рәшит, Флүс Латыйфи һәм кайбер башка әдипләрнең әсәрләрендә халкыбыз тарихының төрле сәхифәләре яктыртыла, үткәннәрне өйрәнү аша бүгенге һәм киләчәк тормыш турында уйланулар бәян ителә. Һәр кешенең, һәр буынның яшәеше үткән белән киләчәкне тоташтыра. Чөнки дөньяга килгән һәр адәм баласы, ул моны

телиме-теләмиме, үзенә кадәрге матди һәм рухи байлык белән эш итә, аны үз ихтыяҗларына туры китереп файдалана, үзгәртә һәм үзеннән дә бу мираска нәрсәдер өсти, вакыты җиткәч, ул байлыкны килер буыннарга калдырып, китеп тә бара. Тереклек яшәеше өчен хас булган бу төр диалектик дәвамчанлык аеруча рухи кыйммәтләр өлкәсендә мөһим. Биредә һәрнәрсә бер-берсе белән тыгыз бәйләнешле, бер-берсен тулыландыра, буыннар, чорлар арасында һәрчак диалогик мөнәсәбәт, бәхәс, сөхбәтләшү бара. Газиз телебезгә һәм әдәбиятыбызга гына игътибар итик. Аларда бит ничәмә-ничә гасырларда яшәгән миллионлаган әби-бабаларыбызның иҗади хезмәте, йөрәк тибеше, кайгы-шатлыгы, уй-кичереше, тереклек рәвеше, фәлсәфәсе теркәлеп, оешып, миләнеп калган. Тукай һәм Җәлил иҗатында без, мәсәлән, рун истәлекләренең, «Кыйссаи Йосыф»ның өнен, Кандалый шигъриятенең аһәңен ишетәбез, фольклорга хас лөгати матурлыкны, өслүб сыгылмалылыгын тоябыз. Шуңа күрә туган телне һәм әдәбиятны зиһенең хәзинәсенә әверелдерү, аларны саклау, үстерү һәм килер буыннарга тапшыру — гадәти эш-гамәл генә түгел, ә әби-бабаларыбыз алдындагы изге һәм тарихи бурыч та. Үз ихтыяры һәм җәмгыятьтәге хезмәт бүленеше белән рухи мирас өлкәсендә махсус эшләргә алынган һәр кеше бу хакыйкатьне, заруриятне һәм әхлакый вазифаны һәрчак күз уңында тотарга бурычлы. Без фәкыйрегез дә үзенең эзләнү-күзәтүләрен көче җиткән кадәр әнә шул юнәлештә алып барырга тырыша.

Мәгълүм ки, узган йөзнең соңгы дистә елы, нәкъ XX гасырның башындагы кебек, халкыбызның милли уяну, кузгалу, үзенең табигый хокукларын таләп итү чоры булды. Мондый тарихи вазгыять милли иҗат көчләренең, фән һәм мәгариф әһелләренең эшчәнлегенә дә уңай йогынты ясады. Милли тормышны чагылдырган күп санлы әдәби әсәрләрнең, монографияләрнең язылуы, кызыклы дәреслек-хрестоматияләрнең дөнья күрүе, дини китапларның нәшер ителүе — шуның ачык билгесе.

Күрәсең, халыктагы рухи күтәрелеш без фәкыйрегезгә дә тәэсир иткәндер. Шуның шифалы нәтиҗәсе буларак, соңгы 10—15 елда шактый гына мәкалә-хезмәтләр язылды. Шуларның зур өлеше рухи мираска, әдәбият тарихына карый. Шөкер Ходайга, ике гасыр аралыгында берничә монография, дәреслек дөнья күрде. Рус, төрек телләрендә дә басылган хезмәтләр бар. Ниһаять, 1999 елда Сәйф Сараи әсәрләрен туплап чыгаруга ирештем. 2001 елда Таҗеддин Ялчыголның зур күләмле «Рисаләи Газизә» китабын кереш мәкалә, тиешле шәрех-аңлатмалар белән «Иман» нәшриятында бастырып чыгардым. 1999 елда XX гасыр азакларында язылган мәкаләләрне, чыгышларны туплаган «Дөньяда сүземез бар...» дигән китабым дөнья күрде.

«Гасырлар өнен тыңлап...» китабында «Тукай энциклопедиясе» өчен әзерләнгән материаллар әле бер җирдә дә нәшер ителмәгән.

Җыентыкта, нигездә, соңгы 10 елда язылган мәкалә-чыгышларның бер өлеше туплап бирелде. Китапка моңа тикле монографияләрдә, җыентыкларда, дәреслекләрдә басылган материаллар кертелмәде диярлек. Көндәлек матбугатта дөнья күргән язмалар, кагыйдә буларак, үзгәрешсез калдырылды.

Китаптагы мәкалә-чыгышлар тематик яктан төрле. Аларда аерым әдипләрнең иҗатлары да, әсәрләренең идея-сәнгати үзенчәлекләре дә, рухи мирасның мөһим проблемалары да, әдәбият методикасы мәсьәләләре дә яктыртыла. Чынлыкта, вакыт ягыннан һәм тематик җәһәттән төрле булган бу материаллар меңьеллык әдәбият тарихын, аның үзенчәлекләрен, үсеш-үзгәреш тенденциясен, бәйләнешләрен, уку-укыту, өйрәнү серләрен билгеле бер дәрәҗәдә күзаллауга, милләтнең язмышын тарихи-мәдәни контекстта ачыклауга ярдәм итәрлек.

## «АРПАСЫЗ АТ АШУМАС»

*(Әдәби мирасны өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре)*

Төрки халыкларның, шул исәптән татарларның да олуг галиме Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» (1072—1074) китабында мондый мәкаль бар: «Арпасыз ат ашумас, арпасыз алп чәриг суемас», ягъни «арпасыз ат йөрмәс, терәксез (артында терәге булмаган) батыр чирүне (дошман гаскәрен) җиңә алмас». Бу юлларда халыкның акылы, яшәеш тәҗрибәсе гәүдәләнеш тапкан. Мәкальнең әһәмияте шунда ки, ул, туры мәгънәдән тыш, фәлсәфи, күпсыйдырышлы төшенчәләргә дә ия: рухи азыгы, артында таянырлык мәдәни терәге булмаган халык та ерак китә алмый. Ни өчен алманнар, японнар, инглизләр, шведлар яисә французлар бар яктан да алда? Чөнки алар матди мәнфәгатьләрен кайгырту белән беррәттән, элек-электән үк рухи байлыкларын үзләштерүгә һәм ишәйтүгә дә даими игътибар итеп килгәннәр һәм киләләр. Бу төр алдынгы халыклар, үзләрендәге рухи мирас белән генә чикләнеп калмыйча, башкалардагы, шул исәптән бездәге казанышларны да туплап, өйрәнеп, тиешлесен иҗади эшкәртеп, үз хәзинәләренә әйләндерәләр. Тагын шунысы да бар: агрессив сәясәт алып баручы хөкемдарлар үзләренә дошман дип санаган көчләрне, халыкларны тәмам буйсындыру, сыту өчен аларның рухи байлыкларын юк итәргә, хәтерләрен «пакьләргә» омтылалар.

Безнең халыкның якынча мең ел ярымлык дәүләтчелек һәм язу тарихы бар. Шушы вакыт эчендә ул гаять бай рухи мирас, интеллектуаль хәзинә туплаган. Әгәр дә мондый бай әдәбият, рухи байлык мөстәкыйль яшәүче башка халыкларда булса, алар бу чыганактан ничек файдаланырга, аны дөньякүләм ничек күрсәтергә белерләр иде! Кызганыч ки, без озак еллар буе үз байлыгыбызның бик аз өлеше белән генә эш иттек. Аның күпчелеге безгә йә бөтенләй билгесез булды яисә, русча әйткәндә, «мертвый капитал» рәвешендә кала килде. Хәзер әнә шул бинињая олуг хәзинәбезне бөтен тулылыгында барлау, өйрәнү, киң массага җиткерү, кыскасы, аның белән тыгыз мөнәсәбәткә керү, бу байлыкны милләтебезнең бүгенге һәм киләчәк үсешенә җигү, хезмәт иттерү вакыты җитте. Бу,—һич кичектергесез, безнең милли мөстәкыйльлегебезне турыдан-туры тәэмин итә торган бурыч; аның гамәлгә ашырылуы шактый дәрәҗәдә галимнәрнең, укытучыларның мәгариф системасы хезмәткәрләренең эшчәнлегенә бәйле.

Элеккеге рухи мирасның зур өлешен әдәби мирас, аеруча Тукайгача чор әдәбияты алып тора. Хәзер шуны өйрәнүнең кайбер методологик һәм методик мәсьәләләренә кыскача, атап китү рәвешендә генә булса да, тукталып үтәм.

Иң алдан ук шуны искәртергә кирәк: алдынгы халыкларның мәгариф нигезенә милли тәрбия бирү салынган. Бу аңлашыла да. Чөнки милли үзаңны үстерми торып, милләтне яшәтеп булмый. Әхлакый, эстетик һәм тәрбиянең башка төрләре бары тик туган телгә, мәдәниятkә, гореф-гадәтләргә, милли тарихка нигезләнеп алып барылганда гына нәтиҗәле була. Шунсыз манкортлык, милли нигилизм туасын көт тә тор.

Тел-әдәбият укытканда һәм гомумән педагогик процесста милли тәрбия бирү бары **халык** тарихы белән **тыгыз** бәйләнештә барганда гына нәтиҗәле була ала. Кызганыч ки, безнең тарихыбыз бозылып, имгәтелеп, өзек-көтек кенә өйрәнелгән. Күп кенә тарих китаплары, аеруча дәреслекләр татарга мәхәббәт түгел, киресенчә, нәфрәт тәрбияләүгә хезмәт итте һәм итә. «Татар» атамасы төрлечә сүгелә; «без—болгар», «без фәлән» дип кәпрәюләр, һәр татар баласы өчен ана кебек изге булырга тиешле «татар» исемен алыштырырга чакырулар күбәйде. Болар бар да татар тарихын белмәү, дөресрәге, белергә теләмәү галәмәте, аны сәяси максатларга, «олы туган» мәнфәгатьләренә буйсындырырга омтылу билгесе иде.

Мәгълүм булганча, халкыбызның борынгы тарихы, мәдәнияте гомумтөрки чор белән тыгыз мөнәсәбәтле.

Ерак Көнчыгыштан, Монголия далаларыннан алып Карпат тауларына, Дунай тамакларына кадәрге җирләр — борынгы төркиләрнең асыл Ватаннары. Биредә төрле күчешләр, үзгәрешләр, үзара керешүләр булып торган, төрле дәүләтләр (Төрки, Уйгур, Хәзәр, Болгар, Кимәк, Сәлҗүк, Кыпчак һ.б.) корылган, таралган. Менә шушы гаять зур төрки дөньясында V—XI йөзләрдә үк инде язма культура шактый зур үсеш ала. Моның сәбәпләре әлбәттә күптөрле: утрак тормыш, дәүләтчелек, сәүдә-һөнәрчелек шәһәрләре һәм иң мөһиме — башка илләр, халыклар (Кытай, Һиндстан, Иран, Византия һ.б.) белән бәгланышта тору, аларның рухи казанышларын үзләштерү һәм үзләреннән дә бирү…

Шунысы мөһим: безнең борынгы әби-бабаларыбыз күршеләренең олуг мәдәниятләре алдында югалып калмаганнар, үзләренең рухи культураларын үз нигезләрендә, үзләренчә үстерергә омтылганнар һәм зур гына уңышларга да ирешкәннәр.

Билгеле булганча, язу җәмгыятьнең эчке һәм тышкы ихтыяҗлары нәтиҗәсендә туа һәм үсә. Моның өчен халыкның иҗтимагый яктан чагыштырмача югары торуы да таләп ителә. Шуңа күрә тарихта бик сирәк кенә халыклар үз әлифбаларын булдыруга ирешкәннәр. Төркиләр исә нәкъ әнә шундыйлар рәтенә

керə дə. Алар гарəп язуын кабул иткəнче үк инде өч графика — туран, рун һəм уйгур əлифбаларын кулланалар… Борынгы төркилəр өчен билгеле бер дəрəҗəдə кытай, санскрит, еврей, латин язулары да чит булмый.

XII—XIII йөзлəргə кадəр төрле графикаларда язылган төркичə ядкярлəр — хəзерге төрки халыкларның уртак мирасы, милли əдəбиятларның нигезе, елга башы. Гомумтөрки əдəбияты дип исемлəнгəн бу кыйммəтле рухи хəзинəлəрнең традициялəре татар мəдəниятендə дə көчле ташкын булып күп гасырлар буена дəвам итə. Мəсəлəн, фикер-кичерешлəр синтезының тирəн диңгезе булган «Котадгу белек» поэмасында (1069) сүзнең, шигъри фикернең əһəмиятенə, үлемсезлегенə кат-кат басым ясала. Шуңа охшаш мотив Кол Галидə, Котбта, Харəзмидə, Мөхəммəдьярда, Акмуллада һəм башка татар шагыйрьлəре иҗатында күзəтелə. Муса Җəлилнең «…Сез (ягъни җырларым) үлсəгез, мин дə онытылырмын, Яшəсəгез, мин дə яшəрмен» дигəн юллары — традицион мотивның яңа шартларда дəвам ителеш формасы ул…

Күптəн түгел «Мирас» журналында (1993.— № 2) Х.Мəхмүтовның «Ташка язган җуелмас» исемле кызыклы гына мəкалəсе дөнья күрде. Анда автор рун графикасы белəн теркəлгəн мəкаль-əйтемнəрнең төрки-татарларда ничек дəвам ителешен күзəтə.

732 елда Күлтəгин хөрмəтенə куелган каберташ язмасында мондый юллар бар: «…өзим сакынтым: күрер күзем күрмəз тəг, белер белегем белмəз тəг болты». Ягъни «…үзем кайгырдым: күрер күзем күрмəс, белер белегем белмəс булды». Фольклор шигыренең матур бер үрнəге булган бу юллар, теге яки бу дəрəҗəдə үзгəреш алып, Идел буе ядкяре «Нəһҗел-фəрадис»та да (1358) кулланыла: «Күрер күзең күрмəс, тотар илкең (кулың) тотмаз, йөрер аягың йөрмəс, сөйлəр телең сөйлəмəс булгай…» Акмулла да, борынгы мирастан файдаланып, болай яза:

Бəла килсə, күрер күз күрмəз улыр,
Каза килсə, аяклар йөрмəз улыр.

…XII йөздə яшəгəн һəм иҗат иткəн Ясəви һəм Бакырганый — Октябрь инкыйлабына кадəр татар укучылары арасында бик мөхтəрəм һəм популяр исемнəр. Аларның əсəрлəре əүвəл кульязмаларда, аннан басма рəвештə гаять киң таралалар, мəктəп-мəдрəсəлəрдə өйрəнелəлəр. Ясəви һəм Бакырганый традициялəре безнең əдəбиятта көчле агым булып бара (Мəүла Колый, Ш.Зəки, Г.Тукай һ.б.).

Кыскасы, Борынгы һəм Урта гасыр əдəбияты хакында сүз барганда, аның Идел-Урал буйлары белəн генə чиклəнмəгəнлеген, гомумтөрки хəзинəгə барып тоташуын, ныклы мəдəни нигезе барлыгын, бай традициялəргə таянуын да истə тоту зарури. Бу исə əдəбиятны тарих белəн бəйлəнештə караганда гына мөмкин. Күп кенə чыганаклар һəм аерым галимнəр күрсəтүенчə, безнең төп əби-бабаларыбыз — болгарлар, хəзəрлəр, кыпчаклар һəм татарлар—борынгы төрки дөньяның сəяси һəм мəдəни тормышында мөһим роль уйнаганнар һəм «гомумтөрки» дип йөртелгəн мирасны тудыруга үзлəреннəн зур өлеш керткəннəр.

Тарих белəн бəйлəнеш аеруча Алтын Урда чоры татар əдəбиятын өйрəнү процессында мөһим. Əле күплəр безнең тарихны Болгар белəн генə чиклилəр. Алтын Урданың татар мəмлəкəте икəнлеген, андагы төп халыкның, телнең татар булуын танырга телəмилəр. Бу ялгыш фикерне җиңмичə торып, без татар тарихын тиешенчə торгыза да, дөрес итеп күзаллый да алмаячакбыз.

Күп кенə укытучылар бүгенге ихтыяҗларга җавап бирерлек дəреслеклəр, уку-укыту əсбаплары җитмəүгə зарланалар. Һəм бу урынлы да. Əмма шунысын да онытмаска кирəк: тормыш бик тизлек белəн үзгəреп тора (кайсы якка — анысы икенче мəсьəлə), фəнни фикерлəү еш кына чынбарлыктан арттарак та кала. Шуңа күрə дəреслеклəрнең өр-яңалары чыкса да (моңа кимендə ике еллап вакыт кирəк), алар барыбер безнең ихтыяҗларга тулысынча җавап бирə алмый. Нишлəргə соң? Хəзер «Мирас», «Татарстан», «Казан утлары», «Идел», «Мəгариф», «Ватаным Татарстан», «Шəһри Казан» һəм башка газета-журналларда тарихи үткəнебезгə, əдəбият тарихына мөнəсəбəтле күп санлы материаллар чыгып тора. Төрле нəшриятларда кызыклы гына китаплар да басыла. Əнə шуларны иҗади рəвештə файдалану, киң катлау укучыларга җиткерү — бүгенге көннең мөһим бурычы. Кызганыч ки, татар вакытлы матбугаты, андагы материаллар əле педагогик процесста йомшак файдаланыла.

Татар əдəбиятын укытканда, аның башка əдəбиятлар белəн реаль бəйлəнышын да исəпкə алу зарур. Дөрес, без моңа кадəр дə бу мəсьəлəгə игътибар иттек. Əмма ул берьяклырак барды: кирəксə дə, кирəкмəсə дə рус əдəбияты белəн элемтəлəргə басым ясалды, «өлкəн туган» əдəбиятының өстенлеге, остазлыгы күрсəтелде. Шуның нəтиҗəсендə, мəрхүм Нəкый ага Исəнбəт əйтмешли, татар əдəбияты рус əдəбияты арбасына тагылган дегет чилəге рəвешендə калды… Мин һич тə рус əдəбияты белəн бəйлəнышларны өйрəнүгə каршы түгел. Алар булган, бар. Рус əдəбияты соңгы гасырда безгə зур йогынты ясаган. Əмма шунысын ныклап истə тотарга кирəк: XX йөз башына кадəрге татар əдəбияты Шəрык классикасы, мөселман мəдəнияте белəн аеруча тыгыз бəйлəнышта торган. Дин уртаклыгы, сəүдə, икътисади, сəяси

мөнәсәбәтләр әдәби бәйләнешләрнең нигезен тәшкил иткән. Мәгарри, Фирдәүси, Низами, Гаттар, Руми, Сәгъди, Йуныс Әмрә, Әхмәди, Нәваи кебек гарәп, фарсы, төрки классиклары татарларның да яраткан әдипләре булганнар, аларның әсәрләре оригиналда да, төрле тәрҗемә-шәрехләрдә дә безнең әби-бабаларыбыз тарафыннан яратып укылган. «Кәлилә вә Димнә», «Мең дә бер кичә», «Тутыйнамә» кебек мәшһүр истәлекләрнең дә татар укучыларына яхшы таныш булуы мәгълүм. Элеккеге күп кенә әсәрләр («Кыйссаи Йосыф», «Кыйссасел-әнбия», «Хөсрәү вә Ширин», «Җәмигъ эт-тәварих», «Мәҗмугыл хикаят», «Мең дә бер сәхәр» һ.б.) Шәрык мәдәниятенә мөнәсәбәттә туганнар. Татар әдәбиятының поэтикасы, аеруча жанрлар һәм шигырь системасы үсешендә гарәп, фарсы классикасының роле гаять зур. Мәсәлән, Рабгузый, Харәзми, С.Сараи, Ш.Зәки, Г.Тукай, Н.Арслан, Р.Гаташ иҗатларында кулланылган газәл жанры генетик яктан Шәрык шигъриятенә барып тоташа.

Әхлакый тәрбия бирү — әдәбиятның һәм аны укытуның иң мөһим проблемасы. Бу мәсьәлә исә хәзер аеруча актуаль. Чөнки без күп кенә әхлакый байлыкларыбызны җуйдык яисә аңлы рәвештә читкә аттык. Шуның нәтиҗәсендә буыннар арасында өзеклекләр барлыкка килде. Хәзер исә халкыбызның әхлакый хәзинәсен торгызу, аны яшь буынга җиткерү процессы җанланып бара. Биредә элеккеге әдәби мирас, аеруча Урта гасыр һәм XIX йөз әдәбияты — менә дигән материал, чыганак. Чөнки рухи сафлык, әхлакый матурлык, сүз һәм эш берлеге, шәхескә хөрмәт — бу дәвер эстетик идеалының төп компонентлары. «Һәркем үз гамәле өчен үзе җаваплы», «дөньяда игү атың калырлык итеп яшәргә кирәк» — бу төр идеяләр элеккеге әдәбиятны буйдан-буйга ярып бара.

Үткән чорларның күп кенә әдипләре кешене рәнҗетүгә кискен каршы төшәләр, адәм балаларының табигый тигезлеген һәм хокукларын яклап чыгалар. Котб мәхәббәттә хакимиятнең, матди байлыкның әһәмияте юклыгына кат-кат басым ясый. Харәзминең лирик каһарманы сөйгән ярын — хатын-кызны иляһилаштыру дәрәҗәсенә барып җитә. Сәйф Сараи кеше белән итагатьле, әдәпле мөгамәлә кылырга чакырып, болай ди: «Әгәр дә син бер кешене рәнҗетсәң, аннан соң йөз яхшылык кылсаң да, ул рәнҗетү кеше хәтереннән китмәс. Тимер ук җәрәхәттән чыгар, әмма җөе калыр».

Янә бер мәсьәлә — ул да булса безнең өчен иң газиз, әмма хәзерге вакытта иң аянычлы хәлдә булган туган тел мәсьәләсе. Ул милли барлыгыбызның, милли мәдәниятебезнең нигезен, арка сөяген тәшкил итә. Ансыз милләт тә, безнең киләчәк тә юк. Шуның өчен татар халкының бәйсезлек, тигезлек, суверенитет өчен көрәшендә туган тел иң мөхтәрәм урынны алырга тиеш.

Татар язма теле искиткеч бай. «Гөлестан бит-төрки» авторы: «Җәваһир кыйммәте юк кян эчендә»,— ди (ягъни чыккан җирендә җәүһәрнең кадере юк). Без дә шуның кебек. Бай тел хәзинәбезнең без бит бик аз өлешен генә кулланабыз. Башкасы кала бирә.

Халкыбыз алга барыр өчен, Кашгарый мәкалендәгечә әйткәндә, аның арпасы да, арка терәге дә бар, җитәрлек. Безгә бу рухи хәзинәне, эчке энергияне хәзерге шартларда мөмкин кадәр тулырак, нәтиҗәлерәк файдалану зарури. Бары шул чагында гына без халыктагы милли-мәдәни наданлыкны җиңә һәм татарны милли яктан үстерә алырбыз.

*1993*

## ӘДӘБИЯТТА «ИГҮ АТ» МОТИВЫ

Игү аты калса ирнең йахшырак,
Соңра калгыйнча тулы алтун рәвак (сарай).

*Сәйф Сараи*

Адәм балалары дөньяга яратылганнан бирле үзләренең тереклек рәвешләре, яшәү мәгънәсе хакында уйланганнар. Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгән гомерне ничек итеп уздыру мәсьәләсе һәр инсанны, һәр кавемне, һәр дәвер җәмгыятен борчыган. Котбның атаклы «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә (1342) мондый юллар бар:

Янә сорды: «Бу йирдә ник йөрербез?
Ни йирдин без? Янә канда (кая) барырбыз?»[1]

XIX йөзнең бер шагыйре «Мәкәрҗә бәете»ндә (1860) болай ди:

Әгәр бер кемсәнә дөньяга килсә,
Ни өчен килдекене анда белсә,
Ходаем нә боерды — аны кыйлса,
Дәхи тыйганнардин ул тыелса[2].

Чынбарлыкка нисбәтән, ничек яшәү мәсьәләсенең сүз сәнгатендә гәүдәләнеп килүе табигый хәл. Чөнки әдәбиятның үзәгендә кеше, аның яшәү рәвеше. Мәгълүм ки, сүз сәнгатендә инсан нинди дә булса идеал яктылыгында тасвирлана. Ягъни адәм баласы нинди булырга һәм ничек яшәргә тиеш? Кеше нәрсәгә омтыла? Ул үзен һәм башкаларны, җәмгыятьне ни рәвешле күрергә тели?.. Мәсәлән, Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия» китабында (1310) легенда-риваятьләр, мифлар аркылы инсан яшәешенең төрле вазгыятьләре, холык-фигыльләрнең төрле типлары бирелә. Шушындый ук хәлне без Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә дә (1358) күрәбез.

Төрки-татар әдәбиятында яшәү мәгънәсе инсан идеалы белән тыгыз бәйләнештә, дөресрәге, аларның асылын белдерү рәвешендә «игү ат» калдыру мотивы еш гәүдәләнеп килә. Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» китабында (1072—1074) тормыш фәлсәфәсен чагылдырган «Әдгү ир сөңүке эрер, аты калыр» (Яхшы ирнең сөяге кабердә черер, исеме яшәр) мәкале теркәлгән[3]. Мәшһүр «Котадгу белек» (1069) авторы, үз укучысына дәшеп, болай ди:

Кеше тугды, үлде, сүзе калды, күр,
Үзе барды йаңлук, аты калды, күр
[Үзе киткәч тә (яхшы) исеме калды, күр]…

…Тереклек теләмә, ат әдгү (изге) телә,
Ат әдгү кирәк бу терекле (бу тереклеккә), белә.
Үзең үлгү (үләрсең), ахыр бу атың калыр,
Атың әдгү булса, тереклек татыр (тереклек татлыдыр)[4].

Йосыф Баласагунлы «игү ат» мотивын инсанның бөтен эш-гамәле, әхлакый асылы белән бәйли. Аның уенча, дөньяга килгән һәр адәм баласы белем тупларга, күркәм «кылкка» (холыкка) ия булырга, игелекле гамәлләр генә кылырга бурычлы. «Камил инсан» төшенчәсендә шагыйрь аеруча сүзгә, сөйләшә белүгә зур урын бирә. Чөнки тел кешене «нурлый» да, «бәхетле» дә итә, «очсызлый» да, «башын» да яра. Йосыф Баласагунлы һәм Урта гасырның күп кенә әдипләре аңлавынча, сүздә, бер яктан, инсанның холкы, мәдәнилеге күренә, икенче яктан, адәм хакында үзе исән чакта да, үлгәч тә төп хәбәрне сүз, тел җиткерә. Мәҗлиси: «Бу дөньяда сүзем калыр, үзем — юк»,— дип, юкка гына әйтмәгәндер.

XII йөз шагыйре Әхмәд Йүгнәки дә «игү ат» төшенчәсен белем, әхлак белән тыгыз бәйләнештә карый. Аның фикеренчә, белексезлек үлемгә тиң:

Белекле ир үлде, аты үлмәде,
Белексез исән иркән аты үлек
(Белексезнең исән чакта да, исеме үле)[5]…

«Кыйссаи Йосыф»тагы каһарманнар төрле холыклы, төрле сыйфатларга ия. Йосыф — сабыр, зирәк, гүзәл; Зөләйха — хисчән, максатка омтылучан; Ягъкуб — итагатьле, олы җанлы. Аларның эш-гамәлләрендә, үз-үзләрен тотышында инсаннарга, яшәешкә хас күренешләр, сыйфатлар гәүдәләнеш тапкан. Иң мөһиме шул: «Кыйссаи Йосыф»ның күп кенә геройлары, тормыш имтиханнары аша уза-уза, кимчелекләреннән арына, рухи яктан камилләшә бара. Зөләйха өчен мәхәббәт бар нәрсәдән өстен. Сөйгәне

белән кавышу юлында ул ата йортын, байлыгын, яшьлеген корбан итә, сукырая, фәкыйрь кала. Әмма аның мәхәббәте һаман сүнми, киресенчә, арта гына бара. Йосыфка, аның аркылы иляһияткә мәхәббәт Зөләйханы тагын да күтәрә, аңа карата хөрмәтне арттыра. Йосыф инсанда булырга тиешле һәм булырга мөмкин күп кенә күркәм сыйфатларга ия: белемле, әхлаклы, гадел, тугрылыклы һ.б. Ул кыенлыклар һәм рәхәтлекләр аша үзен халык белән идарә итүгә әзерли. Һәм Йосыф үзе куйган максатка ирешә дә. Хөкемдарлыкның мәгънәсен ул гавам мәнфәгатьләренә хезмәт итүдә күрә. Йосыф ахыр чиктә үлә. Әмма аның исеме, яшәү рәвеше башкаларга үрнәк, камил инсан символы булып кала; Йосыф факторы үзенең йогынтысын тагын да арттыра. Хәтта каһарманның табуты да илгә «муллык» китерә:

Мисыр эчрә йаулак үкүш (бик күп) нигъмәт улды,—
Ике йанга (һәр якта да) очызлык улыр имди[6].

Бераздан табутны Кәнганга «дәфен кыла»лар, ягъни җирлиләр. «Зийарәтә бу көн анда варырлар имди» («Бүген дә халык анда барып йөрер…»),— ди Кол Гали.

…Зиярәт кылу, кабергә йөрү — киң таралган гамәл. Мәсәлән, атаклы суфый шагыйрь Ясәвинең (1166 елда үлә) каберен зиярәт кылу ярты хаҗга баруга тиңләнгән. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» романында Фәрһад — бар яктан килгән зат:

Кыйлып күргәзгәй ул йөз төрле сәнгать,
Каю яндин тисәң — бар анда кувәт[7].

Кызганыч ки, һөнәрле, гүзәл, белемле, һәр эшне сәнгать дәрәҗәсенә җиткереп башкаручы, олы мәхәббәт иясе Фәрһад мәкер аркасында һәлак була. Ширин әмере белән аның кабере өстенә «гыймарәт», «хуш коббә» корыла.

Боерды кем: «Бу Фәрһадка гыймарәт
Кыйлың, ил халкына булсын зиярәт!»[8]

Зиярәт кылу, туры мәгънәсеннән тыш, күчерелмә мәгънәгә дә ия: игелекле затлар үзләренең эш-гамәлләре белән халык хәтеренә кереп кала, андыйлар үлемсез. XX гасырның бөек шагыйре Муса Җәлилнең «Эш күрсәткән ирне ил онытмас, Каберенә эзне суытмас» дигән юллары[9] — бу традицион хакыйкатьнең янә бер күркәм шигъри гәүдәләнеше. Автор шәхси батырлыгы, тиңсез фидакарьлеге белән үзе дә буыннар хәтеренә кереп калды.

Алтын Урда чоры шагыйре Сәйф Сараи (1321—1396) әсәрләрендә, Алланы онытмыйча, тормышны мәгънәле, нәтиҗәле уздыру хакында күп әйтелә. Әдип фикеренчә, кешеләр мәнфәгате өчен кылган хезмәт онытылмый.

Кем килде исә җәһанга, шәкк йук ки, китәр,
Гакыйл кәлибән (килеп), бу йирдә күб хәйр итәр.
Сән игелек ит, дәгый тиңизгә (диңгезгә) салгыл,
Йазыйда (далада) сәңа, йакын бел, ул хәйр йитәр[10].

«Игү ат» калдырырлык яшәү Сәйф Сараи идеалының да төп асылын тәшкил итә.

Йадкяре калса кемнең игү ат,—
Үлмәс ул ир,— кемдә булса бу сыйфат[11].

Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр да (1497—1549) әлеге мәсьәлә хакында Сәйф Сараи рухында уйлана:

Йийдер үтмәк (икмәк) кешегә, и никү (изге) зат,
Бакый калыр бу җәһанда йахшы ат[12].

Икмәк — игелек, яхшылык билгесе, тереклек символы. Икмәк ашату,— димәк, кешене яшәтү, аңа яхшылык кылу. Син шушы юлда икән, «игү ат»ың мәңгелеккә таралыр.

Мөхәммәдьяр «камил инсан» төшенчәсенең тулы бер сурәтле кодексын, системасын бирә. Халык күңеленә барып җитәрлек итеп тугры, гадел сөйләү («Сүзләмәкдә сән йөземне ак кыйл,— Сүзләреми ил күңлигә йомшак кыйл»), тәкәбберлектән йөз чөерү («Мәнмәнлек кыйлыб, мәнмәнлек сатмаңыз, Онга — кибәк, серкәгә су катмаңыз»), ваемсыз булмау («Гафләт илә Тәңрене табмас кеше»), авыр хәлдә калучыларга ярдәм итү («…егылганда кулын тот моңлының, Ул тәкый тоткай кулың бер көн сәнең»), яманлыктан ерак тору («Йахшылык кыйл, йахшылыкда — бар мәза, Кем йаманлык кыйлса — табгай җәза»), нәфескә бирелмәү, яманлыкка яхшылык белән җавап бирү («Йаманлык кыйлгучыга кыйлма йаман, Йахшылык кыйл аңа, әгәр булсаң, һәр заман»), олы һәм кечеләрне хөрмәт итү («Олугны олугдыр тиб гыйззәт иткел, Кечеккә рәхим итеб хөрмәт иткел»), гаделлекне тереклекнең нигезенә салу («Гадел берлә бу

җиһан мәгъмур ирүр, Гадел берлә уш җиһан пөр нур ирүр»; «Гадел берлә ил гыймарәт булыр уш») һ.б.— идеал яшәү рәвешенең һәм игелекле инсан төшенчәләренең төп сыйфатлары.

«Игү ат» мотивы Утыз Имәни (1754—1834) игътибарыннан да читтә калмый. Ул да бу мәсьәләне, Мөхәммәдьяр кебек, камил инсан, үрнәк эш-гамәлләр һәм хосусиятләр яссылыгында карый. Шагыйрь фикеренчә, кешене үлемсез итүнең төп шарты — белемлелек:

Мәңге яшәргә теләсәң, и угыл,
Ал гыйлем, чөнки тереклек суы ул…
Ал гыйлем, чөнки яшәүнең аслы шул,
Хәл итә барлык кыенлыкны тик ул…
Килсә дә үлем, галим үлми һаман,
Үлеме килгәнче үк үлә надан[13].

Утыз Имәнинең гыйлемлелекне беренче планга куюы, бер яктан, элеккеге әдәби традицияләр тәэсирендә булса, икенче яктан, шагыйрь яшәгән чорда белем-мәгърифәт идеяләренең гаять активлашып китүе белән дә аңлатыла. Юкка гына XIX йөз сүз сәнгатен мәгърифәтчелек әдәбияты дип йөртмиләр. Утыз Имәни исә моңа үзеннән гаять зур өлеш керткән әдип.

К.Насыйриның «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» китабындагы бер хикәяттә мондый юллар бар: «Егет — егет түгелдер, әгәр дә аның күләгәсе белән берәү дә күләгәләнмәсә һәм җир йөзендә аның эзеннән берни дә калмаса. Берәү вафат булып, үзеннән соң бер истәлек калса, кешеләр каршында ул кеше мәет түгелдер»[14]. Күрәсез: биредә дә үзеңнән соң эз, «игү ат» калдырырлык итеп яшәү хакында сүз бара.

Ясәви, Бакырганый, Өмми Кәмал, Колшәриф, Мәүла Колый, Шәмседдин Зәки кебек дини-суфыйчыл әдипләр «игү ат» калдыруның төп шарты итеп Аллага бирелүне, аңа гыйшык тотуны, мал-мөлкәт, хакимият артыннан кумыйча, хәләл ризык белән яшәүне саныйлар. Алар карашынча да, белемсез кеше үлек кебек. Чөнки ул динне дә, Коръәнне дә танып белә алмый. Надан сүзен ничек, кайсы яктан укысаң да, һаман надан булып кала.

Суфый шагыйрьләрдә бу (фани) һәм теге (бакый) дөнья тормышын каршы кую, беренчесен төрлечә түбәнәйтү, икенчесен идеаллаштыру көчле. Алар, гомумән, кешене теге дөньяга мөнәсәбәттә, инсан гомерен аңа хәзерлек рәвешендә, символик перспективада тасвирларга яраталар.

Урта гасыр һәм XIX йөз рухи тормышында, сүз сәнгатендә «игү ат» белән инсаннар хәтеренә кереп калган аерым затлар да бар. Бу,— иң беренче чиратта, Алланың илчесе Мөхәммәд пәйгамбәр. Аның холык-фигыле, эш-гамәлләре камил инсанның өлгесе, үрнәге рәвешендә карала. Госманлы әдибе Языҗ-углының «Мөхәммәдия» әсәрендә (1449) пәйгамбәр образы шактый тулы гәүдәләнеш тапкан.

Таҗеддин Ялчыгол (1768—1838) үзенең «Рисаләи Газизә» әсәрендә Мөхәммәд пәйгамбәрне «Ходаның дусты», «падишаһлар падишаһы», «диннең чырагы», могҗиза иясе, «дөнья халкын тугры юлга күндерүче» дип атый. «Пәйгамбәремез кеби пакь гәүһәр юктыр көллә (барлык) җанлар эчендә»,— ди автор. Аның «кайгусының олугы — өммәт (ягъни халык) кайгусыдыр»[15]. Нәкъ менә шуңа күрә дә ул халык хәтеренә олуг зат буларак кереп калган.

Шәрык сүз сәнгатендә, шул исәптән татар әдәбиятында «игү ат» белгән мәшһүр башка шәхесләр дә билгеле. Шундыйларның берсе — Ибраһим Әдһәм (VIII йөз). Ул әүвәл Үзәк Азиядәге Бәлх мәмләкәтенең хөкемдары була, бал-майда йөзә, кәеф-сафа кора. Әмма бераздан үз ирке белән тәхетен, байлыгын ташлый, тәүбә кыла, изге кеше, атаклы суфый булып таныла. Ибраһим Әдһәм Шәрык һәм татар әдәбиятларында, хәтта XIX йөз шагыйрьләре Әбелмәних Каргалый һәм Габделҗәббар Кандалый әсәрләрендә дә гәүдәләнеш тапкан. Ул — һәр кеше, әгәр дә тели икән, үзенең яшәү рәвешен үзгәртә, үзен рухи яктан пакьли ала дигән идеянең җанлы бер образы. Элеккеге әдәбиятта Локман Хәким акыллылык, Искәндәр Зөлкарнәйн, Нәүширван мәгърифәтле, гадел хөкемдар символы буларак мәшһүр.

Мәгълүм ки, сүз сәнгате еш кына булырга мөмкин нәрсәне бар, күрергә теләгәнне чынбарлык рәвешендә дә тасвирлый. Әдәбиятның бу хосусияте касыйдә, мәдхия, мәрсия кебек мактау (панегирик) жанрларының асыл табигатен билгели. Мәсәлән, Мөхәммәдьяр сурәтләвендәге Сәхибгәрәй хан — идеаль хөкемдар. Ул гадел, көчле, белемле, зирәк. Шагыйрь аны «галәм шаһы», «ханнар ханы» дип атый («Шаһи галәм, дөньяда ханлар ханы»)[16]. Сәхибгәрәй хан вакытында илдә утопик җәмгыятькә туры килешле иминлек, «рахәтлек» урнаша:

Рахәт эчрә ил-улус булды камуг (барысы),
Имди тынды дөньяда кечек-олуг[17].

Шуңа күрә дә бу ханның игелекле аты дөньяга тарала.

Гадел берлә чыкты шаһи атыңыз,

Дөньяда пайәндә булсын (яшәсен) затыңыз[18].

Яшәеш, үлем-тереклек, «игү ат» мәсьәләләре аеруча мәрсия жанрында зур урын били. Кеше туа, яши, үлә, ул — бу җирнең кунагы гына. Мәрсияче шагыйрь аның гомер юлын, гомумән, вакыт агышы, инсаният язмышы белән тыгыз мөнәсәбәттә карый, үзенең камил инсан турындагы уй-хыялларын да теге яки бу дәрәҗәдә искә төшереп ала. Утыз Имәни мәрсияләрендәге Хәмидә шәфкатьле ана, уңган хатын, олы җанлы инсан буларак күзаллана. Ул үзе китсә дә, дөньяда аның эзе калган. Хәмидәнең якты образы ире, балалары, якыннары күңелендә яшәвен дәвам итә.

Акмулланың мәшһүр мәрсиясендә Мәрҗани камил инсанның, «игү ат» калдырырлык яшәүнең классик өлгесе, «тиңсез» мисалы рәвешендә сурәтләнә:

Караңгыда фанусны («утны») кабызган ул,
Кайнар сөткә сары майны тамызган ул…

…Болагы — саф, чәйгә һәркем су алгандай,
Халыкка чүлләгәнләр куангандай…

…Дәрденә дәрдемәндләр шифа тапды,
Сукырлар күзен ачды карманмастай[19].

Мәрҗанинең үлемен автор болай сурәтли:
Качан ул зат китеп барды,
Казан күрке китеп калды,
Һәммә әхбаб (дус-ишләр) йәтим калды,—
Җөда булдык, дәрига, аһ[20]!
(Аерылдык, аһ, ни кайгы.)

Заһир Бигиев (1870—1902) — татар әдәбиятына реалистик эчтәлекле тәүге романнар биргән автор. Аның «Мавәраэннәһердә сәяхәт» исемле юлъязмасы басылу уңае белән, Г.Тукай «Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә» исемле мәрсиясен иҗат итә (1908). Бу вакытта инде әдипнең үлүенә берничә ел үткән. Әмма аның әсәрләре укыла, исеме яши. Татар җәмәгатьчелегенең Заһир Бигиевкә мөнәсәбәтен Тукай шигырь юлларында гәүдәләндерә. Анда мондый строфа да бар:

Гәрчә «үлде» дисәләр дә, син бөтенләй үлмәдең;
Яхшы исмең калды, син мәнсийү мәтрүк улмадың
(онытылмадын)[21].

Лев Толстойның «В чем моя вера?» исемле тирән эчтәлекле фәлсәфи-публицистик язмасында (1883) мондый юллар белән очрашабыз: «Я умру так же, как и все, так же, как и не исполняющие учения (сүз дини өйрәтмәләр турында бара); но моя жизнь и смерть будут иметь смысл и для меня, и для всех. Моя жизнь и смерть будут служить спасению и жизни всех…»[22] Биредә мәгънәви яшәү, мәгънәви үлем хакында сүз бара. Ягъни синең тереклегең, синең вафат булуың, синең исемең — шәхси күренеш кенә түгел, ә иҗтимагый, гавами, гомуминсани фактор. Мәшһүр тюрколог, милләттәшебез Рәшит Рәхмәти («Казанлы») үзенең Ризаэддин Фәхреддин үлеме уңае белән язылган мәрсияви мәкаләсен мондый юллар белән тәмамлый: «…Риза Казый безнең өчен «үлмәс үлүләрнең» берседер. Үзен мәңге яшәтәчәк эзләр калдырмышдыр…»[23]

Абдулла Алишка багышлап иҗат иткән «Дуска» шигырендә тоткынлыкта газап чиккән М.Җәлил, яшәү һәм үлем хакында уйланып, үлемнең дә тереклеккә ярдәм китерүе, иҗтимагый яңгырашлы булуы турында искәртә:

…Билгеләми гомер озынлыгын
Еллар саны, картлык җитүе,
Бәлки, менә шушы үлем безгә
Мәңге бетмәс яшәү китерер?!

…Чикләнсә дә гомер, яшьлек безнең
Эзсез сүнә, диеп уйлама!
Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда[24].

Кыскасы, «игү ат» калдырырлык итеп яшәү идеясе элек-электән әдәбиятыбызның үзәгендә торган. Бу традицион мотив бүгенге һәм киләчәк көннәребез өчен дә актуаль калачак.

[1]Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары.— Казан: КДУ нәшрияты, 1981.— 138 б.
[2] Татар мәгърифәтчелек әдәбияты.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1979.— 6 б.
[3] Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары.— 19 б.
[4] *Х.Й.Миңнегулов*. Татар әдәбиятыннан хрестоматия (9 нчы сыйныф өчен).— Казан: Мәгариф, 1995.— 13, 16 б.
[5] *Х.Й.Миңнегулов*. Әдәбият (9 нчы сыйныф өчен дәреслек).— Казан: Мәгариф, 1994.— 31 б.
[6] *Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф…— Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.— 291 б.
[7] Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары.— 98 б.
[8] Шунда ук.— 45 б., 111 б.
[9] Татар поэзиясе антологиясе.—II китап.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.— 61 б.
[10] *Сәйф Сараи*. Гөлестан. Лирика. Дастан.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.— 266 б.
[11] Шунда ук.— 45 б.
[12] *Мөхәммәдьяр.* Нуры содур…— Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.— 78 б.
[13] Татар әдәбиятыннан хрестоматия (9 нчы сыйныф өчен).— 153, 154 б.
[14] *Каюм Насыйри.* Фәвакиһел-җөләса… //Мирас.— 1995.— # 7—8.— 38 б.
[15] Рисаләи Газизә… //Мирас.— 1998.— # 11.— 22—23 б.
[16] *Мөхәммәдьяр.* Нуры содур…— 173 б.
[17] Шунда ук.— 222 б.
[18] Шунда ук.— 173 б.
[19] *Акмулла*. Шигырьләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.— 60, 83 б.
[20] Шунда ук.— 87 б.
[21] *Габдулла Тукай.* Әсәрләр: Дүрт томда.I том.— Казан: Татар. кит. нәшр, 1975.— 214 б.
[22] *Л.Н.Толстой*. Полное собрание сочинений: Серия первая. Произведения.— Т. 23.— М.: ГИХЛ, 1957.— С. 402.
[23] *Казанлы.* Ризаэддин бине Фәхретдин // Яңа милли юл (Берлин).— 1936.— # 7—8.— 22—24 б.
[24] Татар поэзиясе антологиясе.— II китап…— 60 б.

*2000*

## ӘХЛАК ҺӘМ ӘДӘБИЯТ

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә (III том) мондый юллар бар: «Әхлак — кешеләрнең бер-берсенә һәм җәмгыятькә карата мөнәсәбәтләр нормасы һәм принциплар җыелмасы». Шушында ук әхлаклы сүзенә «әхлак ягыннан тотанаклы; тәрбияле; әдәпле» аңлатмалары бирелә. Әхлак атамасы, күргәнебезчә, инсанга, аның үз-үзен тотышына, башкалар, җәмгыять белән бәйланышларына мөнәсәбәттә карала. Димәк, әхлакның үзәгендә кеше тора. Әмма бу төшенчә катып калган, үзгәрмәүчән түгел. Аның төрлелеге күп төрле факторларга бәйле. Инсан,— бер яктан, табигать җимеше. Нәселгә, климатик шартларга бәйле рәвештә ул төрле булырга мөмкин. Мәсәлән, Кавказ халыкларына, гомумән, кызулык, кайнарлык хас. Күп кенә төньяк кавемнәрендә салмаклык, гадәттән тыш сабырлык күзәтелә. Кешенең нindiлеге, үз-үзен тотышы аның яшь үзенчәлегенә дә бәйле. Балалар өчен, алар кайда гына, кайчан гына яшәмәсен, уенга бирелү, мавыгу хас. Өлкән яшьтәге кешеләрнең балалар кебек йөгереп, уйнап йөрүе исә һәркайда гайре табигый күренеш буларак кабул ителә.

Кеше — табигать баласы гына түгел, җәмгыять җимеше дә. Һәм, әйтергә кирәк, монысының урыны хәтта зуррак та. Җәмгыятьнең нindiлеге, иҗтимагый һәм тарихи шартлар инсанга, аның үз-үзен тотышына гаять зур йогынты ясый.

Мәгълүм булганча, һәр чорның, һәр җәмгыятьнең билгеле бер дәрәҗәдә үзенә хас таләпләре, әхлакый нормалары туплана. Мәсәлән, ырулык, феодализм дәверләренең иҗтимагый мөнәсәбәтләрендә, идеалларында җитди генә аермалар бар. Милләт оешу, этник үзенчәлекләр шәкелләшү — шулай ук тарихи категория. Ул аерым кавемнәрнең билгеле бер җирлектә озак еллар буе үзара аралашып, керешеп яшәве, чагыштырмача бөтенлек, бердәмлек туу нәтиҗәсендә барлыкка килә. Шушы катлаулы, каршылыклы процесс вакытында милләтнең үзенчәлекләре, рухи кыйммәтләре, әхлакый өлгеләре оеша. Биредә гомумән кешеләргә, инсаниятkә хас булган аерым күренешләр дә еш кына үзенчәлекле төсмер ала. Димәк, әхлак турында сүз барганда, аның тарихилык, миллилек белән бәйләнешле булуын да истә тоту зарури.

Кешеләрнең үз-үзләрен тотышына, мөгамәлә нормаларына шөгыль-вазифа (гаскәри, укытучы, рухани, түрә…), нәсел-нәсәп (кол, аксөяк), урын, вазгыять (өй, эш…) һәм башка хосусиятләр дә билгеле бер дәрәҗәдә йогынты ясый. Әхлакый кагыйдәләр һәм сыйфатлар инсаннарның нинди дин тотуларына да бәйле. Ни өчен? Чөнки дин, бер яктан, аерым чор, җирлек, җәмгыять әгъзаларының яшәеш нормаларына, рухи мирасына һәм тормыш тәҗрибәсенә нигезләнә, аларга таянып, үзенең кануни өлге-идеалларын билгели. Икенче яктан исә диндәге төп кыйммәтләр, инсани бизмәннәр (критерийлар) аны тотучыларның шәхси һәм иҗтимагый тәртипләрендә, эш-гамәлләрендә билгеле бер охшашлыклар, якынлыклар тудыра. Мәсәлән, ислам дине хәмер эчүне гаепли, аны бөтен начарлык һәм явызлыкның төп чыганагы дип саный. Шуңа мөнәсәбәттә аеклык мөселманнар арасында кешеләрне бәяләүнең мөһим үлчәме итеп алына.

Күренә ки, әхлакый, әхлак сүзләре белән бәйләнешле төшенчәләр шактый төрле, катлаулы. Хәтта бер үк эш-гамәлләр, охшаш сыйфатлар, вакыты һәм урынына карап, капма-каршы бәяләр дә алырга мөмкин. Мәсәлән, кеше үтерү, кан кою —гөнаһ эш. Ә аерым чорларда исә инсан җанын кыю каһарманлык билгесе итеп тә каралган. Шуңа күрә мораль-әхлак төшенчәләре белән эш иткәндә, аларның билгеле бер дәрәҗәдә тарихи, үзгәрүчән күренеш булуын, төрле фактларга бәйле икәнлеген дә хәтердән чыгарырга ярамый.

Әмма, шуның белән бергә, һәм гомумкешелек моралендә, һәм аерым халык, инсан әхлагында чагыштырмача тотрыклы, үзгәрешсез кыйммәтләр дә була. Гаделлек, намуслылык, шәфкатьлелек, гамәл һәм сүз берлеге, ата-ананы, өлкәннәрне хөрмәт итү һ. б.— әнә шундыйлардан. Дөрес, бу төшенчәләргә төрле мәгънә төсмерләре дә салынырга мөмкин. Әмма моңа карап, аларның асылы юкка чыкмый, һәр очракта асылташ кебек балкып-балкып китә.

Әхлакый норма-кагыйдәләргә бу төр чагыштырмача гомумилек, тотрыклылык кешеләргә, яшәешкә хас даимилек сыйфатлары белән билгеләнә. Мәгълүм ки, туу, яшәү, үлем, мәхәббәт, гаилә кору, бала тәрбияләү, эшләү, ял итү, йокы, белем һәм һөнәр туплау, ата-ана һәм бала-чага мөнәсәбәте, сабый бала, үсмер, егет-кыз, ата-ана, әби-бабай булу һ.б.— һәр чор, һәр халык һәм, нигездә, һәр инсан өчен хас булган зарури күренешләр. Аларның спираль рәвешендә даими кабатланып, яңарып торуы кешеләрнең яшәешендә бердәйлекләр, типологик охшашлыклар, чагыштырмача гомуми әхлак нормалары һәм сыйфатлары тудырып тора.

Сүз сәнгатенең үзәгендә — кеше, аның рухи дөньясы, эш-хәрәкәте, җәмгыять һәм табигать белән үзара мөнәсәбәтләре. Бу яктан ул әхлак төшенчәсе белән турыдан-туры керешеп китә. Әдәп-әхлак, әдәплелек-әхлаклылык сүзләре юкка гына янәшә яисә синоним рәвешендә кулланылмыйлар бит. Әдәбиятның асыл максатларыннан берсе — үз чаралары белән инсанга йогынты ясау, кеше тәрбияләү, адәм баласын әдәпле, әхлаклы итү. Әдәби әсәрләрдә, кагыйдә буларак, әхлакый һәм эстетик идеаллар кушылып, үрелеп китә, дөресрәге, алар чагыштырмача табигый бөтенлек, бердәмлек тудыра.

Инсаният, әдәп-әхлак, әдәбият аерылгысыз. Аларның һәрберсенең дә асылын кеше тәшкил итә, адәм баласы турында җәмгыять туплаган рухи тәҗрибә, инсани кыйммәтләр бу күренешләрнең төп эчтәлеген билгели.

Табигый җан иясеннән иҗтимагый затка, кешегә үсеп әверелү өчен инсанның һәрберсе белем-тәрбиягә мохтаҗ. Ягъни өлкәннәр яшь буынга моңа кадәр тупланган белем-мәгълүматларны, яшәеш тәҗрибәсен, тормыш итү күнекмәләрен җиткерергә бурычлы. Шунсыз инсани һәм иҗтимагый үсеш туктalып, буыннар арасындагы табигый дәвамчанлык, керешү, хәтер чылбыры өзеләчәк. Нәкъ менә шуңа күрә дә, бу һәлакәтне, инкыйразны булдырмас өчен, һәр ата-ана, халык, җәмгыять, кагыйдә буларак, яшь буынны тәрбияләүгә, аны белемле, һөнәрле итүгә даими игътибар бирә һәм бу катлаулы, изге, дәвамлы процесста күп төрле чаралардан файдалана. Аларның иң мөһимнәре — тел, фольклор, язма әдәбият. Бу тармакларда халыкның рухи тәҗрибәсе, күңел тарихы, кеше һәм дөнья турындагы күзаллаулары аеруча тулы гәүдәләнеш тапкан.

Инсанны тәрбияләүдә сүз сәнгате — чын мәгънәсендә остаз. Фольклор һәм язма истәлекләр кешелек туплаган күңел байлыгын, әдәп-әхлак кагыйдәләрен, нәрсә ул изге, нәрсә ул начар төшенчәләрен инсаннарга үтемле, тәэсирле итеп җиткерә. Сүз сәнгате кешеләргә мөнәсәбәттә чынбарлык һәм яшәешнең күп төрле якларын бөтен катлаулылыгында, бөтен каршылыклары белән чагылдырырга, җанландырырга омтыла, тәрбияви һәм танып белү максатларын бергә куша. Әдәбиятны юкка гына «кешелек хәтере», «тормыш дәреслеге» дип атамыйлар. Сүз сәнгате аша яшь буын һәм, гомумән, кеше дөньяны, инсанны һәм үз-үзен танып белә, тормыш тәҗрибәсен үзләштерә, яшәешкә, тереклеккә дәрт, стимул ала. Әдәбият — элеккеге, хәзерге һәм киләчәк буыннарны ялгаучы, бербөтен итүче мөһим чара да.

Әдәби ядкярләр кешеләрне фикер йөртергә, хисләнергә, хыялланырга, иҗатка өйрәтәләр, башкаларның кайгы-шатлыкларын, рухи халәтләрен аңларга ярдәм итәләр. Инсанның сөйләм һәм язма телен, гомуми культурасын үстерүдә дә сүз сәнгатенең роле зур.

Фольклорыбызда, мең елдан артык тарихы булган төрки-татар язма әдәбиятында һәм, гомумән, телебездә бүгенге педагогик процесста, әхлакый тәрбия эшендә файдаланырлык ядкярләр, материаллар гаять күп. Бары аларны табып, аңлап, максатка яраклы рәвештә куллана белү генә шарт. Биредә укучыларның яшь һәм белем дәрәҗәләрен, бүгенге милли-мәдәни ихтыяҗларны истә тоту зарур.

Әгәр дә без реалистик әдәбият тәмам формалашканчы булган Урта гасыр һәм XIX йөз әдәбиятын, ягъни Тукайгача чор сүз сәнгатен чагыштырмача бербөтен итеп карасак (моның өчен тулы нигез бар!), анда без кеше образының бирелешендә, эстетик һәм әхлакый идеалларының гәүдәләнешендә билгеле бер закончалыклар, өстенлек итүче сыйфатлар күрербез. Реалистик әдәбияттан үзгә буларак, бу дәвер сүз сәнгатендә инсан образын бирүдә, индивидуальлектән бигрәк, гомумилеккә ныграк игътибар ителә. Кешене гәүдәләндерүдә традицион алымнар һәм чаралар иркен кулланыла. Матур икән, ул тиңсез матур; ямьсез икән, тәмам иләмсез. Уртада торучы, каршылыклы образлар чагыштырмача сирәк. Йөз гүзәллеге, гадәттә, ай, кояш белән, буй зифалыгы тал, сәрв (кипарис) белән чагыштырыла… Сыйфатны саннар символикасы аша бирү бик актив (Йосыф 72 телне белә, ул 40 ирдән куәтлерәк…). Кыскасы, уңай, идеал инсан, кагыйдә буларак, ямьсез була алмый. Әдәбиятта андый зат, гадәттә, тышкы яктан да күркәм итеп тасвирлана. Фольклор эстетикасы белән аваздаш булган мондый иҗат принцибы исә реалистик әдәбиятта үзгәреш кичерә: тышкы яктан ямьсез кешеләр дә кайвакыт уңай, өлге рәвешендә тәкъдим ителә.

Урта гасыр һәм XIX йөз сүз сәнгатендә кешеләрдәге әхлакый сыйфатларны, эш-гамәлләрне бирү ысулы да портретларны тасвирлау алымына охшаш. Автор, мәсәлән, инсанның юмартлыгын күрсәтергә уйлый икән, ул аны гадәттән тыш зурайту, максималь югарылыкка күтәрү рәвешендә башкара. Саран икән, андый кешенең саранлыгы хәттин ашкан итеп сурәтләнә.

Элеккеге әдәбиятның күп кенә вәкилләре кешене төрлечә олылап, данлап, аны рәнҗетүгә, түбәнсетүгә кискен каршы чыкканнар. Инсани яктан бу бик мөһим момент. Авторлар карашынча, кеше барлык башка әйберләр, җан ияләре кебек Ходай Тәгалә тарафыннан яратылган. Инсан моны һич тә онытмаска тиеш. Кешенең Аллага буйсынуы, дин кануннарын һәм таләпләрен үтәве, ягъни диндар булуы — идеал, үрнәк зат турындагы күзаллауларның мөһим элементы. Күп кенә әдипләр, бигрәк тә суфыйчылык тарафдарлары, кешене Алланың иҗат җимеше дип карап, инсаннар арасында табигый тигезлек идеясе дә үткәргәннәр. Кешене рәнҗетү, түбәнсетү —ул гөнаһ. Мондый гамәл — Тәңрегә каршы килү дигән сүз. Адәм баласы үзен дә түбәнсетмәскә тиеш. Бары Ходай Тәгалә алдында гына буйсыну лязем… Әл-Мәгарри, Котблардан килүче бу фикерне соңгы дәвер әдибе Нәҗип Думави аеруча калку гәүдәләндерә. Аның «Син — кеше!» шигырендә (1916) мондый юллар бар:

…Син — бөек! Салган Ходай күктән синә үз орлыгын.
Бул — гали! Таптатма, зинһар, шул «Ходайлык» зурлыгын!..

Тукайгача чор татар әдипләренең күпчелеге әхлаклылык төшенчәсен белем-мәгърифәт белән тыгыз бәйләнештә карыйлар. Матур әхлакый сыйфатларга, күркәм эш-гамәлләргә ия булган укымышлы зат — бу дәвер авторларының төп идеалы. Алар фикеренчә, надан кеше дөнья эшен дә, ахирәтне дә белми. «Гыйлемдин хасыйл улыр сирәте хуб (яхшы холык), Гыйлемдер адәмигә васфы мәргуб (үзе теләгән яхшы сыйфатларны бирә)»,— ди Утыз Имәни. Шушы ук авторның «Гыйлемнең өстенлеге турында төркичә бәетләр» шигыре мәктәп дәреслеге аркылы укучыларга яхшы таныш. Анда шагыйрь белемне «камил инсан»ның мөһим компоненты итеп карый. Гыйлемлелек,— Утыз Имәни карашынча, инсаннарны мәңге яшәтә торган «тереклек суы» ул. Ансыз һөнәр дә, бәхет тә юк:

Белмәде һөнәрне гыйлемсез кеше,
Булмады аңарда бәхетнең эзе.

Урта гасыр һәм XIX йөз сүз сәнгатен әхлакый әдәбият дип тә атарга мөмкин. Чөнки анда гаделлек, намуслылык, шәфкатьлелек, сабырлык, киң күңеллелек, юмартлык һәм башка шундый уңай сыйфатлар һәм эш-гамәлләр турыдан-туры да, вакыйга-хәлләр аша да гәүдәләндерелә. Шунысы үзенчәлекле: бу төр төшенчәләр кайвакыт әсәр, бүлекчә (бәян, баб, фасыл…) атамаларында да бирелә. Мәсәлән, Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы мондый баблардан гыйбарәт: «Гадел кылмак сүзләрен бәян кылыр…», «Рәхим-шәфкать сүзләре…», «Сәхавәт (юмартлык)…», «Сабыр кылмак…», «Хәйа (оялчанлык)…» һ.б. Шушыңа охшаш күренеш Әхмәд Йүгнәки, Сәйф Сараи, Утыз Имәни кебек авторларның әсәрләрендә дә күзәтелә. Мәүла Колый үзенең поэмаларын «Береккәннәр (ягъни бердәм булганнар) сыйфаты» һәм «Хәләл ризык эстәгәннәр сыйфаты» дип исемләгән.

Элеккеге әдипләребез кешеләрдәге уңай әхлакый сыйфатларны еш кына аларның тискәреләре белән бергә гәүдәләндерәләр. Мәсәлән, Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә (1358) өченче һәм дүртенче баблар болай аталган: III баб. Аллага якын булу өчен кирәкле гамәлләр, яхшы әхлак нормалары (ата-анага хезмәт итү, хәләл, дөрес юл белән табылган мал белән яшәү, сабырлык…). IV баб. Ходай Тәгаләдән ераклаштыручы, ягъни тискәре эш-гамәлләр турында: кеше үтерү, хәмер эчү, ялган сөйләү, риялану һәм масаю, кинә һәм көнчелек, малга хирыслык һ.б. Антитеза, ягъни капма-каршы кую алымы белән эш итү уңай әхлакый сыйфатларны тагын да үтемлерәк күрсәтүгә ярдәм итә.

Йосыф Баласагунлы, Хисам Кятиб, Мөхәммәдьяр, Ризаэддин Фәхреддин һәм башка күп кенә әдипләр «Нә иксә — ургай аны», «Койуг казыб — үзе төшкәй» мәкальләрен үзләренең төп иҗат принциплары итеп алалар. Ягъни һәр инсан, ул кем булуына карамастан, үз гамәле өчен үзе җаваплы. Ягъкуб хезмәтче хатынның яшь баласын сатып җибәрә. Шушы гамәле өчен ул газиз Йосыфыннан аерыла, әхлакый җәзага дучар ителә. Р.Фәхреддиннең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» романында яхшылыкның яхшылык, яманлыкның яманлык рәвешендә кабат үзеңә кайтуы җанлы сурәтләрдә гәүдәләнеш тапкан. Суфыйчылык рухындагы әсәрләрдә тәүбә кылу, күңелне сафландыру, пакьләү кебек мотивларга зур урын бирелә.

Элеккеге әдәбиятта үз көчең белән, намуслы рәвештә, хәләл юл белән мал табу, яшәү әхлакый төшенчәнең мөһим бер кыйсемен тәшкил итә. Инсан, әгәр дә аның байлыгы, мөмкинлеге бар икән, үз хәзинәсеннән ярлыларга, гарипләргә өлеш чыгарырга бурычлы.

Тукайгача чор әдипләренең күп кенә юллары сөйләшү, «сохбәт әдәбе» турында. Аларның әсәрләрендә кешенең риясызлыгы, ихласлылыгы, мәкер-кинәдән азат булуы мактала. Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» әсәрендә (1391) бер баб «Сохбәт әдәбе турында» дип исемләнгән. Анда сүзнең көче, сөйләшә, аралаша белү хакында гаять кызыклы юллар бар:

Тоз-итмәкне онытмас кәлб (эт), гәр йөз
Куар булсаң, йәнә кайтармас ул йөз.
Монафикъ (икейөзле) сохбәтеңдә нигъмәтең йийр (ашар),
Чыгып, дошманларыңа гайбәтең диер.

Борынгы грекларның акыл иясе Фалестан: «Тереклекнең ниндие яхшы?» — дип сораганнар. Ул: «Башкаларда гаепләгән эш-гамәлләрне үзебез кабатламыйча яшәү»,— дип җавап биргән. Бу принцип безнең күп кенә авторларыбызның да әхлакый идеалларына аваздаш.

Урта гасыр һәм XIX йөз әдәбиятында ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләренә билгеле бер урын бирелә. Гаилә кору, бала тәрбияләү — һәр кешенең изге бурычы. Үз чиратында, балалар да ата-аналарына хөрмәт белән карарга, аларны олыларга бурычлы.

Һәр угыл-кыз ата-ананы белер булса,
Гыйззәт, хөрмәт берлә хезмәт кылыр ирсә,
Күңелене хушнуд кылып (сөендереп.— *Х.М.*) дога кылса,
Ул угыл-кыз Хәкъ дустыдыр, белмәк кирәк,—

ди Мәүла Колый. Бу фикерне аның кече чордашы Габди дә куәтли. Ата-ананы рәнҗетү — ул зур гөнаһларның берсе.

* * *

Татар әдәбияты тарихы — әхлакый, инсани проблемаларны гәүдәләндерүнең, рухи тәҗрибәнең гадәттән тыш бай чыганагы. Әдәби ядкярләрне өйрәнгәндә, вакытлар узу белән һич тә искермичә, мәңгелек кыйммәтләрен саклаган әхлакый байлык белән очрашасың. Һәр очракта аңа укучыларның игътибарын юнәлтү, конкрет вакыйга-хәлләргә, сурәтләргә бәйле рәвештә яшь буынга рухи мирасның асылын җиткерә бару балаларыбызның зиһенен, күңел дөньясын баетыр иде.

Элеккеге әдипләр матур әхлакый сыйфатларга ия булган, күркәм эш-гамәлләр башкарган камил инсан турында хыялланганнар, аның төрледән-төрле үрнәкләрен биргәннәр, шундый затларның гына инсаният хәтерендә «игү ат» калдырырга сәләтле булуын күрсәткәннәр. Аларның хыял-омтылышлары безнең бүгенге яшәешнең, тәрбияви процессның да төп максаты, укучыларның да идеалы булырга лаек.

*1999*

## «КИСЕКБАШ КИТАБЫ»

Борынгы һәм Урта гасыр сүз сәнгатендә фольклор һәм язма әдәбият үзара нык керешкән. Аларның бер-берсенә күчеше, берсе нигезендә икенчесенең тууы — гадәти күренеш. Мәсәлән, Йосыф тарихы турында сюжет әүвәл мифологиядә, фольклорда туган. Бераздан, бу материалга нигезләнеп, күп кенә язма истәлекләр дөньяга килә. Үз чиратында, аерым авторларның әсәрләре фольклорга йогынты ясый. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ына мөнәсәбәттә туган җырлар, бәетләр, мөнәҗәтләр, әкиятләр — шуның ачык бер билгесе. XIII—XIV йөзләргә мөнәсәбәтле «Кисекбаш китабы» да — фольклор һәм язма әдәби башлангычларның үзара синтезы рәвешендә барлыкка килгән ядкяр. «Нәһҗел-фәрадис», «Җөмҗөмә солтан» шикелле, ул да халкыбыз арасында элек-электән киң таралган. «Кыйссаи Йосыф» кебек, аның да татар мәктәп-мәдрәсәләрендә дидактик материал, әдәби текст буларак файдалануы мәгълүм.

* * *

«Кисекбаш китабы»ның хәзерге фәнгә 30дан артык күчермәсе билгеле. Аларның дистәгә якыны Татарстан Фәннәр академиясенең архивында һәм Казан дәүләт университетының Гыйльми китапханәсендә, унысы Санкт-Петербургтагы Шәрыкшенаслык институтында саклана. Мәскәүнең борынгы документларны үзенә туплаган Үзәк дәүләт архивында (ЦГАДАда), Азәрбайҗан Фәннәр академиясенең кульъязмалар институтында бу ядкярнең берәр күчермәсе бар. Шулай ук Уфаның һәм Казанның аерым фондларында да «Кисекбаш китабы»ның берничә нөсхәсе теркәлгән. Бу ядкярнең шәхси китапханәләрдә саклanучы күчермәләре дә шактый. Андыйларның берсе, мәсәлән, безнең үзебездә дә бар.

«Кисекбаш китабы»ның кульъязмалары, нигездә, Идел-йортка мөнәсәбәтле. Мәсәлән, Санкт-Петербургтагы күчермәләрнең күпчелеге Әстерхан һәм Казан төбәкләреннән алынган. Мәскәү нөсхәсе Пугачев хәрәкәтенә (1773—1775 еллар) мөнәсәбәтле татар материаллары белән кергән. Фәнгә билгеле күчермәләрнең төп өлеше XVIII—XIX йөзләргә карый. Күләм һәм эчтәлек ягыннан кульъязмалардагы текстлар арасында әллә ни җитди аермалар юк. Әсәр күләм ягыннан 300 мисрагтан артмый.

XIX гасырның урталарыннан «Кисекбаш китабы», кульъязмалардан тыш, басма рәвештә киң тарала башлый. Ул тәүге мәртәбә 1846 елда Казан университеты тәбыгханәсендә дөнья күрә һәм Октябрь инкыйлабына кадәр күп мәртәбәләр нәшер ителә. Казан басмаларының Идел-йорттан тыш башка төбәкләрдә дә күпләп таралуы мәгълүм. Мәсәлән, минем үземә андыйларны Финляндия татарларында, Ташкентта, Дүшәнбедә күрергә туры килде. Басма нөсхәләрдәге текстларның кабат кулдан күчерелү очраклары да бар.

Кызганыч ки, башка күп кенә элеккеге ядкярләр кебек, «Кисекбаш китабы» да Октябрь инкыйлабыннан соң озак еллар буе нәшер ителмичә торды. Ниһаять, 1979 елда Мәскәү басмасы дөнья күрде[1]. Анда «Кисекбаш китабы»ның басма нөсхәләренә һәм 19 күчермәсенә нигезләнеп төзелгән тәнкыйди, җыйнама тексты (барлыгы 135 бәет) урнаштырылган. Ул — гарәп язуында. Шунда ук дастанның латин хәрефләре белән бирелгән транскрипциясе, русчага әдәби һәм юлга-юл тәрҗемәсе бар. Поэтик тәрҗемә күренекле тюрколог профессор С. Иванов тарафыннан башкарылган.

70 нче елларда поляк галиме Я. Циопиньский Казан басмасы нигезендә «Кисекбаш китабы»ның транскрипциясен, французчага тәрҗемәсен бастырып чыгара[2]. Соңгы елларда бу ядкяр Казанда да кабат, гәрчә теге яки бу күләмдә кыскартылып булса да, нәшер ителә башлады[3].

Ш.Мәрҗани, Г.Рәхим һәм Г.Газиз, Х.Вәли, М.Гали, Р.Ганиева, Ш.Абилов, В.Кожатөрек, И.Боролина, Г.Таһирҗанов, Я.Циопиньский, Х.Миңнегулов һәм кайбер башка галимнәрнең хезмәтләрендә «Кисекбаш китабы» хакында фикер-күзәтүләр бар. Ш. Мәрҗани, мәсәлән, бу ядкярне, аның теленә, таралуына карап, «Болгар әсәре» дип атый. «Нәһҗел-фәрадис», «Башлагали»[4], «Йосыф китабы» кебек төрки истәлекләрнең,—ди ул,— башка мәмләкәтләрдә күрелгәне һәм ишетелгәне юк. Бу китапларның теле госманлы, чыгтай, төрекмән һәм казакъ телләреннән аерылып тора»[5].

Мәгълүм булганча, Г.Тукай «Кисекбаш китабы»на нәзыйрә рәвешендә үзенең «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» исемле атаклы сатирик поэмасын (1908) иҗат итә. Бу ике ядкяргә мөнәсәбәттә Г.Камалның «Өр-яңа Кисекбаш китабы» (1918), Н.Исәнбәтнең «Өр-яңа Кисекбаш» (1928), Н.Баянның «Карәхмәт» (1939), Ш.Мөдәрриснең «Янки базары, яхуд Яңадан-яңа Кисекбаш (1953), Ә.Камалның «Кисекбаш» (1959) һәм башка әсәрләр туа. Шуңа күрә «Кисекбаш китабы», фәнни әдәбиятта махсус рәвештә тикшерелмичә, күбрәк Г.Тукай әсәренә, башка мәсьәләләргә мөнәсәбәттә генә өйрәнелеп килде. Санкт-Петербург галимәсе Ялкын Әтмәтгалеева «Кисекбаш китабы» хакында монографик хезмәт — кандидатлык диссертациясе язды һәм тикшерену нәтиҗәләрен Мәскәүдә һәм Казанда бастырып чыгарды[6]. Галимәнең Мәскәүдә нәшер ителгән монографиясендә «Кисекбаш китабы»ның тәнкыйди текстыннан, русчага тәрҗемәләреннән тыш, әсәрнең өйрәнелү тарихы яктыртыла, кульъязма һәм басма нөсхәләргә тасвирлама бирелә; авторы, язылу вакыты һәм урыны хакында да кызыклы гына фикерләр бар. Хезмәттә төп урынны әсәрнең телен тикшерү

алып тора. Ахырда сүзлек бирелгән. Шулай итеп, Я.Әхмәтгалеева монографиясе «Кисекбаш китабы»н өйрәнүдә хәзерге вакытта чагыштырмача тулы һәм ышанычлы хезмәтләрдән исәпләнә.

* * *

Әсәрнең авторы, язылу вакыты һәм урыны төгәл билгеле түгел. Күпчелек нөсхәләрдә «Кисекбаш китабы» «Башлагали…» дип башлана. Аерым галимнәр бу сүзне икегә аерып, «Башла, Гали...» дип укыйлар һәм шуңа мөнәсәбәттә әсәрнең авторын да «Гали»гә нисбәт итәләр. Фәнни әдәбиятта хәтта «Кисекбаш китабы»н «Кыйссаи Йосыф» авторы Кол Гали язган дип карауЧылар да бар. Әмма Я.Әхмәтгалеева (28 б.) һәм кайбер башка галимнәр күрсәтүенчә, дастанның асыл нөсхәсенә «Башла, Гали…» дип түгел, ә «Башлагали…», ягъни «башлыйк әле» мәгънәсендәге сүз белән керешелә («ba,lagaly s†zi bismilla ila», 136 б.).

«Гали» исемен «Кисекбаш китабы»на карата куллануның башка төрле сәбәбе дә бар. Төрек әдәбиятчысы В. Коҗатөрек кулында «Кисекбаш китабы»ның 1461 елгы күчермәсе булуы мәгълүм[7]. Күчермәнең ахырында болай диелгән:

Bunu eden Kirdeci Ali d„r„r,
Konyada Mevlananin kulu durur.
Kirdeci Ali gelirse f†vbeye,
Lay’k ola kulluga Mevlanaya[8].

Әмма Г.Таһирҗанов «Кирдәчи Гали»нең автор түгел, ә тәрҗемәче икәнлеген искәртә. Чөнки В. Коҗатөрек кулындагы текст — госманлы телендә. «Гадәттә,— дип яза Г.Таһирҗанов,— борынгы төрек шагыйрьләре әсәр ахырында автор хакында мәгълүмат биргән чакта «буны язан» яки «буны диян» (моны язган, моны дигән) кебек трафарет гыйбарәләрдән файдаланганнар... Кирдәчи Гали дә үзе тудырган «Аждаһа дастаны»н (бу әсәр, «Җөмҗөмә солтан» һәм «Кисекбаш китабы» бер җыентыкка тупланган) нәкъ шулай «Буны диян Кирдәчи Гали дорур» дип тәмамлый». Ә «Кисекбаш»ның төрекчәсендә исә «Буны идән Кирдәчи Гали дорур» дип язылган. Төрекчә «диян» (дигән, әйткән) белән «идән» (иткән, эшләгән) сүзләрен чагыштырып карасак, соңгысының тәрҗемә итүне аңлатуы ачыла. Хәлбуки әлеге 1461 елгы төрекчә җыентыкта Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастанының да төрекчә версиясе бар. В.М.Коҗатөрек аны да... төрек Кирдәчи Гали әсәре дип уйлый. Чынлыкта исә һәр ике поэма да болгарлар, кыпчаклар арасында туган һәм, Кырым аша Төркиягә эләгеп, шунда төрекчәгә тәрҗемә «идилән» әсәрләрдер»[9].

Г.Таһирҗанов фикерен Я.Әхмәтгалеева да куәтли. Аның карашынча, Кирдәчи Гали — дастанны төрекчәгә күчерүче, «эшкәртүче» (29, 30 б.). Шунысы кызыклы: төрекчә версия төрки-татар җирлегенә дә кайта. Кайбер татар нөсхәләрендә Кирдәчи Гали исеменең телгә алынуы нәкъ әнә шуның белән аңлатыла.

«Кисекбаш китабы»ның ахырында «Мәүлана Шәмс Тәрази» исеме теркәлгән.

Мәүлана Шәмс Тәрази йадына,
Сән тикергел гаҗизлар морадына (136 б.).

Хәзерге Җамбул (элегрәк — Әүлийа Ата) шәһәре урынында XIV йөзләргә кадәр Тәраз (Талас)[10] каласының булуы, аның IX—XIII гасырларда, аеруча караханилар дәверендә, сәяси, мәдәни, икътисади яктан мөһим роль уйнавы тарихтан мәгълүм[11]. Ул утрак һәм күчмә тормышның, фарсы һәм төрки телләренең, мәдәниятләренең үзенә күрә бер кушылу, керешү үзәге хисапланган. Анда уку йортларының, суфыйчылык тарикатьләренең булуы билгеле. Шуңа күрә Тәразга башка төрки төбәкләрдән, шул исәптән Идел-йорттан да кешеләрнең килүе табигый. («Кисекбаш китабы» авторы да, мөгаен, шундыйларның берсе булгандыр.)

Ш.Абилов фикеренчә, Урта Азиядә Тәраз шәһәре белән бәйләнешле «Шәмс Тәрази» исемле «мәүлана» яшәгән[12]. «Кисекбаш китабы»ның авторы шушы күренекле затны үзенең остазы дип санаган.

Кыскасы, хәзерге фәнни мәгълүматлар шуны күрсәтә: «Кисекбаш китабы» XIII—XIV йөзләрдә Идел-йортта билгесез автор тарафыннан гарәп, фарсы, төрки чыганакларын һәм фольклорын файдаланып иҗат ителә. XV гасырның икенче яртысында ул Кирдәчи Гали тарафыннан госманлы теленә күчерелә. «Кисекбаш китабы», татарлардан тыш, башка төрки төбәкләрдә дә теге яки бу дәрәҗәдә таралыш таба.

* * *

«Кисекбаш китабы»ның сюжеты түбәндәгечә: бервакыт Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең якыннары («утыз өч мең сәхабәсе») белән әңгәмә корып утыра. Шулвакыт алар янына бер Кисекбаш тәгәрәп килә. Ул

елый-елый үзенең моң-зарларын сөйли: «Гәүдәм илә углымны,— ди ул,— бер Дию йийды (ашады), хатынымны алып китте». Мөхәммәд пәйгамбәрнең якыны — Гали батыр Кисекбашка ярдәм итәргә алына. «Зөлфәкар» кылычын алып, «Дөлдел» атына атланып, Гали Кисекбаш белән берлектә, бер олуг кое янына килә. Аркан бәйләп, коега «җиде көн һәм җиде төн» төшкәч («йите төни һәм көни иңәр ирде»), «сикезенче көн азакы»нда бер тимер капканы ачып, «олуг сарай»га керә. Диюләр патшасын үтерә, 500 кешене, шул исәптән Кисекбашның хатынын да, Җәбраил фәрештә ярдәмендә, җир өстенә алып чыга. Кисекбаш, аның улы, пәйгамбәрнең Ходайдан үтенече белән, элеккеге хәлләренә кайтарылалар («Ул Кисекбаш бер егет булды йәнә...»).

Күрәсез: «Кисекбаш китабы» үзенең эчтәлеге һәм поэтикасы белән, алдарак әйтелгәнчә, әкият-легендаларга, риваятьләргә тартым. Нинди дә булса явыз көчнең матур хатын-кызны урлап китүе, бәхетсезлеккә тарыган бу затны батыр ир-егетнең коткаруы күп кенә халыкларның, шул исәптән төрки кавемнәрнең дә фольклорында еш очрый торган хәл. Җир асты патшалыгы, Дию белән сугыш, үлгән кешеләрнең кабат терелүе һ.б.— болар бар да әкият-легендаларга хас күренешләр. Автор шулар ярдәмендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең изгелеген, Гали батырның көч-куәтен, кешелекле эш-гамәлләрен күрсәтүгә ирешкән.

Дастандагы бөтен вакыйга-хәлләр гаделлек, кешеләр иминлеге өчен көрәш рухы белән сугарылган. Явызлык җиңелә, гаделлек тантана итә, тоткыннар коткарыла, гаилә торгызыла, кеше гомере саклап калына. Әсәрдә Гали батырның бөтен тырышлыгы хатын-кызны коткаруга, аны, гаиләсе белән кавыштырып, бәхетле итүгә юнәлтелгән.

Күп кенә фольклор әсәрләрендә хатын-кызны коткаручы батыр ахырда аңа үзе өйләнә. Мәсәлән, «Идегәй» дастанының төп каһарманы, Кара Тиен Алыпны юк итеп, әсирлектәге Акбеләкне азат итә һәм бераздан аның ире була. Гали батыр исә үзенең шәхси мәнфәгатьләре өчен түгел, ә ислам дине һәм пәйгамбәр өчен, башкаларның үтенеч-теләкләрен гамәлгә ашыру өчен тырыша.

«Кисекбаш китабы»ның халык тарафыннан яратып укылуына, әлбәттә, аның гуманистик рухта булуы, күркәм әхлакый сыйфатларны, инсани эш-гамәлләрне алга сөрүе дә зур йогынты ясаган.

Мәгълүм булганча, әсәрдәге Мөхәммәд пәйгамбәр, Гали батыр — хыял җимеше түгел, ә тарихи, реаль нигезләре булган каһарманнар. Әмма алар инде дастанга турыдан-туры түгел, ә язма әдәбияттагы һәм фольклордагы эстетик казанышларга таянып кертелгәннәр. Шуның нәтиҗәсендә бу ике каһарман әкияти-дастани сыйфатлар да алганнар. Кисекбаш белән булган вазгыять рәсүлнең бөеклеген һәм изгелеген, Галинең тәвәккәллеген һәм батырлыгын укучы һәм тыңлаучы алдында янә бер мәртәбә күрсәтүгә ярдәм иткән.

«Кисекбаш китабы» белән Гаттарның «Җөмҗөмәнамә» һәм Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» әсәрләре арасында билгеле бер охшашлыклар да бар. Һәр өч ядкярнең дә үзәгендә гайре табигый образ — Кисекбаш тора, үткәнгә кайтып, идеал планда аның тарихы бәян ителә. Һәр өч автор да вакыт һәм урын белән иркен эш итәләр, еш кына җир өсте һәм җир асты тормышлары гадәти рәвештә кушылып китәләр. Хронотоп, фольклордагы кебек, чагыштырмача йомык, шартлы, реаль вакыт һәм җирлек белән бәйләнмәгән. Әмма Фәридеддин Гаттар һәм Хисам Кятиб әсәрләреннән үзгә буларак, «Кисекбаш китабы»нда дөньявилык, җир тормышын мәдехләү көчле. «Җөмҗөмә солтан»ның төп каһарманы, кабат терелгәч, солтанлыкны да, байлыкны да дәгъва итми, ә «бер тау тишегенә кереп», «йитмеш ел гыйбадәт» кылу белән генә мәшгуль була. Аннан үлеп китә. «Кисекбаш китабы»нда исә, әйткәнебезчә, төп каһарман гаиләсе белән кушыла, янә элеккеге бәхетле, имин тормышына ирешә. Әсәрдә тәмуг күренешләрен сурәтләү дә юк.

Хисам Кятибтә төп каһарманның гадәти булмавы, нигездә, аның солтанлыгын, байлыгын сурәтләү аша белдерелә. Билгесез авторның әсәрендә исә Кисекбаш шәхесенең гайре табигыйлегенә басым ясала:

Сакалы ак һәм йөзендин нур акар,
Күзе камар һәр кем йөзенә бакар (125 б.).

Мәгълүм ки, уңай, идеал каһарманны нур чыганагы рәвешендә тасвирлау борынгы төрки фольклорыннан ук килә. Кол Гали әсәрендәге Йосыф образының да нурлар сирпеп торуы юкка гына түгел.

Кисекбаш күп төрле уңай сыйфатларны, эш-гамәлләрне үзенә туплаган. Хәтта ул — билгеле бер могҗизалар иясе дә. Әсәрнең кайбер нөсхәләрендә Кисекбашның төрле рәвешләргә керүе дә искәртелә. Гали батырның аны күтәрү түгел, урыныннан да кузгата алмавы («Зәррә мыскал йирендән тибрәтмәде»), бәлкем, бу образның алдан ук өлге, идеал рәвешендә бирелүе белән аңлатыладыр?!

«Кисекбаш китабы»ның тукымасында кызыклы гына поэтик күренешләр күзәтелә. Аларның шактый өлеше генетик яктан фольклорга барып тоташа. Мәсәлән, әкият-дастаннарда вакыйга-хәлләрнең дәвамчанлыгын, әһәмиятен белдерү өчен символик саннар еш кулланыла. «Кисекбаш китабы»нда да без бу күренеш белән очрашабыз. Гали батыр кое янына җиде көн һәм җиде төн чабып килә, җир астына да

шулвакыт эчендә төшә. Эпик каһарманнар кебек, ул да йоклаган Диюне «нәгъръә орып» уята. Алар арасында да, нәкъ дастаннардагы шикелле, әүвәл сүзләр белән чәкешү була. Аннан сугыша башлыйлар. Бу гамәл дә теләсә ничә мәртәбә түгел, ә өч тапкыр кабатлана…

Үлгән кешеләрнең кабат терелүе, күз ачып йомганчы ерак араларны үтү (Гали батырның үзе коткарган кешеләр белән җир өстенә тиз генә чыгуы) — болар да борынгы мифология, фольклор эстетикасы белән бәйләнешле. Билгесез автор, күп кенә чордашлары кебек, гайре арттыру, хыялый һәм чынбарлык картиналарын кушу, эш-гамәлләрне һәм сыйфатларны максималь югарылыкка куеп тасвирлау алымнарын теләп куллана. Дию портретын сыйфатлау — әнә шуларның бер мисалы: «Диюне күрде: биңзәр (охшаган) ул манарайа»; «Бармаклары охшар адәм гәүдәсе»; «Гөмбәзә охшар ирде аның башы» (130 б.).

Урта гасырның аерым ядкярләрендә рационалистик башлангыч, акыллы фикер, хикмәтле сүз әйтү өстенлек итә. «Кисекбаш китабы»нда исә гыйбрәтле хәлне конкрет образлар, җанлы картиналар аша бирүгә, ягъни эстетик якка басым ясала. Дастанның тәүге өлешендә үк автор юкка гына бу сүзләрне әйтми:

Сүзләгәем бер хуп изге дастан,
Кем күңелләр шад кыйлгай дустан.
Дөньяда бер хуп-хуп эшләр күп торыр,
Һич моның тик бере тәкый йук торыр (124 б.).

«Кисекбаш дастаны»нда фольклор традицияләре генә тү-гел, ә язма әдәби казанышлар да шактый файдаланылган. Әсәр үзара рифмалашучы икеюллык строфалар — бәетләр (мәснәви) белән язылган. Дастан ахырында автор «фагыйлатен фагыйлатен фагыйлат» дип, үз әсәренең рәмәл белән язылуын искәртә. Әмма текстта бу үлчәм һәрчак сакланмый. Моның сәбәбен галимнәр авторга 11әр иҗекле силлабик системаның да нык тәэсир итүе белән аңлаталар[13].

Әхмәд Ясәви, Хисам Кятиб әсәрләрендәге кебек, «Кисекбаш китабы»нда да, эстетик максатны күздә тотып, шигырь юлларын бер үк сүзләр белән башлау, кабатлау, эндәш, сорау һәм башка тасвир чаралары кулланыла:

Синме килдең, йа Гали дошманымыз,
Синең иleңдин чыкармы җанымыз?!
Синме кистең барча Диюләр башыны,
Синме түктең монча Диюләр каныны?! (131 б.)

«Йә мән үләм, йә Диюнең башын кисәм» (127 б.) һ.б.

«Кисекбаш китабы»нда билгеле бер күләмдә гарәп-фарсы сүзләренең кулланылуы да шактый дәрәҗәдә язма әдәби традицияләрнең тәэсире белән аңлатыла. Әмма, гомумән, әсәр үзенең төп лексик фонды, фонетик һәм грамматик шәкелләре белән турыдан-туры төрки-татар язма әдәби теле белән керешеп китә. Нәкъ шуңа күрә дә ул озак гасырлар буе бернинди тәрҗемәсез татарлар тарафыннан укылып килгән. «Кисекбаш китабы», гомумән, татар кешесенең рухына сеңгән, аның эстетик фикерләвендә зарури бер элементка әйләнгән. Бөек Тукайның һәм кайбер башка әдипләрнең «Кисекбаш китабы»на мөрәҗәгать итүләре, андагы сюжет-мотивларны, образларны, вәзенне, шигъри чараларны иҗади файдаланулары нәкъ әнә шул сәбәпләр белән аңлатыла да.

[1] *АхметгалееваЯ.С.* Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы».— Москва: Наука, 1979.— С. 191. (Алга таба җәяләр эчендә битләр саны гына күрсәтеләчәк.)

[2] *Ciopinski J*. Kesik ba, kitaby, Variante de Kazan.— Folia orientalia. 1970.— t. 11; 1971.— t. 12; 1972.— t.13 /Мәгълүмат Я. Әхмәтгалеева китабы аша китерелә.— 10, 190 б.

[3] Татар поэзиясе антологиясе.— I китап.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.— 90—93 б.; «Ватаным Татарстан» газетасы.— 19, 26 июнь, 1992 ел; Татар әдәбиятыннан хрестоматия (9 нчы сыйныф өчен…)—Казан: Мәгариф, 1995.— 76—79 б. һ.б.

[4] «Кисекбаш китабы»на «Башлагали...» сүзе белән керешеп кителә. Әсәрне тәүге сүзе белән атау әдәбият тарихы өчен чит түгел. Мәсәлән, Ф.Гаттарның «Пәндnamә»сен еш кына «Хәмде би хәдд...» дип атыйлар.

[5] *Шиһабетдин Мәрҗани*. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар... — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.— 58 б.

[6] Ахметгалеева Я. С. Исследование...; Татар әдәбияты тарихы.— I том.— Казан: Татар. кит. нәшр.,— 1984.— 273—282 б.

[7] Kocat„rk V. M. T„rk edebiyat, tarihi.
Ba‚langistan bug„ne kadar…—Ankara, 1964.— 119 б.

[8] Өзекләр. Я.Әхмәтгалеева китабы аша китерелә (26 б.).

[9] *Габдрахман Таһирҗанов*. Әдәбият тарихында иҗтимагый-мәдәни мөнәсәбәтләрнең роле // Казан утлары.— 1975.— # 8.— 154 б.

[10] Урта гасыр төрки чыганакларында ул *Талас*, *Талаш* рәвешендә кулланыла. *Тәраз —* гарәпчә язылу шәкеле.

[11] *БартольдВ*. Сочинения.— Т II, часть I.— М.: Изд-во Восточн. лит., 1963.— С. 241.

[12] Татар әдәбияты тарихы.— I том.— 274 б.

[13] Татар әдәбияты тарихы.— I том.— 287 б.

*1996*

## ГАДЕЛЛЕК ҺӘМ ХАКЛЫК ҖЫРЧЫСЫ

### 1. Шәһре Казан шагыйре Мөхәммәдьяр

Безнең әби-бабаларыбызның яшәеш тарихы, рухы белән бәйләнешле кала-бистәләр шактый: Итил, Болгар, Сарай, Әстерхан, Касыйм, Төмән, Тобол, Кызылъяр (Петропавловск), Оренбург, Уфа, Җаек һ.б. Әмма болар арасында Казан, йолдызлар арасындагы ай кеби, аеруча мөһим урынны били: ул инде менә берничә гасыр буена татарның төп яшәү урыны гына түгел, ә кыйбласы, символик һәм реаль мәркәзе дә.

Болгар, Алтын Урда чорларында провинциаль шәһәр булган Казан XV йөзнең урталарында чын мәгънәсендә дәүләти башкалага, Көнчыгыш Европаның мөһим икътисади, сәяси һәм мәдәни үзәгенә әверелә. Моңа, әлбәттә, шәһәрнең уңайлы географик урыны, бигрәк тә Идел сәүдә юлында урнашуы сизелерлек йогынты ясый. Әмма бу каланың әһәмияте артуда төп фактор — Казан ханлыгы төзелү, аның бер гасырдан артык яшәве. Бу дәүләт хәзерге Татарстаннан берничә мәртәбә зур булган мәйданны били. Аның составына бүгенге Идел буе округының күпчелек өлкә һәм республикалары урнашкан җирләр, андагы халыклар керә. Казан — татарларның гына түгел, чуваш, удмурт, мари, башкорт һәм Идел-Урал төбәгендәге кайбер башка кавемнәрнең дә башкаласы.

Татар халкының берничә гасырлык дәүләти, икътисади, рухи казанышларына нигезләнгән Казан ханлыгы шактый зур үсешкә ирешә. Биредә күпләгән мәктәп-мәдрәсәләрнең булуы, әдип-галимнәрнең яшәве мәгълүм. Ислам төп дин булса да, илдә, Хәзәр һәм Алтын Урда мәмләкәтләрендәге кебек, вөждан иреге саклана. Татар теле — дәүләт теле, ил эчендә һәм халыкара аралашу вазифасын үти. Шуның белән бергә, мәмләкәттә башка телләрне куллануда да бернинди чикләүләр булмый. Татар укымышлылары һәм руханилары гарәп, фарсы һәм төрки телләрен яхшы белә, Шәрык классик әдәбиятыннан хәбәрдар була. Бу чорда «Корьән тәфсире» төзелү, Сәхибгәрәй хан ярлыгының гарәп, фарсы сүзләре катнаштырылган чуар телдә язылуы, Шәрифинең «Зафәрнамә…»сендә (1550) гарәпчә, фарсыча юлларның очравы, «Кәлилә вә Димнә» һәм кайбер башка әсәрләрнең татарчага күчерелүе үзләре үк күп нәрсә хакында сөйли.

Казан ханлыгының сүз сәнгате, элеккеге төрки-татар рухи казанышларына, фольклорга таянып, билгеле бер үсеш кичерә, шул дәвер тормышын сәнгати гәүдәләндерүдә уңышлы гына адымнар ясый. Бу чор әдәбиятының үзегендә — кеше, аның рухи дөньясы, әхлагы, иман-ышанулары, уй-хыяллары. Аерым ядкярләрдә социаль, иҗтимагый, тарихи мәсьәләләр дә гәүдәләнеш тапкан. Әмма, үкенечкә каршы, Урта гасырның башка дәверләре кебек, Казан ханлыгының да күпчелек матди һәм мәдәни истәлекләре юкка чыккан. Шуңа күрә безгә элеккеге чорлардан сакланып калган аз санлы ядкярләр аеруча кыйммәтле.

Татар халкы — элек-электән әдәби талантларга бай кавем. Шулай килеп чыккан ки, аларның күпчелеге Казан белән бәйләнешле. Безгә мәгълүм мәшһүр шагыйрьләрнең берсе Мөхәммәдьяр Мәхмүд Хаҗи углы әнә шундыйлардан. Аның тормышы, иҗаты Казан каласы белән табигый керешкән.

Хәзерге фәндә Мөхәммәдьярның туган елы 1497 елга нисбәт ителә. Шунысын да искәртик: 1997 елның август азагында, Бөтендөнья татар конгрессының икенче корылтае кысаларында шагыйрьнең тууына 500 ел тулу киң күләмдә һәм тантаналы рәвештә билгеләп үтелде.

Әдип Казан тормышының эчендә кайнаган, татар дөньясындагы вакыйга-хәлләрдән хәбәрдар булган. Яшәешнең куаныч-шатлыгын да, кайгы-газабын да күргән. Әгәр дә Мөхәммәдьяр «Мән бигин (кебек) әш адәмигә төшмәгәй, Мән тиггән утка кеше пешмәгәй»,— дип яза икән, бу — шигъри сурәт кенә түгел, ә авторның язмышына да теге яки бу дәрәҗәдә кагылышлы реаль чынбарлык. Аның гомер юлы да фаҗигале өзелә: Мөхәммәдьяр Казан делегациясе составында тылмач сыйфатында Мәскәүгә килә. Муром тирәсендә аны 1549 елның җәендә Явыз Иван гаскәриләре вәхшиләрчә үтерә. Әмма шагыйрь үзе китсә дә, якты дөньяда аның мәгънәле сүзләре, рухи халәтен гәүдәләндергән шигъри юллары калган. Алар халык күңелендә, гасырлар узуга да карамастан, һаман да яши, һаман да тере. Шагыйрьнең үзе хакында да төрле әсәрләр туып тора икән, бу да күп нәрсә хакында сөйли.

Мөхәммәдьярның бай иҗат мирасыннан бары өч әсәре генә билгеле: «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге». Аны кайвакыт «Ирләр бүләге»дип тә атыйлар, 1540), «Нуры содур» («Күкрәкләр нуры» яки «Күңелләр нуры», 1542) һәм «Нәсыйхәт». Әсәрләрнең исемнәре үк нинди мәгънәле, нинди символик! Шагыйрь үзен чын мәгънәсендә ир-ат, егет итеп тойган. Һәм ул күңелләрне нурландырырлык уй-кичерешләрен, киңәш-нәсыйхәтләрен килер буыннарга бүләк итеп калдырган.

Мөхәммәдьярның һәр өч әсәре дә лиро-эпик характерда, шигъри формада. Шуңа күрә аларны хәзерге фәндә еш кына поэма дип атыйлар. «Нәсыйхәт»тә бер генә сюжет булса, калганнарында аларның саны ике дистәгә якыная. Сюжет-хикәятләр, нигездә, авторның хис-кичерешләре, лирик чигенешләре, фәлсәфи уйланулары белән үреп барыла, еш кына төп фикергә, шагыйрьнең уй-ниятенә күрсәтмәлелек вазифасын үти.

Мөхәммәдьярны аеруча нинди мәсьәләләр борчый соң? Шагыйрь, гомумән, сүз сәнгатенең асылына һәм иҗтимагый вазифасына тугры калып, үзәккә кеше проблемасын куя һәм аны үзенә кадәрге әдәбиятта шәкелләшә (формалаша) килгән олуг идеаллар югарылыгында яктыртырга омтыла. Автор фикеренчә, инсан үзенең яратылышы, табигый асылы белән «пакь», «шәриф» (кадерле, затлы). Кешенең кем һәм нинди булып үсүе, яшәве исә тәрбиягә, җәмгыятькә, адәм баласының үз-үзенә мөнәсәбәтенә бәйле.

Мөхәммәдьяр әсәрләрендә «камил инсан» төшенчәсе шактый ачык төсмерләнә. Ул диндар, тыйнак, киң күңелле, юмарт, гадел, ярдәмчел, белемле. Автор бу төр сыйфатларның асылын, өстенлеген еш кына махсус рәвештә, аерым-аерым тасвирлый: «Нуры содур» әсәренең төп өлеше ун бабтан гыйбарәт. Бу бүлекләрдә «гадел кылу», «рәхим-шәфкать», «сәхавәт» (юмартлык), «хәя» (оялу), «сабырлык», «вафа» (тугрылык), «гафу кылу» һәм башка матур әхлакый сыйфатлар, игелекле эш-гамәлләр шактый тулы һәм җентекле яктыртыла, аларның рухын күрсәтмәле шәкелдә гәүдәләндергән гыйбрәтле хикәятләр дә китерелә. Шунысы үзенчәлекле: автор биредә һәм, гомумән, башка әсәрләрендә дә уңай инсани сыйфатларны еш кына аларның капма-каршылары белән бәйләнештә сурәтләргә ярата (юмарт — саран, дөрес — ялган…). Мондый алым шагыйрьнең уй-ниятләрен халыкка үтемлерәк җиткерүгә булыша.

Мөхәммәдьяр үз укучысын игелекле эш-гамәлләр генә кылырга, кыен хәлдә калучыларга ярдәм итәргә («кем егылганда кулын тот моңлының»), кешеләрнең күңелен бары «яхшылык берлә» алырга чакыра. Шунда синең яхшы исемең мәңгелеккә калыр:

Йийдер үтмәк (ашат икмәк) кешегә, и никү (изге) зат,
Бакый калыр бу җиһанда яхшы ат.

Урта гасырның күп кенә әдипләре кебек үк, Мөхәммәдьяр да кешенең үз гамәле өчен үзе җаваплы булуын кат-кат искәртә. Аның фикеренчә, игелек игелек булып, яманлык яманлык рәвешендә кире үзеңә кайта: «Коюг казып, үзе төшкәй», «Һәркем иксә, даим гыйвазын (әҗерен) табар…»

«Төхфәи мәрдан» авторы, күп кенә үз элгәреләре кебек, инсан гомеренең чикләнгәнлеге, үлемнең котылгысызлыгын яхшы тоя: «Бу үлемдин качса,— котылмас кеше, Үлмәен бу дөньяда калмас кеше». «Гафил»лек, ягъни ваемсызлык, пошмаучанлык, битарафлык — шагыйрь өчен тискәре төшенчәләр. Аның фикеренчә, һәр инсан Ходай Тәгалә тарафыннан үзенә бирелгән гомерне «гафил»лектә түгел, даим хәрәкәттә, игелекле эш-гамәлләр белән уздырырга бурычлы. Кешеләргә бәя биргәндә, автор аларның тышкы кыяфәтен түгел, ә «сирәт»ен, ягъни эш-гамәлен, төп бизмән дип хисаплый.

Мәгълүм ки, Урта гасыр төрки-татар дөньясында, бигрәк тә Алтын Урда дәүләтендә, аннан соңгы татар мәмләкәтләрендә дә хатын-кызга ихтирами мөнәсәбәт яши. Мондый вазгыятьне саклауда әдипләрнең дә роле зур. Харәзминең лирик герое үз сөйгәнен «пәри вә хурдан», «фәрештә»дән өстен куя, аны үзенең җаны белән тиңли. Сәйф Сараи хатын-кызны «садыйк», ягъни тугрылыклы дус дип саный, аны сөяргә, аның киңәш-теләкләрен тыңларга өнди. Мөхәммәдьяр да үз укучысын хатын-кызны ихтирам итәргә, аны ир-атлар белән тиң күрергә чакыра.

Шагыйрь фикеренчә, җәмгыятьне сафландыру, кешеләрне бәхетле итү, бер яктан, инсаннарның белемле, әхлаклы булуына, икенче яктан, хөкемдарларның гаделлегенә, зирәклегенә, мәгърифәтлелегенә бәйле. «Падишаһ,— ди Мөхәммәдьяр,— бер дәм (мизгел) гадел кыйлса», мәмләкәткә хөрлек, рәхәтлек килер; илдә шундый шартлар урнашыр ки, хәтта «Бүре берлә куй бергә су эчәр, Үрдәк берлә карчыга бергә очар». Бу юллар Казан ханлыгының, татар мәмләкәтләренең авыр, ыгы-зыгылы, һәлакәт алды елларында иҗат ителгән. Билгеле булганча, бу чор татар хакимият ияләренә нәкъ менә бердәмлек, зирәклек, икенче төрле әйткәндә, гадел хөкемдарга куелган сыйфатлар, эш-гамәлләр җитми. Шуңа күрә шагыйрьнең киңәш-теләкләре, аһ-зарлары, әрнү-бәргәләнүләре — илһам җимеше генә түгел, ә шул чор җәмгыятенең турыдан-туры кайтавазы да. Чөнки Мөхәммәдьяр өчен сүз әйтү, әдәби иҗат — «тылсым ачкычы», «әл-гаҗәб» (гаҗәеп) эш. Җиһандагы һәрнәрсә сүз, тел ачкычы белән ачыла («Ни ки телдин чыкты — ул башка килер»).

Сүзләмәкдә сән йөземне ак кыйл,—
Сүзләреми ил күңлигә йомшак кыйл.

Бу юллар — шагыйрь эшчәнлегенең төп девизы, асыл мәгънәсе.

*2002*

**2. «Ярмөхәммәд, сүзне тугры сүзләгел»**

*(Мөхәммәдьярның тууына 500 ел тулу уңае белән)*

Бу фани дөньяга адәм балалары килә дә китә, килә дә китә. Илләр, авыл-шәһәрләр корыла, җимерелә, яңалары төзелә... Әмма вакыт галиҗәнапларының рәхимсез эш-гамәлләрен үзара ялгаучы, тарау вакыйга-күренешләрне процесс рәвешенә китерүче, инсаният хәтеренең дәвамчанлыгын тәэмин итүче бер бөек көч

бар. Ул да булса — тел, сүз, китап. Аларда кешеләрнең яшәеше, тормыш тәҗрибәсе, уй-кичерешләре, табигать, тирә-юнь белән мөнәсәбәтләре миләнеп, оешып кала. Бу хакыйкать аеруча әдипләргә яхшы таныш. Чөнки алар — сүз осталары, гавам тормышының, инсан күңеленең елъязмачылары. Шуңа күрә дә әдипләр шигъри сүзгә, телгә гаять җитди карыйлар, сөйләмдә кеше эшчәнлегенең үзен дә, аның рухи гәүдәләнешен дә күрәләр. Телгә мондый мөнәсәбәт аеруча Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятында көчле. XI йөзнең мәшһүр шагыйре Йосыф Баласагунлы болай ди:

Үкеш сүзләмә сүз, бераз сүзлә аз,
Төмән сүз төгенен бу бер сүздә яз.
(Күп сөйләмә сүз, бераз (гына) сөйлә,
Ун мең сүз төенен бер сүз белән яз (чиш).)

Сәйф Сараи кешенең асылы белән теле арасында турыдан-туры бәйләнеш күрә («Кем аның телендәдер, бәс, ни һөнәр ки бар эчендә»). Төрки-татар укучысының яраткан китабы «Кыйссаи Сәйфелмөлек»тә дә сүз югары бәяләнә: «Әгәр сүз булмаса, кем кемне белер?! — Сүзеннән адәмиләр мәгълүм булыр». Мәҗлиси сүзнең «гәүһәр» булуын, аның кадерен белергә кирәклеген искәртә.

Моннан 500 еллар элек туып, үз Ватаны — Казан мәмләкәте белән бер үк чорда дөньядан киткән «Мәхмүд хаҗи углы Мөхәммәдьяр», ягъни «Ярмөхәммәд» өчен дә сүз, тел — изге төшенчә, Ходай Тәгалә биргән олуг байлык, тылсым ачкычы.

Адәм углының вөҗүде эчрә (яшәешендә) бел,
Бер тылсым, бер әлгаҗиб (гаҗәеп) ирер бу тел.
Кем җиһан эчендә, и дин олугы,
Гәнҗ, дәүләт, рәнҗ, михнәт — камугы (барчасы).

Ул тылсым ачкычы берлә әчелер,
Нә ки телдин чыкты — ул башка килер...
…Бәс, ни килсә башка, бел, телдин килер,
Адәмигә нә ки кыйлса, тел кыйлыр.

Шагыйрь сөйләмдә хакыйкатькә тугры калырга, «онга кибәк, серкәгә су катмаска», ихлас булырга, инсаннарның күңеленә хуш килерлек сүзләр генә сөйләргә чакыра:

…Кем олуглык теләсә даим үзе —
Барча берлә хуш, күни (дөрес, тугры) булсын сүзе…

…Кеше ялган сүз белә тапмас нәҗат (котылу),
Тугры сүз берлә табар даим хәят (тереклек).

Мөхәммәдьяр безгә билгеле һәр өч әсәрендә дә (алар: «Төхфәи мәрдан», ягъни «Егетләр бүләге», 1540; «Нуры содур», ягъни «Күкрәкләр нуры», 1542; «Нәсыйхәт») әдипнең төп коралы булган сүз ярдәмендә үзенең гуманистик идеалларын, матур җәмгыять турындагы уй-хыялларын бәян итәргә омтыла. Шагыйрьнең асыл максаты — камил инсан тәрбияләү. Ул бу төр затны, реаль шәхес булудан бигрәк, өлге, идеал рәвешендә күзаллый, аны гомуми, галәми камиллеккә ирешүнең алшарты, хәят гармониясенең хәлиткеч буыны итеп карый.

Әдип фикеренчә, инсани камиллеккә ирешү өчен кешенең билгеле бер сыйфатларга ия булуы зарури. «Нуры содур» әсәрендә аларның шактый тулы системасы, үзенә күрә бер кодексы бирелгән: гаделлек, рәхим-шәфкать, юмартлык, оялчанлык, газәват, сабырлык, сүздә тору, тугрылык, телне тыю, гафу итү. Шагыйрь бу сыйфатларның һәрберсенә махсус баб (бүлек) багышлый: әүвәл аларның төп мәгънәсен, асылын ачыклый, алга таба гыйбрәтле сюжетлар ярдәмендә бу төр күркәм сыйфатларның шәхси һәм иҗтимагый кыйммәтен гәүдәләндерә. Еш кына ул аларны тискәреләренә (гаделсезлек, саранлык, гайбәтчелек һ.б.) каршы куеп тасвирлый. Антитезалы фикерләү автор сүзләренең үтемлелеген арттыра.

Мөхәммәдьяр һәр ике поэмасында да гаделлекне беренче урынга куя. Һәм ул бу сыйфатны инсаннар, аеруча җаһ вә дәүләткә ия булган затлар, ягъни хөкемдарлар өчен зарури саный. Шагыйрь язуынча, гаделлек хәтта гыйбадәттән дә өстенрәк; һәрбер эш-гамәл гаделлеккә корылган булырга тиеш.

Гадел берлә ил гыймарәт (төзек) булыр уш,
Барча эшләр табар аның берлә хуш.
Гадел булыр барча эш башы, белең,
Гадел берлә даимән, бәс, эш кылың.

Халкыбыз әхлагында элек-электән «оят» (хәя) төшенчәсенә нык игътибар ителгән. Кызганыч ки, бүген бу сүзне без «оятсыз» мәгънәсендә адым саен ишетәбез. XVI йөз шагыйре Мөхәммәдьярның оят турындагы шигъри юллары хәзерге чорга да аваздаш яңгырый: «Ир хәя берлә күрер дәүләт йөзен»; «Ул оялса Тәңредин, кыйлмаз йаман, Һич кемирсәгә тикермәс ул зийан»; «Кем эчендә саклар ул оятыны, Изгелек берлә чыкарыр атыны»; ...Оятсыз кешедә иман йук. Оятсызлык — авыру ул, дәвасы юк...»

Алтын Урда шагыйре Хисам Кятиб юмартлыкны («сәхавәт»не) инсан әхлагының югары дәрәҗәле сыйфаты итеп карый.

Ир әгәр булса сәхавәт һәм кәрәм,
Гайбе йук үзгә һөнәр булмаса һәм.

Мөхәммәдьяр да юмартлыкны барлык башка кимчелекләрне каплый торган сыйфат рәвешендә күзаллый: «Кем сәха ирер иргә олуг һөнәр»; «Барча гаебләрне сәхавәт йабар»... (Гомумән, Хисам Кятиб белән «Нуры содур» авторы арасында охшашлыклар күп. Төп аерма шунда: беренчесендә киная, тәнкыйди пафос, икенчесендә уңай күренешләрне турыдан-туры тасвирлау өстенлек итә.)

Мөхәммәдьярның башка әхлакый сыйфатлар хакындагы фикерләре дә гаять кызыклы. Рәхимле, шәфкатьле булу, ди автор, күңелне йомшарта, нурландыра, Аллага якынайта. Сабырлык максатка ирешергә булыша («Сабыр берлә барча эш хасыйл булыр, Сабыр кыйлган даимән гакыйл булыр»). «Вафа», ягъни вәгъдәгә тугрылык инсанны олуг итә, сафландыра, бәхет-сәгадәткә юнәлтә. Гафу кылу — чын ирлек билгесе («Гафу кыйлмак ирер ирнең ирдәме»).

Үз-үзеңне пакьләү, сафландыру, рухи яктан савыктыру, нәфескә бирелмәү, тойгыларыңа гакылны хуҗа итү инсани камиллеккә ирешүдә мөһим роль уйный. Шагыйрь һәртөрле эш-гамәлдә үзеңне башкалар урынына куеп карарга («Үзеңә ни — үзгәгә аны сакын, йыглатып...йийма үксезнең хакын»), кешеләрнең кайгысына кайгырырга, шатлыгына шатланырга («Бер үзгәгә килсә яхшы — шад булмак»), инсаннарга игелек кылырга («Яманлык кыйлгучыга кыйлма яман, Яхшылык кыйл, гәр булдырсаң һәр заман»), ышанырга («Кеше сәндин күңел өзсә, сән өзмәгел») чакыра.

XIV йөз шагыйрьләре Хисам Кятиб «Һәр кем ирсә нә иксә — ургай аны», Сәйф Сараи «Күзәгә (савытка, чүлмәккә) ни койсаң, аны эчкәсән» диләр. Мөхәммәдьяр да бу әхлакый принципка теләктәш. Аның карашынча, үзгәләргә кылган начарлыгың ахыр чиктә янә үзеңә кайта: «Кем яманлык кыйлса, ул табкай җәза»; «Коюг казып, үзе төшкәй». Шунысы мөһим: үз гамәлең өчен үзең җаваплы булу идеясе соңгырак дәвер әдәбияты өчен дә чит түгел. Ризаэддин Фәхреддин үзенең «Сәлимә, яки Гыйффәт» романында (1899), тәрбия турында сүз алып барганда, болай ди: «Ни сачсаң — шуны урырсән» дип бабаларымыздан ядкяр калмыш сүз гаять тугры бер хикмәт улса кирәк».

Мөхәммәдьяр гакылы бар инсан, кеше күңелен рәнҗетмичә, бары игелек, файда гына китерергә бурычлы дип искәртә («Нәфегъ тикүр адәмигә сән бүген, Гакыйл ир, ир күңлигә салма түңел»). Элеккеге әдәбиятта юмартлыкны, игелекне яңгыр белән чагыштыру бар. Мөхәммәдьяр да ул сурәтне файдалана: «Нәфегъ тикүр барчага ямгур бикин».

Урта гасырның күп кенә әдипләре кешене олы итеп, аның потенциаль мөмкинлекләрен зурлап күрсәтәләр. Котб үзенең «Хөсрәү вә Ширин» романында (1342) менә ничек яза:

Гаҗәп шәхес ирер бу адәми зат!
Булыр мум адәми әлгендә пулат
(Адәм кулында корыч та балавыз кебек булыр).

Булыр, бел, эш башлагынча дөшвар (кыен),
Ни эш башланса, кыйлныр ахыр, әй йар.

Һич эш адәм углыдан котылмаз,—
Мәгәр үлмәк кем-анда чара булмаз.

Мөхәммәдьярның да инсанга ышанычы зур. Элеккеге язма телебездә гарәп-фарсыдан кергән «һиммәт» сүзе еш очрый. Ул тырышлык, сәләт, көч, мөмкинлек, теләк, талант һәм башка шундый мәгънәләрне белдерә. «Төхфәи мәрдан» авторы да инсанны бөек һиммәтле итеп күрергә тели («Ир углының һиммәте кәрәк»). Уңай каһарманнарын Мөхәммәдьяр еш кына «фөтүвәт» (затлылык; егетлек, батырлык…) иясе, мөрәүвәтле (киң күңелле; кешелекле, затлы) дип атый («Ир аталганга мөрәүвәт һәм кәрәк»).

Кыскасы, күркәм әхлакый сыйфатларга, белем-һөнәргә, гуманистик эш-гамәлләргә ия булган камил инсан — Мөхәммәдьярның идеалы. Шул нигездә ул иҗтимагый мөнәсәбәтләрне савыктырырга, бәхетле, имин җәмгыять корырга хыяллана. Шагыйрьнең бу теләк-омтылышлары — абстракт, зәминсез гомуми төшенчәләр генә түгел, ә шактый дәрәҗәдә шул чор, реаль җирлек белән билгеләнгән социаль ихтыяҗ җимешләре дә.

«Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» иҗат ителгән еллар — татар дөньясының эчке һәм тышкы каршылыклар белән кайнаган чоры. Тәхет өчен көрәш бара, халыкта бердәмлек җитми. Мәскәүнең мәкерле агрессив сәясәте татар мәмләкәтләрен болгата, берсен икенчесенә каршы котырта. Шушындый шартларда шагыйрь тормышта сыналган, әдәбиятта тупланган әхлакый тәҗрибәне, инсани идеалларны бәгырь казанында кайнатып, зиһен хәзинәләре белән баетып, үз чоры укучысының җанына, рухына сеңдерергә омтыла, икейөзлелекне, алдауны кире кагып («Ләкин җырга матур ялган нигә, Күңел алдый торган сүз нигә?!» *Әхмәт Рәшитов*), хаклыкны, тугрылыкны үзенең кыйбласы итә…

...Татарның Казан, Әстерхан һәм башка мәмләкәтләре дә, алар белән бергә Колшәриф, Мөхәммәдьярлары да юкка чыга. Никадәр «сүз гөлләре», җимеш бирмичә, киселеп кала!

Шагыйрь халкы өчен бөтен шартлар
Тудырылган тизрәк үләргә.

Кайда барып бәрелергә белми,
Чәбәләнә алар дөньяда,

Яшәүләре гел тәмугтан торгач,
Оҗмахларын эзләп югала...

(*Әнгам Атнабаев.* Син ашыктың, без соңладык)

Татар халкының «Япанчылар җыры»нда мондый юллар бар:
Яланда-япанда эзләрем калыр,
Үзем китсәм дә, сүзләрем калыр.

Олуг идеаллар белән янган, шәхси тормышында күп кыенлыклар кичергән Мөхәммәдьярның татар тарихында эзләре, мәдәни мираста сүзләре калган. Аларда халкыбызның рухи байлыгы, шагыйрьнең йөрәк җылысы, моңы.

Казан зират караучысы түгел,
Бер атаклы улы халыкның,
Мөхәммәдьяр —безнең күңелгә яр,
Ничек чорлар аша калыктың?!
(*Рәдиф Гаташ*. Татар китабы)

* * *

Дөньяга килгән һәр инсан үз халкының тарихын, рухи тәҗрибәсен, үзе өйрәнеп, үз шәхесе аркылы уздырырга бурычлы. Бары шунда гына милләтнең нормаль яшәеше, үсеше тәэмин ителә ала.

Рухи хәтер дәвамчанлыгы шактый дәрәҗәдә әдәби мирасны мәктәптә өйрәнүгә бәйле. Соңгы вакытта әдәбияттан яңа программалар, дәреслекләр төзелде, күп кенә методик әсбаплар дөнья күрде. Аларда элеккеге ядкярләргә дә шактый урын бирелгән. 90 нчы елларга кадәр әдәбият тарихы курсында Борынгы һәм Урта гасыр чорына, мәсәлән, барлыгы 4 сәгать каралган булса, хәзер исә бу кадәр вакыт Мөхәммәдьярның берүзенә бирелгән. Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларының X сыйныф программасында да шагыйрь иҗатын өйрәнү күздә тотылган. Киләчәктә, әлбәттә, Мөхәммәдьяр әсәрләреннән аерым үрнәкләрне түбән һәм урта сыйныфларда да уку әйбәт булыр иде.

Әдәбият тарихы курсында, ягъни югары сыйныфларда Мөхәммәдьяр иҗатын өйрәнгәндә, безнең уебызча, түбәндәгеләргә игътибар итү зарур.

Шагыйрь әсәрләрен күпгасырлык татар сүз сәнгатенең бер буыны итеп карау, ягъни әдип иҗатын әдәби-тарихи контекстта тикшерү шарт. Мәгълүм булганча, Мөхәммәдьяр үзенә кадәрге күп кенә әдәби казанышларны, җөмләдән Йосыф Баласагунлы, Кол Гали, Котб, Хисам Кятиб, Сәйф Сараи тәҗрибәләрен мул файдалана, баета, үзеннән соңгы буыннарга тапшыра. Аның традицияләре Мәүла Колый, Утыз Имәни, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай иҗатларында уңышлы дәвам иттерелә.

Мөхәммәдьяр иҗатын өйрәнүнең үзәгендә аның әсәрләре торырга тиеш. Шагыйрьнең поэмалары 1966 елда аерым китап булып басылган иде. «Борынгы татар әдәбияты»нда (1963), «Татар поэзиясе антологиясе»ндә (1 китап, 1992), 9 нчы сыйныф өчен «Татар әдәбиятыннан хрестоматия»дә (1995) шагыйрь поэмаларыннан үрнәкләр урнаштырылган. Хәзерге вакытта Шакир ага Абилов тарафыннан Мөхәммәдьяр әсәрләренең тулы, тәнкыйди басмасы әзерләнә. Шәт, ул, Алла боерса, тиз көндә дөнья күрер. (Бу китап 1997 елда нәшер ителде.)

Текстның оригиналда, укытучы тарафыннан шәрехләп укылуы нәтиҗәле. Уку процессында аңлашылмаган сүзләрне, гыйбарәләрне ачыклау, мөһим фикерләргә, мәкаль-әйтемнәргә басым ясау, шигъри сурәтләрне һәм чараларны күзәтү зарур. Билгеле бер күнекмә алгач, укучылар өзекләрне үзләре дә укый ала. «Мирас» журналында (1996.— # 9; 1997.— # 6…) шагыйрь әсәрләренең хәзерге телгә тәрҗемәсе дә басылып килә. Аны да педагогик процесста файдаланырга мөмкин.

Мөхәммәдьяр иҗаты шактый катлаулы һәм бай. Аны өйрәнү вакытында укытучы дәреслекләрдән, «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томыннан (1984), «Мирас» журналының шагыйрьгә багышланган махсус саннарыннан (1996.— # 9; 1997.— # 6) һәм башка басмалардан темага мөнәсәбәтле күп нәрсә таба ала. Бу төр материалларның кайберләре буенча укучылардан доклад-рефератлар да хәзерләтергә мөмкин.

Мөхәммәдьяр әсәрләренең үзәгендә — әдәп-әхлак проблемалары. Аларны өйрәнгәндә, әхлакый сыйфатларның асылын аңлау, гаделлек, рәхим-шәфкать, оят һәм башка төшенчәләрнең бүгенге көнебез өчен дә аваздаш булуын искәртү әһәмиятле. Әдип поэмаларындагы иҗтимагый, социаль мәсьәләләргә дә укучыларның дикъкатен юнәлтү файдалы.

Мөхәммәдьяр поэмаларында шактый гына шигъри хикәятләр бар («Шаһ Һарун», «Заһид», «Игелекле кыз…», «Җеп эрләп сатучы ир белән хатын», «…Нәүширван», «Муса», «Хәммал» һ.б. турында). Алар тормыш, яшәеш, инсан өчен хас булган гомуми типологик вазгыятьләрне гәүдәләндерүләре белән тәрбияви яктан аеруча гыйбрәтле. Шуңа күрә бу төр хикәятләрне укуга, сюжетларын үзләштерүгә, эчтәлекләрен сөйләтүгә игътибар итү шарт.

Соңгы вакытта Казан ханлыгы чорын әдәби үзләштерү юнәлешендә мөһим генә адымнар ясалды. Р.Батулла, М.Хәбибуллин, Ф.Латыйфи романнарында, мәсәлән, Мөхәммәдьяр образы да бар. Шагыйрь иҗатын өйрәнгәндә, бу төр әсәрләрне дә күз уңыннан ычкындырырга ярамый. Чөнки аларда гыйбрәтле вакыйга-хәлләр гәүдәләндерелә, мөһим генә мәсьәләләр яктыртыла. Мәсәлән, Әхмәт Рәшитовның Казан мәмләкәте чорына мөнәсәбәтле өч поэмасы (трилогиясе) бар: «Сөембикә», «Колшәриф», «Мөхәммәдьяр».

Болар өчен фикер-кичерешләр тыгызлыгы, вакыйга-хәлләр драматизмы, публицистик аһәң хас. «Мөхәммәдьяр» поэмасы (Мирас.— 1996.— # 9) XX гасыр шагыйре белән XVI йөз әдибе арасындагы әңгәмә-бәхәскә корылган. Чорлар диалогы аркылы автор татарның аянычлы тарихын, фаҗигале язмышын, киләчәккә өмет-хыялларын гәүдәләндерергә омтыла. Әйтерсең ул ерак бабасы Мөхәммәдьяр белән киңәш-табыш итә, аңа хисап бирә, аннан ярдәм-таяныч көтә. Әсәр «Нуры содур» авторы тарафыннан әйтелгән түбәндәге юллар белән төгәлләнә:

Я, хушлашыйк… ни әйтим соң ахыр сүздә;
Минем урын — ахирәттә, дөнья — сездә;
Киңәшем бер: түз, сабыр бул, өмет өзмә,
Илгә кирәк хакыйкатьне үзең эзлә.

Билгеле ки, Мөхәммәдьярның тәрҗемәи хәле хакында мәгълүматлар юк диярлек. Төп чыганак — шагыйрьнең үз әсәрләре. Аларда мөһим генә детальләр, фактлар һәм, иң әһәмиятлесе, әдипнең рухы бар. Илдар Юзеев «Чын Юзине күрәсегез килсә, Минем чын йөземне — дәфтәрләрнең Үзем язганыннан эзләгез!» — дип (Казан утлары.— 1997.— # 1.—4 б.), юкка гына әйтмидер.

Мәгълүм булганча, романнарда һәм поэмаларда Мөхәммәдьярның тормышы төрлечә бирелә. Аларда хыялый, уйдырма моментларның булуы табигый, хәтта зарури да. Чөнки бу авторлар шагыйрьнең фәнни биографиясен язуны максат итеп куймыйлар, алар әдәби әсәр иҗат итәләр. Шуңа күрә Мөхәммәдьярның тәрҗемәи хәлен, эшчәнлеген өйрәнгәндә, үзәккә реаль факторларны, тарихи мәгълүматларны кую мәҗбүри. Башкаларын фараз рәвешендә генә әйтергә мөмкин.

Мөхәммәдьяр темасын укытучы күп төрле ысуллар, чаралар һәм формалар ярдәмендә ача ала: лекцияләр, шәрехләп һәм сәнгатьле уку, эчтәлекне сөйләү, анализлау, язма эшләр, доклад-рефератлар тыңлау, конференцияләр үткәрү, әдәби кичәләр оештыру, альбомнар төзү, дивар газеталары чыгару, шагыйрь әсәрләрен һәм аңа мөнәсәбәтле язмаларны сәхнәләштерү һ.б. Күп кенә мәктәп укытучыларының хәзер бу юнәлештә туплаган бай тәҗрибәләре бар.

* * *

Хәзерге чор шагыйрәсе Фирдәвес Бәшированың «Киләчәк» исемле парчасында мондый юллар бар:

Кат-кат кайтып, кешеләргә һәрчак
Үткәннәре бәя бирәчәк.
Карындагы баласыман туа
Үткәннәрдән безнең киләчәк.

Әйе, үткән, хәзерге һәм киләчәк бер-берсе белән аерылгысыз бәйләнешле. Яшәргә теләгән халык үткәненнән сабак алып, үзенең аксакаллары белән киңәш-табыш итеп, киләчәккә карап яши. Тугры сүзле шагыйрь Ярмөхәммәд тә —шундый мөхтәрәм затларның берсе. Әхмәт Рәшитов сүзләре белән әйткәндә, аның әсәрләре «әле һаман күңелләрне нурлап», безгә көч һәм ялкын өстәп тора.

*1997*

**ЗАТЛЫ ИНСАН КОЛШӘРИФ**

Казан ханлыгы йөз елдан артыграк вакыт дәвамында гына яши. Тарих өчен бу бик аз. Әмма татар халкы язмышында ул мөһим урын тота. Казан иле, бер яктан, халкыбызның борынгы Төрки, Хәзәр, Болгар, Кыпчак һәм аеруча Алтын Урда мәмләкәтләреннән үк килүче дәүләтчелек традицияләрен дәвам иттерә. Икенче яктан, башка татар ханлыклары (Кырым, Әстерхан, Олы Урда, Касыйм, Нугай, Себер) белән беррәттән, халкыбызның этник үсешенә, мәдәниятенә шактый өлеш кертә. Әмма, ни үкенеч, Казан мәмләкәтенең архивы, бай китапханәләре, мәдәни истәлекләренең күпчелеге илбасарлар тарафыннан юк ителгән. Мәскәүнең соңгы 450 елдагы рәсми сәясәте дә татарны хәтерсезләндерү юнәлешендә зур эш башкарган. Шул сәбәпле без бүген Казан ханлыгының һәм башка татар илләренең эчке тормышы, кешеләре хакында бик аз беләбез. Мондый шартларда безгә бүгенгә кадәр сакланып калган һәр факт, һәр ядкяр, һәр исем кыйммәт. Алар безгә элеккеге тормышыбызны күзалларга, әби-бабаларыбызның рухи дөньясын теге яки бу дәрәҗәдә ачыкларга ярдәм итәләр.

Казан ханлыгы дигәч тә, иң беренче чиратта, аның хөкемдарлары, Мөхәммәдьярлары хәтергә килеп төшә. Болар арасында Колшәриф тә дәрәҗәле, үзенә лаеклы урыннарның берсен били. Ул — элек тә, хәзер дә еш ишетелүче, телгә алынучы исем. Юкка гына Колшәриф хезмәт иткән сигез манаралы Җәмигъ мәчетне — Казан шәһәренең төп гыйбадәт йортын — бу зат үзе исән вакытта ук аның исеме белән йөртмәгәннәр. Әгәр дә хәзер мәшһүр Кремль калкулыгында күп манаралы мәһабәт мәчет бинасы төзелгән икән, бу да һич очраклы хәл түгел. Ул — тарихи хәтернең яңару, олуг затка бүгенге буынның хөрмәт билгесе.

Колшәрифнең туган елы билгеле түгел. Үлеме исә 1552 елның 2 октябренә карый. Риваятьләрдә аның 50 яшькә дә җитмичә якты дөньядан китүе искәртелә. Димәк, Колшәрифнең туган елын якынча XVI гасыр башларына, шартлы рәвештә 1503—1506 елларга нисбәт итәргә һәм шуңа мөнәсәбәттә шагыйрьнең 500 еллык юбилеен да үткәрергә мөмкин.

Язма чыганакларда Колшәрифнең укымышлы, затлы гаиләдән булуы күрсәтелә. Әти-әнисе, улларының киләчәген белгән кебек, аңа исемнең дә лаеклысын, җисеменә туры килешлесен бирәләр: Алланың кадерле, затлы, хөрмәтле колы. (Кайбер хезмәтләрдә аны Шәриф Кол дип атау, Кол Шәриф дип язу да бар.) Колшәриф төпле белем, ныклы инсани һәм әхлакый тәрбия ала, гомерен акыл, әдәп белән игелекле юлда уздыра. Мөхәммәдьяр кебек, аның тормышы һәм эшчәнлеге дә Казан мәмләкәтенең эчке һәм тышкы тормышы белән тыгыз бәйләнешле. Ул XVI йөзнең икенче чирегендәге сәяси, иҗтимагый, рухани, мәдәни вакыйгаларның үзәгендә кайный, дөресрәге, аларга юнәлеш бирүдә төп көчләрнең берсе була. Колшәриф 1546 елда, әтисе Мансур үлгәч, Казан руханиларының башлыгы (сәед) итеп сайлана. Мәмләкәтнең һәлакәт алды елларында ул ил белән җитәкчелек итү эшләрендә дә турыдан-туры катнаша, эчке һәм тышкы каршылыкларны, аеруча Мәскәү белән мөнәсәбәтләрне тыныч юл белән хәл итәргә омтыла. Аның хәтта 1551 елда рус хакимияте белән сәяси сөйләшүләрдә Казан делегациясе белән җитәкчелек итүе дә мәгълүм. Әмма, ни үкенеч, сугыш, басып алу нияте белән агуланган Явыз Иван һәм аның иярченнәре, төрле сәбәпләр табып, үзләренең агрессив сәясәтләрен дәвам иттерәләр. Мондый шартларда Колшәриф тә, башка ватандашлары белән берлектә, Идел-йортны, сөекле шәһәрен саклаучылар сафына баса һәм бу изге көрәштә батырларча һәлак тә була. Аның һәм кайбер башка татар укымышлыларының фидакарьләрчә көрәшүен рус гаскәрләре белән җитәкчелек иткән кенәз А.Курбский да билгеләп китә.

Колшәриф — Казан ханлыгының күренекле рухание, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, дипломаты. Бер үк вакытта, ул — билгеле әдип тә. Әмма, кызганыч ки, ул иҗат иткән әдәби әсәрләрнең бик азы гына сакланган. Дини хезмәтләренең үзләре генә түгел, исемнәре дә билгесез.

Татар тарихы, мәгарифе, әдәбиятыннан аз гына хәбәрдар булган кешегә дә «Бакырган китабы» теге яки бу дәрәҗәдә таныш. Хрестоматия, антология тибындагы бу китап элек-электән татар дөньясында гаять киң таралган. Аның кульязмалары, Казан басмалары бик күп. Татар мәктәп-мәдрәсәләрендә уку-укыту әсбабы рәвешендә кулланылган «Бакырган китабы»нда, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Нәсими, Фәкыйри һәм Урта гасырда иҗат иткән кайбер башка төрки-татар шагыйрьләренең әсәрләре белән беррәттән, Колшәрифнең дә дүрт шигыре урын алган (барлыгы — 70 юл). Алар газәл, мөнәҗәт жанрларында. Бу шигырьләр ритмик-интонацион яктан камил, эчтәлекләре белән дини-суфыйчыл характерда. Лирик герой Алланы зурлый, бөтен күңеле белән аңа тартыла. Автор «әүвәле», «ахыры» билгесез булган бу «көһнә», ягъни карт, сәләмә дөнья белән мавыкмаска, үлемне һәрчак истә тотарга чакыра. Һәр инсан үз күңелен пакьләргә, «гафләт» (ваемсызлык) йокысына бирелмәскә, нәфескә иярмәскә, иляһи гыйшыкта яшәргә бурычлы. Шагыйрьнең «И күңел, бил баглама, күпне кичергән дөньядыр» дип башланган газәле — татар суфыйчылык поэзиясенең классик бер үрнәге. Ул күп кенә шагыйрьләргә, шул исәптән Тукайга да йогынты ясый.

1899 елда Казанда «Кыйссаи Хөбби Хуҗа» исемле бер кечерәк кенә китап басылып чыга. Аны аерым галимнәр Колшәрифкә нисбәт итәләр.

«Кыйссаи Хөбби Хуҗа» — лиро-эпик характердагы әсәр. Ул шигырь белән язылган. Әмма ахыргы бер-ике бите чәчмә юллардан гыйбарәт.

Бу дастанның төп каһарманнары: Хәким Ата Сөләйман, аның хатыны Ганбәр, уллары Хөбби Хуҗа, Әсгар һәм Мәхмүд. Болардан тыш әсәрдә изге, абруйлы шәхес буларак Әхмәд Ясәви дә катнаша. Шунысы мөһим: бу персонажлар,— нигездә, тарихи затлар. Әмма дастанда алар, реаль шәхестән бигрәк, әкияти, романтик планда чыгыш ясыйлар. Мәсәлән, чалынган сыерлар Хәким Ата һәм Хөбби Хуҗа кодрәте белән янә терелә һәм утлап (үлән ашап) китәләр. Хөбби Хуҗа, Сак белән Сок кебек, кошка әверелә, Хозыр Ильясның аркадашына әверелә. Ананың улын югалтудан аһ-зар килүе, күз яшьләрен агызуы әсәрнең иң эмоциональ өлешен тәшкил итә.

Дастанда мөһим генә фикерләр гәүдәләнеш таба. Автор фикеренчә, ата-ана баласыннан көнләшергә тиеш түгел. Хәким Ата Хөбби Хуҗаның могҗизаларына, зирәклегенә тискәре мөнәсәбәттә тора, икебез дә «гариф» (акыл иясе) булып, илгә сыймабыз, ди. Мондый көнчелек аянычлы нәтиҗәләргә китерә. Улыннан мәңгелеккә аерылган ата үкенә, кайгы-хәсрәт диңгезенә чума.

Мәгълүм ки, Хәким Атаның хатыны Ганбәр — атаклы Богра хан кызы. Бервакыт ул иренең «тәне бик кара икән» дип уйлый. Шунда Хәким Атага, Алладан илһам килеп, миннән дә «карага барырсың» дигән фикер килә. Шулай булып та чыга. Ире үлгәч, Ганбәрне сыер көтүче бик «кара» кешегә — Зәңгигә бирәләр. Бу зат хатынын кыйнап, рәнҗетеп тора. Дастан ахырында шундый нәтиҗә ясала: «Ганбәр анадан мирас калды ирләрен яратмаган хатыннарга: ирләрен хурлап чыккан хатыннар әүвәле иреннән яманрак иргә баралар; яисә ирләре үлсә, шундый әүвәлге ире кебек булмый, диләр».

Күптән түгел генә безнең рухи тормышка Шәрифинең (Шәриф Хаҗитарханиның) «Зафәрнамәи вилаяти Казан» («Казан мәмләкәтенең җиңүе», 1550) исемле әсәре әйләнеп кайтты. Чәчмә һәм тезмә юллар катнашмасыннан торган бу дастан — әдәби-тарихи яктан гаять мөһим ядкяр. Анда Казан — Мәскәү сугышының реаль фактлары, вакыйгалары сәнгати-публицистик стильдә бирелгән. Авторның илбасарларга тискәре мөнәсәбәте, Казанны яратуы, чын ватанпәрвәр булуы ачык күренеп тора. Кайбер галимнәр «Зафәрнамәи вилаяти Казан» әсәрен дә Колшәрифкә нисбәт итәләр. Әмма чынлыкта бу авторлар — икесе ике зат. Чөнки аларның тел-стильләрендә, фикерләүләрендә аермалар бар. Шәрифи Хаҗитархан, ягъни Әстерхан белән бәйләнешле. Колшәриф исә Казан җирлеге кешесе. Тарихи чыганакларда да Колшәрифнең Хаҗитархани тәхәллүсе (кушаматы) телгә алынмый. Кыскасы, бу ике затны тәңгәлләштерерлек дәлилләр хәзергә юк.

Колшәриф — үткән тарихыбызның, мәдәниятебезнең күренекле бер вәкиле. Ул безнең рухи тормышыбызда тирән эз калдырган. Шуңа да халык аны онытмый. Шагыйрь, рухани, дәүләт эшлеклесе булган бу зат хакында сәнгать әсәрләре, әдәби ядкярләр туып тора. Әхмәт Рәшитнең «Колшәриф» поэмасы — әнә шундый әсәрләрнең берсе. Анда бу мөхтәрәм инсанның катлаулы, каршылыклы язмышы, шул чордагы фаҗигале хәлләр шактый тулы гәүдәләндерелә. Поэманың ахырында автор, чәчмә юлларга күчеп, болай ди:

«И Раббем! Хак динебезне, күркәм гореф-гадәтләребезне иң авыр заманнарда мыскыл-мәсхәрәдән аралаган Колшәриф сәед кебек олуг имамнарыбызны, кяферләрдән тән вә җан газаплары татып дөнья куйган соңгы ханларыбызны изгеләр рәтенә исәплә!»

*2002*

**ТАҖЕДДИН ЯЛЧЫГОЛ**
**ҺӘМ АНЫҢ «РИСАЛӘИ ГАЗИЗӘ» ӘСӘРЕ**

Милли дәүләтчелеген югалтканнан соң, татар халкы аяусыз эзәрлекләүләргә, коточкыч геноцид сәясәтенә дучар ителә. Әмма шуңа да карамастан, гәрчә зур югалтулар белән булса да, ул үзенең милли асылын, телен, динен, моңын, гореф-гадәтләрен саклап, аларны алдагы буыннарга тапшыра килә. Милли барлыкны саклауда аеруча белем-мәгърифәт зур роль уйный. Безнең әби-бабаларыбыз караңгы елларда да мәктәп-мәдрәсәләр ачарга, китапка мәхәббәтне сакларга омтыла. Шушы чорларда без күпләгән китапларның күчерелүен, иҗат ителүен беләбез. Дәүләтле халыклар күзлегеннән, бүгенге көн югарылыгыннан караганда, бәлкем, ул чор мәгарифендә, мәдәниятендә күп төрле җитешсезлекләр, гайре табигый нәрсәләр дә бардыр. Әмма халкыбызның колониаль изелү чорындагы рухи байлыгын, язма истәлекләрен татар җирлегендә, татарның ачы язмышы белән тыгыз бәйләнештә карарга кирәк. Шунда гына без үз зыялыларыбыз эшчәнлегенең мәгънәсен, татар китапларының вазифасын һәм әһәмиятен тиешенчә аңлый һәм аңлата алырбыз.

Дәүләтле халыкларның күп кенә әдип-галимнәре дөньяның матди һәм рухи ләззәтләрен татып, хөкемдарларының ярдәмен тоеп, затлы сарайларда иҗат итсәләр, татарның Мәүла Колый, Утыз Имәни, Ялчыголлары юньләп торыр урын да таба алмыйча, каңгырып, гомерләрен ачлы-туклы уздырырга мәҗбүр булалар. Аларның шушындый шартларда әдәби, гыйльми, педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүләре — үзе бер батырлык вә фидакарьлек. Шуңа күрә мондый затларның тәрҗемәи хәленә, язган китапларына игътибарлы булу, кимчелекләренә киң күңеллелек күрсәтү безнең әхлакый һәм инсани бурычыбыз.

I

Кыен чорларда халыкка белем һәм тәрбия бирүдә армый-талмый хезмәт түккән зыялыларыбыз шактый. Алар арасында исеме, эшчәнлеге күпләргә мәгълүм булган Таҗеддин Ялчыгол да үзенә лаеклы урынны алып тора. Аның тормыш юлы катлаулы, сикәлтәле. Тәрҗемәи хәлендә (биографиясендә) томанлы, каршылыклы сәхифәләр дә җитәрлек. Шулай да Таҗеддин Ялчыголның язма мирасына, иң беренче чиратта «Тәварихе Болгария» («Тарихнамәи Болгар») әсәренә, нәсел-нәсәбенең истәлекләренә, Г.Чокрый, Ш.Мәрҗани, Р.Фәхреддин, Г.Газиз, Г.Рәхим, М.Госманов, Ә.Харисов, М.Гайнетдинов, Д.Гарифуллин, И.Галәветдинов, М.Әхмәтҗанов, Р.Хәмәдиев һәм кайбер башка авторларның мәкалә-хезмәтләренә, үзебезнең шәхси тикшеренүләргә нигезләнеп, әдипнең тәрҗемәи хәлен һәм күпкырлы эшчәнлеген билгеле бер дәрәҗәдә ачыкларга мөмкин.

Таҗеддин Ялчыгол якынча 1768 елның октябрь аенда, әдипнең үз сүзләре белән әйткәндә, «Әй дәрьясы илән Арша дәрьясы арасында Курмаш-елга авылында» туа[1]. Мәгълүм булганча, Әй — Көньяк Уралдан башланып хәзерге Чиләбе өлкәсе (Златоуст) һәм Башкортстан җирләре (Кыйгы, Мәләвез... районнары) аша Караиделгә коючы елга. Арша — аның бер кушылдыгы. Таҗеддиннең әтисе Мәмәткол углы Ялчыгол (Ялчыкол) — күп мәртәбәләр хаҗда булган рухани, мулла. Әнисе, туганнары хакында мәгълүматлар юк.

Таҗеддингә 8 яшьләр чагында, ягъни 1776 елда Ялчыгол мулла, улы белән бергә, Сәгыйд бистәсе, ягъни Оренбург Каргалысы аркылы Әстерхан төбәгенә юнәлә. Максаты — хаҗга бару. Фәндә аның күчеп китү сәбәбен Пугачев хәрәкәте белән бәйләп карау да бар. Мондый ихтималлыкның булуы бик мөмкин. Ни өчен? Чөнки крестьян хәрәкәтендә бик күп мөселман зыялылары да катнаша. Пугач хәрәкәте бастырылгач, анда катнашучыларны кулга алу, төрлечә эзәрлекләүләр башлана. Мондый шартларда күп кенә кешеләр качып, күчеп китәргә, эзләрен яшерергә мәҗбүр булалар. Ялчыгол мулланың да андыйлар арасына эләгүе гайре табигый түгел. Әдипнең үзе теркәгән биографик мәгълүматларындагы каршылыклы, томанлы яклар да, бәлкем, билгеле бер дәрәҗәдә шушы тарихи сәбәпләр белән аңлатыладыр?!

Мөһаҗир Таҗеддин һәм аның әтисе, Әстерхан төбәгендә бер еллап булгач, Дагстанга киләләр. Биредә алар Җаксай (Яксай) шәһәрендә яшәгән булса кирәк. Чөнки монда элек-электән нугай, комык, татар аралашып яши. Бу шәһәргә Таҗеддин Ялчыголның соңрак, 1827—1828 еллар аралыгында да килүе мәгълүм. Р.Фәхреддин искәртүенчә, әдип 1234/1819 елда да Җаксайда булган. Бу хакта Таҗеддин Ялчыголның «Һидаятел-хикмәт» ахырында мәгълүматлар бар (Асарь, VI җөзә, 1904.— 336 б.).

Әстерхан, Дагстан якларында Ялчыгол мулла балалар укыта, руханилык кыла, хаҗ сәфәренә мая туплый.

Таҗеддин әүвәл әтисендә белем ала, аннан Кавказ якларындагы мәдрәсәдә укый. Дагстанда дүрт еллап яшәгәч, Ялчыгол мулла 13 яшьлек улы белән Төркиягә юнәлә. Биредә алар Кече Азиядәге мөһим сәүдә һәм мәгърифәт үзәкләренең берсе булган Диарбәкер шәһәрендә (ул — хәзерге Төркиянең Сүрия, Гыйрак, Иран

чикләренә якын бер җирендә) туктыйлар. Ялчыгол мулла, улын бер танышында калдырып, үзе Гарәбстанга хаҗга китә. Таҗеддин бер мәдрәсәдә төрле фәннәрдән белем ала, мөстәкыйль яшәү күнекмәләрен үзләштерә. Бу хакта әдип үзенең «Тәварихе Болгария» китабында менә ничек яза: «...Андан (ягъни Дагстаннан) Диарбәкерә вардык. Ул заманда бән фәкыйрь Таҗеддин унөч яшемдә ирдем. Диарбәкердә бәне бер хуҗа әленә (кулына) биреб китде. Хода өчен бу угланчыкны әфәнделәрә вireб, тәхсыйле гыйлем кылсын дийү (белем алсын дип). Атамыз хөҗҗаҗел-мөслимин (мөселман хаҗилары) илән хаҗ китде. Бән фәкыйрь Таҗеддин атам мелла Ялчыголны ундүрт ел көтдем. Ундүрт ел эчендә бән әнвагы голумларны (төрле гыйлемләрне) тәхсыйль әйләдем (өйрәндем). Ахреләмр (ахырда; кайчан) Диарбәкердәге мөрәбби (остаз) хуҗам дөньядин үтде, бән атамны эстәйү (эзләп) Истанбула вардым» (Тәнкыйди текст, 38—39 б.).

Күп кенә авторлар Таҗеддин Ялчыголның Диарбәкердә 14 ел түгел, ә дүрт кенә ел яшәвен искәртәләр. Чөнки тәүге сан (ул ялгыш күчерелгән булса кирәк) әдип тормышының бүтән хронологик баскычлары белән каршылыкка керә.

Ялчыгол мулланың берничә ел буена улыннан аерылып тору сәбәпләре билгесез. Бәлкем, изге җирләргә баргач, ул авырып яткандыр. Бәлкем Гарәбстан якларында күңеленә хуш килгән шөгыль тапкандыр...

Остазы вафат булгач, Таҗеддин Ялчыгол, әтисенең кайтуын ишетеп, Госманлы мәмләкәтенең мәркәзенә — Истанбулга юнәлә. Алар мәчеттә очрашалар. Бу күренешне автор үзе менә ничек сурәтли: «Истанбулда мәсҗеде әхйада (мәчеттә, мәчет ихатасында) атамны күрдем. Ул хөҗҗаж (хаҗилар) илә рабигылъ-әүвәлнең ахыргы пәнҗешәнбесендә Истанбула кермеш. Бән иртәсендә җомга көнне күрдем. Бәне күрдеке заманда углы ирдеке икәнне белмәде. Бән белдем. Бәндән сөаль кылды: «Нә йирлек фәрзәндесән (углы син)?» — дийү. Бән әйтдем: «Болгарлык иштәкмен»[2],— тидем. Шул заман һушы китеб екылды. Һушына килде: «Таҗеддин, сәнмесән?» — тиде. Әйтдем: «Бәли (әйе), чигәргөшең (җигәргөшәң — сөекле балаң; бавырыңның парәсе), мөнгыйм (игелек иясе)»,— тидем. Янә аһ орыб, гакылы башындан китде. Мәсҗед әһле йаранлары хәйранә (хәйран) калдылар. Шул ахшам өч мәртәбә һушы китде» (Тәнкыйди текст, 39 б.).

Алга таба Таҗеддин Ялчыгол «ике ел» әтисе белән Истанбулда яшәвен искәртә. Биредә ул укыганмы, эшләгәнме,— анысы мәгълүм түгел. Автор ниндидер «Әхмәд әфәнде тәрбиясендә тору»ларын белгертеп куя. Истанбулдан аларның юлы «кәрван илә Хаҗитәрханә» юнәлә. Әстерхан төбәгендә «бер ел» торгач (әтисе «дәрес әйтә»), Мәскәүгә киләләр. Биредә ата белән угыл «алты ай» яшиләр. Аннан Ялчыголларның өч атна («өч җомга») Мәкәрҗәдә («Мәкәрийә кальгасендә»), «ике ай» Казанда торулары мәгълүм.

Алдагы тормышлары хакында «Тәварихе Болгария» авторы үзе болай дип яза: «Казандан Троиски[3] каласына кырык сум илә ат әҗарийә алыб (ат яллап), ямщиклар берлән чыкдык. Казандан чыкдыкымыз көн (чыккан көндә) әткәм: «Башым агрыйдыр,— тиде вә дәхи әйде: Әй балакаем, Әй дәрьясыны ахры күрмәмдер,— тиде.— Кайчан ки бән дөньядин үтсәм, бәнем каберемне гариб идеб, ташлаб, бәнем кабрем әтрафындан (тирәсеннән) ерак китмәгел, шул урында йорт-йир әйләнәл («яшә») вә дәрес әйткел, вә дәресне әгәрчә күздән калсаң да әйткел[4] ,вә һәм елында ике мәртәбә бәнем кабремә зиярәт иткел. Бу шартларымны йиренә килтерсәң, бән синдән хушындым (риза булырмын),— тиде.— Әгәр бивәфак (үтәмәсәң), бән сәндан әбәдән (һич тә; мәңгегә) разый дәгелмән,— тиде.— Һәм мондан гайре васыятьләрем вардыр,— тиде,— сандык эчендә дәфтәремдә табарсән»,— тиде. Әлкыйсса (кыскасы), безләр Казан шәһәреннән чыкыб, бу җанибә (тарафка) килдек. Юлымыз Мамадыш өязенә уграды (керде). Урта Сөн тидеке[4а] авылга йитдекемездә, әҗәл ирешде, дөньядин үтде алтмыш биш яшендә, рәҗәб аенда, әүвәлге җомгасыны Рәгаиб киче[5] диерләр. Шул кичдә җәүзәнең (ягъни май-июнь айларының аралыгына туры килүче Игезәкләр аеның) 24 нче йәүмендә (көнендә) тарихе һиҗрәтнең 1200 (миладиның 1786) елында, куй елында иде» (Тәнкыйди текст, 166—167 б.).

Атасыннан аерылуны Таҗеддин бик авыр кичерә. «Рисаләи Газизә» китабының ахырында ул, бу вакыттагы рухи халәтен яңартып, «гариб»леге, «Сөннең тагына» әтисен җирләве, «андин соң гаять хәзәндә (кайгыда) калуы», «аһ-зар итүе» хакында[6] яза[7].

Әтисе васыятенә тугры калып, Таҗеддин Ялчыгол «Сөн карьясендә өч ел дәрес әйтә», аннан якынча XVIII йөзнең 90 нчы еллар башында Зәй елгасы буйларына күчеп килә. Мәгълүм ки, бирегә, ягъни хәзерге Түбән Кама, Зәй төбәкләренә, Мамадыш якларыннан элегрәк тә күчеп утыручылар була[8] . Күрәсең, XVIII гасыр азакларында да ике арада бәйләнешләр яшәп килгәндер.

Уфа галиме И.Галәветдинов, шагыйрь Гали Чокрый (1826—1889) төзегән кульязмага нигезләнеп (ул Санкт-Петербургтагы Шәрыкшенаслык институтында саклана. Шифры — В 2673), әдипнең хәзерге Түбән Кама районында яшәү елларын болай билгели: 1792—1799 елларда, ягъни «йите ел» Җирекле (Зирекле, Каенлы) авылында, 1799—1824 елларда («екерме биш ел») — шул тирәдәге Кызыл Чапчак «карьясендә»[9] .

Әдип һиҗри белән 1240, ягъни милади белән 1824 елда хәзерге Зәй районының Мәлем (Югары Налим) авылына күчеп килә һәм калган 14 ел гомерен шунда уздыра[10].

Таҗеддин Ялчыгол — халкыбыз тарихының, Рәсәй мәмләкәтенең шактый катлаулы һәм каршылыклы чорында яшәгән әдип. Милли һәм социаль изү, төрле сугышлар һәм баш күтәрүләр, мөселманнарны эзәрлекләү, көчләп чукындыру һәм руслаштыру, фәкыйрьлек һәм ачлык — болар бар да бу чорга хас сыйфатлар. Шушындый кыен шартларда Таҗеддин Ялчыгол, үз туган теленнән тыш, гарәп, фарсы, госманлы (төрек) һәм кайбер башка телләрне белә, Шәрык гыйлемнәрен һәм мәдәниятен үзләштерә. Аны, төрле тармакларда кылган гамәлләренә, язган китапларына карап, энциклопедик табигатьле галим дип тә атарга мөмкин. Ул,— әлбәттә, барыннан да элек педагог. Әтисе васыятенә тугры калып, Таҗеддин Ялчыгол Мамадыш ягында да, Зәй төбәгендә дә «дәрес әйтә», ярты гасырдан артык гомерен халыкны белемле, тәрбияле итүгә багышлый. Шул чорга хас булганча, аның мөгаллимлеге руханилык эшчәнлеге белән үрелеп бара. Әдип халыкта гасырлар буена тупланып килгән ислам рухын сакларга һәм ныгытырга, милләттәшләрен чукындыру афәтеннән коткарырга омтыла. Билгеле булганча, Таҗеддин Ялчыгол — мәгълүм табиб, дарулар ясаучы да. Аны авылдан авылга, хәтта ераграк төбәкләргә, Ык буйларына да чакырып торалар. Шушындый сәфәрләр вакытында бу могтәбәр зат халыкны физик яктан гына түгел, әлбәттә, рухи яктан да дәвалый, кавемдәшләрен инкыйраздан сакларга, иманлы, белемле итәргә тырыша. Ул язган китапларның да төп өлеше нәкъ менә тәрбияви, дини-әхлакый ихтыяҗларны күздә тотып төзелгән. Алар, нигездә, шәрхи-аңлату характерында.

Таҗеддин Ялчыголның язма мирасы әле тиешенчә барланмаган, өйрәнелмәгән. Аның тарих, әдәбият, фәлсәфә, медицина (тыйб), фикъһе (хокук), илаһият һәм кайбер башка тармаклар буенча дистәдән артык китап язуы билгеле[11]. Югарыда телгә алынган Гали Чокрый кульъязмасында авторлыгы Таҗеддин Ялчыголга мөнәсәбәтле китаплар атала. Мәсәлән, шундыйлардан «Хәдисел-баб»ка шәрех (Җирекледә языла). Кызыл Чапчакта яшәгән вакытта язган китаплары: «Сөбател-гаҗизин»гә шәрех», ягъни «Рисаләи Газизә», «Кафия» китабына шәрех (ягъни «Әл-касыйдәтел-кафия». Аны «Гафия» дип тә йөртәләр), «Тәнбиһел-гафилин» («Ваемсызларны искәртү».—Бу әсәр «Рисаләи әййүһа әл-вәләд» ядкяренә шәрех), «Мөфатихел-Кодури» (Кодуринең «Холасател-җәүһәри» әсәренә шәрех), «Мөфатихел-һидая» («Хикмәтел-һидая»га шәрех), «Фәваиде-әшрәфийәт» («Тәлхис»кә аңлатма), «Фәваиде-җәлалийәт» («Тәгълимет-тарик» һәм «Китабе бәһтәрин» ядкярләренә шәрех), «Фәваиде-бәһаийәт»[12] («Гыйльме тыйб» — медицина турында), «Фәваиде-госсалийа» («Фәраиз»га тәсниф), «Тәрҗемәтес-салат» («Тәгълимес-салайа»га шәрех). 1240/1825 елда, Мәлем авылына күчкәч, язган китабы «Тәфсирү сидрәтел-мөнтәһи» («Һәфтияк»кә тәфсир)[13] дип исемләнгән. Таҗеддин Ялчыголга мөнәсәбәтле язмаларның берничәсе («Рисаләи Газизә», «Шәрхел-касыйдәтел-кафия», «...Тәгаллимес-салават», ягъни «Тәгълимес-салайа», «Шорутел-салават») Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» китабында да телгә алына[14].

Таҗеддин Ялчыгол язган тәфсир-шәрехләрнең тик берничәсе генә басылган («Рисаләи Газизә», «Тәфсирү сидрәтел-мөнтәһи», «Тәварихе Болгария»...). Күпчелеге кульъязма хәлендә.

Сарман районында табылган бер кульъязмада Таҗеддин Ялчыгол «24 кыллы татар гөсләсен, скрипка, думбра һәм тәгәрмәчле лираның сурәтләрен һәм алар хакында кыскача мәгълүматлар бирә»[15]. Аерым истәлекләрдә аның музыка коралларын үзе ясавы һәм аларда үзе дә уйнап җырлавы искәртелә.

**«Тәварихе Болгария»** (1806.— Аны кайвакыт «Тарихнамәи Болгар» дип тә йөртәләр) — әдипнең мәгълүм әсәрләреннән берсе. Аның хәзерге фәнгә дистәдән артык кульъязмасы билгеле. Күпчелеге Татарстан авылларында табылган. Әле күптән түгел генә бу әсәрнең бер нөсхәсе, Раиф Мәрдәнов тарафыннан Кукмара районында табылып, фәнгә мәгълүм булды[16].

«Тәварихе Болгария» тәүге мәртәбә, кыскартылып, М.Өмедбаевның «Ядкяр...» китабында нәшер ителә (Казан, 1897). Әсәргә сылтамалар, аннан аерым өзекләр татарча, русча, башкортча чыккан төрле китапларда күзгә еш ташлана. Уфа галиме И.Галәветдинов 1990 елда бу ядкярнең тәнкыйди текстын оригиналда һәм башкорт графикасында, русчага тәрҗемәдә бастырды. Монографиядә әсәрнең грамматик һәм лексик үзенчәлекләре дә яктыртыла, сүзлеге дә бар[17].

«Тәварихе Болгария» — жанры белән шәҗәрәи, ягъни нәсел-нәсәпне чагылдырган, чагыштырмача кечкенә күләмле ядкяр (Тәнкыйди тексты, искәрмәләре белән бергә, 41 б.). Үзенең эчтәлеге, төзелеше һәм, гомумән, рухы белән ул төрки-татар әдәбиятындагы «Шәҗәрәи төрк», «Дәфтәре Чыңгызнамә», Шәрәфеддин бине Хисамеддин Мөслиминең «Тәварихе Болгария» кебек китапларын да теге яки бу дәрәҗәдә хәтерләтә. Кайбер гарәпчә юлларны һәм тәгъбирләрне исәпкә алмаганда, теле шактый аңлаешлы, үтемле. Тел җәһәтеннән дә ул шул чордагы татар язма истәлекләре белән табигый керешеп китә.

Әсәр төрле чыганакларга, авторның шәхси күзәтүләренә нигезләнеп язылган. Тәүге юлларда китапның язылу вакыты, исеме искәртелә: «...Тарих мең дә ике йөз дә егерменче елда (ягъни 1806 елда), куй елында... ирде. ...Бу рисаләгә «Тәварихе Болгария» аты бирдем» (206 б.). Алга таба файдаланылган чыганаклар

атала. Алар арасында Тәбәри, имам Туси, Чәләби, имам Тәбризи, имам Тәрази, әл-Бохари һәм Шәрыкның башка билгеле затлары бар. Алга таба шәҗәрәи тема яктыртыла башлый.

Автор үз шәҗәрәсенең беренче буыны итеп Адәм галәйһиссәламне күрсәтә. Ул мең ел гомер кичерә. Адәм галәйһиссәлам үлеп бер ел үткәч, «анамыз Хәва» вафат була. Аларның икесен дә Шәйс җирли. Ул үзе 910 ел яши. Алга таба — Әнуш һ.б. Шәҗәрәнең иң ахыргы, ягъни 84 нче буыны итеп автор үзен һәм балаларын күрсәтә.

«Тәварихе Болгария»дә төрле чорларга, диннәргә, чынбарлыкка, мифологиягә мөнәсәбәтле күп санлы исемнәр, этнонимнар, ил, кала, авыллар, географик атамалар телгә алына (Һиндстан, Гыйрак, Исфәһан, Кәюмарс, Сиам, Сократ, Нәүширван, Айдар, Аксак Тимер, Идел һ.б.). Әмма үзәктә — төрки-татар, болгар дөньясы. Автор Кәнҗәне Идел-йорттагы төрки кавемнәрнең атасы дип саный. Аннан, әдип фикеренчә, Татар, Мишәр, Иштәк, Нугай исемле угыллар туа. «Иштәк,— ди ул,— «камил ир», гыйлемлектә нәзыйре (тиңе) юк ирде». Аның бик күп балалары булды. Шуларның берсе Бәкатун «төб йорты» «Гаму-Дәрьяны» калдырып, «Миач (Миас) дәрьясына килде...» (Тәнкыйди текст, 193—194 б.).

Китапта төрле сюжетлар, гыйбрәтле хәлләр, биографик мәгълүматлар да бар. Мәсәлән, автор Болгарның ислам динен кабул итүен Гарәбстаннан өч изге кеше килүе, аларның Айдар хан кызын фалиҗ (паралич) авыруыннан дәвалавы белән бәйләп карый. «Тәварихе Болгария»дә Аксак Тимер һөҗүме, Иске Казан, Бүләргә нигез салынуы хакында да легенда-риваятьләр бар. Таҗеддин Ялчыгол фикеренчә, Болгар ханы Габдулланы Аксак Тимер үтертә. Аның бер углы — Галимбәк Болгар мәмләкәтендәге Кашан (Кышан) каласында «имам вә мөдәррис» була. Аннан Мирхаҗи туа. Ул утыз ел Кашанда яшәгәч, «Зай (Зәй) тамагына» килә. Бараҗ ханда имам булып, шунда ук үлә. Мирхаҗиның углы Колгали Харәземгә китеп, анда 45 ел мөдәррис була. Бераздан «атасы йорты Зай тамагына» кайта. 110 яшендә Аксак Тимер һөҗүме вакытында вафат була... (Тәнкыйди текст, 174—176 б.).

«Тәварихе Болгария» галимнәр һәм укучылар тарафыннан төрлечә бәяләнә. Берәүләр аны чыганак, әдәби ядкяр буларак уңай яктан телгә алалар, дәлил рәвешендә китерәләр. Икенчеләре бу китапның хыялый, уйдырма характерда булуын искәртәләр.

Чыннан да, Таҗеддин Ялчыгол китабында бүгенге күзлектән, тарих фәне югарылыгыннан караганда очы очка ялганмаган, гайре мантыйкый урыннар шактый күп. Мәсәлән, 1336—1405 елларда яшәгән Аксак Тимер Болгар ханы Габдулланы да, аның оныгы Колгалине дә һәлак итә. Әгәр дә без соңгыларын реаль тарихи затлар дип исәпләсәк, хронологик яктан шактый төгәлсезлек җибәрербез. Таҗеддин Ялчыгол Искәндәр Руминың (Александр Македонскийның) Сократ хәким белән Болгарга килүе, аннан, «абехәят» (тереклек суы) эзләп, Төньякка походка китүе турында яза. Шушы юнанлылар Болгар шәһәренә нигез салалар. Сократ хәким «Болгардагы бер кыз»га өйләнә. Гофтар исемле углы туа. Һәм ул Болгарда «шаһ була...» Бу,— әлбәттә, риваять. Әмма автор ул легенданы үзе уйлап чыгармаган. Искәндәрнең Болгарга походы, биредәге мажаралары Шәрыкның күп кенә язма истәлекләрендә, шул исәптән Низаминың һәм Әхмәдинең мәшһүр «Искәндәрнамә»ләрендә гәүдәләнеш таба. Аерым кешеләрнең нәсел-нәсәбен пәйгамбәрләр, мифологик һәм күренекле тарихи затлар белән бәйләү Урта гасыр Шәрык фольклорында һәм язма әдәбиятында тулып ята. Таҗеддин Ялчыгол да нәкъ шул рухта эш итә. Мифологик һәм тарихи затларның яшәү вакытларынһәм гомер озынлыкларын күрсәтүдә дә автор Урта гасыр поэтикасына, традицияләренә тугрылыклы кала.

«Тәварихе Болгария»,— гәрчә ул тарих сүзе белән башланса да, саф тарихи әсәр түгел. Ул — мифологик, әкияти, тарихи, фәлсәфи һәм эстетик башлангычларның бер җыелмасы, үзенә күрә бер синтезы. Шуңа күрә аңа саф тарих фәне үлчәмнәре белән якын килү дөрес булмас. Әдәби әсәрләрдә, дастан-риваятьләрдә чынбарлык, тарих шактый үзенчәлекле гәүдәләнгән кебек, «Тәварихе Болгария» ядкярендә дә тарихи вакыйгалар, фактлар теге яки бу дәрәҗәдә үзгәртелеп, үзгә бер системада бирелгән. Шушы хосусиятне күздә тотып, тәнкыйди эш иткәндә, бу әсәрдән мөһим мәгълүматлар алырга мөмкин. Мәсәлән, андагы аерым вакыйга-хәлләр, күп кенә тарихи затларның исемнәре, эш-гамәлләре башка чыганаклар белән дә раслана. Әсәрдән төрки кавемнәрнең якынлыгы, тарихи яшәешләренең үзара керешеп баруы, дини ышанулары, төрле күчешләре шактый ачык күренә. Шунысын да хәтердә тотыйк: безнең элеккеге чорларга мөнәсәбәтле язма истәлекләребез болай да күп түгел. Әгәр дә без, бар булганнарын да тиешенчә файдаланмыйча, аңлатмыйча, тәнкыйтьләү, кире кагу юлына гына бассак, нәтиҗәсе аянычлы булыр[18]. «Тәварихе Болгария»не безнең әдәбият фәнендә кабул ителгән әдәби-тарихи жанр истәлеге рәвешендә карау отышлы. Мондый ысул андагы һәм реаль, һәм хыялый урыннарны үзара тыгыз бәйләнештә тикшерү мөмкинлеге бирә.

«Тәварихе Болгария»не тикшергәндә, бәяләгәндә, аның туу шартларын, нинди ихтыяҗларга җавап рәвешендә язылуын да истә тоту зарур. Хокуксызлык, милли һәм дини яктан кысу, эзәрлекләү... Халыкның күңелендә борчылу, шом. Үзе дә шушындый вазгыятьтә яшәгән Таҗеддин Ялчыгол үз нәсел-нәсәбенең,

халкының җир йөзендә озын-озак гомер кичерүен, дәрәҗәле, шанлы тарихы булуын, шәҗәрәсенең дөньядагы бөек затлар, төрле илләр, кавемнәр белән бәйләнешле икәнлеген расларга омтыла. Тормыш юлы бәхет-шатлыклардан гына түгел, фаҗига-кайгылардан да гыйбарәт. Ничек кенә булса да, күңелне төшерергә ярамый, яшәеш дәвам итә. Авторга хронологик эзлеклелектән, тарихи төгәллектән бигрәк, үзенең, халкының, диненең барлыгын, кыйммәтен, якты дөньяда яшәргә хаклы булуын раслау кирәк. Моңа ирешүдә әдип һәм тарихи, һәм әкияти-мифологик материаллардан иркен файдалана, теләк-омтылышларын гәүдәләндерерлек шәкелләр, алымнар куллана.

* * *

«Тәварихе Болгария» ядкяре аша без авторның тормышы, үзенә кадәрге нәсел-нәсәбе белән билгеле бер дәрәҗәдә таныштык. Ә соң аның үз гаиләсе ничек булган? Әдипнең кайчан, кемгә өйләнүе бик мәгълүм түгел. Бу хакта язма чыганакларда да материаллар очрамады. Безгә бу турыда Таҗеддин Ялчыгол оныкларыннан Мәлемдә яшәүче Фәүзия апа Таҗетдинова (ул 1921 елгы) һәм Гамир Госман углы Таҗетдинов (1941 елгы) белән кат-кат сөйләшергә туры килде. Алар фикеренчә, Таҗеддин Ялчыгол Җирекле кызына өйләнгән булса кирәк. Башка өйләнгәнме-юкмы,— анысын әйтә алмадылар[19].

«Тәварихе Болгария»дәге мәгълүматка караганда, Таҗеддин Ялчыголның «дүрт углы», «өч кызы» була. «Ахырындагы гомерендә,— диелә бу китапта,— Ирнә суы буенда Мәлем дидеке карьядә тереклек әйламеш... Олуг углым Бәһаведдин Күперле карьясендә (бу авыл Чаллы белән Сарман арасында) мәншүр илә (указлы) имам улыб, анда тереклек әйладе. Андан кечесе — Җәлаледдиндер. Мәлем карьясендә атасы хозурында хезмәт идеб һәм мәзкүр (шушы) карьядә мәншүр илә имам улыб тереклек әйламеш. Өченчесе — Шәрәфеддиндер. Ул һәм Мәлем карьясендә тереклек әйламешдер. Дүртенчесе — Госамеддиндер. Ул һәм Мәлем карьясендә тереклек әйламешдер. Олуг кызым — Биби-Нәфисә, андан кечесе — Газизә, андан кечесе — Биби-Җәмиләдер» (Тәнкыйди текст, 165—166 б.)[19а]. Күрәсез: Таҗеддин Ялчыгол — шактый зур гаиләнең башлыгы, 7 баланың атасы. Барысы да диярлек үз тирәсендә гомер сөрә. Әдип балаларына белем, тәрбия биргән, алар турында кайгырткан. Кызы Газизә исемен мәңгеләштереп китап язуы үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Улларына да «әй углым» дип яратып кына дәшә торган була.

Ишле гаиләне карау атадан зур тырышлык, хезмәт таләп итә. Ул, укыту-руханилык, гыйльми-иҗади эшләрдән тыш, иген игә, мал асрый, йорт кирәк-яракларының күбесен үзе ясый. Аның балта остасы булуы да мәгълүм.

Таҗеддин Ялчыгол — эш-хәрәкәт, гамәл кешесе. Чыганакларда аның «җәяү йөрергә яратуы» искәртелә. Әдипне кайберүләр «народник» дип тә йөртәләр. Үлемен дә ул адәм балаларына игелек кылганда каршылый. Бер танышының чакыруы буенча ул, сырхауларны дәвалау өчен, Мәлемнән 50 чакрымнар ераклыктагы «Имәнле карьясе»нә (Имәнлебашка) килә[20]. Шунда кинәт авырып, вафат була[21] (1838 елның 26 июне). Мөгаен, көннең эсселеге аркасында, һәм әдипнең «Кайда үлсәм — шунда җирләгез» васыятенә таянып, әдипне Имәнлебашта күмәргә карар кылалар. Бу мөхтәрәм затны авыл һәм тирә-юнь халкы зурлап җирли. Кабере өстенә язулы таш та куела.

Таҗеддин хәзрәт үзе исән вакытта да, үлгәч тә халык арасында бик абруйлы зат була. Әдипнең кабере изге хисаплана. Аңа төрле төбәк кешеләре зиярәт кылып торалар.

Таҗеддин Ялчыгол, үз гомеренең төп һәм мәгънәле өлешен Зәй буенда, Зәй төбәгендә уздырып, «дарелфәнадан дарелбәкага рихләт кылган» (каберташында шулай язылган. Ягъни «вакытлы йорттан мәңгелек йортка күчеп киткән»). Якташлары Таҗеддин хәзрәтне зур хөрмәт белән күңелләрендә саклый. Зәй шәһәренең Җәмигъ мәчете һәм үзәк урамнарыннан берсе Таҗеддин Ялчыгол исемен йөртә. Район Үзәк китапханәсендә әдипкә багышланган махсус стенд бар. Тууына 230 ел тулу уңае белән каберенә мәһабәт чардуган корылган. Рәссам Рушан Шәмсетдинов, Таҗеддин хәзрәтнең нәсел-нәсәбе, шул исәптән Госман ага Таҗетдинов белән очрашып, әдипнең портретын ясады.

Таҗеддин Ялчыгол тормышы, хатирәсе уңае белән янә бер мәсьәләне ачыклап китү зарур. Ул да булса аның исем-атамасын, тәхәллүсләрен бирүдәге төрлелек. Ш.Мәрҗани «Мелла Таҗеддин бине Ялчыгол әл-Башгорди» рәвешендә яза (Мөстәфадел әхбар...— Казан, 1900.— 250 б.). Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар»ендә «Таҗеддин бине Ялчыгол бине Мәмәткол бине Йантимер бине Җианчура бине Котлуг Булат», «остазы Габденнәсыр бине Торымтай вә гайреләр...» диелгән (VI җөзэ, 1904.— 336 б.). Шушында ук «Асарь» авторы әдипнең бер кульязмасы ахырында «Таҗеддин бине Яхшыколый әл-Болгари әл-Иштәки» дигән исемнәрнең теркәлүен дә искәртә (336 б.). Кабер ташында һәм шәхси мөһерендә язучының исеме «Таҗеддин Ялчыкол углы» рәвешендә бирелгән...

Бу атамаларның күпчелеге авторның «Тәварихе Болгария» китабында да бар: Котлуг Булат, Җианчура, Йантимер, Мәмәткол — әдипнең бабалары. Шушында ук Таҗеддин: «Мәмәтколдин мулла Йалчыгол тугмышдыр»,— ди. Бераздан «атам мулла Йалчыгол» дип тә өсти. «Рисаләи Газизә»нең кулъязма һәм басма нөсхәләрендә дә, автор, нигездә, «Таҗеддин Ялчыгол» рәвешендә күрсәтелә. Ә инде «Ялчыгол» һәм «Яхшыкол» атамалары, мөгаен, бер үк «Ялчыгол» исеменең төрлечә әйтелеш вариантлары гынадыр.

«Иштәки» исә этнонимга бәйләнешле тәхәллүс. Әйткәнебезчә, ул — татар һәм башкорт кавемнәре составына кергән кабилә исеме. Автор үзен шул төркем белән бәйли.

Болгари кушаматын исә Урта гасыр һәм XIX йөзнең күп кенә татар зыялылары үзләренең тәхәллүсе итә. Таҗеддин Ялчыголның «Тәварихе Болгария» исемле китап язуы да юкка гына түгел. Ул анда үзен Болгарның бер вәкиле дип саный. «Рисаләи Газизә» китабында да күпчелек очракта татар урынына болгар атамасын куллана («Безнең болгар теле»; «Безнең болгар йортында», «Болгарның нәһре Сөн буенда» һ.б.).

Таҗеддин Ялчыгол үзе Башкорди тәхәллүсен кулланмаган булса кирәк. Күрәсең, аңа бу кушамат «Тәварихе Болгария»дәге мәгълүматларга нигезләнеп бирелә. Шуңадыр ул сирәк очрый. Башкорт атамасының төрле мәгънәләрдә кулланылуын да онытырга ярамый. Тарихтан күп кенә татарларның, матди һәм сәяси якны күздә тотып, үзләрен башкорт дип яздырулары мәгълүм. Яшәгән төбәккә, административ бүленешкә мөнәсәбәттә дә бу атама еш кына этник мәгънә белән туры килми. Мәсәлән, Башкортстаннан чыккан яисә килгән кешеләрнең башкортын да, татарын да кайвакыт башкорт дип атау — гадәти күренеш.

Без, әлбәттә, «Тәварихе Болгария» авторының этник яктан башкорт кавеме белән бәйләнешле булу мөмкинлеген дә инкарь итмибез. Чөнки бу ике тугандаш халык элек-электән үзара аралашып, керешеп яшәгән. Татарлар составына башкорт кавемнәренең дә теге яки бу дәрәҗәдә катнашуы тарихтан билгеле.

Таҗеддин Ялчыгол, этник чыгышы белән башкорт булган очракта да, бала вакытыннан ук туган төбәгеннән аерылган, гомеренең төп һәм мәгънәви өлешен татарлар арасында яшәп, аларча сөйләшеп, аларга хезмәт итеп уздырган[22]. Аның балалары һәм оныклары да шушы традицияне дәвам итә[23]. Этник яктан татар белән бәйләнешле Державинны яисә Купринны, Татарстанда туган Педер Хузангайны татар әдибе дип атап булмаган кебек, Таҗеддин Ялчыголны да «башкорт галиме һәм язучысы» дип йөртү урынлы булмастыр[24].

«Рисаләи Газизә» авторын Г.Чокрый «мәүлана мелла Таҗеддин әл-Болгари Оруви» дип атый (Татар әдәбияты тарихы.— II том.— 1985.— 430 б.). Бу тәхәллүс, мөгаен, Көньяк Урал төбәкләренә (Ор, Орск...) мөнәсәбәттә бирелгәндер.

## II

«Рисаләи Газизә» — Таҗеддин Ялчыгол иҗатында гына түгел, ә гомумән Тукайгача чор татар әдәбияты тарихында мөһим ядкяр. Шактый күләмле бу китап кулъязмаларда, ә XIX гасыр урталарыннан басма рәвештә гаять киң тарала. Казан университеты Фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә генә дә аның 40 тан артык тулы һәм өлешчә нөсхәләре бар [173 Т. (№ 2127), № 138 Т., № 64 Т. һ.б.]. Тәүге мәртәбә бу әсәр 1847 елда Санкт-Петербургта дөнья күрә («Китабе Рисаләи Газизә»). Ул «Нижний губернасының Сергач өязенең Яндивишә волостеның Яңапар авылының[25] Ризван Маллай (?) углының хөраҗате (чыгымы) илән» нәшер ителә. Казанда «Рисаләи Газизә» беренче тапкыр 1850 елда басылып чыга (440 б.)[26]. Аннан соң бу китап Казанда күп мәртәбәләр (аерым елларда хәтта икешәр тапкыр) нәшер ителә (1857, 1863, ... , 1874, ... , 1900, ... , 1908, ...). Октябрь инкыйлабына кадәрге соңгы басмасы («Рисаләи Газизә: Шәрхе «Сөбател-гаҗизин») 1916 елга карый (252 б.). Бу әсәрне басып тарату белән, нигездә, Хөсәеновлар, Кәримовлар кебек күренекле матбагачылар шөгыльләнә.

«Рисаләи Газизә» халыкның төрле катлаулары тарафыннан яратып укыла. Бу хакта Г.Рәхим һәм Г.Газиз үзләренең 1923—1925 елларда дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы» китапларында искәртәләр. «Рисаләи Газизә»,— дип яза авторлар,— безнең татарның бик яратыб укый торган китабларыннан берсе; ысулы кадим мәктәпләрендә дәреслек итеб тә кулланылган» (1925 елгы басма, 156 б.). Г.Тукай да «Исемдә калганнар» әсәрендә Кырлайда яшәгән вакытта ук үзлегеннән «Рисаләи Газизә»не укуын телгә ала.

Таҗеддин Ялчыголның бу китабы хакында Ризаэддин Фәхреддин, М.Гайнетдинов, М.Әхмәтҗанов һәм кайбер башка авторларның да төрле характердагы фикер-күзәтүләре бар. Алты томлык «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томында Таҗеддин Ялчыгол турында махсус бүлек бирелгән (Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.— 443—452 б.). М.Гайнетдинов тарафыннан язылган бу мәкаләнең төп өлешен «Рисаләи Газизә»не тикшерү алып тора. Соңгы вакытта бу әсәр хакында без фәкыйрегезнең дә берничә язмасы укучыларга иреште[27]. Шулай ук «Рисаләи Газизә»нең шактый өлеше, безнең тарафтан әзерләнеп, тиешле шәрех-аңлатмалар белән «Мирас» журналында нәшер ителде (1998.— 10—12 саннар; 1999.— 1—9, 11 саннар). Аның тулы басмасы 2001 елда «Иман» нәшриятында дөнья күрде[27a]. Таҗеддин Ялчыгол әсәренең

аерым өлешләре, хикәятләре 1998 елда бер китапчык рәвешендә дә нәшер ителде (Казан: «Иман» нәшр.— 60 б.). Анда текстны басмага әзерләүче М.Гайнетдиновның әсәр турында кереш мәкаләсе дә бар (3—6 б.).

«Рисаләи Газизә» кайчан язылган соң? Г.Рәхим һәм Г.Газиз әсәрнең тәмамлану вакытын 1807 елга нисбәт итәләр (1925.—156 б.). М.Гайнетдинов һәм кайбер башка авторлар 1796 елны күрсәтәләр. «Рисаләи Газизә»нең 1850 елгы Казан басмасында бу әсәрнең «тарихе һиҗрәтнең 1211 елында елкы елында тәмам» булуы искәртелә (4 б.). Бу дата милади белән 1797 елның беренче айларына туры килә. Ә инде «Рисаләи Газизә»нең тәүге, ягъни 1847 елгы С.-Петербург һәм кайбер башка, шул исәптән 1912/1916 елгы Казан басмаларында нәкъ китапның керешендә, хәтта кайберләренең тышлыгында ук әсәрнең тәмамлану вакыты итеп 1221 ел күрсәтелә. Бу исә якынча 1806 елның декабрь аена туры килә.

Әсәрнең язылу вакытын билгеләүдәге мондый төрлелек нәрсә белән аңлатыладыр — хәзергә әйтүе кыен. Бәлкем, даталарның берсе (аеруча 1211 ел) хатадыр. Бәлкем, автор 1796 елда үз китабының беренче вариантын төгәлләгәндер. Бәлкем, «Рисаләи Газизә» 1796—1806 еллар аралыгында иҗат ителгәндер. Хәзергә без 1806 елга өстенлек бирәбез. Ни өчен?

«Тәварихе Болгария»нең С.-Петербургтагы Шәрыкшенаслык институтында саклanuчы кульязмасында (В. 2673) «Рисаләи Газизә»нең «Кызыл Чапчак карьясендә» язылуы искәртелә. Бу авылда исә автор 1799—1824 елларда гомер кичерә.

Таҗеддин Ялчыгол XVIII гасырның 90 нчы елларында гаилә кора. Газизә — аның уртанчы кызы. Әгәр дә без әсәрнең язылу вакыты дип 1796 елны кабул итсәк, табигый мантыйкны бозарбыз. Бу вакытта әле Газизә я тумаган, туса да — сабый яшендә генә. Китап исә аның үтенече («илтимасы») белән дә языла. Әсәрдән инде бу вакытта кызда «Сөбател-гаҗизин» хакында билгеле бер күзаллау булуы аңлашыла. Тагын шунысы да бар: «Рисаләи Газизә» — зур күләмле, катлаулы әсәр. Аны язу автордан бай тәҗрибә, ныклы хәзерлек һәм күп вакыт таләп итә. Болар бар да бу ядкярнең

1211/1797 елда түгел, ә соңрак, ягъни 1221/1806 елда төгәлләнүенә дәлил булып торалар.

* * *

Таҗеддин Ялчыгол әсәренең тулы исеме — «Рисаләи Газизә: Шәрхе «Сөбател-гаҗизин». Теге яки бу әсәргә шәрех (комментарий) язу — Урта гасыр Шәрык, шул исәптән татар дөньясында гаять киң таралган күренеш. Таҗеддин Ялчыгол да шушы традицияләр кысасында һәм рухында эш итә.

Шәрех ысулы белән тудырылган ядкярләр хакында фикер йөрткәндә, иң әүвәл, нигез итеп алынган, автор мөрәҗәгать иткән әсәрләр турында аерым белешмәләр бирү зарури.

«Сөбател-гаҗизин»[28] («Көчсезләрнең ныклыгы», «Гаҗизләргә терәк»...) — Урта Азиянең күренекле шагыйре Суфый Аллаяр (Аллаһыяр. 1616—1713 яисә 1707)[29] әсәре. Аның хакында Г.Газиз һәм Г.Рәхимнең «Татар әдәбияты тарихы» китапларында, Ф.Яхин хезмәтләрендә[30], М.Гайнетдинов мәкаләләрендә шактый гына мәгълүматлар, фикер-күзәтүләр бар. Шагыйрьнең тормышы, иҗат мирасы хакында фикер йөрткәндә, алар, нигездә, «Рисаләи Газизә»дә Таҗеддин Ялчыгол биргән мәгълүматлардан файдаланалар.

Суфый Аллаяр — этник чыгышы белән нугай татары. Кайбер чыганакларда аның нәсел-нәсәбенең Әстерхан төбәгеннән булуы да искәртелә. Мөгаен, шагыйрьнең әби-бабалары, күп кенә татарлар кебек, Казан, Әстерхан ханлыклары бетерелгәч,Урта Азиягә күчеп яисә эзәрлекләүләрдән качып киткәннәрдер.

Таҗеддин Ялчыгол язуынча, Аллаяр Сәмәркand шәһәре тирәсендәге «Миңлан атлигъ» бер авылда «нәселе нугай» булган Тимерйар исемле «гаять изге тәкъва» гаиләсендә туа. Унике яшендә Бохара мәдрәсәсендә укый башлый («Гыйлемлек үгрәнде, күп фәннәр хасыйл әйладе»). 25 яшендә Бохара шаһы аны салым җыю оешмасына түрә кыла. Ул анда катылыгы белән таныла. Әмма бераздан тәүбә кыла, Хәбибулла шәехне остазы итә. Үзе мәшһүр суфый буларак таныла. Суфый Аллаяр үз кавеменең асыл Ватаны — Идел-йорт, бабаларының туфрагы белән дә бәйләнешен өзми. «Рисаләи Газизә» авторы аның Казан каласына килүе, «Болгарның» Идрис Хафиз исемле «бер камил суфые» белән очрашуы, бирдән хаҗга юнәлүе хакында яза. «Әүвәл,— ди ул,— әрзе Румга (Кече Азиягә) бармыш... Андан Искәндәрия шәһәренә килә; андан дарелфәнадин дарелбәкайә (вакытлы йорттан мәңгелек йортка) рихләт әйладе (күчеп китте, вафат булды)... Аллаярның ул заманда яше туксан ел ирде» (356—357 б.).

Кайберәүләр шагыйрьнең үлгән җирен Бохарага нисбәт итәләр. Фарсы һәм төрки телләрендә иҗат бу могтәбәр зат үзенең фәлсәфи-суфыйчыл, инсани-әхлакый карашларын, кеше, яшәеш турындагы уйлануларын әдәби юлларында теркәп калдырган.

«Рисаләи Газизә» авторы Суфый Аллаярның дүрт китабын телгә ала: «Мәсләкел-мөттәкыйн» («Тәкъвалар мәсләге», «Бәхәссез караш»), «Морадел-гарифин» («Акыл ияләренең морады»), «Михрабел-мотыйгыйн» («Күндәмнәрнең михрабы»), «Сөбател-гаҗизин». Соңгысы,— ди ул,— «бу дүрт китабның

арасында гүзәлрәге вә мөшкелрәгедер. Зирә ки (чөнки) әнваг лөгать (чуар тел) илә мөдәүвәндер (төзелгәндер)».

«Сөбател-гаҗизин» әсәрен Суфый Аллаяр әүвәл фарсыча иҗат итә (12 мең бәеттән артык). Аннан «яраннарының» үтенече белән, кыскартып, төркичә яза[31]. Бу поэма татар дөньясында гаять киң тарала. Аның шәрехләре (Утыз Имәни...)[32], күп санлы кульъязмалары, Казанда нәшер ителгән басма нөсхәләре бар (1802 елдан башлап). Шунысы мөһим: ул — Казанда дөнья күргән тәүге әдәби китапларның берсе.

Безнең кулыбызда «Сөбател-гаҗизин»нең 1841 елгы басмасы[33]. Ул мәшһүр Рәхмәтулла Әмирхан углы хисабына чыгарылган. Күләме — 1712 бәет. Әсәр, нигездә, 3 буынлы һәзәҗ үлчәме белән язылган.

Тулысы белән Коръән рухы белән сугарылган «Сөбател-гаҗизин» — лиро-эпик характердагы әсәр. Анда авторның уй-кичерешләре төрле хикәятләр («Хикәяте Рабига», «...Хәҗҗаҗ», «...Сәүбән», «...Әхмәд бине Хәнбал», «...Локман», «...Шәйх Басрый», «...Хәлил углы Исмәгыйль», «...Габдулла Әнсари» һ.б.) белән үрелеп бара. Күпчелек хикәятләрнең сюжетлары һәм образлары Шәрык дөньясы өчен традицион характерда. Алар төрле чыганакларда, төрле авторларда очрый. Мәсәлән, бер хикәяттә ике дусның суга бата башлавы тасвирлана. Берәү аларны коткарырга тели. Әмма һәлакәткә очраучылар әүвәл үзен түгел, дустын коткаруны сорап, бәхәскә керәләр.

Диде: «Куйгыл мәне, ярым кулын ал.
Моны куйды, аны чөн тотты мазбут (нык)»,
Бу һәм әйде: «Мине куйгыл, аны тот» (87 б.).

Чын дуслык идеясен гәүдәләндерүгә иллюстрация рәвешендә китерелгән бу төр сюжет Сәгъди һәм Сараи әсәрләрендә дә бар.

...Ул әйтте: «И каләме (сүзе) җанына кот (бәхет),
Мәне куй, барыб ул йарым илен тот...»
(*«Гөлестан бит-төрки». V баб*)

«Сөбател-гаҗизин»дә Газали, Гаттар, Руми, Ясәви, Нәкышбәнди, Өмми Кәмал һәм башка әдипләрнең әсәрләре белән охшаш, уртак яклар шактый. Мөхәммәдьяр кебек, Суфый Аллаяр да үз укучысын «мөлаем сүзле», «сөчүк телле» булырга, яманнардан ерак йөрергә («Ямандин кач, ямандин кач, ямандин»), яманлыкка яхшылык кылырга... («яманлык әйлагәнгә яхшылык кыл»), нәфескә бирелмәскә чакыра. Хисам Кятиб, Өмми Кәмал шикелле, ул да гомернең фанилыгын, үлемнең котылгысызлыгын («үлемне даимән яныңда белгел») раслый. Йөзеңне ак, күңелеңне пакь тоту («Әүвәл мәртәбә холкыңны кыл пакь») — аның өчен иң мөһиме.

Дини-әхлакый рухтагы «Сөбател-гаҗизин»дә Алланың бөеклегенә дан җырлана, диндар табигатьле зат идеал итеп куела, кеше холкындагы, эш-гамәлендәге тискәре күренешләр (ваемсызлык, тәкәбберлек, икейөзлелек, комсызлык һ. б.) кискен тәнкыйтьләнә. Күп кенә суфый шагыйрьләр кебек, Аллаяр да иляһи мәхәббәтне зурлый:

Кил, әй талиб, күзең гыйбрәт белән ач,
Мәхәббәтсез кешедин кош булыб кач (48 б.).

Әгәр фәгъфуре Чиндыр, кайсаре Рум,
Мәхәббәт әһленең алдында мәгъдум (38 б.).
(Кытай патшасы, Византия императоры булсаң да,
Мәхәббәт алдында син кочсез.)

Шунысы мөһим: шагыйрьнең Аллага мәхәббәтен, иляһи гыйшыкны гәүдәләндергән юлларын еш кына инсаннарга мөнәсәбәттә дә кабул итәргә мөмкин.

«Сөбател-гаҗизин» мөселманнар өчен үз һәм якын булган дини-суфыйчыл карашларга, әхлакый һәм эстетик тәҗрибәгә, күнегелгән зәвык-ихтыяҗларга нигезләнеп туган. Аның популярлык сәбәпләренең берсе шул. Икенчедән, Суфый Аллаяр поэмасы әдәби яктан да шактый камил һәм үтемле. Автор төрле шигъри чараларны (эндәш, мөрәҗәгать, риторик сорау, кабатлау, аллитерация, чагыштыру һ.б.) уңышлы гына куллана:

Ятырсың яңа өйләнгән егетдик (21 б.).

Аның дик һадига (пиргә; юлбашчыга) кылсаң тагать,
Сәгадәтдер, сәгадәтдер, сәгадәт (37 б.).

Теләсә бүркене, бирмәк кирәк баш,
Әгәр җан эстәсә, кайтармагыл каш (49 б.).

Тот ул дустыңны сөт өстендә каймак (71 б.)...

Шагыйрьнең күп кенә юллары хикмәтле сүз, афористик гыйбарә кебек яңгырый: «Яман хатын — шайтан камчысыдыр» (54 б.); «Еланның ташыдыр (тышы) — йомшак, эче —зәһәр» (60 б.) һ.б.

«Сөбател-гаҗизин» турыдан-туры да, «Рисаләи Газизә» аша да халыкка, әдәбиятка нык тәэсир итә. Аның бер хикәятендә мондый бәет бар:

Бала диб салмагыл җаның бәлагә,
Бала берлә булырсың мөбтәлягә (авыр хәлдә) (53 б.).

Бу юллар миңа кечкенә вакыттан ук таныш. Әнкәй ягыннан әби — 13 бала анасы — ул бәетне «Бала дип башың салма бәлагә, ... калырсың мөбтәлягә» рәвешендә еш кабатлый иде. Суфый Аллаяр әсәрендәге аерым юллар, гыйбарәләр, деталь-сурәтләр Утыз Имәни, Ш.Зәки, Кандалый, Акмулла, Гафури һәм башка авторларның әсәрләрендә күзгә ташлана. Мәсәлән, Утыз Имәнинең «Горбәтнамә» поэмасы Суфый Аллаяр әсәрендәге бәетләр белән башланып китә. «Сөбател-гаҗизин»дәге «Әгәр солтан үзе кылса яманлыг, Кайчан булгай рәгыятьдә әманлыг» юллары (76 б.), өлешчә генә үзгәреш алып, билгесез авторның «Мәкәрҗә бәете»ндә кабатлана[34].

«Сөбател-гаҗизин» — дини-суфыйчыл карашларның, әхлакый кагыйдәләрнең үзенә күрә бер шигъри белешмәсе, энциклопедиясе кебек. Шуңа да ул игътибар үзәгендә тора. Әмма аны уку, төшенү шактый хәзерлек сорый. Бу исә китапка төрле шәрех-аңлатмалар язуны таләп итә. Шундыйларның берсен, мәсәлән, Утыз Имәни төзи. Таҗеддин Ялчыгол әсәре дә — нәкъ әнә шул әдәби-педагогик ихтыяҗлар юнәлешендә туган күренеш. Авторның үзе искәртүенчә, ул «Сөбател-гаҗизин»нең берничә нөсхәсе белән эш итә.

* * *

«Рисаләи Газизә» традицион кереш белән башланып китә. Әүвәл Аллага, аннан пәйгамбәргә мактау-сәналәр бирелә. Алга таба китапның язылу сәбәбе[35] аңлатыла. Биредә әдип бу әсәрне үзгәләрнең, иң беренче чиратта, кызы Газизәнең үтенече белән язуын искәртә. Шунысы мөһим: бу юлларда авторның үз кызына хөрмәт һәм ярату хисләре бөркелеп тора («үземнең күзем нуры, бәгърем парәсе... кыз балам»). Әсәрнең «Рисаләи Газизә» дип аталуы да күп нәрсә хакында сөйли. Китап ахырындагы шигъри юлларда да атаның кызына җылы мөнәсәбәте сизелеп тора: «Кил, әй бадәи саба (таң җиле) — сахибе фәзаил (затлы хуҗа); Сәламем әйлә Газизәмә васыйл» (Газизәмә сәламемне ирештер).

«Рисаләи Газизә» чәчмә һәм тезмә юллар берлегеннән гыйбарәт. Анда Суфый Аллаяр әсәре гәүдәләнеш тапкан. Кайбер бәетләр Таҗеддин Ялчыголның үзе тарафыннан иҗат ителгән. Алар, нигездә, әсәрнең кереш һәм бетем өлешләрендә; эчтәлеге белән автобиографик характерда. Оригиналь тезмәләрнең шигъри ягы уртача.

«Рисаләи Газизә»нең традицион багышлау һәм хатимә (бетем) өлешләре, китапның язылу сәбәбен аңлаткан бүлекчә «Сөбател гаҗизин»нән шактый аерым тора. Әсәрнең төп өлеше исә, нигездә, оригинал эзлеклелегендә бара.

Таҗеддин Ялчыгол Шәрык, шул исәптән татар рухи тормышында тупланган шәрехләү традицияләре кысаларында эш итә. Ул әүвәл оригиналның бер яисә аерым очракларда берничә бәетен китерә, алга таба аларның эчтәлеген ачыклый, мәгънәсен аңлата, аерым сүзләрнең, детальләрнең лексик, шигъри төшенчәләрен яктырта. Кайвакыт вәзен, кафия үзенчәлекләрен дә ачыклый. Бу төр аңлатма-шәрехләр берничә юлдан алып, кайвакыт тулы-тулы битләргә сузыла. Әгәр «Сөбател-гаҗизин»нән китерелгән бәет болай да аңлашылып тора икән, андый юллар (әмма алар бик аз) шәрехләнмичә генә тәкъдим ителә. Бик сирәк очракларны исәпкә алмаганда, гарәпчә, фарсыча юллар татарчага тәрҗемә ителеп бара.

Оригинал байлыгын укучыларга мөмкин кадәр тулырак һәм үтемлерәк җиткерү өчен, Таҗеддин Ялчыгол өстәмә чыганакларга һәм материалларга мөрәҗәгать итә. Болар арасында гарәп, фарсы, төрки телләрдәге китаплар да, турыдан-туры тормыштан алынган факт-мәгълүматлар да бар. Автор аеруча «Кыйссасел-әнбия», «Мөхәммәдия», «Гаҗаибел-мәхлукат», «Җәмигы-мишкат» кебек ядкярләрне, Руми, Җами («Йосыф-Зөләйха»), Ясәви, Нәкышбәнди әсәрләрен алдын күрә. Арага «Сөбател гаҗизин»дә күзгә ташланмаган аятьләр, хәдисләр, гыйбрәтле сюжетлар кертеп җибәрә. Татарча текстта Суфый Аллаяр әсәренең Казан басмаларында булмаган хикәятләре дә очрый.

«Сөбател-гаҗизин» белән «Рисаләи Газизә» арасындагы мөнәсәбәтләрне шәрехләү өчен, төп өлештәге гадәти бер хикәяткә мөрәҗәгать итик. Ул — «Локман хикәяте». Суфый Аллаяр әсәренең 1841 елгы Казан басмасында бу сюжет болай бирелгән:

Нәсыйхәт кыйлды фәрзәндигә (углына) Локман[36]:

Сәңа жаһил (надан) кеше бәхәс итсә, әй жан;
Җаваб әйгел аңа ширин (татлы) вә йомшак,
Мәгәр булгай җәһаләт (томаналык, наданлык) хәмерендин
(исереклегеннән) саг (сау).
Әгәр нәфгъ (файда) итмәсә, кылма агадә (кабат),
Булыр әйган сари җәһали зийадә (наданлыгы артыр).
Аңа сәүд (суд-файда) итмәсә, әймаг савабы,
Сөкүт итмәкдер (эндәшмәүдер) андыйн соң җавабы (70—71 б.).

Инде хәзер «Локман хикәяте»нең «Рисаләи Газизә»дәге бирелешенә игътибар итик.

«Нәсыйхәт кыйлды фәрзәндигә Локман,
Сәңа жаһил кеше бәхәс итсә, әй жан.

Ягъни Локман хәзрәтләре углы Кайдарга нәсыйхәт әйладе бөйлә дию (болай дип): «Әй жан, күзем нуры, углым, һәркайчан сәнең берлә бер надан, сүзгә килеб, бәхәс әйләсә, аңа ачыгланыб җаваб бирмәгел»,— диде.

Әймешләр: Локманның хакыйкый (чын) исеме Борһан ирде. Аллаһу Тәгалә дөшендә хәбәр вирде: «Йа Борһан, сәңа пәйгамбәрлек кирәкме яки гыйльме хикмәт кирәкме?» — тиб. Борһан әйде: «Бәңа гыйльме хикмәт (философия) кирәкдер, пәйгамбәрлек эше агырдыр. Ул бәнем халемдән килмәз»,— диде. Бәс (шулай итеп), Борһан гыйльме хикмәтне ихтыяр әйладе, «Локман» аталды. **Локман** мәгънәсе — күб фикерләүче димәк булыр. Углының исеме Кайдар ирде. Гаять салих (изге) кемсәнә ирде.

Әймешләр: Локман мең ел яшәде. Углы ике йөз егерме ел яшәде. Фәләстыйн (Палестина) йирендә дәфен әйладеләр (күмделәр).

Әймешләр: Локман Сәрәндибдән (Цейлоннан) чыкты. Әймешләр: Остаздан сабак алмады. Аллаһу Тәгалә аңа укымаен (укымыйча) гыйлемлек бирде. Әймешләр: Локманның буе егерме аршын ирде. Кара чырайлыг, арык тәнлек (тәнле) ирде. Әймешләр ки, Локманның хатыны ике ирде: берсенең бер азакы (аягы) юк ирде вә берсенең бер күзе сукыр ирде. Әйделәр: «Йа хәзрәт, нә өчен бончалаен (болай) кәм (ким) әгъзалы хатынларны алдың?» — диделәр. Җаваб әйде ки: «Хатынлар ирәнләрдән (ир-атлардан) һәрнәрсәдә ким булсын: яшьдә һәм җәмалда (матурлыкта) вә малда,— диде.— Әгәр бу ике хатынымның әгъзасы ким улмаса ирде, мине сүмәзләр ирде»,— диде. Локман Хәкимнең гаҗаиб (искитмәле) ләтыйфәләре (гыйбрәтле сүзләре; мәгънәле хикәятләре, мәзәкләре) күбдер. Барыны язмак илә китаб озын булыр.

Җаваб әйгел аңа ширин (татлы) вә йомшак,
Мәгәр булгай җәһаләт хәмерендин саг.

Ягъни Локман Хәким әйде: «Әй углым, анчалаен надан кемсәнә сүзгә килеб бәхәс әйласә, җавабыны сөчүк вә йомшак тел илә биргел; шайәд ки, ул надан кемсәнә наданлык хәмерендин сәламәт улыр, «зирә ки (чөнки) надан ахмакга катигъ сүз берлә җавап бирсәң, үбкәсе кабарыр, хакыйкать сүзне фәһемләмәеб (төшенмичә) калыр». Нәта ки боерды:

Әгәр нәфгъ (файда) итмәсә, кылма агадә (кабат),
Булыр әйгән сари җәһали зийадә.

Ягъни ул надан ахмакга сөчүк (татлы, йомшак) теллек илә җаваб бирдеке (биргән) сүзең файда кылмаса, сүзеңне әйламә, зирә ки сән тәкрар кылган саен, ул наданның үпкәсе кабарыб, наданлыкы артыр, тиде.

Аңа сәүдә (файда) итмәсә әймаг савабы,
Сөкүт итмәкдер андин соң җавабы.

Ягъни ул надан кемсәнәгә синең тугры әйтмәкең файда бирмәсә, бәлки үпкәсе кабарыр булса, ул наданга җаваб бирмәен (бирмичә) тик тормак (сөкүт итмәк) — җавабдыр, диде. Хасыйле кәлам (кыскасы; сүзнең асылы): наданның сордыкы сүзенә — йомшак җавабдыр, ул йомшак сүз илә аңламаса — тик тормакдыр, диде» (1847 елгы басма, 255—266 б.).

Ике текстны чагыштыру шуны күрсәтә: оригинал әсәр дүрт бәеттән тора, ә шәрех күләм ягыннан берничә мәртәбәгә артык. «Сөбател-гаҗизин»дәге юллар тулысы белән «Рисаләи Газизә»дә бирелгән. Алар бәетләп алына да, җентекле шәрехләнә. Оригиналда Локман Хәкимнең углына биргән җавабы, ягъни бер сюжет кына бар. Шәрехтә исә алар берничә (Локманның хәкимлеккә ничек ирешүе; углы, хатыннары хакында мәгълүматлар...). Таҗеддин Ялчыгол хикәяттәге төп каһарманны тагын да тулырак, күпкырлырак

бирергә тырышкан. Аның асыл текстны аңлатуы һич тә бәхәс тудырмый. Оригинал белән шәрех арасындагы бу һәм башка төр мөнәсәбәтләрне күпләп китерергә мөмкин.

Таҗеддин Ялчыгол еш кына аерым сүзләр, этнографик детальләр ярдәмендә оригиналның артык үзгәртелмәгән эчтәлеген дә үз укучысына якынайта төшә. Мәсәлән, хатын-кыз һәм ир-ат мөнәсәбәтләре хакында сүз барганда, автор болай ди: «...Безнең Болгар йортында бер Сабан туе дидеке бәйрәме вардыр. Анда хатын вә кызларны таган асты дидеке уйный торган урынларына йибәрерләр вә яшь егетләр кызларның вә хатынларның кулындан тотыб уйнарлар, гауга, һай вә һуй илә урамлар тулуг улыр...» (190 б.).

Гомумән, «Рисаләи Газизә»дә халкыбызның тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, яшәгән табигате белән бәйләнешле мәгълүматлар шактый күп. Мәсәлән, суфыйчылыкта зикер әйтүчеләр, экстазга бирелүчеләр, ди автор, Болгарның кайбер урыннарында, җөмләдән «нәһре Сөндә (Сөн елгасы буенда) вә нәһре Керкәледә вардыр, әмма мәшһүр дәгелдер» (183 б.).

«Сөбател-гаҗизин» белән «Рисаләи Газизә»не үзара чагыштыру шуны күрсәтә: Таҗеддин Ялчыгол Суфый Аллаяр әсәренә механик рәвештә якын килмәгән, аны күңел казанында кайнаткан, зиһене аркылы уздырган, оригиналга бәйләп үзенең күп кенә белем-мәгълүматын, фикер-күзәтүләрен, уйлануларын бәян иткән. Шуның нәтиҗәсе буларак, «Рисаләи Газизә»дә алынма һәм авторның үз материаллары, уй-кичерешләре кушылып, табигый бер эчтәлек, идея-эстетик бөтенлек тудырганнар. Шуңа күрә бу әсәрне гадәти шәрхи ядкяр дип кенә карарга ярамый. Ул — татар рухи тормышында, сүз сәнгатендә мөһим бер урынны били торган китап.

Ш.Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар...» хезмәтенең икенче томында (Казан, 1900.— 250—251 б.) Таҗеддин Ялчыгол «Сөбател-гаҗизин»не «бер дә белмәгән, галәт (ялгыш) бәян иткән»,— дип яза. Күрәсез: тәнкыйть бик җитди.

Әйткәнебезчә, Суфый Аллаяр китабы — аңлау һәм аңлату өчен шактый кыен һәм катлаулы әсәр. Шуңа күрә аны шәрехләүдә аерым ялгышларның, төгәлсезлекләрнең китүе, бәхәсле урыннарга юл куелуы һич тә гайре табигый хәл түгел. Китапта, мәсәлән, стиль кытыршылыклары, урынсыз кабатлаулар, хәрфи төгәлсезлекләр күзгә ташлана. Боларның кайберләре, әлбәттә, күчерүчеләрнең, нәшер кылучыларның игътибарсызлыгы аркасында да киткән. Аерым аңлатмалар да бәхәс кузгата. Мәсәлән, «Сөбател-гаҗизин»дәге «лай» сүзен автор «балчык мәгънәсендә; төрекмән илә һинди лөгате» дип кенә аңлата (339 б). Бу исә татар теленә дә хас сүз. Әмма Таҗеддин Ялчыгол «Сөбател-гаҗизин»не «бер дә белмәгән» дию хакыйкатьтән ерак тора. Оригинал һәм шәрехне үзара янәшә кую «Рисаләи Газизә» авторының үз эшенә гаять җаваплы каравын, моңа күп көч түгүен, аның хәзерлекле әдип һәм галим булуын күрсәтеп тора. Шунысын да искә төшерик: Идел-йорттан тыш, Кече Азия, Кавказ якларында да яшәп алган, этисеннән һәм төрле остазлардан гыйлем өйрәнгән Таҗеддин Ялчыгол гарәп, фарсы, төрки телләрен шактый белгән, Шәрыкның күп кенә әдәби һәм гыйльми китапларыннан хәбәрдар булган.

Ш.Мәрҗани — гаять таләпчән, хәзерлекле галим. Ул хәтта Утыз Имәни шәрехләреннән дә хаталар таба. Үз мәсләгенә, рухына туры килмәгән авторларга (болар арасында, мөгаен, Таҗеддин Ялчыгол да булгандыр) аның бәя-хөкемнәре аеруча катгый. Шуңа күрә «Рисаләи Газизә» хакында «Мөстәфадел-әхбар...» хезмәтендә әйтелгән кискен тәнкыйди фикерне без бәхәсле, галимнең шәхси, субъектив карашы дип кенә саныйбыз. Аннан тыш бит әле шунысы да бар: бөтен әдип-галимнәр дә Мәрҗани дәрәҗәсенә күтәрелә алмый, һәм моны без мәҗбүри таләп тә итә алмыйбыз. Тормышның үзе кебек, фән һәм әдәбият та төрлелекне, заманча әйткәндә, плюрализмны ярата. Шәрех жанрының, дөресрәге, ысулының шәхси аңлау, кабул итү белән сыйфатлануын да онытырга ярамый.

Шунысы кызыклы: Ризаэддин Фәхреддин «Рисаләи Газизә» авторының эшчәнлегенә тел-теш тидерми, нindидер чыганактан Ш.Мәрҗанинең Таҗеддин Ялчыголның язучылык хезмәтен хуплаган сүзләрен китерә. Анда «Таҗеддин хәзрәт гаять кятиб (язучы) вә сәйях (сәяхәтче)... бер зат иде... Язуы мәргуб (сыйфатлы; әйбәт) вә камил рәвешендәдер» дигән юллар да бар (Асарь, VI җөзэ, 357 б.).

«Сөбател-гаҗизин»нең идея-эстетик табигате хакында әйтелгән фикерләр «Рисаләи Газизә»гә дә тулаемы белән туры килә. Шуларга өстәп, биредә янә берничә үзенчәлекне искәртеп китәбез.

«Рисаләи Газизә» — Алла һәм пәйгамбәрләр, бу һәм теге дөнья, табигать, инсан, аның холкы һәм эш-гамәле, яшәеш хакында уйлануларның, мәгълүматларның, мифологик күзаллауларның мәҗмугаи, бергә тупланган бер гәүдәләнеше. Анда, кеше белән беррәттән, үрмәкүч, кырмыска, фил, елан һәм башка «мәхлукатлар», ягъни җан ияләре турында әкияти мәгълүматлар бирелү дә — нәкъ әнә шул барын да колачлауга, бөтенлеккә омтылышның бер галәмәте. Китаптан хәтта елан һәм ул чakkаннан дәвалау ысуллары, «чынаяк ясамак», «алмас тимере», «чык суы кебек» темалар да читтә калмый.

Китапның эпик, лиро-эпик характерындагы сәхифәләрендә, хикәятләрендә, пәйгамбәрләрдән тыш, Хәсән Басрый, Вәйсел-Карани, Рабига, Сәүбан, Ясәви, Хуҗа Бәһаэддин Нәкышбәнди, Габдулла Әнсари,

Шәйх Хәбибулла, Суфый Аллаяр һәм башка мәгълүм затлар, аларның могҗизаи эш-гамәлләре турында сөйләнелә. Төрки һәм гомумән ислам дөньясының мәшһүр акыл иясе, шагыйре Әхмәд Ясәви — (1166 елда вафат була), автор фикеренчә, «шәригатьнең көнәше» (кояш), «камиле мөкәммәл», «котбе галим» (ягъни галимнәрнең юлбашчысы, остазы) (187—188 б.). Һәм, гомумән, Таҗеддин Ялчыгол, Шәрык әдәбиятындагы дини-суфыйчылык традицияләренә тугрылыклы калып, үз каһарманнарын еш кына гайре табигый планда күрсәтергә, кәрамәт иясе, изге итеп тасвирларга омтыла. Бу яктан аеруча Хуҗа Бәһаэддин Нәкышбәнди хакындагы хикәят (344—351 б.) гыйбрәтле. (Мәгълүм булганча, Урта Азиядә яшәп, 1390 елда дөньядан киткән бу зат Идел-йортта да бик хөрмәт ителә.) Таҗеддин Ялчыгол аның ана ягыннан «Хозыр пәйгамбәр» белән бәйле икәнлеген күрсәтә. Нәкышбәндинең дөньяга киләсе Мөхәммәд пәйгамбәргә үк билгеле була. Хикәяттә аның зирәклеге, төрледән-төрле изгелекләре шактый үтемле итеп тасвирлана. Мәсәлән, ачлык елда Нәкышбәнди өч бөртек «богдай»дан «олуг таг кеби» икмәк көшеле хасил итә, кешеләрне үлемнән саклап кала. Ул вафат булгач, «ике кечерәк ак кош һәрвакыт да кабер өстенә куныб, «хак-хак» дийү» кычкыра. Бу да аның хаклыгын белгертеп тора.

«Рисаләи Газизә» авторы алга сөргән идеаллар гомумкешелек кыйммәтләре, инсаният төшенчәләре белән табигый керешеп китә. Ул күрергә теләгән камил кеше — иманлы, укымышлы, күркәм холыклы, инсани эш-гамәлле зат. Әдип «ачкүзлелек», «монафикъ»лык (икейөзлелек), «гафил»лек (ваемсызлык), көнчелек, нәфес колы булу һәм башка шундый сыйфатларның кешене тугры юлдан читкә сөйрәвен, әхлаксызлык, намуссызлык упкынына алып баруын үтемле итеп тасвирлый.

Әсәрдә суфыйчылык, аның асылы, төрләре, гамәлләре шактый җентекле тасвирлана. Мәүла Колый, Утыз Имәни шигырьләрендәге кебек, «Рисаләи Газизә»дә дә тыштан изге, эчтән комсыз булган руханилар, ялган суфыйлар кискен тәнкыйтьләнә. Безнең бу замандагы суфыйларның күпчелеге, ди Таҗеддин Ялчыгол, «мал өчен мөридләр бәсләрләр (тотарлар), кайусының малы улса, аны газиз тотарлар вә байлар ишекендә ишек саклаучы этләр кеби торырлар, артык тәгамләрене бирерләр дийү... Кайу мөриднең малы улмаса, накабел (киресенчә) безләрдән сәңа тәрбият юк дийү алдаб кайтарырлар. Бончалаен җәмәгате суфыйлар(ның) дөнья вә ахирәт йөзләре карадыр... Аслан анларда яхшы ният юкдыр ки, күбләре надандыр...» (171—172 б.). «Рисаләи Газизә» авторы да, Ясәви, Гаттар, Хисам Кятиб, Өмми Кәмал традицияләрен дәвам итеп, гомернең фанилыгына, үлемнең барлык инсаннар өчен котылгысыз булуына басым ясый («Әгәр сән йир йөзенең падишаһы булыб хөкем әйласәң дә, ахыр бер көнне үлем чәнгаленә, ягъни тырнагына тотылыб, кара йир астына керерсән, үлемдән калмазсәң».— 151 б.). Кеше, ул кем булуына һәм нинди вазифа башкаруына да карамастан, тыйнак, итагатьле, сабыр булырга, мал-мөлкәт артыннан кумаска, күңелен, рухын пакь кылып яшәргә бурычлы. Әдип фикеренчә, кешеләрнең яшәү рәвешләре төрле-төрле: бае бар, ярлысы бар. Әмма аларның «һәр икесе дә әҗәл ширбәтене эчсәләр, ... бердәк (бердәй) кара туфрак улырлар» (332 б.).

Таҗеддин Ялчыгол китабында тәрбияви, әхлакый яктан фикер-киңәшләр шактый күп: «Яманнарның яманы — кинә (ачу, үч) тотмак»; «Күңел милкенең падишаһы булсаң, сиңа хаҗәт дәгелдер йир йөзенең падишаһы улмак»; «... укыдыкы Коръән вә дәресдән үгет вә нәсыйхәт алмасаң, һаман бер кара чебен кебидер. Сән аның Коръән йөзенә куныб тордыкы кеби ула, ягъни әүвәл үзеңне тугры юлга күндер, андан соң адәмиләрне күндерерсән» (147 б.); «Сары май кеби мөселман кардәшләреңә мөлаем улгыл вә дәхи сөчүк (татлы) телеңне мөселманларга бал кеби даим әйлагел» (256 б.); «Үзеңә рәва (дөрес, урынлы) күрмәгән нәрсәне, зинһар, мөселман карындашыңа рәва күрмәгел» (335 б.); «Нәсыйхәт сүзене ишетмәс каты күңелле кемсәнә, нә кадәр вәгазь китабларыны укысаң да, кабул әйламәс... Таш өстенә үлән бөтмәдеке (үсмәгән) кеби...»; «Пәйгамбәр г.-м әйде ки: «Һәркем хатындан вә балачыкларындан качыб, нәфәка (туендырырлык ризык) бирмәен йөрсә, ул кемсәнәнең аслан кылдыкы гыйбадәте кабул дәгелдер»,— диде» (232 б.) h.б.

«Рисаләи Газизә» — өйрәтү-аңлатуны, кабул итү-үзләштерүне, ягъни педагогик процессны күздә тотып язылган китап. Бу аның стилендә дә, төзелеш-структурасында да, поэтикасында да үзен нык сиздерә. Текстта бәян итү, бәхәс, сорау-җавап формасы, кабатлау, төрле искәрмәләр бирү үзара үрелеп бара. Әсәр чагыштырмача мөстәкыйль структур берәмлекләрдән, төрле хикәятләрдән гыйбарәт. Бу ягы белән ул тартмалы композицион жанр төркеменә керә. Текстта мәгънәви эчтәлекне ачуга, эстетик тәэсир көчен арттыруга ярдәм итәрлек кызыклы сурәтләр, чагыштырулар бар: «Башың һәм күккә йитсә, кол сән, әййар» (323 б.); «...агыр сабырлы улгыл дөньяда, йир кеби. Нитәк ки йирнең өстендә төрлек нәрсәләр вардыр: изгедән, явыздан, хәсисдән вә нәфисдән — барчасыны күтәреб торыр» (338 б.); «... сән ... хурлыкда калдым диб, «вай» димәгел, нитәк ки чынаякны күб тибкән вә баскан балчыкдан ясарлар» (339 б.). Автор тау-ташларны «йир йөзенең кадаклары» дип атый (108 б.), күз яшен «кырау белән» (351 б.), «кызларның «сач толымын» «сөнбел» (351 б.) белән чагыштыра. Таҗеддин Ялчыгол фикеренчә, «йир илә күк — җефетләрдер. Яз фасылында йир җефетенә зәүкъ әйләр, күк аңа чык суыны йибәрер. Аның илә йир рахәтлек табыб, үләнләр

илә хамилә (йөкле) улыр...» Шуннан табигать камиллеккә ирешер» (321 б.). Автор үз укучысына дәшеп, китаптагы сүзләрне «колагыңа алка кеби... тагыл»,— ди (366 б.).

Урта гасырның күп кенә әсәрләрендәге кебек, телдәге омонимия мөмкинлекләре «Рисаләи Газизә»дә дә иркен файдаланыла: «Бу төнне төш белән төш кылма» (137); «Кыямәтнең уен куйсаң, уен куй» (359 б.); «Булыбсән кер (керле), нәдәм (үкенмәклек) дәрьясына кер» (153 б.); «Кара димә, кара хуш фигълене...» (193 б.); «Тирем хиҗләт (оялу) белән акса тиремдин» (120 б.). Бер бәетнең тәүге мисрагында «сал» сүзе «гомереңнең елы», икенче юлында суны кичү әсбабы һәм гадәти фигыль рәвешендә кулланыла [«...Тәвәккел салыны максат бәхренә сал...» (233 б.); «Вә гәр йөз табыса (йөз мәртәбә кыйнаса), кайтармас йөзене...» (192 б.)]. Шигъри юлларда, эстетик максатны күздә тотып, бер үк сүзне кабатлау да күзгә ташлана: «Ушал пиригә (шәйхка) пирнең пире булгай» (134 б.); «Мөселман алы («вәкиле») булсаң, алма алын, әгәр алсаң, кабул итмә вәбалын» (ярамаганын) (191 б.)...

Таҗеддин Ялчыгол сүз-гыйбарәләрне чагыштырма аңлатуның да күп кенә үрнәкләрен бирә: «...Рум халкының шаһыны «кайсар» дирләр; ...Чын халкы шаһыны «фәгъфур» дирләр; ...татар халкының шаһыны «хан» дирләр; Русия халкының шаһыны «император» дирләр». «Яңгак ләфзы (сүзе) фарсы лөгатендә (телендә) «чар мәгыз» дирләр, болгар (татар) теленчә «әчтерхан чикләвеге» димәкдер, төрекмән лөгатенчә — «яңгактыр...» (218 б.).

Г.Рәхим һәм Г.Газиз, «Рисаләи Газизә»нең телен күздә тотып, болай язалар: «...аның теле җиңел вә һәрбер татар өчен ансат аңлашылырлык» (Татар әдәбияты тарихы...—

1925.— 159 б.). Чыннан да, XVIII—XIX йөзләрнең күп кенә язма истәлекләре арасында бу китап тел-стиленең чагыштырмача аңлаешлы булуы белән аерылып тора. Әмма Октябрь инкыйлабыннан соң без күп кенә элеккеге казанышларыбыздан, аеруча тел байлыгыннан шактый аерылдык. Шуның өчен Таҗеддин Ялчыгол әсәрендә бүгенге көн укучысына бөтенләй яисә өлешчә таныш булмаган сүз-гыйбарәләр, грамматик шәкелләр дә очрый. Андыйларга аерым гарәп-фарсы, борынгы төрки-татар сүзләре һәм формалары керә. Кайбер сүз-атамалар, гәрчә алар татарча язылсалар да, катлаулы дини-суфыйчыл, фәлсәфи төшенчәләрне белдерү нәтиҗәсендә, бүгенге укучы тарафыннан авыр кабул ителә.

«Рисаләи Газизә» ядкяре тел ягыннан бай, кызыклы. Китапта без төрки-татар язма һәм сөйләмә тел хәзинәсенең шактый мул һәм тулы файдаланылуын күрәбез. Хәтта арада кылк (холык), ут (үлән), иркәк-теши (ир-ат һәм хатын-кыз), азак (аяк), үтмәк (икмәк) кебек борынгырак формалар да очрый. Татар теленең мишәр диалекты һәм Урта гасырның аерым ядкярләре («Хөсрәү вә Ширин»...) өчен хас булган

-мага/-мәгә (алмага, эшләмәгә...) кебек элементлар да «Рисаләи Газизә» өчен чит түгел. Автор, үз чорының сөйләм чынбарлыгына мөнәсәбәттә, әсәргә моңа кадәр язма әдәбиятта бик күзгә ташланмаган аерым сүзләрне дә кертеп җибәрә. Мәсәлән: «Шаль дидеке кәзә мамыкыннан ясалмыш затдыр» (158 б.); кабак — мәйханә (238 б.); панар — фонарь (248 б.); шәберчек — йомыртка (269 б.); кыекча — яулык (250 б.); филтә — пилтә (290 б.); «кисмәк вә чапчак» (242 б.); әзбиз — известь (340 б.)... Китап, әйткәнебезчә, иң беренче чиратта, педагогик ихтыяҗны, тәрбияви максатны күздә тотып язылган. Шуңа күрә анда үгет-нәсыйхәт, киңәш бирү интонациясе өстенлек итә. Моңа мөнәсәбәттә еш кына мәкаль-әйтемнәр, канатлы гыйбарәләр кулланыла: «Күз өстендә каш кеби газиз...» (171 б.); «Күб чишмә бер-беригә кушылса, олуг елга булыб акар» (177 б.); «Кадәм туфракы күзгә тутыядыр» (...аяк басдыкы туфракы күзгә сөрмәдер.— 171 б.), «Үлмәздән борын үлеп куй» (275 б.); «Яманлык әйлагәнгә яхшылык кыл» (339 б.) h. б.

«Рисаләи Газизә» — күпгасырлык төрки-татар әдәби казанышларына нигезләнеп туган ядкяр. Иң беренче чиратта, ул Рабгузый, Мәхмүд Болгари традицияләрен дәвам иттерә. Бу аларның һәм идея эчтәлегендә, һәм тел-стилендә, һәм төзелешендә күзгә ташлана. Бу өч ядкяр дә тартмалы композицион жанрда, дини-әхлакый, синкретик характерда.

XII йөз шагыйре Сөләйман Бакырганыйның «Сәңа кол булгам — солтандин артык» шигыре бар. «Рисаләи Газизә»дә шуңа охшатып язылган юллар очрый («Сәнең юк булганың — барыңдан артык».— 303 б.). Мөхәммәдьяр (XVI йөз) болай ди: «Кем егылганда кулын тот бер моңлының, Ул тәкый тоткай кулың бер көн сәнең»[37]. Моңа аваздаш фикерне без «Рисаләи Газизә»дә күрәбез: «Әгәр мәртәбәң (дәрәҗәң) ирер, әгълаи афак («күкләргә тиярлек биек булса да»), Екылган хәстәләрнең халигә бак» (156 б.). Шунысы мөһим: Сәйф Сараилардан ук килә торган мондый мотив Мөхәммәдьяр, Таҗеддин Ялчыгол аша Тукай, Гафуриларга да ирешә. Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» әсәрендә (1069) тел, сөйләшү турында махсус бүлек бар. Шагыйрь фикеренчә, инсанны тел хөрмәтли дә, түбән дә итә. «Рисаләи Газизә» китабында да бу мәсьәлә читтә калмый. «Теленңне,— ди автор,— суык сүздән саклагыл... Яман тел сәбәбе берлә хур улырсән» (253 б.); «...инә җәрахәте үңәлер (төзәлер), сүз җәрахәте үңәлмәз...» (252 б.). Котб, Сәйф Сараи тозлы (шурә) җиргә иген игүнең файдасыз шөгыль булуын кат-кат искәртәләр. «Рисаләи Газизә» китабында да бу мотив гәүдәләнеш таба: «Зирагать әйламә шуре зәминне» (ягъни тозлы, уңдырышсыз җирне.— 293 б.).

XVIII йөзнең ахыры — XIX гасыр башлары — татарларның, колониаль тукмаклардан бераз айнып, янә тернәкләнергә омтылган чоры. Пугач хәрәкәтеннән соң туган иҗтимагый-сәяси вазгыятьтә халкыбыз, чукындыру, эзәрлекләү, кысу сәясәтенә калкан итеп, белем-мәгърифәтне, ислам динен, гореф-гадәтләрне торгызу, ныгытуны үзенә бурыч итеп куйды. Бу иҗтимагый заруриятне гамәлгә ашыруга, Утыз Имәни, Курсави һәм кайбер башка зыялылар белән бергә, Таҗеддин Ялчыгол да үзеннән сизелерлек өлеш кертте. «Рисаләи Газизә» — шуның күркәм бер үрнәге. Ул халыкта бик популяр була, аны рухи яктан азыкландыруда мөһим роль уйный. «Рисаләи Газизә»дәге мотивлар, фикер-идеяләр, сурәтләр, шигъри чаралар Шәмседдин Зәки, Һибәтулла Салихов, Акмулла, Тукай, Гафури һәм башка авторлар тарафыннан теге яки бу дәрәҗәдә файдаланылды. Гали Чокрыйның бу ядкяр тәэсирендә «Дибаҗәи Фаизә» әсәрен язуы да (Татар әдәбияты тарихы.— II т.— 430 б.) күп нәрсә хакында сөйли (Фаизә — автор кызының исеме).

«Рисаләи Газизә»— әдәбиятны, динне, телне, мәгарифне, гореф-гадәтләрне, гыйлем тарихын тикшерүдә дә мөһим чыганак. Аны үзләштерү әхлаклылыкка, хәтер дәвамчанлыгына өйрәтә. Шагыйрь һәм галим Гали Чокрый (1826—1889), Таҗеддин Ялчыголны мактап, махсус мәдхия яза[38]. Ул шундый юллар белән төгәлләнә: «Аның ханы нәвалендән ничә гам Алыр бәһрә ничә айда, ничә гам».— Ягъни аның хәзинәсеннән никадәр халык ничә айлар, еллар алса да, өлешле булыр (сый-табыны кимемәс).

Таҗеддин Ялчыгол үз китабын кызы хөрмәтенә «Рисаләи Газизә» дип атаган. Әтисе «күзем нуры», «бәгърем парәсе» дип йөрткән Газизәнең кабере Мәлем зиратында. Еллар узган, ничәмә-ничә буын туфрак булган, кабер өсләрендә агачлар үскән. Әмма «Рисаләи Газизә» ядкяре вакытның агышына, җил-яңгырына да бирешмичә яшәвен дәвам итә.

[1] *И.Г.Галяутдинов*. «Тарих нама-и булгар» Таджетдина Ялсыгулова.— Уфа: Башкирское книжное изд-во, 1990.— С. 169. Бу басманың 124—206 битләрендә гарәп, кириллица хәрефләрендә һәм русчага тәрҗемәдә тәнкыйди текст урнаштырылган.

[2] Иштәк-истәк — татар һәм башкорт составына кергән кабилә атамасы.

[3] Троиски-Троицк — Көньяк Уралдагы шәһәр исеме. Шуңа мөнәсәбәттә Таҗеддин Ялчыголның туган җирен Троицк тирәләренә нисбәт итү дә бар.

[4] Әдип әтисенең васыятенә тугры кала: нинди генә кыенлыклар булса да, гомере буе «дәрес әйтә», халыкны белемле, тәрбияле, сәламәт итү өчен тырыша, бу сыйфатларны үзенең балаларына һәм оныкларына да сеңдерә.

[4a] Ш.Мәрҗани фикеренчә, Таҗеддиннең әтисе Кече Сөндә (аны Кечавыл дип тә йөрткәннәр) җирләнә (Асарь, VI җөзә.— 337 б.).

[5] Рәгаиб киче — рәҗәб аеның беренче җомгасында дини бәйрәм кичәсе, ягъни теләкләр теләү кичәсе.

[6] Китабе Рисаләи Газизә.— Санкт-Петербург, 1847.— 367—368 б.

[7] «Тәварихе Болгария»дә Таҗеддин Ялчыгол әтисенең «65 яшендә», һиҗри белән 1200 елда (милади белән 1786 елда) вафат булуы хакында яза. Ә инде «Рисаләи Газизә»нең ахыргы битләрендәге шигырьдә атасының 53 яшендә үлүе искәртелә: «Ки илле өчдә ирде хәяты, Суйи шәгъбанда ирде мәмате» (*Шәгъбан аенда иде үлеме.*) (368 б.). Шушында ук әсәрнең «мең ике йөзнең унында» (ягъни 1796 елда) язылуын, инде «унөч ел» аерылышу утында («наре фиракън»да) януын телгә ала. Янәшәдә үк мондый юл да бар: «Унике яшемдә калдым гарибдә, Тәвабигы вә Болгар, вә Казанда» (*Болгар вә Казан тирәләрендә*).

Күрәсез: «Тәварихе Болгария» белән «Рисаләи Газизә»дәге саннар арасында аермалар шактый. Моның сәбәбен әйтүе кыен. Төрлелек, әлбәттә, әдәби гомумиләштерү һәм яшьне һиҗри ел хисабында бирү белән дә булырга мөмкин. Кульязманы күчерүчеләрнең дә төгәлсезлек җибәрүе ихтимал. Әмма авторның «12 яшемдә калдым гариб» диюе «Тәварихе Болгария»дәге фактлар белән бөтенләй ярашмый. Ирексездән сорау туа: әллә Таҗеддин Ялчыгол, нинди дә булса сәбәп аркасында, даталарда төрлелекне махсус рәвештә җибәргәнме?!

[8] Миңа 1995 елның 21 октябрендә Түбән Кама педагогия училищесы директоры, гаҗәеп тә милләтпәрвәр зат Рәфкать Муллин белән Зирекле авылында (аны Каенлы, Татар Җиреклесе дип тә йөртәләр) булырга туры килде. Биредә мин пенсионер укытучы Фәхри ага Шәрәфиев (1907 елгы) белән очраштым. Ул, төрле чыганакларга нигезләнеп, авыл тарихын язган. Фәхри ага раславынча, Каенлының шактый халкы Мамадыш ягындагы Кече Сөн һәм Үсәли авылларыннан күчеп килгән. Ул: «Таҗеддин Ялчыгол биредә 9 ел яшәгән»,— дип яза.

[9] *И. Г. Галяутдинов*. Күрсәтелгән хезмәт.— 23—24, 28 б.

[10] Мәлем (Югары Налим) — Зәй шәһәреннән 20 чакрымлап ераклыкта (Сарман ягына таба) урнашкан уртача зурлыктагы (200 ләп өй) татар авылы. Элек Уфа губернасы Минзәлә өязенә кергән бу «карья»нең тирә-юнендә рус, татар, керәшен авыллары. Аннан 6 гына чакрым ераклыкта минем туган авылым Апач та (Сармаш по Ирне) бар. Шуңа күрә Мәлем, аның кешеләре миңа шактый таныш. Минем әтинең бертуганы Салихҗан абыйның (без аны «дүрәти» дип йөртә идек) хатыны Галимә түти («дүрәни»), әйтүләренә караганда, Мәлем килене, Таҗеддин Ялчыгол нәселенең бер вәкиле була. Әдипнең Апачта булуы хакында да мәгълүматлар бар.

[11] Бу мәсьәлә безнең катнашта язылган «Тарихта эзле инсан» мәкаләсендә (Мирас.— 1998.— # 11.— 4—12 б.) шактый тулы яктыртылган.

[12] *И.Г.Галяутдинов*. Күрсәтелгән хезмәт.— 23—25 б.

[13] Бу китапны «Фәваиде Баһавия» дип атау да очрый (Татар әдәбияты тарихы.— 1 том.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.—444 б.).

[14] *Шиһабетдин Мәрҗани*. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. 11 кыйсем.— Казан, 1900.— 250—251 б.

[15] *Дамир Гарифуллин*. Тарихта үз эзе бар// Казан утлары.— 1989.— 2 нче сан.— 182 б.

[16] *Марсель Әхмәтҗанов*. «Тарихнамәи Болгар»ның яңа табылган бер кулъязмасы// Эхо веков.— Гасырлар авазы.— 1996.—
№ 3—4.— 25—29 б.

[17] Әмма бу җитди генә хезмәттә әдип атамасын «Ялсыгулов» рәвешендә бирү бәхәсле. Чөнки бу исем чыганакларда *с* хәрефе аша түгел, ә *ч* ярдәмендә бирелгән (Ялчыгол). Китапта телгә алынган Г.Чокрыйны да Г.Сокрый дип язу фәннилеккә хилафлык китерә.

[18] *Рәшит Хәмәдиев*. Тарихта эзле инсан// Мирас.— 1998.— # 11.— 10—11 б.

[19] Гамир әфәнденең әтисе Госман ага Таҗетдинов белән (ул 1910 елгы) минем очрашкалаган бар иде. Әмма, кызганычка каршы, мин Таҗеддин Ялчыгол, ягъни аның бабасы хакында махсус сораштырырга өлгерми калдым. Госман ага 1998 елның 7 июлендә вафат булды. Д.Гарифуллин исә бу могтәбәр заттан алган аерым мәгълүматларын «Тарихта үз эзе бар» мәкаләсендә (Казан утлары.— 1989.— # 2) файдалана.

[19а] Әйткәнебезчә, «Тәварихе Болгария» 1806 елда төгәлләнә. Ә әдипнең гаиләсе хакындагы бу мәгълүматлар соңрак, Таҗеддин Ялчыгол Мәлемдә яшәгәндә теркәлгән.

[20] Имәнлебаш район үзәгеннән (ягъни Зәйдән) 15 чакрым ераклыкта тора. Ул Зәй һәм Түбән Кама шәһәрләре арасында урнашкан.

[21] Таҗеддин Ялчыголның үлеме хакында Ш. Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар...» китабында (Казан, 1900.— 250—251 б.) болай яза: «Сәяхәтендә әхбабларындан берәүнең даренә дохул илә эчәргә сораб, сахибе бәйт шәрабе гасәл китереб биреб, шуны эчеб... Имәнле нам карьядә вафат улды». Ягъни әдип бер сәяхәте вакытында бер дустының өенә кергәч эчәргә сорый, өй хуҗасы аңа ачы бал бирә, шуны эчеп... үлә. Бу хәлне кайвакыт заманча аңлату очраклары да бар. Имеш, Таҗеддин Ялчыгол эчеп үлгән. Ә бит бу факт бик гади аңлатыла. Җәйге эссе көндә кешенең сусавы, аңа су урынына хуҗаның эчемлек бирүе, моның 70 яшьлек кешегә ярамавы табигый. «Шәрабе гасәл» («Мөстәфадел-әхбар...»ның 1989 елгы басмасында аны «балдан ясалган аракы» дип тәрҗемә иткәннәр.— 293 б.) — гадәти ачы бал. Градусы түбән бу эчемлекне элеккеге татар гаиләләрендә сусауны басар өчен дә кулланганнар.

Тынгысыз әдипнең күпләгән дуслары гына түгел, аерым дошманнары да булгандыр. «Ачы бал» вакыйгасын аларның гайбәт рәвешендә таратулары да мөмкин.

Таҗеддин Ялчыгол — әхлаклы, аек акыллы, итагатьле зат. Моны әдипнең тормыш юлы да, хезмәтләре дә, аның хакындагы якты истәлекләр дә раслап тора. Юкка гына бу инсанны халык ул исән вакытта да, вафат булгач та «Таҗеддин хәзрәт», «изге зат» дип атамый.

[22] Таҗеддин Ялчыгол яшәгән Каенлы, Кызыл Чапчак, Мәлем — элек тә, хәзер дә саф татар авыллары. Аларны элеккеге Уфа губернасына керүләренә карап, башкортка, Башкортстанга бәйләргә омтылу бөтенләй нигезсез.

[23] Әдипнең оныклары үзләренең нәсел-нәсәбе белән шактый кызыксына. Мәсәлән, Фәүзия һәм Госман Таҗетдиновларның бабалары — Таҗеддин хәзрәтнең углы Җәләледдин (аның углы Мөхәммәдшакир, аның углы Сөнгатулла.— 1873—1921...). Әле яңарак кына арабыздан киткән әдибә һәм журналист Диләрә Газый кызы Зөбәерова (1930—2000. Ул кайбер язмаларын Ялчыгулова имзасы белән дә бастырды. Аның әнисе — Җәләледдин буыныннан) заманында Таҗеддин «бабасы хакында материаллар җыйган, өлкәннәрнең аның турында сөйләүләрен тыңлаган...» Бабасының «төп кебек нык, күзләренең зәңгәр, мыегының сары (бакыр) булганлыгын» искәрткән (Тарихта үз эзе бар // Казан утлары.— 1989.— № 2.— 183 б.). Фәүзия апа фикеренчә, аның әбисенең әнисе Фәрхидоха (ул хәзерге Зәй районы Чыбыклы авылыннан килен булып төшкән) Ризаэддин Фәхреддин шәҗәрәсе белән бәйле.

Таҗеддин Ялчыголның нәсел-нәсәбе, оныклары төрле төбәкләргә таралган. Алар арасында төрле шөгыль ияләре бар. Мәсәлән, Әнәс Габдулла углы Таҗетдинов (1927—1991) 1971—1987 елларда Татарстанның юстиция министры булып эшләде. Әсгать Сәфәров (1961) — генерал, Татарстанның эчке эшләр министры. Гамир Таҗетдинов (1941) Зәй төбәгендә укытучы, мәктәп директоры, район мәгариф бүлеге мөдире һәм башка җаваплы урыннарда эшләде. Хәзер шул ук районның Аксар авылында күмәк хуҗалык рәисе.

[24] Тарихта эзле инсан // Мирас.— 1998.— № 11.— 8 б.

[25] Яңапар (Актүк) — Сергач төбәгенең мәшһүр авылы. Финляндиядәге күпчелек милләттәшләребезнең әби-бабалары шушы авылдан. Мөгаен, Ризван Маллай да Петербург, Суоми якларында сәүдә яисә башка эш белән шөгыльләнүче укымышлы бер зат булгандыр. Авыл тарихы, аның кешеләре хакында Хәсән Хәмидулланың «Яңапар тарихы»н карагыз (Мирас.— 1998.— № 6.— 77—102 б.). Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев, Рифат Фәттахов һәм кайбер бүтән билгеле затлар да — шушы авылдан.

[26] Казан университеты басмаханәсендә 1850 елда дөнья күргән бу китапны матбугатка «Казан мешчаны (мещаны) Шаһиәхмәд Хисамеддин углы вә һәм Хәсән Бәһаэддин углы Саликовлар һәр икесенең хөраҗатлары илән» әзерлиләр. Алар фикеренчә, басма текстның «асыл нөсхәсе» нигезендә башкарыла (437 б.).

[27] Рухи пакьлеккә өндәгән китап // Мирас.— 1988.— № 10. — 5—13 б.; Әдәбият (9 нчы сыйныф өчен дәреслек...) — Казан: Мәгариф, 1994.— 178—179 б.

[27a] *Таҗеддин Ялчыгол*. Рисаләи Газизә / Әсәрне басмага әзерләүче (гарәп графикасындагы текстларны укып, басмалар арасындагы аерымлыкларны күрсәтеп, гамәлдәге язуга күчерүче, аңлашылмаган сүз-гыйбарәләрне һәм юлларны тәрҗемә итүче, тиешле шәрехләр бирүче) һәм кереш мәкалә авторы — Хатыйп Йосыф углы Миңнегулов.— Казан: «Иман» нәшр., 2001.— 480 б.

[28] «Рисаләи Газизә»дә ул «Интекмәклекне исбат әйлагүче» дип тә тәрҗемә ителә (1847 елгы басма, 35 б.).

[29] Фәнни әдәбиятта Суфый Аллаярның яшәү вакыты 1616—1713 еллар дип күрсәтелә. Шагыйрь 1616 елда туган дип алсак, аның үлеме 1706—1707 елларга туры килә. Чөнки Таҗеддин Ялчыгол аның »туксан яшендә» үлүен искәртә. 1707 елда Суфый Аллаяр үзенең «Мәсләкел-мөттәкыйн» әсәрен төгәлли. Шунысы ачык: шагыйрь 1707 елдан да иртәрәк үлмәгән.

[30] *Фәрит Яхин*. Урта Азиядә яшәгән татар шагыйре // Мирас.—1997.— № 9.— 16—19 б. Шушы ук автор «Сөбател-гаҗизин» поэмасын, хәзерге татар теленә тәрҗемә итеп, тиешле аңлатмалар белән әүвәл «Мирас» журналында (1997.— # 9—12), аннан аерым китап рәвешендә бастырды [*Суфи Аллаһияр*. Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк)].— Казан: «Иман» нәшр., 2000.— 156 б.

Фәрит Яхинның «Татар шигърияттендә дини мистика һәм мифология» монографиясенең дә (Казан: Татар дәүләт гуманитар институты нәшрияты, 2000.— 267 б.) бер бүлекчәсе (239—258 б.) Суфый Аллаяр иҗатын тикшерүгә багышланган.

[31] «Сөбател-гаҗизин»нең язылу вакыты билгеле түгел. Мәгълүм булганча, Суфый Аллаяр иҗат эшенә шактый соң — 40—50 яшьләрендә генә керешә. Бу әсәр якынча XVII гасырның соңгы чирегендә язылган булырга мөмкин.

[32] «Сөбател-гаҗизин»нең Утыз Имәнигә нисбәт ителүче «шәрех»ендә (Казан университетының фәнни китапханәсе. Сирәк китаплар һәм кульязмалар фонды.— № 736 Т.— 128 кәгазь) төп урынны Суфый Аллаяр тексты алып тора. Биредә аңлатма-шәрехләр тик аерым сүзләргә, гыйбарәләргә генә бирелгән.

[33] Сөбател-гаҗизин.— Казан, 1841.— 108 б.

[34] Татар мәгърифәтчелек әдәбияты / Төзүчесе М.Гайнуллин.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1979.— 12 б.

[35] «Рисаләи Газизә»нең бу өлеше белән Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки»ендәге кереш типологик яктан охшаш. Һәр икесендә дә башка авторның (берсендә — Сәгъдинең, икенчесендә — Суфый Аллаярның) әсәрен үз укучыларыбызга җиткерү үтенече белдерелә. Һәм Сараи, һәм Ялчыгол үзләрен кимчелекле дип саныйлар. Ахыр чиктә һәр икесе дә үзгәләрнең теләгән гамәлгә ашыруга керешә.

[36] Локман — Локман Хәким — Шәрык дөньясының легендар акыл иясе.

[37] *Мөхәммәдьяр*. Нуры содур.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.— 66 б.

[38] *И.Г.Галяутдинов*. Тарих нама-и булгар...— 25—26 б.

*1998, 2001*

**ШӘМСЕДДИН ЗӘКИНЕҢ ШИГЪРИ ДӨНЬЯСЫ**

Шагыйрь, галим һәм укытучы Шәмседдин Суфый Зәки үзенең эшчәнлеге, шигъри таланты, зирәклеге белән бик күп кешеләрнең, күренекле зыялыларның игътибарын үзенә тарткан. «Зәкилектә зәки, гамил вә камил»,— дип яза аның турында шагыйрь Гали Чокрый (1826—1889). Ризаэддин Фәхреддин әдипне еш кына белем-зирәклекнең өлгесе, эталоны дип карый һәм аны Шәрыкның бөек шагыйрьләре Әл-Мәгарри (973—1057) һәм Физули (1494—1556) белән тиңли. (Асарь. XIII җөзэ, 2 җилд.— Оренбург, 1907.— 421—422 б.). «Шәмседдин Суфый, Багдад Физулие булмаса да, Урал-Волга буйларының, иң дөрестә безнең Физулиемыз идекендә шөбһә юк»,— ди ул («Шура» журналы.— 1913.— № 11.— 352 б.). Г.Рәхим һәм Г.Газиз тарафыннан язылган әдәбият тарихы китабында без Ш.Зәки хакында мондый юлларны укыйбыз: ул «борынгы шагыйрьләребез арасында иң парлак исем»; «...мәрсияче шагыйрьләрнең бөтенесен бергә алганда да бер Шәмседдин Суфыйга алмаштырырга мөмкин түгел... Ул ... безнең Идел буе әдәбиятын чыгтай әдәбиятының алтын гасыры белән бәйли... Аның... шигырь валчыкларына карап кына да..., даһилык дәрәҗәсендәге истигъдадлы лирик булганлыгын бер дә тартынмыйча әйтергә мөмкин» (Татар әдәбияты тарихы.— Казан, 1925.— 187, 191 б.). Ш. Зәки шәхси сыйфатлары, драматик язмышы белән дә татар тормышының кабатланмас бер сәхифәсен тәшкил итә.

Шагыйрьне гыйльми өйрәнү XIX йөздә үк башлана. «Мөтәдәйн (динле), фазыйл вә зәки иде, Хафизел Коръән улыб, әдасе («стиле») гүзәл иде, сахибе әүрад-у салих (изге) бер зат иде»,— ди аның хакында Ш.Мәрҗани (Асарь, XIII җөзэ, 2 нче җилд.— Оренбург, 1907.— 420 б.). Әмма әле бу әдип турында тәүге гомуми мәгълүмат кына иде. Ш.Зәкинең тормышын һәм иҗат мирасын ныклап өйрәнү Ризаэддин Фәхреддиннән башлана. Аның шагыйрь турындагы мәкалә-хезмәтләре фәнни яктан хәзер дә әһәмиятле. М.Рәмзи, Җ.Вәлиди, Гата Исхакый, Г.Рәхим һәм Г.Газиз, Г.Сәгъди, М.Гайнуллин, М.Госманов, Ә.Харисов, А.Фәтхи һәм кайбер башка галимнәр Ш.Зәкинең тормышын һәм иҗатын өйрәнү буенча шактый эш башкардылар.

«Татар әдәбияты тарихы»ның XIX йөзгә багышланган икенче томында да (Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.— 170— 184 б.) Ш.Зәки хакында М.Гайнетдинов тарафыннан язылган бай эчтәлекле мәкалә бар.

Мәгълүм булганча, Ш.Зәки элеккеге Оренбург губернасы Зәк-Ишмәт авылында дөньяга килә. Сукыр. Казанда укый. Гомеренең зур өлешен туган авылында уздыра. Хаҗга барганда, Таганрог шәһәрендә үлеп китә. Кабере Азов диңгезе буендагы шул калада. Шагыйрьнең якташы Зиннәтулла Мөхәммәдрәхими (1858—1922) Ш.Зәки тормышын өйрәнә, әсәрләренең җыентыгын төзи. Әмма 1916 елда тәмамланган бу мәҗмуга басылмый кала. Хәзер ул Башкортстан Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми архивында саклана (3 нче фонд, 63 нче тасвирлама, саклану берәмлеге — 47).

Ш.Зәкинең иҗат мирасы, шул исәптән З.Мөхәммәдрәхими җыентыгы да, безнең тарафтан махсус тикшерелеп, аның нәтиҗәләре түбәндәге китапта дөнья күрде: *Х.Миңнегулов, Ш.Садретдинов*. XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре.— КДУ нәшрияты, 1982.— 3—86 б. Биредә Ш.Зәки шигырьләренең тәнкыйди тексты да тиешле шәрех-аңлатмалар белән бирелгән. (Алга таба текстлар шушы хезмәттән алыначак.)

* * *

Тома сукыр Шәмседдин Зәки үзенең кыска гына гомерендә татар, гарәп, фарсы телләрендә күп санлы әсәрләр, заманы өчен хас фәнни-методик хезмәтләр тудырган. Аларның безгә билгеле кадәресен генә күздән кичерү дә шагыйрь иҗатының шактый үзенчәлекле, катлаулы һәм шул ук вакытта каршылыклы икәнлеген, әдәбият тарихында мөһим генә урын алып торуын ачык күрсәтә.

Ш.Зәкинең күпчелек әсәрләрендә дини тематика гәүдәләнә. Поэтик контекстта Алла еш кына абсолют хаклык, гаделлек, сафлык, шәфкатьлелек, юмартлык кебек сыйфатларга ия булган өлге, абсолют идеал рәвешен ала. Лирик каһарман шуны сөя, шуңа сыгына, тартыла, үзенең һәм үзгәләрнең һәр сулышын, һәр адымын шуның белән яраклаштырырга омтыла. Кеше табигатендәге кимчелекләр, җәмгыятьтәге бозыклык һәм начар яклар да нәкъ әнә шул өлгегә, абсолют идеалга мөнәсәбәттә тәнкыйтьләнә.

Үзенең әсәрләре аркылы Ш.Зәкинең, суфыйчылык шигъриятенә хас чараларны яхшы белеп, алар белән иркен эш иткәнлеге күренә. «Сәндә-сәнлик (синлек) пәрдәседер, нуре хакдан — хайлең (аерып торучың)»; «Варлыгың ошбу җиһанның варлыгына гаядыр (дәлилдер)»; «Бу җиһан зиндан ирер, безләр каму зинданивуз (безнең барыбыз да тоткын)»; «Бу кафәс җисмендә бер кач көн нәфәс миһман икән» һәм башка күп юллар — моның ачык мисалы.

Ш.Зәки суфыйчылыкның үзәк проблемасы — кешенең Аллага мөнәсәбәтен яктыртуга төп урынны бирә. Шәхеснең рухи халәте, эш-гамәлләре, тышкы дөнья белән бәйләнеше шушы мөнәсәбәткә нисбәтән гәүдәләнә. Мәгълүм булганча, суфыйчылык кешенең Алла белән мөнәсәбәтен эчке рухи сферада карый.

Аныңча, Алла синең җаныңда. Уңай, кимчелекле якларыңны, асылыңны белү аша гына үз-үзеңне камилләштерергә һәм Аллага якынаерга мөмкин дигән фикер Ш.Зәки шигырьләреннән дә ачык аңлашылып тора. Бәхеткә ирешү, ягъни Аллага якынаю кыен һәм катлаулы.

Сафа вә нигъмәтә ирмәклек өчен,
Җәфа вә михнәте дүзмәк кирәкдер,—

ди шагыйрь.

Авторның лирик каһарманы үз-үзеннән һәрчак канәгатьсез: үз-үзен ваемсызлыкта, бозыклыкта, нәфескә бирелеп, фани дөнья белән мавыгуда һәм башка гөнаһлы эш-гамәлләрдә гаепли:

Яландыр барча әкъвалем (сүзләрем),
Ямандыр кяр-әфгалем (эш-фигыльләрем),
Юкдыр һич изгү әгъмалем,—
Дишвар (кыен) улды бәнем хәлем.

Бән Ходаның бер гариб, гасый-у җафи колы мән,
Күңлемнең күзене ябды гәрде гафләт карасы (*ваемсызлык тузаны*).

Бу төр кимчелекләрдән котылу өчен, лирик каһарман даими эзләнә, бөтен барлыгы белән «игри юл»дан тугры юлга басарга, үз-үзен онытып, Аллага гашыйк булырга омтыла; бу эштә үзенә ярдәм сорап, еш кына Алланың үзенә мөрәҗәгать итә.

Ничә еллар ошбу дошман (ягъни нәфес) илкедә булдым әсир.
Сән хәлас ит (коткар), йә Иляһи, әл-әман, әл-әман.

Син ярдәм итмәгәннәр, ди шагыйрь, мәңгегә бәхетсезлектә кала («һәркеме кем сәндан улмады мәдәд. Ул шәкавәт эчрә калды та әбәд»), андыйларны «мәхшәр көне» җәзалары көтә.

Ш.Зәки иҗатында кешенең әхлакый сыйфатлары да Аллага якынаю карашыннан чыгып билгеләнә. Тәкъвалык, күндәмлек, диндарлык кебек төшенчәләр белән бергә, шагыйрь дөреслек, ярдәмчеллек, сабырлык, итагатьлелек, тугрылык һәм башка инсани сыйфатларны да кешене «тугры юлга» илтүче категорияләр дип карый; тәкәбберлек, ялганчылык, икейөзлелек, залимлек, ваемсызлык кебек әхлакый сыйфатлар тискәре бәяләнә.

Шагыйрь фикеренчә, инсанны Алладан ераклаштыручы сыйфатларның иң хәтәре — нәфескә — «иблис» кулына бирелү, ягъни җисмани ихтыяҗларың белән генә яшәү, дөньяның мал вә рәхәтләре белән мавыгу, хирыслыкның колы булу. «Бу хәл,— ди автор,— вафасызлыкка, бозыклыкка этәрә, башка начар сыйфатларның һәм эш-гамәлләрнең тууында төп сәбәпче булып тора». Шуңа күрә дә Ш. Зәки үзенең күп кенә юлларын нәфеснең начарлыкларын күрсәтүгә, гакыл (яисә «җан») белән нәфес көрәшен тасвирлауга багышлый.

Бу яман нәфсең сәнең җаныңда агыр йөк дорыр,
Җаның аныңчөн сәнең дәүләт күгенә бенмәде.

Фәнни әдәбиятта суфыйларның мистик позициядә торулары, ягъни хакыйкатькә ирешүдә гакылны түбәнсетеп, интуицияне, эчке сизүне (төшенүне) генә беренче планга куюлары күрсәтелә. Ш.Зәки исә бу мәсьәләдә бераз аерылыбрак тора. «Алла,— ди шагыйрь,— кешене гакылы белән нәфесе карамагына тапшырган» («Гакыл илә нәфсе җәсәд икълименә солтан» иткән). Шәхеснең нәфесе гакылга буйсынырга тиеш: «Нәфсе куеб гакыла, уян, адәм углы»; «нәфес гаклә монкад улмаз», ягъни гакылга буйсынмас. Әдип Әхмәдҗан бине Нуриманга җибәргән хатында да танып белү процессында гакылның ролена, дәлиллелеккә югары бәя бирә. Ш.Зәкинең гакылны бу рәвешле күтәрүе һәм аның дошманы булган нәфесне кискен тәнкыйтьләве — әдәби-тарихи һәм фәлсәфи яктан мөһим момент.

Кешегә гакыл бирелгән икән, димәк, ул үзенең эш-гамәлләре, гомер юлы өчен үзе җаваплы:

Нә кыйлса — аны күрер адәм углы;
Нә иксә — аны урыр, ахры кяр,—

ди шагыйрь бер парчасында. Бу юллар әдипнең бөтен иҗатына аваздаш яңгырый.

Кеше гомере чикле, үлем зарури:

Чөн бу тормакың соңы — китмәк дорыр.
Һәм бу барлыкың соңы — бетмәк дорыр.

Гәр кылурсән дөньяда мең ел карар,

Гакыйбәт, җан вирәсең сән зар-у зар.

Биредә сиңа җаһ-власть та, дөнья малы да «ярдәмче», «яр» түгел:

Гәр җиһан халкы сәнең әмреңдә рам улмыш (буйсынып) дорыр,
Хак газабындан сәңа анлар мәдәдкяр (ярдәмче) улмая.

Йир йөзенең кәнҗ-малы гәр сәнең улурсә һәб,
Чөн әҗәл килде, аның нәфгы (файдасы) сәңа йар улмая.

Шуңа күрә кеше гомеренең кадерен белергә («форсатың вак тын ганимәт бел, әҗәл килмәздән үк»; «әлең баглы дүгел көн изге эш кыл»), даими рәвештә белем-мәгърифәт тупларга, бер-береңә золым кылмыйча («күңел рәнҗетмәгел золм иlә...»), үзара ярдәмләшеп «бакый ад» калдырырлык итеп яшәргә бурычлы. Ш.Зәки дөньяны камилләштерергә, өзлексез хәрәкәт итәргә, «җиһан әтрафыны гизәргә» чакыра; С. Сараи кебек, кайгы артыннан шатлык киләчәген икърар итә:

Исеб йил дик, акыб су дик тәмамәт,
Бу юлда ут кеби кызмак кирәкдер.

...Йөре, вар, эстә,кер чикләр якасын.

...Тынмайун гизмәкне агун судан үгрәнмәк кирәк.

...Канкы кайгы вар ки, соңында фәрәх (шатлык) йар улмая.

...Канкы ачлык вар ки, соңы ризык бесийар (күп) улмая.

Шагыйрьнең яшәеш, кеше гомере турындагы уй-кичерешләре аеруча аның атаклы «Булгай, булмагай» газәлендә калку гәүдәләнеш тапкан. Автор биредә төрле сурәтләр һәм шигъри чаралар ярдәмендә тереклеккә, яшәү мизгелләренә дан җырлый.

Карчыга кулыңдадыр: аула бу күңлең шәһрине,—
Нагяһан ул карчыга өндәүгә килгәй, килмәгәй.

...Бу җәһанның шәһринең базарының сәүдәсе күб,
Кыйл бу сәүдәне янә базары булгай, булмагай.
...Та терек (исән чакта) сез, дустларым, бер-береңә гыйззәт кылың,—
Ваһ, бу үлем! Үзгә дәм нәгяһ булгай, булмагай.

Шуның белән бергә, Ш.Зәки иҗатында «дарелфәнаны», ягъни дөнья тормышын түбәнсетеп, «дарелбәка»ны идеаллаштырган, дәрвишлекне, аскетлыкны мактаган юллар да еш очрый. Аларның тууы очраклы күренеш түгел. Кайбер суфый шагыйрьләр мал җыюны гаепләү, аскетлыкны мактау юлы белән үз укучыларын дөньядан биздерергә һәм шуның нәтиҗәсендә хөкемдарларның килерен киметеп, властьны какшатырга омтылганнар. Күрәсең, Ш.Зәки дә бу фикерне уртаклашкан. Әгәр дә шагыйрь «күңел гамьгин» (кайгылы), күзем нәмгин (яшьле) һәмишә (һәрчак), «бу дөньядин качкым килер» кебек пессимистик эчтәлекле юлларны әйтүгә кадәр барып җиткән икән, биредә, әлбәттә, социаль шартлар, суфыйчылык традицияләре белән беррәттән, авторның авыр шәхси язмышы да билгеле бер роль уйнагандыр.

* * *

Ш.Зәки иҗатын идея-тематик яктан күзәтү шуны күрсәтә: шагыйрь күпчелек очракта, үз остазлары Ф.Гаттар, Җ.Руми, Нәкышбәнди, Суфый Аллаяр кебек, сурәтләү предметына дини идеология, суфыйчылык фәлсәфәсе позициясеннән торып якын килә, тормыш күренешләрен, кешенең эш-гамәлләрен, эчке дөньясын Аллага, ягъни абсолют хакыйкатькә (идеалга) мөнәсәбәт призмасы аша яктырта, бәяли. Шуның нәтиҗәсендә аның әсәрләрендә дини-суфыйчыл һәм дөньяви идеяләр, үзара тыгыз үрелеп, үзенчәлекле бер синтез тәшкил итәләр. Аларны бер-берсеннән аеру кыен, хәтта урыны белән мөмкин дә түгел.

Реалистик сәнгатьтә тәрбияләнгән соңгы дәвер укучыларына Ш.Зәки иҗаты белән шул чор тормышы арасындагы бәйләнешне күрү авыр. Чөнки элекке әдәбиятта заман тормышын танып белү, аның ихтыяҗларын канәгатьләндерү, кагыйдә буларак, моңа кадәр билгеле булган темалар кысасында, традицион идея-мотивларга бәйләнештә, еш кына дини төшенчәләр ярдәмендә башкарылган. Шулай ук бу процесс барышында укучы өчен электән таныш образлар да, кинаялелек алымы да иркен файдаланылган.

Урта гасыр әдәбияты өчен хас булган бу үзенчәлек Ш.Зәки иҗатында да ачык күренә. Иллюстрация өчен берничә мисалга мөрәҗәгать итик.

Фарсы телендә язылган парчасында Ш.Зәки болай ди: «Җиһандагы дөреслек — шәйхлар аркасында, әмма аларда ул (ягъни дөреслек) аз һәм сирәк була». Шагыйрь эчтән бозык, тыштан изге булып йөрүче «әһле заһир» суфыйларны, хаҗиларны, мөрид җыеп, кеше алдап көн итүче икейөзле «мөтәшәйх»ләрне кискен тәнкыйть уты астына ала. «...Анларның кыйбласы,— ди ул,— хатыннардан үзгә, һиммәтләре — карын туйдырмакдан үзгә, динләре дәрһәмдән үзгә дүгелдер,— вә анлар ошбу дин юлында хәрамиләрдер».

Билгеле булганча, ялган, икейөзле суфыйларны тәнкыйтьләү Шәрык әдәбиятының күпчелек вәкилләре өчен хас. XVII йөз татар шагыйре Мәүла Колый хикмәтләрендә, мәсәлән, ялган суфый — начар, бозык, ә чын суфый — идеал, үрнәк кеше мөнәсәбәтендә яктыртыла. Икейөзле, кәсепче суфый-ишаннарның XIX йөз татар җирлеге өчен дә чит булмаганлыгын без төрле тарихи һәм әдәби чыганаклар аша яхшы беләбез. Шуңа күрә Ш.Зәкинең ялган суфыйларны фаш иткән парчалары да үз чоры өчен табигый һәм заманча.

Янә бер мисал. Мәгърифәтле, гадел патша (хөкемдар) идеясен пропагандалаган әдипләрдән үзгә буларак, суфыйларның бер өлеше, әйтергә яраса, аларның сул канаты, йә рәсми властьларга оппозициядә тордылар, яисә идарә формасын бөтенләй кире кактылар. Һәммә затларның җаннары (рухлары) бер үк иляһи чыганактан булу сәбәпле, кешеләр үзара тигез итеп каралды; абсолют идеалга, ягъни Аллага буйсыну идеясе генә хупланды. Ш.Зәки иҗатында да патша, власть идеяләре тискәре бәяләнә, еш кына алар бөтенләй инкарь да ителә: Алла буйсынырга лаеклы бердәнбер «падишаһ», «шаһ» рәвешендә карала:

Һәр нә килсә, безгә ул шаһдан килер.

Ходა дәргяһының булсам гәдасы —
Ни хаҗәт ки җәһан халкы — колымдыр?!

Шагыйрьнең, җирдәге властьны кире кагып, абстракт иляһи затны гына «шаһ», «рәһбәр» (юлбашчы, җитәкче) дип тануы халыкның шул дәвердәге милли колониаль сәясәте белән ризасызлыгын, аңа карата протестын да билгеле бер дәрәҗәдә белдереп тора. Бу уңай белән шуны да әйтергә кирәк: Ш.Зәки иҗатында, гомумән, тормыштан канәгатьсезлек, аны гаделсезлектә, золым һәм бозыклыкта гаепләү көчле.

Байның күзе малдан туймаз,
Ачның күзе ашдан туймаз,
Бәнем күзем йәшдән туймаз,—
Дишвар улды бәнем хәлем.

* * *

Күрү — кешегә табигать тарафыннан бирелгән иң зур бүләкләрнең берсе. Күз ярдәмендә кеше тышкы дөнья хакында информация ала, күзаллау һәм фикерләү өчен материал туплый, башкаларны һәм үз-үзен танып белә. Софокл (б. э. к. 496—406 еллар тирәсендә яшәгән грек әдибе) трагедиясенең баш каһарманы Эдип патша, кылган явызлыкларыннан котылу өчен, үз күзләрен үзе чукып чыгара. Шушы уңай белән автор «сукырлык — үлемнән дә авыр җәза» дигән фикер белдерә. Бәлкем, бу сүзләрдә бераз арттыру, әдәбиятка хас гиперболизация бардыр. Чөнки көндәлек тормышта без шактый күр табигатьле сукырларны да очратабыз. Шулай да сукырлыкның кеше өчен гаять зур бәхетсезлек булуын беркем дә, шул исәптән күзсезләр үзләре дә инкарь итә алмас.

Офтальмологлар фикеренчә, сукырлык берничә төрле була: 1) тоташ караңгылык, ягъни яктылыкны бөтенләй күрмәү; 2) шәүләләрне, яктылыкны бераз аеру; 3) предметларны томанлы гына күрү, әмма аларны бер-берсеннән аера алмау һ.б. Истәлекләр Ш.Зәкинең шактый иркен йөри алуын сөйлиләр. Мөгаен, анда сукырлыкның икенче дәрәҗәсе булгандыр. Шунысы факт: ул бу дөньяның гаҗәеп яктылыгын, шәфәкъ балкышын, хатын-кызларның матурлыгын, табигатьнең искиткеч төрлелеген күрә алмаган. Бу, әлбәттә, башка кешеләр өчен бер бәхетсезлек булса, күңелендә шигъри талант ятканнар өчен икеләтә бәхетсезлек. Чөнки күз — шигърият өчен зарури булган күрсәтмә сурәтлелекне тудыруда төп информацион каналларның берсе.

Әдәбият тарихыннан безгә сукыр әдипләрнең булуы, алар иҗат иткән әсәрләрнең дә укучылар тарафыннан укылуы мәгълүм. Димәк, сукыр кеше дә иҗат итә ала. Ә соң бу процесс ничек бара? Әдипнең күрмәве әсәрдә чагыламы; чагылса, ни рәвешле? Образлылыкның күрүгә нигезләнгән өлеше нәрсәләр белән компенсацияләнә (алыштырыла)? Тумыштан ук сукыр әдипләр белән дөньяның яктылыгын һәм төрлелеген күреп, хәтерләренә сеңдереп, гомерләренең билгеле бер баскычында күрү сәләтен югалткан әдипләрнең психологиясендә, әсәрләрендә нинди уртак һәм үзгә яклар бар? Бу төр мөһим сорауларга без фәнни әдәбияттан тиешле җаваплар таба алмадык. Тапкан кадәресе дә тәмам ышандырмый, каршылыклы.

Мәсьәләнең болай торышы Ш.Зәки иҗатын да, сукырлыгына нисбәтән, тиешенчә яктыртырга мөмкинлек бирми. Биредә бары тик теге яки бу дәрәҗәдә хакыйкатькә якын торган аерым күзәтүләр һәм фараз кылулар белән генә чикләнергә туры килә.

Ш.Зәкинең безгә мәгълүм әсәрләрендә күзсезләр өчен генә хас дип әйтерлек саф билгеләр күренми. Әмма шулай да шагыйрь иҗатын сукырлар психологиясе һәм фикерләү рәвеше белән якынайтырлык кайбер катнаш сыйфатларны һәм күренешләрне атап китәргә мөмкин.

Әдип әсәрләрендә кешене, күренеш-әйберләрне тышкы форма һәм төс ягыннан сурәтләү юк дәрәҗәсендә. Булган берничә бөртеге дә гомуми сөйләм теленнән сүзтезмә рәвешендә генә алынган («сач-сакалы акарыб», «сары йөз», «ала карга» һ.б.).

Ш.Зәки кеше өчен күзнең кирәклеген, әһәмиятен яхшы аңлый:

Күз кирәкдер, күз кирәк, и мәрде ан,
Күзлейә гыйбрәт дорыр хале җәһан.

Әмма шулай да ул беренче планга, маңгай күзеннән бигрәк, «күңел күзен» куя. Аның уенча, бары тик күңел күзе генә «гали кәмалгә» (*олуг камиллеккә*) ирешергә, «мәгъна йөзен» күрергә мөмкинлек бирә. Үз иҗатында да шагыйрь сурәтләү объектына, ничектер, «күңел күзе» аша карый, аны эчке сыйфатлары, вазифасы аркылы яктыртырга омтыла. Урыны белән ул биредә тенденциозлык та күрсәтә. Мәсәлән, «нәфес» гел тискәре сыйфатлар аша гына бирелә.

Ишетү — сукыр кешеләр өчен тышкы дөнья белән бәйләнешнең төп каналы. Шуңа күрә аларда тавышны (авазны) тою, интонацион сизгерлек бик көчле була. Ш.Зәки шигырьләрендә дә бу сыйфат үзен нык сиздерә. Аның әсәрләре өчен ритмик нәфислек, музыкаль яңгыраш хас. Автор гарузның төрле үлчәмнәре һәм вариантлары (күбрәк һәзәҗ һәм рәмәл) белән иркен эш итә, интонацион мөмкинлекләр белән образ тудыруның кабатлау, рәдиф, анафора, аллитерация, шигъри янәшәлек (параллельлек), эчке рифма һәм башка төрле чараларыннан еш файдалана. Мәсәлән, аның күпчелек газәлләре рәдиф белән язылган. Арада хәтта берничә сүзле рәдифләр дә очрый:

Нәфес шәрреңдән, Иляһи, әл-әман, әл-әман!
Барчаның сәнсән пәнаһы, әл-әман, әл-әман!

Әдип урыны белән, эмоциональ тәэсирне көчәйтү максатыннан чыгып, шигъри фигураларның берничәсен берьюлы да куллана:

Сән сәне сәндән кидәрмәк вәсгы имкянеңдәдер.
(*Кабатлау, аллитерация, ассонанс*)

Ул кирәкдер, ул кирәкдер, ул кирәк,
Ул йаңа вармага туры юл кирәк.
(*Анафора, кабатлау, көчәйтү, эчке рифма, рәдиф*)

И җиһанның җаны, җанның җаны сән.
Бәхре мәгънә вә сәгадәт кяны сән.
И каму дәрдлеләрең дәрманы сән,
И каму галәмләрең солтаны сән.
(*Аллитерация, рәдиф, анафора, баетылган рифма* һ. б.)

Ш.Зәки — ишетү аша үзенә кадәрге язма әдәби хәзинәне, шигъри стиль һәм формаларны, аеруча Шәрык поэтикасын шактый камил үзләштергән әдип. Әсәрләре — моның дәлиле. Әмма сукыр булу сәбәпле, ул үз әсәрләрен кәгазьдә түгел, ә күңелендә эшкәртергә һәм соңыннан кемгә дә булса әйтергә мәҗбүр булган. Биредә аңа ораторлык сәнгате чаралары ярдәмгә килгән. Шагыйрь сөйләмә тел өчен хас булган эндәш, чакыру, өндәү, сорау, үтенү кебек интонацион чараларга, төрле стиль һәм синтаксик формаларга чагыштырмача еш мөрәҗәгать итә:

Һай, нә ойурсән? — Уян! — Йөз мең хәтәр яныңдадыр,
Күңлеңе гыйшкъ илә дергез, кем, үлем җаныңдадыр.

...Дотар ирсәң, өстеңә рәхмәт йага.
Дотмаз ирсәң, вар йулыңа, кидә күр,
Дот үг(е)тем, сән үзеңе кылма зур.

* * *
Иляһи, пәрдә күтәр күземдән,
Мәгасый карасын йугыл йөземдән.

* * *

Кил бирү сән, кил бирү сән, кил бире,—
Килмәз ирсәң, йөри бир андан ары.
Килдекең үзең өчендер, и ага,
Аның өчен әйдерем боны сәңа.

Катлаулы вакыйга-хәлләрне, уй-кичерешләрне тыңлаучы өчен гадәти, үз булган деталь-күренешләр ярдәмендә аңлату —ораторлар сәнгатендә киң таралган алым. (Язма әдәбиятка да ул шуннан керә.) Ш.Зәки бу алымны бик теләп куллана:

Алчак улыб юл ариның аякын үпмәклеге
Аяк алтындагы өзәңгедән үгрәнмәк кирәк.

* * *

Тонды күңлең көзгесе тогйан, гыйсъйан зәнгилә.

* * *

Җан илә иман — икәүләр — бер өйүдә бал эчәр.

* * *

Бер гаҗәб гөлзар ирер: анда нә гәрм (җылы) ула, нә сәрд (суык),
Мивәсе һәргиз дөкәнмәз, һәм кыш вә кар улмая.

Җаһил вә мәгъбунә гарь улмаз җәһанда хирсы мал,—
Ала карга җенесенә сиркин йемәк гарь улмая.

* * *

Күз, колак һәм лисан (тел), әл-айак,—
Җөмләдин мәсъүл улыр, шөкер илә бак.

Ш.Зәкинең лирик герое еш кына авыр хәленнән зарлана:

Бәгърем башлы, күзем йашле,
Әлем һәм аягым баглы,
Йөрәгемдер бәнем даглы,—
Дишвар улды бәнем халем.

Дөшде гамь гәрдабенә (упкынына) шимди вөҗүдем көймәсе.

Пессимистик эчтәлекле мондый юлларның шагыйрь иҗатында күпләп очравын «лирик герой» төшенчәсенең, «мәламәт» (үз-үзеңне битәрләү, түбәнсетү) алымының үзенчәлеге дип кенә карый алмыйбыз. Аларда теге яки бу дәрәҗәдә әдипнең авыр шәхси язмышы да гәүдәләнгән.

Ш.Зәки, күп кенә әдипләрдән аермалы буларак, сукырлар яшәешенең төп терәкләре булган ишетү, ис сизү, тою әгъзалары, аларның вазифалары хакында махсус шигъри юллар да иҗат итә. Мәсәлән: «... улмая» газәле һ.б.

Ш.Зәкинең суфыйчылык идеяләрен уртаклашуы, аскетизмга теләктәшлеге дә аның сукырлыгы белән каршылыкка керми, киресенчә, алар үзара тагын керешә генә төшәләр.

Шагыйрьнең сукырлыгы һәм иҗат үзенчәлеге... Бу ике төшенчә арасында бәйләнеш бар. Аны югарыдагы күзәтүләр дә күрсәтеп тора. Әлбәттә, әле алар тулы, камил түгел, ә шәхси уйланулар, тәүге эзләнүләр характерында гына. Шуңа күрә аларның бәхәсле булуы табигый.

* * *

Ш.Зәки иҗатында төп урынны газәлләр алып тора. Әдип шигырьләренең 40 проценты диярлек шушы жанрда иҗат ителгән. Мөгаен, шуңа күрәдер автор урыны белән, гомумән, шигырьне дә «газәл» дип таный. Мәсәлән, *аааб вввб*... рәвешендәге бер мөнәҗәтен ул «газәл әйдем», ди. Шунысы мөһим: бередә әдип газәлне күңелне шатландыручы, кайгыны таратучы, гакылга киңлек бирүче чара рәвешендә карый:

Газәлсез күңлем шад улмаз,
Һәргиз гамьдин азад улмаз,
Нәфес гаклә мөнкад улмаз,—
Дишвар улды бәнем халем.

Газәл кальбемне шад әйләр,
Фәрәх юлын әшһад әйләр,

Гакылын һәм абад (төзек) әйләр,—
Дишвар улды бәнем халем.

Шигырьнең рухи тормыштагы ролен болай югары бәяләве белән бу юллар әдәбият тарихы, эстетика өчен дә әһәмияткә лаек.

Ш.Зәкинең классик газәл жанрында иҗат ителгән әсәрләре арасында 4 бәеттән алып 23 бәеткә кадәрле шигырьләр бар. Аларның уртача күләме 12 бәеттән гыйбарәт. Бер шигырьне исәпкә алмаганда, шагыйрьнең башка газәлләрендә тәхәллүс юк. Ике газәл «шаһ бәет»сез, ягъни *аа* рәвешендә рифмалашучы тәүге строфасыз бирелгән. 13 шигырь рәдиф белән язылган. Газәлләр, нигездә, гарузның рәмәл, һәзәҗ үлчәмнәре белән иҗат ителгән. Рәмәлнең дүрт буынлы формасы күпчелекне тәшкил итә. Мәсәлән, «Һай, нә ойурсән?..», «Игре юлларны куйубән...», «Йа Иляһи, бән зәгыйфең...» дип башланган газәлләр «рәмәле мөсәммәне мәхзүф», ягъни «фагиләтен фагиләтен фагиләтен фагиләт» вәзене белән язылганнар. Күрәсез: шагыйрь, гомумән, газәл жанрының тышкы таләпләрен саклый.

Суфыйчылык тәгълиматы нигезендә, мәхәббәт — кеше өчен зарури күренеш. Ни өчен? Чөнки кешенең җаны — абсолют хакыйкатьтән, ягъни Алладан вакытлыча аерылган бер нур, кисәкчә; шуңа күрә ул, нәфесне җиңеп, үз асылы белән кабат кушылырга омтыла. Ш.Зәки газәлләренең дә төп эчтәлеген иляһи мәхәббәткә мөнәсәбәттә лирик геройның рухи халәтен, уй-хисләрен, теләк-омтылышларын гәүдәләндерү тәшкил итә. Шагыйрь чын гашыйкларны «гариф»лар, ягъни «акыл ияләре», «мәгънәгә төшенүчеләр» дип карый һәм аларны үзе өчен үрнәк итеп куя:

Гариф ул, кем гыйшкъ илә дерлек кыйлыр бу дөнйада,—
Гакылны бу дәрдилә хәйран идәр, хәйран идәр.

Арзум улдыр ки, бу галәмдә гарифлар кеби
Атәше гыйшкъ (гыйшыкути) илә кайнатсам йөрәгем
йаг(ы)ны.

Автор фикеренчә, чын гашыйклар өчен бернәрсә дә, шул исәптән «үлем» дә куркыныч түгел.

Шагыйрь, лирик геройның «җанан»ына, ягъни мәхәббәт адресатына мөнәсәбәтен белдерү өчен, еш кына символик образларга мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, «пәрванә» мәхәббәткә җаныңны корбан итү, үз-үзеңне югалту символы буларак кулланыла:

Вәсләте җанан өчен җан сарыф кылмакны мөдам (һәрчак),
Ир исән, пәрванәи хушхойдан үгрәнмәк кирәк.

Гыйшкъ мәгъна шәмгына пәрванә кыйлды үзене.

Ә инде «җам», «мәй», «шәраб», «нәфес»не оныттырып, кешене гашыйклык халәтенә китерүче поэтик детальләр рәвешендә алына.

Ш.Зәки, кагыйдә буларак, иляһи сөю хисләрен мәхәббәт аша, аңа хас чаралар ярдәмендә гәүдәләндерә. Щуңа күрә аның күп кенә юллары еш кына аллегорик планда түгел, ә гадәти мәгънәсендә кабул ителә:

Сәнең гыйшкың белән дивана булдым,
Акыздым канлы яшем бән күземдән.

Зөлф(е) зынҗырына чолгангым килер.

Шагыйрьнең аерым юлларын хәтта символик аспектта аңлатуы да авыр. Мәсәлән, «Эстәсәм галәмдә сәндик йар булгай, булмагай» мисрагындагы «йар» сүзен Алланың символы итеп карыйбыз икән, «булгай, булмагай» сүзләре аның барлыгын шик астына алачак. Шуңа күрә бу парчадагы «йар» сүзен, гадәти укучы кабул иткәнчә, «сөйгән кеше» мәгънәсендә аңларга туры килә. Шулай итеп, суфыйчылык поэзиясе өчен хас булган ике планлылыкның символик, мистик катламы дөньяви эчтәлекне белдерүче поэтик чара, образ дәрәҗәсенә төшерелгән. Шунысы мөһим: алга таба бу тенденция тагын да көчәеп китә. Г.Кандалый, Г.Тукай, М.Гафури һәм башка әдипләрнең иҗатларында, мәсәлән, суфый поэзиясеннән алынган, әмма мистик вазифаларын җуйган сурәтләрне (пәрванә, шәм, гөл, былбыл, мәй һ.б.) күпләп очратырга мөмкин.

Газәлдән тыш Ш.Зәки башка жанрларга да мөрәҗәгать итә. Аның 16 әсәре мәснәви формасында иҗат ителгән. Арада эчке табигате белән мөнәҗәт, тышкы төзелеше (мәсәлән, *аабб*... рәвешендә рифмалашуы) белән мәснәвигә туры килешле парчалар да бар.

Үз элгәреләре кебек, Ш.Зәки дә мәдхия, робагый, кыйтга, хикмәтле сүз, фәрд кебек поэтик жанрлардан да иркен файдалана. Шуның белән бергә, без аның иҗатында язма әдәбиятыбызда чагыштырмача сирәгрәк күзгә ташланучы жанрларны да очратабыз. Мәсәлән, шагыйрьнең 85 юллык дини-суфыйчыл эчтәлектәге

бер гарәпчә әсәре *ааааа, ббббб*... рәвешендә рифмалашучы бишьюллыклардан төзелгән. Шәрык поэтикасында бу төр строфалар белән язылган әсәрләрне «мөхәммәс» дип йөртәләр.

Билгеле булганча, Ш.Зәки дәверенең күп кенә укучылары, татар теленнән тыш, гарәп, фарсы телләрен дә яхшы белгәннәр. Шуны күздә тотып, шагыйрь үзенең кайбер әсәрләрен мөләммәгъ (ягъни шигырьнең бер юлын яисә бәетен бер телдә, икенчесен икенче телдә язу) ысулы белән дә иҗат иткән. Аның иҗат мирасыннан гарәпчә-татарча-фарсыча яисә аларның икесен чиратлаштырып язган шигырьләрне очратырга мөмкин.

Ш.Зәкинең берничә шигъри хаты да («дәгъватнамә», «гарызнамә») бар. Аларда кызыклы сурәтләр, тормышчан детальләр шактый гына. Безнең уебызча, татар әдәбиятында шигъри хат жанрының активлашып китүендә, Г.Кандалыйның мәшһүр әсәрләре белән беррәттән, «татар Мәгаррие»нең дә бу парчалары билгеле бер роль уйнагандыр.

Мәгълүм булганча, Урта гасырның күп кенә әдипләре, аеруча суфый шагыйрьләре, сюжетлары төрле чыганаклардан алынган хикәят жанрын бик яратып кулланганнар. Ш.Зәки исә бу мәсьәләдә бераз аерылыбрак тора. Аның фәнгә мәгълүм иҗат мирасында без бары бер генә хикәят очратабыз. Аллегорик эчтәлекле (балчыкның-сабынның гөлдән хуш ис алуы турында), кечкенә күләмле бу әсәр Сәгъди-Сараи «Гөлестан»нарының керешендәге шигъри хикәятләр белән аваздаш. Әдип әсәрләренең калганнары һәммәсе диярлек лирик жанрда. Аларның үзәгендә — хис-тойгылар, уй-кичерешләр. Бер-берсе белән тыгыз бәйләнешле бу парчалар төрле халәттәге шагыйрь күңеленең поэтик сурәтләре булып торалар.

Алдарак, башка мәсьәләләргә нисбәтән, Ш.Зәкинең поэтикасы хакында инде шактый гына фикерләр әйтелде, күзәтүләр ясалды. Шуңа күрә биредә бу мәсьәләгә махсус тукталу зарури түгел. Бары берничә моментны атап китү белән генә чикләнәбез.

Әгәр дә шагыйрьләрне образлы фикерләү дәрәҗәләреннән чыгып төркемләргә мөмкин булса, Ш.Зәки, һичшиксез, күренекле урыннарның берсен алыр иде. Ул, ничектер, поэтик чаралар белән иркен һәм табигый эш итә, күңелендәге фикер-тойгыларны, теләк-омтылышларны, катлаулы уй-кичерешләрне тәэсирле итеп, үтемле сурәтләр ярдәмендә гәүдәләндерүгә ирешә. Мәсәлән, автор шигырь язуны күз яшен сүз белән агызу («Акыр күзем йәше, аһ, сүземдән»), энҗене җепкә тезү белән тиңли («Бу дөрре бер йибә тезмәк кирәкдер»), авыр хәлне көчле ташкынга эләккән көймә белән чагыштыра («Дөшде гамь гәрдабенә шимди вөҗүдем көймәсе»). Лирик геройның идеал халәтен түбәндәгечә бирә:

Суда йөзмеш каз илә үрдәк кеби,
Мәгърифәт бәхрендә тулгангым килер.

Телебездә хәзер архаиклашып бара торган «тутия» сүзе бар (тутия — күзгә сөртә торган шифалы май төре; купорос). Элеккеге әдәбиятта бу сүз, үзе белдерә торган матдәнең вазифасына мөнәсәбәттә, образ буларак иркен кулланылган.

Ш.Зәки дә ышанычлы, тугрылыклы кешеләрне сыйфатлауда тутия (күз даруы) төшенчәсен сурәт итеп файдалана.

Кани шул әр (ир) кем, күзе ачык, сүзе садыйк дорур,—
Тутия кылсам күземә аягы тупрагыны.

Шагыйрь иҗатында арттыру («Йитмеш өч милләттә улмаз буйлә, би инсаф улан»; «Йөз мең хәтәр яныңдадыр»), сынландыру («ачды фикрем тависы ике канадын ошбу дәм»; «бозды гаклымның хисарын ләшкәри нәфес җохүд», ягъни гаклым крепостен нәфес кабат җимерде), тәҗнис — омонимия («Кани олуг кара күзләр?! — Кыямәт юлыны күзләр»), ялгау («... икътидарым калмады. Калмады һәргиз өмидем...»), антитеза («Гәрчә раһ раушан дорыр, илля сәфәр — вәхшәтледер»), янәшәлек һәм әдәби мирастагы башка төрле чараларны уңышлы куллануның матур гына үрнәкләре бар.

* * *

Ш.Зәки, Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдипләренең күпчелеге кебек үк, гарәп-фарсы сүзләренә һәм формаларына еш мөрәҗәгать итә, хәтта урыны белән татарча шигырьләренең аерым гыйбарәләрен һәм юлларын да шул телләрдә «язып» китә, кайчак татар сүзләренә фарсы кушымчалары да ялгап җибәрә. Мәсәлән:

Гөл илә бер заман ултырмышым бән,
Әсәр вирде бәңа гөл кухусындан,
Вәилля туфрагам бән та әзәлдән.

Биредә гарәп-фарсыдан кергән сүзләр (кухусындан, вәилля, та әзәлдән һ.б. ) генә түгел, кушымча да бар. Шагыйрь символик сурәт булган «туфрак»ка игътибарны көчәйтү өчен һәм интонацион яңгырашны күздә тотып, беренче зат алмашлыгын бер үк урында ике мәртәбә куллана. Аның берсе — фарсыча (-ам), икенчесе — татарча (бән).

Ш.Зәки әсәрләрендәге төп лингвистик күренешләр һәм закончалыклар хәзерге әдәби һәм сөйләмә телебез өчен дә хас.

Әдәбият үсешендә мөһим бер күренеш булган Ш.Зәки иҗаты, әлбәттә, үзеннән соңгы әдипләргә билгеле бер дәрәҗәдә йогынты ясады. Акмулла үз остазының фикри тирәнлеген, афористик стилен дәвам иттерде. «Син бөек!» Салган Ходай күктән синә үз орлыгын! Бул гали! Таптатма, зинһар, шул «Ходайлык» зурлыгын!» — дип, Н.Думави Ш.Зәкидәге фәлсәфәне «Син — кеше» һәм кайбер башка шигырьләренең төп мотивына әверелдерә. Дәрдемәнд, С.Рәмиев иҗатларында да Ш.Зәкигә аваздаш яклар бар. Мәсәлән, Дәрдемәнд, үз якташы кебек үк, ике планлылык алымыннан, образ-символлардан иркен файдалана, дөнья агышы хакында фәлсәфи фикерләрен белдерә. С.Рәмиев, Ш.Зәки шикелле, «мин»нең уй-тойгылар диалектикасын мөмкин кадәр тулырак, калкурак бирергә омтыла. Г.Сәгъди фикеренчә, татар әдәбиятында символизмның агым буларак формалашуында да Ш.Зәкинең тәэсире бар (Символизм турында.— М., 1932.— 93 б.). Мәгълүм булганча, Г.Тукай — үзенә кадәрге әдәби казанышларны аеруча мул һәм нәтиҗәле кулланган әдип. Аның Ш.Зәкине «шагыйрьләребезнең тәсбих тезмәсенең «Мәрьям анасы» дип атавы бу казанышлар арасында «татар Мәгаррие»нең дә мөхтәрәм урын биләвен ачык күрсәтә.

Ш.Зәки, үз халкының укучыларыннан тыш, билгеле бер дәрәҗәдә башкорт, үзбәк һәм кайбер башка төрки халыкларның вәкилләренә дә таныш. «Аның (Ш.Зәкинең),— ди үзбәк әдәбиятчысы, Ташкент университеты галиме Бегали Касыймов безгә язган шәхси хатында (18.10.1977),— кайбер шигырьләре безнең халык арасында да таралган. Мәсәлән:

Ат сәнең астыңдадыр, йөргел бу йирнең хәдден ал,
Нагяһан ул ат сәнең астыңда булгай, булмагай һ. б.».

*1982*

## «КҮҢЕЛНЕ САФЛАМАК ДӘВАДЫР»

### 1. Милли каһарманыбыз

(*Ризаэддин Фәхреддиннең тууына 140 ел тулу уңае белән*)

Борынгы һәм Урта гасыр, XIX йөз татар сүз сәнгатендә камил инсак проблемасы — иң төп мәсьәләләрнең берсе. Соңгы меңьеллыкта иҗат иткән һәр әдип кешене камилләштерү, аны тәрбияле, күркәм итү турында хыялланган. Әдәбияттагы «камил инсан» төшенчәсе, иң беренче чиратта, укымышлы, һөнәрле, әхлаклы, иманлы зат рәвешендә күзаллана. Әгәр дә миннән: «Андый кеше тормышта бармы?» — дип сорасалар, мин, һич икеләнмичә: «Бар, аның җанлы үрнәге — Ризаэддин Фәхреддин (1859—1936)!» — дип җавап бирер идем. Мин бу олуг, могтәбәр затта, ничектер, әдипләр күрергә теләгән идеал, ягъни камил инсанның калку гәүдәләнешен күрәм.

Разаэддин Фәхреддин Рим, Петербург, Казан кебек мәшһүр калаларда тумаган, Сорбонна, Истанбул, Каһирә университетларында белем дә алмаган. Аның туган җире — Әлмәт төбәгенең гап-гади Кичүчат авылы, укыган урыны — гадәти татар мәдрәсәсе. Эшләгән җире — авыл мәктәбе, Оренбург, Уфа шәһәрләрендәге редакцияләр, дини оешмалар. Әмма шуңа да карамастан ул үзенең тырышлыгы, максатчанлыгы белән Идел-йортта гына түгел, ә бөтен төрки, мөселман дөньясында, шәрыкшенаслык (ориенталистика) фәнендә иң укымышлы кешеләрнең берсенә әверелә. Тыйнаклыгы, итагатьлелеге, фикер-карашларының ачыклыгы белән замандашларын сокландырган.

Ризаэддин Фәхреддин (аны еш кына Ризаэддин Хәзрәт, Ризаэддин Казый дип тә йөртәләр) — әдип, дин әһеле, тарихчы, педагог, текстолог, журналист, библиограф, әдәбиятчы һ.б. Ул — фән һәм мәдәниятнең, рухи эшчәнлекнең төрле тармакларында, үзенең саллы һәм төпле сүзен әйтеп, тирән эз калдырган шәхес. Мәгълүм булганча, 1908—1918 елларда Оренбургта Ризаэддин Фәхреддин редакторлыгында «Шура» журналы чыккан. Андагы материалларның күпчелеген баш мөхәррир үзе язган. Журнал — үзенең энциклопедик табигате, бай эчтәлеге белән фән һәм мәдәният дөньясында тиңсез, рәсми тел белән әйткәндә, уникаль күренеш. Аны төрки галимнәре генә түгел, рус, таҗик, әфган, Европа авторлары да ышанычлы чыганак рәвешендә файдаланалар. Әгәрдә Р.Фәхреддин башка тармакта бернәрсә эшләмәгән булса да, «Шура» журналы белән генә дә ул тарихка кереп калыр иде. Ә бит аның күптомлык библиографик «Асар»е, төрки-татарлар хакындагы тарих китаплары, мәшһүр затлар турында тирән эчтәлекле монографияләре, мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек рәвешендә кулланылган дини-әхлакый әсбаплары һ.б.— боларның һәрберсе кешене бөек, дәрәҗәле итәрлек.

Р.Фәхреддин,— барыннан да элек, язучы, әдип. Ул, иң беренче чиратта, үзенең «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1898) һәм «Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903) романнары белән билгеле. Һәр ике әсәр дә инсани, милли рух, тәрәкъкыяткә омтылыш идеясе белән сугарылган. Алар — сәнгати язма гына түгел, ә авторның кеше, тормыш, тарих, милләт турындагы уйлануларының бер синтезы да. Р.Фәхреддин үз халкын белемле, тәрбияле, һөнәрле итәргә, аны алдынгы кавемнәр белән бер сафта күрергә тели. Милли һәм инсани тәрәкъкыятьтә ул хатын-кызларга зур өмет баглый.

Урта гасырның мәшһүр әдипләре Йосыф Баласагунлы, Мәхмүд Болгари традицияләрен дәвам итеп, Р.Фәхреддин дә хәмер эчүне кискен гаепли. Аның фикеренчә, «...исерткеч эчмәк — агу эчмәк кадәр зәһәрле вә һәртөрле хәстәлекләрнең баш сәбәбе...». Автор гасырлар буе тормышта сыналган, әдәбиятта гәүдәләндерелгән «ни чәчсәң — шуны урырсың» әхлакый принцибын үз әсәрләренең нигезенә сала. Кешеләргә начарлык кылган Зәйнүш абыстай, еллар узу белән, авыр хәлдә кала. Бу уңай белән «Әсма...» романында мондый юллар китерелә: «Нәкадәр орлык сачмыш исә, җөмләсене үзе урды вә кешегә хәзерләмеш чокырларга кәндесе (үзе) төшеп, олуг бәдбәхетлеккә калды...» Автор тәрбияви процесста әдәбиятның, музыканың гаять мөһим роль уйнавына басым ясый. «Әдәбият илә иштигаль (мавыгу),— ди ул,— күңелне сафламак вә нәфсене тәрбия итмәк бабында иң әсәрле улган дәвадыр».

Р.Фәхреддиннең дидактик рухлы бу романнары гыйбрәтле вакыйга-хәлләргә, кызыклы сурәтләргә шактый бай. Мөгаллимәнең ятим балаларга «ачык йөз вә ләззәтле сүзләр илә биргән» нәсыйхәтләренең тәэсирен автор Наполеон гаскәреннән дә көчлерәк дип бәяли. Язучы фикеренчә, мәхәббәт — «башка бер дөньядыр!.. Иң саф күңелле вә иң гүзәл холыклы затларны,— ди ул,— мәхәббәт әһелләре арасыннан эзләгел!»

Ризаэддин Хәзрәтнең әдәби, гыйльми, педагогик китаплары өчен фикри тирәнлек, инсани итагатьлелек хас. Ул үз халкының үткәнен, бүгенгесен үзара тыгыз бәйләп, кешенең иминлеге, бәхете өчен тирәнтен борчылып, уйланып яза. Татар дөньясында тарихны, әдәбиятны, динне һәм гомумән рухи казанышларны Р.Фәхреддин кебек ныклап тоеп, белеп язучылар, мөгаен, бик сирәктер. Ул татар яшәешен тарихи контекстта, төрле бәйләнешләрдә карый. Галим ислам диненең, Шәрык рухи казанышларының татар

язмышында мөһим роль уйнавын аңлап, мөселман дөньясының олуг затлары Ибне Сина, Әл-Мәгарри, Әл-Газали, Сәгъди, Хафиз, Ибне Гарәбшаһ, Нәваи һ. б. хакында тирән эчтәлекле махсус мәкалә-китаплар яза, аларның әсәрләрен, фикерләрен үз укучыларына җиткерү юнәлешендә мөһим эшләр башкара.

Ризаэддин Хәзрәт хезмәтләренең кыйммәтен, мәгънәви асылын һәм иҗтимагый, милли әһәмиятен аның замандашлары ук яхшы аңлыйлар...

Халкыбызның мәшһүр улы Гаяз Исхакый 1928—1939 елларда Берлинда «Яңа милли юл» исемле журнал чыгара. Үзенең идея-тематик байлыгы белән «Шура»ны хәтерләткән бу журналның 1936 елгы 7—8 кушма саны Ризаэддин Фәхреддингә багышланган. «Мөфти Ризаэддин Хәзрәт» исемле мәкаләсендә Г.Исхакый бу затның олуг шәхес, бөек милләтпәрвәр, милли каһарман булуына басым ясый. «Мәрхүм Ризаэддин Хәзрәт,— ди Г.Исхакый,— безнең Идел буе төркиенең фикри хәрәкәтене, бер тарафдан, Курсавилар, Мәрҗаниләр, Габделкаюм Насыйрилар берлә, икенче яктан, Идел-Урал истикъляды (бәйсезлеге) агымы берлә баглаучы бер тарихи шәхсыятьдер. Аның кыйммәте безнең үткәнләремезне белер өчен генә түгел, киләчәгемездәге барачак юлымызны, кыйбламызны тәгъйин итәр (ачыклар) өчен дә бик зурдыр». Г.Исхакый фикеренчә, Ризаэддин Хәзрәт — азатлык өчен көрәшнең рухи, мәдәни нигезен коручы, милли барлыгыбызны саклаучы. «Аның калдырган мәгънәви азыклары киләчәк гаскәремезнең мәгънәви ачлык вә сусавыны кандырыр (басар) өчен биргән коралларыдыр... Безнең милли тормышымызны коруда бик зур хезмәт иткән Исмәгыйль бәк Гаспралы, Йосыф Акчура, Каюм Насыйри кеби безнең милли йортымызны корышучы, төзешүче милли мөһәндисемездер (инженерыбыздыр)». Ул «бу дәрәҗәгә... үз тырышлыгы, үз казынуы берлә генә ирешкәндер. Үз-үзен идарә итә белүе берлә генә дөньяның җилле-давыллы җирләрендә, кызыл руслыкның иксез-чиксез вәхши золым-җәбере алдында башын югары тота алып, соңгы сулышына кадәр үзенең иман иткән милли сафы башында калгандыр. Бу мәдәни җәсарәте (батырлыгы, кыюлыгы) берлә чит халыкларны хәйрәткә (гаҗәпкә) калдырып, безнең Идел-Урал төрегенең мәгънәви кыйммәтен тагын (да) күтәргәндер... милли вазифасыны тулы көенчә үтәгән милли каһарманымыз булып Алланың рәхмәтенә кавышкандыр».

Г.Исхакый сүзләренә өстәп шунысын да әйтик: вөҗданлылыкның өлгесе булган Ризаэддин Хәзрәт халыкка хезмәт итүнең игелекле юлында гаять кыенлыкларга да тап булды. Аны һәм патша, һәм совет чоры рәсми хакимиятләренең эзәрлекләве билгеле. 1920 елда ул, мәсәлән, бераз вакыт Уфа төрмәсендә утырып та чыга. Ризаэддин Хәзрәтнең академик А.Н.Самойловичка 1935 елның 5 февралендә язган хатында менә нинди юллар бар: «1933—1934 елларда ризык тугрысына авыр хәлләр үткәрдек. Чәй урынына кайнаган су эчеп тору, бал вә шикәр, сөт вә май, ит шулпасы кебек нигъмәтләрне авыз итми дә көн үткәрү мөмкин булса да, икмәк ашамый тору мөмкин булмады. Хокуксыз булганлыгыбыздан, азык сатыла торган кибетләрнең ишекләре безнең өчен ябык булды. Шул сәбәптән табыш алып сатучылар кулыннан икмәк вә арыш оны кебек ризыкларны кыйммәт хаклар белән алырга мәҗбүр булдык. Аның өстенә 1934 елның февралендә көчебез җитмәслек дәрәҗәдә өстебезгә налог төште...» Хат «һәр сәгатьтә үлем көтеп торам» дигән сүзләр белән тәгәлләнә. Тагын бер мәртәбә уйланыгыз: моны бит гадәти кеше түгел, ә дөньякүләм мәшһүр галим, күренекле әдип, Рәсәй мөселманнарының мөфтие, татарның йөз аклыгы булган 76 яшьлек аксакал яза. Никадәр фаҗига, никадәр хаксызлык!

Ризаэддин Хәзрәт — төрки, мөселман дөньясында да абруйлы, билгеле зат. Миңа Ташкент, Дүшәнбе, Анкара, Истанбул, Баку, Алма-Ата кебек мәдәни үзәкләрдә булырга, андагы зыялылар белән очрашырга, сөйләшергә туры килде. Шәрык галимнәре Ризаэддин Фәхреддинне яхшы беләләр, аңа таяналар, аның бөек шәхес булуын икърар итәләр.

1925 елда Ленинградта Россия Фәннәр академиясенең 200 еллык юбилее була. Анда И.Крачковский, А.Самойлович кебек мәшһүр шәрыкшенаслар чакыруы белән Ризаэддин Хәзрәт тә катнаша. Бирегә Төркиядән атаклы галим Фуат Күпрелезадә дә килә. Татар һәм төрекнең ике бөек углы очрашып гәпләшәләр. Ф.Күпрелезадә, Төркиядәге аркадашларына Р.Фәхреддинов хакында исе китеп, хөрмәт белән сөйли. «Сәлимә...», «Әсма...» романнарының авторы — Ф.Кәрими, Г.Исхакый, Г.Тукай, М.Гафури һәм кайбер башка каләм әһелләренең рухи остазы да. Аның фикер-карашлары күпләгән әсәрләр, китаплар тууда нигез, кыйбла булып та хезмәт итте.

Р.Фәхреддиннең рухи мирасын, эшчәнлеген өйрәнү, халыкка җиткерү юнәлешендә галимнәр сизелерлек эш башкардылар. Әдип иҗаты мәктәпләрдә, уку йортларында өйрәнелә башлады. Соңгы вакытта гына да мөһим басмалар дөнья күрде. «Болгар вә Казан төрекләре» (Казан, 1993.— 287 б.— Әзерләүчесе Әнвәр Хәйри), «Алтын Урда ханнары» (Казан, 1996.— 126 б.— Татар һәм рус телләрендә.— Әзерләүчесе Равил Әмирхан), «Казан ханнары» (Казан, 1995.— 19 б.— Әзерләүчесе Равил Әмирхан) һ.б әнә шундыйлардан. Оренбургта яшәүче милләтпәрвәр галимәбез Мәдинә апа Рәхимкулова озак еллар буе Р.Фәхреддиннең тормышын һәм мирасын фидакарьләрчә өйрәнеп килә. Ул инде берничә китап та нәшер итте. Әле менә 1998 елда галимәнең Ризаэддин Хәзрәтнең тууына 140 ел тулуга багышланган махсус

җыентыгы дөнья күрде (Оренбург: Пресса.— 250 б.). Китап төрле мәкаләләрне, хатлар, истәлекләр, кызыклы иллюстратив материалларны үз эченә ала. Анда Р.Фәхреддингә мөнәсәбәтле 202 мәкалә-хезмәтнең исемлеге урнаштырылган. Шулай ук җыентыкта галимнең «Шура»да басылган 312 мәкаләсенең библиографиясе дә бар. Аерым материаллар русча да бирелгән. Кызганычка каршы, гаҗәеп кызыклы һәм бай эчтәлекле бу китапның тиражы гына бик аз: бары — 300 данә.

Р.Фәхреддиннең кече Ватаны — Әлмәт төбәгендә дә соңгы елларда игелекле эшләр башкарыла. Кичүчатта музей оештырылды. Әлмәт шәһәрендәге татар гимназиясенә, Ислам институтына, каланың бер урамына Р.Фәхреддин исеме бирелгән. Алга таба да игелекле гамәлләр кылу планлаштырыла.

Әмма әле Ризаэддин Фәхреддин мирасын өйрәнүдә, халыкка җиткерүдә башкарылган эшләргә караганда башкарыласылары бермә-бер күбрәк. Бөтен язганнарын, аеруча кульязма материалларын туплап, гыйльми аңлатмалар белән тәэмин итеп, күптомлыклар рәвешендә чыгару олуг бурыч булып тора. Галимнең фәнни-популяр биографиясен язу, альбомнар төзү дә көн тәртибендә. Иң мөһиме — Р.Фәхреддин язганнарны укучыларга җиткерү, алар рухында халыкны тәрбияләү. Галимнең китапларында әби-бабаларыбызның яшәеш тәҗрибәсе, милли байлыгы гәүдәләнеш тапкан. Аларны үзләштерү рухыбызны баетуга, хәтер дәвамчанлыгын тәэмин итүгә, милли үсешебезгә ярдәм итәчәк.

«Милләт,— ди Ризаэддин Фәхреддин,— никадәр хурлыкка төшсә дә вә никадәр зәгыйфь булса да, ...аны кимсетү, санга сукмау, инде бу кеше булмас, дип хөкем йөртү ярамый». Бөек остазыбызның бу киңәшен без һәрвакыт күңелебездә тотарга бурычлы.

Безнең халыкта гадәттә олы гәүдәле, физик яктан таза, көчле кешеләрне каһарман дип атау бар. Ризаэддин Хәзрәт,— гәрчә ул кечкенә гәүдәле, ябык кеше булса да, рухы, кылган эш-гамәлләре белән каһарман. Шуңа күрә без дә аны, Г.Исхакыйга кушылып, милли каһарманыбыз дип атыйбыз.

*1999*

### 2. Буй җитмәс шәхес

(*Ризаэддин Фәхреддин турында уйланулар*)

Тарихта, кешелек хәтерендә тирән эз калдырган шәхесләрнең күпчелеге күптармаклы, энциклопедик эшчәнлек иясе була. Ибне Сина һәм Ломоносов, Нәваи һәм Гёте, Утыз Имәни һәм Исхакый — әнә шундыйлардан. Еш кына инсанның үзен кечкенә бер дөнья — микрокосм рәвешендә күзаллыйлар. Мөгаен, шуңадыр гыйльми, иҗади хезмәт белән шөгыльләнүче адәм балалары үзләренең эчке мөмкинлекләрен, рухи халәтләрен, чынбарлык белән мөнәсәбәтләрен төрле шәкелләрдә, төрле чаралар ярдәмендә гәүдәләндерәләр. Шәхеснең, ягъни микрокосмның башкалар өчен ничек, ни рәвешле һәм ни дәрәҗәдә ачылуы, әлбәттә, инсанның потенциаль энергиясенә, рухи халәтенә һәм, иң мөһиме, иҗтимагый шартларга бәйле. Ризаэддин Фәхреддин исә — бу яктан гаять бәхетле зат, феноменаль күренеш. Ул Ходай Тәгалә тарафыннан үзенә бирелгән табигый мөмкинлекләрне, сәләтне тулысынча диярлек ача алган, аларны шәхси мәнфәгатьләренә түгел, ә гавам, милләт ихтыяҗларына хезмәт иттергән.

Р.Фәхреддин эшчәнлеге шундый киң ки, аны хәтта колачлау, төп тармакларын, хезмәтләрен атап, санап китү дә гаять кыен. Ул — әдип, рухани, тарихчы, философ, журналист, казый, мөфти, әдәбиятчы, шәрыкшенас (ягъни ориенталист), тюрколог, библиограф, педагог, җәмәгать эшлеклесе, архивчы, археограф, тәрҗемәче һ.б. Бу мөхтәрәм зат ул тармакларның һәммәсендә диярлек үзенең саллы сүзен әйткән, якты эзен калдырган. Аның энциклопедик эшчәнлеген, олуг мирасын күз алдына китергәч, кайвакыт: «Ничек моны бер кеше башкара алды икән?!» — дип аптырап та куясың.

Р.Фәхреддиннең фән һәм мәдәният өлкәсендә шундый югарылыкка ирешүендә, күп хезмәтләр тудыруында, аның шәхси хосусиятләреннән тыш, чор һәм җирлек, иҗтимагый шартлар һәм милли ихтыяҗлар да мөһим роль уйнаган.

Ризаэддин Фәхреддин үз дәвере өчен укымышлы гаиләдән. Дингә, китапка хөрмәт аңа кечкенәдән үк сеңә. Озак еллар буе ул берничә мәдрәсәдә белем ала. Төрле урыннарда эшли. Оренбург, Уфа кебек мәдәни үзәкләрдә яшәү аның күңел офыкларын киңәйтә. Бу мөхтәрәм инсан И.Гаспралы, Дәрдемәнд, Г.Исхакый, Ф.Кәрими, Һ.Атласи, В.Бартольд, А.Самойлович, Ю.Крачковский, Ф.Күприлезадә һәм башка билгеле шәхесләр белән аралаша.

Р.Фәхреддин татар гаиләсендә, татар җирлегендә туып үсә, аның тормышын, моң-зарларын, рухи ихтыяҗларын тирәнтен тоеп яши. Төрки халыклар белән дә аралаша.

XIX йөзнең икенче яртысы — XX йөз башы, ягъни бу энциклопедик шәхеснең формалашу, җитлегү еллары — дөнья, Россия тарихының катлаулы, каршылыклы дәвере: капитализм ныклап үсә, илләр, халыклар арасында аралашулар көчәя, фән, техника алга китә, иҗтимагый-социаль, сәяси мөнәсәбәтләр

кискенләшә, милли, дини хокуклар өчен көрәш шактый җанлана, халыкларның үзаңы күтәрелә. Бу чорда Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, И.Гаспралы, Х.Фәезханов эшчәнлекләре татар тарихи, иҗтимагый һәм мәдәни фикеренең үсешенә көчле йогынты ясый. Шәрыкшенаслык, тюркология фәннәре зур үсеш ала һ.б.

Урта Азия халыкларының Россия империясе составына кертелүе дә татар тормышына билгеле бер йогынты ясый. Кыскасы, XIX йөзнең икенче яртысына — XX гасыр башына мөнәсәбәтле бу төр факторларның һәм вакыйга-күренешләрнең Р.Фәхреддин эшчәнлегенә теге яки бу дәрәҗәдә тәэсир итүе бәхәссез.

Бөек мәгърифәтче һәм галим, ул кайсы гына тармакта иҗат итмәсен, инсан мәнфәгатен, милләт язмышын һәм ихтыяҗларын үзәккә куя, гаделлек, әхлаклылык өчен көрәшә. Бу сыйфат аның бөтен язганнарына, кылган эш-гамәлләренә эчке бөтенлек бирә, якты нур бөрки. Гомумән, Р.Фәхреддин хезмәтләрен фән тармаклары буенча аеру да кыен. Чөнки алар еш кына үзара керешеп китә, синкретик төсмер ала. Мәгълүм ки, ул ун ел буе «Шура» журналының баш мөхәррире була. Ә бит Р.Фәхреддин бередә без күзаллаган журналистлык вазифаларын үтәү белән генә чикләнми. Бу басма татар рухи тормышының мөнбәренә, чорның елъязмасына, мәдәни һәм гыйльми тикшеренүләрнең тулы бер тупламына әверелә. «Шура» битләрендә әдәби, тарихи, дини, фәлсәфи, этнографик мәсьәләләр дә, үткән һәм бүгенге дә, дөнья халыкларының тормышы һәм башка бик күп темалар, проблемалар гәүдәләнеш тапкан. Журналдагы материалларның күпчелеге (300 дән артык күләмле мәкалә!) баш мөхәррирнең үзе тарафыннан язылган. Аларга гыйльми тирәнлек, факт-мәгълүматларга байлык хас. «Шура» журналы минем күзаллавымда, ничектер, махсус гыйльми тикшеренү институты эшчәнлеген хәтерләтә.

Р.Фәхреддин,— чордашлары М.Акъегетзадә, З.Бигиев традицияләрен дәвам итеп, татар әдәбиятында реалистик принципларны ныгытуга үзеннән зур өлеш керткән әдип. Аның «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1898) һәм «Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903) романнары татар рухи тормышында вакыйга рәвешендә кабул ителә. Алар Г.Исхакый, Г.Тукай һәм Ф.Әмирхан кебек таләпчән әдипләр тарафыннан да уңай бәяләнә. Шунысы кызыклы: Р.Фәхреддиннең романнары — гадәти әдәби әсәрләр генә түгел, ә тарихи, публицистик, педагогик башлангычларны үз эченә алган үзенчәлекле язмалар да.

Соңгы дәвернең аерым галимнәре әдәби әсәрдә үгет-нәсыйхәт бирелүне тәнкыйтьлиләр, киңәштеләкләрнең турыдан-туры түгел, ә әдәби сурәтләр һәм күренешләр аша җиткерелергә тиешлеген хуплыйлар. Әмма мондый эстетик таләп өлешчә генә дөрес, һәм ул, нигездә, реалистик әдәбиятка карый. Мәгълүм булганча, Урта гасыр Шәрык, шул исәптән татар әдәбиятының күп кенә классик ядкярләрендә авторлар үгет-нәсыйхәткә зур урын бирәләр. «Сәлимә…» һәм «Әсма...» романнарының авторы да үз элгәреләренең дидактик традицияләрен дәвам иттерә һәм моның белән бары ота гына.

Р.Фәхреддин — чын мәгънәсендә тикшеренүче, әйтергә яраса, фәндә ничек эшләргә кирәклекнең идеалы, күркәм бер өлгесе. Остазы Ш.Мәрҗани кебек, ул да факт-мәгълүматларны туплауга, чыганакларны ачыклауга гаять зур игътибар бирә. Аның гарәп, фарсы, татар, госманлы, үзбәк, рус һәм башка телләрдәге күп санлы китапларны, кульъязмаларны җентекләп өйрәнүе мәгълүм. Галим төрле архивларда була, Дини нәзарә архивын тәртипкә китерә. Аның тырышлыгы ярдәмендә төрле урыннардан, хосусый китапханәләрдән гаҗәеп күп санлы язма материаллар туплана. Р.Фәхреддин аларның күпчелеген, тәнкыйди иләктән уздырып, үзе үк бастырып та чыгара. Аның мәкалә-хезмәтләрендә, күптомлык библиографик «Асар»ендә тәүге мәртәбә гыйльми әйләнешкә кертелгән материаллар гаять күп. Мәсәлән, Р.Фәхреддин XIX йөзнең мәшһүр шагыйре Шәмседдин Зәкинең тәрҗемәи хәлен, шигырьләрен укучыларга тәкъдим итә. Шунысы мөһим: ул үз үрнәге, үзенең инсани мөгамәләсе белән кешеләрне хезмәткә рухландыра белә, рухи мирасны өйрәнүгә дәрт, теләк уята. Мәсәлән, Көньяк Уралдагы Зәк-Ишмәт авылы имамы Зиннәтулла Мөхәммәдрәхими, Р.Фәхреддиннән үрнәк алып, үзенең авылдашы Ш.Зәки хакында махсус монография яза, аның шигырьләр мәҗмугасын төзи. Ислам дөньясының билгеле заты Муса Бигиев (Муса Җарулла) үзенең «Кавагыйде фикъһия» («Шәригать кануннары».— Казан: «Үрнәк» матбагасы, елы күрсәтелмәгән.— 232 б.) китабын «остазы мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләренең иршады (җитәкчелеге), нәзарәте (күзәтүе) һәм замане (җаваплылыгы) тәхтендә (астында)» бастыра. Бу төр мисалларны күпләп китерергә мөмкин.

Теләсә нинди факт-мәгълүмат фәнни тикшеренүләр өчен әһәмиятле. Бу хакыйкатьне Р.Фәхреддин дә тирәнтен аңлый. Әмма ул аларны теләсә ничек түгел, ә үзара системада, чагыштырма, тәнкыйди планда файдаланырга омтыла. Шуның нәтиҗәсендә галим язмаларының ышандыру көче арта, мантыйклыгы күңелеңне һәм зиһенеңне биләп ала. Ләкин ул кирәгеннән артык объективлыкка да бирелеп китми. Тиешле урында шәхси мөнәсәбәтен, үзенең хосусый уй-кичерешләрен, шик-шөбһәләрен дә белдереп куя.

Р.Фәхреддин, аерым шәхесләр турында язганда, аларны иҗтимагый, тарихи, мәдәни бәйләнешләрдә карый. Үзенең гыйльми-тикшеренү ысулы, методологиясе хакында ул үзе дә берничә мәртәбә искәртә.

Чыннан да, галимнең хезмәтләре шәхеснең рухын, эшчәнлегенең асылын, әһәмиятен тулырак һәм тирәнрәк аңлауга ярдәм итәрлек күп төрле факт-мәгълүматларга, күзәтү-белешмәләргә гаять бай.

Р.Фәхреддин, гомумән, күренекле затлар хакында язарга ярата. Алар арасында дөньяның Атилла, Бируни, Гёте, Мәрҗани һәм башка мәшһүр вәкилләре бар. Бу юкка гына түгел. Галимнең бу төр затларга мөрәҗәгать итүендә тирән фәлсәфи мәгънә ята. Аның фикеренчә, иҗтимагый процесста, тарихта талантлы шәхесләрнең роле гаять зур. Аларның тормышын, эшчәнлеген өйрәнү җәмгыятьне, инсанны тирәнрәк аңларга, тарихтан сабак һәм гыйбрәт алырга ярдәм итә. Шунысы үзенчәлекле: Р.Фәхреддин бигрәк тә каршылыклы затларга игътибар итә. Мәсәлән, ислам дөньясының Әл-Газали, Ибне Гарәби кебек акыл ияләре, әдипләре үз дәверләрендә дә, хәзерге чорда да төрлечә кабул ителәләр, төрлечә бәяләнәләр. Берәүләр аларны күкләргә күтәреп мактый, икенчеләре кискен тәнкыйтьли. Р.Фәхреддин исә бу затларның тарихта тирән эз калдырган олуг шәхесләр булуын таный, аларның тормышларын һәм эшчәнлекләрен мөмкин кадәр тулылыкта, чынбарлыкка тапкыр килешле каршылыкларда бирергә омтыла. Галим карашынча, «дөньяның бөтен маһияте (ягъни үзлеге, сыйфатлары) даими хәрәкәттән гыйбарәт». Дөнья белән бергә кеше дә, карашлар да үзгәреп тора. Фәндә бу төр диалектик фикерләү Р.Фәхреддин карашларына җанлылык, табигый төсмер бирә.

Бөек мәгърифәтче эшчәнлегенең мөһим бер өлешен мөселман диненә кагылышлы язмалар алып тора. Алар өчен итагатьлелек, кешеләрнең инануларына игътибарлылык, дини тәгълимат белән инсанны үзара тыгыз бәйләнештә карау, әхлаклылык хас. Р.Фәхреддиннең гарәп телен камил белүе «Шәрык латины»ндагы чыганаклар белән иркен эш итәргә мөмкинлек тудырган. Аның Коръәнне, хәдисләрне, изге китапка шәрехләрне, ислам фәлсәфәсен яхшы үзләштергәнлеге мәгълүм. Билгеле булганча, XX йөз башында Коръәнне татарчага тәрҗемә итү хакында матбугатта көчле бәхәсләр булып ала. Бу сөйләшүгә Тукай да катнашып китә. «Әгәр,— ди ул,—Русиядә Коръән тәрҗемә ителергә кирәк булса, мөтәрҗимлеккә (тәрҗемәчелеккә) иң муафыйк кеше — Риза Казый. Чөнки ул «Әсма...», «Сәлимә...» кебек китаплары белән куәи тәхририя (язу көче) вә хәтта шигъриясен күрсәткән вә гомумән ифадәсе ачык, язу тарызы (өслүбе) садә вә гүзәл бер язучыдыр. Әллә аның гарәбияте (гарәпчәне белүе) Мусадан кимме?» (*Тукай Г.* Әсәрләр: Дүрт томда. 4 т.— Казан, 1977.— 324 б.) Игътибар итегез: Муса Бигиев — Шәрык мәркәзләрендә махсус югары белем алган, гарәп телен, әдәбиятын, фәнен камил белгән зат. Тукай Р.Фәхреддинне аннан ким санамый. Әйткәнебезчә, М.Бигиев бу олуг инсанны үзенең остазы дип йөртә.

1998 елда Шәрык белгече Җ.Зәйнуллинның «XVIII йөз — XX йөз башында татар рухани әдәбияты» исемле монографиясе басылып чыкты. Анда башка китаплар, чыганаклар белән бергә, Р.Фәхреддиннең хезмәтләре дә карала. Шунысы әһәмиятле: Риза Казый мөселман диненә мөнәсәбәтле китаплар белән җентекләп танышып барган икән. Аның ислам дөньясындагы бу төр хезмәтләргә бәяләренең ачыклыгы, аналитик-тәнкыйди мөнәсәбәте игътибарны җәлеп итә. Р.Фәхреддиннең үзе язган, төзегән дини китаплары, шәрехләре фикри төгәллекләре, Коръәнгә тугрылыклары белән аерылып торалар. Аның «Җәвамигуль-кәлим шәрхе» (1916) хезмәтен Җ.Зәйнуллин менә ничек бәяли: бу китап «үзенең тел байлыгы һәм уңышлы тәрҗемә ителгән булуы» белән сыйфатлана. «Анда тупланган энциклопедик мәгълүмат һәр укучы өчен бик файдалы һәм кирәкле» (97 б.).

Р. Фәхреддин эшчәнлегенең зур өлешен шәрыкшенаслык, ягъни ориенталистика алып тора. Мәгълүм ки, халкыбызның мең елдан артык тарихы, яшәеше, рухи мирасы мөселман дөньясы, аеруча гарәп, фарсы мәдәнияте белән гаять тыгыз бәйләнешле. Аның нигезен дини уртаклык — ислам тәшкил итә. Шәрык телләрен, рухи мирасын татар мәктәп-мәдрәсәләрендә өйрәнү дә ике арада якынлыкны тәэмин иткән. Күп кенә зыялылар фикеренчә, Урта гасыр һәм XIX йөз татар мәгыйшәте, татар рухи тормышы үзе дә Шәрыкның табигый бер кыйсеме булып тора. Бу тарихи чынбарлыкны тирәнтен аңлаган Р. Фәхреддин гарәп, фарсы һәм төрки дөньясы белән татар дөньясындагы багланышларны өйрәнүгә һәм гомумән Шәрык тематикасын тикшерүгә үзеннән гаять зур өлеш кертә. Югарыда телгә алынган дини хезмәтләре, шәрехләре дә нәкъ әнә шул тармакка карый. Болардан тыш, ул Шәрык дөньясының бөек затларына багышланган махсус китаплар-монографияләр дә яза. «Ибне Рөшдә (Казан, 1905), «Имам Газали» (Оренбург, 1910.), «Ибне Тәймил» (Оренбург, 1911), «Әхмәд Мидхәд әфәнде» (Оренбург, 1913) — әнә шундыйлардан. Боларга әдипнең «Мәшһүр ирләр», «Мәшһүр хатыннар» сериясендә чыккан башка хезмәтләрен дә өстәргә мөмкин. Автор Шәрыкның бу бөек әһелләренең тормыш һәм иҗатларын гаять күп төрле чыганакларга, материалларга таянып, тулы һәм җентекле итеп тасвирлый, аларның эшчәнлекләрендә чорга аваздаш, файдалы булган урыннарга аеруча басым ясый. Мөселман Көнчыгышының бу затлары хакындагы монографияләре төрки дөньяда хәзер дә югары бәяләнәләр. Кызганыч ки, алар бүгенге татар укучысына әле һаман да юньләп билгеле түгел.

Р.Фәхреддин Шәрыкның Әл-Мәгарри, Әл-Мәтәннәби, Хәйям, Сәгъди, Хафиз, Нәваи кебек классик әдипләренең әсәрләрен укучыларга җиткерү юнәлешендә дә зур эшләр башкара. «Шура» журналы битләрендә, мәсәлән, Шәрык сүз сәнгатенә даими рубрика биреп барыла. «Ибне Гарәби» китабында бу акыл иясенең һәм шагыйрьнең күп кенә хикмәтле сүзләре, нәсыйхәтләре укучыларга тәкъдим ителгән:

«Адәмнәр хакында нә кеби мөгамәлә улсаң, адәмнәр сәнең хакында шөйлә (шундый) мөгамәләдә улырлар», «Сүзе тугры улан кемсәнәнең хале дә тугры улыр», «Тәүбә димәк тәүбә дәгел, бәлки тәүбә үкенмәк вә ул эшдән тәмам бизмәктән гыйбарәтдер», «Нәфесне йиңмеш адәмнең дошманнары йиңел йиңелер» һ.б.

Р.Фәхреддин өчен тарихи шәхесләр, иң беренче чиратта, шәхси сыйфатлары белән түгел, ә хезмәтләре белән кыйммәтле. 1912 елда дөнья күргән бер монографиясенең (Ибне Гарәби) ахыргы битләрендә мондый юллар бар: «Бән,— ди автор,— тәрҗемәи хәлләрне сахибләре (хуҗалары, ияләре) садыйк (тугры, дус) яки зиндикъ (динсез) улмак ноктасыннан дәгел, бәлки галим вә әдип улдыклары һәм дә дини вә иҗтимагый хәлләрдә әсәрләр куеп китдекләре ноктадан язарым».

Миңа 1977 елда Уфада Р.Фәхреддиннең архивы белән өлешчә танышырга туры килгән иде. Аның кульязма хәлендә калган «Асарь» томнарында гына да никадәр әдәби байлык туплануы мине сокландырды.

Р.Фәхреддиннең иҗат мирасы, әйткәнебезчә, искиткеч бай, күпкырлы. Аны җентекләп өйрәнү, укучыларга җиткерү милли яшәешебез, фәнебез, мәдәниятебез өчен зарури. Галимнең хезмәтләрендә аеруча әхлакый тәрбиягә мөнәсәбәтле материаллар күп.

Р.Фәхреддиннең тарихи язмалары үткән юлыбызны, андагы уңай, кимчелекле якларны ачыграк күрергә ярдәм итә. Бөек мәгърифәтченең шәхесе, тормыш юлы күп буыннар өчен үрнәк булырлык. Аның өчен әхлакый сафлык, вөҗданлылык, тырышлык, милләтпәрвәрлек хас.

Гарәпнең Әбу Галя Әл-Мәгарри исемле (973—1057) бөтен дөньяга мәгълүм бөек философы, шагыйре бар. Р.Фәхреддин бу сукыр әдип хакындагы китабын мондый юллар белән башлый: «Кыйммәтле вә мәгърифәтле кавемнәр үзләренең бөек адәмләре хакында бер чук әсәрләр язып, исемләрен милләтләр арасына таратырлар. Вә шунлар илә фәхерләнерләр (куанырлар), боның илә канәгать итмәй, күп вакытда бөек шәһәрләрдә гыйлем юлында йөрүчеләрнең күз уңнарына (алларына) шөйлә кемсәләрнең исемләренә һәйкәлләр (нишаннар.— *Р.Ф.*) утырталар, мәктәб вә мәдрәсәләр тәэсис итәләр (төзиләр). Боның хилафына уларак, мөселманнарда күб вакыт адәмнәрнең исемләре онытылыныр; газиз әсәрләре дә үрмәкүч оясы вә көя азыгы уларак, юешләнеп, череп вә яки… тузан оясы улып торыр».

Олуг җанлы, энциклопедик эшчәнлеккә ия булган Р.Фәхреддиннең бу юллары безнең өчен, бүгенге көн өчен дә актуаль яңгырый. Шөкер, без дә әкренләп уяна, тарихыбызны, мирасыбызны өйрәнә, бөек затларыбызны таный башладык. Әлмәт төбәгендә бу эш аеруча җанлы. Биредә, мәсәлән, Р.Фәхреддин, Ф.Кәрими һәм башка әһелләрнең музейлары бар, якташларына багышланган күп төрле чаралар үткәрелә.

Ризаэддин бине Фәхреддин — халкыбызның вөҗданы, горурлыгы, йөз аклыгы. Шундый олуг затларыбыз белән даими киңәшеп торганда, аларның васыятьләрен, хезмәтләрен зиһенебездә тотканда гына, татар үзенең милли нигезләрендә үсә, тәрәккый кыла алыр һәм киләчәктә җиһан халыклары арасында үзенә лаеклы, мөхтәрәм урынны биләүгә ирешер.

*1999*

### 3. Ризаэддин Фәхреддин — әдип һәм әдәбиятчы

Ризаэддин Фәхреддиннең энциклопедик эшчәнлеге безнең алда күптармаклы гыйльми-тикшеренү институты, Академия рәвешендә күзаллана. Аның тикшерү объекты һәм эшчәнлегенең төп адресаты — кеше, кавем, җәмгыять. Инсани башлангыч, инсани эчтәлек бу олуг зат хезмәтләренең, эш-гамәлләренең төп асылын билгели.

Каюм Насыйриның «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше») исемле мәшһүр китабында (1884) шушындый хикмәтле сүзләр бар: «Әгәр берәүгә гыйлем өйрәтергә теләсәң, әүвәл үзеңне өйрәт, изге гадәтләреңне тот, башкалар, күреп, гыйлем алсыннар» («Мирас» журналы.— 1995.— # 4.— 38 б.). Бу яктан Ризаэддин Фәхреддин — мөгаллим-остазның классик өлгесе. Шәхси сыйфатлары белән язган-сөйләгәннәренең табигый ярашуы аның киңәш-теләкләренең, вәгазь-нәсыйхәтләренең әһәмиятен, бәясен тагын да арттыра, тагын да күтәрә. Чөнки ул һәрчак иҗади, үзенчә фикерле, кешене үзәккә куя, инсанны тәрбияләүне һәм камилләштерүне үзенең асыл максаты итеп саный. Р. Фәхреддин шәхесенең һәм мирасының мондый үзенчәлеге, «әдәби»леге шактый дәрәҗәдә элеккеге традицияләр белән дә бәйле. Чөнки Урта гасыр Шәрык, шул исәптән татар сүз сәнгатендә, аеруча чәчмә әдәбиятта эстетик, фәнни, дини, әхлакый, тарихи һәм башка төр башлангычлар, еш кына үзара үрелеп, табигый бер синтез рәвешендә бирелгәннәр. «Кәлилә вә Димнә», «Кабуснамә», «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис», «Нәсыйхатес-салихин», «Җәмигъ эт-тәварих», «Тәварихе Болгария», «Рисаләи Газизә» һәм башка бик күп ядкярләр — әнә шундыйлардан. Боларда, әлбәттә, әдәби башлангыч, тел-стильнең чагыштырмача нәфислеге һәм үтемлелеге, фикерләүнең образлылыгы өстенлек итә. Әмма шуңа да

карамастан бу төр ядкярләр бүтән вазифаларны да башкаралар һәм әдәбиятчылар өчен генә түгел, ә кайбер башка инсани фәннәр өчен дә мөһим чыганак, материал булып та хезмәт итәләр. Р.Фәхреддиннең тарихи, дини, педагогик, фәлсәфи, биобиблиографик китапларында, күп санлы мәкаләләрендә мавыктыргыч стиль үрнәкләрен, җанлы, кызыклы сурәтләрне күпләп очратырга мөмкин. Аның, мәсәлән, татар ханнары турындагы язмалары, мәшһүр ирләр һәм хатыннар сериясендәге хезмәтләре әдәби әсәр, тарихи очерк һәм роман кебек укылалар.

Кыскасы, Р.Фәхреддин, гәрчә ул төрле тармакларда эшләсә дә, иң беренче чиратта, киң мәгънәдә әдип дип аталырга лаек. Мәгълүм ки, әдип, әдәбият сүзләре әдәп белән бер тамырдан. Р.Фәхреддиннең шәхси сыйфатлары, язган хезмәтләре, кылган гамәлләре барыннан да элек нәкъ әнә шул сүзләргә, язучы, тәрбияче, мөгаллим төшенчәләренә туры килеп тора.

* * *

Ризаэддин Фәхреддин — киң төшенчәле әдип исеменә генә түгел, ә заманча мәгънәле әдип атамасына да лаеклы зат. Ул — ике роман авторы да. Аларның беренчесе — «Сәлимә, яки Гыйффәт» (ул «Гафил бине Габдулла» тәхәллүсе белән язылган) — тәүге мәртәбә Казанда 1898 елда басылып чыга (80 б.). Икенчесе — «Әсма, яки Гамәл вә җәза» романы — 1903 елда Оренбургта нәшер ителә (130 б.). Боларның башка басмалары да бар (мәсәлән, «Сәлимә...» 1904 елда дөнья күрә). Шунысын да искәртик: совет чорында нәшер ителгән текстларда аерым кыскартулар, төгәлсезлекләр дә күзгә ташлана. Шуңа күрә һәр ике роман да тулы, гыйльми басмаларын көтәләр.

Р.Фәхреддиннең һәм «Сәлимә...», һәм «Әсма...» әсәрләре, гәрчә аларга госманлы теле йогынтысы көчле булса да, үз вакытында да, хәзер дә яратып укылалар, әдипләр һәм галимнәр тарафыннан уңай бәяләнәләр. Г.Тукай 1912 елда язган хатларының берсендә Р.Фәхреддин хакында болай ди: «Ул «Әсма...», «Сәлимә...» кебек китаплары белән куәи тәхририясе (язу көче) вә хәтта шигъриясен күрсәткән вә гомумән ифадәсе ачык, язу тарызы (стиле.— *Х.М.*) садә вә гүзәл бер язучыдыр». Мөһаҗирлеккә төшеп, Ерак Шәрыкта гомер кичергән татар зыялысы Хатыйп Халиди «Милли Байрак» газетасында басылган бер мәкаләсендә (1936, # 30) Р.Фәхреддин әсәрләренең тормышчан булуын, «Идел-Урал төрек-татарларының иҗтимагый вә мәдәни хәрәкәтләре кузгалышына баглы» рәвештә «бик матур әдәби тел берлә язылуын», тәрбияви яктан әһәмиятле булуын искәртә. М.Гайнуллин, «Сәлимә...» һәм «Әсма...» әсәрләрен күздә тотып: «Татар проза жанрын үстерүдә Р.Фәхреддиновның зур өлеше бар»,— дип яза (Татар әдәбияты тарихы.— II том.— Казан, 1985.— 322 б.).

Мәгълүм булганча, Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәбиятында хикәяләүгә корылган күп кенә эпик һәм лиро-эпик әсәрләрне хикәят дип йөрткәннәр. Р.Фәхреддин дә, элеккеге традицияләргә тугрылыклы калып, үз язмаларын шушы термин белән атаган. Әмма хәзерге әдәбият фәнендә һәм «Сәлимә...», һәм «Әсма...» әсәрләрен роман дип йөртү гадәткә кергән. Чыннан да, һәр ике ядкяр дә (аеруча икенчесе) образларның бирелеше, вакыйга-хәлләрнең бәян ителеше, идея эчтәлекләре белән роман исеме белән аталырга лаек.

«Сәлимә...» әсәренең композициясе сәяхәт, юл йөрү алымына корылган. Казан мәдрәсәләренең берсендә ун еллап белем алган хәлле генә бер шәкерт егет, дөнья күрү максаты белән, сәфәргә чыга. Пароходта Сәлимә исемле бер гүзәл, акыллы, укымышлы кыз белән таныша. Бу туташ — Тыйһран шәһәрендәге бер мәшһүр сәүдәгәр кызы. «Сәлимә туташ гади кызлардан дәгел иде,— ди автор.— Бәлки «яшь гомердә тырышканнар картлыкта рәхәт күрерләр» диелгән сүзгә муафыйк лязем тәхсилне (белемне) вә хаҗәте тәрбияне алмыш иде. Ана деле улган фарсычаны Тыйһранда укып, соңра Мисрыл-Каһирәгә вармыш, анда исә кызлар дарелфөнүнендә (университетында) биш ел укымыш, гарәп, француз, инглиз делләрене мөкәммәл сурәттә белмеш, кул һөнәрләренә, йорт итмәк вә мәгыйшәт кылмак гыйлемнәрене гүзәл үгрәнмеш...» Әтисе үлгәч, ул Тыйһранга кайта. Бераздан әнисе белән Петербургка баралар. Хәзер ватаннарына кайтып барышлары икән. Егет белән кыз аралашып торалар, төрле темаларга әңгәмәләр корыла. Пароход туктаган арада Самарадагы бер танышларына да кереп чыгалар. Танышуларына ике атналап вакыт үткәч, егет белән кыз Баку шәһәрендә гаилә корып та җибәрәләр.

«Сәлимә...» әсәре билгеле бер дәрәҗәдә сәяхәтнамә жанрын да хәтерләтә. Анда сәфәргә мөнәсәбәтле шәһәр-калалар (Казан, Болгар, Самар, Баку...), географик һәм этник төшенчәләр (төрки кавемнәр, Итил...) хакында мәгълүматлар, тарихи-этнографик белешмәләр бирелә. Әмма юлъязмалардан үзгә буларак, биредә төп сюжет шактый дәрәҗәдә уйланма, хикәяләүче (сәяхәт кылучы) «мин» белән автор язмышы туры килми. Мәгълүм ки, Р.Фәхреддин Казанда бөтенләй укымаган, Иран кызы белән гаилә дә кормаган. Авторның үзен Гафил бине Габдулла дип тәкъдим итүе, «хикәят»нең чынлыгына кат-кат басым ясавы да — реалистик әдәбиятның тернәкләнүе, хосусияте, үсеше белән бәйләнешле сәнгати чаралар.

«Сәлимә...» романында әле уй-фикерләрне вакыйгалар, конфликтлы вазгыять, сурәтләр аша гәүдәләндерү йомшаграк. Анда авторның турыдан-туры сөйләве, мәгълүмат бирүе өстенлек итә. Шуның

нәтиҗәсендә әсәрнең эчке динамикасы, мавыктыру көче кими. «Әсма...» романында исә бу сәнгати камиллек шактый дәрәҗәдә бетерелә. Биредә сюжет катлаулана, каршылыклар көчәйтелә төшә. Каһарманнар язмышы белән бәйләнешле эчке конфликт әсәрнең бөтенлеген, композицион яктан чагыштырмача төзеклеген тәэмин итә. Персонажларны индивидуальләштерү дә камилләшә төшкән. Исем алыштыру, «үлгән» дигән кешенең «кабат терелүе» әсәргә маҗаралылык төсмере дә өсти.

«Әсма...» романы «базары», «почтасы», «сәүдәгәрләре» булган зур гына бер авылда имамлык вазифаларын башкаручы Габбас гаиләсен тасвирлау белән башланып китә. Гайшә абыстай ирен, кызын тәрбияләүгә күп көч түгә. Авылның Хикмәт хаҗи дигән кешесе бу гаиләгә үчлек тота, йорт хуҗасына төрле ялалар яга. Хаҗ сәфәреннән Габбас мелланың «үлем хәбәре» килгәч, озакламый хатыны Гайшә дә күзләрен йома. «Унынчы яшенә чыккан» Әсма тәмам ятим кала. Аның өчен газаплы көннәр башлана: төрле кешеләрдә тору, теләнчелек, хастаханә... Әмма кыз (ул бу вакытта Зәйнәп исеме белән йөртелә) үзенең тәрбиялелеге, тырышлыгы аркасында, хәят корбанына әйләнми, алга бара, тәрбияханәгә эләгә, анда белем, һөнәр туплый һәм шул ук уку йортында мөгаллимә булып эшли башлый. Әсманың зирәклеге, уңганлыгы, матурлыгы күпләрне сокландыра. Ул үсмер чагында ук танышкан егетенә кияүгә чыга. Әтисенең дә исәнлеге ачыклана. Әсмага, аның ата-анасына начарлык, хөсетлек кылучылар исә төрле җәзаларга дучар булалар: комсыз Хикмәт хаҗи ачлыкта, фәкыйрьлектә үлә; йөзәрләгән хатын-кызларның аһ-зары мәкерле Зәйнүш абыстайга да төшә... Татар әдәбиятында элек-электән эшкәртелгән «ни чәчсәң — шуны урырсың», «һәр гамәл өчен тиешле рәхмәтен яки җәзасын алырсың» мотивлары биредә янә бер конкрет гәүдәләнеш таба. «Нәкадәр орлык сачмыш исә, җөмләсене үзе урды вә кешегә хәзерләмеш чокырларга кәндесе төште»,— дип, автор моны үзе дә искәртеп куя.

Р.Фәхреддиннең һәр ике романы да, гәрчә аларның сюжетлары, каһарманнары, төзелешләре үзгә булса да, идея-проблематикалары, персонажларга салынган мәгънәви йөкләмәләре белән үзара шактый якын, охшаш.

Мәгълүм булганча, Урта гасыр сүз сәнгатен еш кына әхлакый әдәбият дип йөртәләр. Белем төшенчәсе белән дә тыгыз бәйләнешле бу сыйфат XIX йөздә үзенең әһәмиятен тагын да арттыра (аңа карата фәндә мәгърифәтчелек атамасын куллану гадәткә кергән). К.Насыйри, Г.Чокрый, М.Акмулла... язмалары — моның ачык мисалы. Шунысы мөһим: XIX гасырның соңгы чирегендә әхлак, белем — мәгърифәт, милләт мәсьәләләре шактый тормышчан образлар, вакыйгалар ярдәмендә, чынбарлыкка тапкыр шәкелләрдә гәүдәләндерелә башлый. Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев, Габдрахман Ильяси нигез салган бу хәрәкәткә Р.Фәхреддин дә килеп кушыла. Аның романнары милли хәят, тарихи чынбарлык белән тыгыз бәйле. Сюжет-вакыйгаларның конкрет төбәкләргә, билгеле бер вакыт аралыгына нисбәт ителүе дә — авторның реализмга хәерхаһлыгын күрсәтүче дәлил.

Р.Фәхреддинне, барыннан да элек, инсан һәм халык язмышы борчый. Бөтен җанын, барлыгын биләгән бу проблеманы ул төрле яктан, төрле аспектларда гәүдәләндерергә омтыла. Автор фикеренчә, милләтнең ниндилеге, аның тәрәкъкыяте, иң беренче чиратта, хатын-кызга бәйле. Игътибар итегез: һәр ике әсәр дә хатын-кыз исеме белән аталган, һәр ике романның да төп каһарманнары — хатын-кызлар. Бу — юкка гына түгел, ә автор инанычының мантыйкый гәүдәләнеше. Сәлимә — кечкенәдән үк белем, тәрбия алган зат. Тормышын да ул көйли белә. Бу гүзәл, гыйффәтле инсаннан үзгәләргә, тирә-юньдәгеләргә нур, игелеклелек бөркелеп тора. Бөтенләй үзгә шартларда үсеп житкән Әсма да Сәлимә образы белән каршылыкка керми. Чөнки аның өчен дә тәрбиялелек, белем, һөнәрне өстен күрү, гыйффәтлелек хас. Әсманың мөгаллимә булып эшләве дә символик. Автор карашынча, милләтнең киләчәге — бүгенге хатын-кызлар, мөгаллимәләр кулында.

Һәр ике роман да төп каһарманнарның үзләре яраткан, үзләренә рухи һәм фикри яктан тиң булган кешеләргә кияүгә чыгулары белән тәмамлана. Р.Фәхреддин мәхәббәткә, хөрмәт-ихтирамга, үзара җаваплылыкка корылган гаилә тормышын, андагы инсани тәрбияне милләт яшәешенең нигезе, төп шарты дип саный. Автор фикеренчә, «ирләрнең һиммәте (тырышлыгы; дәрте) урыннарыннан тауларны күчерер, диерләр. Ләкин хатыннарның һиммәте боннан дәхи бәләндтер (артыктыр)». «...Гаилә,— ди ул икенче бер урында,— кечкенә бер дәүләт кебидер». Андагы тәртип һәм тәрбия — «җөмләсе гаилә башлыгы улган хатын вазифасыдыр». Биредә иң төп таләпләрнең берсе — балаларга кечкенәдән үк тиешле белем һәм тәрбия бирү. «Инсанның яшьлегендә алмыш тәрбиясе ... каберенә кадәр берлектә улыр, аерылмас»,— диелә «Әсма...» романында.

Автор кешеләрне һәм гомумән кавемне ислам дине рухында, моңа кадәр тупланган инсани һәм әхлакый тәҗрибә-казанышлар нигезендә тәрбияләүне яклый. Шуның белән бергә, Р.Фәхреддин — заманчалык тарафдары да. Аның әсәрләрендә Шәрык һәм Гареб телләрен өйрәнүнең, фән һәм техника казанышларын белүнең зарурилыгы, чынбарлыкка туры килерлек фикерләү һәм хәрәкәт яклана. Автор болай ди: «Бер милләт вә кавемнең тәрәкъкыйсы укымак, һөнәр вә санагать белмәккә мәүкуфтыр

(бәйледер). ...Бабаларымыз «гакыл яшьтә улмаз, башта улыр» димешләр. Русча, төркичә җөмләңез (барыгыз) яхшы белдекеңез кеби, араңызда аз улса да француз, немец, гарәп, фарсы делләрене белүчеләр һәм вардыр. Бу делләрне белмәк олуг сәрмаядыр (байлыктыр). Бу делләр сәбәбеннән кәрәк Россиядә, кәрәк Европа вә Америкада, кәрәк Иран, Әфган, Һинд тарафларында сәүдә итмәк мөмкин улачактыр».

Р.Фәхреддин үзенең әдәби әсәрләрендә һәм башка төр язмаларында дини наданлыкны, тәгассыбны (фанатизмны) кискен тәнкыйтьли, дин исеме белән нәфесен, шәхси мәнфәгатьләрен генә кайгыртучыларны фаш итә. Шуның белән бергә, бөек мәгърифәтче мөселман диненә ихлас ышана, аның сафлыгын тәрбияви процесстагы олуг вазифасын сакларга омтыла.

Әйткәнебезчә, совет чоры басмаларында Р.Фәхреддин романнары теге яки бу дәрәҗәдә кыскартып басылды. Мәсәлән, мин «Сәлимә...» романының 1898 елгы басмасын «Татар мәгърифәтчелек әдәбияты»нда (Казан, 1979) бирелгән текст белән чагыштырдым. Бер гыйбрәтле нәрсә ачыкланды: баксаң, кыскартуларның күпчелеге динне мактаган, аңа уңай мөнәсәбәт белдергән өлешләргә карый икән. Тәүге басмада, мәсәлән, мондый юллар бар: «Мөселманларга хезмәт итмәк өчен, иң элек ислам гыйлеме илә белем вә шәригать кагыйдәләре илә әшна (таныш) улмак тиешледер. Буйлә (мондый) улмаганда, мөселманлар инабәт итмәзләр (ышанмаслар)... Үз динене, үз делене, үз гореф-гадәтене белмәгән кемсәнәгә ялгыз әһле ислам дәгел, һичбер кавем игътибад әйләмәз (ышанмаз)...» (24 б.) Кызганыч ки, бу мөһим фикерләр 1979 елгы басмада күзгә ташланмый.

Һәм «Сәлимә...», һәм «Әсма...» романнарында автор башлангычы гаять көчле. Ул үзенең уй-кичерешләрен, теге яки бу күренешкә мөнәсәбәтен турыдан-туры да, каһарманнарның эш-гамәлләре, сөйләмнәре аркылы да нык сиздереп тора. Чөнки әдәби иҗат — аның өчен бер мөһим мөнбәр, үтемле чара. 1917 елда язылган бер мәкаләсендә (Шура.— 1917.— # 23—24.— 540 б.) Р.Фәхреддин болай ди: «Сәлимә...» берлә «Әсма...» — минем яшь вакытларымның ядкярләре һәм дә эчемдәге зар-моңнарымны вә хәсрәт-кайгыларымны уртаклашкан сердәшләремдер...» (Өзек «Татар әдәбияты тарихы»ның II томыннан алынды.— 329 б.) Инде менә бер гасыр буена бу ике роман — киң катлам укучыларның да күңел сердәше. Чөнки аларда тормыш тәҗрибәсе, инсани әхлак казанышлары, кеше психологиясенең аерым яклары гәүдәләнеш тапкан. «Сәлимә...» һәм «Әсма...» әсәрләре, тәрбияви яктан тыш, әдәбиятыбызның реалистик нигездә үсешенә, роман жанрының камилләшүенә дә билгеле бер өлеш керттеләр.

* * *

Ризаэддин Фәхреддин — сәнгати әсәрләр иҗат иткән әдип кенә түгел, ә әдәбиятны өйрәнгән, тикшергән галим дә. Аның әдәбиятчы булуы бу мөхтәрәм затның бөтен эшчәнлегендә, әдәби һәм гыйльми китапларында, публицистик язмаларында, «Шура» журналындагы сәхифәләрдә ачык күренә. Ул — сүз сәнгатенең текстологы да, тарихчысы һәм теоретигы да, методисты һәм библиографы да, әдәби багланышларны тикшерүче дә... Бу зат — гарәп, фарсы, төрки әдәбиятларының олуг белгече дә... Р.Фәхреддин — әдәбият фәненең төрле тармакларында үз сүзен әйткән, билгеле бер эз калдырган галим. Аларның һәрберсе махсус һәм җентекле тикшеренүләргә мохтаҗ. Биредә исә без гомуми күзаллау тудыруны гына максат итеп куябыз.

Камил инсан тәрбияләү — Р.Фәхреддин эшчәнлегенең асылы, арка сөяге. «Инсан улмак өчен,— ди ул,— гыйлем илә күркәм холык кирәктер. Һәм дә бонларны бер-берләреннән аермак дөрест улмаз». Әдип фикеренчә, күркәм, гүзәл холык ул «әдәп, гыйффәт, сабыр, тәхәммелдән (түзүдән) гыйбарәттер...». Камил инсан тәрбияләүдә Р.Фәхреддин сүз сәнгатенә төп авырлык төшүен искәртә. «Әдәбият илә иштигаль (шөгыльләнү; мавыгу),— дип яза ул «Әсма...» романында,— күңелне сафламак вә нәфсене тәрбия итмәк бабында иң әсәрле улган дәвадыр». Икенче бер урында автор: «...Гарәпләрнең вәзенле көйләреннән әсәрләнеп, дәвәләр ашыгып-ашыгып китәрләр»,— ди.

Сүз сәнгатенең кеше тормышында, тәрбияви процесста биниһая көчкә ия булуын-тирәнтеп аңлап, Р.Фәхреддин элеккеге әдәби ядкярләрне туплауга, кирәк икән, текстологик эшкәртүгә, халыкка җиткерүгә җитди игътибар итә. Ул XVIII йөзгә мөнәсәбәтле «Исмәгыйль сәяхәтен» 1903 елда тиешле шәрех-аңлатмалар белән бастырып чыгара. Ш.Мәрҗани хаҗнамәсенең дөнья күрүе дә Р.Фәхреддин эшчәнлеге белән бәйле. Бу мөхтәрәм зат Ш.Зәки, Акмулла һәм башка күп кенә шагыйрьләрнең әсәрләрен дә укучыларга ирештерүгә зур өлеш кертте.

Р.Фәхреддин үз чоры рухи тормышының, әдәби процессының үзәгендә кайнады, аның катнашы, игелекле сүзе, таләпчәнлеге белән күп кенә кешеләр әдәбият юлына кереп китте. Ул мөхәррирлек иткән «Шура» журналының тәүге санында шушындый юллар бар: «Шура» милләтне гыйлемле, мәгърифәтле итмәк хакында мәшвәрәт (киңәш) мәҗлесе улачакдыр». Чыннан да, журнал үзенең мәсләгенә тугрылыклы калды. Аның һәр саны сүз сәнгатенең, төрле-төрле фикер-карашлар көрәшенең бер мөнбәре булды. Менә мин аның 1908 елгы саннарын гына актарам. Никадәр хәзинә, никадәр байлык! Һәр санда диярлек

Дәрдемәнд шигырьләре басылган. Шунысы кызыклы: биредәге текстларда аерым үзгәлекләр дә күзгә ташлана. Мәсәлән, «Кораб» шигырендәге «җилкәнен», «дулкын» сүзләре журналда «йилкәнен», «тулкын» рәвешендә басылган (# 1.—31 б.) «Шура»да әдәби, гыйльми яңалыклар даими рәвештә бирелеп бара. 5 нче санда, мәсәлән, Заһир Бигиевнең «Мавәраэннәһердә сәяхәт» әсәре басылуы хәбәр ителә, аның авторы һәм китабы хакында фикерләр әйтелә (148—149 б.). Яшьли үлсә дә, «Заһир әфәнде хакыйкать хальдә бәхтиярдер, әсәр укылырга вә һәр тарафда нәшер иделенергә лаек...»

Шушы ук 1908 елгы саннарда рус, госманлы, гарәп, Европа әдәбиятлары хакында житди эчтәлекле, күләмле язмалар бар. 18 нче санда мәшһүр «Котадгу белек» (1069) нөсхәләре хакында белешмә бирелә (575 б.). 21 нче санда «Кыйссаи Йосыф» дастанының «назмы гаять да мәүзүн (төзек), лөгате ачык вә фәсыйх (килешле; ятышлы) улыб, өслүбе (стиле) һәм мәргуб (сыйфатлы, затлы) вә әсәрле» булуы искәртелгән (673 б.). Шушында ук моңа кадәр аерым китап рәвешендә басылган 34 әдәби әсәрнең исемлеге урнаштырылган (673—674 б.). Журналның тәүге саннарында Сократ, Ибне Фадлан, Әл-Мәгарри, Физули, «Граф Толстой», Пушкин, Гаспралы, Й.Акчура, Ф.Кәрими һәм башка күренекле затларга мөнәсәбәтле язмалар бар. «Шура» 1908 елда 24 сан чыккан. Барлыгы — 784 бит. Ә бит ул 10 ел буена нәшер ителеп килгән. 240 сан. Тәүге елның тәҗрибәсе, традицияләре тагын да баетылган, үстерелгән. Ризаэддин Фәхреддиннең тормышын, иҗат мирасын өйрәнүгә һәм пропагандалауга гаять зур өлеш керткән Мәдинә апа Рәхимкулова исәпләвенчә, баш мөхәррир «Шура» да үзе 312 мәкалә бастырган (Ризаэддин бин Фәхреддин. Юбилей чыгарылышы: Тууына 140 яшь тулу мөнәсәбәте белән...— Оренбург: Пресса, 1998.— 250 б.). Бу санга әле төрле белешмә-мәгълүматлар, кечерәк рецензияләр керми. Журналда басылган 4 меңнән артык мәкалә-публикациянең дә бит күпчелеге Р.Фәхреддин кулы, зиһене аша уза. Аларның зур өлеше әдәбият һәм сәнгать турында, яисә сүз сәнгате белән бәйләнешле. «Шура» журналында әдәбият мәсьәләләре» темасына яшь галим Раиф Мәрдәнов академик Миркасыйм Госманов җитәкчелегендә бай эчтәлекле кандидатлык диссертациясе язды. Шәт, аның бу хезмәте аерым китап рәвешендә дә дөнья күрердер.

«Шура»,— иң беренче чиратта, Ризаэддин Фәхреддин журналы. Чөнки ул — аның баш мөхәррире, төп авторы, оештыручысы, кыскасы, анасы һәм атасы да. 1928—1939 елларда Берлинда нәшер ителгән «Яңа милли юл» журналында да без шундый ук хәлне күрәбез. Аны да шуңа күрә еш кына Гаяз Исхакый журналы дип йөртәләр. Һәр ике журнал татар рухи тормышының мәркәзе, үзенә күрә бер штабы булдылар.

Р.Фәхреддиннең әдәбият фәнен яңа чыганаклар белән баетуда, әйткәнебезчә, роле гаять зур. Әмма ул әдәби ядкярләрне, факт-мәгълүматларны эзләү, эшкәртү, бастыру белән генә чикләнмәде, алар нигезендә үзе дә җитди мәкаләләр, хезмәтләр тудырды. Аның «Шура» журналында, күптомлык «Асарь»дә басылган материаллары — элеккеге әдип-галимнәребезнең тормыш юлларын һәм иҗатларын өйрәнүдә бәһаләп бетергесез чыганак. Шунысын да искәртик: ниһаять, XX гасырның соңгы елында «Татар энциклопедик сүзлеге» дөнья күрде (кызганычка каршы, анысы да рус телендә). Ә бит бу изге эшнең нигезе Ш.Мәрҗани, Р.Фәхреддин тарафыннан салынган. Галимнең басма һәм кульязма хәлендәге «Асарь» томнарын тулы килеш хәзерге укучыларга җиткерергә иде.

Ризаэддин Фәхреддин — җиһан әдәбиятының, иң беренче чиратта, Шәрык сүз сәнгатенең бөек затларын өйрәнүгә, аларның әсәрләрен халыкка җиткерүгә зур өлеш керткән галим дә. Мондый шәхесләр арасында Әл-Мөкаффәгъ, Ибне Сина, Сәгъди, Хафиз, Нәваи һәм башка бик күп мәшһүр исемнәр бар. 1917 елда XIV йөз сәяхәтчесе Ибне Батутаның Алтын Урдага сәфәре хакында язмасын тәрҗемә итеп бастыра. Р.Фәхреддиннең Әл-Мәгарри, Имам Газали, Ибне Гарәби, Ибне Рөшдә, Әхмәд Мидхәд һәм башка классик әдип-галимнәр хакында махсус монографияләре дә бар. Бу төр язмалар өчен гыйльми тирәнлек, факт-мәгълүматларга муллык, комплекслылык, инсанилык, тугрылык хас. Үзенең тикшерү ысулын аңлатып, Р.Фәхреддин «Әбу Галя Әл-Мәгарри» монографиясенең (Оренбург, 1908) «хатимә» өлешендә болай яза: «Бән бер кемсәнең тәрҗемәи халене үгрәнмәк эстәдекем вакыт, шу(л) адәмнең хосусый әхвалендән башка, гаиләсене, тәрбия алмыш адәмләрене, йөрмеш йирләрене, сохбәт итдеке әкъран вә әмсалене (якыннарын һәм чордашларын), хәтта ки гасырыны һәм берлекдә үгрәнәм. Бу шәй (әйбер; нәрсә) бәндә гадәтдер. Бу шәйләрдән мөҗәррәд (ялгыз) уларак (аерылып) язылмыш тәрҗемәләрнең (биографияләрнең) сахибләрене (ияләрене) сахра уртасында үсмеш бер агач кеби күрдекем сәбәбендән, алар хакында бер хөкем чыгара белмәкдән гаҗизем. Бәнем өчен бер агачның юанлыгы, нечкәлеге, озынлыгы вә кыскалыгы, төзлеге вә кәкрелеге илә хөкем итмәк өчен, мотлакан күб агачлар арасында улынырга вә шунлара (шуларга) кыяс иделенергә (чагыштырылырга) мәүкуфдыр («тиештер»)... Бән мөмкин кадәр тугры язарга сәгый итдем (тырыштым)» (69—70 б.). Бу — декларатив юллар гына түгел, ә мөхтәрәм галимнең һәр язмасында, бөтен эшчәнлегендә кулланылган методология, иман-ышаныч.

Р.Фәхреддиннең шәрыкшенаслык, тюркология буенча хезмәтләре Төркиядә, Үзбәкстанда, Әфганстан һәм кайбер башка илләрдә хәзер дә бик теләп кулланылалар, аларның абруе, гыйльми ышанычлылык дәрәҗәсе югары.

Ризаэддин Фәхреддиннең әдәби мирасы, сүз сәнгате белән бәйле хезмәтләре — татар әдәбиятының һәм фәненең кыйммәтле сәхифәләре. Аларда — олуг затның йөрәк тибеше, дөнья, тормыш турында уйланулары, тарихка, киләчәккә карашлары. Бу язмалар өчен бөек инсанилык, күркәм әхлаклылык, фидакарь милләтпәрвәрлек хас. Күренекле милләттәшебез Рәшит Рәхмәти Арат («Казанлы») 1936 елның 17 маенда Анкарадан язган мәрсияи мәкаләсендә болай ди: Фәхреддин «безнең өчен үлмәс үлемнең бередер. Үзен мәңге яшәтәчәк эзләр калдырмышдыр...» (Яңа милли юл.— 1939.— # 7—8.— 26 б.) Әйе, бу мөхтәрәм зат, үзе күптән үлсә дә, безнең арабызда замандашыбыз, остазыбыз, киңәшчебез рәвешендә яшәвен дәвам итә... «Инсаннар,— ди ул,— тормыш юлында туктап торыр өчен килмәгәннәр, әмма һәмишә (һәрчак) алга барырга, югары үрмәләргә омтылырга килгәннәр». Ризаэддин Фәхреддиннең шәхесе, гыйбрәтле эшчәнлеге, бай мирасы безне тәрәккъыяткә этәрә, хәтеребезне баета, иманыбызны ныгыта, милләткә хезмәт юлында дәрт вә илһам, көч вә куәт биреп тора.

*1999*

**БӘХТИЯР ӘДИП**

(*Заһир Бигиевнең тууына — 130 ел*)

«Шура» журналының 1908 ел 5 нче санындагы бер язмада (аның авторы баш мөхәррир Ризаэддин Фәхреддин үзе булса кирәк) яшьли үлсә дә, «Заһир әфәнде хакыйкать хальдә, бәхтиярдер» диелгән (149 б.). Бу кыска гына җөмләдә Заһир Бигиев язмышының мөһим бер үзенчәлеге тотып алынган. Чыннан да, ул, гәрчә Тукай, Бабич, Такташлардан бераз озаграк яшәсә дә, гомумән, бу якты дөньядан бик иртә китеп бара. 32 яшь —бу бит әле кеше гомеренең уртасы гына. Әмма Заһир Бигиев әдип буларак чыннан да бәхтияр, ягъни бәхетле: аңа Ходай Тәгалә әдәби талантны мул итеп биргән, шуңа да ул 16—19 яшьләрендә үк төрле чор укучылары яратып укырлык романнар тудыруга ирешкән. Аның әсәрләре автор үзе исән чакта да (1887, 1890, 1895, 1896...), аннан соң да (1908, 1925, 1960, 1991...) даими басылып тора, мәктәпләрдә, югары уку йортларында өйрәнелә, галимнәрнең, әдипләрнең игътибарын җәлеп итә.

Тормышта еш кына шушындый хәл күзәтелә: кешенең сыйфатларын, эш-гамәлләрен, хезмәтләрен күреп, тоеп йөрисең, әмма алар хакында фикер әйтергә, ничектер, җае чыкмый, сылтау табылмый. Заһир Бигиев турында да әүвәл шулай була. Әмма аның 1908 елда «Мавәраэннәһердә сәяхәт» исемле китабының басылып чыгуы («Китап» нәшрияты.— 108 б.) җәмәгатьчелекнең әдип хакындагы тәэссоратларын, уй-кичерешләрен белдерүгә бер этәргеч ясый, сәбәп була. Чорның күп кенә күренекле шәхесләре узыша-узыша матбугатта З.Бигиев турында язмаларын бастыра башлыйлар. Ф.Әмирхан «Дамелла» кушаматы белән басылган бер язмасында (Әлислах.— 1908.— # 21.— 5—6 б.) әдипне «Татар милләтенең соңгы еллары йитешдергән вә иртәрәк күзе ачылган мөхәррирләрендән» берсе дип саный. «Заһир әфәнденең бу әсәре (ягъни «Мавәраэннәһердә сәяхәт»),— ди ул,— хәзергә кадәр татар әдәбиятында назыйрәсездер (тиңсездер), рәгъбәт (теләк) белән укып чыгарлык сурәттә төрләндереп язылган». Шунысы кызыклы: бу сөйләшүдән хәтта ерак сөргендәге Гаяз Исхакый да читтә калмый. «Бәянелхак» газетасында басылган язма (1908.—16 март.) — шуның бер мисалы.

Г.Исхакый «Мавәраэннәһердә сәяхәт» әсәренең, соң булса да, аерым китап рәвешендә басылуын хуплый. «Бу сәяхәтнамә,— ди ул,— Заһир әфәнденең соңгы әсәре булганга, бу яшьли әрәм булган мөхәррирнең укучылар берлә актык сөйләшүе, аларга үзенең йөрәгенең кайнаганнарын актык әйтүе булганга, безнең әдәбият тарихымызда да бу китап, шөбһәсез, бер әсәр булачакдыр. Бу китап хакыйкать Заһир әфәнденең кем идеке вә ничек уйладыкы, вә ниләр теләдеге берлә танышдырганга, Заһир әфәндене таныр өчен, бу китап бик зур ярдәм итәчәкдер. «Мавәраэннәһердә сәяхәт» моннан 15 ел элек язылганыны искә төшерелсә, Заһир әфәнденең шул вакытта башын вата торган фикерләр татар әдәбиятына 1901 ел Риза Казыйның «Сәлимә...»сенә кадәр кермәве хисап кылынса, Заһир әфәнденең бик алдагы бер мөхәррир, татарның халендән бик хәбәрдар бер язучы булуында аз гына да шик калдырмыйдыр. Шуның өчен Заһир әфәнденең яшь вакытта әрәм булуы безнең татар әдәбиятын сөйгән кешеләр алдында, шөбһәсез, бер зур кайгырырлык эшдер». Рецензент фикеренчә, «Заһир Бигиев — безнең татарларның Габделкаюм Ән-Насыйридан соң иң карт мөхәррирләреннән» берсе, «татар дөньясында мәгълүм бер кеше»; шуңа күрә «аның әсәрләре хакында газеталарда язу вә әсәрләрен тәнкыйд кылу бик файдалы эш...». Г.Исхакый әдипнең сәяхәтнамәсе хакында аерым тәнкыйть фикерләре дә әйтә. Мәсәлән, мәкалә авторы Заһир Бигиевнең «госманлычарак» тел белән язуын, мәшһүр шәрыкшенас Вамберины «шпион ясау»ның «хаксыз» икәнлеген искәртә. Рецензент үз язмасын мондый юллар белән төгәлли: «Гомумән караганда, китап бик файдалы, матбугатымызның тулмаган йирләрен тутыра торган, халкымызның бик күп аңламаган мәсьәләләрен аңлата торган бер әсәрдер. Шуның өчен Заһир әфәнденең бу соңгы әсәрен һәркемгә укырга тәүсыя (киңәш) итәмез».

* * *

Татар рухи тормышында тирән эз калдырган агалы-энеле, ягъни бертуган шәхесләр бар: Хөсәен һәм Габделгалләм Фәезхановлар, Һади һәм Садрый Максудыйлар, Нил һәм Илдар Юзеевлар... Заһир Бигиев тә — әнә шундый затларның берсе. Аның энесе Муса (24.12.1875—12.11.1949. Кайбер язмаларда туган елы 1871 ел дип күрсәтелә) — дин галиме, шәрыкшенас, педагог, журналист, җәмәгать эшлеклесе, мөселман дөньясының күренекле шәхесе. Татар зыялылары арасында Муса Җарулла кебек күп җирләрдә укыган, җиһанның төрле почмакларында яшәгән шәхесләр, мөгаен, башка юктыр. Булса да, бик аздыр. Ул әтисенең туган авылында, Казанның Зәңгәр мәчет мәдрәсәсендә, Ростовтагы лицейда, Бохарада, атаклы Әл-Әзһәр югары уку йортында, Санкт-Петербург университетында укый, Казан, Оренбург, Петербург, Мәскәү, Ташкент, Истанбул, Хельсинки, Берлин, Каһирә, Һиндстан, Япония, Кытай, Иран һәм башка күп кенә шәһәрләрдә, мәмләкәтләрдә була, эшли, үз чорының мәшһүр кешеләре белән очраша, аралаша. Болар арасында Тукай һәм Исхакый кебек әдипләр дә, Ленин һәм Ататөрек кебек дәүләт эшлеклеләре дә бар.

Муса Бигиев, дини-сәяси карашлары өчен, өч ай буе Лефортово (Мәскәү), алты ай Пишавар (элеккеге Һиндстанда) төрмәләренең «рәхәтлекләренә» дә дучар ителә. Шунысы мөһим: аның хатыны Әсмаи-Галия дә — затлы нәселдән. Ул — Чистайның атаклы Закир хәзрәт кызы. Аның абыйсы Ибраһим Шәүкәт Кәмал Каһирәдә Муса белән бергә укый. Әсмаи-Галия белән Мусаның Чистайда үткәрелгән туй мәҗлесендә (ул 1905 елның 20 маенда була) Рәшит казый Ибраһимов (1857—1944), Нәҗип Әмирхан (1859—1921) һәм бүтән могтәбәр затлар катнаша (*Равил Әмирхан*. Соңарып килгән гаделлек // Шәһри Казан.— 6.06.2000). Муса Җарулла 1949 елның 12 ноябрендә Каһирәдә вафат була. Татар, рус, гарәп, фарсы, төрек һәм кайбер башка телләрне «мөкәммәл» белгән бу затның шәхси китапханәсе үзенең васыяте буенча Анкарадагы Милли китапханәгә тапшырыла.

Заһир Бигиевнең туганнары күп була. Алар арасында да, гәрчә Муса Җарулла кебек булмаса да, шактый билгеле шәхесләр бар.

* * *

Заһир Бигиевнең тормыш юлы һәм иҗаты дәреслек-хрестоматияләр, әдәбият тарихы китаплары, төрле мәкаләләр аша укучыларга, киң җәмәгатьчелеккә шактый таныш. Безгә дә инде бу әдип хакында берничә мәртәбә язарга туры килгән иде [«Исмең синең милләт яшәдекчә яшәр» (Тууына 125 ел тулу уңае белән) // Мирас.— 1995.— # 11—12.— 38—47 б.; Татар әдәбияты: Рус мәктәпләренең 10 нчы сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек-хрестоматия.— Казан: Мәгариф, 1996.— 172—185 б. һ.б.]. Шуңа күрә биредә, Муса Бигиевнең «Мавәраэннәһердә сәяхәт» китабына (Казан, 1908) кереш рәвешендә бирелгән мәкаләсенә, А.Баттал-Таймасның Истанбулда нәшер ителгән «Муса Җаруллаһ Биги» (1958.—61 б.) монографиясенә һәм кайбер башка материалларга нигезләнеп, әдипнең тәрҗемәи хәле, иҗаты хакында кайбер мәгълүматлар биреп китәрбез.

Мөхәммәдзаһир Бигиев 1870 елның көзендә Ростов-Дон каласында яшәүче рухани гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Җарулла (Ярулла) һәм әнисе Фатыйма — һәр икесе дә Пенза төбәгендәге «Алтыавыл»ның берсе Мачалидан (Кикин авылына нисбәт итүчеләр дә бар). Мөхәммәдзаһирның әнисе ягыннан бабасы Хәбибулла Биги углы авылның укымышлы имамы була. Җарулла Габделкәрим углы анда укый, гарәп, фарсы телләрен үзләштерә, русча да өйрәнә. Мәскәү — Ростов тимер юлында сәүдә белән шөгыльләнә. Мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев, ислами гыйлемлелеген исәпкә алып, аны Ростов-Дон шәһәренә имам итеп билгели. Әмма булачак әдипнең әтисе 45 яшьләрендә 1881 елда ниндидер «бөек бер бәлагә очрап» үлеп китә. Гаиләнең бөтен авырлыгы, балаларны тәрбияләү Фатыйма абыстай җаваплылыгында кала. Ул үз балаларын еш кына авылга әби-бабалары янына алып кайта, аларга Мәскәү, Петербург, Казан калаларын да күрсәтә. Укымышлы, дини гаиләдә туып үскән, үзе дә шактый гыйлемгә ия булган бу хатын балаларын белемле, иманлы итүгә күп көч түгә. Фатыйма абыстай, сукыраеп, 1908 елда вафат була.

Муса Бигиев язуынча, «Заһир әфәнде яшь бала икән (ягъни яшь вакытта ук) русча уку, язу вә үгрәнеп, соңра валидәсе (әнисе) Фатыйма ханым банате дамелла Хәбибулла хәзрәтләренең тәрбиясендә иске мәдрәсәләрнең берендә күп еллар калып, иске ысул үзрендә (искечә) гомуме диния, гомуме гарәбия укымышдыр». Шул елларда аның рус, француз, госманлы авторларының әсәрләрен күпләп укуы мәгълүм. Заһир Бигиев бигрәк тә маҗаралы, детектив романнарны ярата. Болар бар да табигый сәләткә ия булган үсмерне әдәби иҗат белән шөгыльләнүгә китерәләр. Һәм ул 16 яшендә «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» исемле атаклы романын яза. Мәгълүм булганча, Заһир Бигиев 1886 елда Казанда Күл буе мәдрәсәсендә укый башлый. Биредә ул, «Өлүф...», яисә «Меңнәр...» романын төгәлләп, 1887 елда «Вячеслав» басмаханәсендә нәшер итә. Әдипнең Казандагы тормышы әллә ни билгеле түгел. Чыганакларда аның күпләп укуы, төрле кешеләр белән аралашуы, әдәби иҗат белән шөгыльләнүе гомуми планда гына искәртелә. 1890 елда Казанның шул ук басмаханәсендә әдип үзенең «Гөнаһе кәбаир» («Зур гөнаһлар») исемле икенче романын нәшер итә.

Мәдрәсәне тәмамлагач, 1891 елда З.Бигиев Ростов-Донга кайта һәм шунда шәһәр мөселманнарының имамы булып эшли башлый. «Имам улмыш исә дә,— ди аның хакында энесе Муса Бигиев,— гомеренең ниһаясенә (ахырына) кадәр валидәсенең тәрбиясендә калды... Ростов шәһәренең көтебханәи гомумиясенә варып, даимән рус әсәрләрене моталәгә идәр (укыр) иде». 1893 елда З.Бигиев Мавәраэннәһергә, ягъни Урта Азиягә сәяхәт кыла. Шуның нәтиҗәсе буларак, аның атаклы сәяхәтнамәсе языла. Бу язма 23 яшьлек авторның гаять зыялы, укымышлы, Шәрык һәм Европа гыйлемен шактый тирән үзләштергән шәхес икәнлеген ачык күрсәтеп тора.

З.Бигиевнең Төркестан якларына баруында ике төп сәбәп бар. Әдип, Исмәгыйль Гаспралы кебек, татарча газета чыгарырга хыяллана. Әмма бу ният гамәлгә ашмый. З.Бигиевнең Бохарада укырга калырга

да теләге була. Әмма андагы уку йортларында белем бирүнең түбән дәрәҗәдә икәнлеген күргәч, ул бу ниятеннән баш тарта.

З.Бигиев Төркестаннан күңел төшенкелеге белән кайта. «Мавәраэннәһердә сәяхәт» язмасының ахырында ул болай ди: «Гаять көчле авырулы бер хәлгә төштем. Башлануы кайгыдан юану өчен бер кәеф-сафа кору сымаграк булып күренсә дә, ахыры соң дәрәҗәдә һәлакәтле булды. Кулыма каләм алмас бер хәлгә килдем. Тормыш ләззәтләреннән өмет өздем. Моннан соң яшәвемдә файда булмас дидем дә әҗәл сәгатен, Газраилнең визитын көтә башладым...». Шушындый төшенке халәт алга таба да дәвам итә. Муса Бигиев тә абыйсының «гаять бөек мөдһәш (куркыныч) бер бәлая (бәлагә) ибтилясы (төшүе, дучар булуы)» хакында яза. 1902 елда әдипнең йөрәге тибүдән туктый. Аның кайчан, кемгә өйләнүе хакында кулыбызда мәгълүматлар юк. Муса Бигиев абыйсының урын өстендә хыянәт кулы белән үтерелүен яза («дәсте хыянәт илә катыйл улынып, шәһид улды»). «Валидәсе, баласының җәсәдене (гәүдәсен) табиблар әлендә (кулыннан) тугратмас өчен, бөек-бөек парәләр (акча) сарыф идеб, ун сәгать мөкаддәм (ягъни 10 сәгать үтүгә) ... дәфен итдермеш (күмдермеш)». М.Гайнуллин да әдипнең тууына 75 ел тулу уңае белән язылган мәкаләсендә (Совет әдәбияты.— 1945.— # 9.— 74—83 б.) шушы ук фикерне куәтли: «Язучының соңгы көннәре матур узмаган. Үзе әйткәнчә, башта тынычлану нияте белән куллана башлаган кәеф-сафасы (эчүе) һәм хатынының аңа карата хыянәте Заһир Бигиевне һәлакәткә алып килгән. 1902 елда үзенең түшәгендә хатыны тарафыннан үтерелгән».

Әдәбиятчы галим Шакир ага Абилов З.Бигиевкә багышланган радиотапшыруларның берсеннән соң болай диде: «Мин заманында Бохарада әмир архивында З.Бигиевкә мөнәсәбәтле кульязмалар белән кызыксындым. Әмма алар арасында «Катыйлә» белән «Мөртәд» юк иде. (Бу ике әсәрнең кульязмасын автор 1892 елда Ростов-Донга килгән Бохара әмире Габделәхәдкә биргән була.) Әйтүләренә караганда, Бохара әмире инкыйлабтан соң Әфганстанга кача. Шәхси китапханәсенең дә зур өлешен шунда алып китә... Мөхәммәд Гайнуллин 50 нче елның урталарында Ростовта була. З.Бигиевнең бик өлкән яшьтәге хатыны белән очраша (балалары булмый). Шундый сүз таралган була: имеш, хатыны З.Бигиевне мунчада үтерә. М.Гайнуллинга әдипнең хатыны бу версиянең дөрес түгеллеген әйтә. М.Гайнуллин Ростовта әдипнең каберен дә күрә. Бәлкем, фотосын да алгандыр. Соңыннан баручылар исә З.Бигиев каберен таба алмадылар. Үзенең Ростовка сәфәре хакында М.Гайнуллин Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми советында сөйләгән иде». Кайберәүләр З.Бигиевнең үз-үзенә кул салуы хакында язалар. Әдипнең Ростовта стачкалар вакытында христиан карагруһчылары тарафыннан кыйнап үтерелүе, эзне җую өчен, бу җинаятьне аның хатынына ябештерүләре хакында да (имеш, ул ирен агулаган) хәбәрләр бар (*М.В.Гайнутдинов*. Татарская литература XIX века...— Казань, 2000.— С. 82—83).

* * *

Әйткәнебезчә, З.Бигиевнең ике романы, бер сәяхәтнамәсе басылган. Әмма чыганаклар аның янә «Мөртәд» (диннән язган, иманын алыштырган; юньсез) һәм «Катыйлә» (үтерүче хатын-кыз) исемле романнар язуын да искәртәләр. Дөрес, Рәфыйк Нәфыйгов «Катыйлә»не «Гөнаһе кәбаир»нең беренче варианты дип саный. Ул Ленинград (С.-Петербург) Үзәк дәүләт архивында цензура комитетыннан кергән «Катыйлә хатын» әсәренең кульязмасын таба. (Бу текст цензурага 1889 елның 22 июлендә тапшырылган була.) Цензор авторның Инҗилдән өзекләр китерүен, аларны шик астына алуын искәртә һәм тагын башка сәбәпләр белән әсәрне басудан тыя. Шуннан З.Бигиев, романны төзәтеп, «Гөнаһе кәбаир» исеме белән бастыра (*Рәфыйк Нәфыйгов*. Җитмеш дүрт ел үткәч // Совет әдәбияты.— 1963.— # 5.— 142—144 б.). Бу — кызыклы караш. Әмма З. Бигиев үзе һәм аның энесе бу романнарны тәңгәлләштермиләр, аерым карыйлар. Һәм «Мөртәд», һәм «Катыйлә» 90 нчы еллар башында инде төгәлләнгән була. «Мөртәд» — «Гөнаһе кәбаир»нең дәвамы. «Катыйлә» хакында Муса Бигиев менә нәрсәләр яза: «Шу(л) әсәр... бөек бер мәһарәт илә (осталык белән) язылмышдыр, әсәрләре арасында иң беренчеседер. Бән ул «Катыйлә»дә Мәрьям ханым илә кызы Әсманың адәм күңеле тәхәммел итмәз (түзмәс) дәрәҗәдә дәһшәтләрене күреп, соңра «Сәфилләр»дә (Виктор Гюгоның «Хокуксызлар» романы күздә тотыла) Фантина илә кызы Козетта дәһшәтләрене укыдым. Шу(л) ике китап арасында гаять бөек бер мөнасибәт булдым (ягъни бәйләнеш күрдем). Белмәдем: Заһир әфәнде Виктор Һийуго җәнабләренең «Сәфилләр»ене «Казан романы» калыбында язмышмы? Яхуд кәндүсенең (үзенең) куәи шигъриясе илә... бер китап мәйданә чыкармышмы? Уйлә (ничек) улса да, бөйлә улса да, бәһре тәкъдир у(л) китап Заһир әфәнде намено (исеменә) һәрвакыт фәхер улачак (дан, шөһрәт китерәчәк) бер китапдыр. Бер кач сәбәбләр илә кәндүсенең хәятында (үзе исән чакта) тәбыг улынмады (басылмады). Инша Алла, ганкариб (тиздән, тиз көндә) тәбыг улыныр». Бу ике романның чыгачагы хакында «Китап» нәшрияты 1908 елда белдерүләр дә бастыра. Әмма, ни сәбәптәндер, ул китаплар дөнья күрми кала. Кульязмалары да юк. Монда кайберәүләр Муса Бигиевне дә гаеплиләр. Дөрес, ике туган арасы

соңгырак елларда киеренкерәк булганга охшый. (Биредә, әлбәттә, абыйсының эчүчелеккә бирелүе дә билгеле бер роль уйнагандыр.) Моны энесенең абыйсы хакындагы кереш сүзе дә сиздереп тора. Әмма шулай да без романнар нәшер ителмичә калуда Муса Бигиевне шелтәләргә җыенмыйбыз. Бәлкем, без белмәгән башка сәбәпләр булгандыр.

* * *

Заһир Бигиевнең әдәбиятка кергән еллары — татарның милли үзаңы уяну, тәрәккъыятенең җанлану чоры. Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Х.Фәезханов хезмәтләре халкыбызның тарихи офыкларын киңәйтте, Кандалый, Акмулла шигырьләре әби-бабаларыбызның рухи дөньясын баетты. XIX йөзнең икенче яртысында Шәрык телләреннән күпләгән әсәрләр тәрҗемә ителә. Рус, Европа әдәбиятлары белән кызыксыну көчәя. Госманлы сүз сәнгате биредә арадашчылык ролен дә үти. Исмәгыйль Гаспралы эшчәнлеге, бигрәк тә аның «Тәрҗеман» газетасы мәдәни үсешкә, мәгарифкә көчле этәргеч ясый. 80 нче елларда татар драматургиясе туа. Иҗтимагый-мәдәни вазгыять, рухи ихтыяҗлар нәкъ менә Муса Акъегетзадәнең тормышчан эчтәлекле, милли аһәңле, инсани фикерле «Хисамеддин менла» әсәрен (1886) тудыруга китерде. Аңа табигый рәвештә З.Бигиев романнары һәм сәяхәтнамәсе килеп кушылды. Гасыр азакларында бу башлангычны Р.Фәхреддин, Ф.Кәрими, Г.Исхакый һәм башка әдипләр уңышлы дәвам иттерде. Кыскасы, З.Бигиевнең әдәбиятка килүе һич тә очраклы хәл түгел, ә татар рухи үсешенең зарури бер буыны, баскычы иде. Кайбер авторлар аның рус, Европа әдипләреннән файдаланып язуын искәртәләр. Мәсәлән, Муса Бигиев «Өлүф...» романының «Погоня за миллионами» исемле рус әсәренә ияреп иҗат ителүен әйтә. Ф. Әмирхан да шул фикерне куәтли. «Бу романнарның һәр икесен дә,— ди ул,— мөэллиф (автор, язучы) рус әсәрләренә тәкълид итеп, бәгъзән дә бөтенләй рус типларын татар ясап чыгарадыр» (Әдәбиятка гаид // Әлислах.— 1908.— 8 сентябрь). М. Гайнуллин «Гөнаһе кәбаир» романының француз әдибе Эмиль Габорио (1832—1873) әсәрләреннән («Господин Лекок», «Преступление в Орсивале» һ.б.) файдаланылып язылуын ассызыклый (Совет әдәбияты.— 1945.— # 9.— 81б.). Күчеш чорында башка халыкларның әдәби казанышларына мөрәҗәгать итү, алардан теге яки бу дәрәҗәдә файдалану мәдәният тарихында табигый һәм гадәти хәл. Пушкинның Байрон иҗаты белән кызыксынуы да — шуның күркәм бер мисалы. Тәнзыймәт (реформалар) чорындагы госманлы әдипләре дә француз әдәбиятыннан шактый мул файдаланалар, үзләре әйтмешли, «франк каһарманнарын госманлаштыралар».

З.Бигиев эшчәнлегенең әһәмияте шунда: ул, үз халкының һәм башка кавемнәрнең эстетик казанышларына таянып, Муса Акъегетзадә белән берлектә, милләттәшләре кызыксынып укырлык, татар сүз сәнгатенең заманча үсешен билгеләрлек әсәрләр тудырды. Нәкъ менә шуңа күрә дә аларны шул чорда ук «яңа әдәби агымның җимеше» (Тәрҗеман.— 10.08.1890), «әдәбият бәһарыбызның (язының) иң әүвәлге чәчәкләре» (Тукай), татар телендә «роман диярлек әсәрләрнең әүвәлгеләре» (Ф.Әмирхан) дип атыйлар да.

«Бу романнарда,— ди Ф.Әмирхан,— камилән, татар тормышыннан алынган типлар [«бер-икене истисна белән» (исәпкә алмаганда)] юк дияргә мөмкиндер. Шулай да булса бу әсәрләрдәге типларны Заһир Бигиев, булачак мәгыйшәтне алдан сизенеп чыгарган шикелле, вөҗүдкә чыгарадыр. Муса вә хатынына (ягъни Маһруйга), җинаяте соңында да, гуманный мөгамәлә итеп гафу итә алырлык хөр фикерле татар (биредә Җиһангир образы күздә тотыла) менә бу көннәрдә генә вөҗүдкә килә башларлык типлардыр. Шулай итеп, бу романнар кыйсмән (өлешчә) безгә яз якынлашканын күрсәтә торган кышкы якты кояшлы көннәр булып хезмәт иткәннәрдер. Заһир әфәнде, әгәр гомере мөсагадә (мөмкинлек) иткән булса, бәлки дә бик үткен милли әсәрләр вөҗүдкә китергән булыр иде» (Әлислах.— 8.09.1908).

Әмма Ф.Әмирханның миллилек турында бу искәрмәләре бераз бәхәсле дә. Чөнки З.Бигиев романнарында, аеруча «Гөнаһе кәбаир»дә татар мәгыйшәте, татар рухы шактый тулы гәүдәләнеш тапкан. Мәсәлән, карт хәзрәтнең укырга китүче Габделгафурга биргән теләкләре тулысы белән ислам дине, милли гореф-гадәтләр рухында. «Һәлакәт юлы, яманлык вә кимлекнең башы һәм чыганагы — шул хәрам исерткечтер»,— диелә анда. Шулай ук карт «зур гөнаһлар»ның «аз-азлап башланып», аннан «күбәеп вә куәтләнеп» китүен искәртә. Мәгълүм ки, татарның бер өлеше элек-электән шәһәрләрдә башка халыклар белән аралашып яши. З.Бигиев шундый тормышны гәүдәләндергәндә, әлбәттә, милли персонажлар белән генә чикләнә алмый. Аның әсәрләрендә Муса, Габденнасыйр, Зөләйха образлары белән беррәттән, Андреев, Шубин кебек затларның да сурәтләнүе нәкъ шуның белән аңлатыла. Бу яктан автор XIX йөзнең икенче чирегендә иҗат иткән Гомәр Мөхәммәд углы традицияләрен дә дәвам иттерә. Романнарда аерым кимчелекләрнең булуы авторның яшьлеге, иҗади тәҗрибәсе җитмәү белән дә аңлатыла.

З.Бигиев — халкыбызның зирәк, гыйлемле вәкиле. Шуңа күрә ул нәрсә турында язса да, аны, иң беренче чиратта, үз милләтенең язмышы, хәле борчый. Автор үз халкын ярата, аны алдынгы, тәрбияле

итәсе килә. Әмма ул милләтпәрвәр булса да, үз халкына тәнкыйди күзлек аша да карый. Мондый алым алга таба Г.Исхакый, Г.Тукай, Ф.Әмирхан тарафыннан аеруча нәтиҗәле кулланылды.

З.Бигиевнең һәр ике әсәре дә детектив характерда, ягъни җинаять кылу һәм аны ачуга юнәлтелгән. Бу, бер яктан, укучыны мавыктыруны күздә тотса, икенче яктан, гадәти булмаган, киеренке шартларда кешеләрнең холык-табигатен, үз-үзен тотышын, үзгәләр белән мөнәсәбәтен тулырак ачарга мөмкинлек бирә. Шунысын да искә төшерик: З.Бигиев ахун гаиләсендә туып үскән, үзе дә шул вазифаны башкарган. Гадәттә, андыйларга шәһәр һәм округ судларында катнашырга, төрле җинаять эшләре белән танышырга туры килгән. Шуңа күрә автор андый вакыйга-хәлләрне шактый белеп тасвирлый.

Һәр инсан үз гамәле өчен үзе җаваплы. Бу әхлакый принцип — Урта гасыр һәм XIX йөз әдәбиятының төп сыйфатларыннан берсе, З.Бигиев өчен дә — ул катгый канун. Зөләйха, Габденнасыйр, Ягъкуб Галиев һәлакәтләрен, Габделгафурның төрмәгә эләгүен автор, иң беренче чиратта, аларның үзләренә бәйләп карый. Әмма З.Бигиев тирәлек, мохитнең дә кешегә тәэсир итүен аңлый, инсанны табигый яктан гына түгел, иҗтимагый-социаль мөнәсәбәтләр җимеше рәвешендә дә карый. Шунысы мөһим: автор кешенең үзгәрүенә, камилләшүенә ышана. Маһруй, мәсәлән, үз гамәлләре өчен җәзага тартыла, газаплар кичерә, тәүбә кыла, «кабат терелеп», рухи яктан пакьләнә.

З.Бигиев тугрылыкны, әхлакый сафлыкны, иманлылыкны яклый, эчүчелекне, икейөзлелекне, җинаятьчелекне, фәхешлекне кискен тәнкыйть итә. Татар әдәбиятында алга таба төп проблемаларга әверелгән мәсьәләләрнең бер өлеше «Өлүф...»тән, «Гөнаһе кәбаир»дән яисә алар аркылы юл ала.

З.Бигиевнең «Мавәраэннәһердә сәяхәт» язмасы татарның һәм әдәбияты, һәм публицистикасы, һәм гомумән рухи тормышы өчен аеруча әһәмиятле. Ул, бер яктан, авторның өлгергән шәхес икәнлеген, күңел дөньясын күрсәтсә, икенче яктан, тарихның, сәясәтнең гыйбрәтле сәхифәләрен ачып бирә. З.Бигиев моңа кадәр татар табынып яшәгән Төркестанның мәгълүм сәбәпләр аркасында гадәттән тыш артта калуын, андагы кавемнәрнең хокуксызлыгын тасвирлый. Сәяхәтнамәдә патша хөкүмәтенең традицион колониаль сәясәте, аның рәхимсезлеге күрсәтелә.

«Мавәраэннәһердә сәяхәт» — әдипнең җәмгыять, тормыш, мәдәният, милләт турында уйлануларының бер хисабы, килер буыннарга бер васыяте.

* * *

Мәгълүм ки, Тукай — тәнкыйди рухлы шагыйрь. Аның мактавына, хөрмәтенә бик сирәк затлар гына лаек була: Мәрҗани, Ямашев... Шундыйлар арасында Заһир Бигиев тә бар. Бу күп нәрсә хакында сөйли. Тукай «Төшемдә күргәннәрем» исемле язмасында (1908) әдипне «ахирәттәге сарайда» күрүен искәртә. Имеш, ул сарайның диварларына, идән-түшәмнәренә алтын хәрефләр белән әдипнең әсәр исемнәре язылган.

Тукай «Мавәраэннәһердә сәяхәт» язмасын кульязма хәлендә үк укып чыга һәм, шуннан илһамланып, үзенең мәшһүр «Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә» дигән мәрсиясен яза. Бу шигырь «Мавәраэннәһердә сәяхәт»нең тәүге басмасында (1908) алгы өлештә үк урнаштырыла.

...Гәрчә «үлде» дисәләр дә, син бөтенләй үлмәдең;
Яхшы исмең калды, син мәнсийү мәтрүк улмадың
(онытылып калмадың).

...Иртәрәк милләтне сәүкайлар (сәвык өйләр — алга әйдәр)
идең чын эзгә син!
Нинди гали (бөек), нинди зур эш эшләр идең безгә син!

Шунда да исмең синең милләт яшәдекчә яшәр,
Милләт үсдекчә үсәр һәм милләт ашдыкча ашар (югарыга).

Бөек Тукайның мондый бәясенә лаек булган Заһир Бигиев,— чын мәгънәсендә, бәхтияр әдип. Аның әсәрләре даими укыла, исеме милләт белән бергә «аша», ягъни бергә бара, бергә яши.

*2000*

## ТУКАЙ БЕЗНЕҢ БЕЛӘН

Апрель — гадәти ай гына түгел, ул табигатьнең сыйфади үзгәреш вакыты, яшәеш-тереклекнең гадәттән тыш җанлану, алга омтылу көннәре дә. Апрель безнең өчен, тәнендә татар йөрәге типкән адәм балалары өчен, аеруча якын һәм үз. Чөнки ул безгә бөек Тукайны бүләк итте. Тукай исә безнең рухыбызны кузгатты, зиһенебезне баетты, гасырларны, буыннарны ялгап, милли яшәешебезнең кыйбласын, киләчәген билгеләде. «Тереклек — капма-каршылыклар берлеге» дип юкка гына әйтми торганнардыр. Апрель безнең өчен куанычлы, нурлы ай гына түгел. Ул татар кавеме өчен моңсу, сагышлы ай да. Чөнки Апрель безне Тукайдан мәхрүм итте: олуг шагыйрьнең кечкенә генә җәсәде нәкъ шушы айда җир куенына иңдерелде.

Тукайның яз фасылында вафаты да мәгънәле, символик. Мәгълүм ки, адәм балаларының һәммәсе туфрак була, табигатьнең яшәешенә үзеннән өлеш, аш кертә. Тукай да нәкъ менә Апрельдә — табигатьнең шытым биргән, татарның кузгалган чагында туфрак була, үзенең үлеме белән дә тереклеккә хезмәт итә, иҗаты белән генә түгел, тәне белән дә татар тәрәккъыятен азыкландыра.

Еллар искән җилләр, аккан сулар кебек уза да уза. Инде менә шагыйрьнең тууына 115, үлеменә дә 88 ел үтеп китте. Шушы вакыт эчендә дөньяда, тормыш-мәгыйшәттә әллә никадәр үзгәрешләр, яңалыклар, шатлык-фаҗигаләр булды: империяләр җимерелү, яңадан-яңа дәүләтләр корылу, бөтендөнья сугышлары, атом-төш энергиясен файдалану, галәмгә очышлар, компьютер-интернетларның гамәлгә керүе һ.б. Әмма шагыйрь үзе үлсә дә, еллар узса да, Тукай иҗаты һич тә искермәде, һич тә үзгәрмәде, ул һаман да безнең белән, хәтта бездән, заманнан алдарак та әле. Ни өчен? Чөнки Тукайның кодрәтле таланты кешенең табигате, инсанның рухы һәм психологиясе өчен хас булган уй-кичерешләрне, типологик сыйфатларны үзенчә, оригиналь ысул-чаралар һәм стиль ярдәмендә гәүдәләндереп калдырды. Шагыйрьнең көчле эчке энергиягә ия булган ялкынлы, күп сыйдырышлы шигырьләре һәр чор, һәр буын укучыларын сохбәт-әңгәмәгә тартып тора, катализатор кебек, кешеләрнең күңел дөньясын кузгата: уйландыра, көлдерә һәм елата, иң мөһиме — битарафлык-гафләт йокысыннан уята.

Тукай,— гәрчә ул күбебезнең энесе, улы яшендә якты дөньядан китсә дә, татар кавеме өчен үз чорында да, хәзер дә иң абруйлы остазларның берсе. Искә төшерик: шагыйрь —энциклопедик Ризаэддин Фәхреддиннәр, ислам дөньясының мәгълүм заты Муса Бигиевләр, Сорбонна университетын тәмамлаган Йосыф Акчура һәм Садрый Максудыйлар чордашы. Ә бит бу мәшһүр адәмнәр Тукай исән вакытта ук аның бөек талантын таныйлар, аны хөрмәт итәләр.

Шагыйрьнең һәм шәхесе, һәм иҗаты — бүген дә үтә гыйбрәтле сабак. Бездә «Тукай укулары» дигән гыйбарә, чара соңгы вакытта бик активлашып китте. Бу гадәти гыйльми-педагогик төшенчә, мәдәни чара гына түгел, ә бөек шагыйрьнең киңәш-теләкләрен тыңлау, аның яшәү, фикерләү, хис итү, кичерү рәвешенә төшенү, әдип идеаллары белән бүгенге теләк-максатларыбызны үзара мөнәсәбәттә карау, чагыштыру, әдәбиятыбызның, телебезнең язмышы хакында уйлану дигән сүз дә.

Тукай — инсаниятькә, халыкка соңгы сулышына кадәр хезмәт итүнең, милли мәнфәгатьләр өчен фидакарьләрчә көрәшүнең классик үрнәге. Ул Ходай Тәгалә тарафыннан үзенә бирелгән гомерне метеор кебек янып, яшен кебек яшьнәп уздырды.

Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,  
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;  
«Без китәрбез, сез каласыз!»— дип җырлармын,  
Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә.

Бу шигырь — хыял җимеше, гадәти тезмә-мисраглар гына түгел, ә шагыйрьнең яшәеш шигаре, иҗат кредосы. Тукай бу вөҗдани антына ахыргача тугрылыклы калды, аны намус белән үтәде. Игътибар итик: шагыйрь «Без китәрбез, сез каласыз!»— ди. Автор гомернең фанилыгын, үлемнең котылгысызлыгын белә, әмма моны табигый хәл дип кабул итә! Аның өчен «сез»ләр, «калучы»лар, аларның яшәеше, мәнфәгате, киләчәк мөһим.

Һәр инсан бәхетле, тулы канлы тормыш өчен яратылган. Бу хосусият адәм баласының табигатенә тумыштан ук салына. Шагыйрь фикеренчә, кешенең «матлабы гали», ягъни теләк-максаты бөек, күңеле тумыштан ук «гарше әгъляләргә» (биеклеккә) җилкенеп тора. Әмма дөнья мәкерле, анда «мәлгунь... кара көчләр» бихисап. Автор өчен күңел сафлыгын саклап, «инсанлыгыңны җуймыйча», «һәр көн, һәр сәгатьтә яхшырып» яшәү барыннан да кыйммәт.

Мәгълүм булганча, төрки-татар дөньясында шагыйрь сүзе элек-электән югары бәяләнгән. Йосыф Баласагунлының мәшһүр «Котадгу белек» әсәрендә (1069) мондый юллар бар (тәрҗемәдә): «Кылычтан үткенрәк боларның (ягъни шагыйрьләрнең) теле, Янә кылдан нечкәрәк хәтер юллары... Алар мактасалар, мактаулары илгә таралыр, Әгәр сүксәләр, (кешенең) яман аты калыр». «Тәхет-таҗдан да сүз кыйммәт-

ләрәктер»,— ди XIV йөз шагыйре Котб. Тукай да, борынгы традицияләрне дәвам итеп, шигъри сүзнең дәрәҗәсен, иҗтимагый яңгырашын тагын да арттырды, аның кылыч та, дәва да булуын үз иҗаты белән янә бер мәртәбә раслады.

Тукайның мирасына мөрәҗәгать итсәң, исең-акылың китәрлек! Кыска гына иҗат гомерендә әдип гаҗәеп күп һәм кыйммәтле хәзинә калдырган. Аның мирасы өчен идея-тематик байлык, жанр, аһәң төрлелеге хас. Шагыйрь чор заруриятен, заман сулышын бөтен барлыгы белән тоеп яши. «Һәр минут миннән тели дөнья күңел җимешләрен»,— дип, автор үзе дә бу хакта искәртә. Шунысы мөһим: Тукай үз иҗатының нәтиҗәлелеге, иҗтимагый яңгырашы хакында да җитди уйлана: «Җырлыймын, ләкин җырымнан файда бармы халкыма?» дигән сорау аның күңеленнән һич тә китми.

Тукай — инсаннарның, милләтләрнең, илләрнең хөрлеге, иминлеге, бәхет-сәгадәте тарафдары. Аның «Иң бөек максад безем: хөр мәмләкәт — хөр Русия!» дигән сүзләре бүген аеруча актуаль яңгырый.

Тукайның мөһим бер үзенчәлеге шунда: ул нәрсә хакында язса да, аны татар рухы, татар язмышы аркылы бирергә тырыша: «Чорт белә,— ди ул бер язмасында,— мин ахырысы сөюдә дә милләтче!.. Мин татар кызының телен, сөйләшү рәвешен яратам». «И каләм» шигырендә аның мондый сүзләр бар: «Бакма һич кәс (һичкемнең) хәтеренә, милләтнең дәрденә (авыруына) бак!»

Тукай — татарның бөек, тиңсез шагыйре. Әмма ул кайбер башка, иң беренче чиратта, тугандаш төрки кавемнәр өчен дә үз һәм кадерле. Казакъларның күренекле әдибе Габиден Мөсрепов болай ди: «...без казакъ язучылары Габдулла Тукайны, Абай кебек үк, үзебезнең гомуми элгәребез дип саныйбыз». Төрекмән халкының билгеле прозаигы Бирде Кербабаев Тукайны һәм Ибраһимовны үзенең «чын остазлары» дип атый.

Тукай — шагыйрь генә түгел, ул — публицист һәм журналист, тәнкыйтьче, фольклорчы, тәрҗемәче, сәясәтче, педагог та. Боларның һәммәсендә Тукай үзенең саллы сүзен әйткән, «гүзәл эзен» калдырган. Аның мирасы, заманга аваздаш булып, бүген дә яши, бүген дә уйландыра. Тукай — Рәсәй киңлекләренә, дөнья кыйтгаларына сибелгән татарны туплап, бербөтен итеп тотучы көч тә. Шуңа күрә аның әсәрләрен уку, белү, күңел хәзинәсе итү — һәр татарның вөждани бурычы.

*2001*

**ТУКАЙ САБАКЛАРЫ**

Бөек шагыйрьнең якты дөньяны ташлап китүенә бер елдан 90 ел тула. Шушы вакыт эчендә җиһан, җәмгыять, тормыш шактый үзгәрде, башка да китереп булмаган никадәр фәнни-техник ачышлар ясалды! Телевидение, компьютерлар, галәмгә очу гадәти күренешкә әйләнде. Әмма чынбарлыктагы үзгәрешләрнең, ачыш-яңарышларның төп сәбәпчесе, әйдәүче көче булган кеше үзенең төп асылын һаман да саклап калды: ул һаман да табигый эш-гамәлләрен, теләк-ихтыяҗларын үти, һаман да сөя-сөелә, гаилә кора, эшли, алдый-алдана… Шушындый ук сыйфади даимилек, чагыштырмача тотрыклылык адәми затларның кавем, милләт, мәмләкәт кебек берәмлекләренә дә хас. Нәкъ менә шуңа күрә дә инсанның рухын төшенеп, халык яшәешенең пульсын тоеп иҗат ителгән әсәрләр, еллар узуына да карамастан, һич тә искерми, буыннан буынга яшәвен дәвам итә. Тукай — әнә шундый ядкярләр авторы.

Мәгълүм ки, туры һәм үткен сүзле, хәтта вакыты белән ачы телле Тукайның дуслары гына түгел, дошманнары, хәзерге термин белән әйткәндә, оппонентлары да күп була. Аны төрлечә түбәнсетергә, кимсетергә омтылалар. Бу хакта шагыйрьнең үзе тарафыннан әйтелгән әрнүле юллары да бар:

Күп «җыланнар» сызгырып читтән карыйлар бәхтемә,
Борла-сырла, бәдбәхетләр, үрмәлиләр тәхтемә…
… Үзләре… сүздән түбәннәр, күзләре тездән түбән;
Эт кеби һаулап ялманып, күз йомалар яхшыма…

(*«Дошманнар»*)

Әмма кечкенә гәүдәле авыру Тукай теләсә нинди шартларда да пәһлеван кебек курыкмыйча алга баруын дәвам итә:

Кирәк баймы, фәкыйрьме, падишаһмы — күрсәтәм гайбен;
Укыйм ялкынлы аятьләр — карау юк һичберәү кәйфен.
Керештем мин мәхәббәткә, карендәшлеккә өндәргә,
Ашамый, эчми көндез, кич белән баш куймый мендәргә…

(*«Пигамбәр»*)

Бу изге, әмма гаять кыен көрәш юлында шагыйрьнең, үзеннән кала, ике таянычы бар: берсе аның — Алла, икенчесе — халык.

…Түкмә күз яшь: ярдәмеңдә һәр заманда Алла бар;
Ал җәсарәт (батырлык), алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!

(*«Киңәш»*)

…Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем.

(*«Дошманнар»*)

Туган кавеме Тукайны шагыйрь исән чакта ук үзенең бөек җырчысы итеп таныды. Аннан соңгы бер гасырлап вакыт эчендә дә әдип һәм халык сохбәтләшеп бергә яши. Яшь кенә Тукай, олуг остаз кебек, милләттәшләренә тормыш сабаклары бирә, аларны чын инсаннарча яшәргә өйрәтә. Әмма, кызганыч ки, безләр еш кына шагыйрьнең киңәш-теләкләренә тиешенчә колак салмыйбыз, шуның нәтиҗәсендә шәхесебезгә, милли барлыгыбызга күп кенә зыян да китерәбез. Безгә Тукайга хас тугрылык, кыюлык, тәвәккәллек җитми. Табигатебездә, эш-гамәлләребездә, тормышыбызда, язганнарыбызда шагыйрь сөймәгән нәрсәләр буа буарлык. Кайвакыт шулар хакында уйланып: «Их, Тукай булса!»— дип ачынып куясың.

Тукай — мең еллык татар әдәби казанышларын иҗади дәвам иттерүче, үстерүче, баетучы. Йосыф Баласагунлы, Кол Гали, Котб, Харәзми, С. Сараи, Мөхәммәдьяр, Акмулла кебек, ул да сүз сәнгатен инсанны, кавемне тәрбияләүдә, җәмгыятьне әхлаклы итүдә көчле корал, җитди чара итеп карый. Әдәби иҗат — шагыйрь өчен тулы канлы яшәүнең төп формасы, гомер итүнең асыл мәгънәсе.

Шигъреми яздым; басылды; мин тагын зур кайгыда;
Фикремә юк-бар белән исмемне игъланым килә.

Һич риза булмыйм үземнән, язганымнан соңра мин;
Һәр заман күз алдыма кимлек вә ноксаным килә.

Кайвакытлар һәр сәгадәттән өмидемне өзәм,—
Әллә кайдан шунда икъбал (өмет, бәхет; илһам) атлы

чулпаным килә.

Ялтырый ул күкләремдә, күп өмидләр арттыра:
Күз яшем сөртергә гүя назлы җанашым килә.

(*«Тәрәддед вә шөбһә»*)

Апрель ае — Тукай ае. Ул — бөек шагыйрьне тудырган һәм теге дөньяга алып киткән ай. Татар халкы үзенең җырчы улын һәрчак күңел түрендә тота. Әмма апрельдә Тукайга булган җылы мөнәсәбәт, ихтирам хисләре тагын да көчәя. Бу айда күп төрле чараларның уздырылуы — шуның ачык мисалы. Апрельдә Язучылар берлеге, Тукай музее, Тукай җәмгыяте вәкилләре, укытучылар бөек шагыйрь каберенә зиярәт кыла, татарның мәшһүр әдибенә үзләренең хөрмәт хисләрен белдерә, бу айда Тукайга багышланган Республикакүләм фәнни-гамәли конференцияләр үткәрелә, ә 26 апрельдә — традицион Тукай бәйрәме.

Тукай көннәре уңае белән радио-телевидениедән махсус тапшырулар, мәдәният учакларында төрле чаралар үткәрелә. Көндәлек матбугат та бөек шагыйрь тематикасына даими урын бирә.

Бүгенге «Тукай укулары» — бөек әдипне искә алуның мөһим чараларыннан берсе. Аның инде дистә еллап тарихы бар. Галимнәр, әдипләр бу көнне үзләре башкарган эшләре хакында Тукай алдында хисап тоталар, алга бурычлар билгелиләр. «Тукай укулары»нда сөйләнгән доклад-чыгышларны аерым җыентык рәвешендә бастыру да гамәлгә кереп бара. Яңа гасыр башында шагыйрь, аның элгәреләре, даирәсе, традицияләре һәм гомумән Тукай хакында шактый гына әдәби әсәрләр, мәкалә-хезмәтләр, китаплар язылды. Шагыйрьне гыйльми өйрәнүгә һәм әдәби үзләштерүгә гаять зур өлеш керткән Ибраһим ага Нуруллинның «Моңлы саз чыңнары» исемле китабы Татарстан китап нәшриятында кабат басылып чыкты. Заһир Шәйхелисламовның «Аңлыем дип шагыйрь җанын…» дигән монографиясендә (Казан: Фикер, 2001.— 144б.) Әхмәт Фәйзи иҗатында зур урын тоткан Тукай тематикасы яктыртыла. Китап бай эчтәлекле. Анда архив материаллары мул файдаланылган. «Раннур» нәшрияты чыгарган «Габдулла Тукай» китабы да (Казан, 2001.— 383 б.— Төзүчесе Н.Газизова) — укучылар һәм укытучылар өчен файдалы җыентык. Анда шагыйрь иҗатыннан үрнәкләр, фәнни-методик материаллар тупланган.

2002 елда Казан дәүләт университеты татар филологиясе һәм тарихы факультетының 2001 ел өчен «Фәнни язмалары» нәшер ителде (Казан: Школа.— 336 б.). Анда, башка материаллар белән беррәттән, шагыйрьгә мөнәсәбәтле мәкаләләр дә бар (*Таһир Гыйлаҗев*. Габделбари Баттал һәм Тукай; *Диләрия Абдуллина*. Тукайның дини эчтәлекле шигырьләре: басылу тарихы һ.б.). Шушы ук җыентыкта һәм «Казан утлары»ның быелгы беренче санында безнең «Тукай турында Исхакый кызы», „Яңа милли юл» журналы һәм Тукай» мәкаләләре, Сәгадәт Чагатай, Солтан һәм Хөсәен Габдүшнең шагыйрь хакындагы язмалары бар.

Мәгълүм ки, Нәваи, Пушкин, Абай кебек классиклар турында йөзәрләгән диссертацияләр язылган. Тукайга багышланганнары исә бер дистәгә дә тулмый: бер докторлык диссертациясе (*Г.Әмиров*. Тукайның теле), калганнары кандидатлык диссертацияләре (Я.Агишев, И.Нуруллин, Ю.Туишев, Р.Башкуров, Р.Ганиева, Ю.Вәлитова, Н.Лаисов, А.Җамалетдинов…). Шунысы куанычлы: соңгы вакытта Тукай турында бу төр хезмәтләр әзерләү активлашты. 6 майда Казан университеты Советында Зөфәр Рәмиев «XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм текстология мәсьәләләре» темасына докторлык диссертациясе якларга ниятли. Бу хезмәтнең төп өлешен Тукай эшчәнлеге, аның әсәрләрен текстологик тикшерү алып тора. Мәсәлән, диссертант Тукайның 64 ачык һәм яшерен имза белән басылуын ачыклый. Яшь галимә Нурфия Гафиятуллина профессор Т.Галиуллин җитәкчелегендә «XX йөз татар поэзиясендә Тукай образы» темасына кандидатлык диссертациясе язды һәм аны 13 майда якларга җыена. Хәзерге вакытта да берничә аспирант тарафыннан Тукай белән бәйләнешле диссертацияләр әзерләнә.

Шагыйрьнең тууына 115 һәм 116 ел тулу аралыгында Тукайга теге яки бу дәрәҗәдә мөнәсәбәтле әдәби әсәрләр дә туа торды. Ишетүемчә, Ренат Харис яңа поэмасын төгәлләгән. Иң өлкән язучыларыбызның берсе Сафа ага Сабиров «Казан утлары»ның узган елгы 10 нчы санында «Алтын балдаклы абыстай» дигән кызыклы гына повестен бастырды. Анда Тукай образы да гәүдәләнеш тапкан.

Тукай музее — элек тә, хәзер дә шагыйрьнең иҗат мирасын туплауда, пропагандалауда үзенә күрә бер мәркәз, штаб булып килде һәм килә. Музей коллективы гаять күп төрле һәм файдалы чаралар үткәрәләр. Бүгенге «Тукай укулары»ның музей бинасында узуы да күп нәрсә хакында сөйли.

* * *

Яңадан 4 елдан, ягъни 2006 елда, Тукайның тууына 120 ел тула. Алдагы елда исә шагыйрьнең вафат булуына — 90 ел. Бу истәлекле даталар галимнәрдән, мәдәният әһелләреннән, хакимияттән һәм гомумән җәмәгатьчелектән максатка юнәлтелгән системалы эшчәнлек таләп итә. Хөкүмәтнең махсус карарын чыгару да соралып тора.

Безнең фикеребезчә, Тукайның 120 еллыгына шагыйрь әсәрләренең тулы һәм гыйльми басмасын чыгару зарур. Чөнки әдипнең соңгы бишенче басмасы моннан ике дистә еллар элек дөнья күрде. Беренчедән, ул хәзер күпләрдә юк. Икенчедән, анда шагыйрьнең барлык язмалары да урын алмаган. Өченчедән, Тукайның тормышына һәм әсәрләренә шәрех-аңлатмалар шактый тулыландыруны, камилләштерүне сорый.

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Тукай энциклопедиясе әзерләнү күпләргә мәгълүм. Әмма бу катлаулы һәм изге эш соңгы вакытта, ничектер, бераз сүлпәнәйде. Бәлкем, бу эшне оештыруның һәм башкаруның махсус даими төркемен төзергә кирәктер?! Энциклопедия хәзерләүне Казанның мең еллык программасына кертү дә нәтиҗәле булыр иде.

Тукай хакында төрле мәкалә-хезмәтләр шактый. Хәзер шулардагы казанышларга нигезләнгән, чор ихтыяҗларына җавап бирерлек, күләмле, масштаблы монографик тикшеренүләр, докторлык диссертацияләре соралып тора.

Әгәр дә татарның мең еллык әдәби тарихы булмаса, әгәр XX йөз башында Исхакыйлар, Ибраһимовлар, Гафурилар, Әмирханнар иҗат итмәсә, шагыйрь Тукай була алмас иде. Шуңа күрә шагыйрь иҗатын әдәби-тарихи, фәлсәфи-эстетик контекстта, чынбарлыкка туры килешле бәйләнешләрдә тикшерү зарури. Тукайның башка халыклар һәм әдәбиятлар, бигрәк тә төрки дөнья белән бәйләнешләре да хәзерге гыйльми фикер югарылыгыннан яктыртуны көтә.

Юбилейга әзерлек көннәрендә Тукайга мөнәсәбәтле яңа әсәрләр, спектакльләр, кинофильмнар туар, альбомнар төзелер дип ышанасы килә. Иң мөһиме,— әлбәттә, Тукай әсәрләрен даими рәвештә халыкка, иң беренче чиратта, яшь буынга җиткерү, милләттәшләребезне шагыйрь, аның фикер-хисләре рухында тәрбияләү.

*2002*

## ТУКАЙ ҺӘМ ШӘРЫК ӘДӘБИЯТЫ

Тукай һәм яз[1]. Тукай һәм Апрель. Бу төшенчәләр, ничектер, үзара бик якын һәм табигый бәйләнешле. Бөек шагыйрьнең яшәү вакыты да татар милләтенең уяну, язгы ташкындай шаулы чорына туры килде. Биредә халык кына түгел, Тукай да гавамны кузгатуга үзеннән зур өлеш кертте. Мәшһүр әдипнең шигъри юллары да яз кебек саф, яз кебек ашкынулы, дәртле, куәтле. Җаны булган адәм баласын алар һәрчак яшәешкә, тулы канлы тормышка өндәп, чакырып торалар. Галәмдә яз барда, тереклек, хәрәкәт бар, Тукай шигырьләре барда, алар укылганда, алар яңгыраганда, татарның үзе һәм теле бар. Яз, татар, Тукай — бербөтен, аерылмас төшенчәләр.

Тукай — татарның чын мәгънәсендә милли, халык шагыйре. Иҗатының башлангыч чорында ук язылган «Милләткә» шигырендә автор болай ди:

Җөмлә (барлык) фикрем кичә-көндез сезгә гаид
(сезнең хакта), милләтем;

Сыйххәтеңдер — сыйххәтем һәм гыйлләтеңдер — гыйлләтем
(Саулыгың — минем саулык, авыруың — минем авыруым).

Сән Мөкаддәс, мөхтәрәм гыйндемдә (каршымда) варлык
нәрсәләрдән;
Сатмазым бу кяинатә милләтем, миллиятем
(Милләт һәм милләтне сөюемне дөнья бәрабәренә дә сатмам)[2].

Әмма Тукай — бер үк вакытта бөтен инсаният шагыйре дә. Ул, гомумән, кеше, аның уй-кичерешләре, кайгы-шатлыклары, рухи халәте хакында татар тоемы аша җырлады. Шагыйрьнең идеалы — җирдәге инсаннарны бәхетле, сәгадәтле, хөр итү, аларны кеше исеменә лаеклы дәрәҗәдә яшәтү, адәм баласын кимсетү-рәнҗетүләрдән саклау. Әдип фикеренчә, инсанның җаны «яратылышында ук бөек» [«Юк! Түбән калмас бу җан: фитьрәттә гали булган ул».— 1 т., 161 б.]. Нәкъ менә шуңа күрә дә Тукай татар өчен генә түгел, башка кавемнәр өчен дә үз һәм якын. Миңа үз гомеремдә Тукай шигырьләрен яттан белгән башкорт, казакъ, үзбәк, кыргыз, төрек, таҗик, комык һәм кайбер башка кавем зыялылары белән дә очрашырга туры килде. Әмма, ни кызганыч, әле без бөек шагыйребезне татарның һәм үзенә, һәм башка халыкларга җиткерү юнәлешендә йомшак эшлибез.

* * *

Мең ел ярымлык төрки-татар поэзиясендә әдәбиятыбызга зур өлеш керткән шагыйрьләр берничә йөздән артык. Әмма алар арасында Тукайга тиңләшерлекләр мөгаен юктыр. Булса да, берничә генәдер.

Кечкенә Апушның олуг һәм тиңсез шагыйрь дәрәҗәсенә ирешү сәбәпләре нәрсәдә соң? Моңа кырт кистереп, бер генә төрле җавап бирү мөмкин түгел. Чөнки Габдулланың шагыйрь Тукай булуында берничә сәбәп, фактор, алшарт бар. Иң беренчесе һәм иң мөһиме,— әлбәттә, шагыйрьнең гадәттән тыш көчле һәм табигый талантка ия булуы. «Вакыт» газетасы 1906 елның урталарында ук (27 июль) инде Тукай турында: «... табигый бер шагыйрь идеке хакында шөбһәбез калмады», «милли шагыйрьләремезнең даһиларыннан улачагына өмид итәбез...» — дип язып чыккан иде[3]. Тукайның шәхси менталитеты, фикерләве, үз-үзен тотышы, хис итүе — бар да үзенчә, кабатланмас. Ул — хәтта публицистикасында, гадәти язмаларында да шагыйрь. Шигъри талантны аңа Ходай Тәгалә мул итеп биргән.

Һәммә нәрсәдә дә отып булмый. Бер нәрсәдә отасың икән, икенчесендә, гадәттә, оттырасың. Бу — яшәеш кануны. Тукай туганнан алып үлеменә кадәр матди кыенлыклар кичереп, гади генә уңайлыклардан да мәхрүм булып яшәде. Шагыйрьнең үзе әйтмешли, «азмы какканны вә сукканны» күтәрә ул (2 т., 229 б.): сабый чакта ук ата-анасыз калу, ягъни үксезлек, ятимлек; кулдан кулга, бер төбәктән икенчесенә күчеп йөрү; үпкә чире; «Болгар» кунакханәсенең кунакчыл булмаган шыксыз бүлмәләре; нахакка рәнҗетелүләр, урынсыз гайбәтләр һ. б. «Ни эшлим, асылым-нигезем кайгы-хәсрәткә корылган; Яратылыштан ук кайгы-хәсрәткә батканмын, ни эшлим?» (1 т., 292—293 б.); «Ник мине шат итмәдең, ник кайгы юлдашы иттең? Әллә кайгы диңгезенең башы да, ахыры да миндәме?» (1 т., 330—331 б.) — ди шагыйрь бу хакта үзе дә. Әмма тормыш газаплары, кайгы-хәсрәтләр Тукайны курыкмаска, көрәшергә, шәхси бөтенлеген сакларга өйрәтте. Кыйналган саен, ул рухи яктан тагын да чыныга, үсә барды, шигъриятендә һәм публицистикасында үзенең уй-кичерешләрен, симпатия-антипатияләрен тагын да ачыграк, тагын да тулырак гәүдәләндерә килде. «Күңел йолдызы» шигырендә аның мондый юллар бар: «Ничаклы изсә дөнья, ирке бар — куркытмыйдыр безне; Елар җирдә көләм мин, һич чытып тормыйм аңар йөзне» (2 т., 62 б.).

Тукай атаклы Сорбонна, Истанбул уку йортларында белем алмаса да, Горький кебек, тормыш университетларының «тулы курсын», хәтта артыгы белән узды. Биредә аның мөгаллимнәре, остазлары халык булды. Шагыйрьнең табигый талантын үстерүгә фольклор, җыр сәнгате зур йогынты ясады. Аның җырчы да булуы халыкның күп гасырлар буе тупланып килгән моңын бөтен күңеле, җаны белән тоярга, кичерергә, зиһенен хисләндерергә булышты.

Тукай — мулла, рухани улы. Гыйлем-мәгърифәткә омтылыш, мәхәббәт аның канына, нәсел кодларына сеңгән. Мөгаен, шуңадыр да ул бик яшьли укырга, язарга өйрәнә, китапны гомере буе үзенең юлдашы, сердәше итә. «Китап» шигырендә автор кайгылы, эч пошулы вакытларында кулына китап алуын, укудан күңел тынычлануы табуын юкка гына язмый.

...Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем
Була минем юл күрсәткүче йолдызым;
Сөйми башлыйм бу дөньяның ваклыкларын,
Ачыладыр, нурланадыр күңлем, күзем.

Җиңелләнәм, мәгъсумланам (сафланам ) мин шул чакта,
Рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка;
Ышанычым арта минем үз-үземә,
Өмид берлән карый башлыйм булачакка
(2 т., 44 б.).

Истәлекләрдән, шагыйрьнең үзе язганнардан аның һәрчак укуы, хәтеренең гадәттән тыш яхшы булуы аңлашыла. Тукайның, шул дәвернең күп кенә зыялылары кебек, мәдрәсәләрдә төпле гыйлем алуын да онытырга ярамый.

Шагыйрь, гәрчә авылда туса да, күп кенә татар әдипләреннән үзгә буларак, гомеренең төп һәм мәгънәле өлешен шәһәрдә уздыра. Мәгълүм ки, кала тормышы инсанның интеллектуаль, профессиональ үсешенә уңай йогынты ясый, билгеле бер шартлар тудыра. Казан һәм Җаек (Уральск) — татар тормышы һәм мәдәниятенең, рус культурасының мөһим үзәкләре. Тукай ул мөмкинлекләрдән шактый нәтиҗәле файдалана. Аеруча Җаекта яшәү елларында русча газета-журналларны, китапларны күпләп укый, рус дөнья классикасы белән билгеле бер дәрәҗәдә таныша.

Шагыйрьнең яшәү вакыты да җәмгыятьтәге кискен үзгәрешләр, мөһим вакыйгалар чорына туры килде: рус-япон сугышы; беренче инкыйлаб; җәдитчелек, демократия, азатлык хәрәкәтләре; татарда вакытлы матбугатның тууы һәм ныклап үсеп китүе; театрның мәдәни тормышта урын алуы; татар китапларының күпләп басылуы; мәгариф системасында үзгәрешләр, тел-әдәбият укытуга игътибарның гаять көчәюе; милләттәшләребезнең үз мәктәп-мәдрәсәләрендә генә түгел, ә рус, чит ил уку йортларында да белем алуы, гарәп, фарсы, төрек телләрен генә түгел, рус, француз, немец, инглиз телләрен белергә дә омтылышның артуы; халыкара, илара икътисади, мәдәни бәйләнешләрнең активлашуы һ.б.

Тукай татар сүз сәнгатен, рус классикасын яхшы белгән. Шагыйрьне Тукай итүдә, башка факторлар, сәбәпләр белән бергә, Шәрык рухи хәзинәләре, Көнчыгыш классикасы да мөһим роль уйнаган, җитди алшарт булып торган.

* * *

Тукай,— иң беренче чиратта, һәм тумышы, һәм яшәеше белән традицион милли рухлы, ислам дине тәрбиясе алган зат. Бу аның бөтен эш-гамәлендә, тереклек күзәнәгендә ачык сизелеп тора. Мәгълүм булганча, Октябрьгә кадәрге татарның рухи тормышы, яшәү рәвеше шактый дәрәҗәдә Шәрык белән бәйләнешле. Бу аеруча түбәндәгеләрдә ачык күренә: ислам диненең киң таралышы; мөселман рухлы мәктәп-мәдрәсәләр, гореф-гадәтләр, бәйрәм-йолалар; зыялыларның гарәп-фарсы, госманлы, иске үзбәк телләрен яхшы белүе, ул телләрдәге китапларны оригиналда һәм тәрҗемәдә укулары; Шәрык әсәрләренең татарлар арасында күпләп таралуы, абруйлы булуы; хаҗга барулар; мөселман Көнчыгышы илләрендә белем алу һ.б. Болар һәммәсе дә Тукайга теге яки бу дәрәҗәдә тәэсир итә, дөресрәге, шагыйрь шул факторлар яшәгән мохиттә тәрбияләнә.

Билгеле ки, Тукай Жаекта Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсендә укый. Мөселман динен, фәлсәфәсен, әдәбиятын озак еллар буе Шәрык дөньясында, шул исәптән Каһирәдә дә өйрәнгән Муса Бигиев тибындагы бу мөхтәрәм зат үз сабакташының улын тәрбияләүгә, белемле итүгә нык игътибар бирә. Мотыйгулла хәзрәтнең улы, гаять эрудицияле, белемле Камил Төхфәтуллин да (1883—1941) Тукайны Шәрыкнең күп кенә рухи казанышлары белән таныштыра. Шагыйрьнең Истанбул университеты студенты Габделвәли белән дуслыгы да Тукайның госманлы сүз сәнгате белән кызыксынуын көчәйткән.

Истәлекләр, әдипнең язмалары Тукайның гарәп, фарсы, чыгтай (иске үзбәк) һәм госманлы телләрен, әдәбиятларын яхшы белүен күрсәтә. Мәгълүм ки, XIX йөздә Рәсәйдә, аеруча Казанда шәрыкшенаслык фәне, тюркология зур үсеш ала. Галимнәрнең бу өлкәдәге казанышлары татар зыялыларына, шул исәптән Тукайга да шактый билгеле була. Мәсәлән, ул Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Р.Фәхреддин, М.Бигиев хезмәтләрен белә. Ризаэддин Фәхреддиннең XX йөз башында дөнья күргән «Ибне Рөшдә», «Әбу Галя Әл-Мәгарри», «Ибне Гарәбшаһ», «Имам Газали» һәм башка монографияләре. Шәрык галимнәре һәм әдипләре хакында «Шура» журналында басылган мәкаләләре, гарәп, фарсы, төрки классикларыннан үрнәкләр, Муса Бигиевнең «Әдәбияте гарәбия илә гомуме исламия» (1908.— 72 б.), «Әл-Лозумийят» тәрҗемәләре (1 т., 56 б.; 2 т., 208 б.) һәм бу төрдәге кайбер башка материаллар Тукайга яхшы таныш була. Шагыйрь андый басмалар хакында үз фикерләрен дә әйтә.

Тукай һәм Шәрык классикасы хакында сүз барганда, бер бик мөһим моментны искәртү зарур. Шагыйрь, аеруча Тукай кебек талантлы зат, һич тә механик күчерүче, гадәти файдаланучы түгел. Аның һәрнәрсәгә, шул исәптән тәрҗемә текстына да үз карашы, үзенең иҗади мөнәсәбәте бар. Ул, гадәттә, алынма материалларны чимал рәвешендә генә файдалана, аларны иҗади, шәхси эшкәртүгә дучар итә. Шәрык тематикасы һәм чыганаклары белән дә шундый ук хәл. Тагын шунысы да бар: Тукай Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәбиятын яхшы белә, андагы традицияләрне уңышлы дәвам иттерә[4]. Ә инде бу дәверләрнең сүз сәнгате Шәрык белән шактый керешкән. Анда алынма материаллар, генетик уртаклыклар белән бергә, типологик охшашлыклар да тулып ята. Мәсәлән, гаруз шигырь системасы гарәп-фарсыдан безгә электән үк кергән, төрки-татар шигъри казанышлары, җирле элементлар белән баетылып, Идел-йортта киң таралып, тамыр җибәреп, татарның үз күренеше, үз хәзинәсе булып киткән. Тукайның күпчелек шигырьләре дә гаруз белән язылган. Моңа карап Тукай бу шигырь системасын Шәрыктан алган дию төгәл булмас. Шагыйрь кулланган газәл, робагый, фәрд, мәдхия, мәрсия, хикмәт, кыйтга кебек жанрлар белән дә шундый ук хәл. Дөрес, аларның да кайберләре генетик яктан Шәрыкка барып тоташа. Әмма инде Тукайга кадәр үк С.Сараи, Өмми Кәмал, Колшәриф, Мәүла Колый, Утыз Имәни, Ш.Зәки, Г.Кандалый, Акмулла кебек татар шагыйрьләре бу жанрларда иҗат иткәннәр. Шуңа күрә Тукай һәм Шәрык сүз сәнгате мөнәсәбәтләрен, әдәби-тарихи факторларны онытып, гадиләштерергә, бер яссылыкка гына күчерергә ярамый. Кызганычка каршы, мондый турысызыклылык хәзерге фәндә генә түгел, элеккеге тәнкыйтьтә дә күзгә ташлана. Мәсәлән, Җ.Вәлиди Октябрьгә кадәрге бер язмасында болай ди: «Тукаевның иң элек телен ачкан шигырьләре форма ягыннан гына түгел, хис вә мәгънә игътибары илә дә Шәркый бер характердадыр»[5].

Кыскасы, шагыйрьнең Шәрык әдәбияты белән мөнәсәбәтләрен тикшергәндә, йогынты, тәэсир, алынма кебек күренешләргә караганда, типологик охшашлыкларның, генетик уртаклыкларның өстенлек итүен хәтердә тотарга кирәк. Үзара багланышлар мәсьәләсенең куелышында, әлбәттә, билгеле бер шартлылык та бар.

Тукай иҗаты тамырлары төрле тарафлардан башланган мәһабәт агачны хәтерләтә. Милли һәм Шәркый җирлектән тыш, ул рус, Европа мәдәни казанышларына да барып тоташа. Шагыйрьнең Гареб әдәбиятларыннан тәрҗемәләре, нәзыйрәләре бар. Әмма бу иҗади процесста Тукай үз игътибарын күбрәк генетик яктан Шәрык белән бәйләнешле күренешләргә юнәлтә[6]. Менә шагыйрьнең «Иссез чәчәк» шигыре (2 т., 126 б.). Галимнәр бу парчаның И.Дмитриев әсәреннән файдаланып иҗат ителүен искәртәләр (2 т., 354 б.). Шигырьдә гадәти бер чәчәкнең, «гүзәл исле чәчәкләр бәйләме»ндә булып, «хуш исләнүе» әйтелә.

Шуның күк, безне тәүфикъли дуст-ишләр һәм белешләр дә
Өйрәтерләр гүзәл гадәткә һәм изге эшләргә.

Шушы ук мотивның Сәгъди, Сәйф Сараи, Ш.Зәки һәм кайбер башка авторлар тарафыннан эшкәртелүе, Шәрык, татар укучыларына күптәннән үк таныш булуы мәгълүм**.** Тукайның «Өч хакыйкать» әсәре А.Майков әкиятенә мөнәсәбәттә язылган. Үз чиратында исә рус шагыйре бу сюжетны Җәләледдин Руминың, ягъни Мәүлананың «Мәснәви»еннән алган. Ә инде Руми әсәрләре Идел-йортта күптәннән мәгълүм. Аларны безнең зыялы әби-бабаларыбыз оригиналда да, төрле тәрҗемә-шәрехләрдә дә укыган. Утыз Имәни, Әбелмәних Каргалый Мәүлананың аерым сюжетларын, мотивларын файдаланып, яңа әсәрләр иҗат иткәннәр. Кыскасы, Тукай рус**,** Европа әдәбиятларыннан теләсә нинди әдәби күренешкә түгел, ә, иң беренче чиратта, татар укучыларының образлы фикерләвенә, традицион зәвыгына авраздаш, якын булган ядкярләргә туктала.

* * *

Тукай мирасындагы әсәрләрнең бер кыйсеме тәрҗемә, нәзыйрә ысуллары белән язылган. Аларның шактые генетик яктан Шәрык классикасы белән бәйле. Мәгълүм ки, Тукай 1906—1907 елларда «Әлгасрелҗәдид» журналында «Мәҗмугаи Мөфидә» («Файдалы җыентык») исеме белән 65 мәсәл бас-

тырып чыгара. Бу эшен әдип алга таба да дәвам иттерә (3 т., 420—421 б.). Тукай үзе бу мәсәлләрнең Крылов һәм госманлы китапларыннан ирекле тәрҗемә булуын искәртә (3 т., 320 б.). Заманында без бу мәсьәлә белән махсус кызыксынып, Тукай мәсәлләрендәге күп кенә сюжетларның, мотивларның, образларның мәшһүр «Кәлилә вә Димнә»гә барып тоташуын ачыклаган идек[7]. Татар әдибе билгеле факт-мәгълүматларны теге яки бу дәрәҗәдә үзгәртә, вакыйга-хәлләрне, автор үзе әйтмешли, «татар мәгыйшәтенә борыбрак» бирергә тырыша (3 т., 420 б.), ягъни адаптацияли, яраклаштыра.

Тукай иҗатында Низами, Әл-Мәгарри, Гаттар, Сәгъди, Хафиз, Нәсими, аеруча госманлы әдипләреннән файдаланып язылган юллар, парчалар бар. Әмма татар шагыйре еш кына үзе мөрәҗәгать иткән текстларның шәкелен, шигъри калыбын (вәзенен, кафиясен) ала да яңа эчтәлекле әсәр иҗат итә. Шундыйларның берсендә, мәсәлән, Камил Мотыйгый белән иске фикерле Казан сәүдәгәре Әхмәтҗан Сәйдәшев арасындагы гаугалы низаг гәүдәләнеш тапкан. Ул болай башлана:

Диде Камил ки, йа Сәйдәш, оныттым,
Яңылдым юлый, яңлыш юла киттем
(1 т., 167 б.).

Бу юллар һәм гомумән бу шигырь госманлы әдибе Язычуглының атаклы «Мөхәммәдия»сеннән (1449) файдаланып язылган. Һәр ике текстның да строфа төзелеше, үлчәме, рифмалары, хәтта күп сүзләре дә уртак. Әмма эчтәлек, мәгънә үзгә («Диде адәм ки, йа Раббым, оныттым, Яңылдым юлый, яңлыш юла киттем...»). Тукайның шушындый ысул белән иҗат ителгән башка шигырьләре дә бар («Хатирәи Бакырган», «Ачы хакыйкать», «...Мәдхи Мостафа» һ.б.).

Мөселман дөньясының башка әдипләре кебек Тукай да Коръәнгә, пәйгамбәр хәдисләренә бик теләп мөрәҗәгать итә. Изге китап — аның өчен дә җан азыгы, иман таянычы, хаклык, тугрылык чыганагы: «Безләри иршад идән (безне тугры юлга күндерүче) Коръән икәндер, белмәдем» (1 т., 284 б.), «Аңлангачтын Коръәндәге бик күп серләр, Үз-үзеннән агаралар дини керләр» (2 т., 273 б.). Шагыйрьнең 1908 елның 21 гыйнварында иҗат ителгән «Тәэсир» шигыре мондый юллар белән башлана:

Гомернең иң читен, җайсыз, уңайсыз бер минутында,
Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында.
Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗаиб сүрә Коръәндән,
Газаблар мәгънәви бер кул илән алынадыр җандин...[8]

Ходай Тәгаләнең бөеклеген, игелеклелеген, кодрәт иясе булуын зурлап шигырьләр язу бөтен Урта гасыр әдәбияты өчен хас. Без моның матур үрнәкләрен гарәп язучысы Ибне Гарәбидә дә, фарсы шагыйре Җамида да, үзбәк классигы Нәваида да, татар авторы Мөхәммәдьярда да күпләп очратабыз. Бу изге традицияне Тукай да дәвам иттерә («Тәфсирме? Тәрҗемәме?», «Алла яратсын өчен», «Йокы алдыннан», «Сөальләр» һ.б.), «Киңәш» парчасында автор, үз укучысына дәшеп, болай ди:

Түкмә, күз яшь: ярдәмеңдә һәр заманда Алла бар;
Ал җәсарәт (батырлык), алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!
(2 т., 63 б.)

Шагыйрьнең лирик герое моң-зарларын гына түгүче пассив зат түгел. Ул, Аллага мөрәҗәгать итеп, җирдәге гаделсезлекләрне үзәккә куя, аларны бетерүдә актив ярдәм көтә:

И Тәгалә! Җир йөзеннән алчы бу алтынны, ал,
Яндыручы бу мөкаддәс җирне — бу ялкынны ал.
Куш мәләкләргә,— җиһаныңны тазартсыннар иде,
Барча алтынны җыеп, дүзәхкә (тәмугка) атсыннар иде...
(1 т., 103 б.)

Йа Ходая! Нигә төрле-төрле кыйлдың бәндәни?
Ни сәбәб соң җөмлә әдна бәндәләрдән бән дәни?
(Ни сәбәптән соң мин барлык түбәннәрдән дә түбән.)
(1 т., 330 б.)

Суфыйчылык — Урта гасыр мөселман дөньясында тирән эз калдырган күренеш. Аның традицияләре, фикер-сурәтләре билгеле бер дәрәҗәдә Тукай иҗатында да күзәтелә. Бер өлеш суфый шагыйрьләр, гомернең фанилыгын, байлык-хакимиятнең бибәһа булуын белдерү өчен, туфрактан туфракка кайту идеясенә басым ясыйлар. Чөнки җир һәммәне тигезли. Бу фикер Тукайда да очрый: «Үл! Туфрак бул, кайт аслыңа,— аслың яхшы» (1 т., 92 б.). Икенче бер төркем суфыйлар (Гаттар, Ибне Гарәби...) кешенең җанын

Алладан вакытлыча аерылган кисәкчә, нур рәвешендә күзаллыйлар. Ул һәрвакыт үзенең беренче чыганагына — абсолют чынбарлыкка — Тәңрегә тартыла. Тукайда да мондый карашның образлы гәүдәләнеше бар: «Тәндә җаным, чык та Тәңреңә юнәл, бар, кайт кире» (2 т., 115 б.); «Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы...» (2 т., 137 б.) һ.б.

Суфыйчылык белән бәйләнешле мотивлар, сурәтләр татар укучысы өчен дә үз һәм якын. Тукай, шушы эстетик хосусиятне күздә тотып, аларны материал, элемент рәвешендә файдалана, бу төр образларга (пәрванә, шәмгъ, дәрья, гөл, былбыл ...), символик, мифологик мәгънәдән бигрәк, тормышчанрак вазифа йөкли. Мәсәлән, суфый шагыйрьләр фани дөньяны еш кына зиндан (читлек), андагы тереклекне тоткынлык белән чагыштыралар. Тукай исә — дөньяви рухлы әдип. Аңа инсаннарның, барлык кавемнәрнең, җан ияләренең хөр, иреклe яшәүләре кыйммәт. Табигый канун — аның иман-ышанычы. Бу мотив шагыйрьнең хәтта балалар өчен язылган «Фатыйма белән Сандугач» шигыренә дә килеп кергән. Сандугач «әйбәт» читлектә, янында «ашы» да бар. Әмма ул күңелсез. Кош авызыннан мондый сүзләр әйтелә: «Белмисеңме син: читен мәхбүслек (тоткынлык) ул, Булса да алтын, һаман да читлек ул». Шуннан аны кыз бала азат итә: «Бар, азат бул, кыйл миңа изге дога» (2 т., 154 б.). Шәрыкның күп кенә шагыйрьләре кебек, Тукай да ялган суфыйларны, ишанлыкны шәхси мәнфәгатьләре өчен файдаланучы затларны кискен тәнкыйтьли.

Сөю-мәхәббәтне иляһилаштыру, аны абсолют югарылыкка күтәреп тасвирлау Хафиз, Йуныс Эмре, Физули һәм Шәрыкның башка күп кенә классиклары өчен хас. Тукай да бу традицияне уңышлы дәвам иттерә. Аның өчен дә мәхәббәт «гали» (бөек), «идеал» (2 т., 177 б.); «йөрәк»ләрне «парә-парә кисүче» халәт (1 т., 191 б.), мәңгегә башны әйләндерүче «дәрд» (1 т., 282 б.). Әмма шуның белән бергә, татар шагыйре сөю хисләрен, гыйшкый халәтне тормышчан планда, еш кына юмористик рухта тасвирлый («Утырышу», «Татар кызларына», «Сөбханалла, сөбханалла» һ.б.). Мондый хосусият бу төр шигырьләрне укучыга тагын да якынайта төшә.

Урта гасыр Шәрык галәмендә, гәрчә телләр, этник барлык, гореф-гадәтләр төрле булса да, билгеле бер уртак идея-эстетик байлык, гомумшигъри хәзинә туплана. Башка халыкларның иҗат ияләре кебек, татар шагыйре дә бу поэтик мираска мөрәҗәгать итеп тора, андагы сюжет-мотивларны, образларны, шигъри детальләрне үзе теләгәнчә куллана. Ләйлә, Мәҗнүн, Фәрһад, Ширин, Салсал, Сәет Баттал һәм башка билгеле исемнәрнең Тукай әсәрләрендә очравы нәкъ әнә шуның белән аңлатыла. Мәсәлән: «Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн — мин аларның таңчысы» (1 т., 191 б.). «Бирмәде Ләйлә кеби мәхбүбәгә дөнья бәһа; Ул болай бер кыз гына — каршында Мәҗнүн булмаса» (1 т., 321 б.)... Әмма шагыйрь урыны белән традицион образларга, күнегелгән төшенчәләргә үзгә мәгънә дә бирә. Ләйлә белән Мәҗнүн,— мәсәлән, Шәрык сүз сәнгатендә парлы, бөтен мәхәббәтнең аерылмас затлары. Тукай исә «Бер рәсемгә» шигырендә кызның искиткеч гүзәллеген тасвирлый да болай ди:

Күрсә яңлыш бу матур кызның фәкать рәсмен генә,
Шөбһәсез, селтәр кулын Мәҗнүн дә үз Ләйләсенә.
(1 т., 178 б.)

Тукай кайвакыт укучы күнеккән, үз иткән сурәтләргә бөтенләй икенче төсмер бирә. Кояш, таң образлары,— гадәттә, уңай эмоция тудыручы чаралар. Тукай исә «Читен хәл» шигырендә аларга, үзенең авыр рухи халәтенә нисбәтән, тискәре төсмер бирә: «Каршыма чыкма, кояш, син канлы тап! Ак кәфендәй син җәелмә өсткә, таң!» (2 т., 183 б.)

Татар шагыйре иҗатында Шәрык классикасына охшаш, аваздаш булган башка төр күренешләр дә шактый. Тукай да белем-мәгърифәтне зурлый, кешеләрне, Сәгъди, Низами кебек, изге ат, «эз» калдырырлык итеп яшәргә чакыра («Җиһанда калдырып китсәм икән, йа Рабб, гүзәл эзне!» — 2 т., 62 б.; «Булса калдырмак берәү ушбу җиһанда изге ат, Тир белән тапсын ашарын, итсен, әлбәт, иҗтиһад».— 2 т., 171 б.). Шигырьләрендә, Хафиз, Нәваи, Нәсими шикелле, рәдиф, тәҗнис, кабатлау кебек поэтик чараларны иркен куллана («Тыныч торма, каләм, дәртеңне яз, яз! Тагын җитте мөнәүвәр яз, аяз яз».— 1 т., 81 б.).

* * *

Тукай иҗаты, аның Шәрык классикасы белән мөнәсәбәтләре хакында күпләп, тагын да җентеклерәк сөйләргә мөмкин булыр иде. Әмма шунысы ачык: шагыйрь гарәп, фарсы, төрки рухи мирасын яхшы белгән, андагы казанышларны материал, чыганак рәвешендә иҗади файдаланган. Бу аның һәм идея-тематикасында, һәм тел-стилендә күзәтелә.

Тукай якты дөньядан киткәнгә дә бер гасырга якын вакыт узып бара. Бу чор эчендә җәмгыятьтә, безнең тормышыбызда күп нәрсә үзгәрде. Әмма бөек Тукай, аның әсәрләре ике гасыр, ике меңьеллык аралыгында

да заманча яңгырый, заман белән бергә яши. Шагыйрьнең ялкынлы шигырьләре тәэсир көчен арттыра гына бара. Ни өчен? Чөнки аларда инсанга, милләткә, җәмгыятькә хас булган уй-кичерешләр, яшәеш проблемалары сәнгати югарылыкта гәүдәләнеш тапкан. Шагыйрьнең идеаллары һаман да күңелләрне җилкетә. Тукай хөр, ирекле, бәхетле күрергә теләгән татар милләте әле һаман да ул сыйфатларга мохтаҗ. Шагыйрьнең «Бер генә милли бәхетнең безгә көлгән вакты юк» (2 т., 117 б.), «Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул» (2 т., 280 б.), «Тәнмез айрым булса да, Бер җан булыйк, бәдәвам» (1 т., 29 б.) дигән юллары һаман да заманча, һаман да актуаль яңгырыйлар.

[1] «Тукай һәм яз» — өйрәнү өчен үзе бер махсус тема.

[2] *Габдулла Тукай*. Әсәрләр: Дүрт томда.— 1 т.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1975—1977.— 316—317 б.; — Алга таба бу чыганакның том һәм битләр саны җәяләр эчендә генә күрсәтеләчәк.

[3] Татар әдәбияты тарихы: XX йөз башы.— 3 т.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.— 112 б.

[4] Бу хакта карагыз: *Хатыйп Миңнегулов*. Тукай һәм Урта гасыр әдәбияты / Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте: Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция (1996) материаллары.— Казан, 1997.— 54—63 б.; Мирас.— 1997.— # 1.— 39—50 б.

[5] Өзек түбәндәге мәкалә аша китерелә: *Таһир Гыйлаҗев*. Тукай һәм Вәлиди // Казан утлары.— 2000.— # 4.— 181 б.

[6] Бу турыда безнең «Тукай һәм Урта гасыр әдәбияты» дип исемләнгән мәкаләдә конкрет мисаллар, күзәтүләр бар.

[7] *Хатыйп Миңнегулов*. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар. — Казан: КДУ нәшрияты, 1988.— 23—24 б.

[8] *Г.Тукай*. Мәҗмугаи асарь.— Казан, 1914.— 19 б.

*2000*

## «ЯҢА МИЛЛИ ЮЛ» ЖУРНАЛЫ ҺӘМ ТУКАЙ

Күп кенә татарлар, төрле сәбәпләр аркасында, үзләренең асыл Ватаны — Идел-йорттан чит-ят җирләргә китәргә, күчәргә мәҗбүр булган. Элек-электән башланган бу процесс XX йөзнең беренче яртысында, аеруча Октябрь инкыйлабыннан соң, тагын да көчәя. Бу чорда шактый гына милләттәшләребезнең Германия, Финляндия, Кытай, Япония, Корея, Төркия, Польша һәм кайбер башка мәмләкәтләрдә гомер кичерүе мәгълүм. Алар, гәрчә читтә яшәсәләр дә, Идел-йорттан тәмам аерылмыйлар: ата-баба җире, туган як мөһаҗир милләттәшләребезне төшләренә кереп йөдәтә, җирсү тойгысы бәгырьләрен кимерә. Ана теле, милли моң, дин, гореф-гадәтләр аларда теге яки бу дәрәҗәдә дәвам иттерелә.

Миңа 70 елдан артык гомерен читтә уздырган мәшһүр профессор-тюрколог Әхмәд ага Тимер белән Анкарада берничә мәртәбә очрашырга туры килде. Ул тумышы белән Әлмәттән. Минем дә шул яктан икәнне белгәч, Урсал тауларын, Зәй суларын, Бигәш белән Әлмәт арасындагы инешне, өянкеләрне сораштыра башлады. Үзе сөйли, ә күзләрендә яшь, моң-сагыш... Шунда мин мөһаҗирлектәге адәм баласының рухи халәтен, күңеле ничек җирсүен янә бер мәртәбә күрдем.

* * *

Читтәге татарларның туган кавем белән бәйләнешен саклауда, милли рухны үстерүдә китаплар, вакытлы матбугат гаять мөһим роль уйный. Узган гасырның 20—40 нчы елларында, хәтта бераз соңрак та милләттәшләребез яшәгән илләрдә төрле газета-журналларның чыгуы мәгълүм. «Милли Байрак», «Яңа япун мөхбире», «Азат Ватан», «Ерак Шәрык», «Идел-Урал», «Шәкердләр таңы», «Белдереш», «Казан» һ.б.— әнә шундыйлардан. Болар арасында аеруча Г.Исхакый мөхәррирлегендә Берлинда нәшер ителгән «Яңа милли юл» журналы (ул әүвәл «Милли юл» исеме белән басыла) мөһим урынны алып тора. Гарәп хәрефләре белән басылган бу журналның (ул 1928—1939 елларда чыга) барлыгы 136 саны дөнья күрә.

«Яңа милли юл», аның тематикасы, характеры, авторлары хакында инде без язган берничә материалның басылганы бар (Азатлык көрәшенең мөнбәре // Казан утлары.— 1993.— № 3.— 122—135 б. һ.б.). Журналдагы аерым язмалар, бигрәк тә Г. Исхакыйның публицистик, тәнкыйди, тарихи мәкаләләре, тиешле шәрех-аңлатмалар белән, укучыларга билгеле бер дәрәҗәдә иреште. (Бу хакта карагыз: *Х.Миңнегулов*. Исхакый мөһаҗирлектә.— Казан: Таң-Заря, 1999.— 82—83 б.)

«Яңа милли юл» — иҗтимагый, әдәби, тарихи, сәяси, педагогик, гыйльми... журнал. Ул тематик байлыгы, материалларның төрлелеге, вакыт ягыннан һәм географик җәһәттән масштаблылыгы белән сыйфатлана. Әмма журнал милли рухта. Аның үзегендә — татар тормышы, бу кавемнең язмышы, үткәне, бүгенгесе, киләчәге, дөнья халыклары арасында тоткан урыны. Игътибар итик: журналның исеме дә аның җисеменә, төп мәсләгенә туры килеп тора.

«Яңа милли юл»ның чыгымнары тулысы белән мөһаҗир татарларның үзләренеке. Аңа бернинди дәүләти оешма да ярдәм итми. Киресенчә, Советлар Берлегендәге иминлек оешмалары турыдан-туры да, башка дәүләтләр аркылы да журналга, аның хезмәткәрләренә, авторларына, хәтта укучыларына да төрле киртәләр, комачаулыклар тудырып тора. Бу басманы алган аерым зыялыларны, гаеп ташлап, төрмәгә утырту очраклары да бар.

Журналны чыгаруга иң күп һәм даими ярдәм күрсәтүчеләр,— әлбәттә, Финляндиядәге милләттәшләребез. «Яңа милли юл» сәхифәләрендә Суомидагы татарларның тормышы, рухи дөньясы киң яктыртыла. Биредәге милләттәшләребез — журналның иң актив укучылары да. Хәзер дә бу мәҗмуганың күп кенә нөсхәләре Финляндиядәге татар гаиләләрендә бар. Өлкән буын аннан бүген дә хәбәрдар.

Төрки-татарның күренекле әһелләре — журналның даими игътибар үзегендә. Болар арасында, әлбәттә, төп урыннарның берсен Г.Тукай алып тора. Бу уңай белән шунысын да искәртик: миңа мөһаҗәрәттә чыккан татарча газета-журналларның шактые белән танышырга туры килде. Аларның һәммәсендә диярлек Тукай мөхтәрәм урынны били. Мәсәлән, 1970—1980 елларда Төркиядә төрек һәм татар телләрендә (нигездә, төрекчә) нәшер ителгән «Казан» журналының (барлыгы 23 сан) һәр санында диярлек Тукай турында материал, аның шигырьләре бар. «Милли Байрак», «Азат Ватан» һ.б. газета-журналлар да бөек әдипне читләтеп үтми.

«Яңа милли юл»да, әдәбият, сәнгать, мәгариф, милли тел һәм гомумән татар яшәеше хакында сүз барганда, еш кына Тукай исеме, аның әсәрләре телгә алына, шигырьләреннән өзекләр китерелә. Аерым юллары бөтен журналга эпиграф рәвешендә дә бирелгән. Кыскасы, шагыйрь абруйлы зат, татарның бер символы рәвешендә күзаллана.

Мәгълүм ки, мөһаҗир милләттәшләребез гомер кичергән күп кенә илләрдә Тукай кичәләре уздырыла, шагыйрьнең туган, аеруча вафат булган көннәре билгеләп үтелә. Мәсәлән, журнал 1936 елның 10 апрелендә Берлинда Тукай кичәсе булуын хәбәр итә. Мәҗмугада әдипнең рәсемнәре дә күзгә ташлана.

Болардан тыш «Яңа милли юл»да Тукай турында махсус мәкаләләр, әдәби язмалар да басылып килә. Алар, нигездә, шагыйрьнең туган-үлгән көннәренә, бигрәк тә тууына 50, үлеменә 20, 25 ел тулу мөнәсәбәте белән бирелгән.

Бу төр материалларның һәммәсендә Тукайның бөеклегенә, көчле талантына, халыкчанлыгына басым ясала. Аның татар рухын, халыкның кайгы-шатлыгын, өмет-идеалларын тасвирлавы ассызыклана. Тукай туган телне, туган кавемне саклаучы һәм яшәтүче, милләтне бергә туплаучы, бербөтен итүче бер көч, куәтле бер энергия чыганагы рәвешендә карала. Әлбәттә, мәкалә-язмалар үзләренең фикри тирәнлекләре, тел-стильләре белән төрле. Авторлары,— нигездә, мөһаҗир татарлар, үзебезнең зыялылар.

Журналның мәсләге, рухы, әлбәттә, иң беренче чиратта, баш мөхәрриргә, аның талантына, тәҗрибәсенә, эчке тоемына, дөньяга карашына бәйле. Г.Исхакый бу җәһәттән — татар журналы өчен идеаль мөхәррир. Ул — бөтен иҗади һәм иҗтимагый сәләтен, тормышын, яшәү максатын милләткә, «милли юл»га багышлаган зат.

Тукай һәм Исхакый... Татарның бу бөек ике әһеле, аларның үзара мөнәсәбәте — һәм әхлакый, һәм инсани, һәм милли ноктадан гаҗәеп кызыклы, гаҗәеп актуаль мәсьәлә. Бу хакта инде мөһим генә язмалар да бар. Мәсәлән, мөхтәрәм Ибраһим ага Нуруллин «Г.Тукай һәм Г.Исхакый» мәкаләсендә (Шәһри Казан.— 17.07.1993) бу ике затның бер-берсенә ихтирами карашлары турында кызыклы факт-мәгълүматлар китерә. Тукай Исхакыйда «даһи» кешене, милли таңны аттыручы затны, зыялыларның остазын күрә, хәтта аны билгеле бер дәрәҗәдә иляһилаштыра да. Г.Исхакый да, гәрчә алар һич очрашмаса да, Тукайны элек-электән хөрмәт иткән, аны олуг шагыйрь дип таныган, илдә вакытта да, мөһаҗәрәттә дә әдип хакында уңай фикерләр әйткән, бай эчтәлекле мәкаләләр язган. Мәсәлән, «Сүз» газетасының 1916 ел, 3 апрель санында басылган «Мәрхүм Тукай» язмасы (Эльмира Ханнанова публикациясе.— Мәдәни җомга.— 23.05.1996) — шуның бер гәүдәләнеше. Шагыйранә тел-стиль белән язылган, эмоциональ эчтәлекле бу мәкаләдә Исхакыйның Тукайга гаять җылы мөнәсәбәте, шагыйрь хакындагы уй-кичерешләре, аның татар тормышындагы бөек роле турында уйланулары үтә дә калку, үтә дә оста итеп бирелгән. Язма авторы шагыйрьнең бик иртә үлүенә, милләтнең аны саклый алмавына тирән үкенеч белдерә. «Сигез ел фәүкылгадә (гадәттән тыш) авырлыкта кичергән вакытында, шагыйрьлегенең сабыйлык дәверендә татарның гамәл дәфтәренә шулкадәр Тукай ниләр язган булыр иде! Нинди әсәрләр белән, нинди шигырьләр белән татар әдәбиятын, татар шигырь дөньясын бизәкләгән булыр иде!» — диелә ул мәрсияви мәкаләдә.

* * *

«Яңа милли юл» журналында Тукайга мөнәсәбәтле материаллар арасында Г.Исхакыйның шагыйрь турында үзенең дә махсус мәкалә-язмалары бар. Шундыйларның берсе «Тукай истәлеге» дип аталган. Шагыйрьнең үлеменә 20 ел якынаю уңае белән язылган бу материал журналның 1932 ел 11 нче санында дөнья күргән (1—4 б.). «Тукай юбилее,— ди мәкалә авторы,— «Тәрҗеман»ның чыга башлавына 50 ел тулу белән бергә туры килә. Исмәгыйль Гаспринский бөтен төрк иленең уртак пәйгамбәре булганга, «Тәрҗеман»ның 50 еллыгын бәйрәм итү — аны искә төшерү бөтен төрк кабиләләренең уртак бурычы». Чөнки аларның бер өлеше — Төркия — «үз эшенә үзе хуҗа». «Тик Тукайның 20 еллыгын кем искә төшерәчәк?» Ул «безнең Идел буе төрк-татарының шагыйре булганга, ул безнең халкыбызның моңын җырлаучы, безнең дәртебезне күпләүче булганга, аны искә алу да турыдан-тугры безнең өстебезгә йөкләнә»... «Әмма,— ди Г.Исхакый,— илдә халкыбыз хокуксыз. Тукай татар халкы өчен аның кайгысын-хәсрәтен әйтеп бирә торган бер халык шагыйре булса да, Совет карашыннан, ул — мулла баласы, милләтче, динче; коммунизм карашыннан, ул — урыслаштыру тәрбиясенә киртә салып торучы бер контрреволюционерчы; илебезне-йортыбызны урыс мөһаҗире берлә тутырырга теләүче кызыл Мәскәү карашыннан, ул — шовинист-милләтче; бөтен большевик сәясәте карашыннан, ул,— үзенең халкы кебек, үз илендә бөтен нәрсәдән мәхрүм «хокуксыз — лишинтәс».

Г.Исхакый читтәге татарларны Тукайның үлеменә 20 еллыкны мөмкин кадәр хәзерлек белән, тиешле югарылыкта үткәрергә чакыра. Моның өчен мәкалә авторы махсус комиссия төзү, шагыйрьнең әсәрләрен бастыру, Тукай турында җыентык чыгаруны кирәк саный. Г.Исхакый фикеренчә, шагыйрьне зурлау, искә алу — милләтнең уртак бурычы.

Баш мөхәррирнең шагыйрь турындагы язмалары арасында аеруча «Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә» мәкаләсе игътибарга лаек (1938.— # 4.— 1—9 б.). Бу материал, яшь галимә Алсу Кәримова тарафыннан әзерләнеп, кереш сүз белән «Казан утлары» журналында да басылып чыкты (1999.— #4.— 180—186 б.).

Г.Исхакыйның гыйльми-теоретик һәм тәнкыйди эчтәлекле бу язмасы шактый кызыклы, полемик рухлы. Мәкалә авторы шагыйрьләрне, «шәхси кабилиятләренә» (сәләтләренә), иҗади фикерләү үзенчәлекләренә, җәмгыять белән мөнәсәбәтләренә карап, икегә бүлә. Беренчесе — индивидуалист табигатьле, шәхси уй-кичерешләрен генә үзәккә куючы, «бәйнәлмиләл шигырьләр» тудыручы авторлар. Икенчеләре исә үзләрен «тирә-юньнең, мохитнең бер өлеше итеп хис итеп, шуның бөтен күңел алышынуларына үзенең йөрәк тибүе берлә катышып, үзенең шатлыгына сөенеп, аның кайгысына янып, шатлык-кайгыдан дәрт алып кына шигырь яратучылардыр» («язучылардыр»). Болар — «туган халкы, аның тирә-юне, яшәгән мохитенең шул вакытта кичергән уйлары, хисләренең тәрҗеманы» («күчерүчесе»; «тылмачы»), «термометры».

Г.Исхакый беренче төркемнең вәкиле итеп С.Рәмиевне күрсәтә, икенчесенә Г.Тукайны кертә. Соңгысын тасвирлап, ул болай яза: «Үзенең мохитенең шатлыгын, кайгысын, дәрден шигырь төсенә сугучы бер тел остасыдыр. Аның яшәгән, язган дәвере бездә милләтчелекнең иң кайнаган, милли теләкләрнең берсе өстенә берсе үсеп, тирә-якны тутырган вакыт булганга, ул шул теләкләргә, шул омтылышларга бер шигырь төсе бирүче, чуалчык фикерләрдән туган агымларга тугры юл күрсәтергә теләүче милләт хезмәтчесе, милли шагыйрьдер... Бөтен кыска гомере буенча ул... милли юлдан һичбер тайпылмаенча, кабергә кадәр милләт ерын ерлап, милләт кайгысын көйләп, милләт көлкесендән көлеп, үзенең милләтчелек калыбына сугып киләдер».

Г.Исхакый Тукай тирәсендәге бәхәсләргә, аны «шагыйрьлек» тәхетеннән төшерергә маташучыларның эшчәнлегенә дә туктала, «Мөнтәкыйдкә» һәм кайбер башка шигырьләрен анализлау аша Тукай мәсләгенең «дөрест вә тугры» булуын янә бер мәртәбә раслый. «Бәрәкәт боерсын,— ди ул,— Тукайны бу ялгыш тәнкыйтьчеләр бу хата юлларга суга алмадылар. Тукай үз юлында баручы, милләт кайгысын кайгыртучы халык шагыйре булып калды».

Г.Исхакый Тукай шигырьләренең, шул исәптән әдәби тәрҗемәләренең дә тәрбияви әһәмиятенә югары бәя бирә. Шагыйрьнең «Туган тел» парчасы хакында ул, мәсәлән, болай ди: «Милли хис вә милли гакыл бергә кушылып эшләнгән бу шигырь... Тукайның тәрбияви шигырьләренең иң кыйммәтлесеедер... Бу шигырь бөтен мәктәпләребездә милли һәймәнә (гимн) төсен ала алмышдыр һәм бу шигыре Тукайны мәңгегә безнең балаларның иң сөйгән бер ерчысы итеп куймышдыр».

Мәкаләдә Тукайның, тәнкыйтьчеләрдән тыш, икенче «дошманы» — чир белән көрәше дә телгә алына. Авыру халәт «аның шигъри куәтен зәгыйфьләндермәсә дә,— ди Г.Исхакый,— аның бу шәхси дәрде (авыруы), бу кайгысы аның сазын тагы да нечкә кылларында уйнатып, аның шигырьләрен тирәнәйтте».

Г.Исхакый, Октябрь инкыйлабына кадәр язган мәкаләләрендәге кебек, биредә дә Тукайны саклап кала алмауга үкенечен белдерә. «...Бөтен төрк-татар дөньясы алдында,— ди ул,— Тукай йиилдә яна торган шәм кеби, көндән-көн аның актык сәгатьләре якынлаша. Ләкин аны саклау тәдбире (уй-нияте) иң соңгы вакытка кадәр кичектерелә».

Г.Исхакыйның мәкаләсе шушындый юллар белән төгәлләнә: «Тукайның вафатының 25 еллыгы көнендә үксез иленең бүген кызыл руслык хөкеме сөргән үксез почмагында ятим яткан кабере алдында теземезне чүгәмез. Исән вакытта кирәге кадәр кадерен белмәгән, кыйммәтен танымаган милләтнең бүгенге хөрмәтен, сөйгесен газиз рухына сонамыз» («багышлыйбыз»).

«Яңа милли юл» журналында Тукай турында басылган язмалар арасында Сәгадәтнең мәкаләләре дә игътибарга лаек. Аларның берсе шагыйрьнең тууына 50, икенчесе үлеменә 25 ел тулу уңае белән язылган [1936.— # 6 (100).— 14—17 б.; 1938.— # 4 (121) — 9—14 б.]. Һәр ике мәкалә дә «Габдулла Тукай» дип исемләнгән.

Мәгълүм ки, Сәгадәт (1907—1989) — Гаяз Исхакыйның кызы. Ул Германиядә университет белеме ала. 1932 елда кияүгә чыга һәм аннан соң Чагатай фамилиясе белән дә йөри башлый. Сәгадәт — тормышта, аеруча «Яңа милли юл»ны чыгаруда әтисенең төп таянычы. Гаяз Исхакыйның Ерак Шәрыкка өч еллык сәфәре вакытында журнал белән, нигездә, Сәгадәт Чагатай мөхәррирлек итә. Бу мөхтәрәмә затның соңгы 50 еллык гомере, эшчәнлеге Төркия белән бәйле. Ул анда гыйльми-тикшеренү, педагогик эшләр белән шөгыльләнә, мәшһүр тюрколог-профессор буларак танылa.

Тукай турындагы мәкаләләрендә Сәгадәтнең шагыйрь рухын яхшы аңлавы, поэзияне әйбәт тоемлавы сизелеп тора. Европа тормышы һәм университеты аның милли тәрбиясенә, татарлыгына зыян китермәгән, киресенчә, яшь галимәнең офыкларын киңәйтә, милләтпәрвәрлек хисен үстерә, карашларын тирәнәйтә төшкән. Тукайның шигъри үзенчәлеген, татар хәятындагы ролен билгеләүдә Сәгадәтнең фикерләре әтисенең уйланулары, бәя-хөкемнәре белән шактый якын һәм авазадаш.

Исхакый кызы язган мәкаләләрдә дә Тукайга хөрмәт, ихтирам бөркелеп тора, аның халык шагыйре, татарны берләштерүче символ булуына басым ясала. «Нә күңелле, нә яхшы ки,— Тукаемыз бар! Халык өчен (бу)... бөек юаныч...» — ди автор. Тукайны Тукай иткән иң мөһим нәрсә — «милли вөҗдан». «Бу

милли вөҗдан,— ди Сәгадәт,— Тукайда шулкадәр саф, шулкадәр тирән ки, аның тәэсиренә бирелмәү мөмкин түгел». Галимә шагыйрьдәге аерым җитешсез якларны да күрә. Әмма ул бу төр күренешләрне Тукайның яшьлеге, тәҗрибәсезлеге, милли үсешнең торышы белән бәйләп аңлата. Чөнки аның иҗаты — билгеле бер дәрәҗәдә «шул дәвернең көзгесе» дә. Сәгадәт фикеренчә, безнең халык, гәрчә алга таба шактый зур адымнар ясаса да, «бөтен, тулы җитешкән бер милләт булып тәмам җитмәгән». Әмма ул «югары баскычларга» күтәрелү юлында. Тукай иҗаты исә милләтнең алга барышын җиңеләйтә, безне рухи яктан пакьләндерә, үстерә.

Сәгадәт шагыйрьнең балалар өчен язылган парчаларын аеруча кыйммәтле дип саный. «Тукай,— ди ул,— балалар өчен язып калдырган бик матур шигырьләре берлә үзенең бала сөючән рухын, үз халкының балалык дәверен кичерүен вә халык өчен бала тәрбияләү киләчәк өчен иң нык нигез булуын күрсәтеп торадыр». Галимә шагыйрьнең балалар поэзиясе өлкәсендәге уңышларын аның шәхси табигате («вөҗдан сафлыгы», «керсезлеге», «самимилеге», «ихласлыгы»...) белән дә аңлата. Сәгадәт карашынча, Тукайны яшәтүнең, «аның берлә бергә булу»ның иң «тугры» чарасы — шагыйрь әсәрләрен «тагын да күбрәк уку».

Мөһаҗир татарлар чыгарган газета-журналларны, китапларны актарганда, Солтан (Әхмәд Виргаз) исеме күзгә еш ташлана. Ул чыгышы белән Мордовия якларыннан. Ерак Шәрыкта — мөһаҗир. 1929 елда аның Харбинда 27 битлек «Шигырьләр» исемле китабы да чыга.

«Яңа милли юл» журналының 1935 елгы 7 нче санында Солтанның «Габдулла Тукай» исемле язмасы бар (20—22 б.). Ул шагыйрьнең «үлүенә 22 ел тулу уңае берлә» басылган.

Солтан мәкаләсенең тел-стиле шактый камил, урыны белән хәтта шигъри. «Милли моңнар» әсәреннән алынган өзекләр, ничектер, язма эчтәлегенең лейтмотивы булып та яңгырый.

Милләт һәм шагыйрь проблемасы — мәкаләнең үзәгендә. Чын әдип үз халкының кайгы-шатлыгын, моң-зарын белдерә, аның мәнфәгатьләрен, язмышын кайгырта. Тукай — нәкъ әнә шундый шагыйрьләрнең берсе. Ул «үзенең иҗаты... берлә халкыбызның әйтергә теләгән тойгыларын җиңел, шома бер телдә әйтеп бирде; ...Тукай шигырьләрендә — халкыбызның тибеп торган күңел чишмәсе». Мәкалә авторы шагыйрьнең үзенчәлеген, популярлыгын нәкъ әнә шунда — халык белән тыгыз бәйләнештә күрә. Тукай иҗаты тормыш белән бергә яши, милләтне дулкынландыра. Шагыйрь әсәрләрен, ди Солтан, «укыган саен мәгънәсе арта бара. Мәгънәсе арткан саен, Тукай югарыга күтәрелә».

Солтан милләтнең, андагы әдипләрнең дөньяга танылу-танылмавын турыдан-туры иҗтимагый-сәяси шартларга бәйләп карый. Кагыйдә буларак, хөр, бәйсез халыкларның әдип-шагыйрьләрен дә дөнья халкы белә. Тукай, ди мәкалә авторы, «изелгән, мәхкүм милләтнең шагыйре». Әгәр дә ул «үзенең хөр илендә иркен яшәп, истикълален (бәйсезлеген) алган бер милләт шагыйре булса иде, ул башка милләтләргә дә күптән танылган булыр иде». Колониаль изелү астында җәфа чиккән татар халкы исә озак дәверләр буе күңелендә «янган ялкынлы теләкләр»ен дә яза алмый килде.

Мәкаләдә Тукайга мөнәсәбәтле аерым материалларның чит ил матбугатында да күренә башлавы искәртелә. «Тукайның үлүенә 20 ел тулганда (димәк, 1933 елда),— ди Солтан,— поляк телендә чыга торган «Daleki Wschod» журналы Тукайның рәсемләрен төшереп, мәкаләләр багышлап, берничә шигырен тәрҗемә дә иткән иде». Минем белүемчә, бу материаллар хәзерге татар фәненә мәгълүм түгел. Димәк, поляк телендәге бу журналны, һичшиксез, табу, гыйльми әйләнешкә кертү, Тукай музеена кую зарури*.

Мәкалә ахырында Солтан Тукайның Заһир Бигиевкә багышлап язган түбәндәге строфасын китерә:

Шадыман ул мәркадеңдә (шат бул кабереңдә)! —
 без онытмыйбыз сине;
Белмәсәк вактында кадрең, инде котлыйбыз сине.

Бу юлларны ул шагыйрьнең үзенә карата куллана.

Прозаик, драматург, журналист, мөгаллим, режиссер, актер, җырчы Хөсәен Рәхимҗан углы Габдүш (1901—1944) — мөһаҗир татарлар арасында Тукайны өйрәнүгә, пропагандалауга, мөгаен, иң зур өлеш кертүчеләрнең берседер. Мәгълүм ки, 1933 елда Токиода «Матбагаи исламия»дә гарәп хәрефләре белән Тукай әсәрләренең биш томлыгы дөнья күрә. (Барлыгы 646 бит.) Хөсәен Габдүшнең бу игелекле эштә дә катнашы бар. 1932 елда ул Харбинда шагыйрьнең үлеменә 20 ел тулу алдыннан Тукай турында «программ» характердагы бер китапчык та бастыра. (Кызганычка каршы, ул безнең кулыбызда юк.)

«Яңа милли юл» журналының 1936 елгы 5 нче санында Х.Габдүшнең «Бөек Кушлавыч ятиме» дигән мәкаләсе бар (4—8 б.). Ул шагыйрьнең тууына 50 ел мөнәсәбәте белән язылган. Мәкалә шактый кызыклы, үзенчәлекле. Анда авторның үз карашы, үз тоемы сизелеп тора. Текст гыйльми-тәнкыйди, публицистик, лирик-эмоциональ башлангычларның синтезыннан гыйбарәт.

Мәкалә шагыйрьнең исеме, тәхәллүсе хакында фикер йөртүдән башлана. Әмма автор шушы билгеле нәрсәләрдә тирән мәгънә, Тукай иҗатының символик асылын, тормышчанлыгын күрә. «Аның исемендән

үк,— ди Хөсәен Габдүш,— халкыбызның үзлегендән аерым алынмас бер нота яңгырый: Тукай! Ата-анасы кушкан исеме — халкыбыз арасында иң күп таралган вә сөелеп әйтелә торган исем — Габдулла.

Тукай — бу Габдулланы башка бик күп Габдуллалардан аерып, аны «Кечкенә Апуш»лыгыннан аерып, «зур-зур» төрк-татар шагыйре дәрәҗәсенә күтәргән исеме дә арабызда сирәк очрый торган саф үзебезчә, милли бер исем...

Тукай — ... төрк-татар тарихында мәңге онытылмаслык бер исем.

Шагыйребезнең исеме халкыбыз арасында шул дәрәҗәдә киң таралган ки, кайбер вакыт әдәбиятдан бөтенләй хәбәрсез, надан кешеләрнең авызындан да аның берәр шигырен ишетергә туры килә».

Хөсәен Габдүш Тукай әсәрләренең идея-тематик яктан гаять киң һәм күптөрле булуына, милләт яшәеше белән табигый керешүенә басым ясый. «Тукайның яратышындагы (ягъни иҗатындагы) рух халкыбызның күңеле берлә шул дәрәҗәдә, әгәр гыйбарә дөрест булса, игезләнеп беткән ки, халкыбыз хакында фикер әйткәндә, Тукайны искә алганда, милләтебез тугрында сүз сөйләми мөмкин түгел. Алар бер-берләрендән аерылмыйлар».

Хөсәен Габдүш шагыйрьне өйрәнүчеләрдән Җәмал Вәлиди хезмәтләрен, аеруча аның Тукай җыентыгына (1914) кереш рәвешендә язылган «...Мөляхәза»сын (уйлануларын) уңай бәяли, аннан өзекләр китерә.

Җәмал Вәлиди: «Татар халкында түземлек, ... ерак ноктаны күзәтеп эш күрү юк,— ди.— Аның асаре шигъриясендә хыялый бөтенлек, киңлек түгел, бәлки бер хисси чуарлык, тарлык күрәмез. Хәтта бу тарлык, чуарлык шул дәрәҗәдә ки, ул бөтен ике мисраглык бер җыр җырлый алмый. Һич мөнәсәбәтсез вә туп-тугры Ак Идел буйларындан үзенең җанкәсенә күчә, тәрәзә капкачындан туган иленә килеп төшә». Җәмал Вәлиди шушындый чуарлыкны Тукай шигырьләрендә дә күрә. Әмма Хөсәен Габдүш халык, шагыйрь турындагы мондый фикерләрне сорау астына ала, бу төр мәсьәләләр хакында укучыны уйланырга чакыра. Аның карашынча, милли күтәрелеш чорында мондый «мөляхәзалар» яшьләребезгә, табигый, файдалы якдан тәэсир итмиләр», «Кимчелекләребезне санау гына түгел,— ди ул,— аларның төп сәбәпләрен һәм аларны төзәтү юлларын күрсәтеп, аңлатып бирү — укымышлы сыйныфыбыз өстенә килеп төшкән милли вазифаларның берсе».

Гомумән, мәкалә эзләнү, уйлану рухында. «Тукай көнләренә багышланып язылган мәкалә вә хатирәләрдә,— ди Хөсәен Габдүш,— шагыйребезгә мактау сүзләре язып кына утыру берлә канәгатьләнү җитми, бу уңай берлә гомумән милли тарих, әдәбият, тормыш вә мәгънәви ихтыяҗларыбыз хакында туган фикерләрне матбугат битләренә чыгара баруыбыз кирәк». Мәкалә авторының бу төр искәрмәсе бүгенге көнебез өчен дә актуаль. Чөнки күренекле әдипләрнең юбилей көннәрендә без күбрәк мактау, билгеле хакыйкатьләрне искә төшерү белән мавыгып китәбез.

Хөсәен Габдүш Тукай әсәрләренең яшәүчәнлегенә басым ясый. «Безнең милли аңыбыз, милли хисебез үсә барып, мәгънәви тормышыбызның офыклары киңәя вә тәҗрибәбез арта барган саен,— дип яза ул,— Тукай шигырьләре күбрәк аңлана барачаклар».

Мәкалә авторы Тукайның «Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә» мәрсиясендәге юлларын шагыйрьнең үзенә күчереп, язмасын мондый сүзләр белән төгәлли: «Аның кадерле исеме үлмәячәк. Ул «... милләт яшәдекчә яшәр. Милләт үсдекчә үсәр һәм милләт ашдыкча ашар»... (Шагыйрь) үзенең бик иртә өзелеп киткән ялгыз гомеренең соңгы секундларына чаклы талант көчен аямады...» Хөсәен Габдүшнең үз гомере дә халыкка хезмәт итү, шагыйрьне аңлау-аңлату юлында өзелде. Бу милләтпәрвәр зат ел саен апрель аенда Харбин һәм гомумән Ерак Шәрык татарлары өчен Тукай кичәләре уздыра. Ул шундый кичәләрнең берсенә хәзерлек вакытында сәхнәдә йөрәк өянәгеннән үлә. Гомере буе Идел-йортны сагынып яшәгән бу моңлы затның җәсәде дә еракта, Харбин зиратында. Бәлкем, инде аның кабере дә юкка чыккандыр.

«Яңа милли юл» журналында Тукай турында, гыйльми, тәнкыйди, публицистик язмалар белән беррәттән, шигырьләр дә бар. Шундыйларның берсе «Габдулла Тукайга» дип атала (1936.— # 6 .— 17—18 б.). Аның авторы — Шаһвәли Келәүле (Илдәр. 1900—1970). Бу шигырен ул Мукденда яшәгәндә, «Милли Байрак» газетасында эшләгәндә яза.

Шаһвәли Келәүленең тормыш юлы һәм иҗаты Надир Дәүләт мәкаләсендә (Казан утлары.— 2000.— # 2.— 141—153 б.) шактый тулы яктыртылган. Биредә бары шуны гына искәртәбез: бу затның Дим буйлары, Идел-йорт (Габдессәлам, Дәүләкән, Келәүле, Кызылъяр...), Себер, Шанхай, Мукден, Истанбул һәм кайбер башка төбәкләр белән бәйләнешле гомер юлы шактый катлаулы, каршылыклы, фаҗигале. Әмма шуңа да карамастан ул әдәбиятка мәхәббәтен сүндерми: үзе дә шигырьләр, поэмалар, сәхнә әсәрләре иҗат итә. Аның «Асламчылар» исемле комедиясе милләттәшләребез тарафыннан Шанхайда һәм Төркиядә куела да. Әдипнең әсәрләре «Яңа милли юл», «Милли Байрак», «Казан» һәм башка газета-журналларда дөнья күрә.

«Габдулла Тукайга» шигырендә ул шагыйрьне «юл күрсәтүче», кояш кебек нурландыручы, «файдалы орлык чәчеп» калдыручы дип атый. Шигырьнең соңгы юллары болай яңгырый:

Әй Раббым, ник син алдың яшьли аны дөньядан?
Ачы авазлар белән без яд итәбез (хәтергә алабыз) һәр заман.
Аерылып китсәң дә бездән, данлы шагыйрь, мәңгегә,—
Калды эшең һич югалмас тарихи милләтеңә.
Бар төрк-татар бу көндә баш иябез рәсмеңә,
Рухыңа оҗмах телимез һәр догада Тәңрегә.

* * *

«Яңа милли юл» журналы һәм Тукай... Билгеле бер күзәтү ясау да бу ике төшенчә арасында тыгыз, табигый мөнәсәбәтләр яшәвен ачык күрсәтә. XX гасырдан башлап татар яшәеше шагыйрь рухы белән сугарылган. Тукайсыз милли юлның яңасы да, искесе дә юк. Шушы хакыйкатьне тирәнтен аңлаган һәм чынбарлыкка тугры калган журнал нәкъ менә шуңа күрә дә Тукайга үзенең түрен бирә, аны милли үзлекнең мөһим бер символы итеп карый.

Безгә бөек шагыйребез хакындагы һәр төрле мәгълүматны, шул исәптән «Яңа милли юл» журналындагы материалларны да хәзерге укучыга җиткерергә, бүгенге югарылыктан торып анализларга кирәк. Бу — безнең әхлакый, инсани һәм милли бурычыбыз.

*2002*

## «ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ»* СӘХИФӘЛӘРЕНӘ

Милләт тормышында тирән эз калдырган күренекле әдипләрнең тормышын һәм гомумән эшчәнлеген яктырткан энциклопедияләр, белешмә-сүзлекләр төзү күп кенә халыкларда инде күптәннән күзәтелә. Шушы тәҗрибәне исәпкә алып, узган гасырның 90 нчы елларында Татарстан Фәннәр академиясе һәм Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты бөек шагыйребез Г.Тукайның белешмә-сүзлеген әзерләү эшенә кереште: авторлар коллективы тәгаенләнде; язылачы мәкаләләрнең тематикасы, исемлеге ачыкланды; булачак китапның төп принциплары, таләпләре эшләнде. Шулар нигезендә инде хәзерге вакытта шактый гына эшләр башкарылды. Без фәкыйрегез дә, куелган гомуми таләпләр кысасында, үзебезгә бүленеп бирелгән әсәрләр, атамалар, темалар хакында берничә дистә мәкалә язды. Бу китапка шуларның бер өлеше тәкъдим ителә. Мәкаләләрдә төп чыганак итеп Г.Тукайның тууына 90 һәм 100 ел тулу уңае белән шагыйрь әсәрләренең Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән дүртенче һәм бишенче басмалары алынды.

«Тукай энциклопедиясе»нә мөнәсәбәтле мәкаләләр үзләренең эчтәлекләре белән берничә төргә бүлеп бирелде:

1. Шагыйрь әсәрләре турында;
2. Тукай кулланган жанрлар;
3. Шагыйрь иҗаты белән бәйләнешле авторлар һәм журналлар.

### 1. Шагыйрь әсәрләре турында

Исемсез шигырьләрнең берсе. Бу атама — әсәрнең тәүге юлыннан. «Тугъды, көн тугар кеби...» — Тукайның өйрәнчек шигырьләрен-

нән берсе. Ул госманлы (төрек), гарәп телләре йогынтысында иҗат ителгән. Шуңа күрә бу шигырь соңгы басмаларда хәзерге татар теленә тәрҗемәдә дә бирелә.

Әсәр *аа бб...* рәвешендә кафияләшүче 16 икеюллык строфадан гыйбарәт. Шигырь үзенең рухы белән, нигездә, мәдхия жанрында. Мактау, арттыру, күрергә теләгәнне бар, гамәлдә дип күрсәтү аның шигъри лексикасын тәшкил итә (әүлия; хәбибе әнбия-пәйгамбәрләрне сөюче; пакьлеге, гүзәллеге — оҗмахтай; «тагъ кисәрдәй» эшлекле; «... зөбдәэ сәнгать илаһи» — иляһи осталыкка ия һ.б.).

Мәдхиядә Вәлиулла (Вәли Хәмидуллин) дигән кешенең мәдрәсә бинасын төзекләндерүе, яңартуы мактала. Мәдрәсә — белем, мәгърифәт учагы. Аны зурлау, хуплау аша автор үзенең мәгърифәтче икәнен дә күрсәтә. Шагыйрь фикеренчә, мәктәп-мәдрәсәләргә ярдәм итүче мондый химаячеләр тагын да артсын иде.

Шигырь ике кисәктән гыйбарәт. Алты бәйтлек тәүге өлеше тулысы белән мактау рухында. Аның 15 әр иҗекле юллары да, ничектер, салмак, тантаналы яңгырый. Әсәрнең икенче өлешендә шигъри үлчәм дә кыскара — 11 гә генә кала, интонация дә үзгәрә. Мәдхия тукымасына юмор, һөҗү-сатира эчтәлегендәге юллар да килеп керә. Автор мәдрәсә бинасын кешеләштерә, телгә китерә: «...Мортаза бай! Мортаза бай! / Сән нигә бигрәк саран булдың болай? // Нигә салдың син бәни — карамагач, / Үз малың үз файдаңа ярамагач // Мортаза бай! Син төзәлмәссең бугай — / Мин телимен Алладан икенче бай». «Мин»нең теләге кабул ителә.

Бу шигырь реаль вакыйга-фактларга нигезләнеп язылган. Мәгълүм булганча, Тукай әсәр иҗат ителгән елларда Җаек шәһәрендә яши, «Мотыйгия» мәдрәсәсендә укый. Мортаза бай (миллионер М.Гобәйдуллин) бу уку йортының бинасын салдырган була, әмма ахырда, гәрчә аның назире саналса да, мәдрәсәгә ярдәм итми. Бераздан бу затны Вәлиулла Хәмидуллин дигән кеше белән алыштыралар. Бу игелекле затның Җаек (Уральск) мөселманнарының җәмгыяте хәйрия рәисе, нашир булуы да билгеле. «Әлгасрел-җәдид» журналы, «Фикер», «Уральский дневник» газеталары аның җитәкчелегендә дә чыга.

Шигырьдә төзәтелгән бинада «мәхдүм өчен» дә бер бүлмәне җиһазлау телгә алына. Бу мәхдүм — Камил Мотыйгый. Ул бу елларда мәдрәсәдә дәресләр дә алып бара.

«Т...» шигыре хакында «Әлгасрел-җәдид» журналының 1904 елгы 4 ноябрь санында (№ 15) бер хәбәр бар. «Мәҗлесе Гыйльмия» дигән бу язмада «Мотыйгия» мәдрәсәсендә җыелыш булуы, анда төрле мәсьәләләр тикшерелүе әйтелә. Шул мәҗлестә катнашкан Габдулла Тукаев югарыда телгә алынган шигырен укый. Язмада «Т...» да урнаштырыла. Ахырда мондый юллар бар: «Бундан аңламак мөмкин ула белүр ки, хәмед (мактау) улсын, «Мәдрәсәи Мотыйгия»дә гүзәл әдиб вә шагыйрьләр дә вар...»

Шуннан соң «Т...» Тукай әсәрләренең дүртенче басмасында «өйрәнчек шигырьләр» рубрикасында дөнья күрә (1 т., 352—354 б.; аңлатмасы 415—416 б.). «Т...» хакында аерым фикер-күзәтүләр И. Нуруллинның «Моңлы саз чыңнары» китабында да бар» (Казан, 2000. — 73—74 б.).

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 314—316 / 391—392 б.

Әлеге шигырь *аа бб...* рәвешендә рифмалашучы 19 бәйтле, һәр юлы 11 әр иҗекле, өчәр ритмик буынлы, гарузның һәзәҗ төре белән язылган. Теле — ярымтатарча, ярымгосманлыча. Исеме юк. «Бу көндә...» атамасы — шигырьнең тәүге юлыннан.

1905 елның ноябрь аенда Уральск (Җаек) шәһәрендә «Казан» кунакханәсе (чәйханәсе) ачыла. Шигырь, шул уңай белән язылып, «Фикер»нең 1905 ел, 11 декабрь санында басылыр өчен гранкага салынган. Әмма аның урынына бу чәйханә хакында башка материал урнаштырыла. Әсәр бары тик Академик басманың беренче томында (1943) гына дөнья күрә. Шигырьне Татарстан Язучылар берлегенә заманында «Әлгасрел-җәдид» һәм «Фикер»нең мөхәррире булган Вәлиулла Хәмидуллин тапшыра.

Әсәр үзенең эчтәлеге белән мәдхия рухында. Анда «сарай» (ягъни миһманханә) ачылу зур бер вакыйга рәвешендә тасвирлана. Аның матурлыгы, бизәлеше гадәттән тыш арттырылып, әкияти планда сурәтләнә: «Гүзәлдер һәр җире»; ул «кайгылы күңелгә шатлык бирә»; «Җиһанда мисле надир (охшашы аз)» һ.б. Автор алга таба бу сарайны барлыкка китерүчеләрне мактый. Шунда ук тәвәккәл, инициативалы инсаннарны хуплый, эш-гамәлнең милләт өчен зарурлыгын искәртә: «Ниләр эшләмәс бу милләт, әгәр керешсә! / Милләтнең чире — керешмәүдер эшкә». Шунысы мөһим: «бу сарай гадәти кунакханә генә түгел, анда безнең хәлебезгә бәйле» «төрле газеталар» да бар («Ятыр өстәлидә дөрлү җәраид»).

Тукай шушы вакыйга уңае белән үзенең идеалларын да бәян итә, үзе күрергә теләгәнне чынбарлык рәвешендә дә тасвирлый. «Б...» мәдхия жанрына хас сыйфатларны язу белән төгәлләнә: «Күңел канәгатьләнми күпме мактасам да,— / Торасым килә мактап һаман да.// Аны мактавыбыз — мәңгелек (Аны мәдхе сәнамыз та әбәддер), / Каләм гүя аны мәдхә әсәддер (Аны мактауда каләм — арыслан кебек)».

*Г. Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 37—39 (332—333) б.

Әлеге әсәр шигъри формада язылган 9 строфадан гыйбарәт. Һәр юлы, нигездә, 15 әр иҗекле. Икеюллыклар рәвешендә язылса да, строфаларны дүртьюллыкларга да әйләндерергә була. Моңа шигырьнең интонациясе, ритмик буыннар, цезура һәм рифмалар мөмкинлек бирә. Әсәрнең исеме юк. «...Безнең әти аягында җыермалы ал читек...» — аның тәүге юлы.

Бу әсәр «Тукайга нисбәт ителгән һәм өйрәнчек шигырьләр» рубрикасында йөри. Ул тәүге мәртәбә «Әлгасрел-җәдид»нең 1905 ел, 13 гыйнвар санында дөнья күрә. Аның алдыннан мондый сүзләр язылган (тәрҗемәдә): «Надан бер бай улына чыккан кызлардан берсенең түбәндә китерелгән җырларны матур күзләреннән яшь агызып җырлаганын ишетеп, сынык күңелебезгә бик нык тәэсир иткәнгә күрә, журналыбызда бирдек. Йөрәк җимеше булган җәннәттәге хур кызларына тиң сылу-сылу кызларын, аягына таш бәйләп суга салган кебек, белмәгән-сынамаган кияүгә биреп, бичара кызларын шушы җырларда чагылган яшерен утка салучылар бик күп. Без телгә алган җырлар түбәндәгечә...»

Әлеге шигъри юллар — халык җырларының бер үрнәге. Лирик герой «мин» исеменнән дә, «без» авызыннан да үзенең рухи халәтен, аерылу, кайгы-сагыш хисләрен бәян итә. Кагыйдә буларак, тәүге юл психологик фон, кабул итүгә әзерлек, эмоциональ халәт тудыру вазифасын үти. Строфаның икенче юлында исә төп мәгълүмат, уй-кичереш белдерелә. Мәсәлән: «Күк күгәрчен — күлләрдә, ак күгәрчен — сайларда; Сагыну түгел, саргаерсың — җиләк пешкән айларда».

Тукай һәм тормышта, һәм иҗатында хатын-кызны зурлады, авыр хәлдә калучыларына һәрчак теләктәшлек белдерде. Җыр текстлары да, мөгаен, аның теләк-омтылышларына аваздаш булгандыр. Шуңа күрә шагыйрьнең аларны, теге яки бу дәрәҗәдә эшкәртеп, укучыларга тәкъдим итүе бик ихтимал.

*Г. Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 1 т. — 318 (392—393) б.

Бу әсәр — шигъри, лиро-эпик характердагы поэма. Ул барлыгы 184 мисрагтан (шигырь юлыннан) гыйбарәт.

Әсәрдә Сафи һәм Фатыйма исемле кешеләрнең гаилә тормышы, үз-үзләрен тотышлары, үзара мөнәсәбәтләре тасвирлана. «Тире сатып, җан алып» яшәүче ир бик юаш, күндәм. Хатыны исә, киресенчә, гайрәтле, иренә бер дә көн күрсәтми торган зат: «Сафи — абыстай иде, бу — абзыйдыр»; «Сафи — муен, Фатыйма апай — баш иде». Хәтта ул иренә кул күтәрүдән дә тартынмый. Сафи хатынының бөтен кирелекләренә, кылану-капризларына түзеп яши бирә.

Бервакыт кешеләрне аздырып йөрүче бер явыз карчык («Бәдбәхет, йөзе кара, җалмавыз») Фатыйманы бозык юлга өнди: «Ник торасың син ирең берлән, кызым?.. «Яшь егетнең куйны — оҗмах, агъзы — бал, / Йөзләре алсу-кызылдыр, буе — тал». Хатын ят ирләр белән азып-тузып йөри башлый. Сафи моңа күз йома («Хатынының һәр эшеннән күз буа, / Кара карганы сабын берлән юа»), балаларын ятим итмәү нияте белән, хатынын «ак», «пакь» дип аклау юлына да баса. Алты еллап вакыт уза. Ахыр чиктә Сафи, күршеләренең «тәнбиһләрен» исәпкә алып, хатынын аерып җибәрә. Фатыйманың газаплы, үкенечле тормышы башлана («Эш үткән шул, бик күрәсе килә ирен, / Балаларын, гомер иткән йортын-җирен»). Әмма инде соң!

Автор хатынның әхлаксызлыгын, азып-тузып йөрүен гаепли. Әмма ахырда ул аны кызгана («И Фатыйма, кызганамын — нигә аздың?»). Авыр хәлгә төшкән хатын-кызларның аянычлы язмышы хакында уйлануы белән Тукай Г.Исхакый карашларына («Кәләпүшче кыз» һ.б.) якын тора.

Әсәрдә Сафи образының бирелешендә эзлеклелек, мантыйк бик сакланмый. Автор аны әүвәл «дине таза, бик каты тәкъва кеше» дип тәкъдим итә. Бераздан, хатынының бозыклыкларына түзеп торганы өчен, аны «дин белмәү»дә гаепли («Белсә дин, Фатыйманы тотмас иде»). Шагыйрь ирнең «балалар» дип талак бирмичә торуын да тәнкыйтьли: «Куркъканы: үксез кала ике бала. / Нигә куркыйм? Калсын унике бала!» Гомумән, автор хикәяләү барышында геройларның эш-гамәленә, вакыйга-хәлләргә үзенең мөнәсәбәтен дә белдереп бара.

Әсәр тел-стиленең үтемлелеге, халыкчанлыгы белән сыйфатлана. Автор еш кына кызыклы чагыштырулар, мәгънәле тәгъбир-гыйбарәләр куллана: «Сафи абзыйны изәр көрпә кеби, / Кабарып үзе ата күркә кеби»; «Ир илән торганчы, тор син чир илән»; «Көн саен агулы ут йотмас иде...» Әсәр үзенең рухы белән элеккеге «хикәят»ләр традициясен дәвам итә. Әмма ул эчтәлегенең тормышчанлыгы, заманчалыгы белән аерылып тора. Газизә апасының әйтүенчә, Тукай бу әсәрен реаль вакыйгаларга нигезләнеп язган. Хәтта Сафи абзыйның хатыны шагыйрьнең кардәше булган дигән фикерләр дә бар.

«Кәҗә тугрысында» шигыре кебек, әлеге әсәр дә ике төрле үлчәм, строфа белән язылган. Аның тәүге өлешенең һәр юлы 11 әр иҗекле 80 икеюллыктан гыйбарәт. Соңгы бәйттә «Фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт» дип, автор үзе дә шигъри үлчәмнең ниндилеген искәрткән.

«К...» нең соңгы өлеше «Кыйссаи Йосыф» үлчәмендә язылган. Ягъни аның һәр юлында 12 шәр иҗек, рифмалашуы *аааб*, *вввб*... рәвешендә. Автор әсәрнең бу өлешен «Бәхре сани» (икенче үлчәм) дип үзе дә искәртә.

«К...» тәүге мәртәбә «Фикер»нең 1906 ел, 17 май (18) санында «Гъ» инициалы белән нәшер ителә.

*Г. Тукай.* Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 74—81 (338—339) б.

Тукай 4 бәйтлек бу шигырен Пушкинның «Про себя» исемле дүртьюллыгыннан (1818) файдаланып язган. Әмма русча текст белән татарча әсәрнең ике юлы гына үзара охшаш («Великим быть желаю» — «Телим булырга мин инсане гали»; «Я много обещаю» — «Хисапсыз күп минем милләткә вәгъдәм»). Калган юллары бөтенләй яңа, үзгә. Тукай теләк-омтылышларының гамәлгә ашуын, «бөек инсан» дәрәҗәсенә ирешүен милләт язмышына бәйләп карый. Пушкин: «Люблю России честь»,— ди. Тукай исә татар булуны, татарга хезмәт итүне, аның тәрәкъкыяте өчен көрәшне үзенең асыл максаты итеп куя: «Күңел берлән сөям бәхтен татарның, / Күрергә җанлылык вактын татарның. // Татар бәхте өчен мин җан атармын: / Татар бит мин, үзем дә чын татармын».

Бу чорда кайберәүләр татар атамасына каршы чыгалар: «төрек», «мөселман» яисә «болгар» исемнәрен яклыйлар. Тукай «Үз-үземә» шигыре белән мондыйларга ачык һәм үтемле итеп җавабын бирә. Эчке рифмалар, аллитерация, кабатлаулар шигырьнең сәнгати тәэсир көчен арттыруга ярдәм итәләр.

Шигырьнең соңгы строфасы үзенчәлекле: «Хисапсыз күп минем милләткә вәгъдәм, // Кырылмасмы вавы, валлаһе әгъләм?» «Вәгъдәм» сүзенең беренче хәрефен алып ташласаң, «әгъдәм» сүзе кала. Бу исә гарәпчә юкка чыгу, бетү мәгънәсен белдерә.

«Үз-үземә» гарузның өч буынлы һәзәҗ үлчәме белән язылган. Рифмалашуы *аа бб*... рәвешендә.

Шигырь «Әлгасрел-җәдид»нең 1906 елгы 11 нче санында (15 ноябрьдә) «Г.Т.» имзасы белән басылган. «4 нче дәфтәр»дә (1907) «Күрергә шаһлыгын, тәхтен татарның...» дигән юл «Күрергә җанлылык вактын татарның...» — дип үзгәртелгән.

*Г. Тукай*. Әсәрләр: Дүрт томда. 1 т.— 60 (368) б.; *Г. Тукай.* Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 120 (349) б.; *А. С. Пушкин*. Полн. собр. соч.: В 6-и томах. Т. 1. (Стихот. 1813—1825 гг.) — М.: ГИХЛ, 1949.—С. 280.

«Хәзерге халемезә даир», ягъни «Хәзерге хәлебезгә карата» шигыре — Тукайның милләтпәрвәр булуын һәм бер үк вакытта аның үз

халкына тәнкыйди дә карый белүен раслаучы ачык бер мисал. Әсәрнең тәүге строфасында ук автор болай ди: «Хәсәд (көнчелек), кинә илән тулган татарлык, / Төяб илтеб Мәкәрҗәдә сатарлык». Тезис рәвешендә әйтелгән бу фикер алга таба ачыклана, конкрет факт-мәгълүматлар, детальләр ярдәмендә тулыландырыла.

Ислам дине, сүз сәнгате, рухи мирас элек-электән үк белем-мәгърифәтне, язма китапны зурлап, изгеләштереп килгән, аларны татар әхлагының мөһим компонентына әйләндергән. Әмма, ди шагыйрь, хәзер «мөхәррир»гә, «каләм»гә хөрмәт юк. Автор каләм «ияләре»нең тормышта мөһим роль уйнауларына басым ясый («Каләм сәед дорыр руе зәминдә» — «каләм хөкем йөртүче җир йөзендә»; / «Мөхәррирләр ирер исламә куәт», «Зәгыйфьләргә» иптәш, «сагъларга» җитәкче; «Сүземә бакыңыз — юллар ачармын»).

Тукай бу шигырендә дә, «И каләм!» әсәрендәге кебек, каләмгә мәдхия укый, аның тәрәккыяять юлында, кимчелекләрдән арынуда көчле чара булуын искәртә (тәрҗемәдә): «Каләм — бөек, каләм — дәрәҗәле...», «Каләм данлы, каләм шанлы; каләм ул — / Чиргә дәва, кайгыны юар сабындыр». Тукай, чын мәгърифәтче буларак, наданлыкка бирелмәскә, каләмгә каршы бармаска чакыра. Чөнки, ди ул, «җәһаләт таптамасын — яньчелермез, / Каләмгә каршы бармыйк — чәнчелермез».

Тукай, күп кенә башка әсәрләрендәге кебек, бу шигырендә дә Изге Китапны өлге итеп куя, Коръәннән аерым мисаллар да китерә (Каләм белән «ант ителгән «Нур» сүрәсендә»...).

«Х...» гыйлем-мәгърифәтне олылавы, милләттәге кимчелекләрне күрсәтүе, тәнкыйди пафосы белән соңгы дәвер татар тормышына да аваздаш.

Шигырь *аа бб...* рәвешендә кафияләшүче 14 бәйттән-строфадан гыйбарәт. Һәр юлы 11 әр иҗектән, 3 әр ритмик буыннан тора. Бу ягы белән ул гарузның кыскартылган һәзәҗ үлчәменә туры килә.

«Х...» әсәре госманлы, гарәп телләренең йогынтысында иҗат ителгән. Шигырь тәүге мәртәбә «Әлгасрел-җәдид» журналының 1906 елгы 1 (15 гыйнвар) санында «Уральскида Габдулла Тукаев» имзасы белән нәшер ителгән.

*Г. Тукай.* Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 48—50 (335) б.

Шигырь 11 дүртьюллык строфадан гыйбарәт. Аның һәр юлы өчәр ритмик буыннан, 12 шәр иҗектән тора.

Тукайның кайбер башка әсәрләре кебек, «Утырышу» да халык тарафыннан яратып укыла, сәхнәләрдә яңгырый. Бу эштә автор үзе дә катнаша. «Казан мөхбире» газетасы язуынча (1908 ел, 31 март), Казанда Биржа залында булган бер әдәби кичәдә (1908 ел, 29 март) «Утырышу» шигырен Тукай үзе укый. «... Әсәре, матур гына язылганга күрә, халыкка ошады»,— диелә ул мәкаләдә.

Шигырьнең исеме очрашу, гәпләшү мәгънәләрен белдерә. Лирик рухтагы бу әсәр мәхәббәт темасына язылган. Лирик герой белән кызның очрашуы, «мин»нең сөю хисләре, мәгъшукасын иляһилаштыруы шигырьнең төп эчтәлеген тәшкил итә. Лирик герой өчен сөйгән ярының килеш-килбәте, сүз-сөйләме — һәммәсе якын һәм үз. Ул дөнья ваклыкларыннан, көндәлек кайгы-шатлыклардан өстен: «Минемчә, тик яралган ул сөелергә, / Сөяргә һәм куанырга, сөенергә; / Күргән саен, минем төсле гашыйкларга: / «Бу минеке булмас!» — диеп көенергә».

«Мин» өчен бу «фәрештәдәй» ярның нәрсә әйтүе, сүзләренең мәгънәсе мөһим түгел. Лирик герой белән очрашу, аның сөйләм агышын тыңлау — үзе бер бәхет-сәгадәт.

Тукайның хатын-кызлар белән мөнәсәбәттә оялчанлыгы, әхлакый тыйнаклыгы мәгълүм. Шигырьдәге лирик герой да, гәрчә күңелендә «дәрте» «тулып ташса» да, итагатьле, хәтта сөйгәненең кулыннан тотарга да читенсенә («Ак кулыннан тотыйм, тотыйм, җибәр, диеп, / Гакълым берлә шул вакытта кул талаша»). Тукайның кайбер башка әсәрләрендәге кебек, бу шигырьдә дә лирик геройның күңел каршылыгы, икеләнү-шөбһәләнүләре шактый оста бирелгән. Урыны белән юмористик аһәң дә үзен сиздерә («Белмәс хәлне,— яшь нәрсә бит,— аңлый алмас / Кычкырсам да: «Кочаклашыйк, тукта! Тукта!»).

«Утырышу»ның тел-стиле аңлаешлы, үтемле, халыкчан. Шигырь тәүге мәртәбә «3 нче дәфтәр»дә (1907) дөнья күргән.

*Г. Тукай.* Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 177—178 (356, 369) б.

Бу — Тукайга нисбәт ителгән шигырьләрнең берсе. Ул фәрд, ягъни икеюллык жанрында: «Мәгатыйль кыйлды милләтне гаталәт вә кәсаләтдән; / Бу хезмәтчөн азад улды у цензур нам

әсарәтдән». Тәрҗемәсе: «Азат итте милләтне ул дәртсезлек (дөресрәге, эшсезлек.— *Х.М.*) һәм ялкаулыктан; / Бу эше өчен азат булды цензур исемле коллыктан».

Шигырь «Фикер»нең 1906 елгы 1 гыйнвар санында «Төрле хәбәрләр» бүлегендә имзасыз басылган. Шигырьдән алда: «Тәрҗеман» газетасы декабрь уртасыннан бирле цензурасыз чыкмая башлады һәм урысча кыйсемене (өлешен) ташлады. Хәзер «Тәрҗеман»ымыз, хәмед (мактау) улсын, бик яхшы улды. Аның хакында диерсез»,— дигән сүзләр бар.

Исмәгыйль Гаспралы (1851—1914) җитәкчелегендә чыккан «Тәрҗеман» газетасы төрки-татар халкының аң-белем дәрәҗәсен күтәрүгә зур өлеш кертте. Шигырьдә дә бу момент, гәрчә бераз кинаяле тонда булса да, ассызыклана. Мәгълүм ки, 1905 елдан, татарча күпләп газета-журналлар чыга башлагач, алар фонында «Тәрҗеман» бераз тоныкланып кала. Ул берничә мәртәбә Тукай тәнкыйтенә дә дучар була.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 320 (393) б.

— Тукайның «Вак-төяк» исеме астында басылган парчаларының берсе. Ул дүртьюллык 5 строфадан гыйбарәт. Парча «Мин арканда туй итим...» дип башлана.

XII йөздә иҗат иткән Урта Азия шагыйрьләре Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганый әсәрләренә ияреп язылган бу шигырьдә элек-электән үк төрки-татар әдәбиятында эшкәртелеп килгән тема — ялган суфыйларны фаш итү яктыртыла. Әмма Тукай бирелә үзенчә эш итә: сөйләм ишәк исеменнән алып барыла. Ахмаклык символы булган бу җан иясе дә ишанның арттальгыннан, наданлыгыннан көлә. Шигырь аерым җырларга хас булган «дөньяда», «вай дөнья» рәдифләре белән бирелә: «...Халыкның каралуына (дөньяда) / Чын күңелдән чалыйшан (тырышкан.— *Х.М.*) вай дөнья».

Шигырь «Фикер»нең 1906 елгы 3 декабрь (45) санында басылган.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Дүрт томда. 1 т.— 64 (369) б.;
*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 125 (351) б.

Кечкенә күләмле бу чәчмә хикәят рухы белән мәсәл жанрында. Сафа исемле берәү алпавыт сарыкларын көтә. Ул малларны бүре ашый дип зарлана. Аучылар, «бөтен урманны актарып», бүрене эзлиләр. Әмма «бүренең эзе дә юк, исе дә юк». Чөнки бүре сылтау гына. Чынлыкта исә «сарыкларны Сафа» дигән «бүре» ашый. Аның табынында ит, «шурпа» «һич бер дә өзелми».

Бу хикәят И.Крыловның «Пастух» дигән мәсәленә нигезләнеп язылган. Үз чиратында, рус әдибе Шәрык чыганакларын файдаланган. Тукай алынма сюжетны, үзе искәрткәнчә, «татар мәгыйшәтенә борыбрак», ягъни адаптацияләп (яраклаштырып) язган.

«Көтүче» иң әүвәл «Мәҗмугаи мөфидә» («Файдалы җыентык») исеме астында «Әлгасрел-җәдид» журналының 1906 елгы 15 октябрь санында дөнья күргән.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 5 т.— 138 (293) б.

Бу шигырь 1907 елның декабрендә иҗат ителеп, «Әлислах» газетасының 1908 елгы 1 гыйнвар санында «Феакут» («Тукаев» атамасының киредән укылышы, ягъни анограммасы) имзасы белән басыла. Шуңа күрә шигырьнең датасы, язылу, басылу вакытына карап, ике төрле: я 1907, я 1908 ел дип күрсәтелә.

Фөрьяд — «аһ-зар» дигән сүз. Шигырьнең эчтәлеге дә әсәрнең атамасына туры килеп тора. Җәяләр эчендәге «Бер хатын авызыннан» сүзләре аһ-зарның кемнеке икәнлеген тәгаенли.

«Фөрьяд» — хатын-кызның ачы язмышын гәүдәләндергән монолог. «Мин», гәрчә ул, «бала чактук тиберченгән, тик тормаган» зат булса да, әүвәл «тыгыз биләү»гә, аннан тормыш «зинданы»на салына. «Кол» табигатьле ата-анасы балаларын да «кол»лык психологиясе рухында тәрбиялиләр. Үсеп җиткәч, аны берәүгә дүртенче хатын итеп кияүгә бирәләр. «Шул зинданда үсеп җиттем унсигезгә, / Хатын булдым зур корсаклы бер симезгә. / Мәгълүм инде, аңа бардым түгел сөеп: "Егълау-риза, дәшмәү-риза»га буйсынып».

Алга таба автор хатынның исерек, тупас ир белән гаугалы, газаплы, тәмугтай гаилә тормышын сурәтли.

Мәгълүм ки, хатын-кыз язмышы — XIX йөз ахыры — XX гасыр башы татар тормышында һәм әдәбиятында иң мөһим мәсьәләләрнең берсе. Р.Фәхреддин, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан һәм башка күп кенә әдипләр милләтнең тәрәккыятен турыдан-туры хатын-кызның хокуклы, белемле, тәрбияле булуына бәйләп карыйлар. «Фөрьяд» шигыре дә әнә шул контекстта туган. Әсәрнең «Әлислах»та басылган тексты соңында «ахыры бар» дип куелган. Әмма, ни сәбәптәндер, аның бу өлеше дөнья күрми. Әсәрнең тәмамланмаганлыгы аның эчтәлегендә дә сизелеп тора. Ул «Бик нык торам үз хакымны теләүдә мин, / Һәнүз (һаман) шулук хокук көен көйләүдә мин» дигән юллар белән башлана. Димәк, инде бу зат

күндәмлек халәтеннән чыккан, үзенең хокуклары өчен көрәш юлына баскан. Әсәрдә исә әле аның мондый үзгәреш-эволюциясе тасвирланмый калган. Әмма шулай да бар булган текстта хатынның үз хәлен үзе аңлавы, коллык психологиясенә тәнкыйди каравы ачык сизелә. Бу исә кешене тасвирлауда, шәхес үсешендә мөһим момент.

Шигырь *ааба ввгв*... рәвешендә рифмалашучы 16 дүртьюллыктан гыйбарәт. Һәр юлы 4 әр иҗекле 3 ритмик буыннан тора (4+4+4).

*Г. Тукай.* Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 202—204 (369) б.

Бу — Тукайга нисбәт ителгән шигырьләрнең берсе. Ул «Фикер»нең 1907 елгы 22 февраль санында «Болгар» тәхәллүсе белән басылган. Шигырь *ааба ввгв*... рәвешендә рифмалашучы, һәр юлы 8 әр иҗекле, 8 строфадан гыйбарәт. Интонацион яңгырашы белән такмак калыбына якын.

«Кайгыру» Дәүләт Думасына мөнәсәбәттә язылган. Тукайның бу тематикага нисбәтле берничә шигыре бар. Мәсәлән, «Государственная Думага» әсәрен (1906) ул I Дәүләт Думасы куып таратылгач яза. Анда шагыйрь бу органны эшлексезлектә, вәгъдәсезлектә гаепли. «Кайгыру» шигыре исә II Думага теләк-өметләрне үз эченә ала. Биредә инде гомумән Думаны тәнкыйтьләү юк. Шагыйрь депутатларны икегә бүлеп карый. Уңнар — халыкка каршы затлар. Суллар — «фәкыйрь эшче, кара халык» мәнфәгатен яклаучылар. Әгәр дә Думада суллар җиңсә, өмет бар: «Халыкның өмиде туар, / Ачыккан тамагы туяр; / Золым бетеп, хөрриятләр / Нуры берлән дөнья тулар». Әмма шагыйрь, гәрчә ул Думага аерым өметләр багласа да, реаль фикер йөртә. Аның карашынча, без теләгән Дума булган очракта да, «залим байлар дулап», хөкүмәтнең «эче пошып», андый Думаны «тагын куар». «Кайгыру» авторы хәлнең «начар»лыгын, «ирек», «тигезлек»ләрнең һаман булмавын искәртә, риторик сорау ярдәмендә «хөррият»нең килүен үзебезнең тырышлыкка бәйләп карый: «Хөрриятләр качан агар, / Башымызга качан тамар! / Үземез йокласак, дустлар, / Кемнәр безнең хәлне карар?» Публицистик яңгырашлы, иҗтимагый-сәяси эчтәлекле бу шигырь хәзерге көнгә дә аваздаш.

*Г. Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 325 (394—395) б.

Әлеге шигырь «Фикер»нең 1907 елгы 2 апрель саны кушымтасында «Шүрәле» тәхәллүсе белән дөнья күргән. Икешәр юллы 9 строфадан гый-барәт. Һәр юлда 4 әр ритмик буын, 16 шар иҗек. Бу гарузның һәзәҗ үлчәменә туры килә. Рифмалашуы газәлдәгечә: *аа ба ва*. Әмма эчтәлеге мәхәббәт турында түгел, ә иҗтимагый-әхлакый характерда. Газәлдән аермалы буларак, бу шигырь сатирик, тәнкыйди рухта. Хәтта аларның да шактый усалы, тәмам бетереп ташлый торганы.

Мәгълүм ки, 1906—1917 елларда Оренбургта «Дин вә мәгыйшәт» (әүвәлге исеме — «Дөнья вә мәгыйшәт») журналы чыга. Ул хатын-кызларга ирек, азатлык бирүгә каршы аерым материаллар бастыра. Журналның мондый эш-гамәле алдынгы, демократик көчләрдә тирән ризасызлык уята. Иҗатында хатын-кыз хокукларын, аның бәхет-сәгадәтен яклаган Тукай бу шигырендә «мәгыйшәтче»ләрне кискен тәнкыйтьли, аларны «шарлатаннар», «ахмак», «исергән баш», «кара йөзләр» дип атый. Һәр бәйт диярлек риторик сорау белән төгәлләнә. Мондый алым укучыны уйландырырга, мәсьәләнең асылына керергә мәҗбүр итә. Гомумән, шигырь үзенең публицистик яңгырашы, эчтәлеге белән ярсулы оратор чыгышын хәтерләтә. Ахыргы строфа исә алда сөйләгәннәргә җавап, нәтиҗә рәвешендә килә: «Дөрест, һәрбер халыкта бар дорыр мондый кара йөзләр, / Вәләкин һичбере милләткә мондый сасы иснәтми».

Шигырьнең теле гарәп-фарсы сүзләре белән чуарланган. Бу, мөгаен, «Дөнья вә мәгыйшәт» журналының теленә, төп адресатка нисбәтән дә шулай эшләнгәндер.

*Г. Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 152 (356) б.

Тукайның бу шигыре 12 дүртьюллык строфадан гыйбарәт. Рифмалашуы төрлечә: *ааба..., ввгв.., ддед*... Иҗтимагый-социаль һәм фәлсәфи эчтәлектәге бу шигырь авторның дустына мөрәҗәгать итүе, киңәш бирүе рәвешенә корылган. Сатирик элементлар, чынбарлыкны фаш итү рухы да бар. Шигырьнең тәүге өчтән ике өлешендә мондый фикер уздырыла: бу җәмгыятьтә намус белән, вөҗданлы яшәп булмый. «Ялганласаң», «ач-ялангачларны белмәсәң», «иманыңны сатсаң», «корсак» мәнфәгатьләрен генә кайгыртсаң, «кәп-кәкрене туры дисәң», иҗатыңда «майласаң да балласаң», «капиталга» сәҗдә кылсаң...— бу дөньяда яшәү ансат. Алга таба автор үзе әйткән киңәш-теләкләрнең дусты өчен чит булуын искәртә. Чөнки ул тугры, кыю. Әмма мондый затларга яшәүгә караганда үлем

яхшы: «Хаклык астка күмелгән шул, өсттә түгел, / Шуның өчен астка табан тарта күңел; // Хаклык берлән мәхшәргәчә бергә булыр / Өчен, син дә,— тиз бул, тиз бул,— җиргә күмел!»

Шигырьдә элек-электән әдәбиятта эшкәртелеп килүче туфрактан туфрак булу идеясе дә гәүдәләнеш тапкан («Үл! Туфрак бул, кайт аслыңа,— аслың яхшы»).

Бу строфада автор, дустына эндәшен алыштырып, Җир шарына мөрәҗәгать итә: «И Җир шары! Нидән, белмим, хак сөйгәнгә» / «Мең кат синең өстеңнән дә астың яхшы». Моның белән шагыйрь, гүя үз әйткәннәренең хосусый күренеш кенә булмыйча, гомумән яшәеш өчен хас сыйфат булуын да искәртә.

«Дөньяда торыйммы? — дип киңәшләшкән дустыма» тәүге мәртәбә «Таң мәҗмугасы»ның 1907 елгы 1 июнь санында басылган.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Дүрт томда. 1 т.— 91—93 (375) б.;
*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 163—164 (360) б; Татар әдәбияты тарихы — 3 т.— 117—118 б.

Тукайның «Булмадың ярым вә булмассың, беләм, җефтем минем» мисрагы белән башла-

нып киткән бу шигыре *аа бб*... рәвешендә рифмалашучы икешәр юллык өч строфадан (бәйттән) гыйбарәт. Әсәрдә хатын-кызның, бернинди канун, әдәп-әхлак кагыйдәләрен санга сукмыйча, үзе теләгәнчә яшәве, лирик каһарманның йөрәген яндыручы зат булуы рәсемләнә. Шигырь Урта гасыр әдәби традицияләре рухында язылган.

«Гыйлавә» 1908 елда язылып, шул ук елда «4 нче дәфтәрдә» басылып чыга.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Дүрт томда. 1 т.— 128 (382) б.;
*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 199 (368) б.

Тукайның6 бәйтлек бу шигыре миниатюр драманы хәтерләтә. Егет кызга үзенең гыйшкый

хис-тойгыларын юмористик планда бәян итә: «Сөям чүмеч кеби борыныңны, җаным, / Гашыйк булдым, тәмам бетте мәҗалым (тәкатем, сабырлыгым)». Кыз да аңа шул рухта җавап бирә. Шигырьдә халыкның көлү культурасына һәм фольклорына хас лексика, эндәш, риторик сорау кебек поэтик чаралар кулланылган. Тукай бу шигырен язганда, өлешчә Г.Кандалыйның (1797—1860) «Сахибҗәмал» әсәреннән дә файдаланган. Кандалый: «Насыйб булып, ала калсам, җанашым, / Савыт-саба, табаклар да кирәкми». Тукай: «Сине алсам, чүмечле һәм иләкле / Булам ич — акча туздырмак кирәкми».

«Егет илә кыз» концерт программаларында еш яңгырый.

Шигырь, 1908 елда язылып, шул ук елны «Әлислах»ның 28 февраль санында «Кыз илә егет (авылда)», «Диван»да «Егет илә кыз» исеме белән дөнья күргән (1908).

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Дүрт томда. 1 т.— 138 (383) б.;
*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 210 (370) б.

Тукайның бу исемдәге өч шигыре бар. Бу парчасы мондый юллар белән башлана: «Якын

дустым! Сиңа миннән киңәш шул: / Кешеләргә сереңне сөйләмәс бул. // Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел, / Үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл».

Мәгълүм ки, үзгәләргә сереңне ачмаска кушу — татар әдәбияты һәм фольклоры өчен хас мотив. Мәсәлән, Сәйф Сараи (1321—1396) болай ди: «Ни серрең (сереңʼ) кем бар — дустларыңа димәгел (әйтмәгел), ни белүрсән кем — бер вакыт дошман булгайлар...» «Дустыңның да дусты булыр, / Сер сөйләмә дустыңа»,— дип җырлый халык. Тукай шушы традицион мотивны үзенчә эшкәртә. Шагыйрь карашынча, кешеләргә эгоизм хас. Шигъри фикерне тагын да үткенәйтеп, ул болай ди: «Алар ерткыч, алардан читтә бул син, / Алар барда бүрең бер якта торсын».

Шагыйрь, аеруча, «мактаулардан» сакланырга куша. Кайгы-хәсрәт килсә, «аулакта утыру», «сабыйдай, тәмле-тәмле күз яше түгү» лязем. Мондый чакта берәү килеп керсә, аңа: «Күзләрем никтер авырта, / Өзелми яшь ага кич һәм дә иртә!» — дип җавап бирергә куша.

Шигырьнең интонациясе аның эчтәлегенә туры килеп тора. Эндәш, мөрәҗәгать, кабатлау, поэтик синтаксис чаралары әсәрнең идеясен үтемлерәк итүгә булыша.

«Киңәш» тәүге мәртәбә «Әлислах»ның 1908 елгы 15 сентябрь санында басылган.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Дүрт томда. 1 т.— 185—186 (396) б.;
*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 1 т.— 253 (382) б.

Тукайның бу шигыре рус шагыйре Майковтан тәрҗемә ителгән. Бу хакта Тукай үзе дә искәртә. Майковның «Совет» парчасы да, Тукай шигыре дә бер үк идеяне раслыйлар: һәр инсан

үзгәләрнең ярдәменә ышанып ятмаска, үзе тырышырга, үзе хезмәт итәргә бурычлы. Моның киресе икән, кеше авыр хәлдә кала, хәтта ачтан үләргә дә мөмкин.

Оригинал белән тәрҗемәнең гомуми эчтәлеге, күп кенә сурәтләре үзара бер-берсенә бик якын, хәтта уртак та. Әмма Тукай русча текст белән иҗади эш итә: урыны белән кыскарта яисә өсти. Мәсәлән, Майковтагы «Много слышал добрых я советов, / Наставлений, ласки и обетов» юлларын Тукай болай бирә: «Миңа дустлар, танышлар һәм белешләр / Хисапсыз бирделәр яхшы киңәшләр». Татарча текстта киңәш бирүчеләр конкретлаша, ә «наставлений, ласки и обетов» гыйбарәсе «яхшы киңәшләр» рәвешендә генә белдерелә. Оригиналдагы «Я поверил, ждал, заботы кинул» мисрагы тәрҗемәдә киңәйтелә, «иҗтиһад», «эшсез»лек төшенчәләре үзәккә куела: «Ышанмаслык түгел бит,— яхшы сүзләр; / Бирә тәмле өмидләр,— якты йөзләр.// Ышандым, иҗтиһадны ташладым мин,/ Һаман уйнап көләргә башладым мин». Тәрҗемәнең соңгы өлешендә лексика татар әдәби традицияләре рухында сайланган. Мәсәлән, Тукай оригиналдагы «человек-то добрый» сүзләрен С. Сараи, Мөхәммәдьяр һәм башка шагыйрьләр иркен кулланган «ихсанлы кеше» рәвешендә бирә.

«Кемнән ярдәм эзләргә?» шигыре тәүге мәртәбә Тукайның «Диван»ында (1908) басылган.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Дүрт томда. 1 т.— 176 (391—392) б.;
*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 245 (378) б.

«Япун хикәясе» — *аа бб...* рәвешендә рифмалашучы, һәр юлы өчәр ритмик буынлы, 12 шәр иҗекле, 46 бәйтлек лиро-эпик әсәр. Үзенең

эчтәлеге, төзелеше белән ул элеккеге тезмә хикәятләр рухында иҗат ителгән. Тукай бу әсәрен рус әдибе (шагыйре, публицисты, драматургы, прозаигы) В.П.Буренинның (1841—1926) «Японская сказка» исемле көйле хикәясеннән файдаланып язган. Сюжет һәм геройларда аермалар артык зур түгел. Әмма детальләрдә, шигъри формада үзгәлекләр шактый.

«Я...» Көнчыгыш сүз сәнгатенә, әкиятләргә хас булган традицион, шартлы башлам белән башланып китә: Электә бер Ташчы торган бу дөньяда,/ Безнең җирдә түгел — ерак Япунъядә.// Үзе булган таза гына бер яшь егет; / Ялыкмыйча эшли икән ул таш эше». Ул көн саен хезмәт иткән, арган-талчыккан. Бервакыт Ташчы, Ходайга мөрәҗәгать итеп, үз хәленә зарланган: «Ходаем, ник фәкыйрь иттең мине болай?/ Рәхмәтең киң, мин бәндәңне кыйлсаң да бай». Бу сүзләрне «бер фәрештә» ишетеп ала да Ташчыны «шул минуттук зур бай» итә: «Инде хәзер авыр эшләр муенда юк,/ Рәхәт ята, һичбер нәрсә уенда юк». Әмма егетне болар гына канәгатьләндерми, аның «Олугъ бер хан» (русчада — император) буласы килә. Ташчы бу теләгенә дә ирешә: «...Уенчылар матур көйләр көйләгәли,/ Баш өстендә алтын зонтик күләгәли». Әмма эссе, кояш кыздыра. Шунда ул Фәрештә ярдәмендә кояш була: «Күктә тора, бу дөньяга нурлар коеп». Әмма аны болыт каплый. Моңа кимсенеп, Ташчы болыт була: «чиләк-чиләк» яңгыр яудыра, «сахра, игенлекләрне» су белән бастыра. Ә таш-тауның моңа исе дә китми. «Егет әйтә: «Кирәк түгел болыт булу,/ Артык миңа болыт булганчы юк булу!» Менә ул — таш-тау. Горурланып, «селкенми дә, кузгалмый да тора». Әмма кулларына балта белән чүкеч тоткан бер Инсан килеп, таш-тауны вата башлый: Шунда егет элеккеге һөнәренә кайта: «Кирәк түгел, мин яңадан Ташчы булам,/ Әүвәлгечә иҗтиһадлы (тырыш) эшче булам».

Төрки-татар халкында, аның сүз сәнгатендә хезмәтне зурлау, аны бәхет-сәгадәт чыганагы, әхлаклылык факторы дип карау элек-электән килә. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» романында (1342) Фәрһад — ташчы, кешеләргә игелек китерүче зат. XVII йөз шагыйре Мәүла Колый игенчелекне иң «гали» (бөек) һөнәр дип саный: Тукай да бу күркәм традицияләрне дәвам итә («Эшкә өндәү»...). В.П.Буренин әсәре мисалында ул үз укучыларына аваздаш, тәрбияви мотивларны күрә һәм шуңа күрә дә аны, үз иҗат казанында кайнатып, татарчага күчерә.

Төрле рәвешләргә кереп, төрле вазифаларны сынап караган Ташчы, гәрчә әүвәл зарланса да, «галилек һәм бәхет»нең гади хезмәттә генә булуына тәмам төшенә: «Күрдем хәзер: эшкә һичнәрсә тиң түгел,/Эштән көчле нәрсә табу мөмкин түгел. «Иҗтиһадлы эшче» — аның идеалларыннан берсе.

Әсәр салмак хикәяләүгә корылган. Ташчының эш-гамәлләре, Фәрештә белән әңгәмә шигырьнең төп эчтәлеген тәшкил итә. Егетнең бер-берсен кире кагу формасындагы төрле рәвешләргә керүе мантыйкый яктан шактый дәлилләнә. Бай, хан, кояш, болыт, тау-таш булу күренешләре билгеле бер кинокадрлар рәвешендә күзаллана. Борынгы мифологик фикерләү белән бәйләнешле бу төр әверелү-метаморфозалар

хикәяләүгә динамик төсмер бирәләр. Ташчының, төрле сынауларны узып, элеккеге шөгыленә янә кайтуы (әмма рухи яктан баеп) әсәрнең композицион яктан төгәлләнешен дә тәэмин итә.

«Япун хикәясе» тәүге мәртәбә «Әдәбият»та (1909) дөнья күрә. Аннан соң да күп тапкырлар басылып чыга. Педагогик процесста да бу әсәр еш файдаланыла.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 57—60 (352—353) б.

Бу әсәрнең төп эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт: лирик геройны («мин»не) хәлфәсе «сабый чакта» «бер яхшы нәрсә»гә өйрәтә: «Сөбханалла»

диеп әйтү тиеш,— диде/,— Бер мән (кеше) яңа гына туган айны күрсә». «Сөбхан» — мактау, данлау, хуплау дигән сүз. «Сөбханалла» дип, гадәттә, сокланганда, уңай мөнәсәбәтләрне белдергәндә, мактаганда әйтәләр.

Лирик герой хәлфәсенә рәхмәтле, аның киңәшен үзе өчен гадәткә әйләндерә, хәтта сөйгән яры белән очрашып, «теле тотлыкканда» да «сөбханалла!» сүзе аңа ярдәмгә килә.

Алга таба автор кызыклы бер борылыш ясый. Әгәр, ди лирик герой, «шул матурны» укымаган», «гади генә» «Гайнетдиннәр...» күрсә, алар бу сүзне әйтә алмаслар иде. Әсәр «мин»нең бераз мактануы, һавалануы рухындагы юллар белән төгәлләнә: «Әгәр, хәлфә,/ мин дә шулай надан булсам,/ Синнән гыйлем алалмыйча калган булсам,/ Әйтер идем, шулар кеби, мин гыйрфансыз (аң-белемсез):/ Әй-яй, бигрәк матур икән, чукынган кыз!»

Шигырь лиро-эпик характерда. «Мин» һәм «хәлфә» белән мөнәсәбәтле вакыйга лирик геройның уй-кичерешләре, эмоциональ мөнәсәбәте белән үреп бирелә. Әсәр юмористик рухлы. Автор карашынча, гүзәллек, матур кыз алдында укыган да, надан да — берәү дә тыныч кала алмый, һәркем үзенчә соклануын белдерә.

«Сөбханалла, сөбханалла!» шигыре *ааба ввгв*... рәвешендә рифмалашучы 7 дүртьюллык строфадан гыйбарәт. Аерым юлларда «сөбханалла...» сүзенең кабатлануы шигырьдәге фикри һәм хисси бөтенлекне арттыра, әсәрнең эмоциональ яңгырашын көчәйтә. Соңгы строфаның ахыргы сүзе алдагы мисраглар белән рифмалашмаган (надан булсам — калган булсам — кыз). Мондый аерымлык соңгы юлның («Әй-яй, бигрәк матур икән, чукынган кыз!») мөһимлеген, көтелмәгәнчә булуын ассызыкларга ярдәм иткән. «Чукынган кыз» гыйбарәсе дә бу очракта халыкчанлыгы, вазгыятькә тапкыр килүе белән сыйфатлана. Гомумән, әсәр үзенең лексик составы, синтаксик төзелеше белән халыкның образлы фикерләвенә бик якын. Анда халык җырларына, «Кыйссаи Йосыф» китабына хас булган гыйбарәләр һәм сурәтләр дә кулланылыш тапкан («Тулган айга охшаш йөзе», «яңа туган айга охшаш кашы...»; «Укымаган алар, бернәрсә белмиләр»...).

«Сөбханалла, сөбханалла!» шигыре һәр юлы өчәр ритмик буынлы, 12 шәр иҗекле строфалар белән язылган. Бу ягы белән ул Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендәге шигъри төзелешне дә хәтерләтә.

Шигырь сәхнәләрдә, радио-телевидение аша еш яңгырый.

«Сөбханалла, сөбханалла!» тәүге мәртәбә 1909 елның октябрендә «Әдәбият»та нәшер ителгән.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 47 (351) б.

Бу — исемсез шигырь. Такмак рухындагы ике дүртьюллыктан гыйбарәт. «Хайлыйм...» дип башланган тәүге юл «гаҗәпләнәм гаҗәп хәлләргә» мәгънәсендә. Алга таба «Чәйдәш абзы-

кай»га «сторож» булып яллану, «Яшен»чене әрләү, «Мәрьям белән парлап» җырлау хакында сүз бара.

Сатирик рухлы бу парчаның эчтәлеге, мәгънәсе тарихи, реаль фактлар белән бәйләнештә генә тиешенчә аңлашыла.

Шигырь «Яшен»нең 1909 елгы 29 апрель санында рәсем асты тексты рәвешендә имзасыз басылган. Әмма аны Тукайга нисбәт итәләр.

Шигырьдәге «Чәйдәш абзыкай» — Казан сәүдәгәре, «Бәянелхак» газетасы нашире Әхмәтҗан Сәйдәшев. «Яшен»дә аның «Нашир әфәнде» дип исемләнгән рәсем-карикатурасы бар. Портретның бер ягында — тузган чәчле ир-ат башы («Музей сторожы»), икенче кырыенда — хатын-кыз башы. Шунда ук «Мәрьям илә җырлый» дигән сүзләр язылган. Ә бу шигырь шушы рәсемнәр астында китерелгән.

Бу вакытта «Бәянелхак»та эшли башлаган С.Рәмиев «Казан мөхбире» газетасында «Музей сторожы» тәхәллүсе белән «Яшен»гә, «Әлислах»ка каршы аерым тәнкыйть материаллары бастыра. Истәлекләрдән С.Рәмиевнең җырчы булуы да билгеле. Аның җырчы Мәрьям Искәндәрова белән аерым көйләрне бергәләп башкаруы да мәгълүм. Шигырь карикатур шәкелдә әнә шуларга ишарә ясый.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Дүрт томда. 2 т.— 25 (338) б.;
*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 23 (347—348) б.

Тукайның бу шигыре тәүге мәртәбә «Яшен» журналының 1909 елгы 2 нче март санында «Шүрәле» имзасы белән дөнья күргән. Әсәр рус

шагыйре В.В.Князевның (1887—1937) Петербургта чыга торган «Сатирикон» журналының 1909 елгы 24 нче номерындагы «Либерал средней руки перед банкетом» шигыреннән файдаланып иҗат ителгән. Бу хакта Тукай үзе дә әсәрнең исеменнән соң җәяләр эчендә «Сатирикон»нан дип искәртә. Автор үзенең 1909 елгы шигырьләр мәҗмугасында, ягъни «Әдәбият»та, астөшермә ясап, әсәргә мондый аңлатма бирә: «Сатирикон» журналында берәү, хатыннар тарафдары булып, идән буенда: «Хатыннар! Атлаңыз алга!» — дип, гайрәтләнеп йөргән бер кешенең, фәкать чалбарын тазартмаган өчен, үз хатынын эт итеп сүккәненнән көлә.

Миңа килгәч, ул шигырь, табигый, миллиләште. Күп кешеләр бу шигырьдән морад нәрсә икәнен бөтенләй аңлап җитмәгәнгә, азрак изах иттем (аңлатып бирдем). Мөтәрҗим (тәрҗемәче)».

«Х...» *аа бб*... рәвешендә рифмалашучы 9 икеюллык строфадан гыйбарәт. Һәр юлда 16 шар иҗек. Шигырьнең тәүге 7 строфасы публицистик чыгышны хәтерләтә. Лирик герой хатын-кызларга «хөрлек», «азатлык» бирү өчен көрәшне үзенең төп яшәү максатына әверелдерүе хакында яза: «Көям бирмәк өчен хөрлек, азатлыклар хатыннарга;/ Бөтен фикрем, уем шулдыр, карамый көн вә төннәргә». Бу изге эшкә ул бөтен «матбугат»ны, «дөнья халкы»н һәм хатыннарның үзләрен дә чакыра. («Хатыннар! Атлаңыз алга! Бу юлда шаула, матбугат!» «Иел, и халкы дөнья! Уртадан юл бир хатыннарга!»)

Шигырьнең беренче өлеше җитди тонда. Андагы фикер-теләкләр XX йөз башы татар иҗтимагый һәм мәдәни тормышы белән турыдан-туры керешеп китә. Башка әдипләр кебек, «Х...» авторы да милләт тәрәккъыятен хатын-кызның тырыш, белемле булуында күрә: «Укы, яз, бел, тырыш син, и мөкатдәс яртыбыз безнең! Кеше булмак өчен иң-иң беренче шартыбыз безнең!»

Әсәрнең соңгы ике строфасында тон да, эчтәлек тә үзгәрә. Моңа кадәр изге, файдалы сүзләр сөйләгән «мин» чалбарындагы тапны чистартмаган өчен хатынын эт урынына сүгә, аны «сыер» дип атый. Моның белән автор сүз һәм гамәл берлеген сакламаучыларны кытыклый, фаш итә. Әсәрнең «Шүрәле» имзасы белән басылуы да бик мәгънәле, символик.

Тукай, гәрчә ул үзен «мөтәрҗим» дип атаса да, «Сатирикон»дагы текст белән иҗади эш итә. Бу әсәрнең һәм күләмендә, һәм төзелешендә, һәм эчтәлегендә ачык күренә. Татар шагыйре В.В.Князев шигырендәге мотивны, үзе әйтмешли, шактый «миллиләштерә». «Таралырга вакыт инде чапан атлы болытларга;/ Чапаны да, Бохары да ашарга калсын этләргә!» һ.б.— шуның ачык мисалы.

*Г. Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 9 (343) б.

Тукайның бу шигыре 11 бәйттән, ягъни икеюллыктан гыйбарәт. Һәр юлда 15 әр иҗек,

дүртәр ритмик буын. Шигъри үлчәме белән бу әсәр гарузның рәмәл төренә туры килә. Рифмалашуы *аа ба ва*... рәвешендә. Һәр юлдан соң бер үк сүз — «күрсәтә» кабатланып килә, ягъни рәдиф вазифасын үти. Үзенең строфа төзелеше, гаруз белән язылуы, рифмалашуы ягыннан «Күрсәтә» газәл жанрына туры килә. Мәгълүм ки, классик газәлләр, нигездә, мәхәббәт турында. Бу әсәрнең эчтәлеге исә әхлакый-фәлсәфи характерда.

Инсан, гомумән, үзенең тышкы табигате белән яхшыга — уңай, ә яман эшләргә — тискәре мөнәсәбәтле. Шушы закончалык шигырьнең тәүге бәйтендә үк гәүдәләнеш тапкан: «Ай кеше! Тыштан үзендә изге хасләт (сыйфат) күрсәтә,/ Яхшыга — рәгъбәт (теләктәшлек), яман эшләргә нәфрәт күрсәтә». Бу тезис алга таба тулыландырыла, детальләштерелә («... дингә вә Коръәнгә итагать күрсәтә»; «... чынлыкны сөя...»). Әмма, баксаң, кеше еш кына икеөйзлелек күрсәтә, эгоистларча эш итә икән: «Булса килмәслек үзенә тугры әйткәннән зарар,— /Ул да чынлыкны сөя, сүздә сәдакать (турылык) күрсәтә... // Мин арыслан! — ди, синең малны тәләф иткәндә (туздырганда) ул, / Син аңар калсаң: фәкыйрьмен, ди, җәбанәт (куркаклык) күрсәтә». Әмма иң аянычлысы шул: башкаларга ул синең гайбәтеңне сата; ә инде очрашкач, сиңа теләктәшлек, мәхәббәт белдерә: «Чәнчә дә ул күңленә явыз лисане хәнҗәрен (хәнҗәр кебек телен): / Нигә кәйфең китте, дустым? — ди, мәхәббәт күрсәтә...».

Аерым инсаннарга хас мөнафикълык күренешләрен тәнкыйтьләү язма әдәбиятта элек-электән күзгә ташлана (Йосыф Баласагунлы, Мәхмүд Болгари, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр һ.б.). Тукай шул традицияне уңышлы дәвам итә.

«Күрсәтә» тәүге мәртәбә «Әлислах»ның 1909 елгы 30 апрель санында дөнья күргән. «Ахыры бар» дип язылса да, ахыры хәзерге фәнгә мәгълүм түгел.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 25—26 (348) б.

Тукайның бу шигыре фәрд жанрында, ягъни бер икеюллыктан гыйбарәт: «Ялангач калдый-
сәң син һәр җәһәттән фазлы Тәңридән (Алла рәхмәтеннән) / Мыраулый башла бик ямьсез, алып үрнәк Бәширидән».

Бәшири — әдип Зариф Бәшири (1886—1962). Тукай монда аның ашыгыбрак язылган шигырьләреннән көлә.

«Киңәш» «Яшен» журналының 1909 елгы 9 май санында «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында «Шүрәле» имзасы белән дөнья күргән.

*Г. Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 33 (349) б.

Тукайның өч бәйтлек (строфалык) бу әсәре рус шагыйре Н.И.Позняковның (1856—1910) «Если в сердце человека...» шигыреннән өлешчә файдаланып язылган (Н.И.Позняков. В лучшие
годы.— СПб., 1896.— С.61).

Шигырьнең төп мәгънәсе кайтмаска киткән нәрсә өчен кайгырмаска, урынсызга яшь түкмәскә чакырудан гыйбарәт. Лирик герой хәрәкәтне, кыюлыкны, тормышчанлыкны хуплый, Алланың ярдәменә дә өметен баглый: «Түкмә күз яшь: ярдәмеңдә һәр заманда Алла бар; / Ал җәсарәт (батырлык; кыюлык), алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!»

«Киңәш» «Йолдыз»ның 1909 елгы 29 ноябрь санында дөнья күргән. Ул ике кисәктән гыйбарәт: беренчесе — «Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен...», икенчесе «Чикмә гамь...» дип башлана. «Күңел җимешләре» җыентыгында (1911) шигырьнең тәүге 6 юлы «Киңәш», ә калган өлеше «Сәрләүхәсез» исеме белән аерым-аерым басылган.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Дүрт томда. 1 т.— 63 (344) б.;
*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 62 (353) б.

Әлеге шигъри әсәр тел-стиленең халыкчанлыгы, идея эчтәлегенең тормышчанлыгы белән сыйфатлана. Шигырь язма әдәбият һәм фольк-
лор башлангычларының синтезын (кушылмасын) хәтерләтә. Бер үк әсәр эчендә мәсәл һәм бәет жанрлары кушылып бирелгән.

«Кәҗә тугрысында» әкиятләргә һәм мәсәлләргә хас булган сүзләр белән башлана: «Бер заман йорт кошлары, хайваннары / Хуҗаның каршына килделәр бары: // И Хуҗа, безгә ризык биргән Хуҗа! — / Дип сакалын селкетеп сөйли Кәҗә». Ул үзенең сөт бирүен, әмма хуҗасының туярлык ашатмавын, шуның өчен «караклыклар» итүен, тиргәүләргә дучар булуын әйтә. Моңа җавап, аңлатма рәвешендә, Кәҗә турындагы бәет китерелә. Анда Кәҗәнең «Каза» дигән кушаматы да булуы, «кәбестә, суган кыякларын» «кыркып», кешеләргә зыян китерүе хакында сөйләнә. «Ул Кәҗәне кайда күрсәң, шунда кыйна, / Язык булмас, бәлки сәвап булыр имди».

Шигырьнең тәүге 10 строфасының һәр юлы 11 әр иҗекле, 3 әр ритмик буынлы икеюллыклар белән язылган. Ул гарузның кыскартылган рәмәл үлчәменә туры килә. Шигырьнең Кәҗә турындагы бәетне үз эченә алган икенче өлешенең һәр юлы 12 шәр иҗекле, *аааб вввб*... рәвешендә рифмалашучы 3 дүртьюллыктан гыйбарәт. Ул шигъри үлчәме һәм төзелеше белән «Кыйссаи Йосыф» строфасына туры килә.

Әлеге шигырь тәүге мәртәбә «Йолдыз»ның 1910 елгы 23 февраль санында һәм «Ялт-йолт»ның шул ук елгы 1 март санында «Шүрәле» имзасы белән басылган.

«Ялт-йолт»та «Газеталардан» дигән баш астында мондый юллар бар: «Бездә «кәҗә» асраган кешеләр, бик начар нәселләрне генә асрап, һичбер төрле карамаганлыктан, елына 10—25 чиләктән артык сөт ала алмыйлар. Хәтта җәй көнендә, «ул үзенә ашарга таба» дип, бер дә ашатмыйлар да. Шуның өчен кәҗә, һәр төрле караклыкларга бирелеп, «нәфрәте гомумия»гә мөстәхикъ (ия; лаек) буладыр...». Шуннан соң «Бу хосуста кәҗәнең үз фикере» дип куела һәм шигырь бирелә.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 94—95 (356) б.

Дин галиме, философ Муса Бигиевнең (1874—1949) 1910 елда «Рәхмәте илаһия гомуми» исемле хезмәте басылып чыга. Анда Алла рәхмәтенең муллыгы, нинди диннән булуына да карамастан, һәммә кешегә дә җитәрлек икән-
леге хакында фикер уздырыла. Тукай бу шигырен шушы китап чыгу уңае белән туган шау-шу, бәхәсләргә мөнәсәбәттә иҗат итә. Анда «әһле» Петербург, Нью-Йорк, Берлин, «Лондон әһле», «япун»,

«чин», «финнәр»не телгә алу аша гомумкешелек төшенчәсе тудырыла. Һәммәгезгә, ди шагыйрь, «бәшарәт!» Дүрт строфалык бу шигырь шушындый бәйт белән тәгәлләнә. «Беләмсез, калмыйсыз сез утта мәңге,— / Алыр сезне йолып Муса әфәнде!»

«Зур бәшарәт!» «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 1 март санында «Гөмбертт» имзасы белән басылган.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 96 (356) б.

Катле нәфес гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә үз-үзеңне үтерү дигән сүз. Борынгы дини-мифологик карашлар нигезендә, кеше тән һәм җан (рух)

берлегеннән гыйбарәт. Инсан үлгәч, тән туфрак була, ә җан яшәвен дәвам итә. Суфыйчылык шагыйрьләре (Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Өмми Кәмал, Мәүла Колый, Шәмседдин Зәки һ. б.) бу темага аеруча нык игътибар юнәлттеләр. Алар раславынча, тәннең ниндилеге рухка бәйле. Шуңа күрә кеше үзенең яшәешендә тәннән бигрәк рухны пакьләү, камилләштерү белән шөгыльләнергә тиеш. Тукай да бу шигырен нәкъ әнә шул традицияләр юнәлешендә иҗат иткән. Әмма ул аны гомуми планда түгел, фаҗигале язмышка дучар булган затка дәшү рәвешендә язган.

«Татсыз хәяттән», «җан авырттыргыч газаптан» котылырга, «тынычлыкка» ирешергә теләгән бер инсан үз-үзенә кул сала. Тукай мондый гамәлне «зур җинаять», Алла бирергә мөмкин бәхеттән баш тарту дип саный: «Ашыктың, эшләдең бик зур җинаять!» Шагыйрь фикеренчә, тән бер кием кебек кенә: «Кирәк черсен, кирәк торсын — ни ул тән? — / Чыдамсыз бер кием ул җанны өрткән!»

Синең, ди шагыйрь, «дөньяда күргән газабың» — «җаның бозык булудан». Иң мөһиме — рухны камилләштерү, «ислах итү» (төзәтү), җанны «изгелек белән тутыру».

Әгәр рухыңны ислах итми үлсәң, / Барыбер син газапта, яхшы белсәң!

Тукай үз фикеренең үтемлелеген арттыру өчен, шигырьне халык телендәге канатлы сүз белән тәгәлләп куя: «Газап китми кабердә тән черүдән: / Бүрек ташлап котылмыйлар бүредән!»

«Катиле нәфескә» строфалары *аабб...* рәвешендә кафияләшүче 10 бәйттән гыйбарәт. Шигырь кыскартылган өч буынлы һәзәҗ үлчәме белән (V- - - V - - - V - - - ) язылган.

Шигырь «Йолдыз»ның 1910 елгы 15 апрель санында басылган.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Дүрт томда. 2 т.— 103 (351) б.

Тукайның бу шигыре тормышка, инсаннарның үзара мөнәсәбәтләренә хас булган кешегә ышаны-ышанмау, икейөзлелек мотивын тасвирлауга багышланган. Лирик герой, кайчакта ачылып китеп, үзенең кайгы-моңнарын, эч серләрен «иптәшенә» сөйләве хакында яза. Дусты да аны игътибар белән, йөзендә «нурлар» балкытып тыңлый. Әмма ниндидер бер билгесез аваз «мин»гә болай ди: «Ышанма, дөньяда һәркемдә ялган!» Иптәшең «тышыннан» гына сиңа теләктәш, чынлыкта «кара йөз ул, кара эч ул һаман,/ Мәхәббәт һәм кешелек юктыр анда». Бу яшерен «аваз» «иптәш»нең нурлы йөзен дә үзенчә аңлата. Чөнки, ди ул, син «кайгы, хәсрәттән бушандың», «күңлең әчелде», «тирә-якка шуның нуры чәчелде».

«Йөзендә күргәнең нур иптәшеңнең / Нурыдыр саф күңел һәм күз яшеңнең».

Лирик герой бу «аваз»ның кемлеген белергә тели. Тегесе: «...Син рәнҗемә,/ Минем исмем — ачы, карт тәҗрибә»,— ди.

Кешегә ышану-ышанмау, «мөнафикълык» (икейөзлелек) мотивы төрки-татар әдәбиятында элек-электән эшкәртелеп килә. Йосыф Баласагунлы, Котб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Акмулла һәм башка шагыйрьләрнең иҗатларында моңа күпләгән мисаллар табарга мөмкин. Халык җырларында да «Дустыңның да дусты булыр, / Сер сөйләмә дустыңа» диелә.

Тукай шушы традицион мотивны үзенчә эшкәртә, аны тормышта, буыннар яшәешендә сыналган «ачы тәҗрибә авазы» рәвешендә тасвирлый. «Иптәше»нең нурлы күренүен аңлатуы да шигырьдә яңача кабул ителә. Әсәр «мин» белән күңел каршылыгын гәүдәләндерүгә, «аваз»ның сохбәт-диалогына корылган. Серле «аваз» дини мифология белән бәйле. Аны элек «һатиф» («яшерен тавыш бирүче», «изге рух», «гаиптән килгән аваз») дип йөрткәннәр. Мәсәлән, Ш.Бабичның «Һатиф вә татар» шигыре дә бар.

Тукайның «Ачы тәҗрибә авазы» әсәре *аа бб...* рәвешендә рифмалашучы 15 икеюллык строфадан — «мәснәви»дән гыйбарәт. Шигырь 11 әр иҗекле, өч ритмик буынлы. Ул гарузның кыскартылган һәзәҗ үлчәменә туры килә.

«Ачы тәҗрибә авазы» тәүге мәртәбә «Йолдыз»ның 1910 елгы 19 апрель санында басыла. Аннан соң «Күңел җимешләре» җыентыгында да дөнья күрә (1911).

*Г. Тукай*. Әсәрләр: Биш томда.2 т.— 119—120 (359) б.

Әлеге шигырь А.С.Пушкинның «Веселый пир» исемле әсәренә (1819) нигезләнеп язылган. Һәр
ике шигырьнең дә темасы бер үк: мәҗлес, дуслар белән кәеф-сафа кору. Әмма детальләрдә, шигъри формада аермалыклар да күзгә ташлана. Пушкинда: «Я люблю вечерний пир, / Где веселье председатель, / А свобода, мой кумир, / За столом законодатель». Тукайда: «Мин сөям дустлар белән булган хозур мәҗлесне кич, / Шундый мәҗлес: анда хөррият белән шатлык рәис». Оригиналдагы «вечерний пир» татарча текстта «хозур» сүзе белән детальләштерелә. Пушкин, «свобода» сүзенә үзенең экспрессив мөнәсәбәтен белдереп, аны «мой кумир» гыйбарәсе белән ачыклый. Тукай исә «хөррият» белән «шатлык»ны бер яссылыкка куя, «рәис»лекне аларның икесенә дә тапшыра. Алга таба да ике текст арасында төрлелекләр очрый. Русча әсәрдәге «заглушает крики песен» татар шагыйрендә «кясәләр булса тулы без мәст (исерек) булып аугангача» рәвешендә бирелгән. Мәҗлестәге катнашучыларны Пушкин «гость» дип атый. Татарда исә бу төр күңел ачулар бик хупланмый. Мөгаен, шуңадыр Тукай рустагы кунак төшенчәсен «эчкән кешеләр» дип кенә атый.

А.С.Пушкин шигыренең һәр юлы икешәр ритмик буынлы, 7—8 үлчәмле 8 тезмәдән (2 дүртьюллыктан) гыйбарәт. Тукай исә үз әсәрен *аа бб...* рәвешендә рифмалашучы 4 әр ритмик буынлы, 15 әр иҗекле шигъри шәкелдә язган. Ул гарузның рәмәл төрендә.

«Мәҗлес» беренче мәртәбә «Йолдыз»ның 1910 елгы 25 апрель санында басылган.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 122 (359) б.

Иҗат иясенең эшчәнлеге язуга хәзерлек, илһам, уй-кичерешләрне кәгазьгә төшерү, бушанып
калу кебек үзара тыгыз бәйләнешле халәтләр берлегеннән гыйбарәт. Тукайның бу шигырендә шундый халәтләрнең берсе — күңелнең «уйдан... бушанып калуы, «тәгътил», ягъни ял итүе тасвирлана. «Менә шул чак кешеләр шелтәлиләр: / «Нигә син язмыйсың һичнәрсә?» — диләр». Лирик каһарман мондый рухи халәтен акчасы юк кешенең «Сораучыга...: «Миндә вак юк!» — диюе белән чагыштырып, «Вакыт юк!» — дип җавап бирә.

«Кайчакта» — 7 бәйтле *аа бб...* рәвешендә рифмалашучы әсәр.

Тукайның бу шигыре «Йолдыз»ның 1910 елгы 2 май санында басылган.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 125 (360) б.

Тукайның бу шигыре *аа бб...* рәвешендә рифмалашучы 12 икеюллыктан (бәйттән)
гыйбарәт. Ул гарузның өч буынлы кыскартылган һәзәҗ үлчәме белән язылган.

Шигырьнең үзәгендә — авыр хәлдә калган лирик каһарманның рухи халәте, күңел газаплары. Ул үзен «тышкы» «яхшы»лыкка, «ялган көлүгә» ышанып «алдану»да, түбәнәюдә, ирексезлеккә төшүдә битәрли. «Нигә мин тормадым бер читтә ялгыз — / Ничек күктә яна бер данә йолдыз?» — ди лирик каһарман. Хәзер, ди ул, «әсирмен, ычкыналмам инде мәңге, /Күңелсез һәр ягым — нурсыз, караңгы!». Биредә шагыйрь мөселман фикерләвендә элек-электән тискәре мәгънәдә йөргән «монафикъ» сүзен куллана: «Монафикълар камап һәр дүрт ягымны, // Күрәлмим мин кояшым һәм аемны».

Лирик каһарманның идеалы, «кәгъбә»се күренми, рухы «сулыш... алалмый». Әмма әле ул тәмам өметсезлектә түгел. Кыен хәлдән чыгу кешенең үзенә дә бәйле: «Читен хәл: гайрәтең җитсә — ерып чык, / Әгәр җитмәс исә — бет, шунда тончык!»

Шагыйрьнең рухи халәте шактый дәрәҗәдә шул чордагы иҗтимагый-социаль шартлар, илдәге реакция белән дә бәйле.

«Үкенеч» «Йолдыз»ның 1910 елгы 1 июль санында басылган. «28 июнь, 1910 сәнә» дип искәртелгән.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 130 (360) б.

Әлеге шигырь балалар өчен язылган. Тәүге мәртәбә 1910 елда Тукайның шул исемендәге җыентыгында (Казан: «Милләт» матбагасы) дөнья күрә.

«Күңелле сәхифәләр»нең һәр юлы 5 әр иҗекле 7 дүртьюллык строфадан гыйбарәт. Рифмалашуы төрлечә: күпчелеге *ааба...* рәвешендә. Шигырьнең ритмикасы җиңел, хәрәкәтчән, эчтәлеккә туры килеп тора: «Бакчы аучыга, / Кош аулаучыга:/ Шактый читен эш — / Арый, талчыга... // Очадыр үрдәк,—/ Тизрәк бул, тизрәк: / Китмәсен ерак, / Ат мылтыкны, ат!» Аллитерация, ассонанс, мөрәҗәгать чаралары да динамиканы арттыруга ярдәм итә. Шигырьдә юмор да бар: җил аучының эшләпәсен очыра, үрдәк кача, ядрә эшләпәне тишә. Аучы кош урынына тишек эшләпә алып кайта. «Көлсә көләрләр / Кешеләр, күреп; / Тишекләреннән / Җил торыр өреп».

Шигырь балалар тарафыннан яратып укыла, сәхнәләрдән дә еш яңгырый.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 99 (357) б.

Ике бәйтлек бу шигырь табигать һәм күңел, үткән һәм бүгенге көн янәшәлегенә корылган.

Кичәге көннең «ямьсез»леге күңелнең «сынуы»на һәм «боегуы»на китергән. Ә инде «бүгенге» табигатьнең нурлы булуы лирик каһарманның да күңелен «бөтен» иткән. Шагыйрь «нурлы кояш», «ачылган гөл», «былбыл» сайравы аркылы тереклеккә, яшәешкә дан җырлый: «Әй кояш нурлы — ачылган бакчаларның гөлләре; / Яктылык! Рәхәт! Бәхет! Сайрый Ходай былбыллары!»

«Кичә һәм бүген» тәүге мәртәбә «Күңел сәхифәләре»ндә (1910) басылган.

*Г. Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 112 (358) б.

Әлеге шигырь *аа*... рәвешендә рифмалашучы 6 икеюллыктан гыйбарәт. Автор әсәр исеменнән

соң җәяләр эчендә «русчадан» дип искәрткән. Бу шигырь А.С.Пушкин әтисенең абыйсы В.Л.Пушкинның (1767—1830) «Голубка» (1806) исемле түбәндәге парчасына нигезләнеп язылган.

Голубка, под кустом прижавшись, говорила:
Ах, ястреб пролетел! Какая злость и сила!
Но, право, я должна судьбу благодарить,
Что ястребом она меня не сотворила!
Не лучше ль жертвою, а не злодеем быть!

Үз чиратында, В.Л.Пушкин бу мәсәлен Европа шагыйре Буассарадан тәрҗемә иткән.

«Күгәрчен» татар поэзиясенә хас һәм Тукай яратып куллана торган һәзәҗ үлчәменең кыскартылган төре белән иҗат ителгән. Аның һәр юлы 11 әр иҗекле, өчәр буынлы.

Шигырь кинаяле эчтәлектә, мәсәл жанрында. Ул болай башлана: «Бер урманда агач астында, яшьрен,/ Качып утыра иде мискин Күгәрчен».

Шулвакыт «якыннан» гына бер Лачын очып уза: «Көче күп, тырнагы үткен, явыз ул, / Зәгыйфьләрне ашар, канлы авыз ул». Ахырда күгәрчен авызыннан нәтиҗә, резюме ясала: «Вәләкин мин ризамын язмышымнан, / Ходай кылган мине көчсез кошыннан. // Зәгыйфь, корбан булу артык, Ходаем, / Булудан андый көчле һәм дә залим».

Русча һәм татарча текстларның гомуми эчтәлеге, идеясе бер-берсенә туры килә. Әмма Тукай эчтәлекне детальләштерә төшкән, шуның нәтиҗәсендә күләм дә бераз арткан. Строфа төзелешендә һәм шигъри үлчәмдә дә җитди аерымлыклар бар.

Һәм русча, һәм татарча текст үзләренең жанр табигате, сюжеты белән Шәрык сүз сәнгатенә, аеруча «Кәлилә вә Димнә» җыентыгындагы хикәятләргә аваздаш.

«Күгәрчен» тәүге тапкыр «Йолдыз»ның 1910 елгы 15 август санында «Т.» инициалы белән дөнья күргән.

*Г. Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 137 (361) б.;
*Василий Пушкин*. Стихи. Проза. Письма.— М.: Советская Россия, 1984.— С. 49, 318.

Тукайның бу шигыре, 1910 елда язылып, шул ук елда шагыйрьнең «Күңелле сәхифәләр» җыентыгында басылып чыккан. Шигырьдә бала-

ның тырышып укуы, шуның аркасында мактау-хуплауларга, «имтияз»га («мактау кәгазе»нә) лаек булуы искәртелә. Автор фикеренчә, кеше яшьтән үк тырышса, аңа уңышлар «үскәч тә» килер: «Беренче кәррә (тапкыр) мөмтаз булса бер инсан туганнан соң, / Фәхерле имтиязларны алыр үскәч тә аннан соң». Шигырь 3 бәйттән (икеюллыктан) гыйбарәт. Рифмалашуы *аа бб вв...* рәвешендә.

*Г. Тукай*. Әсәрләр. Биш томда. 2 т.— 101 (357) б.

Әлеге әсәр «Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 11 сентябрь санында «Шүрәле» имзасы белән дөнья күргән һәм «Иблиснең гайде фитыр тантанасы (ураза тотуны тәмамлап, ашый башлау бәйрәме)» дип исемләнгән. Журналның соңгы

битендә Иблис тантанасының рәсеме дә бар.

Шигырьдә аерым кешеләрнең, «динне ташлап» яисә ураза аенда «качып», «көндез сәхәр» ясаулары, шуңа да карамастан Гает көнен бәйрәм итүләре тәнкыйтьләнә. Мондый бозык затлар, ди шагыйрь, үзләренең әхлаксызлыкларын шайтанга сылтыйлар. Әмма шайтаннарның монда һич катнашы юк. «Без тик тордык богауда. / Ник аздылар бу айда? / Гөнаһ эшне юк файда / Инде безгә сылтауда»,— ди алар. Шигырь сатирик эчтәлектәге мондый юллар белән төгәлләнә: «Шайтан аздырган» имеш! / «Юлдан яздырган» имеш! / Кире татар, иң элек/ Вөжданың берлән килеш!»

Әсәрдәге «көндез сәхәр» гыйбарәсе шул чорда билгеле бер таралыш тапкан күренешкә ишарә ясый. Ягъни аерым кешеләр, бигрәк тә яшьләр, тыштан ураза тоткан булып, чынлыкта икейөзлеләнеп, бер-берсенең өенә җыелып, көпә-көндез ашый-эчә («сәхәр ашый») торган булганнар. Бу хакта Ф.Әмирханның «Көндезге сәхәр...» исемле «хикәячеге» дә бар.

Тукайның бу шигыре *нааба ввгв...* рәвешендә рифмалашучы 5 дүртьюлыктан гыйбарәт. Һәр юлында — 7 шәр иҗек. Сатирик рухлы бу әсәр форма ягыннан такмакларны хәтерләтә. Риторик эндәш һәм сорау алымнары аның яңгырашын көчәйтә.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 189 (371) б.

Тукайның бу шигыре *аа бб...* рәвешендә рифмалашучы, һәр юлы 15 әр иҗекле 7 бәйттән гый-

барәт. Лирик характердагы бу әсәрдә газаплы иҗат процессы гәүдәләнеш тапкан. Лирик каһарман сүнеп баручы лампа яктысында илһамланып яза: «Якты беткәнче языйм дип, сызгалыйм тиз-тиз генә, / Кәгазь өстендә кала тик кәкре-бөкре эз генә». Шагыйрьнең «нокталар да төртмимен» диюендә милли як — гарәп хәрефләре белән язу күзаллана. Менә бераздан лампа сүнә, «һәр якта золмәт (караңгылык)» урнаша. Шагыйрь «ихтыярсыздан ятарга» мәҗбүр була, «төрле уйларга бата». Язудан тукталып калган лирик каһарман эчке каршылыкта. Киная белән ул түбәндәге сүзләрне әйтә: «Ни бәхет! — дим,— иртәгә кич син тагын да янмасаң, / Бу ятыштан мин дә мәхшәр җитмичә кузгалмасам!»

«Кичке теләк» шигыре тәүге мәртәбә «Җан азыклары» җыентыгында (1912) басылган.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 220 (378) б.

Тукайның бу шигыре *аа бб...* рәвешендә рифмалашучы 14 икеюллыктан (бәйттән) гыйбарәт.

Әсәрнең билгеле бер эчке сюжеты да бар: кышкы көндә «мин»гә көтмәгәндә Шүрәле очрый. Бу җан иясе инсанны, кытыклап, көлдерергә ниятли. Ул адәм баласының башын, муенын, аркасын, күкрәкләрен, аягын капшап карый. Әмма һич максатына ирешә алмый. Чөнки «мин» «кәбестә» кебек катлы-катлы киенгән. Шуннан инсан Шүрәлегә: «Син түгел, тәнгә тиялми китте инде күп суык»,— ди. Һәм болай дип тә өсти: «Кертмәгәч тәнгә, суык абзаң миңа дошман әле, / Миннән үч алмак өчен эшкә буран кушкан әле». Шул сүзләрдән соң Шүрәле юкка чыга.

Шигырь «мин» белән шартлы мифик затның үзара әңгәмәсенә корылган. Сөйләшү, ничектер, дусларча барган кебек. «Мин» әңгәмәдәшенә үз итеп, хәтта «Шүрәлем» дип тә дәшә. Ул явыз, мәкерле зат рәвешендә күзалланмый. Шагыйрь аны юкка гына «табигать иркәсе» дип әйтми: «Ул көлә, һәм көлке эзләүдә үтә кич, иртәсе; / Кем кыеп әйтсен аңар сүз, ул — табигать иркәсе!»

«Көтмәгәндә» шигыре тәүге мәртәбә 1912 елда «Җан азыклары» җыентыгында басылган.

*Г. Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 231—232 (379) б.

Тукайның бу шигыре «Номерың матур булса, күсе булгай» дип башланып китә. Барлыгы дүртьюллык ике строфадан гыйбарәт. Һәр юлы

12 шәр иҗекле, өчәр ритмик буынлы. Строфаларның тәүге өч мисрагында «булгай», соңгы юлларында «туннарым бар» сүзләре кабатланып килә. Шигырьдә тормышның капма-каршылыклар, уңай һәм тискәре күренешләр берлеге булуы, кеше яшәешенең төрлелеге раслана. Әсәрдә юмористик рух та бар. Шигырь үзенең төзелеше, рифмалашуы белән элеккеге язма һәм фольклор традицияләрен дәвам итә.

«Гыйбрәт вә нәсыйхәт» «Ялт-йолт»ның 1912 елда чыккан 11 март санында «Шүрәле» имзасы белән дөнья күргән «Казанга кайтыш» дигән мәкалә эчендә басылган. Аерым шигырь рәвешендә тәүге мәртәбә «Гажур» басмасына (1926) кертелгән.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда. 2 т.— 202 (373) б.

Тукайның 10 бәйтлек, *аа бб вв...* рәвешендә рифмалашучы, гарузның 4 буынлы рәмәл

үлчәме белән язылган бу шигыре ике кисәктән гыйбарәт. Беренче алты строфада шау-шулы карта уены тасвирлана: «...Кем көлә, кем кычкыра, һичбер өзлексез шау да шау; / Бу хозурдан онтыла кайчак эчү берлән ашау». Шагыйрьнең яшьлеккә охшашлы бу төр уенга мөнәсәбәте табигый, тормышчан: «Уйнасын шул бәндә, кемнең акчасы бар, вакты бар; / Әйдә оттырсын бәхетсез, отсын әйдә — бәхте бар». Автор уйлавынча, акчасы беткән кеше уен мәҗлесеннән китәргә тиеш. Әмма андый зат китми дә, хәтта «Иттем инде тәҗрибә, уйнау — начар эш!» — дип, «уйнаганнарны» да тыя.

Алга таба шигырьнең икенче кисәге башлана. Шагыйрь чагыштырмача конкрет, капма-каршылыклы хосусый вазгыятьтән киң, яшәешкә хас булган күренешкә күчә. Хәлсезләнгән, сәлперәйгән, бөкрәйгән, күзләренең нуры беткән карт кеше дә, уенда акчасын оттырып, башкаларга вәгазь биргән кеше кебек, яшьләрне акылга өнди башлый: «Баш бөгәргә өнди башлый инде ул яшьләрне дә / Һәм сөюдән/мәнгъ итә (тыя) башлый кара кашларны да». Ахыргы бәйт шигырьнең һәр ике кисәгенең мәгънәсен гомумиләштереп куя: «Бозмасын мәҗлес хозурын акчасы беткән кеше, / Измәсен яшьләрне дә күптән яше үткән кеше!»

Гомернең һәр чоры өчен үзенә хас табигый сыйфатлар бар. Инсан шуны аңлап, тоеп яшәргә бурычлы. Карт кеше икән, яшьлекнең табигатен аңласын, аңа киртә куймасын. Бу — шигырьнең төп мәгънәсе.

«Картлар» шигыре тәүге мәртәбә «Җан азыклары» җыентыгында дөнья күргән.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Дүрт томда.— 2 т.— 236—332 (375) б.;
*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда.— 2 т.— 226 (378) б.

Тукайның әлеге шигыре, шагыйрьнең вафатына айдан артыграк кына вакыт калганда язылып, «Аң»ның 1913 елгы 1 март санында басыл-

ган. Афористик эчтәлектәге бу өч строфалык (бәйтлек) әсәрдә гомер шәме сүнеп баручы шагыйрьнең җан газабы, иҗат һәм яшәеш кредосы гәүдәләнеш тапкан. Лирик каһарманның юлында «киртәләр» күп, дошманнары «эттәй». Чөнки ул «залимнәрне, өстеннәрне» якламаган.

Шигырьнең эчке рифмага, аллитерациягә, антитезага корылган соңгы строфасы фаҗигале монолог рәвешендә яңгырый: «Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш: / Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым». «Шул булды эш...» «Шул өч сүздә ничаклы үкенү, ничаклы әрнү...» (*С.Хәким*)

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томда.— 2 т.— 1985.— 270 (382) б.
*С.Хәким*. Тукай: кереш сүз / Әсәрләр: Дүрт томда.— 1 т.—1975.— 18 б.

**2. Г.Тукай кулланган жанрлар**

— Шәрык әдәбиятларында лирик жанр. Аның поэтик асылын кемне яисә нәрсәне дә булса гадәттән тыш күпертеп, иң чик дәрәҗәгә җиткереп мактау тәшкил итә. Күп кенә касыйдәләрнең нигезенә күренекле затларның эш-

гамәлләре, чынбарлыкта булган мөһим, тантаналы вакыйга-күренешләр салына. Мактау аркылы шагыйрьләр үзләренең теләк-омтылышларын, идеалларын да гәүдәләндергәннәр.

Касыйдәнең үзенә хас төзелеше, формасы бар. Ул *аа ба*... рәвешендә рифмалашучы икеюллыклардан — бәйтләрдән гыйбарәт. Аларның саны, гадәттә, 12 дән алып 200 гә җитәргә мөмкин. Касыйдә әүвәл гарәп поэзиясендә туа. Аннан, җирле шигъри казанышларга таянып, фарсы, төрки әдәбиятларында тарала. Әл-Мөтәнәбби, Рудәки, Нәваи һ.б. Шәрык шагыйрьләренең мирасларында касыйдәләр бар. XIV йөз төрки-татар әдипләре Харәзми һәм Сәйф Сараи да касыйдәләр иҗат итәләр. Әмма татар әдәбиятында бу жанр киң таралмый. Кайвакыт «касыйдә» атамасы гомумән мактау рухлы әсәрләргә карата кулланыла.

Тукай мирасында «Һазиһи касидәтен фи мәдхи Мостафа» («Мостафаны мактау турында касыйдә») (1912) дип исемләнгән шигырь бар. Ул *аа ба*... рәвешендә рифмалашкан. Бу касыйдә «Кыйссаи Рабгузый» (1310) китабындагы мәдхиягә нәзыйрә рәвешендә язылган. Әмма Тукай әсәрендә сатирик рух, мыскыллау аһәңе өстенлек итә. Автор, мактаган булып, Мостафа Лотфый Исмәгыйлев дигән шул чорның бер «зыялысын» фаш итә.

*Г.Тукай*. Әсәрләр: 2 т.— 211—212 (375) б.
*Х.Миңнегулов*. Тукай һәм Урта гасыр әдәбияты // Мирас.— 1997.— № 1.— 39—50 б.

— Шәрык, шул исәптән татар сүз сәнгатендә эпик яисә лиро-эпик жанр атамасы. Бу атама аеруча Урта гасыр һәм XIX йөз әдәбиятында еш очрый. Кыйсса атамасы гарәп, фарсы һәм

төрки телләрендә хикәят, әкият, повесть, поэма, легенда, риваять, дастан, мәсәл һ.б. мәгънәләрдә кулланыла. Кыйссада, кагыйдә буларак, кызыклы, мавыктыргыч, гыйбрәтле вакыйгалар, хәлләр бәян ителә. Күп кенә кыйссаларда күчмә сюжетлар, төрле легенда-риваятьләр, хәтта мифлар да эшкәртелә («Кыйссасел-әнбия», «Кыйссаи Йосыф», «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» һ.б.).

Тукайда кыйсса вакыйга, хәл рәвешендә телгә алына. Мәсәлән, «Мич башы кыйссасы (Баштан үткән бер эш)» (1912).

Әдәбият белеме сүзлеге.— Казан, 1990.— 77—79 б.

— икеюллыкның (бәйтнең)яртысы, дүртьюллыкның чирек өлеше. Шәрык поэтикасы өчен хас атама. Татар телендә бу сүз XX гасырның 30 нчы елларына кадәр актив. Тукай да бу сүз-

не, сирәгрәк булса да, «шигырь юлы» мәгънәсендә куллана. Мәсәлән, аның «Халык әдәбияты» темасына укылган лекциясендә (1910) болай диелә: «...безнең һәр дүрт мисрагы да бер-беренә ябыша торган җырларымыз да бар».

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томлык.
Әдәбият белеме сүзлеге.— Казан, 1990.— 101 б.

Кайвакыт уяту, кисәтү, искәртү, киңәш бирү, шелтәләү рухындагы аерым әсәрләрне (нигездә,

шигырьләрне) «тәнбиһ» дип атау бар. Тукай мирасында да андый язмалар очрый. Мәсәлән, «Уклар» журналына мөхбир уланлара (хәбәрчеләренә) «Тәнбиһ» шигырендә (1906) шагыйрь авторларны тәвәккәл, сугышчан булырга чакыра: «Атучыга әмремез: укларны кызганмасын! / Атылмышка нәсихәт: йөрәге сызланмасын». Тукайның тәнбиһ рухлы әсәрләре шактый («Мөтәшагыйрьгә», «Татар мөхәрриренә», «Дустларга бер сүз», «Гомер юлына керүчеләргә» һ.б.).

*Г.Тукай*. Әсәрләр: Биш томлык.

— Шәрык, шул исәптән татар поэзиясендә иң кечкенә жанр атамасы. Анда шигъри фикер мөстәкыйль икеюллыкта гәүдәләнеш таба. Фәрд

өчен, кагыйдә буларак, афористик яңгыраш хас. Күпчелек фәрдләр *аа...* рәвешендә рифмалаша. Төрки-татар поэзиясендә фәрдләр М.Кашгарый китабында, С.Сараи, Акмулла, Дәрдемәнд һәм кайбер башка шагыйрьләрнең иҗатларында күзгә ташлана. Тукай да бу традицион жанрга еш мөрәҗәгать итә. Аның өч дистәдән артык (32) фәрде бар («Дәүре галәм», «Гаилә тынычлыгы», «Гакыллылар фәлсәфәсе» һ.б.). Алар, нигездә, *аа...* рәвешендә кафияләшә. Сирәк булса да, *аб...* рифмалы фәрдләре дә очрый. Тукайның бу жанрда язылган шигырьләре төрле эчтәлектә. Юмористик, сатирик рухлы фардләре дә бар («Иман», «Киңәш», «Карга» һ.б.). Тукайның бу жанрдагы бер өлеш әсәрләре тәрҗемә характерында. [«Охшату (Лермонтовтан)», «Шекспирдан», «Төрекчәдән (Хәкиманә сүзләр)», «Толстой сүзе» һ.б.]

Тукай иҗатыннан фәрдкә бер мисал: «Ут, төтен, фабрик-завод берлә һаман кайный Казан; / Имгәтеп ташлап савын, сау эшчеләр сайлый Казан».

*Г. Тукай*. Дүрт томда. 1 т., 2 т.
Әдәбият белеме сүзлеге.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.— 200—201 б.

— гарәп, фарсы, төрки, шул исәптән татар сүз сәнгатендә чагыштырмача кече күләмле жанр. Аның асылын аңлаешлы, афористик формада акыллы, гыйбрәтле сүз әйтү, мәгънәле хәлне

гәүдәләндерү тәшкил итә. Күпчелек хикмәтләрнең идея-тематикасы әхлакый-фәлсәфи характерда. Төрки-татар әдәбиятында хикмәт жанры Әхмәд Ясәви (1116 елда үлә) һәм Сөләйман Бакырганый (1186 елда вафат була) иҗатларыннан ук актив. Мәүла Колый (XVII йөз) үзенең күпчелек шигырьләрен хикмәт дип атаган. С.Сараиның (1321—1396) «Гөлестан бит-төрки» әсәрендә чәчмә һәм тезмә юллар аралаштырып язылган хикмәтләр бар.

Тукай мирасында «хикмәт» дип аталган әсәрләр күзгә ташланмый. Әмма аның поэзиясендә үзенең рухы, эчтәлеге белән хикмәт шәкеленә туры килешле шигырьләр шактый («Нәсихәт», «Шөһрәт», «Вак-төяк» һ.б.). Аларда афористик фикерләү, үгет-нәсыйхәт бирү, акыллы сүз әйтү өстенлек итә.

Әдәбият белеме сүзлеге.— Казан, 1990.—202—203 б.;
*Х.Миңнегулов.* Тукай һәм Урта гасыр әдәбияты // Мирас.— 1997.— # 1.— 39—50 б.

**3. Шагыйрь иҗаты белән бәйләнешле авторлар**

**һәм журналлар**

— төрки-татар шагыйре. Чыгышы белән мишәр татарлары кавеменнән. Котб («Котби» дип язу очраклары да бар) әдипнең кушаматы-тәхәллүсе булса кирәк. Фәндә бу исемне Урта гасыр

Европа карталарында «Котоба» рәвешендә теркәлгән Идел буе шәһәре белән дә бәйлиләр. «Котб» атамасының күренекле затларга, акыл ияләренә, остазларга карата кулланылуын да истә тотарга кирәк.

Котб 1342 елда Сарай каласында «Хөсрәү вә Ширин» исемле шигъри романын төгәлли һәм аны Алтын Урда ханы Тинибәккә багышлый. Бу әсәр Низаминың (1141—1209) фарсы телендәге «Хөсрәү вә Ширин» поэмасына (1181) мөнәсәбәттә туган. Ул — ярымтәрҗемә, ярыморигиналь характердагы ядкяр. Анда мәхәббәт, яшәү мәгънәсе, тормыш иминлеге һәм башка проблемалар югары сәнгати дәрәҗәдә, бай шигъри тел белән гәүдәләнеш тапкан.

Котб әсәренең 1383 елда Бәркә Фәкыйһ тарафыннан Мисырда күчерелгән бердәнбер нөсхәсе хәзерге вакытта Париж Милли китапханәсендә саклана (№ 312). 238 битле бу кульязманың фотокүчермәсе, транскрипциясе, сүзлеге тәүге тапкыр А.Зайончковский тарафыннан 1958—1961 елларда Варшавада өч китап рәвешендә нәшер ителде. Аннан соңгы вакытта «Хөсрәү вә Ширин» Казанда, Ташкентта берничә мәртәбә басылып чыкты. Г.Таһирҗанов (1907—1983) узган гасырның 40 елларында, Котб әсәрен тикшереп, кандидатлык диссертациясе язды.

Тукай, гәрчә ул Котб тексты белән очрашмаса да, Хөсрәү-Ширин тарихы, Алтын Урда чорыннан килгән әдәби традицияләр белән билгеле бер дәрәҗәдә таныш, әлбәттә. Моны бу ике әдипнең әсәрләрендәге охшашлыклар, аваздаш яклар да раслап тора. Тукай да, Котб кебек, олуг мәхәббәткә, хатын-кызга дан җырлый, әхлакый сафлык, гадел җәмгыять турында хыяллана. Һәр ике автор да шигъри сүзнең куәтен, китапның бөек көчен раслый. Тел-сурәтләү чараларын куллануда Котб һәм Тукайда уртаклыклар аеруча күп. XX йөз башы шагыйре Хөсрәү-Ширин тарихындагы геройларны да телгә ала: «Кайда Фәрһад илә Мәҗнүн — мин аларның таңчысы!» («Мәхәббәт»), «Бу — җәһәннәмдер, түгел — Ширин илә Фәрһад җире» («Өмидсезлек») һ. б.

*Котб.* Хөсрәү-Ширин хикәяте: Ике кисәктә.— Казан: КДУ нәшр., 1969.— 441 б.; *Котб.* Хөсрәү вә Ширин / Хәзерге татар теленә Рифкать Әхмәтьянов тәрҗемәсе // Мирас.— 1992.— # 5 —12; 1993.— # 1—5.

*Х.Миңнегулов.* Котб иҗаты.— КДУ нәшр., 1976.— 79 б.;

Татарская литература и Восточная классика... — Изд-во КГУ, 1993.— С. 98—129; «Ни белгәйләр сине сүзләтмәсәң тел» (Алтын Урда әдәби традицияләре) // Мирас.— 1996.— # 5—6.— 252—270 б.; Тукай һәм Урта гасыр әдәбияты// Мирас.— 1997.— # 1.— 39—50 б.; Мәхәббәт җырчысы (Котбның тууына 700 ел тулу уңае белән) / «Дөньяда сүземез бар...» — Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.— 43—52 б.; *Г.Таһирҗанов.* Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре / Татар әдәбияты тарихы.— 1 т.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.— 170— 196 б.

— төрки-татар шагыйре. Идел буендагы Камышлы төбәгендә туа. Сарай шәһәрендә укый,

әдип буларак таныла. Кушамат-тәхәллүсе Алтын Урда башкаласына мөнәсәбәтле. XIV йөзнең 80 нче елларында мәмлүкләр Мисырына күчеп китәргә мәҗбүр була. Вафаты да шунда ук.

С.Сараи мирасының бер өлеше генә мәгълүм. Ул «Китабе Гөлестан бит-төрки» һәм «Ядгярнамә» дип исемләнгән кулъязма җыентыклар аркылы килеп җиткән. Алардагы әсәрләр («Гөлестан бит-төрки», 1391; «Сөһәйл вә Гөлдерсен», 1394 һ.б.) Төркиядә, Татарстанда, Үзбәкстанда, Венгриядә кат-кат басылып чыккан.

С.Сараи иҗаты, шактый еллар онытылып, XX гасыр урталарында гына фәнгә һәм укучыларга кабат мәгълүм булды. Шуңа күрә Тукайның С.Сараи әсәрләре белән турыдан-туры таныш булу ихтималлыгы юк дәрәҗәсендә. Әмма Алтын Урда шагыйренең иҗаты төрки-татар әдәби процессында туган, безнең рухи мираска сеңеп калган. Шуңа күрә дә XX йөз башы авторының әсәрләрендә С.Сараига аваздаш яклар, генетик уртаклыклар, типологик охшашлыклар шактый. Алар идея-тематикада, жанрлар системасында, поэтикада, тел-стильдә ачык күзәтелә. Мәсәлән, С.Сараидагы газәл, робагый, фәрд, мәсәл, хикәят жанрлары, строфа, рифма төрләре, шигырь үлчәмнәре Тукайда да еш кулланыла. «Игү ат» калдырырлык итеп яшәү — һәр ике авторның да яшәү максаты. С.Сараи: «Йадкяре калса кемнең игү ат,— / Үлмәс ул ир,— кемдә булса бу сыйфат». Тукай: «Булса калдырмак берәү ушбу җиһанда изге ат...» («Эшкә өндәү»). Ике гашыйкның мөнәсәбәтен «пәрванә» (күбәләк) һәм шәм аркылы бирү һәм Сараида, һәм Тукайда күзгә ташлана. «Гөлестан бит-төрки»дә хуш исле сабын янында торган балчыкның шулай ук хуш исле булуы хакында шигъри парча бар. Шуңа охшаш мотив Тукайның «Иссез чәчәк» әсәрендә дә гәүдәләнгән. XIV йөз шагыйре Габделмәҗид әсәренә нәзыйрә рәвешендә «...Күңел» дип исемләнгән рәдифле газәл яза. Шушындый ук жанрда, шушындый ук рәдифле әсәр Тукайда да бар.

*Сэйф Сараи*. Гөлестан. Лирика. Дастан / Әсәрләрне басмага әзерләүче, кереш һәм ахыргы мәкалә авторы Х.Миңнегулов.— Казан: Татар.кит.нәшр., 1999.— 296 б. (35—36 битләрдә — С.Сараи әсәрләренең библиографиясе).
*Х.Миңнегулов*. «Дөньяда сүземез бар...» — Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.— 64—88, 148—169 б.

— татар шагыйре, галиме, педагогы, җәмәгать эшлеклесе. Татарстанның Чирмешән районы Утыз Имән (бераз вакыт ул Яңа Кади исеме

белән дә йөртелде) авылында игенче гаиләсендә туа. Кушамат-тәхәллүсе шуңа мөнәсәбәттә алынган. Аерым чыганакларда һәм хезмәтләрдә ул Габдерәхим бине Госман бине Сәрмәки бине Кырыми әл-Болгари дип тә йөртелә.

Булачак шагыйрь ятимлектә, кыенлыкта үсә. Туган төбәгендә, Оренбург янындагы Каргалы мәдрәсәсендә белем алгач, 1788 елда гаиләсе белән Урта Азия якларына китеп бара. Биредә аның Бохара, Үргәнеч, Сәмәрканд, Акча, Бәлех, Һират, Кабул һәм башка шәһәрләрдә булуы, белем туплавы һәм эшләве мәгълүм. 1798 елда Идел-йортка әйләнеп кайта. Элеккеге Чистай, Бөгелмә өязләрендә балалар укыта, әдәби, гыйльми эшләр белән шөгыльләнә, ике дистәгә якын баласын тәрбияли. Гомеренең ахырын хәзерге Лениногорск районындагы Тимәш авылында уздыра. Шунда ук вафат була һәм җирләнә дә.

Утыз Имәни үз дәверенең гаять укымышлы кешесе була. Ул, туган теленнән тыш, гарәп, фарсы, үзбәк, төрек телләрен камил белә. Аерым язмалары гарәп һәм фарсы телләрендә. Русчадан да хәбәрдар була.

Утыз Имәни бай әдәби һәм гыйльми мирас калдыра. Аның, мәсәлән, текстология, фәлсәфә, хокук, астрономия, медицина, логика, биобиблиография буенча хезмәтләре бар. Әдәби әсәрләре генә дә 50 дән артык. Алар арасында «Гаварифез-заман» («Замананың укымышлылары»), «Мөһимматтез-заман» («Замананың мөһим хәлләре»), «Горбәтнамә», «Тәнзиһел-әфкяр...» («Фикерләрне пакьләндерүче») кебек күләмле әсәрләр дә (поэмалар), чагыштырмача кечерәк мәдхия-мәрсияләр, мөнәҗәтләр, шигъри хикәятләр һәм башка жанрдагы әсәрләр дә бар.

Утыз Имәни иҗатының үзәгендә — белем-мәгърифәт, әхлак, социаль гаделлек мәсьәләләре. Әдипнең идеалы — белемле, динле, әхлаклы, һөнәрле зат. Утыз Имәни үзенә кадәрге төрки-татар һәм гомумән Шәрык әдәби-эстетик казанышларын, традицияләрен шактый дәрәҗәдә файдалана, дәвам иттерә. Шуңа күрә аның иҗаты Урта гасыр сүз сәнгатеннән XIX йөз мәгърифәтчелек әдәбиятына күпер вазифасын да үти.

Утыз Имәни әсәрләре кульязма килеш тә, басма рәвештә дә халыкта киң тарала. Шуңа күрә Тукай аның иҗатыннан билгеле бер дәрәҗәдә хәбәрдар була. Утыз Имәни идеаллары XX йөз шагыйре өчен дә үз һәм якын. Тукай да белем, мәгърифәткә, әхлакны камилләштерүгә зур өметләр баглый, үз элгәргесе кебек, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы руханиларны кискен тәнкыйтьли. Утыз Имәни кулланган күп кенә жанрлар (мәдхия-мәрсияләр, робагый, фәрд, хикәят...), шигъри үлчәмнәр, рифма һәм строфа төрләре, тел-сурәтләү чаралары Тукай өчен дә чит түгел.

Утыз Имәни әсәрләре хакында Тукай аерым фикерләр дә әйтә. «Шигырьләребез» исемле мәкаләсендә ул болай ди: «Суфи Аллаһыяр вә Утыз Имәни хәзрәтләре бер төрле нәзымлырак шигырь сөйли белмешләр исә дә, тик тәсауыф бабында гына сөйләгәннәр. Әгәр дә ул әфәнделәр дөньяга вә аның халкына да бераз илтифат итеп дөньядан киткән булсалар, хәзерге көндә исемнәре тагын да артык хәер илә зикер ителер иде» (Биштомлык, IV т., 33 б.). Шунысын да искәртик: Тукайның Утыз Имәнигә карата әйтелгән бу фикерләре хәзерге фән тарафыннан бәхәскә алына. Мәгълүм ки, Утыз Имәни шигърияте шактый төрле, суфыйчылык белән генә чикләнми һәм чынбарлык белән дә бәйле.

*Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари*. Шигырьләр, поэмалар / Басмага әзерләүче, кереш сүз авторы Әнвәр Шәрипов.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.— 398 б.; *Х. Миңнегулов* а) Әдәбият: 9 нчы сыйныф өчен дәреслек...— Казан: Мәгариф, 1998.— 180—187 б.; б) Тукай һәм Урта гасыр әдәбияты // Мирас.— 1997.— # 1.— 39—50 б.

Татар шагыйре Г.Кандалый хәзерге Ульяновск өлкәсенең Иске Майна районы (элеккеге Самара губернасы Ставрополь өязе) Иртуган авы-

лында Габделмәҗид исемле мулла гаиләсендә туа. Бу авылның элек Иске Кандал дип йөртелүе мәгълүм. Шагыйрьнең әдәби кушаматы шуңа мөнәсәбәттә алынган.

Габделҗәббар Кандалый әүвәл этисендә укый. Аннан Мораса, Кизләү, Кышкар һәм Идел-йорттагы кайбер башка мәдрәсәләрдә белем ала. 1824 елдан туган авылында мулла булып тора, балалар укыта. Аның үз туган теленнән тыш, гарәп, фарсы, төрек, рус, чуваш телләрен дә белүе, татар әдәбиятыннан һәм фольклорыннан, Шәрык мәдәниятеннән хәбәрдар булуы мәгълүм. Шагыйрь 63 яшендә вафат була, туган авылында җирләнә.

Габделҗәббар Кандалыйның иҗат мирасы шактый бай. Ул ярты гасырлык иҗат юлында икеюллык шигырьләрдән алып зур күләмле поэмаларга кадәр яза. Шагыйрь үзенең әдәби эшчәнлеген «Рисаләи-л-иршад» («Тугры юлга күндерүче китап»), «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» кебек традицион рухлы һәм әхлакый-фәлсәфи эчтәлекле поэмалар язудан башлый. Автор үз укучысын гыйлемле булырга, олыларга «гыйззәт», «хөрмәт», «кечеләргә... шәфкать» итәргә, нәфескә иярмәскә, күңелне пакь тотарга чакыра.

Шагыйрь алга таба иҗади эзләнүләрен дәвам итә. Аның әсәрләрендә лирик башлангыч, ихласлылык көчәя, шәхескә, кешенең рухи халәтенә һәм чынбарлык белән бәйләнешләренә игътибар арта. Шигырь-поэмаларының тел-стиле чагыштырмача гадиләшә, фикер-кичерешләренең үтемлелеге арта. Автор, XVIII йөз шагыйре Габдессәлам традицияләрен дәвам итеп, фольклор, бигрәк тә халык җырлары казанышларын мул файдалана. Нәтиҗәдә язма поэзия белән киң катлам укучылар арасы тагын да якыная төшә.

Габделҗәббар Кандалыйның бер өлеш әсәрләрендә ата һәм бала мөнәсәбәте, аерылу кайгысы сурәтләнә. Ул, Мәүла Колый традицияләрен дәвам итеп, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы руханиларны да тәнкыйтьли. Әмма Габделҗәббар Кандалый,— барыннан да элек, мәхәббәт шагыйре. Аның күпчелек шигырьләре һәм поэмалары («Шәфгый», «Фәрхи», «Мәгъшукнамә», «Сахибҗәмал» һ.б.) сөю-мәхәббәт турында. Автор аларда бу изге хиснең олылыгын, гашыйкның рухи халәтен, сөйгән ярның гүзәллеген күп төрле сурәтләр һәм чаралар ярдәмендә гаять оста итеп тасвирлый.

Г.Кандалый әсәрләре кульязма рәвештә дә, басма хәлендә дә укучылар арасында киң тарала, татар шигърияте үсешенә зур йогынты ясый. Шуңа күрә Тукай да Г.Кандалый шигырь-поэмалары белән таныш була. «Шигырьләребез» исемле мәкаләсендә (1907) Тукай үз элгәргесенең әсәрләрен, «әдәпкә һәм әдәбиятка хилаф җирләре» булуын күреп, бераз тәнкыйтьләп тә ала.

XX йөз башы шагыйре иҗатында Г.Кандалыйга охшаш, аваздаш яклар шактый. Тукай да,— үз элгәргесе кебек, туры сүзле, ихлас шагыйрь. Ул да фольклорга, халык җырларына югары бәя бирә, алардан файдаланып әсәрләр яза. Ялган руханиларны, икейөзле, әхлаксыз кешеләрне тәнкыйтьли, мәхәббәтнең олылыгын, изгелеген гәүдәләндерә. Тукай да, Кандалый шикелле, Урта гасыр татар, Шәрык рухи казанышларына еш мөрәҗәгать итә. Һәр ике шагыйрь иҗатында бердәй яисә охшаш шигъри үлчәмнәр, строфа, рифма төрләре, сурәтләр күзгә еш ташлана.

Г.Кандалыйда мондый шигырь бар: «Сәнең башың ирер мисле пудаука, / Колакларың гүя торыр ылаука, // Күзең елтырыйдыр сулы чиләкти,/ Авызың җәйрәгән иске иләкти.// Нәсыйб булып, ала калсам, җанашым, / Савыт-саба, табаклар да кирәкми». Бу шигырь тәэсирендә Тукай үзенең «Егет илә кыз» әсәрен иҗат иткән. Аның соңгы строфасы болай яңгырый: «...Сине алсам, чүмечле һәм иләкле / Булам ич — акча туздырмак кирәкми».

*Г. Тукай*. Биш томлык;

*Габделҗәббар Кандалый*. Шигырьләр һәм поэмалар / Төзүчесе... М.Госманов.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.— 558 б.

*Х. Миңнегулов*. Әдәбият тарихыннан сәхифәләр: Г.Кандалый// Татарстан.— 1995.— # 7—8.— 116—127 б.; Тукай һәм Урта гасыр әдәбияты // Мирас.— 1997.— # 1.— 39—50 б.

— казакъ әдәбияты классигы, академик, җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче, Ленин премиясе лауреаты... М.Ауэзов Семипалат шәһәрендә туа

һәм укый. 1928 елда Ленинград университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Мохтар Ауэзов — күп санлы чәчмә, драма әсәрләр авторы. Аның иҗатының йөзек кашы — казакъның бөек шагыйре Абай турындагы роман-эпопея. Ул дөньяның күп телләренә тәрҗемә ителгән. Аның Сәрвәр Әдһәмова тәрҗемә иткән татарча басмалары да (1957, 1960) бар.

Мохтар Ауэзов бераз вакыт Семипалаттагы татар мәдрәсәсендә дә укып кала, татарча белә, гомере буе татарлар белән аралашып тора.

Мохтар Ауэзов, шул чорның күп кенә казакъ әдипләре кебек, татар әдәбиятын укып үсә, аның язмышы белән кызыксынып тора. Истәлекләрдән әдипнең Тукай иҗатын яхшы белүе, аны һәм шәхес, һәм шагыйрь буларак югары бәяләве мәгълүм. «Абай» рухындагы «Тукай» романын язган Әхмәт Фәйзи белән дустанә мөнәсәбәтләрдә тора. Мохтар Ауэзов болай ди: «Тукай образын, шагыйрь һәм халык темасын тагын киңрәк планда югарырак күтәрәсе, зур эпопея тудырасы иде» (Совет әдәбияты.— 1961.— # 7.— 150 б.). Ул Тукай әсәрләрен казакъ телендә бастыру белән дә кызыксынып тора. Хәсән Хәйри язуынча, «Мохтар Ауэзов... Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М. Җәлил турында зур хөрмәт белән сөйли иде» (Совет әдәбияты.— 1961.— № 7.— 150 б.).

*Х. Миңнегулов*. Мохтар Ауэзов һәм татар әдәбияты (Тууына 100 ел тулу уңае белән).— «Дөньяда сүземез бар...» китабында (Казан: Татар. кит.нәшр, 1999.— 281—295 б.).

Татар шагыйре Минһаҗ Исмәгыйлинең туган җире — Чувашстанның Батыр районы Шыгырдан авылы. Ул Касыйм педагогика училищесын

тәмамлый, Казан университетының география факультетында укый. Урта Азиядә укытучы булып эшли. Сугышта катнаша, 1943 елда әсирлеккә эләгә. Гомеренең аннан соңгы төп өлешен Германиядә уздыра. Кабере — туган авылында.

Минһаҗ Исмәгыйли шигырьләре туган җирне, ватанны сагыну, татар халкының үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйлану рухы белән сугарылган. Милли тематика аны Тукай белән якынайта. Минһаҗ Исмәгыйли Тукайга олуг мәхәббәт белән карый, аның шәхесен һәм иҗатын үзе өчен өлге итеп ала («Аһ! Атлар идем Тукай баскан эздән» һ.б.). Бөек шагыйрь кебек, Минһаҗ Исмәгыйли өчен дә Казан — татар халкының мәркәзе, «кыйбласы».

*Минһаҗ Исмәгыйли*; Ватанымны сагыну // Мирас.— 1995.— № 5—6.— 50—51 б.; Фатыймага хат (шигырьләр) // Мирас.— 1996.— № 5—6.— 264—270 б.; Илебезнең киләчәге (шигырьләр) // Мирас.— 1996.— № 11.— 41—49 б.

*Х.Миңнегулов*. «Их шатланам... татар булуыма!»// Мирас.— 1996.— # 5—6.— 252—263 б.

Әхмәт Рәшит углы Яруллин — филолог, монголист, тюрколог, профессор (1962). Әлмәт

авылында (хәзерге Әлмәт шәһәрендә) рухани гаиләсендә туа: әтисе — Ярулла мулла (1880—1938), әнисе — Зәйнәп Абдулфәттах кызы (1888—1978). Әүвәл туган төбәгендә, аннан Бөгелмәдә укый. 1929 елда бер иптәше белән Төркиягә качып китә. Трабзонда «Мөгаллимнәр мәктәбе»ндә укый. Бераздан Анкарадагы тел һәм тарих-география факультетында югары белем ала. 1936—1943 елларда Берлин университетында укый һәм эшли. 1943 елда, Германиядә диссертация яклап, «фәлсәфә докторы» дәрәҗәсен ала. Шул ук елда Төркиягә кайта. 1947—1951 елларда музейлар белән җитәкчелек идарәсендә эшли. Аннан бераз вакыт Гамбургта фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшләр белән шөгыльләнә. 1955 елдан Анкара университетының тел, тарих, география факультеты укытучысы, профессоры. 1961—1975 елларда параллель рәвештә «Төрек культур» институтының җитәкчесе. Ә. Тимер дистәдән артык телне белә, спортчы, музыкант, шахматчы. Күп санлы галимнәрнең остазы. Аның Урал-Алтай телләрен өйрәнүгә, төрки халыкларның тарихын, әдәбиятын тикшерүгә багышланган төрле телләрдә 300 гә якын хезмәте бар. Төрек культурасын тикшерү институты, Ә.Тимернең тууына 80 ел тулуга багышлап, 1993 елда махсус җыентык чыгарды. Анда галимнең тормышы, гыйльми-педагогик эшчәнлеге шактый тулы яктыртыла.

Күренекле милләттәшебез 91 нче яшендә Анкарада вафат булды.

Ә.Тимер Тукай иҗатын яхшы белә. Аның шигырьләрен яттан да сөйли, шагыйрь сүзләренә язылган җырларны да белә.

Ә.Тимернең турыдан-туры ярдәмендә төрек галимәсе Фатма Өзкан 1994 елда Анкарада «Габдулла Тукай шигырьләре» исемле меңгә якын битлек китабын бастырып чыгарды.

Ә.Тимернең үзенең дә Тукайга мөнәсәбәтле язмалары бар. Мәсәлән: «Тукай дәвере Казан шагыйрьләре» («Kazan» журналы.— 1971.— № 3.— 13—17 б.), «Габдулла Тукай» («Төрек культуры» журналы.— III.— 31 май, 1965.— 469—472 б.) һ.б.

T„rk K„lt„ru Ara,t’rmalar’. Prof. Dr. Ahmet Temir’e Armaqan.— Ankara, 1993. — 292 s.

*Х.Миңнегулов*. «Дөньяда сүземез бар...» — Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.— 210—233, 248—249 б.

Төрек галимәсе, филолог, тәрҗемәче Фатма Өзкан 1959 елда Төркиянең Карс каласында

туа. 1976—1980 елларда Әрзурумдагы Ататөрек университетының төрек теле һәм әдәбияты факультетында укый. 1983 елдан Анкарада гыйльми-тикшеренү һәм педагогик эшләр белән шөгыльләнә, җөмләдән Гази университетында дәресләр алып бара. 1992 елдан фән докторы.

Фатма Өзкан тел һәм әдәбият өлкәсендә дә, фольклорда да, чагыштырма тарихи грамматика тармагында да тикшеренүләр алып бара. Аның берничә монографиясе, күпләгән мәкаләләре бар. Галимәнең гыйльми эшчәнлегендә төп урынны татар тематикасы, аеруча Тукай иҗаты били. Докторлык диссертациясенә нигезләнеп, ул 1994 елда Анкарада «Габдулла Тукай шигырьләре» исемле 958 битлек китабын бастырды. Монография өч өлештән гыйбарәт. 112 битлек тәүге кисәгендә, татар тарихы һәм мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә, Тукайның тормышы һәм иҗаты яктыртыла. Китапның төп өлешен (113—951 битләр) Тукай шигырьләре алып тора. Алар латин язуында бирелгән. Бер якта — татарча текст, икенче тарафта — аның төрекчәгә тәрҗемәсе. Фатма Өзкан тәрҗемәдә оригиналның эчтәлеген, сурәтлелеген, шәкел үзенчәлекләрен мөмкин кадәр тулы чагылдырырга тырышкан. Төрек әдәбияты белгечләре бу тәрҗемәне фәнни һәм сәнгати яктан уңай бәялиләр. Китапның уңышлы чыгуында

милләттәшебез, мәшһүр тюрколог Әхмәт Тимернең дә роле зур. Ул — бу басманың «рецензенты», аңа хәер-фатиха бирүчесе.

Монографиянең ахырында (953—958 б.) Тукайга, куелган темага мөнәсәбәтле гаять бай «библиография» урнаштырылган.

Фатма Өзканның «Егерменче гасыр татар шигърияте» хезмәтендә («Төрк дили» журналы.— 1996.— # 531) бу чор шагыйрьләре хакында күп кенә фикер-күзәтүләр бар; әсәрләреннән үрнәкләр дә төрекчә тәрҗемәдә бирелгән.

*Фатма Өзкан*. Габдулла Тукай шигырьләре.— Анкара, 1994.— 998 б. (Латин язуында һәм төрек телендә.)

*Х.Миңнегулов*. Татарга теләктәш төрек галимәсе (Фатма Өзкан турында) // Мирас.— 1997.— # 8.— 28—37 б.;

*Н. Лаисов, Ә. Сибгатуллина*. Төркиядән бүләк // Казан утлары.— 1996.— # 7.— 169—187 б.

*Fatma …zkan*. …mrunun baharinda vafat eden b„ү„k bir ,air: Abdullah Tukay /Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте: Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция материаллары.— Казан, 1997.— 17—27 б.

— гарәп хәрефләре белән айга ике мәртәбә Гаяз Исхакый мөхәррирлегендә чыккан татарча журнал. Аның беренче саны 1928 елның декабрендә дөнья күрә. Соңгысы — 1939 елның сентябрендә. 1930 елга кадәр «Милли юл» исеме белән йөртелә. Журнал, нигездә, Берлинда басыла. Бары берничә саны гына Варшавада нәшер ителә. 11 еллап вакыт эчендә журналның барлыгы 136 саны дөнья күрә. Уртача күләм — 16 бит. Мәҗмуга мөһаҗир татарлар хисабына чыгарыла.

«Я. м. ю.» — иҗтимагый, сәяси, милли, мәдәни журнал. Милли тарих, халык язмышы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге — менә журналның төп тематикасы. Аның сәхифәләрендә илдәге һәм читтәге сәяси вазгыятькә дә зур урын бирелә. Журнал — татарның милли-бәйсезлек өчен көрәшен чагылдыручы елъязма гына түгел, ә бу эшне оештыручы, җитәкләүче бер штаб та.

«Я. м. ю.» татарның күренекле каләм әһелләрен дә даими күз уңында тота. Болар арасында Тукай, әлбәттә, мөхтәрәм урынны били. Аның исеме һәм иҗаты милләтебезнең бер символы, асыл сыйфаты рәвешендә карала. Шигырьләреннән өзекләр хәтта журналның тышлыгында эпиграф итеп тә бирелә. «Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары, / Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары...» юллары, мәсәлән, мәҗмуганың 1932 ел, 5 нче санында күзгә ташлана. Шагыйрьнең «Юк, кояшым, мин беләм: Син батмагансың мәңгегә» дип башланган әсәренең тәүге дүрт юлы журналның 1938 ел, 3 нче санының тышлыгында урнаштырылган.

Тукайның исеме, әсәрләре яисә алардан өзекләр журнал битләрендә еш очрый. Болардан тыш мәҗмугада шагыйрь хакында махсус мәкаләләр, әдәби язмалар да басылып килә. Алар, нигездә, Тукайның туган-үлгән көннәренә, бигрәк тә тууына — 50, үлеменә 20, 25 ел тулу мөнәсәбәте белән бирелгән: *Г.Исхакый*. а) Тукай истәлеге (1932.— # 11.— 1—4 б.); б) Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә (1938.— # 4.— 1—9 б.); *Сәгадәт* (Гаяз Исхакыйның кызы — Сәгадәт Чагатай). (1936.— # 6.— 14—17 б.; 1938.— # 4.— 9—14 б.) Һәр ике мәкаләсе дә «Габдулла Тукай» дип исемләнгән; *Солтан* (Әхмәд Виргаз). Габдулла Тукай (1935.— # 7.— 20—22 б.); *Хөсәен Габдүш*. Бөек «Кушлавыч» ятиме (1936.— # 5.— 4—8 б.); *Шаһвәли Келәүле*. «Габдулла Тукайга» шигыре (1936.— # 6.— 17—18 б.) һ.б. Бу төр материалларның һәммәсендә Тукайның бөеклегенә, көчле талантына, халыкчанлыгына басым ясала. Аның татар рухын, халыкның кайгы-шатлыгын, өмет-идеалларын тасвирлавы ассызыклана («...Тукайның бәхете шунда ки, ул үзенең бөтен үсүене, күтәрелүене халкыбызның үсүе, күтәрелүе белән бергә баглап алып барган. Ул үзенең бөтен иҗадының көч-куәтене халыкның көченнән алып, халыкның кайгы-хәсрәтене, сөенечене халкыбыз белән бергә җырлап, бергә көйләп, халкыбыз эчендә үзенең иҗад куәтен эретеп җибәреп, халык белән берләшкән...» — Г.Исхакый). Тукай туган телне, туган кавемне саклаучы һәм яшәтүче, милләтне бергә туплаучы, бербөтен итүче бер көч, куәтле энергия чыганагы рәвешендә карала.

*Х. Миңнегулов*. а) Азатлык көрәшенең мөнбәре («Яңа милли юл» журналы турында) // Казан утлары.— 1993.— # 3.— 122—135 б.; б) «Яңа милли юл» журналы һәм Тукай // Казан утлары.— 2001.— # 11; в) Бөек шагыйрь турында бөек әдип (шунда ук Г.Исхакыйның «Тукай истәлеге» мәкаләсе) // Мәдәни җомга.— 3.08.2001.

— Төркиядә «Казан төрекләре культур вә ярдәмләшмә» оешмасы чыгарып килгән кечкенә генә мәҗмуга (1965—1968). Аның 24 саны билгеле. «Тукай бюллетене»ндә шагыйрьнең шигырьләре, аның хакындагы материаллар, Тукайга мөнәсәбәтле вакыйга-хәлләр урын алган. Мәҗмугада шулай ук Төркиядәге татарларның мәдәни тормышы турында да аерым мәгълүматлар бар.

*Х.Миңнегулов*. Аерылмас төшенчәләр / «Kazan» журналы турында // Мирас.— 1997.— # 11.— 71—83 б.

— латин хәрефләре белән төрек телендә (нигездә, Истанбул һәм Анкара калаларында)

чыккан журнал (1970—1980). Әмма анда аерым материаллар, бигрәк тә әдәби әсәрләр, фольклор үрнәкләре әүвәл татарча, аннан төрекчәгә тәрҗемә итеп бирелә. Журнал өч айга бер чыга. Барлыгы 23 сан дөнья күрә. Уртача күләме — 64 бит. Гомуми битләр саны — 1426. Журналның төп химаячесе — милләттәшебез Әхмәд Вәли Мәңгәр (1891—1978), төп хезмәткәрләре һәм авторлары — Әхмәт Тимер, Надир Дәүләт, Мәхмүт Таһир, Сәйдә Арсланбәк, Наилә Бинарк һ.б. Журнал «Казан төркләре культур вә ярдәмләшмә дәрнәге (оешмасы)» органы хисаплана.

«Казан» — иҗтимагый, тарихи һәм мәдәни характердагы мәҗмуга. Аның үзәгендә — татарның үткәне, бүгенгесе, язмышы, фольклоры, язма әдәбияты, гореф-гадәтләре, башка халыклар арасындагы урыны. Журналда милләтебезнең күренекле вәкилләренә, аеруча Г.Тукайга, зур урын бирелә. Һәр санында диярлек бөек шагыйрьнең шигырьләре, аның хакында язмалар бар. Мәсәлән, Надир Дәүләтнең «Казан төркләре вә Габдулла Тукай» мәкаләсендә (1971.— №3.— 6—12 б.) шагыйрь иҗаты милләт язмышы белән тыгыз мөнәсәбәттә карала. «Тукай,— ди язма авторы,— татарларның милли рухы, «милләтнең баш таҗы». Сөембикә манарасы казанлыларның бәйсезлек символы булса, Тукай — татар халкының «бер әдәби символыдыр». Журналның шул ук санында шагыйрьнең «Туган тел» һәм «Шүрәле» әсәрләре татар һәм төрек телләрендә басылган (18—26 б.). Биредә үк Солтанның (Әхмәд Виргазның) Тукайга багышланган «Шагыйрьгә», Шаһвәли Киләүле Илдәрнең «Тукай эзеннән» исемле шигырьләре урнаштырылган.

«Казан» журналының 14 нче санында (1975) Тукайның рәсеме һәм «Театр» шигыре бирелгән (29, 31, 32 б.).

Журнал, гәрчә чит илләрдәге милләттәшләребез арасында киң таралыш тапса да, Идел-йорт укучыларына, нигездә, XX йөзнең 90 нчы елларында гына мәгълүм булды.

*Х.Миңнегулов*. а) Аерылмас төшенчәләр («Kazan» журналы турында) // Мирас.— #11.— 71—83 б.; б) «Обретет душа, стремясь к тебе, свободу» (О журнале «Kazan») // Казань.— 1993.— №1.—С. 158—161.

*2002*

**ӘДӘБИЯТ ФӘНЕНЕҢ БҮГЕНГЕ ТОРЫШЫ**

*(Язучыларның XIV корылтаен каршылап)*

Сүз сәнгате һәм аны өйрәнү — элек-электән үзара тыгыз бәйләнешле, бер-берсенә йогынты ясаучы процесс. Чөнки әдәби әсәр, иң беренче чиратта, язучының үзе өчен түгел, ә башкаларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен языла. Ә инде иҗат җимеше, турыдан-туры, үзе генә тәэсир итүдән тыш, еш кына өстәмә аңлатуларга, махсус тикшерү-төшендерүләргә дә мохтаҗ. Нәкъ менә шушы зарурият, автор —әсәр —укучы арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр әдәбият гыйлемен, сүз сәнгатен аңлау, өйрәнү-өйрәтү фәнен тудыра, үстерә һәм яшәтә дә. Кагыйдә буларак, әдәбият үзен өйрәнүче фәннең үсешенә дә көчле йогынты ясый. Мәсәлән, XX йөз башы татар сүз сәнгате, Г.Исхакый, Г.Тукай, Г.Ибраһимовлар иҗаты татар әдәбият гыйлеменең дә көчле үсешен тәэмин итте.

Татар әдәбият фәненең хәзерге торышы нидән гыйбарәт соң? Язучыларның ике корылтае арасында, ягъни өч ел эчендә, бу өлкәдә нинди эшләр башкарылды, нинди уңай яклар һәм проблемалар бар?

Алдан ук шуны әйтергә кирәк: бүгенге әдәбият фәнендә, аның әдәби тәнкыйть тармагын исәпкә алмаганда, шактый гына җанлылык, нәтиҗәле эшчәнлек күзгә ташлана. Өч ел эчендә язылган, басылган мәкалә-хезмәтләрнең, китапларның саны гына да берничә дистә биткә җитәрлек. Биредә исә аларның кайберләре генә телгә алыначак.

Узган гасыр азагында «Әдәбият теориясе» дөнья күрде (Мәгариф, 2000). Ул — Ф.Хатиповның гына түгел, татар әдәбият фәненең дә зур уңышы. Чөнки бу хезмәт, бер яктан, гомуми әдәби-эстетик тәҗрибәгә, икенче яктан, татар сүз сәнгатендәге иҗади казанышларга нигезләнеп язылган. Әгәр дә бу китап янына «Әдәбият белеме сүзлеге»нең (Төзүче-редакторы — А.Г.Әхмәдуллин) тулыландырылган, камилләштерелгән яңа басмасы да чыкса, нур өстенә нур булыр иде.

Моннан ике ел элек рус телендә «Татарская Средневековая литература» дигән китап нәшер ителде. Ул, нигездә, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан язылган. Ниһаять, алты томлык «Татар әдәбияты тарихы»ның соңгы, алтынчы томы да дөнья күрде («Раннур» нәшрияты, 2001). Ул XX гасырның 60—90 нчы еллар әдәбиятын үз эченә ала. Н.Хисамовның «Сюжет Йусуфа и Зулейхи в тюрко-татарской поэзии XIII—XV вв. ...» монографиясе (Казань: Идел-Пресс, 2001) — татар әдәбият фәнендә генә түгел, гомумән тюркологиядә җитди казаныш. Аның Ш.Мәрҗани исемендәге югары дәрәҗәле бүләккә ия булуы үзе үк күп нәрсә хакында сөйли.

Мәгълүм ки, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә, милли үзаң үсешенә мөнәсәбәттә әдәби мирас белән кызыксыну көчәйде. Шуның нәтиҗәсе буларак, соңгы өч елда гына да күп кенә ядкярләр тиешле шәрех-аңлатмалар, кереш сүз белән укучыларга кабат җиткерелде. Болар арасында Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Хисам Кятиб, Сәйф Сараи, Мәүла Колый, Таҗеддин Ялчыгол, Ризаэддин Фәхреддин, Дәрдемәнд һәм башка күренекле әдипләрнең китаплары бар. Әдәби истәлекләрне бастыру эшенә, традицион, дәүләти басмаханәләр белән беррәттән, «Иман», «Раннур» кебек яңарак оештырылган нәшриятлар да үзләреннән сизелерлек өлеш кертә. Мәсәлән, Котдус Хөснуллинның «Раннур» басмаханәсендә дөнья күргән «Мөнәҗәтләр һәм бәетләр» китабы (2001) мирасны колачлавы, идея-эстетик байлыгы һәм полиграфик бизәлеше белән киң җәмәгатьчелек күңеленә аеруча хуш килде. «Мирас», «Гасырлар авазы» («Эхо веков»), «Казан утлары» һәм кайбер башка журналлар да әдәби мираска даими рәвештә урын биреп киләләр. Ике корылтай арасында, авырлыклар белән булса да, Г.Исхакый томнары чыгуын дәвам итте. Г.Ибраһимов мирасының да мөһим өлеше IX том рәвешендә дөнья күрде.

Ике гасыр аралыгында рухи мирасның, әдәбиятның мөһим проблемаларына, аерым әдипләрнең иҗатларын яктыртуга багышланган саллы гына монографияләр, күләмле җыентыклар нәшер ителде. Академик М.Хәсәновның 70 еллыгына багышланган «Татарның Яңарышы: заман һәм шәхесләр» исемле китапта (Казан: Фән, 2000.— Рус һәм татар телләрендә), мәсәлән, күп кенә күренекле шәхесләрнең, шул исәптән гуманитар фән әһелләренең, әдәбиятчыларның язмалары урын алган. Ә.Сәхаповның «Вестник Возрождения» дип исемләнгән монографиясендә (Казань: Центр инновационных исследований, 2001) Г.Исхакый иҗаты XX йөз әдәби-эстетик контекстында яктыртыла. Мәсгуд Гайнетдиннең «Хакыйкать юлыннан» җыентыгы (Казан: Татар. кит. нәшр., 2001) әдәбият тарихының төрле чорларын, аерым авторларның әдәби портретларын үз эченә ала. Тәлгат Галиуллинның «Шигърият баскычлары» исемле китабында (Казан: Мәгариф, 2002) XX гасыр шигърияте, андагы үзенчәлекләр бүгенге көннең гыйльми-эстетик югарылыгыннан торып яктыртыла.

«Тукай укулары» җыентыгында, Казан дәүләт университеты, Татар гуманитар институты чыгарган еллык «Фәнни язмалар»да да сүз сәнгатенең мөһим мәсьәләләрен яктырткан шактый гына мәкаләләр бар.

Ике корылтай арасында мәктәпләр, махсус һәм югары уку йортлары өчен дәреслек-хрестоматияләр, әсбаплар, төрле циклдагы («Хәзинә» һ.б.) җыентыклар чыгуын дәвам итте. Укытучылар һәм студентлар Дания Заһидуллинаның «Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы»н да (Казан: Мәгариф, 2000) бик теләп кабул иттеләр. Соңгы өч елда халык авыз иҗаты ядкярләрен туплаган һәм фольклорны тикшерүгә багышланган кызыклы гына китаплар дөнья күрде.

Әдәбиятны гыйльми өйрәнүнең шактый өлеше диссертацияләр язу һәм яклау кысаларында бара. Бу өлкәдә исә соңгы өч елда җитди генә эшләр башкарылды. Монда, әлбәттә, Казан дәүләт университетында һәм Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында махсус советлар булуы да җитди роль уйный. 1989—1998 елларда, ягъни 10 ел эчендә, татар әдәбиятыннан 11 докторлык, 23 кандидатлык диссертациясе якланган. Ә инде соңгы өч елда докторлык диссертацияләре яклаучыларның саны 14 кә җиткән, кандидат булучыларның саны өч дистәдән артып китә.

Язылган һәм якланган диссертацияләр татар сүз сәнгатенең төрле тармакларын, проблемаларын тикшерүгә багышланган. Алар арасында элеккеге һәм хәзерге әдәбият та, аерым язучыларның иҗатлары да, теория һәм текстология дә, идея-тематика һәм поэтика да, әдәби бәйләнешләр һәм үзара йогынты да бар. Шактый гына хезмәтләр өчен комплекслылык, масштаблылык хас. Кагыйдә буларак, күпчелек диссертацион тикшерүләр аерым монография рәвешендә нәшер ителеп килә. Шундыйлардан Ф.Галимуллин, З.Рәмиев, Р.Салихов, Д.Заһидуллина, М.Бакиров, Ә.Шәрипов, Ф.Яхин, Р.Исламов, Ф.Бәширов һәм башкаларның саллы монографияләрен мисалга китерергә мөмкин. Алар җәмәгатьчелеккә теге яки бу дәрәҗәдә таныш һәм студентлар, укытучылар, галимнәр тарафыннан инде файдаланылалар да.

Гомумән алганда, әдәбиятны өйрәнүдә шактый гына эшләр башкарылган. Әмма шуның белән бергә әле бу өлкәдә мөһим генә проблемалар, аерым кимчелекләр дә яшәп килә. Кайбер хезмәтләргә фәннитеоретик тирәнлек, заманча фикерләү, милләт язмышы белән бәйләнеш, яңалык җитми. Кабатланулар, әзер юлдан бару, Американы кабат ачулар күзгә еш ташлана. Кайвакыт модалы күренешләр, чит-ят терминология, тәэсирләр белән мавыгып, татар сүз сәнгатенең үзенчәлеген, асылын күз уңыннан ычкындырып җибәрәбез. Аерым авторлар һәр нәрсәдән суфыйчылык эзләү белән дә артык мавыгып китте. Диссертацион хезмәтләрнең күпчелеге элеккеге чорларны тикшерүгә багышланган. Ә менә совет чоры һәм бүгенге әдәбият, ничектер, икенче пландарак калды. Төрле нәшриятларда, журналларда гаять күп санлы әдәби әсәрләр басылып тора. Алар исә тиешенчә анализланмый, Тукайлар чорындагы кебек, җитди тәнкыйтькә дучар ителми. Кызганыч ки, бүгенге әдәби тәнкыйть өлкәсендә эшләүчеләребез бик аз, бармак белән генә санарлык. Фән докторларыбызның һәм кандидатларыбызның төп өлеше, нигездә, үткән чорлар, педагогик эш белән мәшгуль. Әдипләр исә үзләре җитди тәнкыйть белән бик сирәк чыгыш ясыйлар. Гомумән, хәзерге әдәби тәнкыйтьтә мактау, әшнәлек өстенлек итә. Аналитик, принципиаль, үтемле чыгышларга ихтыяҗ зур. Безгә әдәбиятның үзен генә түгел, ә аны өйрәнүче фәнне дә, әдәби-гыйльми хезмәтләрне дә пропагандалау, халыкка сеңдерү җитми. Башка халыклар, бигрәк тә төрки кардәшләребез белән бәйләнеш йомшарды, бер-беребезгә тәрҗемәләр, мөһим мәсьәләләр хакында фикер алышулар да кабат яңартуны көтәләр.

* * *

Халкыбызның мең елдан артык тарихлы, идея-тематик яктан бай, сәнгати яктан камил сүз сәнгате бар. Ике корылтай арасында ул яңадан-яңа әсәрләр, әдәбиятның төрле чорларын һәм мәсьәләләрен яктырткан гыйльми, тәнкыйди хезмәтләр белән баеды. Мондый ныклы нигез һәм иң мөһиме — туган телен саклаган иманлы халкыбыз булганда, киләчәккә өмет һәм ышаныч бар.

*2002*

## ГЫЙЛЕМ ДӨНЬЯСЫНА ЮЛКҮРСӘТКЕЧ

Диссертацияләр язу, яклау хакында элек тә, хәзер дә төрле, хәтта капма-каршы фикерләр яши. Әмма аларның гыйльми һәм педагогик процесста, фәнне үстерүдә, югары квалификацияле кадрлар тәрбияләүдә мөһим роль уйнавы бәхәссез. Тормыш инде үзе диссертацияләр язуның зарурилыгын раслаган. Аларны алыштырырлык башка нәтиҗәле система хәзергә юк.

Физика-математика, табигать белеме, техник һәм иҗтимагый-социаль фәннәр буенча диссертацияләр күпләп якланып тора. Ә татар филологиясеннән бу өлкәдә эшләр ничек соң? Әлбәттә, үзләре бу тармакта шөгыльләнүчеләр хәлнең торышын билгеле бер дәрәҗәдә күзаллыйлар. Моңа Ә.К.Кәримуллинның «Диссертации, защищенные в Казанском университете» (Казань, 1960) һәм Р.А.Асылгәрәеваның «Библиография авторефератов кандидатских и докторских диссертаций, защищенных за годы советской власти по татарской филологии» (Вопросы татарского языкознания, 1971.— 181—185 б.) хезмәтләре дә өлешчә ярдәм итә иде. Әмма бу төр күрсәткечләр хәзер күпләрдә юк. Бу — бер. Икенчедән, инде соңгы 30 ел эчендә шактый үзгәрешләр булды, 300 гә якын диссертация генә якланды. Кыскасы, татар филологиясеннән гыйльми хезмәтләрне язу һәм яклау өлкәсендә тулы картинаны тудырырлык библиографик күрсәткечкә ихтыяҗ зур иде. Күренекле галим, академик, китап фәненең атасы Әбрар ага Кәримуллин үзенең углы Шамил (үкенечкә каршы, инде хәзер мәрхүм) ярдәме белән, объектив заруриятне тоеп, гаять тә файдалы һәм кирәкле белешмә төзегән: А.Г.Каримуллин, Ш.А.Каримуллин. «Указатель авторефератов и диссертаций по татарской филологии по состоянию на 1998 год». Татарстан Фәннәр академиясе грифы белән басылган бу хезмәт Казанның «Фикер» нәшриятында 2000 елда дөнья күрде.

Хезмәт бай эчтәлекле кереш мәкалә белән ачыла. Авторлар сүзне СССРда диссертацияләр язуның, гыйльми дәрәҗәләр бирүнең рәсми документларын бәян итүдән башлыйлар. Билгеле бер вакыт аралыгы саен бу төр фәнни хезмәтләрнең библиографиясе, каталогы басылып тора. Шушындый гомуми, ил күләмендәге мәгълүматлардан соң авторлар татар филологиясеннән язылган диссертацияләргә күчәләр. Алар фикеренчә, тәүге кандидатлык диссертациясен 1941 елда В.Н.Хангилдин, ә инде докторлыкны телдән Латыйф ага Җәләй 1954 елда, әдәбияттан Мөхәммәд ага Гайнуллин 1958 елда яклыйлар. Китапта күрсәтелгәнчә, 1998 елның соңгы айларына кадәр татар филологиясеннән барлыгы 329 диссертация яклана. Шуның 60 ы — докторлык (31е — телдән, 29 ы — әдәбияттан һәм фольклор буенча). Күпме бу, азмы? Кереш мәкаләдә искәртелгәнчә, 1935—1998 елларда бөтен илдә филологик фәннәрдән 100 меңгә якын диссертация якланган. М.Горькийның тормышы һәм иҗаты буенча гына да 60 докторлык, 500 ләп кандидатлык диссертациясенең язылуы мәгълүм. Күрәсез: бу фонда татар теленнән һәм әдәбиятыннан якланган диссертацияләр гаять аз. Казакъ, үзбәк, азәрбайҗан, грузин, әрмән филологлары арасында да фән кандидатлары һәм докторлары бездәгедән берничә мәртәбәгә артык. Кереш мәкалә авторлары мондый аермалыкның сәбәбен Мәскәү тарафыннан үткәрелгән рәсми сәясәттә күрәләр. Билгеле булганча, бездә озак еллар буе даими эшләүче диссертация советлары булмады. Шуның нәтиҗәсендә галимнәребез хәтта язылган хезмәтләрен дә озак вакытлар яклый алмыйча йөрделәр. Өлкәнрәк яшьтәге хезмәттәшләребез Мәскәү, Санкт-Петербург, Алма-Ата, Баку, Ташкент юлларында яклау мәшәкатьләре белән кат-кат йөрүләрен хәзер дә онытмыйлар. 329 диссертациянең 110 ы Казаннан читтә яклануы да күп нәрсә хакында сөйли.

1991 елда Казан дәүләт университетында докторлык диссертацияләрен яклау советы эшли башлау югары квалификацияле белгечләр хәзерләүгә шактый уңай йогынты ясады. Бу уңай белән, әлеге советның гыйльми секретаре буларак, шуны да искәртим: 9 ел эчендә биредә 57 кеше яклады (26 докторлык, 31 кандидатлык диссертациясе). Сыктывкар, Саранск, Чабаксар, Махачкала, Уфа һәм кайбер шәһәрләрдән килеп яклаучылар да (нигездә, докторлыкны) булды. Әмма төп өлеше (41 е) татар филологиясеннән иде. Шуның 19 ы —докторлык (11 е — әдәбияттан, 8 е — телдән), 22 се —кандидатлык (5 се — әдәбияттан, 17 се — телдән) диссертацияләре. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты каршында соңгы елларда ачылган докторлык советында да инде дистәгә якын кеше, диссертация яклап, югары гыйльми дәрәҗәгә ия булды.

Кереш мәкаләдә бирелгән таблицадан күренгәнчә, докторлык (7) һәм кандидатлык (20) диссертацияләренең иң күбесе 1998 елда якланган (барлыгы — 27). Элегрәк исә бер генә диссертация дә якланмаган еллар була.

Авторлар факт-мәгълүматларны җыйнау, теркәү, системалаштыру белән генә чикләнмиләр, ә мәсьәләнең асылына кереп тә фикер йөртәләр. Кереш мәкаләдә тикшеренүчеләрнең игътибарын көтеп яткан кайбер мөһим проблемалар да атала. Мәсәлән, күп кенә кулъязма һәм басма китаплар, шактый гына әдипләр читтә кала килә. Татар филологиясендә эшләүчеләр дә, нигездә, безнең үз халкыбыз вәкилләре генә икән. Ә бит, мәсәлән, рус телен һәм әдәбиятын өйрәнүчеләр арасында шактый гына татарлар да бар.

Хезмәтнең төп өлешендә диссертацияләрнең авторлары, темалары, нинди телдә язылуы, кайчан яклануы, гыйльми җитәкчеләре, рәсми оппонетлары, тышкы бәяләмә бирүчеләре һәм башка шундый зарури мәгълүматлар бирелә. Әүвәл автореферат, аннан диссертация тасвирлана. Соңгысының структур элементлары, бүлек исемнәре аталу да хезмәтне күзаллауга ярдәм итә. Әүвәл телдән язылган докторлык, кандидатлык диссертацияләре хронологик эзлеклелектә аерым-аерым китерелә. Аннан — әдәбият һәм фольклор темаларына багышланган диссертацияләр. Ә инде китап ахырындагы «Именной указатель» кирәкле авторны табуны гаять җиңеләйтә.

Шунысы мөһим: хезмәт саф филологик диссертацияләр белән генә чикләнелмәгән. Анда чагыштырма рухлы, теге яки бу дәрәҗәдә татар филологиясенә кагылышлы аерым хезмәтләр дә гәүдәләнеш тапкан. Шул принциптан чыгып, методика, педагогика, тарих, журналистика, музыка тармакларына мөнәсәбәтле кайбер диссертацияләр дә телгә алынган. Әлбәттә, мондыйларны әле тагын да арттырырга мөмкинлекләр калган. Мәсәлән, Ә.М.Закирҗановның «Татар мәктәпләренең югары сыйныфларында драма әсәрләрен өйрәнү» темасына якланган кандидатлык диссертациясе (М., 1993), гәрчә ул педагогик цикл белән барса да, табигый рәвештә татар филологиясе белән керешеп китә.

Мәгълүм ки, Башкортстанда инде шактый еллар буе башкорт теле, әдәбияты исеме астында татар филологиясенә тулысынча яисә теге яки бу дәрәҗәдә мөнәсәбәтле хезмәтләр дә языла, диссертацияләр яклана. Андыйларның да кайберләрен белешмәгә кертеп дөрес эшләгәннәр (мәсәлән: *Г.З.Рамазанов*. Мәҗит Гафури иҗаты; *А.Х.Вильданов*. Башкортстанда мәгърифәтчелек әдәбияты һәм Мифтахеддин Акмулла поэзиясе). Ә.И.Харисовның һәм кайбер башка Уфа галимнәренең дә хезмәтләрен күрсәтү зыян итмәс иде.

Китапның ахыргы бүлекчәсендә «Борынгы һәм гомумтөрки филологиясе» буенча якланган аерым диссертацияләрнең дә авторефератлары теркәлгән. Болар арасында Ә.Нәҗип, И.Стеблева, Г.Айдаров кебек күренекле галимнәрнең дә хезмәтләре бар.

Библиографик материалларны, аеруча элегрәк чорларга караганнарын туплау — шактый четерекле һәм кыен эш. Әмма шуңа да карамаста, табырга мөмкин булган авторефератлар, диссертацияләр, нигездә, китапта бар. Телгә алынмаган хезмәтләр аз. Мәсәлән, Г.Таһирҗановның «Хөсрәү вә Ширин» (Котб) әсәре хакында язылган кандидатлык диссертациясе күзгә ташланмый.

Авторлар чит илләрдә дә татар филологиясенә мөнәсәбәтле хезмәтләр язылуын искәртәләр. Чыннан да, андыйлар шактый. Мәсәлән, Төркиядә Фатма Өзкан Тукай иҗаты буенча 1992 елда докторлык диссертациясе яклый. Бу төр хезмәтләрнең Мостафа Өнәр, Фазыйл Агиш, Алсу Камалиева, Ибраһим Акыш һәм кайбер башка галимнәр тарафыннан да яклануы мәгълүм. Андыйлар Үзәк Азия, Көнбатыш мәмләкәтләрендә дә бар. Шуңа күрә «Күрсәткеч...» авторларының киләчәктә бу төр хезмәтләрне дә барларга кирәк диюләре игътибарга лаек.

Китапта кайбер хосусый төгәлсезлекләр, техник җитешсезлекләр дә күзгә ташлана. Мәсәлән, Ә.Сибгатуллинаның кандидатлык диссертациясе җитәкчесе итеп Хатип Госман күрсәтелгән (129 б.), ә ул — М.Госманов. КДУ укытучысы Камил Латыйп углы Биктаһирова дип язылган (140, 148 б.). Э.Р.Бариева Бадриева рәвешендә теркәлгән (124, 148 б.). «Исемнәр күрсәткече»ндәге саннарның төп өлештәге тәртип номерына туры килмәгән очраклары да бар. Мәсәлән, Г.Таһирҗанов 56 нчы пунктта телгә алына диелгән (152 б.). Ә бирәдә бу исем күзгә ташланмый (35 б.). И.Бәширова һәм К.Бадиковларның кандидатлык диссертацияләре әдәбият төркемендә бирелгән (113, 124 б.). Чыннан да, аларда әдәби-эстетик тикшерү-күзәтүләр шактый. Әмма бу хезмәтләр, хәтерем ялгышмаса, рәсми рәвештә тел белгечлеге буенча якландылар.

«Күрсәткеч...» авторларының «татар әдәбият белемендә «кыйсса» жанрын тикшерүгә багышланган бер хезмәт тә юк» диюләре (9 б.) чынбарлыкка бик үк туры килми. Бу мәсьәлә хакында без фәкыйрегезнең 1988 елда дөнья күргән махсус монографиясе бар. Безнең докторлык диссертациябезнең дә (1991) шактый өлеше «кыйсса», «кысалы кыйсса» жанрларын тикшерүгә багышланган.

Гомумән, бу китап — татар фән дөньясында уникаль күренеш. Аны әзерләүгә һәм чыгаруга күп көч һәм вакыт сарыф ителгән. Хезмәтнең гамәли, фәнни һәм педагогик әһәмияте зур. Бер яктан, ул татар филологиясе фәненең үсеш динамикасын, торышын, төп юнәлешләрен күзалларга ярдәм итсә, икенче яктан, бу өлкәдәге кимчелекләрне күреп төзәтергә, алга таба мөһим проблемаларын билгеләргә, фәндә дәвамчанлыкны сакларга булыша. «Күрсәткеч...» аеруча яшь галимнәр, студентлар, укытучылар өчен файдалы. Ул — кайда нәрсә барын тиз генә табуда менә дигән белешмә.

Әйткәнебезчә, хезмәт, нигездә, 1998 елның ахыргы айлары белән төгәлләнә. Шунысы куанычлы: инде менә шуннан соңгы ике еллап вакыт эчендә генә дә татар филологиясеннән 15 докторлык (Ф.Галимуллин, Х.Алишина, М.Бакиров, Ә.Сибгатуллина, И.Бәширова, Ф.Баязитова, Д.Рамазанова, Ә.Мәхмүдов, Җ.Зәйнуллин, Ф.Сафиуллина, Р.Салихов, М.Гайнетдинов, Ф.Яхин, Р.Вафиев, М.Хәйруллин...), ике дистәдән артык кандидатлык диссертациясе якланды. Әмма соңгы вакытларда аерым диссертацияләрнең

гыйльми дәрәҗәләре бераз йомшаруы да сизелә. Киләчәктә сан ягыннан гына түгел, сыйфади үсешне дә һәрчак күз уңында тоту зарури.

Бу хезмәтнең һәр китапханәдә, һәр филолог кулында булуы шарт. Әмма, кызганычка каршы, аның тиражы бик аз: бары 500 данә генә.

Мөхтәрәм Әбрар ага Кәримуллин үзенең углы белән халкыбыз, фәнебез өчен янә бер игелекле эш башкарган. Моның өчен аңа ихласи рәхмәтне әйтергә кирәк. Ходай Тәгалә бу олуг галимгә исәнлекләр бирсен.

*2000*

**ӘДӘБИЯТ ФӘНЕНЕҢ АКСАКАЛЫ**

XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты фәне шактый үсеп китте. Аның тарихы, теориясе, тәнкыйте, методикасы, текстологиясе, библиографиясе буенча төрледән-төрле хезмәтләр басылу — шуның ачык билгесе. Аеруча әдәбият тарихын, рухи мирасны өйрәнүдә җитди уңышлар бар. Шунысы мөһим: бу чордагы гыйльми тикшеренүләрнең тирәнлеге, фәнни дәрәҗәсе артты, тарихи офыклары киңәйде, моңа кадәр билгесез булган күп санлы материаллар гыйльми әйләнешкә кертелде. Әгәр дә, шәхес культы репрессияләреннән, 1941—1945 елгы сугыш афәтләреннән соң әдәбиятчылар сафы бик сирәкләнеп калса, XX йөзнең икенче яртысында аларның саны шактый артты. Өлкәннәр белән бергә урта һәм яшь буын галимнәр дә сүз сәнгатенең төрле мәсьәләләрен өйрәнүдә өлгерлек күрсәтәләр.

Соңгы ярты гасыр әдәбиятчылары арасында Шакир Шиһап углы Абилов аеруча могтәбәр урынны били. Аның фәнгә килү юлы шактый озын һәм катлаулы. Күз алдына китерегез: аспирантурага ул 40 яшенә җиткәч, 4 бала атасы булгач керә. Әмма Шакир ага яшьтән үк әдәбиятны ярата: үзе дә шигырьләр, мәкаләләр яза, тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. Аның дуслары, танышлары арасында күпләгән әдипләрнең булуы да юкка гына түгел.

Ш.Абилов 1915 елның 18 июнендә игенче гаиләсендә дөньяга килә. Әүвәл үзенең туган төбәгендә — Чиләбе өлкәсе Коншак районы Усть-Багаряк авылында укый. Аннан — Свердловскидагы татар рабфагы укучысы. 1934 елда Оренбург педагогия институтының татар филологиясе факультетына укырга керә. Студент елларында бераз вакыт өлкә газетасында да эшләп ала. Институтны тәмамлагач, ике ел Актаныш урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1940—1946 елларда Шакир ага — хәрби хезмәттә. Сугышның ачысын-төчесен татый, яралана, батырлыклары өчен күпләгән орден-медальләр белән бүләкләнә. Демобилизацияләнгәч, майор Ш.Абилов туган якларында укытучы, мәктәп директоры, район мәгариф бүлеге мөдире һәм башка җаваплы вазифаларны башкара. 1955 елдан аның эшчәнлеге Казандагы Тел, әдәбият һәм тарих институты белән бәйле. Биредә ул әүвәл аспирантурада укый, аннан — гыйльми хезмәткәр.

Шакир ага Абилов — күп санлы гыйльми хезмәтләр авторы. Әмма аның эшчәнлегендә төп һәм мөһим урынны Мөхәммәдьяр иҗаты алып тора. Ул бу шагыйрь хакында кандидатлык диссертациясе яклый (1962).

Мәгълүм булганча, 30 — 40 нчы елларда Борынгы һәм Урта гасыр әдәби мирасын өйрәнү, ул дәвер әдипләренең әсәрләрен укучыларга җиткерү бик чикләнгән иде. 50 нче елларда шәхес культының фаш ителүе сәяси богауларның билгеле бер йомшаруына китерде. Мөхәммәдьяр иҗатын да киң һәм җентекле тикшерү нәкъ менә шул елларда мөмкин булды. Шакир ага Казан ханлыгы чоры шагыйренең кулъязмаларын, аңа кагылышлы материалларны, әдип яшәгән мохитне шактый тәфсилле өйрәнде. Шуның нәтиҗәсендә галимнең диссертациясе Мөхәммәдьяр иҗатын тикшерүдә генә түгел, ә, гомумән, Урта гасыр әдәби мирасын өйрәнүдә дә яңа бер сәхифә, мөһим бер вакыйга рәвешендә кабул ителде. Шакир ага бу шагыйрьне тикшерүен алга таба да дәвам итте, үзенең эзләнү, уйлану нәтиҗәләрен аерым китаплар, татар, рус, үзбәк телләрендә мәкаләләр рәвешендә укучыларга җиткереп торды. Мәсәлән, 1966 елда ул Мөхәммәдьяр әсәрләрен кереш сүз, тиешле шәрех-аңлатмалар белән аерым җыентык итеп нәшер итте. 1963 елда дөнья күргән «Борынгы татар әдәбияты» китабындагы Казан ханлыгы һәм Мөхәммәдьяр турындагы бүлек тә Шакир ага Абилов тарафыннан язылган.

1997 елның августында татар халкы, Татарстан җәмәгатьчелеге Мөхәммәдьярның тууына 500 ел тулуны киң күләмдә билгеләп үтте. Шушы уңай белән Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында тантаналы кичә булды, Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев шагыйрь хакында гаять эчтәлекле доклад сөйләде. Мөхәммәдьяр юбилеен гыйльми әзерләүдә Шакир ага башлап йөрүче һәм төп йөкне тартучы булды. Бу бәйрәмгә шагыйрь әсәрләренең тулы басмасы дөнья күрү юбилей тантанасының йөзек кашын тәшкил итте. Китапта текстлар оригиналда, хәзерге телгә әдәби тәрҗемәдә бирелә. Басма күләмле кереш мәкалә, гыйльми аңлатмалар, библиография белән тәэмин ителгән. Боларның барысын да Шакир ага башкарган. Шуңа күрә Мөхәммәдьяр һәм Шакир Абилов исемнәре хәзерге укучы күзаллавында еш кына аерылгысыз төшенчәләр рәвешендә кабул ителә.

Галим, гәрчә ул төп игътибарын Мөхәммәдьяр иҗатына юнәлтсә дә, Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятының башка мөһим темалары һәм тармаклары белән дә шөгыльләнде. Аның «Кутадгу билиг» в булгаро-татарской литературе» дигән мәкаләсе (Советская тюркология.— 1970.— # 6.— С. 77—89) фактларга байлыгы, гыйльми яңалыгы белән шул чор тюркология фәнендә көчле яңгыраш тапты. Шулай ук Шакир ага Абиловның «О новонайденных списках памятника XIV века «Нахдж аль-фарадис» дип исемләнгән хезмәте дә (Советская тюркология.— 1977.— # 2.— С. 69—73) төрки дөньяда зур кызыксыну тудырды.

60—70 нче еллар әдәбият фәнендә методология, иҗат методы мәсьәләләре буенча Бөтенсоюз күләмендә җитди сөйләшүләр еш булып тора иде. Шакир ага да «Урта гасыр татар әдәбиятының иҗат методы турында» мәкаләсе белән (1979) бу төр сөйләшү-бәхәскә катнашты. Биредә ул хаклы рәвештә элеккеге сүз сәнгатенең гомуми үзенчәлегенә басым ясый. «Тормыш хакыйкатен,— ди автор,— Урта гасыр романтигы чынбарлыктан алынган җанлы картиналар аша түгел, ә хыялый сурәтләр аркылы күрсәтә».

Шакир ага Абиловның «Казан утлары» журналының 1966 ел, 6 нчы санында басылып чыккан «Борынгы әдәбиятыбызны өйрәнүнең өлгергән проблемалары» исемле мәкаләсе бар (135—138 б.). Автор шул чагында ук әдәбият фәненең, рухи мирасны өйрәнүнең төп мәсьәләләрен ачык һәм дәлилле куя: элеккеге әдәби ядкярләрне туплау, гыйльми нигездә бастыру; әдәби әсәрләрнең идея-сәнгати үзенчәлекләрен өйрәнү; әдәбият тарихын чорларга бүлү; текстология; әдәби тел һәм башка проблемалар. Шушы мәкаләдә ул үзенең «төрки тел» хакындагы карашларын да бәян итә. Ш.Абилов фикеренчә, «Урта Азия төрки (чыгатай) теле белән шул вакыттагы (сүз Урта гасырлар турында бара) Идел буе төркисен (болгар-кыпчак телен) бер үк нәрсә итеп карап булмый. Нәваи язган төрки (чыгатай) телен үзбәкләр «иске үзбәк әдәби (китап) теле» дип карыйлар икән, бу дөрес. Шул заманның Казан шагыйре Мөхәммәдьяр үз әсәрләрен төрки (нигездә болгар-кыпчак) телендә язам ди икән, ул да татарның шул чордагы иске әдәби (китап) теле булып тора...» (136 б.). Шунысы мөһим: алга таба татар әдәбияты фәне, нигездә, шушы мәкаләдә куелган проблемаларны гамәлгә ашыру юнәлешендә үсте, һәм Ш.Абилов үзе бу процессның үзәгендә кайнады. Аның бу өлкәдәге нәтиҗәле эшчәнлеге аеруча күптомлык татар әдәбияты тарихының Урта гасырларга багышланган беренче томын хәзерләүдә ачык күренде. Биредә Шакир ага том җитәкчесе һәм күпчелек бүлекләрнең авторы буларак катнашты. Галим бу эшкә 70 нче елларда ук ныклап керешкән иде. Аның турыдан-туры катнашында татар әдәбиятының Казанда һәм илебезнең кайбер башка шәһәрләрендә саклanучы төп чыганаклары, материаллары барланды; фәндәге казанышлар гомумиләштерелде; хезмәтнең гыйльми концепциясе һәм план-проспекты төзелеп, җәмәгатьчелек тикшерүенә куелды; авторлар коллективы төзелде һ.б. Мондый хәзерлек эшләре, әлбәттә, томның эчтәлегенә, гыйльми дәрәҗәсенә уңай йогынты ясады. Беренче томда мең елдан артыкка сузылган төрки-татар сүз сәнгате халык, дәүләтчелек (төрки каганлыклары, Болгар дәүләтләре, Хәзәр мәмләкәте, Алтын Урда, Казан, Әстерхан һ.б. илләр) тарихы, Шәрык әдәбиятлары, фольклор, дин, фәлсәфә белән тыгыз мөнәсәбәттә, дәвамлы процесс рәвешендә карала, әдипләрнең иҗат юллары, күренекле ядкярләр тикшерелә. Боларның һәммәсе дә халкыбызның рухи байлыгын, эстетик тәҗрибәсен, әхлагын, тел хәзинәсен шактый тулы итеп күз алдына китерергә ярдәм итә. Соңгы дистә елда, җәмгыятьтәге, фикерләүдәге үзгәрешләргә нисбәтән, элеккеге фәнни күзәтү-нәтиҗәләргә, бәяләргә дә теге яки бу дәрәҗәдә өстәмә-төзәтмәләр керде. Әмма әдәбият тарихының Урта гасыр һәм XIX йөзгә багышланган тәүге ике томы моңа карап үзләренең әһәмиятен киметмәде. Чөнки алар факт-мәгълүматларга байлыгы, гыйльми принципларның ныклыгы, фәнни дәрәҗәләренең югарылыгы белән сыйфатланалар.

Шакир ага Абиловның гыйльми эшчәнлегендә, Мөхәммәдьяр иҗатыннан кала, атаклы «Кыйссаи Йосыф» ядкяре дә мөһим урынны били. Ул Кол Гали әсәре белән инде берничә дистә ел шөгыльләнеп килә. Бу хакта аның күпләгән мәкалә-чыгышлары бар. Мәгълүм ки, 1983 елда «Кыйссаи Йосыф» әсәренең гыйльми-тәнкыйди басмасы дөнья күрде. Шушы уңай белән Шакир ага «Бөек шагыйрьнең үлемсез әсәре» исемле мәкаләсен язды (Казан утлары.— 1986.— # 2.— 185—188 б.). Ул «Кыйссаи Йосыф» басмасына югары бәя бирә, аның рухи тормыштагы әһәмиятен билгели. Шуның белән бергә, рецензия авторы китаптагы аерым җитешсезлекләргә, бәхәсле якларга да игътибарын юнәлтә. Басмада, мәсәлән, «әүүәл улдыр: кадде йахши, зариф үзлү» дигән юл бар (140 б.). Ул «беренчедән — буе зифа, сылу үзе» дип тәрҗемә ителгән (141 б.). Мәкалә авторы, төрле чыганакларга, шул исәптән Йосыф Баласагунлы поэмасына, Мәүла Колый хикмәтләренә нигезләнеп, биредәге «үзлү» сүзенең «аң», «акыл» мәгънәсендә кулланылуын искәртә һәм «зариф үзлү» гыйбарәсен «зирәк акыллы» дип аңлата (187 б.).

Халкыбызның сүз сәнгате үзенең тарихи яшәешендә башка кавемнәрнең, иң беренче чиратта, шәркый диндәшләребезнең әдәбияты белән тыгыз мөнәсәбәттә торган, алардагы идея-эстетик казанышларны үзләштергән, үзе дә әңгәмәдәшләренә өлеш чыгарган. Шакир ага да, бу хакыйкатьне тирәнтен аңлап, татар сүз сәнгатенең Шәрык, аеруча үзбәк, азәрбайҗан, төрек, фарсы әдәбиятлары белән күпгасырлык бәйләнешләрен даими күз уңында тота. Аның «Казан утлары» журналында дөнья күргән «Низами һәм татар әдәбияты» (1983.— № 3.— 166—171 б.), «Лотфи Идел буйларында» (1968.— № 8.— 138—142 б.), «Нәваиның шифалы йогынтысы» (1991.— № 7.— 143—148 б.) һәм башка мәкаләләре татар әдәбиятының халыкара бәйләнешләрен ачыклауга, милләтләр дуслыгын ныгытуга саллы өлеш керттеләр. Нәкъ менә шуңа күрә дә Шакир аганы Урта Азия, Кавказ галимнәре дә хөрмәт итәләр, аның язмаларын абруйлы чыганак рәвешендә файдаланалар.

Иске кулъязмаларны уку, аңлату — гаять катлаулы шөгыль. Бу өлкәдә Шакир ага судагы балык кебек. Аның хезмәтләре — сүзгә, текстка җаваплы карауның гыйбрәтле үрнәге.

Шакир ага Абилов — эрудицияле, киң карашлы галим. Ул тарих, фәлсәфә, тел белеме, дин, педагогика һәм башка тармаклар буенча да иркен фикер йөртә, еш кына алардагы казанышларны әдәби тикшеренүләрдә уңышлы файдалана.

Мәгълүм ки, 1999 елда «Татар энциклопедик сүзлеге» дөнья күрде. Бу бибәһа хезмәтне әзерләүдә, укучыга җиткерүдә Шакир ага да нәтиҗәле эшләде. Биредә ул күп кенә мәкаләләрнең авторы, мөхәррире, сүзлекнең консультанты буларак катнашты.

Галимнең әдәби традицияләр дәвамчанлыгы, хәзерге әдәбият хакында да язмалары бар. Ул фәндәге мөһим күренешләрне, яңа нәшер ителгән хезмәтләрне күрә белә, аларга профессиональ, төпле бәя бирә. Шакир ага хәзер дә, инде өлкән яшьтә булуына карамастан, гыйльми, мәдәни тормыш белән кызыксынып бара, матбугатта, төрле конференцияләрдә, фәнни мәҗлесләрдә чыгышлар ясый. Ул аеруча яшьләргә игътибарлы. Һәм, гомумән, галим үзенә мөрәҗәгать итүчеләрнең үтенечләрен һәрчак канәгатьләндерергә омтыла. Андыйлар исә шактый күп.

*2000*

## УЗГАН ГАСЫР КАҺАРМАННАРЫНЫҢ БЕРСЕ

*(Ибраһим Нуруллинның тууына — 80 ел)*

XX йөз — төрле инкыйлаблар, канкоюлы сугышлар, фәнни ачышлар, техник казанышлар, җиңү-җиңелүләр, югалту-табышлар дәвере. Бу чорда без социализмга күчеп, коммунизмга омтылып, янә капитализм буразналарына төшеп барабыз. Узган гасырның катлаулы һәм каршылыклы булуы, вакыйгаларга байлыгы һәм вакыт ягыннан тыгызлыгы ул чор кешеләренең гаять төрлелеге, теләк-омтылышларның көчлелеге, талантлы шәхесләрнең күплеге белән дә аңлатыла. Чөнки, ни әйтсәң дә, тарихны кешеләр барлыкка китерә: инсаннарның эш-гамәле, шәхси мәнфәгатьләре, субъектив максатлары, үзара мөнәсәбәткә кереп, җәмгыятьне хәрәкәткә китерә, тарихның объектив агышы туа. Кешеләрнең бу процесстагы роле аларның кылган гамәлләренә, талант-сәләтләренең дәрәҗәсенә, вазифаларына бәйле. Бар бу чорның Ленин һәм Горбачевлары, Сахаров һәм Гагариннары, Маяковский һәм Җәлилләре, Сәйдәш һәм Урманчелары, башка бик күп билгеле һәм билгесез шәхесләре. Болар арасында Тукай һәм Исхакый бүләкләре иясе, филология фәннәре докторы, профессор, күренекле галим, педагог, тәнкыйтьче, әдип, күпләгән иҗат һәм гыйлем әһелләренең остазы Ибраһим Зиннәт углы Нуруллинның да үзенә лаеклы урыны бар. Иҗтимагый, гыйльми, милли-мәдәни яктан шактый югары дәрәҗәле, мактаулы бу урынны ул үзенең фидакарь тормышы, нәтиҗәле эшчәнлеге белән яулап алды.

Ибраһим Зиннәт углы Болгар, Алтын Урда чорларыннан ук халкыбыз яшәешенең үзәк төбәкләреннән берсе булган Сембер җирендә моннан нәкъ 80 ел элек, ягъни 1923 елның 18 апрелендә, мөгаллим гаиләсендә дөньяга килә. Туган җире дә андый-мондый түгел, ә мәшһүр шагыйрь Габделҗәббар Кандалый белән бәйләнешле, аның шигырь-поэмаларында җырланган атаклы Парау авылы.

Парау илендә төш күрдем,
Ки бер кош тотдым, ук атдым,—
Парау илендә бер матур
Өчен уйкумны югалтдым,—

ди «Сахибҗәмал» авторы.

Ибраһим Яңа Малыклы районындагы һәм Мәләкәс (хәзерге Дмитровград) шәһәрендәге мәктәпләрдә белем ала. Аннан дүрт ел буе Казан мех техникумында укый. Сугыш башлангач та, үз теләге белән фронтка китә. Кылган батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә. 1942 елның ноябрендә Сталинград фронтында каты яралана, елга якын Әстерхан госпитальләрендә дәвалана. Әмма хәрби хезмәттән азат ителә. Бераз вакыт туган авылында укытучы булып эшләгәч, 1945 елда Казан дәүләт университетында әле яңарак кына ачылган татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Тормыш тәҗрибәсен туплаган, фронтовик, яшьтән үк каләм тибрәткән И.Нуруллин әйбәт укый, җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Ул — Тукай, Сталин стипендияләре иясе. Укуны бетерү белән, 1950 елда университетта аспирантурада калдырыла, М.Гайнуллин җитәкчелегендә Тукайның идея-эстетик һәм тәнкыйди карашлары турында диссертация язып, өч елдан филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә лаек була. Аспирант вакытында ук дәресләр алып бара башлаган яшь галим 40 елга якын университетта эшли: әүвәл — ассистент, өлкән укытучы, доцент; докторлык диссертациясе яклагач (1967) — профессор. Ул әдәбият тарихының төрле чорларыннан, аеруча XX йөз башыннан, дәресләр бирде, махсус курслар алып барды. Озак вакытлар буе татар әдәбияты кафедрасында эшләгән И.Нуруллин 1978 елда, аерым сәбәпләр аркасында, рус һәм чит ил әдәбиятлары кафедрасына күчәргә мәҗбүр булды. Моны ул бик авыр кичерсә дә, сер бирмәде: авыру булуына да карамастан, рус филологиясе студентларына татар әдәбиятыннан лекцияләр укыды, аларның фәнни эшләре белән җитәкчелек итте.

И.Нуруллинның гыйльми, тәнкыйди, әдәби эшчәнлеге шулкадәр зур, күпкырлы һәм колачлы ки, хәтта аның хезмәтләрен атап китү генә дә шактый кыен эш. Ул — татар, рус, үзбәк, казакъ телләрендә дөнья күргән 28 китап авторы. Алар арасында күп меңләгән тираж белән кат-кат басылган әдәби әсәрләр, дәреслекләр дә бар. Ә инде галимнең мәкалә-чыгышлары берничә йөздән артып китә.

Ибраһим ага университетта минем укытучым булды. Аннан соң да безгә чирек гасырдан артык бергә эшләргә, аралашырга туры килде. Шуңа күрә мин бу мөхтәрәм затны, аның хезмәтләрен теге яки бу дәрәҗәдә беләм, күзаллыйм. Ул алыптай гәүдәле дә, оратордай сөйләүче дә түгел иде. Әмма андагы фикри тирәнлек, көчле мантыйк (логика), оригиналь һәм кыю караш сине бик тиз үзенә җәлеп итә иде. Кечерәк кенә гәүдәле, сәламәтлеккә туймаган бу зат безгә еш кына чын мәгънәсендә каһарман булып күренә иде. Аның мәкалә-чыгышлары, китаплары җәмәгатьчелектә һәрчак зур кызыксыну белән кабул ителде, бәхәсләр дә тудырды, һәммәбезгә дә мәгълүм: хәзерге фән, әдәбият гадел, принципиаль тәнкыйтькә бик мохтаҗ. Бу хәлне күреп: «Ибраһим агалар булса иде хәзер»,— дип уфтанып та куясың.

И.Нуруллинның Урта гасыр һәм XIX йөз, совет чоры әдәбиятының төрле мәсьәләләренә, әдипләренә багышланган мәкаләләре, җыентыклары билгеле. Алар арасында әдәби осталык һәм иҗат методлары, стиль һәм жанр, традицияләр һәм яңачалык (новаторлык) хакындагы язмалар да, Ш.Камал, И.Гази, Ә.Еники, А.Расих ... иҗатларын яктырткан хезмәтләр дә бар. И.Нуруллин — вузлар өчен язылган «Әдәбият теориясе» китабының авторы да. Әмма галим эшчәнлегенең үзәген XX йөз башы әдәбияты алып тора. Мәгълүм ки, бу чор сүз сәнгате — татар әдәбияты тарихының иң үскән, чәчәк аткан дәвере. И.Нуруллин, XX йөз башы әдәбиятын иҗат методлары проблемасы аркылы өйрәнеп, фәндә яңа сүз әйтте, әдәби-эстетик фикерне яңа баскычка күтәрде. Аның бу юнәлештә язылган монографияләре («XX йөз башы татар әдәбияты», 1966; «Путь к зрелости», 1971 һ.б.), аеруча 1967 елда якланган докторлык диссертациясе («Формирование и развитие критического реализма в татарской литературе») Татарстанда гына түгел, бөтен СССРда, бигрәк тә төрки дөньяда зур фәнни казаныш буларак кабул ителде.

Тукай иҗаты — XX йөз башы татар шигъриятенең йөзек кашы. Мөгаен, шуңадыр да И.Нуруллин төп игътибарын аеруча шушы шагыйрьгә юнәлтте. Монография-дәреслекләрендә дә зур урын Тукайга бирелгән. Болардан тыш аның бөек шагыйрь турында махсус китаплары, әдәби әсәрләре дә бар: «Тукай эстетикасы...» (1956), «Тукай иҗаты» (1964), «Тукай турында хикәяләр» (1966), «Тукай Петербургта» (Драма, 1965), «Поэт из деревни Кырлай:Рассказы о Габдулле Тукае» (М.,1967) һ.б. Шунысын да искәртик: авторның драма әсәре Казан сәхнәләрендә уйналды да.

И.Нуруллин үз гомеренең зур өлешен Тукай турында фәнни-популяр китап язуга багышлады. Ул «Тукай» исеме астында тәүге мәртәбә «Атаклы кешеләр тормышы» (ЖЗЛ) сериясендә 1977 елда 100 мең тираж белән Мәскәүдә рус телендә нәшер ителде. Тиздән аның татарча (1979), үзбәкчә, казакъча басмалары дөнья күрде, күп санлы уңай рецензия-бәяләргә лаек булды, Нуруллин Тукайны, Тукай Нуруллинны киң дөньяга танытты, авторны шагыйрь исемендәге Дәүләт бүләге иясе итте. Бөек шәхеснең катлаулы язмышын, гыйбрәтле гомерен тормышчан рәвештә яктырткан «Тукай» китабы хәзер дә укыла. Аның 2000 елда Татарстан китап нәшриятында янә басылып чыгуы — шуның ачык дәлиле.

Тукай һәм Әмирхан — болар олуг әдипләр генә түгел, ә җан дуслар да. Бу затларны тиешенчә аңлау һәм бәяләү өчен, аларның икесен дә аерым-аерым да, үзара мөнәсәбәттә дә ныклап өйрәнү зарур. Шул хакыйкатьне тирәнтен төшенеп, И.Нуруллин Ф.Әмирханны тикшерүне дә һәрчак күз уңында тотты. Аның бу юнәлештәге эшчәнлек нәтиҗәләре шулай ук «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә 1988, 1991 елларда татар һәм рус телләрендә («Прометей из Новотатарской слободы») аерым китап рәвешендә дөнья күрде, һәм ул Гаяз Исхакый исемендәге премиягә лаек булды. И.Нуруллинга бу бүләкнең бирелүе һич тә очраклы хәл түгел иде. Ул — бөек әдип, атаклы сәясәтче исемен аклау, иҗатын кабат халыкка кайтару юлында чын мәгънәсендә фидакарьләрчә көрәшкән зат. Галим, беренчеләрдән булып, Исхакый турында мәкаләләрен бастырды, Төркиягә барып чыкты, әдипне күргән, белгән кешеләр белән очрашты. «Зиндан» китабының (1991) И.Нуруллинның кереш мәкаләсе белән басылуы үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Соңгы елларда Г.Исхакый әсәрләрен бастыру, тормышын һәм иҗатын өйрәнүдә шактый эш башкарылды. Әмма без моңа карап бу эшнең башында торучыларны һич тә онытырга тиеш түгелбез.

И.Нуруллин әдәбиятка хикәяче буларак килеп керде. Аның тәүге әсәрләре университетта уку елларында ук дөнья күрде. Алга таба да ул әдәби иҗат эшен ташламады: кызыклы гына әсәрләре татар һәм рус телләрендә басыла килде. И.Нуруллинның әдиплек сәләте аның фәнни хезмәтләренә дә уңай йогынты ясады. Ул, иҗат эше белән шөгыльләнгәч, үзгәләрнең дә иҗат җимешен ныграк аңлады, тойды. Гыйльми фикер-күзәтүләрен бәян итүдә дә язучы-галим, оригиналь алымнар, чаралар кулланып, җанлы, үтемле тел-стиль белән язарга омтылды. Һәм ул моңа ирешә дә.

Ибраһим ага галим, әдип буларак кына түгел, ә шәхес буларак та үзенчәлекле, гадел, вөҗданлы, принципиаль зат иде. Аның тормышчанлыгы, оптимизмы, машинада егетләрчә йөрүе (бу хакта М.Мәһдиевнең хәтта кызыклы язмалары да бар) безне сокландыра иде. Хатыны Розалина ханым (КДУ доценты) белән алар матур тормыш кичерделәр. Ул күпләгән шәкертләренә, аеруча аспирантларына (М.Мөлеков, С.Хафизов, Р.Харрасова һ.б.) һәм галим, һәм шәхес буларак матур үрнәк, өлге булып торды.

* * *

Ибраһим ага, елның матур фасылында, бөтен табигать уянган, Тукайны тудырган апрель аенда дөньяга килеп, катлаулы, нәтиҗәле тормыш юлы үтеп, җәйнең җимешле аенда, көннәрнең иң озын вакытында, милли-азатлык хәрәкәтенең шаулап торган чорында, ягъни 1995 елның 1 июлендә безнең арабыздан китеп тә барды. Аның җәсәде дә татар мәркәзендә, халкыбызның затлы инсаннары җирләнгән Яңа Бистә зиратында.

*2003*

**ИНСАНЛЫЛЫК ӨЛГЕСЕ**

Әдәбиятыбыз тарихына күз ташласак, бер мөһим хосусиятне ачык күрербез: Йосыф Баласагунлы һәм Кол Гали, Сәйф Сараи һәм Мөхәммәдьяр, Акмулла һәм Тукай, иң беренче чиратта, кеше, аның иҗтимагый вазифасы, яшәү мәгънәсе хакында тирәнтен уйланганнар. Алар фикеренчә, адәм баласы иманлы, әхлаклы, һөнәрле булырга тиеш. Башкаларга игелек кылу, буыннар хәтерендә «игү ат» калдырырлык итеп яшәү — әдипләребезнең төп хыялы. «Камил инсан» төшенчәсе, идеаль сыйфатларны үз эченә алса да, ул чынбарлык, реаль яшәеш белән дә бәйле. Мәсәлән, Акмулла һәм Тукай әсәрләрендәге Мәрҗани образының нигезен, асылын реаль шәхес — бөек галим, мәгърифәтче, тарихчы Шиһабеддин хәзрәт, аның эшчәнлеге тәшкил итә.

Традицион эстетик идеалларга, «камил инсан» төшенчәсенә теге яки бу дәрәҗәдә туры килешле, лаек инсаннар безнең тормышыбызда да бар. Шундыйларның берсе — күренекле галим, профессор Вахит Хөҗҗәт улы Хаков. Ул кара туфраклы, уңдырышлы Буа ягыннан, затлы, укымышлы нәселдән. Галимдәге зыялылык, итагатьлелек, белемгә омтылыш кебек күп кенә күркәм сыйфатлар аның туган төбәгеннән, нәсел-нәсәбеннән, гаиләсеннән килә. Ул аларны, сугыш кырларында, тормышның озын һәм катлаулы юлларында да югалтмыйча, бүгенге көнгә кадәр саклап, баетып, үстереп килә алган. Вахит абыйны минем төрле шартларда, хәтта киеренке ситуацияләрдә күргәнем бар. Әмма ул һәрчак сабыр, зыялы, әхлаклы, тыйнак, кыскасы, үз табигатенә, тәрбиясенә тугры кала иде. Бу мөхтәрәм затның исем-атамасы да, ничектер, аның асылына, холкына, эш-гамәленә туры килеп тора. Вахит — Вахид — бер, бердәнбер; кабатланмас берлек. Хаков — хак сүзеннән: чын, дөрес, туры. Ягъни хаклыкка, гаделлеккә һәм, барыннан да элек, Аллага тугры. Хөҗҗәт — хөҗҗәтле — дәлилле, ышандыргыч. Ул һәрчак кабатланмас шәхес булып кала, кешеләрне ышандырырлык итеп, тугры, дәлилле сөйли. Шуңа күрә дә аны зурлыйлар, хөрмәт итәләр. Миңа Вахит абыйның 70 һәм 75 еллык бәйрәм кичәләрен — мәҗлесләрен алып барырга туры килгән иде. Шул вакытта мин бу зур галимне, остазны, олы җанлы инсанны шәкертләренең, туган-тумачаларының, аеруча якташларының ничек олылавын, хөрмәтләвен күреп, куанып, сокланып утырдым. «Үз илеңдә пәйгамбәр булып булмый» диләр. Әмма бу гыйбарә Вахит абыйга бик туры килеп җитми. Чөнки буалылар аны гаять зурлыйлар, аның белән ихлас күңелдән горурланалар.

Вахит Хөҗҗәт углы — табигате белән дә, алган белгечлеге белән дә чын мәгънәсендә педагог, мөгаллим. Ул, Тәтеш педагогия училищесында, Казан дәүләт университетында укып, укытучы һөнәрен ала. Авыл мәктәбендә, Казанның төрле уку йортларында тел-әдәбият укыта. Уфа, Әлмәт, Ижау һәм башка төбәкләргә барып та лекцияләр укый, дәресләр уздыра. Әмма аның ярты гасырга якын педагогик эшчәнлеге Казан университеты белән бәйле. Ул — меңләгән студентларның, дистәләгән фән кандидатларының һәм докторларның остазы. Чын педагогка хас булганча, Вахит абый өчен эшнең олысы, кечесе юк: ул һәр эшне күңел биреп, булсын дип башкара. Шәкертләре нинди сорау белән мөрәҗәгать итсә дә, аларга ярдәм кулын суза: аңлата, төшендерә, юнәлеш бирә һәм иң мөһиме — кешене дәртләндерә, белем-мәгърифәт юлында канатландыра белә.

Югары уку йортында, аеруча университетта эшләүче педагогка зарури бер таләп бар: ул гадәти мөгаллим генә түгел, ә укытучы-тикшерүче, галим-педагог булырга тиеш. Син, никадәр әйбәт кеше, яхшы укытучы булсаң да, әгәр дә гыйльми тикшеренүләр алып бармыйсың, фәнни хезмәтләр язмыйсың икән, вуз таләпләренә, студент ихтыяҗларына җавап бирә алмыйсың. Бу яктан Вахит абый күпләргә, аеруча яшьләргә, үрнәк булып торырлык. Ул — 1972 елдан бирле фән докторы. Аның күп санлы монографияләре, мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен дәреслек-ярдәмлекләре, исәпсез-хисапсыз мәкаләләре бар. Галим төрле гыйльми конференцияләрдә, шул исәптән халыкара симпозиумнарда доклад-чыгышлар ясап тора, диссертацияләрне, фәнни хезмәтләрне рецензияли.

Тел халыкның рухы, җаны, яшәеш тарихы белән табигый береккән. Бер телдә тәрбия алган кешеләр арасында, никадәр аерымлыклар, капма-каршылыклар булса да, уртаклыклар күбрәк. Әгәр дә, мәсәлән, «Кара урман» яисә «Гөлҗамал» яңгырый икән, тәнендә җаны булган татарлар чагыштырмача бер үк халәт кичерә, бер-берсе белән рухташка әверелә. Вахит абый — гаҗәеп милли җанлы кеше. Бу аның бөтен табигатендә, эш-гамәлендә күзгә ташлана. Шуңа күрә аның телче-галим булуы мантыйкый. Бу могтәбәр инсан өчен газиз туган теле — тикшерү, өйрәнү объектыннан бигрәк, халкының һәм үзенең яшәү рәвеше, милләтнең тарихы, бүгенгесе һәм киләчәге. Нәкъ менә шуңа күрә дә ул телне тар лингвистик кысаларда гына түгел, ә киң планда, вакыт һәм яшәеш контекстында, чынбарлыкка туры килешле югарылыкта өйрәнергә омтыла. Һәм галим бу юнәлештә җитди генә нәтиҗәләргә дә ирешә. Аның тел тарихы, өслүб-стиль, аерым язучыларның тел осталыгы, матур әдәбият һәм тел мөнәсәбәтләре һәм башка мөһим проблемаларны яктырткан хезмәтләре күпләргә мәгълүм. Вахит абый, әдәби ядкярләрнең телен тикшергәндә, әсәрләрнең идея-эстетик хосусиятен дә күз уңында тота. Шунын нәтиҗәсендә сүзләрнең,

грамматик шәкелләрнең әсәр контекстындагы рольләре, мәгънәви һәм хисси-экспрессив вазифалары тулырак һәм үтемлерәк яктыртыла.

Галимнең Борынгы һәм Урта гасыр төрки-татар ядкярләрен тикшергән мәкалә-хезмәтләре дә игътибарга лаек. Биредә ул, гомумтөркичелек белән мавыкмыйча, татар язма теленең ничек, ни рәвешле оеша, үсә, үзгәрә баруын, андагы эчке кануннарны ачыкларга омтыла. Мәсәлән, Тукайның тел-стилен галим меңьеллык традицияләр кысасында, элеккеге әдәби телнең мантыйкый дәвам ителеше рәвешендә карый. Мондый ысул шагыйрьнең яңачылыгын, үзенчәлеген ныграк тоярга ярдәм итә.

Мәгълүм ки, узган гасырның 80—90 нчы еллар аралыгында татар теленең иҗтимагый вазифасын арттыру, аны гамәлгә кертү буенча җитди хәрәкәт башланды. Туган телнең тарихын, хосусиятләрен, язмышын камил белгән Вахит Хөҗҗәт улы бу хәрәкәтнең үзәгендә торды. Үзенең мәкалә-чыгышларында, китапларында ул телебезнең мөһим мәсьәләләрен ышандырырлык итеп яктыртып килде. Җөмләдән, аның Октябрь инкыйлабыннан соң татар теленең гамәлгә куелышын тикшергән хезмәтләре кызыклы. Аларда хәзерге көнгә дә аваздаш яклар шактый.

Вахит абый,— тарихи вазгыятьне, халкыбызның зарури ихтыяҗларын күздә тотып, татарларның латин графикасына күчәргә тиешлеген яклап чыккан, фәнни дәлилләгән һәм аны гамәлгә кертү юнәлешендә фидакарьләрчә эшләгән галимнәрнең берсе. Аның латин язуы турындагы әсбабы — соңгы дистә елда дөнья күргән китапларның, мөгаен, иң популярыдыр.

Вахит абый, гомумән, кабинет галиме генә түгел. Аның бөтен эшчәнлеге киң җәмәгатьчелеккә юнәлтелгән. Ул үзенең һәм үзгәләрнең фәнни ачышларын киң катламга, тиешле адресатка җиткерергә омтыла. Галим катнашкан һәм җитәкчелек иткән «Тел күрке — сүз» радиотапшырулары — шуның матур бер үрнәге. Ул үзенең шәкертләрен гадәти филологлар итеп кенә түгел, ә милләт хадимнәре, җәмәгать эшлеклеләре итеп тә тәрбияләргә тырыша.

Вахит абый — үрнәк ата, ир һәм бабай да. Аның балалары, оныклары галимнең үзе кебек тырыш, милли җанлы, әхлаклы. Җәмәгате Хөрия апа да ирен хөрмәт итеп тора. Шунысын да әйтик: атаклы музыкант Сәйдәш Гарифуллин, җизнәсе тәэсире аркасында, инглиз һәм татар телләренең белгече дә булып китте, диссертация яклап, фән кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия булды.

Безнең әдәбият кафедрасы Вахит Хөҗҗәт улын һәрвакыт хөрмәт итте, аны күренекле сүз сәнгате белгече дип санады, һәм без бу олуг зат, камил инсан белән хезмәттәшлек итүне, аның белән бергә эшләүне үзебез өчен бәхет, дәрәҗә дип саныйбыз. Инсанлылык өлгесе булган бу шәхескә, профессорга исәнлек, киләчәктә дә халкыбызга хезмәт итү юлында уңышлар телибез. Шундый күркәм инсаннарыбыз күбрәк булсын иде!

*2002*

**«КАЮМ БАБА»НЫҢ ДӘВАМЧЫСЫ**

*(Резедә Ганиевага — 70 яшь)*

Бу зат, күп кенә галим-голямадан, иҗат әһелләреннән үзгә буларак, күзгә-башка ташланырга, телевизор экраннарына чыгарга, эфирда һәм газета-журнал битләрендә үзен күрсәтергә яратмый, ул, ничектер, күләгәдәрәк, икенче пландарак калырга тырыша. Хәтта хезмәтләрен китап итеп бастыруда да бераз сүлпәнлек күрсәтә. Мөгаен, шуңа күрәдер аны киң катлам укучылар, халык бик үк белеп тә җиткермидер. Әмма бу шәхес белән очрашкан, аралашкан затлар, аның язганнарын укыган инсаннар, иң беренче чиратта, зыялылар, интеллектуаллар кечерәк кенә буйлы, гадәти кыяфәтле бу хатынның тирән һәм оригиналь фикерле, көчле рухлы булуын, үзләре һәм халык өчен гаять кирәкле, файдалы кеше икәнлеген бик тиз абайлап ала һәм онытылмаслык итеп күңеленә сеңдерә. Кем соң бу үзенчәлекле зат? Сүз Казан дәүләт университеты профессоры, күренекле әдәбиятчы, филология фәннәре докторы, «Татарстанның атказанган фән эшлеклесе» Резедә Кадыйр кызы Ганиева хакында бара. Бу араларда аның түгәрәк датасы, туган көннәре. Соңгы сүз стиль-өслүб таләбе белән генә күплек санда алынмады. Галимәнең туган көне икәү: 25 октябрь һәм 13 ноябрь. Берсе чын, ә икенчесе — рәсми дата.

Резедә Кадыйр кызын үзенчәлекле шәхес итеп формалаштырган, бүгенге абруйлы дәрәҗәгә ирештергән озын да, катлаулы да, гыйбрәтле дә гомер юлы бар. Юкка гына мәкалә исемендә «Каюм баба» атамасы телгә алынмады. Чөнки Резедә ханым бөек мәгърифәтченең традицияләрен, эшләрен дәвам иттерүче генә түгел, ә Каюм Насыйриның якташы да. Ул 1932 елда элеккеге Норлат, хәзерге Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылында белемле генә колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Габделкадыйр абзый сугышның беренче көннәреннән үк, авылдан беренче булып, фронтка китә һәм 1941 елның 17 сентябрендә Ленинградны саклаганда батырларча һәлак була, атаклы Серафим зиярәтына җирләнә. Авылга үлем хәбәрен дә беренче булып Резедәләр гаиләсе ала. Дүрт баланы тәрбияләү, карау Хәбирә апа җилкәсенә төшә. Олы кызы Резедә аңа бу эштә һәрчак ярдәмче, таяныч була. Гомерен балаларына багышлаган олы җанлы, укымышлы нәсел вәкиле Хәбирә апа, озын тормыш юлы үтеп, шушы елның 17 сентябрендә 91 яшендә якты дөньядан китеп барды. (Урыны җәннәттә булсын мәрхүмәнең!)

Резедә әүвәл туган төбәгендә, аннан 1947—1951 елларда Казан педагогия училищесында укый. Алга таба аның мөгаллимәлек эшчәнлеге башлана: 1951—1953 елларда Кече Шырдан авылының җидееллык, 1954—1956 елларда Биектау районы Мүлмә урта мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы. Аннан ике елга якын Казанның 87, 32, 92 мәктәпләрендә башлангыч сыйныфларда балаларга белем бирә. 1952—1958 елларда Резедә Кадыйр кызы Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә читтән торып укый. Татар һәм рус телләрен камил белгән, педагогик тәҗрибәгә ия булган, зиһенле һәм тырыш кызны КДУның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы, җөмләдән Х.Госман һәм И.Нуруллин махсус юллама белән Мәскәү дәүләт университетының СССР халыклары әдәбиятлары кафедрасына аспирантурага җибәрәләр. Биредә Резедә Кадыйр кызы 1958—1962 елларда күренекле әдәбиятчы М.И.Богданова җитәкчелегендә «Тукай иҗатында сатира» темасына кандидатлык диссертациясе яза һәм аны 1964 елның маенда Казан университетының гыйльми советында уңышлы яклый.

Аспирантураны тәгәлләгәннән соң, Р.Ганиева 1962 елның сентябреннән Казан университетының татар әдәбияты кафедрасында эшли башлый: әүвәл — ассистент, бераздан — өлкән укытучы, 1968 елдан — доцент, 1996 елдан — профессор. 60 нчы елларда тарих-филология факультетының кичке бүлегендә декан урынбасары вазифаларын да башкара. Шулай итеп, бу елның көзе галимә өчен икеләтә истәлекле: бердән, аңа 70 яшь тулды, икенчедән, университетта эшли башлавына — 40 ел.

Резедә Кадыйр кызы — һәм белгечлеге, һәм табигате белән педагог. Ходай Тәгалә аңа теләсә нинди аудиторияне тыңлатырлык сөйләү куәсе биргән. (Бу яктан университетның татар бүлеге факультеты студентлары гомумән бәхетле: Якуб Агишев, Хатип Госман, Мөхәммәд Мәһдиев... — болар коеп куйган оратор-лекторлар иде.) Галимә илһамланып, аудиторияне дә дәртләндерерлек итеп сөйли, үзендәге бай белем-мәгълүматны тыңлаучыларга бөтен күңеле белән җиткерергә омтыла, вакыты белән сәхнә осталары кебек интонацион яктан уйнап та күрсәтә. Болар бар да аның лекция-дәресләрен, чыгышларын мавыктыргыч, кызыклы итә.

Р.Ганиева — татар әдәбиятын буйдан-буйга да, төрле чорлап та укыткан зат. 40 ел вакыт эчендә ул күп төрле махсус курслар һәм семинарлар да алып барды, әдәбият методикасыннан да дәресләр бирде. «Шәрык халыкларының әдәбиятлары» — бу галимәнең төп һәм яраткан, дәвамлы курсларыннан берсе. Ул инде совет чорында ук бу фәннең күренекле белгече иде. Соңгы елларда Р.Ганиева Шәрык әдәбиятлары курсын тагын да тирәнәйтте, баетты, аны татар рухи дөньясы белән бәйләнештә өйрәнүнең һәм укытуның матур үрнәкләрен бирде.

Татар әдәбиятын рус филологиясе һәм журналистикасы студентларына укыту — шактый кыен эш. Галимә бу катлаулы вазифаны озак еллар буе зур җаваплылык хисе белән башкарып килде. Шунысы мөһим: ул үз предметын яраттыра, үзләштерттерә белә. Әгәр дә рус филологлары арасыннан А.Саяпова, Ч.Зарипова, Р.Мусабекова кебек галимәләр татар әдәбиятыннан докторлык, кандидатлык диссертацияләре яклаганнар икән, монда, әлбәттә, аларның укытучысы Резедә Кадыйр кызының да роле зур булгандыр.

Безнең күп кенә әдәбият галимнәре — фәнгә әдәби иҗат аша килгән кешеләр. Кайберләре ул ике башлангычны янәшә дә алып бара. Р.Ганиева яшь чагында шигырь, хикәя язганмы,— анысын белмим. Әмма аның күңелендә сүз сәнгатенә мәхәббәтнең көчле булуы бәхәссез. Шунсыз ул, кыен, бормалы юллар үтеп, әдәбият фәненә килмәс иде.

Резедә Кадыйр кызының гыйльми эшчәнлеге Тукайны өйрәнүдән башлана. 1964 елда дөнья күргән тәүге монографиясе дә («Сатирическое творчество Г.Тукая») бөек шагыйрь турында. Мин монда тирән мәгънә күрәм. Мәгълүм ки, Тукай — татарның җанын, рухи казанышларын оста итеп, югары кимәлдә гәүдәләндергән әдип. Галимә аның аркылы халкын, сүз сәнгатенең асылын тулырак аңларга омтыла. Тукай аны фәндә принципиальлеккә, бәяләү бизмәннәрен тугры һәм гадел кулланырга, эзләнүләрне гыйльми-теоретик югарылыкта алып барырга өйрәтә. Шунысы гыйбрәтле: Р.Ганиева бөек Тукайны өйрәнүен, пропагандалавын гомере буе дәвам итте. Аның әле яңа гына табадан төшкән «Шагыйрьнең рухи дөньясы» китабы да Тукай турында булуы үзе үк күп нәрсә хакында сөйли.

Р.Ганиеваның гыйльми эшчәнлеге шактый киң, күптармаклы. Ул, мәсәлән, 1985 елда, З. Рәмиев белән берлектә, Нәҗип Думавиның әсәрләрен тиешле шәрех-аңлатмалар, кереш сүз белән бастырып чыгарды. Күп кенә әдипләр, галимнәр хакында мәкалә-хезмәтләре бар. «Украина...», «Татар...», «Тукай...» энциклопедияләренә дә ул күп санлы мәкаләләр язды. Иҗат методлары турында да галимәнең хезмәтләре бар. Татар әдәбияты тарихының алты томлыгын язуда да катнашты. Әмма аның гыйльми эшчәнлегендә татар сүз сәнгатенең Шәрык, төрки әдәбиятлар белән бәйләнешен өйрәнү төп урынны тәшкил итә. Галимәнең «Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали» монографиясе (1988), «Восточный Ренессанс и его традиции в тюркских литературах» темасына 1992 елда яклаган докторлык диссертациясе һәм күп санлы мәкалә-чыгышлары нәкъ әнә шул темага багышланган. Аларда төрки-татар сүз сәнгате киң планда, Шәрык һәм Гареб әдәби контекстында, үсеш-үзгәрештә карала. Соңгы елларда Р.Ганиева мәдәни мирастагы дини-суфыйчылык күренешләрен, аларның фәлсәфи-эстетик чыганакларын, хосусиятләрен чагыштырма-тарихи һәм типологик планда тикшерүнең матур гына үрнәкләрен бирде. Аның аспиранткасы Нурия Ногманова (шулай ук «Каюм баба»ның якташы) «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә әт-тәүхид (бераллачылык) фәлсәфәсенең гәүдәләнеше темасына диссертация язды.

Р.Ганиева — Г.Исхакый иҗатын кайтаруга, өйрәнүгә дә зур өлеш керткән зат. Ул бөек әдипнең аерым әсәрләрен, текстологик яктан әзерләп, укучыларга җиткерде, аның хакында мәкаләләр язды. Шунысы мөһим: галимә инде дистә еллар буе университет студентларына Г.Исхакый турында махсус курс укый. Бу курсның «Мирас» журналында басылган (1998.— # 5) программасы мәктәп укытучылары, галимнәр тарафыннан да иркен файдаланыла. Р.Ганиева бөек әдип иҗатының төрле мәсьәләләрен курс, диплом язмалары итеп тә эшләтә. Аның җитәкчелегендә Алсу Кәримова, Рифә Харрасова Г.Исхакый әсәрләрен тикшерүгә багышланган кандидатлык диссертацияләре якладылар.

Фән дөньясында төрле кешеләр бар. Берәүләр үзләренең табышларын, фикер-күзәтүләрен, матбугатта бастырмыйча торып, башкаларга әйтмиләр. Р.Ганиева исә бу яктан бөтенләй башка. Ул үзенең идеяләрен, тапкан факт-мәгълүматларын һич яшереп тормый, аларны башкаларга җиткереп, өләшеп кенә тора. Мөгаен, шуңа күрәдер дә аңа студентлар, хезмәттәшләре гел тартыла. Аның җитәкчелегендә язылган курс, диплом эшләренә, диссертацияләргә проблеманың яңалыгы, фәнни-теоретик югарылык хас. Галимә, гомумән, яшьләр белән эшләүдә, фәндә алмаш буын әзерләүдә көчен дә, вакытын да кызганмый.

Гыйльми дөньяда үзең язу гына түгел, башкаларның фәнни хезмәтләрен тикшерү дә мөһим урынны били. Бу бигрәк тә диссертацияләр әзерләүдә һәм яклауда ачык күренә. Р.Ганиеваны бу мәсьәләләрдә классик өлге итеп күрсәтергә мөмкин. Ул үзенең бәяләмәләрендә, оппонентлык чыгышларында хезмәтләрне җентекле анализлый, уңай һәм кимчелекле якларын ышандырырлык итеп күрсәтә. Шунысы әһәмиятле: галимә принципиаль, таләпчән. Әмма ул тәнкыйть фикерләрен дә кешеләрне рәнҗетерлек, күңелне төшерерлек итеп әйтми, киресенчә, уңай якларга таянып, алга таба эшләү юлларын күрсәтә (ахырда үзе конкрет ярдәм дә итә), тикшерүчеләрне, бигрәк тә яшьләрне рухландыра, канатландыра белә. Бу —галимәнең инсани, әхлакый табигатен дә күрсәтүче матур сыйфат.

Соңгы 10—15 елда татар халкы милли уяну, билгеле бер үсеш, яңарыш кичерде. Шушындый вазгыятькә мөнәсәбәттә Р.Ганиева да үзенең эшчәнлеген тагын да көчәйтте, фикри, инсани яктан тагын да үсте, тагын да камилләште. Ул әдәбият фәнендә генә түгел, фәлсәфә, дин, тарих, эстетика һәм башка өлкәләрдәге ачыш-табышлардан да хәбәрдар, шуларны үз шәкертләренә һәм хезмәттәшләренә дә җиткереп

тора. Шунысы кызыклы: бу елларда ул, өлкән яшьтә булуына карамастан, студентлар белән бергә дәресләргә йөреп һәм мөстәкыйль рәвештә дә гарәп телен ныклап өйрәнде. Бу исә аңа элеккеге чыганаклар, текстлар белән эш итүне чагыштырмача җиңеләйтте. Соңгы 2—3 елда гына да бу мөхтәрәмә зат җитәкчелегендә 4 кандидатлык диссертациясе яклану — үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйләүче факт. Аның янә өч аспиранты яклауга әзерләнеп йөри.

Р.Ганиеваның гомере, төп эшчәнлеге Казан университеты белән бәйле. Әмма ул мәктәп укучылары һәм укытучылары, башка вузлардагы студентлар һәм мөгаллимнәр белән дә очрашырга вакыт таба. Галимәнең Чаллы, Түбән Новгород, Мәскәү студентларына да лекцияләр укыганы бар. Аның Финляндиядәге, Төркиядәге чыгышларын да яхшы хәтерлиләр. Галимә чуваш, коми, комык, башкорт, мордва, казакъ һәм башка тугандаш халык вәкилләренә дә гыйльми ярдәмен күрсәтеп тора.

Резедә Кадыйр кызы үзенең 70 яшенә, университетта эшләвенең 40 еллыгына олуг хезмәт, зур уңышлар белән килде. Ул үзенең остазлыгын эштә генә түгел, өендә, гаиләсендә дә нәтиҗәле башкара. Ире — Зөфәр Рәмиев (элеккеге студенты) — быел май аенда XX йөз башы татар әдәбиятында текстология, авторлык мәсьәләләре буенча докторлык диссертациясе яклады. Килене Илсөяр ханым, «Әдәбиятта Сөембикә образы» темасын өйрәнеп, быел фән кандидаты булды.

* * *

Татарда «уңган», «булган» дигән сыйфатламалар бар. Резедә Кадыйр кызы Ганиевага бу сүзләр тулысы белән туры килә. Өстәвенә бу галимә фидакарь, ир-атлар кебек батыр, кыю зат та. Ул,— якташы «Каюм баба»ның мәгърифәти, мәдәни, гыйльми эшчәнлеген дәвам итеп, үстереп, яңа гасырга, яңа меңьеллыкка ялгаучы да.

*2002*

**АСЫЛ ЯКНЫҢ АСЫЛ УЛЫ**

*(Азат Әхмәдуллинга — 70 яшь)*

Татар иленең мәшһүр төбәкләре күп: аларның берәүләре урман-сулары, икенчеләре гыйбрәтле тарихы, өченчеләре күренекле кешеләре белән мәгълүм. Әмма Ходай Тәгалә Саба ягына боларның һәммәсен дә бүләк иткән. Аның күз явын алырлык матур табигате дә, борынгы чорларга тоташкан данлы тарихы да, министрларга тиңләшерлек игенчеләре һәм мөгаллимнәре дә бар. Иң мөһиме: Саба — элек тә, хәзер дә чын татар төбәге. Анда, гасырларның җил-давылларына да карамастан, халкыбызның искиткеч бай теле, моңы, күркәм гореф-гадәтләре сакланган, үстерелгән, буыннан буынга тапшырыла килгән. Хәзерге район үзәгенең Байлар Сабасы дип йөртелүендә дә мин тирән, символик мәгънә күрәм. Ул, чыннан да, татар рухының, татар мәдәниятенең, татар яшәешенең бай һәм матур ягы. Еш кына «бер тамчы суда бөтен диңгез күренә» дип әйтәләр. Күренекле галим, педагог, җәмәгать эшлеклесе Азат Гыйльмулла углы Әхмәдуллин — үз туган төбәгенең асыл сыйфатларын, күркәмлеген аеруча калку гәүдәләндергән зат. Әгәр дә ул үзенең 70 яшьлек бәйрәмен игелекле хезмәт, олуг абруй, пакь күңел белән каршылый икән, монда, әлбәттә, аның кече Ватанының, якташларының да роле зур. Азат Гыйльмулла углын Саба ягы күтәрсә, галим үзе дә туган төбәген, аның дәрәҗәсен күтәрде, сабалыларның горурлык хисен арттырды.

Булачак профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, күп санлы гыйльми хезмәтләр, дәреслек-әсбаплар авторы 1932 елның 13 октябрендә Байлар Сабасы авылында күп балалы хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килә. Аның әти-әнисе — Гыйльмулла абзый һәм Дилшатбану апа — ипле, зыялы, гадел кешеләр була. Углы Азатның тел-әдәбият өлкәсенә китүендә, сүз сәнгатен үзенең төп белгечлеге итеп сайлавында әтисенең дә роле, мөгаен, зур булгандыр. Чөнки Гыйльмулла абзый озак еллар буе журналист, район газетасының баш мөхәррире булып эшли. Һәм, гомумән, бу гаиләдә балаларга белем-тәрбия бирүгә, китап укуга, сәнгатькә җитди игътибар ителә. Шуның нәтиҗәсе буларак, Гыйльмулла абзыйның 4 баласы да, укып, тормышның төрле тармакларында эшләп, халкыбызның алгарышына үзләреннән зур өлеш керттеләр һәм кертәләр.

Азат Әхмәдуллин, Саба урта мәктәбен бик яхшы билгеләренә тәгәлләгәч, бер ел шул ук районның Шекше мәктәбендә мөгаллим булып эшли. Аннан, ягъни 1951 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә, Әхсән Баянов, Хәниф Хәйруллин, Юныс Әминов, Марсель Бакиров, Римма Зарипова (Галиева) һәм мәдәниятебезнең башка билгеле шәхесләре белән бер төркемдә белем ала. Университетны кызыл диплом белән тәгәлләгән егет, берничә ай Татарстан китап нәшриятында эшләгәч, Тобол педагогия институтына укытучы итеп җибәрелә.

Мәгълүм ки, Тобол — элек тә, хәзер дә татарларның мөһим бер мәркәзе. «Хрущев җепшеклеге» дип йөртелгән чорда Тоболда милли-мәдәни тормыш шактый җанланып китә. Бу хәрәкәтнең үзәгендә Казан университетын тәмамлаган Г.Әхәтов, Г.Саттаров, Ф.Хатипов, Ә.Нигъмәтуллин, А.Әхмәдуллин кебек фидакарь егетләр, милләтпәрвәрләр тора. Алар биредә студентларга белем-тәрбия бирүдә, концерт-спектакльләр куюда, газеталар чыгаруда армый-талмый эшлиләр. Шунысы мөһим: югарыда телгә алынган «Казан егетләре»нең барысы да бераздан фән докторы, профессор булдылар, татар фәненең һәм мәгарифенең билгеле шәхесләренә әйләнделәр. Миңа моннан берничә ел элек Төмәндә шул төбәк укытучыларына лекцияләр сөйләргә туры килгән иде. Анда катнашучыларның күпчелеге «Казан егетләре»нең шәкертләре булып чыкты. Һәм алар үз остазларын гаять җылы итеп, яратып искә алдылар.

Югары уку йортында, даими һәм нәтиҗәле эшләү өчен, фәнни хезмәтләр язу, гыйльми эзләнүләр алып бару зарур. Шушы хакыйкатьне аңлап, А. Әхмәдуллин янә Казанга кайта һәм 1958 елда хәзерге Г. Ибраһимов исемендәге институтка аспирантурага укырга керә (Фәнни җитәкчесе — профессор М.Гайнуллин). Аны тәмамлагач, ике елга якын Татарстан радиокомитетында әдәбият-сәнгать тапшырулары бүлегендә баш редактор булып эшли. Яшьтән үк үзе дә каләм тибрәткән, җырлаган, музыка коралларында, аеруча баянда, оста уйнаган яшь белгечнең радиода икенче сулышы ачылып китә. Аның җитәкчелегендә яисә турыдан-туры катнашлыгында эфирдан гаять кызыклы, мәгънәле, милли рухлы тапшырулар яңгырый. Радиода кызып, мавыгып эшләгән Азат Гыйльмулла углын үзе аспирантурада укыган Тел, әдәбият һәм тарих институтына эшкә кат-кат чакыралар. Биредә ул 18 елга якын эшли: әүвәл кече хезмәткәр, аннан гыйльми секретарь, директор урынбасары вазифаларын башкара. Бу чорда күп төрле фәнни хезмәтләр дөнья күрә, югары дәрәҗәле белгечләр әзерләнә, гыйльми, мәдәни чаралар оештырыла, республика һәм ил күләмендәге конференцияләр, юбилейлар уздырыла. Боларны оештыруга, үткәрүгә А.Әхмәдуллин үзеннән зур өлеш кертә. 1981—1999 елларда ул — Казан университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире. Хәзер шул ук кафедраның әйдәп баручы профессоры һәм Казан педагогика университетында татар әдәбияты кафедрасы мөдире вазифаларын да башкара.

Университетта эшләү дәверендә А.Әхмәдуллин иҗади шартлар тудыруда, югары сыйфатлы филологлар хәзерләүдә, фәнне үстерүдә һәм оештыруда нәтиҗәле эш алып бара. Әгәр дә шушы вакыт эчендә татар бүлеге аерым факультет дәрәҗәсенә үскән, андагы докторлар саны гына да дистәдән артып киткән икән, монда, әлбәттә, кафедра мөдиренең дә роле зур.

Азат Гыйльмулла углының эшчәнлеге гаять күпкырлы. Әмма аның үзеген, арка сөяген гыйльми тикшеренүләр, ягъни галимлек тәшкил итә. Ул фәнни эш белән студентлык елларында ук шөгыльләнә башлый. Аның тәүге мәкалә-рецензияләре «Совет әдәбияты» журналында, төрле газеталарда дөнья күрә. Узган гасырның 60—70 нче елларында инде ул республиканың өлгергән тәнкыйтьчесенә, төпле әдәбиятчысына әверелә. Ярты гасырлап вакыт эчендә галимнең татар, рус телләрендә Казанда, Мәскәүдә, Уфада һәм башка урыннарда 450 гә якын исемдә хезмәте басылып чыккан. Болар арасында монографияләр һәм дәреслекләр мөһим урынны били. Өстәвенә ул — берничә дистә китапның, шул исәптән «Әдәбият белеме сүзлеге», «Татар әдәбияты тарихы», «Татар пьесалары...» һәм башка җитди басмаларның төзүчесе я гыйльми редакторы да.

Мин инде А. Әхмәдуллин белән бер кафедрада ике дистә елдан артык бергә эшлим. Моңа кадәр дә аның хезмәтләреннән теге яки бу дәрәҗәдә хәбәрдар идем. Кыскасы, аның тырышлыгы, нәтиҗәле эшчәнлеге сокландыра. Безнең кайбер гыйлем әһелләре эшлисе бар, язам, бастырырга җыенам, нәшер ителде дип шаулап, сөйләп йөри. Ә менә А.Әхмәдуллин бу яктан ыгы-зыгысыз, тыныч кына эшли дә эшли, эшли дә эшли. Хәтта басылып чыккан мәкалә-хезмәтләре хакында да сүз иярә генә  әйтеп куя. Бу мәкаләне язганда, галим хезмәтләренең библиографиясе белән танышкач шаккаттым: гаять киң колачлы, күптармаклы эшчәнлек! Арада әле без белмәгән яисә игътибар итмәгән язмалар да шактый икән.

А.Әхмәдуллин әдәбиятның тарихы һәм теориясе, тәнкыйть һәм методика хакында да, жанрлар һәм әдәби бәйләнешләр, аерым әдипләрнең иҗатлары турында да белеп һәм төпле итеп яза. Әмма гыйльми эшчәнлектә аның төп һәм яраткан тармагы — драматургия. Галим бигрәк тә Ф.Бурнашның сәхнә әсәрләрен һәм гомумән иҗатын тикшерү юнәлешендә зур эш башкарды. Аның «Фәтхи Бурнаш драматургиясе» дигән кандидатлык диссертациясе (1964) һәм тәүге монографиясе (1967) әдипне өйрәнүдә җитди казаныш булды. Алга таба галим Г.Коләхмәтов, К.Тинчурин, Н.Исәнбәт, Р.Ишморат, М.Әмир, Х.Вахит, Т.Миңнуллин һәм башка драматурглар хакында тикшеренүләрен дәвам иттерде, театр сәхнәләрендә барган тамаша-спектакльләр хакында күп санлы мәкалә-рецензияләр бастырды. Соңгы елларда ул Г.Исхакыйның сәхнә әсәрләре турында да үзенең фикер-күзәтүләрен халыкка, укытучыларга җиткереп бара. Галим университетта, драматургиядән махсус курслар укып, диплом эшләре яздырып, яшь буынга сәхнә әдәбиятыннан белем-мәгълүмат та бирә.

А.Әхмәдуллинның фәнгә керткән иң җитди хезмәте шунда: ул, татар драматургиясенең чыганакларын, туу һәм үсү тарихын, аның төп тенденцияләрен, асылын иҗат методы призмасы аркылы тикшереп, гыйльми-теоретик эчтәлекле, җитди монография тудырды. 1983 елда Мәскәүдә «Наука» нәшриятында дөнья күргән «Татарская драматургия: истоки и формирование социалистического реализма» дигән бу хезмәт фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан уңай кабул ителде. Шуның нигезендә галим 1987 елда, Алма-Атада диссертация дә яклап, филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗәгә ия булды.

Милләтнең язмышы, киләчәге милли мәгариф белән тыгыз бәйләнешле. Ә инде милли мәгарифнең үзәгендә милли тел, милли әдәбият тора. А.Әхмәдуллин, иҗтимагый зарурияте бөтен күңеле белән тоеп, мәктәпләр өчен әдәбияттан программалар, дәреслек-әсбаплар төзү белән 30 елдан артык шөгыльләнеп килә. Бу — гаять җитди, авыр, әмма игелекле эш. Галим язган, төзегән мәктәп дәреслекләре, сыналып, инде күп мәртәбәләр кабат басылды.

А.Әхмәдуллин — дистәләгән фән кандидатының, докторының гыйльми җитәкчесе дә. Аның берсе — филология фәннәре докторы Н.Ханзафаров — моннан берничә ел элек фән өлкәсендәге казанышлары өчен Татарстанның Дәүләт бүләгенә дә ия булды. Азат Гыйльмулла углы — күпләгән диссертацияләрнең рәсми оппоненты да булган зат. Алар арасында Уфа, Сыктывкар, Саранск һәм кайбер башка шәһәрләрнең гыйлем ияләре дә бар.

А.Әхмәдуллин — бөтен холкы, эшчәнлеге белән иҗтимагый табигатьле инсан. Ул, төп хезмәтеннән тыш, күп төрле иҗтимагый вазифалар башкарды һәм башкара. Ул — хәзерге вакытта, мәсәлән, «Мәгариф» һәм «Мирас» журналларының редколлегия әгъзасы, КДУ һәм Татарстан Фәннәр академиясе каршындагы диссертацияләр яклау советлары әгъзасы, «Татар энциклопедиясе» баш редколлегиясе әгъзасы, программа һәм дәреслекләр төзү буенча Татарстан Мәгариф министрлыгы каршындагы комиссия рәисе һ.б. Ул озак еллар буе СССР әдәби фондының Татарстан бүлеге идарәсе рәисе вазифаларын башкарды.

Азат Гыйльмулла углы — халкыбызга хезмәт итүче, әдәпле, үрнәк гаилә башлыгы да. Аның хатыны — Фирая ханым — татар мәктәпләре өчен рус теленнән язылган берничә дәреслек-әсбап авторы, профессор, Казан педагогика университетында кафедра мөдире. Улы — Айдар — тәҗрибәле табиб. Кызы — Ләйлә,—

университетны тәгәлләп, китапханәче булып эшли. Кияве — математик, КДУ доценты. Оныклары да үсеп килә.

А.Әхмәдуллинның гыйльми, тәнкыйди, педагогик һәм иҗтимагый эшчәнлеге җәмәгатьчелек, рәсми оешмалар тарафыннан һәрчак уңай бәяләнеп килде. Аның хакында 60 тан артык мәкалә басылу үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

А.Әхмәдуллин — «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» (1982), Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты (1999), күпләгән мактау кәгазьләре, рәхмәт хатлары иясе. Азат Гыйльмулла углы гомере буе халыкка, кешеләргә игелек кылу, ярдәм итү юлында. Ул — милләт алгарышына үзеннән гаять зур өлеш керткән шәхес. Шуңа да халык, җәмәгатьчелек аны зурлый, хөрмәт итә.

*2002*

**ИГЕЛЕК ИЯСЕ**

*(Хуҗиәхмәт Мәхмүтовка — 70 яшь)*

Һәрбер кеше,— ул кем булуына карамастан, үзе бер дөнья: аның үз тарихы, үз тормышы, үз офыклары бар. Җәмгыятьне исә әнә шул «дөньялар» җыелмасы, аларның үзара мөнәсәбәте тәшкил итә. Болар арасында Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт углының дөньясы үзенең яктылыгы, җылылыгы, зурлыгы белән аеруча мөхтәрәм урынны били, башкаларга игелек нурын бөркеп тора.

Мәгълүм ки, милләтнең яшәеше, алга баруы өчен аның үз үткәнен белүе, тарихи хәтергә ия булуы, әби-бабаларының тереклек тәҗрибәсенә таянуы шарт. Боларның шактые исә фольклорда, халыкның сүз сәнгатендә, телендә тупланып, оешып калган. Милләт язмышы турында тирәнтен кайгырткан Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Нәкый Исәнбәт кебек олуг затлар нәкъ менә шуңа күрә дә халык иҗаты әсәрләрен туплауга, аларны өйрәнүгә, гавамга кабат җиткерүгә җитди игътибар иткәннәр. Хуҗиәхмәт Мәхмүтов — әнә шул игелекле традицияләрне дәвам иттерүчеләрнең берсе. Аның өчен фольклорны өйрәнү — гади шөгыль генә түгел, ә яшәешенең төп мәгънәсе. Чөнки галим мәкаль-әйтемнәрдә, алкыш-сынамышларда, җыр-бәетләрдә халыкның асыл табигатен, фәнни атама белән әйткәндә, менталитетын, тереклек фәлсәфәсен, инсани-әхлакый идеалларын күрә, аларны хәзерге укучының күңел хәзинәсенә әйләндерергә омтыла. Һәм моңа ирешә дә. Аның дистәләгән китаплары, йөзәрләгән мәкаләләре — моның ачык дәлиле. Х.Мәхмүтов борынгы төрки истәлекләрен, күп санлы материалларны өйрәнү аша халкыбызның хәтер дәвамчанлыгын, озын-озак юл үтүен раслый.

Галимнең мәкалә-хезмәтләре гыйльми дә, үтемле, кызыклы да. Шуңа күрә алар белгечләрнең генә түгел, киң катлам укучыларның да игътибарын җәлеп итә. Х.Мәхмүтов, ничектер, һәр сүзнең, һәр гыйбарәнең кыйммәтен бөтен күңеле белән тоеп яза. Моңа, бер яктан, аның табигый таланты, сүзгә гашыйклыгы, икенче яктан, тирән белеме, мөгаллимлек, журналистлык тәҗрибә-күнекмәләре дә ярдәм итә. Гомумән, Х.Мәхмүтов — тапкыр, акыллы сүзле, язмалары белән генә түгел, сөйләме белән дә кешеләрне үзенә каратып торучы, көйле, ипле зат. Ул, ничектер, үзе көлмичә дә, үзгәләрне көлдерә, күңелләрне күтәрә белә. Аның белән ыгы-зыгысыз, тыныч кына эшләгәнеңне сизми дә каласың. Үзенең тыйнаклыгы, итагатьлелеге белән ул инсанлылык өлгесе булган профессор Вахит абый Хаков белән бик тә охшаш. Юкка гына алар Татарстан радиосыннан «Тел күрке — сүз» тапшыруын инде ике дистә елдан артык бергәләп алып бармый торганнардыр.

Хәзерге әдипләр арасында әдәби яңалыклар белән даими танышып баруы, каләмдәшләренең, бигрәк тә яшьләрнең иҗади уңышларына ихлас куануы белән Рәдиф Гаташ аерылып тора. Галимнәр арасында бу вазифаны, мөгаен, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов үтидер. Яңа китаплар, хезмәтләр турында ул көндәлек матбугатта еш кына мәкалә-рецензияләр яза, аларның асылын, гыйльми һәм гамәли әһәмиятен ачып бирә, авторларны яңадан-яңа хезмәтләр тудырырга илһамландырып тора.

Х.Мәхмүтовның инде 40 елга якын гомере, эшчәнлеге Г.Ибраһимов исемендәге институт белән бәйле. Ул биредә аспирантура, кандидатлык, докторлык диссертацияләре язган һәм яклаган, күпләгән гыйльми хезмәтләр тудырган, төрледән-төрле бүләкләргә, дәрәҗәләргә ия булган. Ә без аны үзебезнеке — университет кешесе дип саныйбыз, аның хезмәтләре өчен куанабыз. Ни өчен? Чөнки ул 1953—1958 елларда Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аны кызыл диплом белән тәмамлагач, ике елдан артык шунда ук өлкән лаборант булып эшли. Х.Мәхмүтов студентларның, аспирантларның, университет укытучыларының фәнни хезмәтләрен тикшерүдә, рецензияләүдә даими катнашып тора. Ул берничә ел безнең факультетта Дәүләт аттестация комиссиясе рәисе вазифаларын да башкарды. Аның хезмәтләре уку-укыту процессында, бигрәк тә фольклор, әдәбият тарихы курсларында еш файдаланыла. Бездә тәрбияләнгән берничә студентны фән кандидаты һәм докторы дәрәҗәсенә җиткерүдә дә ул, гыйльми җитәкче, оппонент буларак, зур эш башкарды.

Мамадыш якларында туып үскән, Казан университетында белем алган, Буа район газетасында алты еллап журналист булган, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында озак еллар эшләүче, Тукай бүләге иясе, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, Халыкара төрки академиянең хакыйкый әгъзасы-академигы, филология фәннәре докторы Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт углы Мәхмүтов — татар халкының, безнең барыбызның да мөхтәрәм заты. Ул — милләтебезнең рухи үсешенә, алгарышына зур өлеш керткән шәхес. Бу галим — тюркологиядә дә мәгълүм кеше. Хәзерге вакытта Анкарада чыгып килүче «Төрки дөньясы әдәбиятлары һәм фольклоры тарихы» исемле күптомлыкта Х.Мәхмүтов тикшеренүләренең дә басылуы үзе үк күп нәрсә хакында сөйли. Кыскасы, соңгы дәвер фольклор фәнен, татар филологиясен, тюркологияне Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт углы эшчәнлегеннән, хезмәтләреннән башка күз алдына да китереп булмый.

*2003*

## ҮТКӘННЕ БҮГЕНГЕГӘ ЯЛГАУЧЫ

### 1. Яшьтәшләремнең берсе

*(Марсель Әхмәтҗановка — 60 яшь)*

Юбилейлар үткәрү, истәлекле даталарны билгеләп китү тормышыбызның гадәти күренешенә әйләнеп бара. Мондый чаралар теге яки бу шәхес, вакыйга аша милләт язмышы, хәят турында уйланырга, галиҗәнап Вакытның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге хакында фикер йөртергә, башкарылган эш-гамәлләрне барларга, алдыбызга яңа бурычлар куярга мөмкинлек бирәләр.

Минем алда 1999 елгы татар календаре. Актарам. Куян елы, туксан тугызынчы ел булса да, ул шактый гына кыю йөрәкле, акыллы, эшчән шәхесләребезнең түгәрәк даталы юбилей сәнәсе (елы) икән. Биредә мин бер үзенчәлеккә игътибар иттем: баксаң, бу сәнә нигездә утыз тугызынчылар елы, аларның 60 яшьлек юбилей елы икән. Бу хәл, бу феномен нәрсә белән аңлатыладыр,— анысын белмим. Әмма шунысы ачык: бу затларның күпчелеге моңа кадәр бәйрәм-юбилейлар белән бик мавыкмады. Тукай әйтмешли, аттан артык эшләде дә эшләде һәм, Ходайга шөкер, тормыш арбасын, милләт йөген хәзер дә төптән җигелеп тарталар. Шунысы мөһим: утыз тугызынчы елгылар төрле тармак, төрле шөгыль ияләре икән! Әдәбият фәне һәм нефть генераллары Флүн Мусин һәм Ринат Галиев. Үзе бер дөньяны тәшкил итүче сатирик әдип, публицист Фәнзаман Баттал. Татар журналистикасының аксакаллары Миргалим Харисов һәм Нургали Булатов. Халык җырларын күңелләрне тетрәндерерлек итеп башкаручы Рафаил Ильясов. Талантлы рәссам Рәшит Имашев. Күп кенә шигырьләр, җырлар авторы («Чыгарсыңмы каршы алырга» үзе генә дә ни тора!), кулъязмалар, иске китаплар җене кагылган Дамир Гарифуллин. Спектакльләрдә образларның рухын тоеп, рольләрен бирелеп уйнаучы Фирдәвес Әхтәмова һәм Хәлил Мәхмүтов. Мөгаллимнәрнең мөгаллиме, физика методикасыннан фән докторы, мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү һәм яңадан хәзерләү институты ректоры Рәшит Исламшин. Композитор Марс Макаров. Җөмһүриятебездә физик тәрбия эшен алып баруга гаять зур өлеш керткән, Татарстан Республикасы физкультура, спорт һәм туризм комитеты рәисе Хәниф Мортазин... Календарьга кертелмәсә дә, җәмгатьчелек игътибарына лаек булган әле никадәр утыз тугызынчы елгылар бар! Кызганыч, инде кайбер яшьтәшләрем (Фаил Шәфигуллин һ.б.) бу фани дөньядан бакый дөньяга күчеп киткән. Авыр туфраклары җиңел булсын аларның.

Югарыда телгә алынган һәм телгә алынмаган яшьтәшләремнең (безнең Зәй, Сарман якларындагыча әйткәнчә, яшьтиләремнең) һәрберсе махсус язмага, махсус мәкалә-очеркларга лаек. Әмма биредә мин аларның берсе — Марсель Әхмәтҗанов хакында гына сүз алып барырга уйлыйм. Ни өчен нәкъ менә ул? Чөнки безнең икебезнең дә фәнни юнәлешләр, гыйльми мәнфәгатьләр шактый якын, хәтта кайчак үзара керешеп тә китә. Бу — бер. Икенчедән, без икебез дә гадәти, «рядовой» кешеләр, бары үз тырышлыгыбыз, үз көчебез белән яшәүче затлар.

Марсель Ибраһим углы Әхмәтҗанов 1939 елның 26 мартында Татарстанның көнчыгышындагы Иске Шөгер авылында хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе фронтка алынгач, 1943 елда аларның гаиләсе Казан артындагы Яңа Кенәр авылында яши башлый. 1957 елда Марсель биредәге урта мәктәпне тәмамлый. Аннан шул төбәктәге промкомбинатта, май заводында гади эшче булып эшли. 1959 елдан аның Казан тормышы башлана. 10 ел буена ул — компрессорлар заводында балта остасы. Аннан — 4 ел буе сәүдә оешмаларында инженер-товаровед. 1963—1968 елларда Казан дәүләт университеты тарих факультетының кичке бүлегендә укый. 1972 елдан башлап хәзергәчә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәре.

Рәсми яктан караганда, Марсель Әхмәтҗановның фәнгә килүе шактый соң кебек. Әмма ул тел, әдәбият, тарих, иске китаплар, кулъязмалар, кабер ташлары белән мәктәптә уку, производствода эшләү елларында ук ныклап кызыксына. Шул омтылыш аны университетка алып килә дә. Биредә ул, лекцияләр тыңлау, гамәли дәресләрдә катнашудан тыш, рухи мирас өлкәсендә эзләнүләрен тагын да көчәйтә. Күренекле әдәбиятчы, тарихчы, язучы Газиз Гобәйдуллин эшчәнлеген тикшереп, диплом эше яклый. Институтта эшләүнең тәүге елларында ул моңа кадәр галимнәр игътибарыннан читтәрәк кала килгән татар шәҗәрәләрен өйрәнү белән мәшгуль була. Гаҗәеп күп материаллар туплана, алар җентекле анализлана. Шуның нәтиҗәләрен ул кандидатлык диссертациясе рәвешендә якларга тәкъдим итә. Казакъстан Фәннәр академиясе каршындагы диссертация советында аның бу хезмәте югары бәяләнә, һәм Марсель Әхмәтҗанов 1981 елда филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә лаек була. Шунысын да искәртик: галим татар шәҗәрәләрен өйрәнүне алга таба да дәвам иттерде. 1991, 1995 елларда рус һәм татар телләрендә дөнья күргән ике җитди монографиясе — шуның ачык мисалы.

Фәнне яңа факт-мәгълүматлар, чыганаклар белән тәэмин итү, баету гыйлемнең һәр тармагы өчен актуаль. Әмма бу аеруча татар тарихы, әдәбияты, рухи мирасы өчен мөһим. Ни өчен? Чөнки кыен хәлләр,

геноцид сәясәте безнең рухи байлыгыбызны кырган, юкка чыгарган. Безгә мәгълүмнәре — шуның тик бер өлеше генә. Мондый шартларда безнең өчен һәр факт, һәр деталь, һәр кулъязма әһәмиятле. Шунсыз безнең тарихи күзаллауларыбыз, хәтеребез тонык калып, фәнебез үсә алмаячак. Марсель Әхмәтҗанов, нәкъ әнә шул иҗтимагый ихтыяҗны тирәнтен тоеп, иске китаплар, кулъязмалар туплауны, аларны гыйльми өйрәнеп, нәтиҗәләрен халыкка җиткерүне үз эшчәнлегенең һәм, гомумән, яшәешнең асыл максаты итеп куйган. Инде менә 30 еллап ул татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә фәнни экспедицияләрдә була, 7 меңнән артык кулъязма алып кайта. Бу бит үзе генә дә искиткеч хезмәт, гаҗәеп фидакарьлек! Хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясенең «Мирасханә»се төрле материаллар белән гадәттән тыш баеды. Монда, әлбәттә, Марсель Әхмәтҗановның роле гаять зур.

Галим, үзе тапкан басма һәм кулъязма китапларны җентекле өйрәнеп, 1998 елның 22 октябрендә Казан университетының гыйльми советында филология фәннәре докторы дигән фәнни дәрәҗә алу өчен диссертация яклады. Галимнәр аның хезмәтен югары бәяләделәр, бу монографиянең фән, тормыш өчен гаять файдалы булуын күрсәттеләр.

М.Әхмәтҗанов эшчәнлеге өчен күпкырлылык, комплекслылык хас. Шуңа күрә аның язганнарын тарихчылар да, филологлар да, иҗтимагый фән әһелләре дә, гади укучылар да яратып укыйлар. Шунысы мөһим: галим һәр табышын, һәр ачышын халыкка җиткереп барырга тырыша. Аның 400 ләп мәкаләсе, берничә китабы басылып чыккан. «Каһарман Катил» (Казан, 1998), «Төш юрау китабы» (Казан, 1991), «Угызнамә дастаны» (Төркия, 1998), «Татар кулъязма китабы» («Мирас» журналы, 1998—1999) һ.б.— әнә шундыйлардан. Шунысы әһәмиятле: М.Әхмәтҗанов табышлары бик тиз тормышыбызга, гыйльми әйләнешкә кереп тә китә. Мәсәлән, ул XVIII йөз шагыйре Габдессәлам хакында берничә ел элек язып чыккан иде. Хәзер инде бу әдип мәктәп программаларына да кертелде. Шәрифи, Әхмәтҗан Тубыли һәм кайбер башка әдипләр белән дә шундый ук хәл.

М.Әхмәтҗанов — бик тә ярдәмчел инсан. Шуңадыр инде аның яныннан кеше өзелми. Ул авыл укытучысына да, университет студентына да, күренекле әдип-галимнәргә дә бердәй игътибарлы.

Шушы елның гыйнвар аенда Әлмәт төбәгендә Ризаэддин Фәхреддиннең тууына 140 ел тулуга багышланган төрле чаралар (музей ачылу, фәнни-гамәли конференция һ.б.) үткәрелде. Шунда мин бер хакыйкатьне ачыкладым: М.Әхмәтҗанов бу чараларны әзерләүгә алдан ук ныклап катнашып килгән икән. Шуңа күрә биредә аны беләләр, хөрмәт итәләр.

М.Әхмәтҗанов — гыйльми эшчәнлектә дәлиллелек, мантыйкыйлык (логикалык) тарафдары. Шуңа күрә ул факт-мәгълүматлар белән ныгытылмаган, чынбарлыкка хилафлыкта торган карашларга кискен каршы чыга, кыю рәвештә үз фикерен бәян итә.

М.Әхмәтҗанов — гаҗәеп милләтпәрвәр зат та. Аның бөтен эшчәнлеге халкыбызның рухи байлыгын өйрәнүгә, тарихи хәтернең дәвамчанлыгын тәэмин итүгә юнәлтелгән. Галимне тугандаш төрки кавемнәрнең фән әһелләре дә яхшы беләләр, аның хезмәтләренә таяналар.

Татар тарихында фәнгә мөкиббән киткән, халыкка армый-талмый хезмәт иткән кешеләр бар. М.Әхмәтҗанов — әнә шундый күпкырлы, эшчән шәхесләрнең берсе. Мин аны безнең чорның Каюм Насыйрие дип тә атар идем.

60 яшь аз вакыт түгел. Ни әйтсәң дә, гомернең зур өлеше үткән. Әмма Марсель Ибраһим углы тормышының бу сызыгына намуслы хезмәт, мул уңышлар белән килә. Халкы алдында аның йөзе ак, күңеле пакь.

*1999*

**2. Әлмәт ягы — дастаннар ватаны**

Һәр халыкның гомумкультурасын аерым шәхесләрнең, аерым төбәкләрнең иҗади эшчәнлеге барлыкка китерә. Алар үзара бер система рәвешендә һәм аның элементлары мөнәсәбәтендә торалар. Әлмәт төбәге — элек тә, хәзер дә татар мәдәниятенең мөһим үзәге. Ул, гәрчә кара алтыны (нефте) дәрәҗәсендә үк булмаса да, халкыбызның рухи культурасын баетуга үзеннән зур өлеш кертте. Әмма әле моңа кадәр ул байлык тиешенчә өйрәнелмәде, халыкның үзенә кире кайтарылмады. 60—80 нче елларда Әлмәт төбәгеннән Казан университетында шактый гына студентларның укуын хәтерлим. Әмма аларның Р.Фәхреддин, Ф.Кәрими, А.Таһиров һәм кайбер башка күренекле якташлары хакында я бөтенләй, яисә юньләп белмәүләре минем җанны ашый иде. Ниһаять, 90 нчы елларда, әкренлек белән булса да, боз кузгалды. Рухи мирасны өйрәнүгә зыялыларның һәм җирле җитәкчеләрнең игътибары арту куанычлы нәтиҗәләргә китерә башлады. Кичүчат һәм Миңлебай авылларында, Әлмәт шәһәрендә гаҗәеп бай музейлар оештырылды. Ризаэддин Фәхреддиннең тууына 140 ел тулу уңае белән үткәрелгән фәнни-гамәли конференцияләр, төрле чаралар бөтен татар дөньясында яңгыраш тапты. Татарга мөнәсәбәтле урам исемнәре дә арта бара. «Әлмәт

энциклопедиясе» төзелә. Ишетүемчә, анда халкыбызның тарихына, мәдәниятенә тиешле урын биреләчәк. Җирле төбәк белән бәйләнешле төрле китаплар да күренә. Шундыйларның берсе — «Дастаннар ватаны: Кама аръягының көнчыгыш төбәкләре һәм татар әдәбияты тарихы» (Казан: Мәгариф, 1999). Аның авторы — күренекле галим-археограф, филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов.

«Дастаннар ватаны...» хезмәте, иң беренче чиратта, чыганакларга бай булуы белән игътибарга лаек. Анда төрле характердагы әдәби, тарихи, фольклор, лингвистик, архив, кульъязма һәм басма материаллар бар. Аларның шактый өлеше тәүге мәртәбә гыйльми әйләнешкә кертелә.

М.Әхмәтҗанов «Кама аръягы» төшенчәсенә, нигездә, Татарстанның хәзерге көнчыгыш районнарын кертеп карый. Үзәктә,— әлбәттә, Әлмәт. Бу һич тә очраклы түгел. Чөнки Әлмәт инде күптәннән бирле, аеруча соңгы дистә елларда Көнчыгыш Татарстанның үзенә күрә бер мәркәзе булып тора. Шуңа күрә бу җирләргә карата шартлы рәвештә Әлмәт төбәге атамасын куллану һич тә гайре табигый түгел.

Мәдәният, бигрәк тә сүз сәнгате үзен тудырган, яшәткән, үзенә хезмәт иттергән халык тарихы белән тыгыз бәйләнешле. Нәкъ менә шуңа күрә дә китап авторы төбәкнең мәдәни тарихын халкыбызның үткән юлы, этносәяси тарихы белән үреп яктырта.

Кама аръягы — борын заманнан ук безнең әби-бабаларыбызның яшәү урыны. Әмма этник процесс үз кысаларында гына бармаган: бу төбәккә төрле чорда төрле этник кавемнәр килеп, җирле халык белән кушылып торган. Бу Болгар, Алтын Урда, татар ханлыклары һәм аннан соңгы чорлар өчен дә хас. Автор язуынча, Әлмәт төбәге «XV—XVII гасыр урталарына кадәр Нугай Урдасының төп биләмәләре булып саналган» (18 б.). Бу — бик мөһим искәрмә. Чөнки кайберәүләр, дәүләтнең исеменә карап, аның халкын нугай кавеме дип кенә күз алдына китерәләр. Тарихи фактлар Нугай ханлыгының төп халкын хәзерге татарларның әби-бабалары тәшкил итүен ачык күрсәтә. Кама аръягына соңгы ике-өч гасырда татарлар яшәгән башка төбәкләрдән дә милләттәшләребезнең күчеп утыруы мәгълүм. Ризаэддин Фәхреддиннең ерак бабаларыннан берсе Юлдаш баба — тумышы белән хәзерге Яшел Үзән районыннан. Мин үзем дә Әлмәт төбәгеннән. Безнең нәселнең дә бер тармагы Казан белән бәйләнешле. Әби мәрхүмә сөйләвенчә, Казан морзаларына мөнәсәбәтле бабаларымның берсе, Нократ якларын урап, Зәй төбәгенә килеп чыккан һәм шунда төпләнеп калган.

Төбәкнең этник, сәяси тарихын, мәдәниятен, мәгарифен гомуми планда яктыртканнан соң, М.Әхмәтҗанов конкрет ядкярләргә, бу җирлек белән бәйләнешле галим-әдипләргә туктала. «Халык китабы ядкярләре» исеме астында «Китабе авык», «Ана белән угыл» дастаннарының текстлары, аларга аңлатмалар урнаштырылган. «Акай явы турында хикәят» тә тарихны танып белү ягыннан мөһим. Алга таба Мәүла Колый, Габдерахман Тайсугани, Рәхимкол бине Исламкол, Габдерәхим Утыз Имәни, Хисамеддин Мөслими, Әхмәтҗан Тубыли, Әхмәт Уразаев-Кормаши, Ризаэддин Фәхреддин, Кашшафеддин Минзәләви, Һади Атласи, Фатих Кәрими, бертуган Туйкиннар, Афзал Таһиров, Зәкиҗан Шаһгәрәев, Сәхауддин Миңлекәй кебек каләм әһелләре хакында очерклар, аларның иҗатларыннан аерым үрнәкләр бирелә. Мәгълүм булганча, Оренбург төбәген, татар тарихын өйрәнүгә рус галиме П.Рычков (1712—1777) үзеннән зур өлеш керткән. Китапта бу могтәбәр затка урын бирелү дә табигый кабул ителә. Очерклар тыгыз эчтәлекле, факт-мәгълүматларга, фикер-күзәтүләргә бай. Мәсәлән, Хисамеддин Мөслиминең «Тәварихе Болгария» әсәре, күп кенә галимнәрдән үзгә буларак, яңача тикшерелә; авторның тарихи, географик атамалар, төшенчәләр белән чагыштырмача иркен эш итүен М. Әхмәтҗанов шул чор чынбарлыгы, идеологиясе белән аңлата. Әдипләрнең фоторәсемнәре, мөһим ядкярләрнең аерым күчермәләре бирелү дә китапны баеткан. Әлмәт төбәгенә кагылышлы күп кенә археографик материаллар хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясе Мирасханәсендә саклана (аларның шактыен М.Әхмәтҗанов халыктан үзе туплаган). Җыентыкта бу төр кульъязмаларның да исемнәре, саклану берәмлекләре күрсәтелгән.

Китапка карата берничә искәрмәм дә бар:

1. «Тарих һәм әдәби мирас» бүлекчәсендә, ничектер, Көнчыгыштан килгән татар кавемнәренең этник һәм мәдәни процесстагы роле бераз күпертебрәк күрсәтелә, җирле болгар, кыпчак, хәзәр компонентларына, миңа калса, тиешенчә игътибар җитми. Авторның Кол Гали әсәре Идел буена читтән китерелгән дип әйтүе дә (14 б.) фәннең соңгы казанышлары белән ярашмый.

2. Аерым сүзләрне, гыйбарәләрне укуда, язуда, аңлатуда бәхәсле моментлар очрый. Мәсәлән: «Кәшфеллөгате» (12 б.) атамасын «Кәшфел-лөгате» рәвешендә аерып язу дөресрәк булыр. «Сохбәт» аерым битләрдә (40...) «сөхбәт» дип язылган. «Китабе авык»тагы «Әйтер, меним үҗ кечек балачагым бар» юлын (30 б.) «Әйтер: мәнем өч кечек балачыгым бар» рәвешендә уку дөресрәк булмасмы? «Шул гаҗәйеб ул фәлакның эшинә» мисрагындагы (40 б.) «фәлакның» (фәлякнең, фәләкнең.— *Х.М.*) сүзенә «кайгының» дип аңлатма бирелә. Биредә «язмышның», «тәкъдирнең» мәгънәсе контекстка ныграк туры килә. «Йактыйлар ул утынный йавлык катый» тезмәсендәге (44 б.) «йавлык» сүзенең язылышы һәм «якын» дип аңлатылуы

бәхәс тудыра. Биредә борынгы төрки сүз «йаулак» булса кирәк. Шигырь юлында ул көчәйткеч кисәкчә — «бик» мәгънәсенә туры килә (ягъни бик каты).

3. С.Кукляшевның «Диване хикәяте татар» хрестоматиясе 1851 елда басылган (5 б.) диелә. Чынлыкта ул 1859 елда дөнья күрә. 77 биттә Утыз Имәни әсәрләреннән бер сәхифәнең фотокүчермәсе бирелгән. Астагы язуда аның «гарәп телендә» булуы искәртелә. Әмма бу биттәге юлларның күпчелеге татарча.

Гомумән алганда, Марсель Әхмәтҗановның «Дастаннар ватаны...» — үзенең эчтәлеге, төзелеше, гыйльми фикерләре, библиографик материаллары белән әдәби төбәк тарихын өйрәнүнең матур бер үрнәге. Ул белешмә энциклопедия вазифаларын да башкарырлык. Бу китап — мәктәп укучылары, студентлар, укытучылар, галимнәр һәм киң катлау укучылар өчен файдалы ярдәмлек, кирәкле әсбап.

*2000*

## «КҮРИК КҮРӘЧӘКНЕ, БЕЛИК БЕЛӘЧӘКНЕ»

### 1. Мәҗнүн рухлы шагыйрь

*(Рәдиф Гаташка — 60 яшь)*

I

Йа Хода, кырык беренче елгыларга да быел 60 яшь тула. Никадәр боргаласаң да, шомартсаң да, инде бу шактый сан, инсан гомеренең соңгы чирегенә аяк басу. Юкка гына кешене бу яшьтә пенсионер итмиләр, ялга чыгармыйлар. Әмма иҗат ияләренә мондый картаю янамый. Аларның яшьлеге һәм картлыгы, гомер юлы, яшәеше сәнгатькәрнең рухи халәте, иҗат җимешләренең ниндилеге, халык хәтерендә сакланышы белән билгеләнә. Бөек Тукай тикмәгә генә болай димәгән бит:

Еллар үтеп, бара торгач картайсам да,  
Бөкрем чыгып бетсә дә, хәлдән тайсам да,—  
Күңлем минем япь-яшь калыр, һич картаймас,  
Җаным көчле булып калыр, хәлдән таймас...  
...Күңлемдә көн һаман аяз — һаман да яз,  
Шагыйрь күңлендә кыш булмый да кар яумый.

Әйе, чын иҗат кешесенең, талант иясенең күңелендә «һаман да яз», һаман да хәрәкәт, һаман да рухи тормыш кайнап тора. Рәдиф Гаташ — әнә шундый картаймас затларның берсе. Аның мондый булуына туу вакыты, ягъни март азагы (утызы), табигатьнең уянуы, җиһанның җанлануы, яшьлеккә тиң язның килүе дә билгеле бер йогынты ясагандыр. Мәгълүм булганча, туган туфрак, җир-суның ниндилеге адәм баласының табигатендә дә эзсез калмый. Җирсү (ностальгия) хисе дә нәкъ әнә шуның белән бәйле. Рәдиф Гаташның кече Ватаны — тугандаш Башкортстанның Кушнаренко районы — Урал якларының ямьле бер төбәге. Шагыйрь дә гомер буе «Марс йолдызлыгы»н, аның «малайлары»н, «имәннәре»н сагынып яши.

...Ерак Марс авылы! Башлап  
Мин дөньяны күрдем синнән —  
Карап  
Туган йорт тәрәзәсеннән...  
...Якын Марс авылым!  
Туган йортым, туган җирем!  
Мин дөньяга сикереп чыктым  
Тәрәзәңнән синең...

Кырык беренче елгыларның күпчелеге кебек, Рәдиф тә тормышның ачысын-төчесен яшьтән үк татып үсә: сабый чактан ук әтисез калу (ул сугышта һәлак була), фәкыйрьлек, ачлы-туклы көн уздыру. Әмма шулай да күңелен төшерми, ул яшәргә, киләчәккә омтыла. Биредә шагыйрь, иң беренче чиратта, үзенә тереклек кенә түгел, ә иман, әхлак, дәрт биргән олы җанлы, сабыр холыклы, шигъри табигатьле әнисенә — Сәвия апага бурычлы. Ул, тол килеш, өч ир бала үстерә, аларны югары белемле итә. Рәдифнең бер ел элек кенә җир куенына кергән игезәк абыйларыннан берсе Рәшитнең дә шагыйрь булуы Гатауллиннар нәселенең мөһим бер сыйфатын билгели. Озак еллар буе мәктәп директоры булып эшләүче икенче абыйсы Рәфит тә каләм тибрәтә. Аның хатыны Нәҗибә ханым Әминева — Башкортстанның билгеле шагыйрәсе.

Рәдиф әнкәенә һәрвакыт табынып яшәде, иҗатында аңа самими, хөрмәти юлларын багышлады («Әнкәй белән мәңгелек сөйләшү»...). Лирик каһарманның хатын-кызны олылавы, хәтта урыны белән иляһилаштыруы да еш кына шагыйрьнең үз әнисенә мөнәсәбәте аша башкарыла. 1984 елда Рәдифнең әнисе вафат булды. Бу коточкыч олы кайгыдан аның җаны, читлектәге кош кебек, ничек бәргәләнүе әле бүгенгедәй күз алдымда. Мондый рухи халәт шагыйрьнең иҗатында да гәүдәләнеш тапты.

«Үпкәнеңнән бирле...» Тукай сүзе  
Күңелемдә иде...

Сагынганда сине, әнкәй, хәзер  
Мин дә шулай димме?!  
Ә бит үбәлмәдем, соңгы юлга  
Озатканда сине,  
Тартындым мин — кырык яшьлек улың!

Инде кабатлыймын:
— Киткәнеңнән бирле...

Синең җаның күккә ашкан сәгать
Гомеремне дә кыл урталай бүлде,
Элеккечә була алмам хәзер:
Үзгәртте ул мине!..

Яшьтән үк шигырь җене кагылган, китапны су урынына эчкән үсмер өчен, урта мәктәпне тәмамлагач, кая бару мәсьәләсе тормый. Ул туп-туры Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе бүлегенә укырга керә. Биредә Уфа әдәби мохитендә кайный, Әнгам Атнабаевның шифалы йогынтысын кичерә, вакытлы матбугатта шигырьләрен бастыра. Әмма романтик рухлы яшь шагыйрьне татар мәркәзе тарта. Шактый йөреш-мәшәкатьләрдән соң шигъри җанлы галим Хатип Госман ярдәме белән 20 яшьлек егет, ниһаять, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә күчерелә. Без аның белән нәкъ шушы вакытта таныштык. Безне, ягъни тарих-филология факультетының өченче курс студентларын, 1961 елның сентябрендә Питрәч районына (Петрово исемле авыл булса кирәк) бәрәңге алырга җибәрделәр. Безнең төркемдә яшь кенә бер ят егет тә бар иде. Күзлекле. Йомыграк табигатьле, юка гәүдәле. Ничектер, киек кебек читтәрәк тора. Өс-башы да җиңелчә (көзге киемнәрен алып килмәгән иде бугай). Аягында без «чабата» дип йөрткән «плетенки». Бераздан яңгырлар башланды: юеш, пычрак. Егетнең аяк киеме җебеп теткәләнде... Шушы вакытта тигән суыктандыр, ул, бераздан авырып, хастаханәгә дә кереп ятты. Аның бу көннәрдәге матди һәм психологик кыенлыклары, рухи халәте, мөгаен, яшь шагыйрьнең үзенә генә бөтен тулылыгында мәгълүмдер.

Безнең студент төркемендә (элеккечә әйткәндә, группада) әдәбият, сәнгать белән кызыксыну, мавыгу шактый көчле иде. Даут Сөнгатов, Әдхәд Синегулов, Зөфәр Шәйхетдинов шигырьләр яза, Әнүр Исмәгыйлев драма, Нургали Булатов хикәяләр иҗат итә. Малик Хәйруллин Гёте, Гейне шигырьләрен алманча сөйләп йөри. Кәбир Нигъмәтҗанов — җырчы, нәфис сүз остасы. Мин фәкыйрегезне тәнкыйтьче дип йөртәләр... Колхозда вакытта бер көнне, ничектер, Тукай шигырьләрен яттан белү хакында сүз чыкты. Һәм сөйли башладык: бер, ике, өч... Әмма әллә ни артмый. Менә бераздан ят егетебезгә чират җитте. Һәм ул шундый осталык белән Тукайны тоташтан сөйли башлады. Урыны белән аеруча юмористик шигырьләрне уйнап та күрсәтте. Йомык күренгән егетебезне әйтерсең алыштырып куйдылар: Тукай, шигърият аны нурландырды, ачып җибәрде. Без исебез китеп аңа карап, аны тыңлап тордык. Икенче вакытта ул Бабич шигырьләрен тоташтан сөйләп безне шаккатырды. Шуннан соң ят егетебез үз булып, Рәдиф булып китте. Бу вакытта әле ул үзен Гатауллин дип йөри иде. Без исә аңа еш кына Гаташ дип дәштек. Һәм бераздан ул үзе дә, бу исемгә күнегеп, аны үзенең тәхәллүсе — шигъри атамасы итте.

Казанда укуының беренче айларында ук Рәдиф үз сабакташларын Башкортстанда яшәп иҗат итүче Мостай Кәрим, Нажар Нәҗми, Әнгам Атнабаев, Рафаэль Сафин һәм башкаларның иҗатлары белән таныштырды (һәм ул хәзер дә Уфа әдәби яңалыкларын Казан укучыларына җиткереп тора). Тиз арада без аның үзенчәлекле, кызыклы иҗат иясе булуын да белдек. Рәдифнең шигырьләре кичәләрдә, көндәлек матбугат битләрендә еш яңгырый башлады. Һәм ул кыска гына вакыт эчендә яшьләрнең, аеруча студенткаларның, яраткан шагыйренә әверелде. Аның «Төн», «Тиле йөрәк...», «Янган йөрәк», «Мин дөресен сөйлим», «Кыз җавабы», «Таллы алан...» һәм кайбер башка шигырьләрен бу чорда укыган студентларның күбесе әле һаман да хәтерли, хәтта яттан сөйли.

Таллы алан, чыклы үлән.
Көмеш бит ул, чыкмыни?
Чыланам дип чыкмый калма,
Чыктан куркыр чакмыни?

* * *

Син ризамы? «Юк!» — дисеңме? —
Синең эш.
«Сөймә мине, оныт!» — дисең? —
Синең эш!
«Тик оныту һәм онытмау» —
Минем эш....

Без Рәдиф белән ике елдан артык тулай торакта бер бүлмәдә яшәдек. Шуңа күрә аның бу чордагы тормышы, иҗат газаплары, мәхәббәт маҗаралары миңа яхшы таныш.

Безне дүртенче курста, мәктәпләрдә укытучыларга кытлыкны исәпкә алып, Татарстан районнарына, Пенза, Пермь якларына мөгаллим итеп җибәрделәр. Рәдиф берничә ай Буа төбәгендәге Исәк мәктәбендә эшләп кайтты. Ә инде 1964 елда, университетны тәмамлагач, без — Әдхәд, Рәдиф һәм мин — Сарман районына бергәләп эшкә киттек. Әмма шул уку елында Мөслим районы торгызылды, без исә Сарман ягында калдык. Рәдиф, бер ел Мөслим районының Уразмәт авылында балалар укыткач, Казанга кайтты.

1967 елда Татарстан Язучылар берлеге үсеп, танылып килүче яшь шагыйрьне Мәскәүгә Югары әдәби курсларга җибәрде. Биредә Рәдиф ике ел буе башкала һавасын сулый, әдәби, мәдәни, тормышта кайный, Үзбәкстаннан килеп, Мәскәүдә аспирантурада укучы Римма исемле кыз белән таныша, һәм тиз арада алар башлы-күзле дә булалар. Римма ханым, диссертация яклап, техник фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алуга ирешә. Хәзер ул — Казан югары уку йортларының берсендә доцент. Рәдиф белән Римма ханымның уллары Салават (белгечлеге буенча — табиб) һәм оныклары Тимур бар.

Мәскәүдән кайткач, Рәдиф Гаташ «Ялкын» журналында хезмәткәр, Татарстан китап нәшриятында мөхәррир булып эшли. 1975 елдан хәзергәчә, ягъни чирек гасырдан артык, «Казан утлары» журналының шигърият бүлеген җитәкли. Бу абруйлы басманы еш кына татар сүз сәнгатенең көзгесе, әдәби үсешнең бизмәне дип атыйлар. Журналның мондый вазифаларны үтәвендә, әлбәттә, башка хезмәткәрләр белән бергә, бүлек мөдиренең дә роле зур.

70—80 нче елларда Рәдиф Гаташның берничә мәртәбә чит илләргә (Англия, Франция, Испания, Төркия) сәяхәт кылуы мәгълүм. Шуның нәтиҗәсе буларак, аның атаклы «Европада татар шагыйрьләре» циклы туа. Шагыйрьнең шулай ук Рига, Вильнюс, Ташкент, Алма-Ата һәм бүтән шәһәрләрдә булганы, чыгышлар ясаганы бар. Һәм гомумән ул укучылар, аеруча университет студентлары белән очрашырга, әдәбият турында сөйләргә, шигырьләрен укырга ярата. Шагыйрь үзенең фикри байлыгы, мөстәкыйль карашы, сөйләү куәсе белән теләсә нинди аудиторияне сәгатьләр буе үзенә каратып тота. Р.Гаташ гаҗәп күп укый, татар, рус, тугандаш төрки әдәбиятларын, дөнья классикасын яхшы белә, хәзерге әдәби-гыйльми хезмәтләрдән хәбәрдар. Шунысы мөһим: ул яңа китаплар, каләмдәшләренең, классикларның иҗатлары хакында радио-телевидение аша, көндәлек матбугатта еш кына чыгышлар ясый. Мәсәлән, 1992 елда «Татар поэзиясе антологиясе»нең ике китабы дөнья күрде. Р.Гаташ беренчеләрдән булып бу хакта «Шәһри Казан» газетасында (13.03.1993) тирән эчтәлекле мәкалә язды, аның рухи тормыштагы урынын билгеләде. Шагыйрьнең аеруча Такташка хөрмәте зур. Ул аның 90 еллык кичәсендә бик төпле, эмоциональ рухлы доклад ясаган иде. Инде килеп бөек шагыйрьнең тууына бер гасыр тулу уңае белән «Үзгәрмәячәк мәхәббәт сүзе» исемле язмасын бастырды (Казан утлары.— № 1.— 174—179 б.). Анда Такташ шигъриятенең рухи көче дә, тәрбияви әһәмияте дә, шагыйрь традицияләренең ничек һәм ни рәвешле дәвам ителеше дә искиткеч осталык белән яктыртылган. Бу чын мәгънәсендәге эссе, чәчмә рәвештәге поэма кебек кабул ителә.

Р.Гаташ эшчәнлегенең бик тә мөһим бер ягы шунда: ул яшь әдәби талантларны эзләү, барлау, үстерү турында чын күңелдән кайгырта. Аның инде бу игелекле шөгыле яшь чагыннан, Уразмәттә эшләү елларында ук башлана. Шагыйрьнең тәүге шәкертләре инде ир уртасы кешеләр, күренекле әдипләр. Зөлфәт, мәсәлән, үзенең тәүге остазын яратып, һаман да «Хәлфәм» дип йөри. Роберт Миңнуллин, Наис Гамбәр, Фәрит Гыйльми, Газинур Морат иҗатларында да ул мөһим роль уйнады. Соңгы елларда Р.Гаташ яшь алмаш тәрбияләү белән аеруча актив шөгыльләнә. Аның хәер-фатихасы белән, мәсәлән, Чулпан Зариф, Луиза Янсуар, Гөлнур, Илгөлем, Уралия әсәрләре укучыларга мәгълүм булды.

## II

Рәдиф Гаташның шигырьләре Башкортстан һәм Татарстан матбугатында шактый иртә күренә башласа да, китаплары чагыштырмача соңрак басылып чыкты. Аның «Гөлләр су сорый» исемле тәүге җыентыгы 1966 елда нәшер ителде. С.Хәкимнең кереш сүзе белән (анда мондый юл да бар: «Укыйсы, укыйсы килә, хисләр эчкерсез, саф») чыккан бу китап әдәби яңалык дип бәяләнде. Аңа берьюлы берничә рецензия басылу (шуларның берсе — Фатих Хөснинеке) үзе үк күп нәрсә хакында сөйли. 1967 елда шагыйрьнең «Кояшлы утраулар» исемле җыентыгы укучыларга ирешә. Гомумән, Р.Гаташ — әлегә ике дистәдән артык китап авторы. Болар арасында «Шигырь китапханәсе» сериясендә чыккан «Мәхәббәткә — мәрхәмәт» (Казан, 1987) исемле күләмле җыентыклар да, балаларга адресланганнары да бар. Аның «Друзья моих друзей» (М.: Советская Россия, 1973), «Сороковая весна» (М.: Современник, 1985) исемле русча китаплары да дөнья күрде. Соңгы 5—6 елда Р.Гаташның иҗади активлыгы аеруча артты. Шушы чорда аның «Гөлләр су сорый» исемле сайланма лирикасы (Казан, 1998), «Кальбемә хис юлласам» җыентыгы

(Казан, 1999), башкорт телендә «Хистәрем бурандары» (Өфе, 1998) һәм аз тиражлы янә ике китабы (Чулпан йолдыз калыкканда.— Казан, 1994.— 77 б.; Газәлләр.— Казан, 1997.— 104 б.) укучыларга иреште. Болардан тыш шагыйрьнең яңа әсәрләре газета-журнал битләрендә дә еш басылып тора. Рәдиф Гаташның шигырьләре, рус һәм башкорт телләреннән тыш, кайбер башка телләргә дә тәрҗемә ителгән.

Шагыйрь шактый бәхетле язмышка ия. Аның һәрбер китабы укучыларның игътибарын җәлеп итә, уңай рецензияләргә лаек була. Җыентыклары Сибгат Хәким, Әхсән Баян, Гәрәй Рәхим, Сафуан Әлибай, Галимҗан Гыйльманов кебек билгеле шәхесләрнең кереш сүзе белән ачыла. Рәдиф Гаташның иҗаты хакында күренекле әдип-галимнәрнең, каләмдәшләренең һәм гомумән укучыларның (шул исәптән без фәкыйрегезнең дә) төрле телләрдә (татар, рус, башкорт, төрек...) мәкалә-язмалары бар. Аларда кызыклы фикер-күзәтүләр күзгә ташлана. Хәсән Туфан яшь шагыйрьне Язучылар берлегенә тәкъдим иткән тәүсыя-рекомендациясендә (1966) болай ди: «Мин аның тумыштан талантлы икәнлегенә, димәк, Тукайлар — Такташлар — Җәлилләр васыятен дәвам иттерүчеләрнең берсе булачагына ышанам... Телебезнең эчке гүзәллекләрен, нюансларын, аның мөмкинлекләрен гаҗәп нечкә рәвештә сизә һәм шул хисләрне реаль телгә күчерә, әйтә ала Рәдиф». Хәсән Сарьян яшь әдипне «бөтен күзәнәкләре белән шагыйрь кеше» дип атый (1966). Роберт Миңнуллин карашынча, «аның шигырьләре һәркемгә кадерле хисләр белән сугарылган» (1973). «Рәдиф Гатауллин шигъриятен мин якты сагыш белән өртелгән мәхәббәтнамә итеп кабул итәм. Шул мәңгелек темага янәшә генә җирсү моңы, яшьлеккә мәхәббәт, тормышка мәдхия».— Бу юллар Роберт Әхмәтҗановның 1978 елда язылган бер мәкаләсеннән. «Рәдиф Гатауллин,— ди Тәлгат Галиуллин (1988),— чирек гасырдан артык татар поэзиясенә намус белән хезмәт итә...» Ул — «татар поэзиясенең рыцарьларыннан берсе...» Гариф Ахунов фикеренчә, «табигыйлек, иркенлек, сафлык, ышандыру көче» — Рәдиф Гаташ поэзиясенең төп сыйфатлары (1994). «Аның һәр шигыре,— ди Гәрәй Рәхим,— мин — Рәдиф Гаташ шигыре, дип кычкырып тора. Шагыйрьнең үз стиле, үз язу манерасы, үз кулы» (1999). Әдип хакында әйтелгән мондый мөһим фикерләрне «Гаташ турында китап»тан (Казан, 1998) һәм башка чыганаклардан күпләп китерергә мөмкин. Тагын шунысы да бар: соңгы елларда Рәдиф Гаташ иҗаты турында курс һәм диплом эшләре дә языла. Аларда кызыклы гына күзәтүләр бар. Казан дәүләт университеты студенткасы Алия Сабирова безнең җитәкчелектә язылган «Рәдиф Гаташ иҗатында Урта гасыр әдәбияты традицияләре» исемле диплом эшендә (Казан, 1999) болай ди: «Гаташча ярату — кешенең газаплы да, бәхетле дә булган бер халәте; гашыйк кеше дөньяны да башкачарак, ачыграк һәм матуррак төсләрдә кабул итә... Гаташның лирик каһарманы бервакытта да пыскып янмый, аның хисләре — давыллы, шашкын хисләр». Хәзер аспирант Чулпан Гыйлаҗева (фәнни җитәкчесе — профессор Р.Ганиева), шагыйрь иҗатын тикшереп, диссертация яза. Шунысын да әйтик: гәрчә Р.Гаташ хакында фәнни-тәнкыйди язмалар шактый булса да, аның шигъри фикерләү үзенчәлеге, поэтик эзләнү-табышлары әле тиешенчә ачылмаган, Г.Ахунов сүзләре белән әйткәндә, аның поэзиясе тикшеренүчеләр өчен әле һаман да «каты чикләвек» булып калуында дәвам итә.

Рәдиф Гаташ — көчле лирик, ягъни хис-тойгы, уй-кичереш шагыйре. Аның поэма дигәне дә рухи халәтнең төрле мизгелләрен гәүдәләндергән лирик бәйләм-циклларны хәтерләтә. Хәтта әдип фәнни-тәнкыйди чыгышларында да үзенең асылына хилафлык кылмый, эмоциональ рухлы шагыйрь булып кала. Ул — Ясәви һәм Өмми Кәмал кебек суфый әдипләрдән, Габдессәлам һәм Кандалый кебек мәхәббәт җырчыларыннан килә торган ихласлылык, самимилек кебек сыйфатларны уңышлы дәвам итүче. Аның да үз образы, шәхесе лирик каһарман белән бик якын, хәтта алар еш кына үзара кушылып та китәләр.

Рәдиф Гаташның лириклыгы аның романтик фикерләве белән табигый керешкән. Реаль дөнья, катгый иҗтимагый, социаль мөнәсәбәтләр, яшәешнең рәсми кануннары аның өчен бары импульс чыганаклары, язу өчен чимал, материал гына. Аларның объектив рәвешен, хакыйкый нисбәтен саклау шагыйрь өчен мәҗбүри түгел. Шуңа күрә аның иҗатында «гөлләр су сорый», «йолдыздан җилләр исә», «күзләр яз була», кешеләр «күк гөмбәзен» иңнәрендә тотып тора, гомумән, гайре табигый нәрсәләр җирләштерелә, гадәти күренешләр искитмәлегә әверелә.

Тормыш, заман, инсан нинди генә булса да, адәм баласы өчен, гомумән, игелеккә, матурлыкка омтылу хас. Бу юнәлеш Р.Гаташ иҗатында да үзен нык сиздерә. Аның лирик герое гүзәллеккә, гаделлеккә соклана, гармонияле тереклек тантанасы өчен җан ата.

Гадәттә, әдипләрнең иҗатын идея-проблематик яктан тикшерү киң таралган. Әгәр дә бу ноктадан карасак, шагыйрь әсәрләрендә без иҗтимагый, социаль, фәлсәфи, мәхәббәт, милли, ватандарлык һәм башка мәсьәләләрнең яктыртылышын күрербез. Әмма шунысы гаҗәп: бу төр проблемалар анда еш кына чикләрен югалта, үзара кушылып, керешеп китә. Мәсәлән, Р.Гаташның мәхәббәт җырчысы булуы һичкемдә бәхәс тудырмый. Ул сөю хисләрен, кыз — егет, ир-ат — хатын-кыз мәхәббәтен әхлакый, инсани яктан күркәм, калку итеп, үзенчә, үтемле рәвештә тасвирларга омтыла. Әмма аның иҗатында мәхәббәт кеше табигатенең, инсан эшчәнлегенең төрле тармаклары белән бәйләнешле. Котб, Харәзми, Кандалый ке-

бек, бүгенге шагыйребез өчен дә мәхәббәт — кеше тереклегенең асылы, яшәешнең мәгънәви максаты. Автор: «Нинди бәхет! Һәрбер көне белән Дөнья ашыктыра... Яши ала шулай ашыгып җирдә Бары гашыйк кына»,— дип, юкка гына әйтми. Шагыйрь мәхәббәт, хатын-кызны сөю аша, гомумән, кешеләрне дә, матур яшәешне, газиз халкын, «әнкә телен», туган җирен дә яратырга чакыра. Аның инануынча, мәхәббәт — «җитәкләүче» дә, «борма юллардан, чытырманнардан чыгаручы... көч тә». Ышанам, ди ул, «Җирне саклар шул ук... Мәхәббәт!»

Рәдиф Гаташ — бөтен рухы, фикерләве, тел-стиле, хис-тойгылары, чынбарлыкны тоюы һәм сәнгатьчә рәсемләве белән милли шагыйрь. Әмма ул инсаннарның күңел дөньясын, психологик халәтен үзенчә җырлавы белән башка милләт укучылары өчен дә кызыклы. Башкортлар аны, мәсәлән, бик яратып укыйлар. Әмма русчага тәрҗемәләре әле хәзергә бик дан түгел.

Кырык еллык иҗатында Р.Гаташ — татар поэзиясенең шигъри мөмкинлекләрен арттыруга, жанр хәзинәсен баетуга да зур өлеш керткән автор. Ул, бер яктан, классик әдәби казанышларны, милли фольклор байлыгын уңышлы дәвам иттерде, икенче яктан, бүтән халыкларның эстетик тәҗрибәсен дә иҗади үзләштерде. Аның бигрәк тә шигырьнең ритмикасы, строфа төзелеше өлкәсендәге эзләнүләре кызыклы булды. Чордашы Равил Фәйзуллин белән бергә Р.Гаташ та ирекле шигырьнең матур гына үрнәкләрен тудырды. Аларның чорга авраздаш интонацион яңгырашны эзләү тәҗрибәсе кайбер башка шагыйрьләр, бигрәк тә яшьләр тарафыннан уңышлы файдаланылды.

Татарстан Язучылар берлеге каршындагы «Шагыйрьләр секциясе»нең 1966 елгы 5 апрель утырышында Әхсән Баянов болай ди: «Рәдифне шагыйрь буларак та, кеше буларак та яхшы беләм... Миңа аның лирикасы бик ошый, баштарак мине аның Көнчыгыш поэзиясе белән мавыгуы борчый иде, ләкин хәзер күрәм: аның үз тавышы матур, табигый». Күрәсез, шагыйрь инде Шәрык шигърияте белән 60 нчы елларда ук ныклап кызыксынган. Аннан соң да ул бу кызыксынуын дәвам иттерде: күп кенә китаплар укыды, Хафиз, Фөзули, Н.Хикмәт һәм кайбер башка авторларның әсәрләрен дә тәрҗемә итте. Ә менә үз шигырьләрендә 70—80 нче елларда Шәрык тәэсире артык сизелми. Соңгы дистә елда исә Көнчыгыш рухы аның шигырьләренең һәм эчтәлегендә, һәм шәкелендә ярылып ята. Бу нәрсә белән аңлатыла соң? Элегрәк Шәрык белән мавыгу хупланмаган. Моны Ә.Баянов сүзләре дә раслап тора.Үзгәртеп кору чоры башлангач, милли үзаң кузгалуга нисбәтән, рухи тамырларыбыз, мәдәни мирас белән кызыксыну көчәйде. Шәрыкныкы дип әйткән нәрсәләрнең шактые үзебезнең әдәбиятыбызга да Урта гасырлардан ук хас икәнлеге ачыкланды. Газәл, робагый кебек классик жанрлар романтик рухлы, лирик табигатьле Р.Гаташ фикерләвенә дә кулай булып чыкты. Нәтиҗәдә хәзерге укучылар да яратып укый, бирелеп тыңлый торган, милли образ-детальләргә бай газәлләр, робагыйлар туды.

Шагыйрь, классик жанрлар белән беррәттән, поэзиянең башка шәкелләреннән, ирекле шигырь элементларыннан да баш тартмый.

Р.Гаташ — дистәдән артык җыр авторы да. Бигрәк тә аның «Безнең җыр» (Сара Садыйкова музыкасы), «Күңелемдә ике яз» (Фасил Әхмәтов музыкасы), «Язгы ташу» (Марс Макаров музыкасы), «Аңлашу» (Риф Гатауллин музыкасы) җырлары популяр. Әмма әле шагыйрь мирасында үзеннән-үзе көй соралып торган шигырьләр шактый. Аның газәлләренә нигезләнеп, күләмлерәк музыкаль әсәрләр дә (цикллар да) иҗат итәргә мөмкин.

* * *

Татар сүз сәнгате — озын тарихлы, бай әдәбият. Андагы күп санлы әдипләр арасында Рәдиф Гаташның да үзенә лаеклы урыны бар. Соңгы дәвер татар әдәбиятын аннан башка күз алдына да китереп булмый. Ул инде менә дүрт дистә елдан артык әдәбиятыбызга, халкыбызга намус белән хезмәт итә, әсәрләре дәреслекләргә кертелгән. Ул — Кол Гали, Сәйф Сараи, Кандалый, Тукай, Бабич һәм Такташлардан килә торган әдәби традицияләрне уңышлы дәвам итеп, гасырларны тоташтырып, шигъриятебезне үстерүгә, кызыклы ачышлар, фикер-шәкелләр белән баетуга үзеннән иң зур өлеш кертүчеләрнең берсе. Аның язганнары инде хәзер генә түгел, моннан дистә еллар элек үк Тукай бүләгенә лаеклы иҗат. Әмма чын иҗат кешесе, талантлы шагыйрь өчен, бәлкем, монысы бик мөһим дә түгелдер.

Рәдиф дус! Синең «Ирләр булыйк — ир булгач та, картайгач та» дигән шигъри юлың бар. Моңа кадәр син тормышта да, иҗатыңда да чын ир булдың. Алга таба да шулай булып кал.

*2001*

**2. Робагый жанры һәм Гаташ**

Чорыбызның күренекле шагыйре Рәдиф Гаташ инде менә 40 еллап шигърият мәйданында бәйге тота. Аның романтик рухлы, уй-кичерешләргә бай лирикасы укучыларны, бигрәк тә яшьләрне, үзенә җәлеп итә, аларны уйландыра, дулкынландыра. Казан университетының татар филологиясе студентлары тел вә әдәбияттан курс һәм диплом эшләре язалар. Шактый гына темаларның Рәдиф Гаташ иҗаты белән бәйләнешле булуы үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Киләчәктә бу шагыйрь эшчәнлегенең аерым тармакларына багышланган диссертацияләр язу да күздә тотыла.

Рәдиф Гаташ озак еллар буе, аерым жанрларга өстенлек бирмичә, төрле шәкелләрдә (формаларда), хәтта чагыштырмача ирекле рәвештә дә иҗат итеп килде. Аның китапларында кызыклы эзләнүләр, мәгънәви һәм шәкли табышлар тулып ята. Соңгы дистә елда, ягъни 90 нчы елларда, Рәдиф Гаташ, нигездә, газәл һәм робагый жанрларында иҗат итә башлады. Сорау туа: ә ни өчен соң шагыйрь, дөньялар болганып, вазгыятьләр үзгәреп торган заманда, калыплашкан, классик шәкелләр белән мавыгып китте? Бу сөальгә җавап бирү әлбәттә кыен. Чөнки ул, иң беренче чиратта, иҗади процесс, шагыйрьнең рухи халәте, психологиясе, яшь үзенчәлеге белән бәйле. Шулай да биредә берничә факторны атарга мөмкин. Беренчедән, үзгәртеп кору чорында халкыбызның милли үзаңы кузгалды, тарихи үткәннәр, рухи мирас, дин белән кызыксыну көчәйде. Икенчедән, бу чорда татар сүз сәнгатенең Шәрык әдәбиятлары белән традицион бagланышларын өйрәнү, торгызу юнәлешендә җитди генә эшләр башкарылды. Өченчедән, рухи мирасны яхшы белгән Рәдиф Гаташ үзенең күңел серләрен, яшәеш турындагы уй-хисләрен классик газәл, робагый шәкелләрендә дә бирү мөмкинчелеген тоеп алды. Дүртенчедән, чәчләренә чал керә башлаган, әмма күңеле яшьләрчә калган шагыйрь, бәлкем, әдәп йөзеннән уй-хисләрен бераз тезгенләү өчен тотрыклы формаларны кулайрак тапкандыр?! Бәлкем, авторның болгавыр заманга тәртипле, гармонияле сәнгать дөньясын да каршы кую теләге булгандыр?!

Шагыйрьнең газәлләре хакында инде без бер мәкаләбездә язып чыккан идек (Мирас.— 1997.— # 3.— 44—48 б.). Биредә исә сүз бары робагыйлары турында гына барачак.

Робагый — гарәби чыгышлы сүз. Аның тамыр мәгънәсен «дүрт» төшенчәсе тәшкил итә. Дүрт хәрефле сүзне дә робагый дип атау бар. Гарәп, фарсы, төрек, үзбәк, татар телләрендә дүртьюллык шигырьне робагый дип атау гадәткә кергән.

Газәл жанры безгә фарсы аша гарәптән кабул ителгән. Әмма робагый, гәрчә аның исеме гарәпчә-фарсыча булса да,— үзебезнең шәкел. Чөнки дүртьюллыклар элек-электән төрки-татар сүз сәнгате өчен хас. Фольклордагы күп санлы җырлар, М.Кашгарый китабындагы шигырьләр—шуның ачык мисалы. Дүртьюллык шәкел, гомумән, күп кенә башка халыкларның әдәбияты өчен дә чит түгел. Шуңа күрә аны, алынма диюдән бигрәк, типологик яктан охшаш, уртак күренеш дип карау дөресрәк булыр. Чөнки яшәештәге, психологиядәге, фикерләүдәге, иҗаттагы якынлыклар еш кына әдәби-эстетик күренешләрнең дә охшашлыгын, хәтта уртаклыгын да тудыра.

Тормыштагы кебек, сәнгатьтә дә кайчак теге яки бу күренеш аерым шәхесләрнең исеме белән таныла. Робагый белән дә шундый ук хәл. Иранның мәшһүр астрономы Гомәр Хәйям (1048—1132) дөньяга, иң беренче чиратта, үзенең дүртьюллыклары белән мәгълүм. Ул робагый шәкелен камилләштерүгә, аның мөстәкыйль жанр буларак яңгырашын, эчке драматизмын, әһәмиятен арттыруга зур өлеш кертте. Гомәр Хәйям дүртьюллыкларының робагый авторларына, шул исәптән татар шагыйрьләренә дә йогынтысы зур булды. Аның әсәрләре элек тә, хәзер дә татар укучыларына оригиналда һәм төрле тәрҗемәләр аша мәгълүм. Шагыйрьнең Нури Арсланов тәрҗемә иткән робагыйлары 1986 елда Казанда аерым китап рәвешендә дә дөнья күрде. Рәдиф Гаташ та дүртьюллыклар остасына хөрмәт хисләрен белдереп китә: «Булдың, Гаташ, Хәйямнар бакчасында, Робагыйлар яңгырашы җанында...» Әмма кабатлап әйтәбез: фарсы шагыйре Гомәр Хәйямның робагый шәкелен үстерүдә роле гаять зур булса да, бу жанрның нигезе үзебездә; аның яшәеше, үсеше төрки-татар сүз сәнгате белән табигый бәйләнешле. Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Рабгузый, Харәзми, Сәйф Сараи, Мәүла Колый, Акмулла, Кандалый, Дәрдемәнд, Тукай, Бабич, Әхмәт Исхак, Нури Арсланов, Гамил Афзал...— болар бар да робагый жанрында, ягъни дүртьюллык шәкелдә иҗат иткән шагыйрьләр. Димәк, Рәдиф Гаташ парчалары буш җирдә тумаган, аларның ныклы нигезе, бай традицияләре бар.

Кайвакыт робагый атамасын дүртьюллык строфага карата да куллану очрый. Әмма мондый караш буталышка китерә. Шуңа күрә хәзерге фәндә уй-кичереш ягыннан, интонацион җәһәттән тәмамланган, мөстәкыйль дүртьюллыкларны робагый дип атау кабул ителгән. Башка әсәр составындагы дүртьюллык икән, аны робагый (дүртьюллык) дип түгел, ә дүртьюллык строфа дип әйтү дөресрәк булыр.

Робагый — фәрдтән (икеюллыктан) кала, шигърияттә иң кече жанрларның берсе. Аның рифмалашуы, нигездә, *ааба* рәвешендә. Тәүге ике юлда, кагыйдә буларак, төп вазгыять, хәл, күренеш бәян ителә, тасвирлана. Биредә интонация дә хәбәр итү, «хикәяләү», хәтта өлешчә санау рәвешен дә ала, психологик яктан нәрсәнедер кабул итәргә җирлек тә әзерләнә. Тәүге юллардагы уй-хискә, эчтәлеккә реакция,

мөнәсәбәт рәвешендә бирелгән өченче юл югарырак тон, үзгә рифма белән әйтелә. Ахыргы юл чишелеш, нәтиҗә, интонацион яктан төгәлләнеш төсен ала.

Робагый фикер-кичерешләрнең тыгызлыгын, эчтәлекнең, тел-стильнең аңлаешлы булуын таләп итә. Биредә җентекле сурәтләүләргә урын юк. Характерлы деталь, гыйбрәтле вазгыять, ритмик төгәллек, матур яңгыраш, гаруз куллану — классик робагыйларның күпчелегенә хас сыйфатлар. Бу жанр, гәрчә күләм ягыннан кечкенә булса да, идея-тематик җәһәттән үзендә күп төрле мәсьәләләрне гәүдәләндерә ала. Әмма күпчелек робагыйлар, мәсәлән, Гомәр Хәйям парчалары фәлсәфи характерда. Акмулла, Дәрдемәнд төп игътибарларын әхлакый, иҗтимагый-социаль күренешләргә юнәлтәләр. Әдәбият тарихында юмористик, сатирик рухлы дүртьюллыклар да шактый иҗат ителгән.

Рәдиф Гаташ робагыйлары газета-журналлар аша, «Бу — сиңа кылган догам» (Казан, 1997), «Гөлләр су сорый» (Казан, 1998) һәм кайбер башка җыентыклары аркылы укучыларга яхшы таныш. Шагыйрь яңадан-яңа дүртьюллыклар иҗат итә тора. Аның робагыйлары инде, мөгаен, Гомәр Хәйям дүртьюллыклары санына, ягъни 300 гә якынаеп килә торгандыр.

Рәдиф Гаташ үлчәм һәм рифмада (вәзен вә кафиядә) классик робагый таләпләренә тугрылыклы кала: аның күпчелек парчалары *ааба* рифмалашуында, һәр юлы өчәр буынлы, 11 иҗекле үлчәмдә. Элеккеге дүртьюллыкларда музыкальлелек көчле. Моны тудыруда гаруз куллану ярдәм итә. Рәдиф Гаташ исә, гәрчә урыны белән гаруз казанышларын файдаланса да, силабик шигырьгә, сөйләм интонациясенә өстенлек бирә. Шуңа күрә анда ритмик буын аралыклары (цезуралар) чагыштырмача хәрәкәтчәнрәк, иркенрәк төс ала. Тыныш билгеләре (өндәү, сызык, сорау, өтер...) ярдәмендә автор боларны үзе дә еш сиздереп, искәртеп тора.

Классик робагыйлардан үзгә буларак, Рәдиф Гаташ дүртьюллыкларының күпчелеге исемле. Әйтергә кирәк, автор биредә шактый оста, уңышлы эш итә. Ул биргән исемнәр («Фатиха алдым», «Җан сүзем — ул сиңа», «Нигә шулай көлдең?», «Чал гашыйк бәхете» һ.б.), парчаның төп эчтәлеген, мәгънәсен чагылдырып, шигырьләрнең кабул ителешен җиңеләйтә. Шагыйрь, идея-тематикларына мөнәсәбәттә, язган робагый-ларын цикллап та бирә («Әлвидагъ», «Моңлы бер мөнәҗәт», «Кышкы робагыйлар» һ.б.).

Укучылар Рәдиф Гаташны романтик тоемлы лирик-хисси табигатьле шагыйрь буларак беләләр. Аның әсәрләрендә автор һәм лирик герой шактый якын, хәтта кайвакыт үзара кушылып та китәләр. Шуңа күрә мин шагыйрьнең шәхесен белергә теләүчеләргә аның әсәрләрен җентекләп укырга киңәш итәр идем. Аларда авторның күңел дөньясы, яшәеше шактый тулы чагылган.

Шунысы мөһим: Рәдиф Гаташ үзенең робагыйларында да үзе булып, моңа кадәрге шигъри иманына тугрылыклы булып кала. Ул нәрсәләрдә күренә соң? Шагыйрьнең күпчелек дүртьюллыклары мәхәббәт темасына язылган. Лирик герой һаман да сөя, бу изге хис белән яна, көя. Аның өчен мәхәббәт һәм яшәеш аерылгысыз, игезәкләр кебек. «Ничәнче кат яшәү бу?» (исеме үк символик!) робагыенда шагыйрь болай ди:

Әллә дөньяда бер яшәп киткәнмен?
Һәммәсен бер күргәндәй хис итәмен...
Хәтта сөю — таныш... Мең еллар элек
Синең өчен үлмәдемме, иркәм, мин?!

Лирик каһарманның мәхәббәте пакь, рухи (хәтта өлешчә «платоник» та), самими («Илаһи чын роман — ул безнең сөю», «Нигә сине куркыта ихласлыгым?», «Миңа ник ошый илаһи алдавың?..»). Аны матди байлыклар, тәхет-кәнәфиләр кызыктырмый. Сөю хисе — аның өчен иң зур байлык, яшәү мәгънәсе, «дөньякүләм вакыйга» (юкка гына шагыйрь «Сөю» сүзен кайвакыт баш хәреф белән язмый!).

Робагыйларның лирик герое еш кына, гәрчә үзе шашып сөйсә дә («Чынлап шаштым бугай», «...Картайгач нишләрсең, җан? Әле илледә шулай...»), җавапсыз мәхәббәткә дучар ителә.

Иске гыйбарә: Яратам... Ә ул — юк...
Ятлар өчен бу — әллә яңа, кызык?
Ә минем күңелдә яңа бер упкын —
Фаҗига ул... Һәм җыр бугай шул чынлык!

*(«Иске чынлык, яңа газап»)*

Әмма ул, нинди генә битарафлык, салкынлык булса да, мәгъшукасына рәхмәтле, аңа игелек, иминлек тели: «Барсына рәхмәт, үкенәм шунсына: Гөлгә күмәлмәдем киткән юлыңны». Аның өчен мәхәббәтнең «бер көне» «гасырга тиң». Шагыйрьнең лирик каһарманы Кандалый, Бабич геройлары кебек ихлас, ачык күңелле. Моны хәтта автор үзе дә искәртә: «Рухи бабам,— шиксез, Кандалый хәзрәт, илгә фаш булса да сөю — урынлы!»

Эчемдәге тышымда! Күр: йөземә
Язылган — анда уем да, сүзем дә.
Укы ихлас дөньямны — жаныңа сал,
Гыйбрәт ал һәм... нәрсәдер яз үзең дә!

Робагыйлар шагыйрь күңеленең төрле мизгелләрен, халәте рухиясен чагылдырган кадрлар, рәсемнәр кебек. Аларны билгеле бер системада — үзара мөнәсәбәттә карасаң, автор җанының яшәеш елъязмасын, рухи биографиясен шактый күзалларга була.

Рәдиф Гаташ робагыйларының лирик каһарманы — тынгысыз, каршылыклы зат: ул эзләнә, матурлыкка, гармониягә омтыла, вакыты белән кырыс хакыйкать алдында туктап та кала. Өлкәнәя, чәчләренә чал керә башлаган лирик герой үзенең яшьләрчә мәхәббәт хисләрен тезгенләргә дә омтылып карый, эш-гамәлләренә тәнкыйди караш та ташлый. Әмма күңел буйсынмый, һаман ашкына... Мондый каршылык каһарман күңелен телгәли. Үзенең рухи халәтен, эш-гамәлләрен ул кайчак акларга да тырышып карый.

Әйттеләр: — Кем... Улмы сине яндырды?
Оныгың булырдай бала — ярыңмы?
Дидем: — Килә... Киләчәктә яшисем,
Шуңа бирәм яшь кулларга җанымны!

Романтик рухлы лирик герой хыялый чынбарлыкны реаль чынбарлыктан өстен күрә: «Чынлык — шикле... аннан өстен күрик без / Үзебез тудырган хыял-сурәтне».

Рәдиф Гаташ робагыйлары, әлбәттә, мәхәббәт тематикасы белән генә чикләнми. Аларда классик дүртьюллыкларга хас булган кайбер башка мәсьәләләр дә гәүдәләнеш тапкан. Арада реаль факт-вакыйгаларга мөнәсәбәттә туганнары да бар. Мәгълүм булганча, XX гасырның соңгы көзе безнең арадан ике бөек затны — Нажар Нәҗми белән Әнгам Атнабаевны алып китте. Болар — Рәдиф Гаташның якташлары, остазлары, фикердәшләре, дуслары. Бу ике олуг әдипнең үлеме Рәдиф Гаташка аяз көнне яшен суккан кебек тәэсир итә. Күңеле тетрәнгән шагыйрь бу фаҗига уңае белән берничә робагый яза.

Шагыйрь үлү — йолдыз сүнү, югалу...
Күңелләрдә уелып нуры калу.
...Кабатлана — китеп, «кадере арткач»,
Бер пәйгамбәр иде бит! — дип юану...

* * *

... «Кичә берәү китте бу дөньядан», дип
Язган идең, тормышка гашыйк әдип
(ягъни *Ә.Атнабаев*)...

Үзең киттең бүген... Олуг матәмең
Күтәрә алырмы энең — чал Рәдиф?!

«Әллә дөньяда бер яшәп киткәнмен...» циклындагы робагыйларында автор Хафиз, Тукай, Дәрдемәндкә мөнәсәбәтле уй-кичерешләрен дә гәүдәләндергән. Мәсәлән:

Тукай да сәяхәт иткән... җай булган.
Әстерхан, Уфада озак — ай булган...
Пайтәхетне дә күргән, ... әмма горур
Рух тәхетендә чын таҗлы Тукай булган!

*(«Үзгәрмәгән»)*

Шагыйрьне тормыштагы әхлаксызлык, әдәбияттагы зәвыксызлык күренешләре дә борчый:

Нинди фал бу? Арка бирдек әдәпкә:
Җырда — фәхеш, исерек рухы, гайбәт лә...

(*«Җырда ни генә юк бүген»*)

Рәдиф Гаташ — язма һәм сөйләм тел байлыгын, шигъри казанышларны тирәнтен тоеп, белеп язучы әдип. Бу сыйфат аның робагыйларында да ачык күренә. Газәлдән үзгә буларак, дүртьюллык өчен стиль, поэтик лексика төрлелеге хас. Ул җитди һәм көлкеле дә, тантаналы һәм сагышлы да, раслаучан һәм инкари

да булырга мөмкин. Рәдиф Гаташ шигырьнең мәгънәсенә, аһәңенә туры килешле сүз-сурәтләрне уңышлы сайлый, аларның яңгырашына, тәэсир көченә җитди игътибар итә. Шагыйрь татар укучысы өчен эстетик код, символик ым, сигнал рәвешендәге образларны (Сим-сим, Ләйлә-Мәҗнүн; Сөләйманны җиңгән Бәлкыйс, Җәбраил, Нәүрүз, Әбүҗаһил...) робагый тукымасына кертеп җибәрә. Мондый сүзләр, ассоциатив юл белән, укучының хәтер дөньясын, зиһенен кузгатуга ярдәм итәләр. Автор, Нури Арслан традицияләрен дәвам итеп, үз робагыйларында эчтәлеккә һәм жанрга ятышлы борынгырак сүзләрне дә куллана (гөлхан, бостан, болак, әлвидаг, нида...). Шигырьләрдә гаҗәеп отышлы оригиналь чагыштырулар, гыйбарә вә сурәтләр дә еш очрап тора: «Тыпырчына тере җаным учыңда», «Көз чишендергән табигатьтәй халәт», «Газәленнән аерылган мин — рәдифме?», «Чулпан сүрәсе», «Йолдызшаһ», «Гашыйк диванаңнан сиңа — бу диван», «...Кемне уйладың анда — Җыр тарафында? Сине түгел! — дип, җил хәбәр китергәч, Һушсыз булып яттым гөл арасында» һ.б. Автор, гомумән, сүз-сурәтне, тел байлыгын әдәп, зәвык белән куллана, укучыга ярыйм дип шигъриятне очсызландырмый. Бу — эстетик яктан, тәрбияви җәһәттән бик мөһим момент.

Рәдиф Гаташ робагыйлары — XX гасыр ахырында иҗат иткән шагыйрьнең үз-үзе, дөнья, җәмәгать, тарих, киләчәк белән сохбәт-әңгәмәләре, җан хәятенең сәхифәләре, яңа гасырда, яңа меңьеллыкта яшәячәк инсаннарга сөюнең, ирләр мәхәббәтенең олылыгын, изгелеген бөек татар телендә бәян кылган васыятьнамәсе, мөрәҗәгать-догасы.

Учларыма кысам сине, газиз баш,
Нишлим, жәллим, башсыз, акылсыз булгач...
Мең дә беренче кат исмең кабатлап,
Елый Гаташ, тик бер көнгә аерылгач.

(*«Гашыйк бу баш»*)

Бу — сиңа күңел телендә эндәшем:
Гашыйк җаннар аңлар шивәм-сөйләшем —
Холкыма хас сәердер күп сүзләрем —
Тик әнкәм телендә — моңлы күз яшем!..

Рәдиф Гаташның шушындый бер робагые бар:

Үз бәямне көтәм әле җирдә мин:
Инде матур сүзләр тезә беләмен —
Сөю сүзе... Кемгә кирәк ул бүген?
...Һаман яхшы санда түгел илдә мин!

(*«Һаман яхшы саналмыйм»*)

Кешенең, аеруча иҗат иясенең, үз-үзенә ышанычы, башкарган эш-гамәлләренең кыйммәтен белүе зарур. Бу — һич тә тәкәбберлек, мактану, масаю түгел, ә тыйнаклык белән табигый керешкән инсани горурлык. Робагый авторы да Ходай Тәгалә тарафыннан үзенә бирелгән талантның, шатлык-газаплар белән сугарылган, бәгырь каны тамып язылган шигырьләренең әһәмиятен яхшы белә. Шагыйрьнең бу юллары белән һичшиксез килешәбез. Әмма соңгы ике юл бәхәс уята. «Сөю сүзе», мәхәббәт җырлары, бәлкем, аерым очракларда очсызлана, кирәкмәскә әйләнә торгандыр. Әмма гомумән мәхәббәт, аның моңы яшәешнең үзе кебек үк үлемсез. XIV йөзнең бөек шагыйре Котб юкка гына «...Гашыйкъ берлә терек ошбу галәм, Әгәр гыйшкъ булмаса, булмас ирде адәм»,— дип әйтмәгәндер. Ә инде, Рәдиф дус, «яхшы санда түгел илдә мин» диюең белән син ялгышасың. Рәсми бүләкләргә, затлы кәнәфиләргә, күп мал-мөлкәткә ия булмасаң да, син — бәхетле, бай шагыйрь. Чөнки синең олуг Сөю турында таш бәгырьләрне дә кузгатырлык, «туң заманны да эретерлек» шигырьләрең бар!

*1999*

## МӘХӘББӘТ ҺӘМ НӘФРӘТ ШАГЫЙРЕ

Кеше,— ул кем генә булмасын, үзе бер дөнья, үзе бер тарих. Шагыйрь, тәрҗемәче, журналист, мөгаллим, җәмәгать эшлеклесе, милләтпәрвәр Әдхәд Синугыл да (Синегулов та) моннан чыгарма түгел. Аның үзенә генә хас, әмма халык язмышы, заман агышы белән тыгыз бәйләнешле шәхси дөньясы, гыйбрәтле гомер юлы бар. Әдхәд (ул 1935 елның 15 мартында туган) — Урал татары; Эстәрлебаш районы Куганакбаш авылы — аның кече Ватаны.

Тугангамы Урал туфрагында,
Урал тауларына гашыйкмын.
Тормасам да Урал якларында,
Уралымны сагынам шашып мин...

Шагыйрьнең «Куганакбаш» исемле парчасы мондый юллар белән төгәлләнә:

...Йомахуҗа дигән урманнар да,
Куганаккай дигән сулар да —
Гомер буе юлдаш булды миңа
«Тормыш» дигән борма юлларда.

Эстәрлетамак яклары дип йөртелгән бу төбәк үзенең матур табигате, урман-сулары, кыялы таулары белән мәшһүр. Ш.Зәки, Акмулла, Дәрдемәнд, М.Гафури, Г.Ибраһимов, Н.Исәнбәт, М.Әмир һәм башка талантлар тикмәгә генә бу яктан күпләп чыкмагандыр!

Көньяк Урал табигате никадәр генә матур булса да, Әдхәднең гомер юлы бик авыр китә: ятимлек (яше дә тулганчы әнисез кала), балалар йорты, кагылу-сугылу... Бу чордагы тормышы, рухи халәте аның шигырьләрендә дә гәүдәләнеш тапкан:

Сугыш елларында без ни күрдек? —
Кайгыларны чәчеп, җиргә күмдек.
Өс-баш иде күрер күзгә арык,
Өчпочмаклы кара хәбәр алдык.
Сугыш елларында без ни күрдек?
Кара таңнан башак җыеп йөрдек.
Китап битен кәгазь итеп гелән,
Фронтка хат яздык корым белән...

(*«Ул елларда»*)

Яшьлекне урлаттык без яшьли
Сугышлар кан койган кырларда.

(*«Яшьлекне сорама»*)

Әдхәд Синугыл юкка гына бер шигырен «Ятим яшьлек» дип атамагандыр! Әмма шагыйрь өчен үткәннәр, алар ничек кенә кыен булмасын, үз һәм якын:

Кайларда син, ятим Яшьлек, мине
Ташлап киттең ятим калдырып?
Оча-куна миңа кайт кунакка,
Кучмә кошлар белән Яз булып.

...Ятим Яшьлек калган еракларда,
Яшьлекне тик сагынып сөйләрлек.
Җир тудыра, җир тартып та ала,
Тарту көчен юк көч җиңәрлек.

Әдхәд кечкенәдән үк китап укырга, язарга-сызарга ярата. Шушы шөгыленә ул гомере буе тугрылыклы кала. Туган телгә, милли сүз сәнгатенә мәхәббәт хәрби хезмәттә булган, Башкортстандагы «Сәнәк» редакциясендә һәм кайбер башка урыннарда эшләгән 24 яшьлек егетне 1959 елда Казан университетының татар филологиясе бүлегенә алып килә. Әдхәднең шәхес һәм шагыйрь буларак үсешендә бу уку йорты, әлбәттә, зур роль уйный. Ул Х.Госман, И.Нуруллин, Н.Юзиев, З.Мәҗитов, Җ.Алмаз, Л.Савельева, Л.Юдкевич кебек күренекле әдәбиятчылардан белем алды. Шагыйрә Клара Булатова, романтик әдип Рәдиф Гаташ, филология фәннәре докторы Малик Хәйруллин, җырчы һәм атказанган укытучы Кәбир Нигъмәтҗанов, журналист Нургали Булатов, шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Зөфәр Шәйхетдинов, СССР

Югары Советы депутаты, атказанган мөгаллимә Розалия Миңнуллина (Дәүләтбаева), театр белгече Әнүр Исмәгыйлев, гарәп теле укытучысы Лена Яруллина (Таҗиева), заманында матур-матур шигырьләр язган Даут Сөнгатов, әдәбият, фән, мәгариф һәм мәдәният өлкәсендәге кайбер башка билгеле затлар — болар бар да, шул исәптән без фәкыйрегез дә, Әдхәд Синугылның группадашлары, студент елларындагы шәриктәшләре.

Әдхәд әфәнде Барда (Пермь өлкәсе), Сарман районнарында мөгаллим, туган ягында мәктәп директоры булып эшләде. Аннан дистә елга якын Татарстан китап нәшриятында редактор, Татар дәүләт филармониясендә әдәби бүлек мөдире вазифаларын башкара. Бу чорда ул татар дөньясының мәркәзе Казанда кайный, әдәбият, сәнгать, фән әһелләре белән аралашып яши.

Әдхәд Синугыл гомеренең 20 елы (1976—1996 еллар) Ташкент белән бәйле. Биредә аның «Йолдыз» журналында, кино сәнгате өлкәсендә һәм кайбер башка оешмаларда эшләве мәгълүм. 1983—1985 елларда Әдхәд әфәнде — Мәскәүдәге Югары әдәби курслар тыңлаучысы. Бераз вакыт бу зат «Шәһри Казан»да да эшләп китте. 80—90 нчы елларда ул — «Ватаным Татарстан» газетасының, «Татаринформ»ның һәм «Азатлык» радиосының Урта Азиядәге үз хәбәрчесе. Аның иҗтимагый-сәяси, милли, мәдәни, тарихи темага язылган мәкаләләре, үткен публицистик чыгышлары татар дөньясы кешеләренә яхшы таныш.

Әдхәд Синугылның Ташкентка күчеп китүе һәм анда яшәве шактый дәрәҗәдә гаилә хәле белән бәйле. Аның хатыны Ләйлә ханым — Кырым татарларының күренекле әдибе Шамил Аляддин кызы. Ул, әти-әниләре, башка милләттәшләре белән 1944 елда депортацияләнеп, Кырымнан Урта Азиягә сөрелгән була. 90 нчы елларның урталарында, ярты гасырлык сөргеннән соң, Аляддиннәр гаиләсе Акмәчеткә (Симферопольгә) әйләнеп кайта. Бераздан Әдхәд Синугыл да улы Ширван, хатыны Ләйлә ханым белән Кырым башкаласында яши башлый. Бабасы — Шамил ага — 1997 елда вафат була һәм туган туфрагына күмелә.

Симферопольдә гомер кичерүче Әдхәд әфәнде, нигездә, әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Бераз вакыт Донецкида Ибне Фадлан исемендәге Украина Ислам университетында татар теле һәм әдәбияты да укытып ала. Казанга да килгәләп, туган ягына да кайткалап тора.

Казан янында, хәзер инде ул шәһәр составында, Кадыш авылы бар. Анда ханлык заманында Казан аксөякләре ял иткән. Хәзер бу җирдә дачалар, шәхси йортлар. Казанга килгәч, Әдхәд әфәнде шуларның берсендә — профессор Әзһәр Мөхәммәдиев дачасында яши. Шуңадыр, мөгаен, бу авыл шагыйрьнең әсәрләренә дә килеп керә. 1993 елда иҗат ителгән «Кадыш» шигырендә, мәсәлән, мондый юллар бар:

...Дер селкетеп җирне торган ханнардан
Истәлеккә хәзер эз дә калмаган.

Йөрәк әрни шуңамы сулык-сулык,
Ят кавемнәр беткәннәр сиңа тулып.

Күңел ачкан бу җирдә Ил ханнары.
Бүген нәкъ тә чүп-чар, дуңгыз абзары!

Әдхәд Синугыл, Идел-йорттан китеп, Ташкент, Симферополь калаларында яшәсә дә, туган халкыннан аерылмады, аның мәнфәгатьләре, тәрәккыяте, теле өчен көрәшүен дәвам итте:

Тел тидерсәң — тидер миңа,
Телемә тел тидермә.

* * *

...Мин бәхетле булу — бәхетме бу,
Халкым булса әгәр бәхетсез?

(*«Бәхетлеләр»*)

Татарстанның Үзбәкстандагы рәсми вәкиллеге 90 нчы еллар башында гына ачылды. Әмма Әдхәд әфәнде инде бу эшне, җәмәгатьчелек тәртибендә, күптәннән башкарып килә. Урта Азия татарларының мәнфәгатьләрен яклау, мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча төрле чаралар үткәрү, үзбәк һәм татар бәйләнешләрен тәэмин итү, Казаннан артистлар һәм гыйлем-мәдәният әһелләрен чакыру — болар бар да Әдхәд Синугыл катнашында башкарылган эшләр. Аның Ташкент шәһәрендәге фатиры һәм Дөрмәндәге дача йорты, ничектер, татарның бер милли-мәдәни үзәген хәтерләтә иде. Шушындый игелекле гамәлләрен ул Кырымга күчкәч тә дәвам итә. 2001 елның җәендә Ялтада төрки-татар балаларының киң колачлы

мәдәни бәйрәмнәре үткәрелү күпләргә мәгълүм. Аны оештыручыларның берсе җырчы Гөлзадә ханым Сафиуллина фикеренчә, бу эштә Әдхәд әфәнденең дә рухи ярдәме зур була.

Халыкта «Чит җирдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул» мәкале бар. Татарның бу акыллы фикере Әдхәд Синугыл тормышына да турыдан-туры кагыла, һәм менә шагыйрь, үз язмышы хакында уйланып, болай ди:

...Борынгыдан калган сүз хакында
Кайта-кайта, кат-кат уйландым,
Чит җирләрдә йөреп, мин солтан да
Вә олтан да була алмадым!

(*«Мәкальгә ишарә»*)

* * *

Әдхәд Синугылның шигъри әсәрләре матбугатта инде 40 елдан артык басылып килә. Ул — «Чалгы җыры» (1977), «Җыр төбәген сагынып» (1984), «Көньяк гөлләре» (1990), «Ник җылыйсың, курчагым?» (Балалар өчен, 2000) һәм башка шигъри җыентыклар авторы. Шагыйрьнең Кырым татарлары телендә «Яшьлек һәйкәле» (1979), «Каракаш» (1989) исемле китаплары да дөнья күрде.

Әдхәд әфәнде тәрҗемә өлкәсендә дә озак еллар буе эшләп килә. Ул татарчага күчергән «Давыллы Африка» (1968), «Ачык ишек» (1968.— Лиза Антонова белән берлектә), «Пальмалар шавы» китаплары укучыларга яхшы таныш. Тәрҗемәче буларак Әдхәд Синугыл халыкның рухына, милли-эстетик ихтыяҗларына җавап бирерлек әсәрләрне өстен күрә. Рәсүл Гамзатовның «Туган телем» исемле шигыре, мәсәлән, аның тәрҗемәсендә укучыларга иреште:

...Кем өчендер башка бер тел шифа,
Миңа исә шифа — үз телем.
Туган телем үлә диләр икән,
Җан бирергә әзер мин бүген!..

Кавказ шагыйренең түбәндәге строфасы да укучы күңеленә аваздаш яңгырый:

...Күчереп була, буйсындырып була...
Барысын да күчерә кешеләр.
Күкрәк киереп торган таулар гына
Туган җирдән бер дә күчмиләр...

Фирдәүси, Рудәки, Гаттар, Низами, Сәгъди, Нәваи...— болар, гәрчә татар әдипләре булмасалар да, безнең әби-бабаларыбызның яраткан шагыйрьләре. Әмма Октябрьдән соң безнең халык алардан шактый читләштерелде. Әдхәд Синугыл исә, борынгы әдәби бәйләнешләрны, традицияләрне яңартырга теләп, тәрҗемә өчен күбрәк Шәрык классикларына мөрәҗәгать итә. Менә аның «шагыйрьләр падишаһы» Рудәкидән (X йөз) бер тәрҗемәсе:

...Дөньяга килгәннәр, киткәннәр,
Мәңгелек үзен хис иткәннәр.
Киткәндә бу фани дөньядан
Бер кәфен тик алып киткәннәр!

Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» («Бәхет китабы») поэмасы (1069) — төрки халыкларның бөек ядкяре. Ул төрек, үзбәк, рус, алман (немец) һәм кайбер башка телләргә тәрҗемә ителгән. «Котадгу белек»нең татар әдәбияты үсешенә тәэсире искиткеч зур. Шуңа күрә ул урта мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында да өйрәнелә. Әмма хәзерге укучыларга аңлаешлы тексты булмау мөгаллимнәрнең эшен кыенлаштыра. Әдхәд Синугыл соңгы елларда шушы бөек әсәрне татарчага тәрҗемә итү белән дә мәшгуль. Ул поэманың эчтәлегенә, рухына шактый үтеп кергән. Аның татарча юллары уңышлы гына яңгырый:

...Кечедә әдәп юк, өлкәндә берлек,
Күбәйде хәсислек, югалды ирлек...

...Дөреслек тәхетен яулады ялган,
Калдымы бер тугры бәндәң, и Аллам!

...Гөнаһлы бәндәңнәр пул (акча.— *Х.М.*) колы булды,
Кем алтын-көмешле,— шуңа баш орды.

«Котадгу белек»нең «Казан утлары» журналында (2001.— № 6.— 180—184 б.) басылган үрнәкләре укучылар тарафыннан теләп кабул ителде. Әгәр дә Әдхәд Синугыл бу бөек ядкярне (ул 13 мең шигырь юлыннан артык) хәзерге татар теленә чагыштырмача тулы рәвештә тәрҗемә итеп, бастырып чыгарса, бик тә бөек вә изге гамәл кылган булыр иде.

Полякларның бөек шагыйре Адам Мицкевич (1798—1855) исеме дөнья укучыларына күптәннән билгеле. Әдхәд Синугыл аның да «Кырым сонетлары»н, тәрҗемә итеп, бай эчтәлекле кереш мәкалә белән «Казан утлары»нда бастырып чыгарды (2000.— № 7.— 110—130 б.). Менә «Аю-Даг» сонетыннан берничә юл:

Аю-Дагтан яратам, багып ярларга,
Кара дулкыннар биюен мин карарга,
Кар-бураннар алар туздырган арада,
Салават күперләре уйный аларда...

...Шагыйрь йөрәгендә дә дулкыннар куба,
Анда да баш бирмәгән гыйсъяннар туа,
Илһам килсә, беразга йөрәге тына.

Кайбер җырлар дучар мәңге онтылуга;
Ә кем үлемсез җыр тудырып үлә,
Шул җырыннан гасырлар аңа таҗ үрә.

1968 елда Татарстан китап нәшрияты Бөек Ватан сугышында һәлак булган яшь шагыйрьләрнең әсәрләрен туплаган «Туплар һәм музалар» исемле китап чыгарган иде. Ул басманың да авторы — Әдхәд Синугыл.

Җәмгыятьтәге үзгәрешләргә нисбәтән, соңгы 10—15 елда Әдхәд әфәнде үзенең иҗади активлыгын тагын да арттырды. Аның шигырьләре, публицистикасы, тәнкыйди мәкаләләре матбугат битләрендә еш күренеп тора. Әдхәд Синугыл, оригиналь әсәрләр иҗат итү белән бергә, тәрҗемәчелек шөгылен дә ташламый. Ишетүемчә, ул Ибне Синаның (Әбүгалисинаның) тыйбб (медицина) рисаләләрен дә шигъри тәрҗемә иткән.

Шагыйрьнең әдәби иҗаты хакында Н.Арслан, Н.Нәҗми, Г.Афзал, Н.Юзиев, Г.Рәхим һәм кайбер башка каләм әһелләренең мөһим генә уңай фикерләре бар. «Әдхәд Синугыл шигырьләрендә,— ди Г.Афзал,— оптимистик рухлы, борчулы заман сулышы бар. Ул беркемне дә кабатламыйча, үз аһәңен, үз образларын, үзенчә сөйләү-тасвирлау манерасын алып килүе белән игътибарны җәлеп итте. Безнең шигърияткә үзенчә моңлы-сагышлы да, сатирик телле-тешле дә җитди шагыйрь килде». Нури ага Арслан аның тәрҗемә эшчәнлегенә югары бәя бирә, шагыйрьнең Шәрык классикасын татар укучыларына җиткерүен хуплый.

Әмма бездә әле тәнкыйть аерым исемнәр тирәсендә генә сүз йөртүдән һаман да арына алмый. Әдәби процессны мөмкин кадәр тулырак, җентеклерәк карау җитми. Мөгаен, шуңадыр да Әдхәд Синугыл иҗаты, ничектер, гыйльми-тәнкыйди тикшеренүләрдән читтәрәк кала килә. Ә бит ул моңа лаек.

* * *

Әдхәд Синугыл — бөтен барлыгы, яшәеше, тереклек күзәнәкләре белән милли шагыйрь. Ул нәрсә генә хакында язмасын, турыдан-туры да, читләтеп тә, барыбер, татар язмышы хакында уйлана; милләтенең үткәне, бүгенгесе, киләчәге шагыйрьнең күңел түрендә. Шигырьләренең исеме үзләре генә дә күп нәрсә хакында сөйли: «Алтын Дала дастаны», «Нугай Урдасы», «Татар морзалары», «Казан сынаулары», «Ярлы Тукай... Зарлы Тукай», «Татар-башкорт арасы», «Милләтем», «Татарстан, татарларың кайта!», «Без бар!». Боларда без татарның данлы һәм фаҗигале тарихын да, өмет-хыялларын да күрәбез. Шагыйрь үз халкының үткән юлын, бүгенге хәлен яхшы аңлый: «Миндә ага «Бөек Дала» кайнар каны, Атилладан калган яши һуннар каны»; «Кайда хәтәр — шунда татар алдан барган, «Татар бар җирдә хәтәр бар» шуннан калган»; «Биш гасыр богаулы татарның аңы»; «Мәскәүсез без яши алырбыз,— Безсез Мәскәү яшәп карасын!..» Без, ди автор, «Җир йөзендә иң кайгылы халык. Гадел гомер җирдә сөрсәк тә».

Әдхәд Синугылның 1979 елның иҗат иткән «Очырган кош» шигыре бар:

Үзбәк күлмәкләрен кисәң,
Өзелеп тора билләрең.
Алтын теш аралаш көлсәң,
Уйчан кала йөзләрең.

Йөзләреңнең уйчанлыгы

Нидәнлеген белмәдем...
Белмәсәм дә, күреп торам,
Ерак туган җирләрең.

Атаң-анаң үскән якта
Калган бишек көйләрең,
Үстереп очырган кошка
Мин бит сине тиңләдем.

Бу юлларда Урта Азиягә барып эләккән татар хатын-кызларының матди яктан мул, әмма рухи яктан сагышлы язмышы гәүдәләнгән.

Әдхәд Синугыл — туры фикерле, яхшы мәгънәсендә «үзсүзле» шагыйрь. Ул курыкмыйча, күңеле кушканча яза. Бу хакта автор «Язмам!» шигырендә үзе дә искәртә:

Мин кемдер кушканча язмыйм,
Җаным кушканча язам,
Җан теләгәнне язганга,
Каралтып акны язмам,
Язмам!

Әдхәд Синугыл иҗатында без төрле төр һәм жанр үрнәкләре белән очрашабыз. Әмма ул, барыннан да элек, лирик. Аның шигырьләрендә хис-кичерешләр еш кына фикри якка буйсынулы. Шагыйрь җыр шәкелен дә чит итми. Бигрәк тә аның «Татарстан гимны» мәгълүм. Әдхәд Синугылның аерым шигырьләренә публицистик яңгыраш, тәнкыйди рух хас. Инсаният, әхлак кысаларыннан чыккан ямьсез күренешләрне ул сатира уты астына да ала. Аның балалар өчен язылган әсәрләре дә шактый.

Соңгы елларда безнең поэзиядә традицион жанрлар, формалар белән кызыксыну көчәеп китте. Рәдиф Гаташның, мәсәлән, матур-матур газәлләре, робагыйлары бар. Әдхәд Синугылның да бу юнәлештә эзләнүләре һәм, гомумән, эшчәнлеге кызыклы. Ул, мәсәлән, Хәсән Туфан, Әбрар Кәримуллин, Олжас Сөләйманов, Равил Фәхретдинов, Гәрәй Рәхим һәм кайбер башка күренекле затларга багышламалар язды. Иҗатында робагыйлар, мөсәддәсләр дә (алтыюллыклар.— *Х.М.*) бар. Мәгълүм ки, Урта гасырларда дүртьюллык, ягъни робагый жанрының омонимиягә (тәҗнискә) нигезләнгән тоюк (туюг) төре дә бик актив була. Әдхәд әфәнде бу жанрда да көчен сынап карый:

Чү, елама, балам, җиткән!
Үзең үскән, буйга җиткән.
Әткәң бүләккә дип сиңа
Калага ук барып җиткән.

Күрәсез: биредә төрле мәгънә төсмерләрен белдергән «җиткән» сүзенең кафияләшүе шигырьне оештыруда мөһим роль уйный.

Фәрд — төрки-татар һәм гомумән Шәрык классик поэзиясендә иң кечкенә жанр. Анда чагыштырмача бербөтен фикер мөстәкыйль икеюллык шигырьдә гәүдәләнеш таба. Фәрдләр өчен, кагыйдә буларак, фикри тирәнлек, афористик яңгыраш хас. Рифмалашуы, нигездә, *аа*... рәвешендә. Кайчак *аб*... шәкелендә дә кафияләшә. Бездә фәрд үрнәкләре күптәннән күзгә ташлана (С.Сараи, Акмулла, Дәрдемәнд, Тукай һ.б.). Әдхәд Синугыл соңгы дистә елда фәрд жанрын аеруча үз итте. Аның бу шәкелдә язган шигырьләре идея-тематик яктан гаять төрле. Аларда иҗтимагый, сәяси, тарихи, әхлакый, фәлсәфи һәм башка бик күп төрле мәсьәләләр гәүдәләнеш тапкан. Арада бик билгеле хакыйкатьне кабатлаганнары да очрый. Гомумән, Әдхәд Синугыл фәрдләре (аларның саны берничә йөз) тәрбияви яктан файдалы. Аларда фольклордан, классик поэзиядән килә торган тапкыр сүз, гыйбрәтле фикер әйтү традициясе дәвам иттерелә.

Әдхәд Синугыл университетта уку елларында ук иң зәвык белән киенеп, чәч-мыекларын бик «модно» йөртә торган студент иде. (Мәдәнилекнең Ленинград «школа»сын узган профессор Әнвәр ага Ахунҗанов юкка гына аны башкаларга үрнәк итеп куймагандыр.) Алга таба да Әдхәд Мәкәрим углы зәвыклылыкка тугры булып калды. Әмма инде аның яшь чакларда хатын-кызларның һушын китәргән корым-кара чәчләре, күмердәй сакал-мыеклары шактый бәсләнгән, йөзе дә җыерчыклана төшкән.

Үтте яшьлек, саф-саф атлап үтте,
Чәчебезгә карлар яудырып.
Яшь урманнар җырын җырлап үтте,
Карап калдык күзне талдырып!

(*«Үтте яшьлек»*)

Шулай да шагыйрьнең йөрәге әле һаман кайнар, күңеле һаман дәртле. Яше өлкәнәйсә дә, үзе чит-ят җирләрдә яшәсә дә, аның җаны халкы белән, аның күңелендә һаман татар моңы, татар гаме.

Үз илем бар минем якын күргән,
Татар дигән туган халкым бар.
Йөрәгемдә аңа гына булган
Мәңге сүнү белмәс ялкын бар,
Тукайларны биргән халкым бар.

(*«Халкым бар»*)

* * *

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әдхәд Синугылның «Иман гасыры» дип исемләнгән җыентыгына (Казан, 2002) шагыйрьнең төрле еллардагы оригиналь әсәрләре, тәрҗемәләре кертелгән. Әмма аларның күпчелеге соңгы

10—15 елга карый. Җыентык, гомумән, авторның иҗат йөзен, сәнгати фикерләвен чагыштырмача тулы күзалларга мөмкинлек бирә. Анда милли тематика инсани, әхлакый мәсьәләләр белән табигый үрелеп бара. Лирик герой туган теле, туган халкы, туган җире өчен яна-көя. Шуның белән бергә, ул башка кавемнәрнең язмышына да битараф түгел. Гаделсезлек, коллык, икейөзлелек — аның җан дошманнары.

Әдхәд Синугылны, шигырьләренең рухына, эчтәлегенә карап, мәхәббәт һәм нәфрәт шагыйре дип тә атарга мөмкин.

*2002*

## РУХИ АСЫЛЫНА КАЙТУ

Илһам Ибраһим улы Ганиев... Уртача буйлы, төз һәм юкарак гәүдәле, ачык йөзле, бөтен тотышыннан зыялылык, тыйнаклык бөркелеп торган бу зат күп кенә казанлыларга, аеруча соңгы 30—40 елда университетта укучыларга һәм эшләүчеләргә яхшы таныш. Ул — педагог, галим, журналист, партия хезмәкәре, администратор, әдип, запастагы офицер, музыкант... һәм иң мөһиме — бик әйбәт кеше. Мөгаен, шуңа күрәдер дә аның үлеме (17.02.2002) безнең һәммәбезне тетрәндерде. Мәрхүмне соңгы юлга озатырга күпләгән казанлыларның җыелуы, Илһам Ибраһим улының инсанилыгын, игелекле эш-гамәлләрен искә төшерүләре — бар да табигый, бар да мантыйкый рәвештә кабул ителде. Казан шәһәренең һәм Татарстанның элекке башлыкларыннан берсе — Рево Идиятуллин мәрхүмне үзенең остазы, киңәшчесе дип атады... Университет җитәкчелеге аның гыйльми-педагогик һәм проректорлык эшчәнлеген югары бәяләде. Мәрхүмнең васыятен исәпкә алып, туган-тумачалары, якыннары аны чын мөселманча Яңа Бистә зиратында җирләделәр.

* * *

Мин университетта, 1959—1964 елларда укып, 1967 елдан бирле эшлим. Шушы вакыт эчендә без Илһам әфәнде белән, сирәк кенә булса да, очрашкалап тордык. Ул университетның кичке һәм читтән торып уку бүлеге проректоры булган выкытта (1976—1990) миңа биш елдан артык филология факультетының (ул чакта әле журналистлар, рус һәм татар филологлары бер факультет составында иде) декан урынбасары вазифаларын башкарырга туры килде. Шул елларда эш буенча безнең очрашулар еш булды. Әмма ул чакта да һәм гомумән дә мин Илһам Ибраһим улының университетка кадәрге шәхси тормыш юлын бөтенләй диярлек белмәгәнмен икән. Баксаң, аның тәрҗемәи хәле шактый катлаулы, сикәлтәле, хәтта драматик икән.

И.Ганиев 1931 елның 23 сентябрендә Ульяновск өлкәсе Кече Кандал (Иске Майна) районы Тат. Урайкино авылында дөньяга килә. Әмма өч атна да үтми, әнисе — Җамалия Сөләйман кызы вафат була. Бераздан кулак, рухани дип әтисен — тирә-юньнең бик тә абруйлы кешесен — Себергә сөрәләр. Анда берничә ел яшәгәч, Ибраһим Ганиевне 1937 елда, сәяси ышанычсызлыкта гаепләп, 10 елга төрмәгә утырталар. Ярым ятим калган кечкенә Илһам туган-тумачаларында, үги ана янында яши. 1941 елдан 17 яшенә кадәр балалар йортында тәрбияләнә. Бу елларда аның Иркутск шәһәрендә балалар өчен хәрби музыка мәктәбендә, Куйбышевтагы Суворов училищесының музыка бүлегендә, Алма-Атадагы кавалерия полкының музыка взводында укуы, эшләве мәгълүм. Аны еш кына «полк улы» дип тә йөртәләр. Шунысын да әйтик: Илһам әфәндfestenең җыр-музыканы, сәнгатьне тирәнтен аңлавы, музыка коралларында оста уйнавы (ул бу елларда аеруча флейтачы буларак танылa) аның табигый сәләтеннән һәм яшьли үк профессиональ белем-күнекмәләр алуыннан да килгән икән.

Ятимлек, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм булу, дистә елга сузылган детдом тормышы Илһамның күңелендә тирән эз калдыра. Еллар узгач, ул, бу чордагы яшәешен искә төшереп, юкка гына болай дип язмагандыр: «Невзгод и передряг, которые выпали на мою долю, хватило бы на десятерых. И злая сиротская судьба, награждая меня то и дело чувствительными пинками и подзатыльниками, как бы шептала на ушко: «Не рыпайся, дружок, не рыпайся...».

И.Ганиев 1948—1950 елларда Куйбышев шәһәрендә автослесарь булып эшли. Шушы вакытта аның әтисе дә, тоткынлык срогын тутырып, бу калада яши башлый, рухани вазифаларын башкара. (Нурсөя ханым Ганиева фикеренчә, ул 1968 елда вафат була.)

Илһам 1950—1952 елларда — Баку индустриаль техникумы студенты. Аннан ике ел буена — Вольск шәһәрендәге хәрби авиация-техник училищесы курсанты. 1954—1956 елларда ул Баку хәрби округының Небит-Даг каласындагы истребитель полкында авиация технигы (борттехник) булып эшли. Хәрби хезмәт вакытында авариягә эләгә; умыртка сөяген имгәтеп, берничә ай буенча Баку госпиталендә урын өстендә ята. Аннан соң да дәваланулар, хастаханә юлларын таптау дәвам итә. Шулай итеп, кичәге тап-таза кеше, авиация офицеры, сәламәтлеген югалту аркасында, пенсионерга әверелә. Әмма Илһам Ганиев җебеп төшми, тормышта үз урынын табарга, халыкка, җәмгыятькә файдалы кеше булырга омтыла. Елга якын ул Куйбышев индустриаль институтында лаборант булып эшли. Яшьтән үк әдәбиятны, сәнгатьне үз күргән, каләм куәсенә дә ия булган, бераз язгалап та килгән Илһам 1957 елда Казан университетының рус филологиясе бүлегенә укырга керә. Соңгы курста вакытта «Советская Татария» газетасының әдәби хезмәткәре булып та эшли. 1962—1963 елларда — «Волжская новь» газетасының бүлек мөдире. Аннан ике ел буена Татарстан спорт оешмалары һәм җәмгыятьләре советының рәис урынбасары вазифасын башкара. Берничә ай Татарстан китап нәшриятында өлкән редактор булып та эшләп ала. 1965 елның октябрь аеннан

башлап Илһам Ибраһим улы — партия эшендә: КПССның Казан шәһәр комитетында пропаганда һәм агитация бүлеге инструкторы, бүлек мөдире. 1972—1974 елларда университетның философия кафедрасы каршындагы аспирантурада читтән торып укый. 1974 елның 25 гыйнварында ул Казан университетының диссертация советында «Развитие личности рабочего в процессе производственного потребления при социализме» темасына диссертация яклап (гыйльми җитәкчесе — доцент Б.К.Лебедев), 14 июньдә философия фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алуга ирешә. Шушы елда ук И.Ганиев, төп эшеннән аерылмыйча, университетта философиядән дәресләр дә алып бара башлый. 1976 елның мартында ул шәһәр партия комитетыннан тәмам университетка күчә: философия кафедрасында өлкән укытучы, доцент булып эшли; 14 ел буена проректор вазифаларын башкара. 1990 елның гыйнварында үз теләге белән проректорлыктан китә һәм үзен тулысы белән уку-укыту, гыйльми, иҗади эшкә багышлый һәм үлеменә кадәр диярлек доцент булып эшләвен дәвам итә. Намуслы, нәтиҗәле эшчәнлеге өчен, Илһам Ибраһим улы төрле бүләкләргә лаек була. 70 яшь тулу уңае белән университетның гыйльми советы аны «Россия Федерациясе югары һәм махсус белем бирүнең мактаулы хезмәткәре» исеменә тәкъдим иткән иде. Кызганыч ки, бу мәсьәләнең уңай хәл ителүен мәрхүм үзе генә ишетә алмады.

Илһам әфәндене тормыш гаилә ягыннан да сыный. Аның Гүзәл һәм Гөлнара исемле ике кызы бар. Әмма хатыны — Наҗия ханым — 80 нче еллар башында вафат була. 1983 елда ул икенче мәртәбә өйләнә. Олы Мәңгәрдә туып үскән, Арча педучилищесын һәм Казан педагогия институтының рус-татар бүлеген тәмамлаган, мәктәптә һәм комсомол-партия органнарында эшләгән Нурсөя Газиз кызы аңа тормышында таяныч, фикердәш була.

* * *

И.Ганиев — берничә дистә мәкалә-хезмәт, китап авторы. Алар гыйльми, публицистик һәм әдәби характерда. Мәгълүм булганча, ул — совет чорында һәм җирлегендә туып, яшәп җитлеккән кеше. Берничә ел партия органнарында да эшли. Шөгыльләнгән фәне дә теге яки бу дәрәҗәдә иҗтимагый фикер, сәясәт белән бәйле. Шуңа күрә аның диссертацион хезмәте, 70—80 нче еллардагы язмалары марксизм-ленинизм тәгълиматы, КПСС документлары белән шактый керешеп китә, методологик яктан аларга таянып башкарыла. Әмма шунысы мөһим: галим инсан, аның мәнфәгатьләре, шәхси үсеше, үз-үзен тотышы мәсьәләләрен һәрчак күз уңында тота. Белемле, әхлаклы, үз сүзе һәм гамәле өчен җаваплы, актив зат — авторның идеалы. Мәсәлән, «Образ жизни рабочего» исемле монографиясендә (Казань: Тат. кн. изд-во, 1977) ул инсани яшәү рәвешенең социаль нигезләрен, шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрен шактый җентекле яктырта.

Мал-мөлкәт, байлык, аларның кеше тормышындагы роле...— бу мәсьәлә һәрчак фикер ияләрен, әдипләрне борчып килгән һәм килә. И.Ганиевне дә, күрәсең, бу проблема ныклап уйландырган. Аның «Не сотвори себе кумира (О месте вещей в духовном мире человека)» монографиясе (Казань: Тат. кн. изд-во, 1983) — шуның ачык мисалы. Бу китаптагы уй-фикерләр, күзәтүләр бүгенге укучы өчен дә файдалы.

И.Ганиев, нинди темага гына мөрәҗәгать итсә дә, үтемле шәкелдә яза. Менә аның «Крутые ступеньки жизни» китабы (Казань: Тат. кн. изд-во, 1986). Җәяләр эченә «Записки партийного работника» дип куелган. Әмма бу китап әдәби әсәр кебек укыла. Чөнки анда кешеләр язмышы, реаль вакыйга-хәлләр гәүдәләнеш тапкан. Анда документальлек тә, теге яки бу дәрәҗәдә үзгәртүләр дә бар. Мәсәлән, автор үз биографиясенең бер өлешен этисе образы аркылы бирә. Китапта Казан университеты профессоры Борис Лукич Лаптев образы, аның сәнгать, тормыш турында уйланулары җанлы гәүдәләндерелгән. Язманың көндәлек дәфтәр рәвешендә бирелүе дә аны укучыга якынайта төшкән.

И.Ганиевнең 1989 елда Татарстан китап нәшриятында басылган «Сыновний долг» исемле китабы бар. Үкенечкә каршы, бу әсәр белән миңа шушы көннәрдә генә танышырга туры килде. Автор аның жанрын үзе «художественно-публицистический очерк» дип билгеләгән. Әмма ул — чын мәгънәсендә күңелләрне тетрәндерерлек хикәят, повесть. Аның нигезендә менә дигән спектакль, кинофильм да эшләргә мөмкин. Бу әсәр И. Ганиевнең әдәби сәләткә, образлы тел-стильгә ия булуын ачык күрсәтеп тора. Әмма, кызганыч ки, катлаулы язмышка, дистәләгән профессиягә, бай тормыш тәҗрибәсенә ия булган бу зат үзенең әдәби мөмкинлекләрен өлешчә генә гамәлгә ашыра алган.

«Сыновний долг» китабының төп герое — Илдус Ибраһимов. Ул детдомда тәрбияләнгән, ятимлекнең бөтен ачысын-төчесен күреп үскән зат. Авиациядә хезмәт иткән чакта, авыр яраланып, госпитальгә эләгә. Әсәрдә подполковник Вальтер Паулович Балтис, элеккеге очучы Габдулла Касыйм улы Тарнихов, сержант Рафаэль Гарипов, җыр-музыкага бөтен күңеле белән бирелгән Алия, тетя Шура һәм башка тормышчан образлар бар. Повестьта Кукмара районының атаклы рәисе Камил Шакиров, татарның билгеле җырчысы

Хәнәви Шәйдуллин һәм башка реаль затлар да телгә алына яисә сюжетта катнашып китә. Илдус Ибраһимов язмышы шактый дәрәҗәдә авторның тәрҗемәи хәлен хәтерләтә.

Әсәрдә бик тә мөһим мәсьәләләр гәүдәләнеш тапкан. Ятимлек, ата-ана тәрбиясеннән, ана назыннан мәхрүм булып үсү — гайре табигый күренеш. Кеше үз кавеме, үз теле, үз моңы, үз гореф-гадәтләре нигезендә тәрбияләнергә тиеш. Шунсыз яшәешнең нормаль агышы бозыла. Ана теле, милли җыр-моң, әдәбият һәм сәнгать — һәркемгә һава, ризык кебек зарур нәрсәләр. Вальтер Паулович — бөтен барлыгы белән латыш. Әмма ул русча да, татарча да яхшы белә. Чөнки бу зат, сугыш вакытында эвакуацияләнеп, Олы Мәңгәр авылында дүрт еллап яши. Ул татар теленә, татар моңына чын күңелдән гашыйк. Вальтер Паулович, Алия, Рафаэль кебек кешеләр тәэсире астында татарчасын тәмам онытып, руслашып беткән Илдус Ибраһимов күңелендә милли тойгылар уяна. Автор фикеренчә, һәр кеше ата-анасы, туган җире, Ватаны, үз халкының теле, мәдәнияте алдында бурычлы. (Это — «сыновний долг каждого. Долг, которым ни при каких обстоятельствах жизни и поворотах судьбы нельзя пренебрегать... Исчезновение языка равносильно исчезновению народа. Дерево сохнет, если оборван его корень. Потеря же связей с духовными корнями своего народа ведет к бездуховности, ущербности, жалкому жребию — быть человеком без роду, без племени».)

* * *

«Инсани бурыч» («Сыновний долг») — 80 нче елларда, үзгәртеп кору, милли уяну чорында туган әсәр. Үзе дә туган телен, гореф-гадәтләрен, татарлыгын оныта язып, янә үз җирлегенә, милли асылына кайткан Илһам Ибраһим улы милләт язмышын аеруча якын кичерә. Халыкның уянуы, үзенең барлыгы, үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән кызыксына башлавы Илһам исемле бу зыялы затны тәмам илһамландыра, җилкендерә. Иҗтимагый-мәдәни вазгыять, нәсел-нәсәптән килгән татарлык рухы, дини кайтаваз, гаять милли җанлы хәләл җефете Нурсөя ханымның шифалы тәэсире урта яшьләрдәге бу философны әйтерсең яшәртеп, канатландырып җибәрә: ул үзенең һәм хатынының туган ягына ешрак кайта башлый, милләттәшләре, күренекле татар галимнәре, рәссамнары, әдипләре белән очраша; милли тарих, әдәбият, сәнгать, ислам фәлсәфәсе белән ныклап кызыксына, гарәп телен өйрәнүгә керешә, даими рәвештә татарча китаплар укый. Студентлар өчен «Ислам һәм гарәп фәлсәфәсе», «Шәрык һәм Гареб мәдәниятләренең диалогы» дигән махсус курслар әзерли. Аспирантларга татар, Шәрык белән бәйләнешле рефератлар яздырта.

Шунысы мөһим: Илһам әфәнде, профессор Мансур Абдрахмановтан соң, беренчеләрдән булып, университетта фәлсәфә дәресләрен татарча уздыра башлый. Гомере буе русча лекция укып өйрәнгән кеше өчен бу адымны ясау — зур фидакарьлек. Татар филология факультеты студентлары аның лекцияләрен яратып тыңлыйлар. Моннан бер-ике ел элек профессор Резедә Ганиева деканат кушуы буенча Илһам әфәнденең дәресләрендә булган иде. Лекторның тирән эчтәлекле, эмоциональ сөйләмен ул хәзер дә ихтирам белән искә төшерә.

Фәлсәфәне, махсус курсларны татарча укыту барышында И.Ганиев, күп кенә гыйльми төшенчәләрнең телебездә тиешенчә эшкәртелмәвен, атама-терминнарның төрлелеген, гомумән, уку-укыту әсбапларының бик аз булуын күреп, бу юнәлештә гамәли адымнар ясауга керешә. Шуның бер нәтиҗәсе буларак, 2001 елда аның «Фәлсәфи сүзлек» китабы дөнья күрде. Университет студентлары тарафыннан бу әсбап уңай кабул ителде. Җәмәгатьчелектә дә ул кызыксыну тудырды. Әмма бу әсбапның тиражы бик аз иде. Бу — бер. Икенчедән, анда аерым бәхәсле моментлар, авыр аңлаешлы җөмләләр дә шактый иде. (Бу аңлашыла да. Чөнки моңа кадәр русча язуга күнеккән кешегә татар телендә язу шактый авыр.) Нәкъ менә шуңа күрә дә И.Ганиев соңгы вакытта, каты авыруына да карамастан, фәлсәфи сүзлекнең тулыландырылган, камилләштерелгән варианты өстендә туктамый эшләде һәм, ахыр чиктә күләмле кульязманы безгә тоттырып, үзе хастаханәгә юл алды. Хезмәт белән ныклап танышып, тиешле урыннарын төзәтеп, редакцияләп чыккач, 2001 елның декабрь азакларында кульязманы университетка алып бардым. Бергәләп ачыклыйсы, киңәшәсе урыннары да бар иде. Әмма, ни үкенеч, Илһам әфәнде университетка бүтән килә алмады, телефоннан гына сөйләшергә туры килде.

Үләренә атна-ун көн калгач, Илһам әфәнде телефоннан болай диде: «Хәлем начар, көннәрем санаулы... Фәлсәфә дәреслеген яза алмадым инде... Әмма бу хезмәтем басылып чыкса, халкыма, аз гына булса да, минем өлешем булыр иде...» Ахырда бәхилләште. Аның тавышындагы моң-сагыш хәзер дә колагымда чыңлап тора...

* * *

Илһам Ибраһим улы 70 еллык гомерен намус белән үткәрде, төрле тармакларда эшләде, фәнгә, кадрлар әзерләүгә, мәдәнияткә үзеннән сизелерлек өлеш кертте. Аның якты образы замандашлары, шәкертләре, якыннары күңелендә мәңге сакланыр. Ул үзенең һәм ата-бабаларының исемнәренә лаеклы зыялы зат, күркәм шәхес иде.

Илһам Ибраһим улы, үзенең рухи асылына, милли барлыгына кайтып, үз халкына хезмәт итү юлында якты дөньядан китеп барды. Аның иң соңгы язмасы да «Татарның киләчәге якты» дип юкка гына язылмагандыр.

*2002*

## ТӨРКЕСТАН — МӨСЕЛМАННАРНЫҢ ИКЕНЧЕ МӘККӘСЕ

Дөньяда мәшһүр Париж, Лондоннар, куәтле АКШ, Японияләр барлыгын да, аларның җиһан тарихында мөһим урын тотканлыгын да яхшы беләбез. Әмма без төрки-татарлар өчен Урта, ягъни Үзәк Азия, элеккечә әйткәндә Мавәраэннәһер, аеруча үз һәм якын. Бу якларның газизлеге, үзлеге безнең рухыбызга әби-бабаларыбыз аркылы, хәтер тамырлары аша сеңеп калган. Идел-йортка күп нәрсә Мавәраэннәһер тарафларыннан килгән, этник чыгышыбыз, телебез, динебез, мәдәниятебез, рухи байлыгыбыз шактый дәрәҗәдә Урта Азия белән бәйле.

Мавәраэннәһер — төрле халыкларның, әмма, иң беренче чиратта, төрки һәм фарсы телле кавемнәрнең борынгы Ватаны. Мәхмүд Кашгарыйның 1072—1074 елларда төзелгән «Диване лөгатет-төрк» сүзлегендә юкка гына «Татсыз (ягъни фарсыдан башка) төрк булмас, башсыз бүрек булмас» мәкале теркәлмәгәндер. Беренче һәм икенче меңьеллыклар аралыгында биредә Саманилар, Газнәвиләр, Харәземшаһлар, Караханилар һ.б. дәүләтләрнең яшәве мәгълүм. Үзәк Азия дөнья цивилизациясенә Фәраби, Бируни, Ибне Сина, Рудәки, Баласагунлы һ.б. бөек затларны биргән. Бу төбәк борын-борыннан ук үзенең Сәмәрканд, Бохара, Хөҗәнд, Үргәнеч, Отырар кебек шәһәрләре белән мәшһүр. Болар арасында хәзерге Казакъстан мәмләкәтендәге Төркестан каласы да мөһим урынны били. Аның нигезләнүенә быел якынча 1500 ел тулды. (Игътибар итегез: төрки дөньясында мең елдан артык тарихы булган шәһәрләр шактый. Боларга безнең Казаныбыз да керә. Бу үзе үк төркиләрнең озын тарихлы, бай мәдәниятле булуын күрсәтеп тора.)

Исламгача ук нигез салынган бүгенге Төркестан әүвәл Шаугар (Шавгар) исеме белән йөртелгән. Аннан — Йәсе, ягъни Ясы. XVI гасыр ахырында идарә итә башлаган казакъ хөкемдары Есим хан бу шәһәргә Төркестан исеме бирә һәм аны үзенең башкаласы итә. 1785 елда бу каланы Бохара әмире яулап ала. 1864 елда Төркестан Россия империясе составына кертелә.

Бу шәһәр Сырдәрья елгасы буена урнашкан. Аның аркылы элек «Ефәк юлы» узган. Хәзер аның аша Европа өлешеннән Ташкентка баручы тимер юл үтә. Шәһәрдә 100 меңләп халык яши. Төркестан башкаласы Шымкент (Чимкент. Ул Үзбәкстан пайтәхетеннән 120 чакрым төньяктарак урнашкан) булган Көньяк Казакъстан өлкәсенә керә.

Төркестанны дөньяга танытучы, аны мөселманнарның икенче Мәккәсенә әверелдерүче бик тә мөһим бер фактор бар. Ул да булса — Хуҗа Әхмәд Ясәви (Хуҗа Әхмәд, Кол Әхмәд). Бу бөек шагыйрь, атаклы суфый, күренекле философ, XI гасыр азакларында биредә туып, 1166 елда вафат була. Ул руханилар нәселеннән (этисе — Шәйх Ибраһим Мәхмүд углы). Остазлары — Арслан Баба һәм бөтен мөселман дөньясының мәшһүр шәхесе Йосыф Хамадани.

Хуҗа Әхмәд Ясәви (бу тәхәллүсне Яссәви, Йәсәви рәвешендә язу очраклары да бар) үзе исән вакытта ук изге зат, мәшһүр фикер иясе буларак танылa. Ул — күпләгән шәкертләрнең остазы. Болардан иң билгелесе — Сөләйман Бакырганый, ягъни Кол Сөләйман, Хәким Ата (ул 1186 елда вафат була). Аларның исемнәре еш кына бергә язылып, әсәрләре бергә тупланып та йөри.

Ясы шәһәрендә элек-электән үк изге затлар, күренекле кешеләр җирләнә торган зиярат була. Әхмәд Ясәвине дә шунда дәфен кылалар. Кабере өстенә зур гына төрбә (кәшәне) корыла. Бу урын төркиләр өчен генә түгел, ә мөселман дөньясының да зиярәт кылу төбәгенә әверелә. «Мәдинәдә — Мөхәммәд, Төркестанда — Хуҗа Әхмәд» гыйбарәсенең таралуы да юкка гына түгел. Әхмәд Ясәви каберенә баруны Үзәк Азия кавемнәрендә өчтән бер хаҗга, ә Идел-йорт мөселманнарында ярты хаҗга да тиңләп йөртү булган.

Җиһангир Шаһ Тимер, ягъни Аксак Тимер дә Әхмәд Ясәвине изгеләштергән, аның каберенә берничә мәртәбә зиярәт кылган. XV гасыр башларында элеккеге төрбә урынына бинаһая зур корылма төзеткән. Гәрчә ул, Аксак Тимернең үлеме аркасында (Җиһангир 1405 елның февралендә вафат була), тәмам корылып бетмәсә дә, үзенең сәнгати камиллеге, бөеклеге белән бүгенге кешене дә таң калдыра. Алга таба да бу бина тирәсенә күренекле затларны җирләү дәвам итә. Есим ханнан башлап, биредә күп кенә казакъ хөкемдарлары да күмелгән. Шактыеның каберташ язмалары да бар.

Әхмәд Ясәви — бөтен төрки, мөселман дөньясының изге, бөек заты. Әмма ул, барыннан да элек, шагыйрь, сүз остасы буларак мәгълүм. Аның әсәрләре аңлаешлы тел, үтемле шәкел белән язылган. Алар өчен музыкальлек, аһәңлелек хас. Шуңа күрә Әхмәд Ясәви шигырьләрен күмәк рәвештә дә, ялгыз калып та көйләгәннәр, җырлаганнар. Шагыйрьнең әсәрләрендә кешенең уй-кичерешләре, рухи халәте, күңел каршылыклары шактый тулы гәүдәләнеш тапкан. Аларда Аллага, инсаннарга мәхәббәт хисләре җырлана, әхлакый пакьлек, итагатьлелек, сабырлык мактала, тормыштагы, кеше күңелендәге ямьсез күренешләр, сыйфатлар тәнкыйтьләнә. Шагыйрьнең идеалы — аллачыл, әхлаклы, изге эш-гамәлле зат. Ул, үзеннән бигрәк, үзгәләрнең мәнфәгатьләре өчен яна-көя, кешеләрнең, кавемнәрнең язмышы, дустанә

мөнәсәбәтләре, иминлеге өчен борчыла. Нәкъ менә шуңа күрә дә аны миллионлаган кешеләр күп гасырлар буе хөрмәт итәләр, бу бөек затны үзләренең, киңәшчесе, остазы итеп санийлар.

Әхмәд Ясәви — татар дөньясында да бик билгеле зат. Бу, иң беренче чиратта, шагыйрь әсәрләренең идея-эстетик байлыгы, укучылар күңеленә аваздашлыгы, теленең безнең әдәби телебезгә якынлыгы белән аңлатыла. Әхмәд Ясәви шигырьләре Идел-йортта элек-электән оригиналда укылган, күпләп күчерелгән, XIX йөзнең икенче яртысыннан башлап Казанда зур тиражлар белән басылып, бөтен төрки дөньяга таралган. Ясәви шигырьләре татарның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндереп килгән, аны чын мәгънәсендә азыкландырган, туендырган. Бөек шагыйрь иҗатының әдәбиятыбызга да дәвамлы рәвештә йогынты ясавы бәхәссез. Аның шифалы тәэсирен без Хисам Кятиб, Өмми Кәмал, Колшәриф, Мәүла Колый, Шәмседдин Зәки, Әбелмәних Каргалый һәм башка күп кенә шагыйрьләрнең иҗатларында ачык күрәбез. Тукай һәм Гафури, Ясәви парчаларына нигезләнеп, заманча рухлы әсәрләр иҗат итәләр.

Совет чорының рәсми идеологиясе Ясәвине, кара буяуларга буяп, оныттырырга тырышты. Әмма бөек шагыйрьнең җаны халкыбыз рухында яшәвен туктатмады. 90 нчы елларда, җәмгыятьтәге үзгәртеп коруларга нисбәтән, Ясәви белән кызыксыну янә көчәйде. Конференцияләр уздырылу, әсәрләренең программа-дәреслекләргә кертелүе, шагыйрь хакында мәкалә-хезмәтләр басылу — шуның ачык билгесе. 2000 елда «Иман» нәшриятында Хуҗа Әхмәд Ясәвинең «Хикмәтләр»е дөнья күрде. Ул басмага Ф.Яхин һәм С.Гыйлаҗетдинов тарафыннан әзерләнгән.

Шунысын да искәртик: Төркестан каласын, аның йөзек кашы Әхмәд Ясәви эшчәнлеген өйрәнүгә Н.Веселовский, В.Вельяминов-Зернов, В.Бартольд, Ф.Күприлезадә, М.Массон, С.Толстов кебек күренекле галимнәр белән бергә, М.Бекчурин, Г.Әхмәрев, Г.Газиз һәм Г.Рәхим кебек татар укымышлылары, Казан университеты да үзләреннән зур өлеш керткәннәр. Мәсәлән, Оренбургтагы Неплюев уку йорты мөгаллиме Мирсалих Бекчурин (1819—1903), рус армиясенең Урта Азиягә походларында тәрҗемәче ролендә катнашып, 1866 елда «Военный сборник» китабында «Описание мечети Азрета, находящейся в городе Туркестане» дигән мәкаләсен бастырып чыгара (# 8). Х.Фәезхановның танышы, «Мәкәрҗә бәете» хакында тәүге мәгълүмат бирүче П.И.Пашиноның «Путешествие в Туркестан. Дневник 1866 г.» язмасында Төркестан хакында мөһим белешмәләр бар.

* * *

2000 ел — Төркестан каласының 1500 еллыгы. ЮНЕСКО карары белән моңа хәзерлек күптәннән башлана. Төркия ярдәме белән Казакъстан хөкүмәте гаять зур эшләр башкара: Ясәви корылмасы тагын да киңәйтелә, юллар, сәүдә үзәкләре, кунакханәләр, музейлар төзелә. Күпләп гыйльми хезмәтләр дөнья күрә. 4 мең кешене сыйдырышлы Җәмигъ мәчет корыла. Биредә иң мөһиме — Ясәви исемендәге халыкара казакъ-төрек университеты ачылу. 1991 елда анда 300 студент белем алса, хәзер аларның саны 11 меңнән артып киткән (болар арасында татарлар да бар). Бу университетта 91 фән докторы, 226 фән кандидаты эшли. Мәһабәт биналар, заманча җиһазландырылган кабинетлар, спорт заллары һәркемне таң калдырырлык. «Төркестан элек казакъ дәүләтенең башкаласы булса, бүген ул рухи мәркәз булып тора».— Казакъстан Президенты Н.А.Назарбаевның бу сүзләренә, шәһәрдә булу белән, бик тиз ышанасың.

Шушы елның 20—21 октябрендә Төркестанда каланың 1500 еллыгына багышланган бәйрәм тантаналары узды. Анда 100 меңнән артык кеше катнашты. Төркия Президенты Әхмәд Нәҗдат Сәзәр җитәкчелегендә 200 кешелек делегациянең килүе дә күп нәрсә хакында сөйли. Тантанада ЮНЕСКО җитәкчелеге, Кыргызстан, Азәрбайҗан һәм башка илләрнең вәкилләре катнашты. Президент Н.А.Назарбаевның рәсми чакыруы белән бу бәйрәмгә Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе дә барды. Аның составында мәдәният министры Илдус Тарханов, үзем һәм шулай ук Татарстан телевидениесе хезмәткәрләре Резедә Макуева, Мөнир Залюшев һәм җырчы Зоя Борисова да бар иде. Бару, кайту, Казакъстанда булу барлыгы бер тәүлеккә сыеп бетте. Махсус самолетны Чимкент аэропортында Казакъстан вәкилләре, җирле татарлар, зурлап, чәчәкләр белән, милли киемнәрдә, җырлар белән каршы алдылар. Биредә делегациягә Татарстанның Казакъстандагы махсус вәкиле профессор Морад Кәримов һәм аның ярдәмчесе дә кушылды. Чимкенттан без 180 чакрым ераклыктагы Төркестанга юнәлдек. Биредә дә безне олылап каршы алдылар. Эче гаҗәеп келәмнәр белән бизәлгән махсус тирмәдә тукталдык. Аннан шәһәрнең истәлекле урыннарын, Ясәви («Әүлия Ата») хөрмәтенә корылган ядкярләрне карадык. Далада ат чабышлары безнең Сабантуйны хәтерләтте. Әмма биредә сугыш түгел, уеннар бара. Кичен шәһәр үзәгендәге мәйданда зур концерт башланды. Меңәрләгән кеше катнашкан бу искиткеч концертны Казакъстан телевидениесе турыдан-туры күрсәтеп торды.

Юбилей чараларының үзәген Ясәви исемендәге университетның зур актлар залында үткәрелгән фәнни-гамәли конференция тәшкил итте. Аның бер утырышы делегация җитәкчеләренең чыгышларына

багышланды. Казакъстан Президенты Н.А.Назарбаев килгән кунакларны казакъ телендә ихлас күңелдән котлады, Төркестанның тарихына, бүгенге көненә кыскача тукталды, илнең эчке һәм тышкы хәле белән таныштырды. Зал Төркия Президентын аягүрә басып сәламләде. ЮНЕСКО, Кыргызстан, Азәрбайҗан вәкилләреннән соң, сүз безнең делегация башлыгына бирелде. Ул үзенең татарча һәм русча сөйләгән чыгышында бу бәйрәмнең төркиләр өчен уртак бәйрәм булуына, Урта Азиянең, Төркестан каласының тарихи роленә тукталды, Ясәви иҗатының төп моментларын, татар рухи тормышындагы ролен яктыртты. Шагыйрь әсәрләренең юбилей елында аерым китап рәвешендә Казанда басылып чыгуы, Ясәви мирасының бүгенге укучы өчен дә файдалы икәнлеген әйтүе аеруча кызыксыну уятты. Ф.Х.Мөхәммәтшин казакъ һәм татар халыкларының тарихи һәм бүгенге дуслыгын ассызыклады.

Мәгълүм булганча, Казакъстан илбашы Н.А.Назарбаев 1996 елның 3 мартында Муса Җәлил исемендәге театрда М.Ш.Шәймиевнең президентлык антын кабул итүгә багышланган сессиядә казакъ телендә бик эчтәлекле чыгыш ясаган иде. «Биредә,— дигән иде ул,— борынгы Татарстан җирендә, безнең халыкларыбызның тамырлары бердәм икәнлеген, тарихи язмышларыбызның, мәдәният, дин, традицияләр һәм телнең уртаклыгын аеруча нык сизәсең».

Бу сүзләрнең Ф.Х.Мөхәммәтшин тарафыннан татарча искә төшерелүе залдагыларның күңеленә аеруча хуш килде. Гомумән, Татарстан делегациясе башлыгының чыгышы зур кызыксыну белән тыңланды. Ахырда бик озаклап кул чаптылар. Н.А.Назарбаев та безнең Дәүләт Советы рәисенә рәхмәтен белдерде.

Гомумән, Татарстан делегациясенә игътибар, хөрмәт көчле булды. Без моны казакъ халкының татарларга булган дустанә мөнәсәбәтләрнең бер билгесе итеп кабул иттек. Борынгы Төркестан, Чимкент төбәкләреннән озатулар да истәлекле, югары дәрәҗәдә булды.

* * *

Төрле проблемалар туып торса да, Казакъстан мөстәкыйльлеген ныгыта, алга бара. Мәдәнияте үсә, казакъ теле ныклап гамәлгә керә. Илнең халыкара абруе күтәрелә. Төркестан каласының 1500 еллык бәйрәме — моның ачык бер мисалы.

*2000*

## ТАТАРНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ — ТАТАРДА

Милләтпәрвәрләр, ягъни үз милләтен сөючеләр, аның өчен янып-көючеләр, икенче төрле әйткәндә, асыл мәгънәдәге милләтчеләр соңгы елларда шактый артты. Шөкер Ходайга, алар арасында әдәбият-сәнгать әһелләре, тел-әдәбият галимнәре һәм укытучылары гына түгел, башка тармак вәкилләре, төрле шөгыль ияләре дә бар. Бу шулай булырга да тиеш. Чөнки милләт һәммәбезнең да анасы һәм ул барлык балаларының да игътибарына, үзенә теләктәшлегенә даими мохтаҗ.

Тарихи тәҗрибә шуны күрсәтә: аерым чыгармалар булса да, милләтнең асылын, аның нигезен, этник бөтенлеген тел уртаклыгы тәшкил итә. Алар — аерылмас төшенчәләр: тел бар икән — милләт бар, милләт бар икән — тел бар. Шуңа күрә кайбер «акыллы» башларның телсез дә кавемне сакларга, үстерергә мөмкин дип сафсата сатулары — мәгънәсезлек; бу үзләренең, я балаларының, я марҗа яисә марҗалашкан хатыннарының телсезлеген акларга, канунлаштырырга омтылу нәтиҗәсе генә. Телдә милләтнең рухы, яшәеш фәлсәфәсе, тереклек тарихы, моңы, гореф-гадәте, хәтер дәвамчанлыгы.Чын мәгънәсендәге милли сәнгать, милли музыка, милли мәдәният, милли тарих бары тик милли телгә нигезләнгәндә, аның белән табигый бәйләнештә генә туа, яши һәм үсә ала. Кызганыч ки, бездә хәзер татарча юньләп белмәгән артистлар, рәссамнар, композиторлар, сәнгать белгечләре, хәтта филологлар, тарихчылар күбәеп китте. Кайвакыт аерым спектакльләрнең, концертларның, тапшыруларның репетицияләрен күреп, исең-акылың китә: татарча тамаша я катнаш телдә, я русча әзерләнә.

Милли телне торгызу, саклау һәм үстерүнең сыналган системасы милли мәгариф булуы инде бәхәссез күренеш. Соңгы елларда бу юнәлештә шактый гына эшләр башкарылды. Татар балалар бакчалары, мәктәп-гимназияләр ачу, вузларда татар төркемнәре оештыру — шуның күркәм мисалы. Бу игелекле башлангычны алга таба тагын да киңәйтү, тирәнәйтү сорала. Милли университетның ачылуы һәм яшәве — күптәннән өлгергән мәсьәлә. Әмма татарча югары белем бирүне Татарстандагы барлык вузлар да башкарырга тиеш. Чөнки мәгариф, мәдәният, медицина, авыл хуҗалыгы, сәнәгать, хокук, математика һәм башка тармаклар буенча милли кадрлар хәзерләүне бары милли университетка гына йөкләү, аннан көтү — гаять берьяклы караш. Республикабыздагы барлык фәнни, интеллектуаль потенциал милләтебезнең рухи ихтыяҗларына хезмәт итәргә бурычлы.

Милли белем бирү һәм тәрбия хакында сүз барганда, катнаш никахлы гаиләләрдәге балалар белән эшләүнең мөһимлеген дә искәртергә кирәк. Чөнки мондый балаларның саны шактый. Аларга ничек якын килергә, бу процесста нинди максат-бурычлар куярга, дини-рухани факторны ни рәвешле гамәл кылырга? — Бу мөһим мәсьәләләр бар булган тәҗрибәне өйрәнүне, махсус сөйләшү-тикшеренүләрне, фәнни-гамәли конференцияләр уздыруны көтә. Катнаш никахлы гаиләләрдә генә түгел, гомумән, гаиләдә милли тәрбия бирү бездә әле зәгыйфь тора. Чөнки шәһәрләрдә һәм бистә-поселокларда яшәүче ата-аналарның күпчелеге — советча тәрбияләнгән, бәйнәлмиләл рухлы интертатарлар. Аларның татарча сөйләшүләрен, милләт турында фикерләүләрен тыңлап, ишетеп тору — үзе бер фаҗигаи комедия. Шунысы аянычлы: хәтта кайбер олуг галим-әдипләребезнең балалары арасында татарча укымый, татарча сөйләшә алмый торган затлар да бар. Милләтебезнең нигезе, кальга-крепосте булган авыл да соңгы берничә дистә елда як-якка салулый башлады: анда да, игелекле гореф-гадәтләребезне онытып, читләргә иярү, эчүчелек, әхлаксызлык көчәйде. Авылдагы әби-бабайлар да балаларына «хөрмәт» йөзеннән шәһәрдән каникулга, кунакка кайткан оныклары белән русча гына «сиптерәләр». Шуның нәтиҗәсендә бу төр балалар, татарча өйрәнеп китәсе урынга, авылны да руска якынайтып китәләр. Без өлкәннәр исә, бу күренешкә риза булып, эндәшмичә торабыз.

Хәзерге вакытта милләтнең милләт буларак яшәвен милли китап, газета-журналлар һәм радио-телевидениедән башка күз алдына да китереп булмый. Татарстанның үзендә һәм өлешчә Башкортстанда, Пермь өлкәсендә эшләр ярыйсы гына. Әмма күп кенә башка төбәкләрдә гомер кичерүче милләттәшләребез үзләренең милли ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән мәхрүм диярлек. Анда-санда эшләгән «Татар мәктәбе» дигәнең дә рус мәктәбеннән әллә ни аерылмый: татар теленнән башка, барлык фәннәр русча укытыла, төрле чаралар, нигездә, башка телдә уздырыла. Китапханәләрдә татарча басмалар, газета-журналлар юк дәрәҗәсендә. Мәдәният, мәгариф белән бәйләнешле милли кадрлар хәзерләү очраклы рәвештә генә башкарыла. Татарлар кайда да эшли, җәмгыятькә, илгә үзеннән файда китерә, тиешле салымын түли. Әмма аларның милли ихтыяҗлары да барлыгы рәсми хакимият тарафыннан тәмам «онытыла». Бездә хәзер «Рәсәйдә милли сәясәт юк» дип еш ишетергә туры килә. Ул — бар. Әмма бу сәясәт «өлкән туган» файдасына гына. Ә инде калган кавемнәрне мөмкин кадәр тизрәк манкортлаштыру, тел һәм гореф-гадәтләреннән «чистарту», бердәм «россияннар» итү, ягъни руслаштыру — Мәскәүнең рәсми милли сәясәте. Дөрес,ул аны сиздермәскә, төрле дежур сүзләр һәм вәгъдәләр белән шомартырга тырыша. Әмма

гамәлдәге милли сәясәтнең чынлыкта рус булмаган халыкларны милләтсезләндерүгә, ассимиляциягә юнәлтелгәнен күрү һич тә кыен түгел.

Халкыбызның асыл Ватаны, бишеге — хәзерге Татарстан, Башкортстан гына түгел, ә гомумән Идел-йорт, Идел-Урал төбәге. Ул биредә болгар, хәзәр, кыпчак, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Нугай мәмләкәтләре чорларыннан ук гомер кичергән: иген иккән, мал асраган, һөнәрчелек белән шөгыльләнгән, сәүдә иткән, шәһәр салган, китап язган... Шушы зур төбәктә татар моңы яңгыраган, татар теле дәүләт, төп аралашу теле булган. Әмма дәүләтчелектән мәхрүм ителү, колониаль сәясәт татарны гасырлар буена сипкән, тараткан. Архангелга, яисә Ярослау һәм Комига татар үз ирке белән бармаган: аны яисә сөргәннәр, яисә туган төбәген ташларга мәҗбүр иткәннәр. Читтә, ерак төбәкләрдә милли рухны саклау, милли ихтыяҗларны канәгатьләндерү җиңел эш түгел. Андыйларны иртәме-соңмы ассимиляция, башка милләтләр арасында эрү, югалу көтә. Шуңа күрә теләге бар татарларның асыл Ватанына — Идел-йортка кайтулары, әби-бабалары гомер кичергән җирләрдә башка милләттәшләре белән оешып, бер гаилә кебек яшәүләре мәслихәт. Шунсыз татарның киләчәге хафалы.

Тарих, хәзерге дөнья тормышы шуны күрсәтә: милләтнең яшәеше, бердәмлеге, аның теле, мәдәнияте, гореф-гадәте, мәгарифе, кыскасы, кавемне бербөтен итеп тотучы сыйфатлар, шартлар халыкның дәүләтчелегенә, мөстәкыйльлек дәрәҗәсенә турыдан-туры бәйле. Моны элеккеге союздаш республикалар — хәзерге бәйсез дәүләтләр мисалы да ачык күрсәтеп тора. Мәгълүм ки, узган гасырның соңгы дистә елында Татарстан үзенең хокукларын билгеле бер дәрәҗәдә арттырды. Бу хәл халыкның милли үсешенә дә уңай йогынты ясады. Ә менә милли дәүләтчелек формасыннан бөтенләй мәхрүм булган Әстерхан, Оренбург, Төмән, Самара, Нижгар һәм кайбер башка төбәкләрдә татарларның рухи, милли-мәдәни тормышында уңай үзгәрешләр бик күзгә ташланмый. Шуңа күрә Идел-йортта татарларның төп өлешен үз эченә алган мәмләкәтнең яшәве зарури һәм мантыйкый күренеш.

Безнең халыкка бердәмлек, милли горурлык хисе җитми. Моның сәбәпләре, әлбәттә, күптөрле. Мөһим өлеше милли дәүләтчелектән мәхрүм ителү, сәяси һәм икътисади яктан изелү, кысылу һәм кайбер башка объектив факторлар белән дә бәйле. Еш кына без үзебез дә файдасыз бәхәсләргә, урынсыз ыгы-зыгыларга юл куябыз, бер-беребезне юкка рәнҗетәбез, нәтиҗәдә безнең үзебезгә дә, милләткә дә зыян килә, татарның абруе төшә.

Халкыбызның озын һәм катлаулы, данлы һәм фаҗигале тарихы, бай әдәби теле һәм мәдәнияте, күңелләрне тетрәндерерлек һәм җилкендерерлек җыр-моңы, хикмәтле фольклоры, күренекле әдип-галимнәре, мәшһүр затлары бар. Аларны белү, күңел хәзинәсе итү сине үз милләтеңнең рухы, җаны белән тоташтыра, шулар ярдәмендә син чын милләтпәрвәр булып җитешәсең. Милли иман-ышанычы бар инсан теләсә нинди шартларда да үз халкына хыянәт итми, аның дәрәҗәсен саклый. Башка милләтләргә хөрмәт, ихтирам белән карарга кирәк, әмма ул үз кавемеңне кимсетү, аның дәрәҗәсен төшерү хисабына булырга тиеш түгел. Мондый гамәл, ата-ананы хурлап, башкага ярарга тырышу белән тиң. Бу исә әхлаксызлык.

Тарихи яктан караганда, бер генә этник катламнан торган «саф» милләтләр юк дәрәҗәсендә. Аларны барлыкка китерүдә төрле ыру-кабиләләр, кавемнәр катнашкан, этнонимнар да шуңа мөнәсәбәттә үзгәргән. Безнең кайбер әһелләребез исә бу хакыйкатьне һич тә танырга теләми, «без татар түгел, болгар» дигән мәгънәсез һәм файдасыз бәхәсләр китереп чыгара. Тарихтан бит, югыйсә халкыбызның болгар кавеменнән генә түгел, ә хәзәр, татар, кыпчак һәм кайбер башка этник төркемнәрдән оешуы, XIII—XIV йөзләрдән алып татар атамасы белән йөртелә башлавы, шул исем белән дөньяга танылуы көн кебек ачык. Безгә, кайбер авторларның һәм чыганакларның татарны яманлавына карап, бу этнонимнан качарга түгел, киресенчә, аның намусын саклау, дәрәҗәсен күтәрү юнәлешендә бергәләп эшләргә, хәрәкәт итәргә кирәк. Исем-атама алыштырып кына дөнья үзгәртеп, мәсьәләнең асылын хәл итеп булмый. Мишәр, керәшен, типтәр, пензяк, нижгар дип, уйламыйча сөйләшүләребез дә уеннан уймак чыгара язды.

Татар-болгар мәсьәләсендә дин әһелләребезгә дә киңәш бар. Аларның вәгазьләрендә еш кына «болгар бабаларыбыз», «бездә ислам дине 922 елда кабул ителгән» кебек гыйбарәләрне еш ишетергә туры килә. Ә бит, әйткәнебезчә, татар болгардан гына тормый, аның борынгы дәүләтчелеге дә Болгар гына түгел. VII—X гасырларда яшәгән хәзәрләр һәм аларның дәүләте дә турыдан-туры безгә мөнәсәбәтле. Мәгълүм ки, бу мәмләкәттә, ягъни безнең әби-бабалар яшәгән Идел-йортта, мөселман дине рәсми рәвештә 737 елда кабул ителгән. Аңа кадәр дә инде ул биредә шактый таралган була.

Дин әһелләре турында сүз чыккач, янә бер фикер әйтергә җөрьәт итәм. Безнең Ш.Мәрҗани, Р.Фәхреддин, М.Бигиев кебек классик руханиларыбыз гарәп телен, Коръәнне, ислам фәлсәфәсен генә түгел, ә милли телебезне, тарихыбызны, мәдәниятебезне дә камил белгәннәр, татар телендә оста итеп сөйләгәннәр, язганнар, гомуми мөселманнан бигрәк, конкрет мөселман татарларын күздә тотып эшләгәннәр. Миңа калса, хәзер дини белгечләр әзерләүдә, вәгазьләрдә һәм дин китапларында милли

мәдәни байлык, татар теленең кодрәтле көче тиешенчә файдаланылмый. Мөгаен, шуңа күрәдер русча гына сөйләшеп йөрүче шәкертләр, төссез нотык-вәгазьләр укучы имамнар да очраштыргалап тора.

Латинга күчү мәсьәләсе дә татарларда мәсләки бердәмлек җитмәүне янә бер мәртәбә бөтен дөньяга ачып салды. Ярый, бөтенләй татарча укымаган, туган телендә юньләп сөйләшә дә белмәгән аерым татарларның сәяси көчләр ярдәмендә бу хәрәкәткә каршы чыгуы өлешчә аңлашылсын да, ди. Ә бит латинга күчүдә Казанда яшәүче телче галимнәребез дә уртак фикергә килә алмады, ике-өч хәреф өчен бәхәсләшеп, гомуми изге эшкә зыян китерделәр. Латинга күчү исә, без телибезме-теләмибезме, иртәме-соңмы, барыбер гамәлгә ашачак объектив зарурият.

Бердәмлекне ныгытуда, милли үзаңны үстерүдә әби-бабаларыбызның яшәешенә, мәдәниятькә, күренекле әһелләребезнең эш-гамәлләренә тарихи, игътибарлы караш сорала. Без, ничектер, үткәннәр турында реаль шартларны, чор үзенчәлекләрен исәпкә алмыйча, субъектив фикер йөртергә, катгый нәтиҗә-хөкемнәр чыгарырга, кискен бәяләр бирергә яратабыз. Шәхси мәнфәгатьләрен онытып, милләт өчен, җәмгыять өчен армый-талмый көрәшүче олуг затларыбызны, лидерларыбызны тиешенчә кадерли, бәяли белмибез, еш кына, аларның булыр-булмас гаепләрен табып, каралтырга, юкка чыгарырга тырышабыз. Түбән Камадан Фәрид Заһидулла дигән бер адәм «Восточный экспресс» газетасындагы (# 31, 26 июль — 1 август, 2002 ел) «Саморазрушение» исемле мәкаләсендә Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, И.Гаспралы, Ф.Әмирхан һәм күп кенә башка олуг затларыбызны пыран-заран китерә, хәтта милләте өчен янып яшәгән, татарның символына әверелгән бөек Тукайны да Явыз Иван белән янәшә куя. «Не будет преувеличением сказать, что один Тукай причинил своему народу вред, сопоставимый с вредом, причиненным Иваном Грозным». Мин бу авторга (әгәр дә ул сәламәт акыллы булса) Тукай әсәрләрен һәм аның хакындагы хезмәтләрне җентекләп укырга, шул чорның реаль тормышын тирәнрәк өйрәнергә киңәш итәр идем. Тагын шунысы да бар: «Восточный экспресс» газетасы, демократия, матбугат иреге дип, үз укучыларына карата талымсызлык та күрсәткән. Чынлыкта бит «Саморазрушение» дип исемләнгән бу материал, гәрчә анда аерым кызыклы фикерләр булса да, гомумән татарның тарихына, затлы улларына яла ягу, пасквиль.

* * *

Ходай Тәгалә «сакланганны саклармын» дигән. Һәр милләт, аерым инсан кебек, иң әүвәл үзен-үзе сакларга, үзе хакында үзе кайгыртырга бурычлы. Башкаларга ышанып, аркаланып яту, гафиллек-ваемсызлык һәлакәткә илтә. Халыкта «Агай, алдан сагай» дигән гыйбарә бар. Дөньяда элек тә, хәзер дә көрәш, конкуренция бара. Ул киләчәктә дә шулай булачак. Югалып калмас өчен , безгә тарихтан сабак, гыйбрәт алып, үзгәләр тәҗрибәсен өйрәнеп, алда ни буласы хакында да уйланып яшәргә, көрәшергә, хәрәкәт итәргә кирәк. Без үткәнебез өчен генә түгел, бүгенгебез, киләчәгебез өчен дә, иң беренче чиратта, үзебез җаваплы. Татарның язмышы, киләчәге, барыннан да элек, татарда, милләтнең үз кулында.

*2002*

*Биобиблиографик белешмә*

ТОРМЫШ ЮЛЫ

Хатыйп Йосыф углы Миңнегулов 1939 елның 12 маенда Татарстанның Зәй районы Апач (рәсми атамасы — Сармаш по Ирне) авылында колхозчы гаиләсендә туа (әнисе — Гайнелхәят; 1912—1999, әтисе — Йосыф; 1909—1944. Ул сугышта һәлак була). Башлангыч белемне Апачта, җидееллыкны күршедәге Пидәр (Федоровка) авылында ала. Аннан соң бер ел колхозда эшли. 1954—1957 елларда Сарман районы Иске Кәшер урта мәктәбендә укый. Өлгергәнлек аттестаты алгач, берничә ай Таҗикстанның Ленинабад өлкәсендә (Табошар бистәсендә) заводта һәм мамык плантациясендә эшли. Алга таба — туган авылында колхозчы, клуб мөдире. 1959—1964 елларда — Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге студенты. 1962—1963 уку елында, читтән торып укуга күчеп, Пенза өлкәсе Белинский районы Качкару (Кутеевка) авылында балалар укыта. Университетны тәгәлләгәч, Сарман районында ике ел Чукмарлы мәктәбендә директор, колхозның партоешма секретаре, аннан ел ярым КПССның партия райкомында партия мәгарифе кабинеты мөдире булып эшли. 1967 елның ноябреннән — Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы укытучысы. 1984—1989 елларда — филология факультетында декан урынбасары. 1972 елда кандидатлык, 1991 елда докторлык диссертациясе яклый.

Х.Миңнегулов, башка бик күп кенә каләм әһелләре кебек, яшьтән үк әдәбият белән кызыксына, шигырьләр, мәкаләләр яза. Студент елларында яшь тәнкыйтьче буларак танылa. Әдәбият фәне белән ул университетка эшкә күчкәч ныклап шөгыльләнә башлый.

Галим, нигездә, Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәбиятын, аның Шәрык (гарәп, фарсы, төрки...) классикасы белән бәйләнешләрен өйрәнә. Аның XX гасыр әдәбияты, чит илләрдәге татар сүз сәнгате, методика, әдәбият теориясе, текстология, халык һәм дин тарихы, мәдәният һәм мәгариф буенча да хезмәтләре бар. Ул бигрәк тә Котб, Сәйф Сараи, Т.Ялчыгол, Ш.Зәки, С.Кукляшев, Р.Фәхреддин, Ф.Халиди, Г.Тукай, Ш.Бабич, Р.Гаташ кебек авторларны, «Мең дә бер кичә», «Кәлилә вә Димнә», «Тутыйнамә», «Мең дә бер көн» шикелле мәшһүр ядкярләрне өйрәнүгә, хикәят, кысалы кыйсса, газәл, робагый һәм башка классик жанрларны гыйльми яктыртуга үзеннән зур өлеш кертте. Профессор үзенең Г.Исхакый һәм башка мөһаҗир әдипләр (Х.Габдүш, С.Гыйффәт, Х.Хәмидулла, М.Исмәгыйли...) хакындагы язмалары, шулай ук әдәбиятчы галимнәр турындагы мәкаләләре белән дә укучыларга таныш.

Х.Миңнегулов — татар, рус, төрек һ.б. телләрдә дөнья күргән ике дистәдән артык китап, 500 гә якын мәкалә авторы. Алар арасында 7 монография, 4 дәреслек (V, IX, X сыйныфлар өчен), дистәләгән уку-укыту әсбабы, программалар бар. Басылган хезмәтләренең күләме 500 басма табактан артып китә. Галим 30 томлык төрки әдәбиятлар тарихын, энциклопедиясен язуда, антологиясен төзүдә (бу китаплар Анкарада төрек телендә чыга) автор һәм татар әдәбиятчылары җитәкчесе буларак катнаша.

Х.Миңнегулов Казан, Мәскәү (Әдәбият институтында), Истанбул, Анкара, Хельсинки, Ташкент, Алма-Ата, С.-Петербург һәм башка шәһәрләрдә лекцияләр укый, конференцияләрдә, конгресс-симпозиумнарда докладлар ясый. Ул — күп кенә гыйльми хезмәтләрнең фәнни редакторы, диссертацияләрнең җитәкчесе, рәсми оппоненты.

Галим төрле җәмәгать эшләрендә дә актив катнашып килә. Хәзерге вакытта аның түбәндәге иҗтимагый вазифалары бар: Казан университетында һәм Татарстан укытучыларының белемен камилләштерү институтында гыйльми совет әгъзасы, докторлык диссертацияләре яклау советының рәис урынбасары, Югары белем министрлыгы каршындагы «Россия халыкларының телләрен һәм әдәбиятларын Федерация вузларында укыту секциясе»нең рәисе, «Казан утлары», «Билге» (Анкара), «Түркология» (Төркестан) журналларының редколлегия әгъзасы, «Татар энциклопедиясе»нең баш гыйльми-редакцион коллегиясе әгъзасы һәм Тукайгача чор әдәбиятының баш мөхәррире, Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзасы, Тукай җәмгыяте президенты һ.б.

Хатыйп Йосыф углы — күп санлы бүләкләр иясе. 1966 елда ул, лекция пропагандасындагы эшчәнлеге өчен, «Республика Мактау китабы»на кертелә. 1983, 1994 елларда университет күләмендәге фәнни эшләр конкурсында ике мәртәбә лауреат була. 1995 елда «Заман» газетасы уздырган «Алтын Урда: тарихы һәм культурасы» дигән ябык конкурста беренче урынны яулап ала. 1994—1996 елларда Россия Фәннәр академиясенең гыйльми стипендия иясе, хезмәт ветераны. 1995 елда аның «Татарская литература и Восточная классика...» исемле монографиясенә Дәүләт премиясе бирелде. Галимнең чит илләрдәге татар әдәбиятын, матбугатын өйрәнүдәге хезмәтләре 1998 елда Кол Гали исемендәге бүләккә лаек булды. Нәтиҗәле гыйльми-педагогик эшчәнлеге өчен, ул 2000 елда Татарстан Республикасының «Мактау грамотасы» һәм 2003 елда Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» билгесе белән бүләкләнде.

БАСЫЛЫП ЧЫККАН КИТАПЛАРЫ

1. Сәйф Сараиның тормышы һәм иҗаты (Уку-укыту әсбабы).—Казан дәүләт университеты (*алга таба — КДУ*) нәшрияты, 1972.— 50 б.

2. Переводы и оригинальные произведения Саифа Сараи: Автореф. дисс. канд. филол. наук (Научный руководитель — проф. Х. У. Усманов. Официальные оппоненты: проф. ЛГУ Г.Т.Тагирджанов и кандидат филологич. наук Ш.Ш.Абилов. Ведущее учреждение — Институт литературы имени Низами АН Азербайджана).— Казань: 1972.— 31 с.

3. Котб иҗаты (Монография).— Казан: КДУ нәшр., 1976.— 79 б.

4. Сәйф Сараи. Тормышы һәм иҗаты (Монография). — Казан: КДУ нәшр., 1976.— 190 б.

**Рецензия**: *Әнвәр Шәрипов*. Сәйф Сараи иҗатын өйрәнү юлында // Казан утлары.— 1978.—№ 1.— 155—157 б.

5. Диплом эшен ничек язарга (Уку-укыту ярдәмлеге).— Казан: КДУ нәшр., 1975.— 42 б.

6. Педагогик практика (КДУның татар филологиясе бүлеге студентлары өчен ярдәмлек). Ике кисәктә: а) Методик кулланма.— Казан: КДУ нәшр., 1981.— 46 б. б) Библиографик күрсәткеч.— Казан: КДУ нәшр., 1981.— 46 б.

7. XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре (Монография. Ш.Садретдинов белән берлектә язылды).— Казан: КДУ нәшр., 1982.— 143 б.

8. XIX йөз татар хрестоматияләре (Монография. Ш.Садретдинов белән берлектә язылды).— Казан: КДУ нәшр., 1982.— 135 б.

**Рецензияләр**: *М.Бакиров*. Новый шаг в историю литературы // Ленинец (КДУ).— 27.02.1984; *М.Гайнетдинов*. Татар хрестоматияләре // Казан утлары.— 1985.— № 2.— 159—160 б.; Почетные награды (Об итогах конкурса на лучшие научные труды, опубликованные учеными КГУ в 1982 году) // Ленинец.— 26.12.1983; *Закир Әкбәрев*. Горурланырга хаклыбыз // Ильич юлы (Күмертау).— 1.01.1983. (Башкорт телендә.)

9. Әдәбияттан диплом эшләре (Уку-укыту ярдәмлеге). — КДУ нәшр., 1985.— 83 б.

10. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар (Монография).— Казан: КДУ нәшр., 1988.— 198 б.

**Рецензия**: *Шакир Абилов*. Кысалы кыйссалар тарихыннан //Соц. Татарстан.— 6.08.1988; «Мең дә бер кичә»дән бүгенгегә // Татарстан яшьләре.— 27.11.1988; Кыйссалар турында // Соц.Татарстан.— 31.12.1988.

11. Татарская литература и Восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики): Автореф. дисс. докт.филол.наук (Официальные оппоненты: проф. М.Х.Хасанов, М.Ф.Гайнуллин (г. Уфа), Б.К.Касимов (г.Ташкент). Ведущее учреждение — Казанский гос. пединститут).— Казань: 1992.— 54 с.

12. Туган тел китабы: 5 нче сыйныф өчен дәреслек (Б.Мифтахов, Н.Садриев белән берлектә язылды).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.— 208 б.

13. Татарская литература и Восточная классика… (Монография).—Казань: Изд-во КГУ, 1993.— 384 с.

**Рецензияләр**: *Марсель Әхмәтҗанов*. Бу — олы хезмәт // Шәһри Казан.— 11.12.1993; *Шакир Абилов*. Болгар-татар багларында Шәрык гөлләре //Татарстан хәбәрләре.— 28.01.1994; *Хәләф Курбатов*. Әдәбиятыбызның тирән тамырлары // Татарстан.— 1994.— № 7—8.— 136—138 б.; Фатих Урманче. Ерактан килгән чишмәләр // Мирас.— 1995.— № 1—2.—280—282 б.; *Фоат Галимуллин*. Шәркый рухыбыз тамырлары // Казан утлары.— 1995.— № 1.— 179—180 б.; Зур хәзинә (40 укытучы имзасы белән) // Ватаным Татарстан.— 23.08.1995; *Рәдиф Гаташ*, *Чулпан Зариф*. Милли аң сакчыларыннан берсе // Шәһри Казан.— 7.07.1995; *Наҗия Гыймадиева*. Рухи хәзинәләрне барлаганда // Мәгърифәт.— 1.07.1995; *Сергей Исаков.* Восточные корни татарской литературы // Республика Татарстан.— 1.07.1995; *Фатих Урманче*. Восток и Поволжье: литературные взаимосвязи // Известия Татарстана.— 24.06.1995; *Халидә Фәрдиева*. Халык рухы ничек байый // Мәдәни җомга.— 28.07.1995; *Резедә Ганиева*. Бәрәкәтле өлеш // Ватаным Татарстан.— 9.09.1995; *Шакир Абилов*. Мы росли не на пустом месте // Молодежь Татарстана.— 5.10.1995; *Муса Мөлеков*. Мәңгелек ядкярләр… // Кызыл Таң (Уфа).— 16.08.1995; Фән һәм техника өлкәсендә 1995 елгы Дәүләт премияләре бирү турында Татарстан Республикасы Президенты Указы // Ватаным Татарстан. 4.11.1995; *М.Х.Хасанов*. Достойный вклад в развитие науки и техники // Республики Татарстан.— 9.11.1995.

14. Әдәбият: Урта мәктәп һәм гимназияләрнең 9 нчы сыйныфы, урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары, лицей укучылары өчен дәреслек (Урта гасыр һәм XIX йөз әдәбияты) (Ш.Садретдинов белән берлектә язылган).— Казан: Мәгариф, 1994.— 336 б.

Шушы ук дәреслекнең камилләштерелгән икенче басмасы: Казан: Мәгариф, 1998.— 336 б.

15. Татар әдәбиятыннан хрестоматия: 9 нчы сыйныф өчен… (Урта гасыр һәм XIX йөз) (Ш.Садретдинов белән берлектә язылган).— Казан: Мәгариф, 1995.— 383 б.

Икенче басмасы: Казан: Мәгариф, 2000.— 384 б.

**Рецензияләр:** *Илгиз Галимов*. Чишмә башы // Шәһри Казан.— 5.07.1996; *Фәнүзә Нуриева*. Рухи хәзинәгә юл ачучы // Мәгърифәт.—7.06.1996; *Резедә Ганиева*. Бәхет китерүче белем // Мәгърифәт.—25.07.1998.

16. Татар әдәбияты: Рус мәктәпләренең 10 нчы сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек-хрестоматия (Урта гасыр. XIX йөз. XX гасыр башы әдәбияты) (Наҗия Гыймадиева белән берлектә язылган).—Казан: Мәгариф, 1996.— 319 б.

Дәреслек-хрестоматиянең тулыландырылган икенче басмасы: Казан: Мәгариф, 2000.— 320 б.

**Рецензия**: *Гәүһәрия Әхмәтҗанова*. Заман таләпләренә җавап бирерлек // Мәгърифәт.— 22.11.1996.

17. Сәйф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан / Әсәрләрне басмага әзерләүче, кереш һәм ахыргы мәкалә авторы Х.Миңнегулов.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.— 296 б.

**Рецензияләр:** *Әлфинә Сибгатуллина*. Гөлестанга яңа сәфәр // Мәдәни җомга.— 22.12.2000; Сәйф Сараи китабы // Мирас.— 2003.— # 4; *Рәдиф Гаташ*. «Белер Сәйф Сараи гыйшык рәсмен» // Мәдәни җомга.—3.12.1999.

18. Исхакый мөһаҗирлектә (Монография).— Казан: Таң-Заря, 1999.—84 б.

**Рецензияләр:** *Алсу Кәримова*. Мөһаҗирлектә дә йөрәгендә халкы булган // Шәһри Казан.— 1.10.1999.; *Булат Гали*. Язмышны җиңеп // Мирас.— 1999.— № 10.— 153—154 б.

19. «Дөньяда сүземез бар…» — Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.— 336 б.

**Рецензияләр**: *Рәфыйк Нәфыйгов*. Халык язмышы турында // Ватаным Татарстан.— 19.04.2000; *Рәдиф Гаташ*. Төрки дөньяга гашыйк галим // Заман — Татарстан.— 10.12.1999.

20. Таҗеддин Ялчыгол. Рисаләи Газизә / Әсәрне басмага әзерләүче Х.Миңнегулов.— Казан: Иман, 2001.— 480 б.

**Рецензияләр**: *Рәдиф Гаташ*. Бик газиз бу «Газизә»: Тансык «Рисалә»не укыгач // Заман — Татарстан.— 14.06.2002.

21. Хатип Усманович Усманов: к 200-летию Казанского университета.— Казань: Изд-во Казанск. унив-та, 2002.— 20 с.

22. Гаяз Исхакый. Ислам мәмләкәтләрендә (Әсәрне басмага әзерләүче, кереш мәкалә авторы Х.Миңнегулов).— Казан: Иман.— 2003.— 102 б.

1999—2003 ЕЛЛАРДА БАСЫЛГАН МӘКАЛӘЛӘРЕ*

1. Буй җитмәс шәхес (Ризаэддин Фәхреддин турында уйланулар) // Татарстан.— 1999.— № 5.— 55—57 б.

2. Милли каһарманыбыз (Р.Фәхреддиннең тууына 140 ел тулу уңаеннан) // Ватаным Татарстан.— 20.01.1999.

3. Туган якта яшәү ямьле (Дамир Гарифуллин эшчәнлеге турында) // Шәһри Казан.— 30.04.1999.

4—13. Рисаләи Газизә (транслитерация, аңлатмалар) // Мирас.— 1999.— № 1.— 20—30 б.; № 2.— 31—41 б.; № 3.— 17—29 б.; № 4.—12—23 б.; № 5.— 13—26 б.; № 6.— 13—24 б.; № 7.— 11—22 б.; № 8.— 27—37 б.; № 9.— 5—14 б.; № 11.— 5—14 б.

14. Яшәү мәгънәсенең асыл гәүдәләнеше («Олуг Мөхәммәд» драмасы) // Мирас.— 1999.— № 1.— 44—52 б.

15. Язмышлар дулкынында (Г.Исхакыйның «Дулкын эчендә» драмасы) // Мирас.— 1999.— № 2.— 53—58 б.

16. Остазыбыз Каюм Насыйри//Фән һәм тел.— 1999.— № 2.— 30—43 б.

17. Татар Сорбоннасы (КДУның татар бүлеге һәм факультеты турында) // Шәһри Казан.— 24.12.1999.

18. Әдәби герой турында китап (Р.Салихоvның «Герой и эпоха» монографиясенә рецензия) // Мәгърифәт.— 9.10.1999.

19. Гыйбрәтле тамаша (Г.Исхакыйның «Җан Баевич» комедиясе) // Мирас.— 1999.— № 5.— 38—42 б.

20. Яшьтәшләремнең берсе (Марсель Әхмәтҗанов турында) // Шәһри Казан.— 27.03.1999.

21. «Безнең Мөҗип абый» // Татарстан яшьләре.— 29.04.1999.

22. Эшләр муеннан әле (Әдәбият фәне хакында аерым фикерләр) // Заман — Татарстан.— 28.05.1999.

23. Исхакый һәм татар әдәбияты // Мәгариф.— 1999.— № 9.— 24 б.

24. Әхлак һәм әдәбият // Мәгариф.— 1999.— № 5.— 24—28 б.

25. Исхакый васыяте // Мирас.— 1999.— № 2.— 42—49 б.

26. Татар әдәбияты тарихыннан программа (1 нче кисәк. Борынгы һәм Урта гасыр әдәбияты): Югары уку йортлары өчен.— Казан: КДУ нәшр., 2000.— 21 б.

27. Ученый, педагог и писатель (О профессоре Х.Усманове) / Сб.: Фронтовики-ученые Казанского университета.— Казань: Изд-во КГУ, 2000.— С. 182—188.

28. «Казан утлары» журналы турында // Казан утлары.— 2000.—№ 1.— 150 б.

29. Дастаннар китабы (М.Әхмәтҗановның шул исемдәге китабына рецензия) // Мирас.— 2000.— № 5.— 147—149 б.

30, 31. Җаваплылык хисен тоеп (Мансур Хәсәнов турында) а) // Мирас.— 2000.— № 6.— 53—56 б.; б) Татарское Возрождение. Эпоха и личности.— Казань, 2000.— 128—133 б.

32, 33 Әдәбиятта «игү ат» мотивы а) // Мәгариф.— 2000.— № 9.— 28—30 б.; б) Җыентык: Татар теле, әдәбияты, тарихы — үткәне һәм бүгенгесе.— Казан: КДУ нәшр., 2001.— 13—24 б.

34. Бәхтияр әдип (Заһир Бигиевнең тууына — 130 ел) // Казан утлары.— 2000.— № 10.— 171—177 б.

35. Әдәбият фәненең аксакалы (Шакир ага Абилов турында) // Мәгърифәт.— 17.06.2000.

36. Милләтпәрвәрләр һәм шаһгалиләр. Һәм Г.Исхакыйның «Казан китүгә 383 ел үтде» мәкаләсе // Шәһри Казан.— 14.10.2000.

37. Мөстәкыйльлек дигән татлы сүз // Мәдәни җомга.— 25.08.2000.

38. Гыйлем дөньясына юлкүрсәткеч [Әбрар Кәримуллинның «Указатель авторефератов и диссертаций по татарской филологии по состоянию на 1998 год» китабына рецензия] // Ватаным Татарстан.— 15.09.2000.

39. Мөселманнарның икенче Мәккәсе (Төркестан шәһәре, Әхмәд Ясәви … турында. Фоторәсемнәр белән) // Ватаным Татарстан.— 27.10.2000.

40. Уяну һәм асылга кайту (Г.Исхакыйның «Өйгә таба» повесте) / Татарское Возрождение… (М.Хәсәнов эшчәнлегенә багышланган җыентык).— Казан: Фән, 2000.— 256—267 б.

41. Филология: татар теле һәм әдәбияты белгечлегеннән «Бакалавр» дәрәҗәсе алу өчен (Әлмәт муниципаль университеты) филология факультеты студентларына татар әдәбиятыннан чыгарылыш имтиханы программасы.— Әлмәт, 2000.— 32 б. (Соавтор).

42. Гасырның үзе кебек (Кави Нәҗминең тууына — 100 ел) // Мәгърифәт.— 15.12.2001.

43. Мәдәниятебезнең бер вәкиле / Айгөл Хәбибуллинаның «Госман Хәбибуллин: гыйльми һәм мәдәни эшчәнлеге» китабына (Казан, 2000) кереш сүз.— 4—6 б.

44. Мәҗнүн рухлы шагыйрь (Рәдиф Гаташ турында) // Мәдәни җомга.— 23.03.2001. Шушы ук мәкалә: Кызыл Таң.— 14. 08. 2002.

45. Г. Тукайның «Дөньяда торыйммы?— дип киңәшләшкән дустыма» шигыре // Мәгариф.— 2001.— № 4.— 16—17 б.— 0,1 т.

46. Ул безнең арада (Тукай турында) // Ватаным Татарстан.— 20.04.2001.

47. «Бөтен язмышым — шигырьләремдә» / Китапта: Әхмәт Рәшит. Библиографик мәгълүматлар.— Казан: Матбугат йорты, 2001.— 100—109 б.

48. [Хәсән Хәмидулла (Финляндия) чыгарган «Мәгърифәт» газетасы турында] : Интервью // Мәгърифәт.— 1.09.2001.

49. Бөек шагыйрь турында бөек әдип (Тукай турында Исхакый) //Мәдәни җомга.— 3.08.2001.

50. Әдәбият — заман көзгесе (Д.Заһидуллинаның «Әдәбият кануннары һәм заман» китабына рецензия) // Мәдәни җомга.— 22.06.2001.

51. «Шура»ның рухи дәвамчысы // Мирас.— 2001.— № 9.— 71—74 б.

52. Таҗеддин Ялчыгол // Мәгариф.— 2001.— № 9.— 19—20 б.

53. Низами и Кутб / В кн.: Сравнительное и сопоставительное литературоведение: Хрестоматия.— Казань: Изд-во «ДАС», 2001.— С. 312—318.

54. Газәл жанры һәм Гаташ иҗаты / Китапта: Рәдиф Гаташ. Газәлләр.— Казан: Мәгариф, 2001.— 5—11 б.

55—59. Сәйф Сараи, Шәмседдин Зәки, Гали Чокрый, Салихҗан Кукляшев, Акмулла хакында мәкаләләр / Татар календаре.— 2001 ел.

60. «Яңа милли юл» журналы һәм Тукай // Казан утлары.— 2002.— № 1.— 168—179 б.

61. Исхакый васыятенең иясе (Халидә Вафина турында) // Казан утлары.— 2002.— № 6.— 178—185 б.

62. Сания Гыйффәт. шигырьләре (публикация) // Мирас.— 2002.— № 11.— 9—14 б.

63. Татар әдәбияты кафедрасы /Фәнни язмалар: 2001.— Казан дәүләт университеты татар филологиясе һәм тарихы факультеты.— Казан: Школа, 2002.— 175—179 б.

64. Мы все «сыны Адама…» / Фәнни язмалар: 2001.— Казань.: Школа, 2002.— С. 242—246.

65. Тукай турында Исхакый кызы / Фәнни язмалар: 2001.— Казань: Школа, 2002.— 246—253 б.

66. Инсанлылык өлгесе (Проф. В.Хаков турында) // Шәһри Казан.— 6.08.2002.

67. Әдәбият фәненең бүгенге торышы (Язучыларның XIV корылтаен каршылап) // Шәһри Казан.— 31.05.2002.

68. Исхаки о падении Казани // Звезда Поволжья.— № 8 (112).— 28.02.— 6.03.2002.

69. «Гомер бушкарак үтте» (Тормыш, милләт, әдәбият турында уйланулар): Интервью // Атна (Уфа).— 2.03.2002.

70. Асыл якның асыл улы (Проф. А.Әхмәдуллинга — 70 яшь) // Ватаным Татарстан.— 15.10.2002.

71. Татарның киләчәге — татарда // Шәһри Казан.— 24.08.2002.

72. Яшәешебезгә туры килешле бэгланыш (Төркестан шәһәрендә узган I Халыкара тюркологик конгресс уңае белән) // Шәһри Казан.— 6.11.2002.

73—74. Мәхәббәт һәм нәфрәт шагыйре (Әдхәд Синугыл турында)

а)//Кызыл Таң.— 17.08.2002.; б) Шул ук мәкаләнең кыскартылган варианты Әдхәд Синугыл-Куганаклының «Иман гасыры» китабына кереш сүз рәвешендә дә бирелгән.— 5—11 б.

75. «Мәгариф» нәшрияты турында // Мәгърифәт.— 6.11.2002.

76. «Каюм баба»ның дәвамчысы (Проф. Р.Ганиевага — 70 яшь) // Шәһри Казан.— 6.12.2002.

77. Татарская литература дооктябрьского периода в контексте межлитературных взаимосвязей (Сопоставительная филология и полингвизм: Материалы Всероссийской научно-практической конференции. Казанский госуниверситет, 29—31 октября 2002 г.).— Казань: Школа, 2002.— С. 357—360.

78. Тукай һәм Шәрык әдәбиятлары / «Творчество Тукая в контексте евразийской культуры» җыентыгы / Академия наук Татарстана. ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова.— Казань: Фикер, 2002.— 95—107 б.

79. Мөхәммәдьяр // Сөембикә.— 2003.— # 1.— 14—15 б.

80. Сулмас гөлләрнең берсе (Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре язылуга 660 ел) // Казан утлары.— 2003.— # 1.— 160—168 б.

81. Мөһаҗирнең җан авазы (Алманиядә — татар журналы) // Татарстан.— 2003. — # 2.— 58—62 б.

82. «Азат Ватан»: скорбь и надежда (Татарский журнал в Германии) // Татарстан.— 2003.— # 2.— С. 58—62.

83. Рухи асылына кайту / И.И.Ганиев. Фәлсәфи фикер: белешмә-сүзлек / Фәнни редакторы — Х.Й.Миңнегулов.— Казан: Мәгариф, 2003.— 199—203 б.

84. Игелек иясе (Хуҗиәхмәт Мәхмүтов турында) // Мәдәни җомга.— 14.02.2003.

85. Әдәбият фәненең мөһим мәсьәләләре (Э.Г.Галиеваның «Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе» китабына рецензия) // Шәһри Казан.— 14.02.2003.

86. [Гаяз Исхакыйның тууына 125 ел.] Шунда ук: Г.Исхакыйның «Әдәбият һәм нәшрият» мәкаләсе // Мәдәни җомга.— 21.02.2003.

87. Гаяз бабайның мәсләки кыйбласы. Шунда ук: Г.Исхакыйның «Тел мәсьәләсе» исемле мәкаләсе// Шәһри Казан.— 21.02.2003.

88. Узган гасыр каһарманнарының берсе (Галим һәм әдип Ибраһим Нуруллинның тууына — 80 ел) // Шәһри Казан.— 18.04.2003.

89. К национальному согласию и равноправию / Модернизация современного образования в школе: проблемы, поиски, перспективы. Сборник научно-методических материалов Минобразования РТ и ИПКРО.— Казань, 2003.— С. 348—355.

## Х.Й.МИҢНЕГУЛОВ ТУРЫНДАГЫ ЯЗМАЛАР*

1. Республиканың «Мактау китабы»на кертү турында КПСС өлкә комитеты карары // Соц. Татарстан.— 14.08.1966; Советская Татария.—14.08.1966.

2. *Гөлтән Бәдретдин* (Хельсинки). Рәхмәтебез ирешсен…// Соц. Татарстан.— 6.05.1990.

3. *Илбарис Надиров.* Фәнгә яңа сәхифәләр (Финляндиягә гыйльми командировка нәтиҗәләре): Интервью // Татарстан.— 1992.— № 11—12.— 69—75 б.

4. *Әхмәт Сәхапов.* Тынгысыз гомер юлы // Мирас.—1994.— № 5—6.—11—12 б.

5. *Нияз Субаев-Казанлы*. Күмәк күч тау күчерә (Мөһаҗир татарларны өйрәнү турында) // Шәһри Казан.— 16.07.1994.

6. Язучы-академик//Казан утлары.—1996.—№10.—192 б.; Мирас.—1996.— № 12.— 84 б.

7. *Ә. Җиһаншина.* Тынгысыз гомер юлы // Новый Зай.— 26.10.1996.

8. *Гөлнур Айзатуллова*. Академик Хатыйп Миңнегуловка: Шигырь//Мәгърифәт.— 21.03.1997.

9. *Дамир Гарифуллин*. Олуг талант иясе // «Сарман» газетасы.—19.08.1997.

10. Тюркологи современного Татарстана: Справочник / Под редакцией *Ф.С.Хакимзянова*.— М., 1997.— С. 31—32.

11. *Фирдәвес Зариф*. Мирасыбызны өйрәнүче галим//а) Х.Миңнегуловка мөнәсәбәтле библиографик мәгълүматлар // Мирас.—1997.—№ 1—10.— 105—109 б.; б) Новый Зай.— 22.05.1999.

12. Хатыйп Миңнегуловның «Читтә яшәүче милләттәшләребезнең мәдәни вә сәяси эшчәнлеге»н яктырткан фәнни хезмәтләре өчен Кол Гали исемендәге Халыкара премиягә тәкъдим ителү һәм бирелү уңае белән басылган материаллар: а) Мәдәни җомга.—24.07.1998; Шәһри Казан.—21.07.1998; б) Кол Гали бүләге тарихны зурлый // Шәһри Казан.—7.08.1998; Котлыйбыз // Мәдәни җомга.— 7.08.1998; Сабантуй.—19.08.1998; Мирас.— 1998.— № 10; Академикам вручены награды // Республика Татарстан.— 7.08.1998; Кол Гали премиясе лауреатлары // Казан утлары.— 1998.— № 9.— 191 б.

13. Х.Миңнегуловка «Халыкара ел кешесе» исеме бирелү (Англия, Кембридж) уңае белән дөнья күргән язмалар: Халыкара биографик үзәкнең рәсми хаты (инглизчә һәм татарча тәрҗемәдә) // Мирас.— 1998.—№10.— 152—153 б.; Милләтәшебез — «Елның халыкара кешесе» //Ватаным Татарстан — 28.07.1998; А.Изморосин. Казанский ученый — «Человек года» // Республика Татарстан.— 30.07.1998; Хатыйп аганы дөнья таныды // Шәһри Казан.— 31.07.1998; Англиядән сөенечле хәбәр… //Сабантуй.— 12.08.1998.

14,15. *Шакир Абилов*. а) Әдәби мирас дәресләре (Татарстан радиосыннан барган «Мирас» тапшырулары турында)// Ватаным Татарстан.—18.02.1998; б) Әдәбият белеменең имән баганасы // Татар иле.—Июль, 2000.

16. Татарский энциклопедический словарь.— Казань, 1999.— С. 310.

17. «Дөньяда сүземез бар».— Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.— 314—322 нче битләрдә — биографик белешмә, 322—335 нче сәхифәләрдә — Х.Миңнегулов хезмәтләренең һәм аның турында язмаларның библиографиясе.

18, 19. *Флорид Әгъзәмов.* а) Кылны кырыккы ярган // Мәгърифәт.— 19.11.1994; б) Эшсөяр // Татарстан.— 1999.— № 5.— 54 б.; в) Открытия «Человека года» // Казанские ведомости.— 20.05.1999.

20. *Фоат Галимуллин*. Әдәбиятыбыз тарихына ачкыч // Ватаным Татарстан.— 7.05.1999.

21. *Әнвәр Шәрипов*. а) Гасырлар катламын сөргәндә… // Мәдәни җомга.— 7.05.1999; б) Хезмәт иясе — хөрмәт иясе // Зәй офыклары.—8.15.05.— 1999.

22. *Р.Исламов*. Галим, мөгаллим һәм остаз // Казан утлары.— 1999.—№ 4.— 156—160 б.

23. *Флера Сафиуллина*. а) Призвание — его наука // Казанский университет.— Май.— 1999г.; б) Одержимость познанием // Республика Татарстан.— 14.05.1999.

24. *Марсель Әхмәтҗанов*. Галим диган бөек исем // Шәһри Казан.—21.05.1999.

25. *Равил Әмирхан*. Гыйлем һәм остазлык юлында // Татар иле.— Май.— 1999.

26. *Рифә Рахман*. Күңел күгендә йолдызлар // Мәгърифәт.—8.05.1999.

27. *Рәдиф Гаташ*. Шагыйрь җанлы галим дустым // Мирас.— 1999.—№ 5.— 71—72б.

28. *Резедә Ганиева*. Хезмәткә мәдхия // Мирас.— 1999.— № 5.— 67—70 б.

29. *Ирина Апачева*. Без дә «әлмәтле» дибез // Әлмәт таңнары.—22.06.1999.

30. *Иринә Мөрсәлим*. Алтын җирдән, галим илдән чыга // Заман —Татарстан.— 14.05.1999.

31. «Януларым, көюләрем гел синең өчен генә…» Туган тел!: Интервью (Йолдыз Шәрапова) // Сабантуй.— 15.05.1999.

32. *Камил Якупов*. Татар зыялылары: Хатыйп Миңнегулов // Мирас.— 1999.— № 12.— 54—55 б.

33. [Х.Миңнегулов турында редакцион мәкалә] // Мәгариф.— 1999.— № 5.— 24 б.

34. *Айсылу Галиева*. Кол Галиләр заманы белән чагыштырганда (Интервью) // а) Ялкын.— 1999.— № 11.— 24—25 б.; б) Зәй офыклары.—1.01.2000.

35. Сарман районы энциклопедиясе.— Яр Чаллы: «Идел-йорт» нәшр., 2000.— 119 б.

36. Н.Галиев. Казан галиме янә Суомида // Ватаным Татарстан.—25.08.2000.

37. Татар галиме турында // а) Ватаным Татарстан.— 28.03.2000; б) Казан утлары.— 2000.— № 5.— 192 б.

38. *Нәгыйм Мөхибуллин*. Онытылмас сабаклар («Мирас» радиотапшырулар циклы турында) // Шәһри Казан.— 14.01.2000.

39. Татарстан Президентының «Мактау грамотасы» белән бүләкләнү турында Указ // Ватаным Татарстан.— 22.03.2000; Республика Татарстан.— 23.03.2000; Мәдәни җомга.— 24.03.2000.

40. Татарстан делегациясе Төркестандагы юбилейда // Ватаным Татарстан.— 24.10.2000; Республика Татарстан.— 24.10.2000.

41. Кызыклы очрашу // Саба таңнары.— 7.06.2000.

42. *Әдхәд Синугыл-Куганаклы*. Борынгылар чишмәсе: (Борынгы төрки-татар әдәбияты галиме Хатыйп Миңнегуловка) // Ватаным Татарстан.— 22.02.2002.

43. *Рәүф Идрисов*. «… Әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов — бездә кунакта» (Интервью) // Атна (Уфа).— 2.03.2002.
44. [Биографические сведения] Кто есть кто: Авторы издательства «Магариф».— Казань: Магариф, 2002.— С. 69.
45. *К. Камал*. Якташым, яшьтәшем // Зәй офыклары.— 11.01.2003.
46. *Рәдиф Гаташ*. Милли аң сакчыларыннан берсе; Шагыйрь җанлы галим дустым; Төрки дөньяга гашыйк галим; «Белер Сәйф Сараи гыйшык рәсмен!»/Шигърият, синең хакка!..— Казан: Мәгариф, 2003.— 125, 132, 157, 160 б.
47. *Лариса Яруллина*. Әдәбият галәмендә // «Мәйдан».— 2003.—# 5.— 132—135 б.

**ЭЧТӘЛЕК**


**Үткәнгә күзе җиткәннең**
**Киләчәккә дә җитә**

Татар әдәбияты тарихына бер караш .......................................
«Арпасыз ат ашумас» ........................................................
Әдәбиятта «игү ат» мотивы ................................................
Әхлак һәм әдәбият ..........................................................
«Кисекбаш китабы» .........................................................
Гаделлек һәм хаклык җырчысы ..........................................
1. Шәһре Казан шагыйре Мөхәммәдьяр .........................
2. «Ярмөхәммәд, сүзне тугры сүзләгел» .........................
Затлы инсан Колшәриф .......................................................
Таҗеддин Ялчыгол һәм аның «Рисаләи Газизә» әсәре .............
Шәмседдин Зәкинең шигъри дөньясы ..................................
«Күңелне сафламак дәвадыр» ..............................................
1. Милли каһарманыбыз ..............................................
2. Буй җитмәс шәхес ..................................................
3. Ризаэддин Фәхреддин — әдип һәм әдәбиятчы .............
Бәхтияр әдип .....................................................................

**Һич картаймый шагыйрь иҗаты**

Тукай безнең белән ...........................................................
Тукай сабаклары ...............................................................
Тукай һәм Шәрык әдәбияты ...............................................
«Яңа милли юл» журналы һәм Тукай .................................
«Тукай энциклопедиясе» сәхифәләренә ...................................
1. Шагыйрь әсәрләре турында .......................................
2. Тукай кулланган жанрлар ......................................
3. Шагыйрь иҗаты белән бәйләнешле авторлар һәм журналлар ..................................................................

**Заманны инсаннар тудыра**

Әдәбият фәненең бүгенге торышы ........................................
Гыйлем дөньясына юлкүрсәткеч .............................................
Әдәбият фәненең аксакалы .................................................
Узган гасыр каһарманнарының берсе ...................................
Инсанлылык өлгесе ............................................................
«Каюм баба»ның дәвамчысы ..............................................
Асыл якның асыл улы .........................................................
Игелек иясе .....................................................................
Үткәнне бүгенгегә ялгаучы .................................................
1. Яшьтәшләремнең берсе ..............................................
2. Әлмәт ягы — дастаннар ватаны ..................................
«Күрик күрәчәкне, белик беләчәкне» .......................................
1. Мәҗнүн рухлы шагыйрь ..........................................
2. Робагый жанры һәм Гаташ .......................................
Мәхәббәт һәм нәфрәт шагыйре .............................................
Рухи асылына кайту ...........................................................
Төркестан — мөселманнарның икенче Мәккәсе .......................
Татарның киләчәге — татарда .............................................

Биобиблиографик белешмә ...................................................

Учебное издание

*Миннегулов Хатип Юсупович*

ВСЛУШИВАЯСЬ В ГОЛОСА ВЕКОВ...

(*на татарском языке*)

Редакторы *И.И.Кадыйрова*
Тышлык рәссамы һәм бизәлеш редакторы *Р.А.Сәйфуллина*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Л.М.Тилк*
Корректорлары *Р.Ә.Фәйзуллина, Г.Г.Мөхәммәтҗанова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчеләр
*Э.Ф.Нурмөхәммәтова, Л.Р.Вафина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 13.01.2004.
Форматы 60ә90 $^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе.
«Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Басма табагы 21,0. Нәшер-хисап табагы 18,2.
Тиражы 2000 д. Заказ С-278.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48
http: //magarif. kazan. ru
E-mail: magarif @mail. ru

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.